017


ISSN 0206-4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

2.2004



# ЯҢА КИТАПЛАР




**Без көрәшле халык.** Автор-төзүче— **Илдус ИЛДАРХАНОВ.**—Казан: "Гасыр" нәшр., 2003.—400 бит. Тиражы—2000 данә.

Татар халкының милли бәйрәме Сабантуй хакында әдәби китаплар, гыйльми хезмәтләр, методик белешмәләр байтак язылган. Ә Сабантуйның төп бизәге, кульминацион ноктасы, әлбәттә, көрәш. Көрәштә җиңеп чыккан көрәшче Сабантуе каһарманы, ил батыры булып халык күңеленә кереп калган. Бу китап, нигездә, әнә шул батырлар турында. Китап авторы—күренекле журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Илдус Илдарханов китап-альбомның ничек дөньяга килүе турында болай яза: "Бер ел элек республиканың Татар-башкорт милли спорт көрәше федерациясе җитәкчесе Марат Готыф улы Әхмәтов көрәшебезгә, зур батырларыбызга багышланган китап яки альбом әзерләү бурычын куйган иде. Бу эшкә алынып, мин ул чакта көрәшчеләргә, бу хәрәкәтне оештыручыларга үзләрендә булган истәлекләр, фоторәсемнәр белән уртаклашуны үтенеп мөрәҗәгать иттем. Тиз арада миңа якын фоторәсем тупланды, төрле елларда чыккан газеталар, журналлар өйрәнелде. Нәтиҗәдә менә шушындый хезмәт туды".

Чыннан да, татар көрәше, аның батырлары турында документаль зур хезмәт туган. Һәрхәлдә соңгы ярты гасыр тарихында көрәш буенча якты эз калдырган шәхесләр турында шактый тулы мәгълүмат алып була бу китаптан. Шулай ук, ераграк тарихтагы күренекле затлар тормышыннан да кызыклы, моңарчы күпләр белмәгән фактлар искә алынган. Мәсәлән, мәшһүр галим Шиһап Мәрҗани хәзрәтнең, күренекле тарихчы Һади Атласиның заманында атаклы көрәшчеләр дә булганын бик азлар белә булыр…

Көрәш—интеллектуаль хезмәттән, әдәбияттан ерак кебек тоелса да, төптәнрәк уйласаң, алар бер-берсе белән бик керешкән; көрәш мотивлары язучыларыбыз әсәрләрендә бик күп урын алган. Бу китап-альбом тукымасында да бүгенге байтак шагыйрьләрнең шигырьләре файдаланылган. Китап ахырында аларның исемлеге дә бирелгән: Клара Булатова, Лена Шагыйрьҗан, Мөдәррис Әгъләмов, Равил Фәйзуллин, Разил Вәлиев, Рашат Низамиев, Ренат Харис, Роберт Миңнуллин, Салисә Гәрәева, Харрас Әюпов.

Китап-альбом зур форматта, яхшы ялтыравыклы кәгазьдә, төрле төсләр белән бизәлеп нәшер ителгән. "Без көрәшле халык" китабы татар көрәшенә битараф булмаган һәр кеше кызыксынып укырлык һәм карарлык күркәм басма булып чыккан.

# Казан утлары
# Qazan utları

2004

2

(976)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Диләрә Максутова, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
**Факс** — (8432) 43-56-12.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**


Фәнис ЯРУЛЛИН. Туган як түсе. Шигырьләр ........ 5
Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Карга короле. Роман ........ 9
Мөдәррис ӘГЪЛӘМ. Культуралы катлам. Шигырьләр ........ 80
Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ. Кылдан нәзек, кылычтан үткен. Роман ........ 84
Илсөяр ИКСАНОВА. Күңел дигән дөньяда... Шигырьләр ........ 124
Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. Хикәяләр ........ 128
Роза ХАФИЗОВА. Картлыктамы хикмәт? Хикәя (А. Гыймадиевнең кереш сүзе белән) ........ 136


**ПУБЛИЦИСТИКА**


Мирфатыйх ЗӘКИЕВ. Милли хәрәкәтнең максаты — милләтне тергезү, саклау һәм үстерү ........ 139


**ДИСКУССИЯ: "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"**


Радик ФӘИЗОВ. Алар безнең арада ........ 149


**ФӘН**


Марсель БАКИРОВ. Иң борынгы шигырь нинди булган? ........ 155
Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге ........ 173


**ШӘРИФ КАМАЛНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ**


Фәрит БӘШИР. Кошларда да кеше язмышлары ........ 177


**КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ**


68 — Каләм (Каләм) сүрәсе ........ 182
69 — Хакка (Котылгысызлык) сүрәсе ........ 183

Безнең календарь ........ 185
"Казан утлары" архивыннан ........ 186
Берлекнең яңа әгъзалары ........ 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 189

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": роман Р. МИР-ХАЙДАРОВА "Масть пики" (продолжение), роман А.ГИЛЯЗОВА "Тоньше струны, острее меча" (окончание), рассказы Ф. ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ; стихи Ф. ЯРУЛЛИНА, М. АГЪЛЯМОВА, И. ИКСАНОВОЙ.
"К 75-летию Р. Хафизовой": рассказ Р. ХАФИЗОВОЙ "Старость не порок".
"Публицистика": статья М. ЗАКИЕВА "Цель национальной политики—возрождение нации".
"Дискуссия: "Герой нашего времени": статья Р. ФАИЗОВА "Они среди нас".
"Наука": статья М. БАКИРОВА "Каким был самый древней стих?" и А. ТИМЕРГАЛИНА "Словарь нации".
"К 120-летию Шарифа Камала": статья Ф. БАШИРОВА.
Коран на татарском языке.
В номере отмечается 90-летие Фарита Яруллина.
Новые члены союза писателей.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Сергей ШИРОКОВ. "Загулявшие". Из коллекции Рауля Мир-Хайдарова; поэт Нияз Акмал.

## IN THIS ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": R. MIR-HAJDAROV'S novel "Colour peaks", A. GILJAZOV'S novel "More thin than a string sharper than a sword", F. ZAMALETDINOVA'S stories; verses by F. JARULLIN, M. AGLJAMOV, I. IKSANOVA.
"To R. Hafizova"s 75-anniversary": story by R. HAFIZOVA "Old age is not a vice".
"Publicism": article by M. ZAKIEV "Purpose of a national policy—revival of the nation".
"Discussion: "Hero of our time": article by R. FAIZOV "They are among us".
"Science": articles by M. BAKIROV "What was the most ancient verse?" and A. TIMERGALIN "Dictionary of the nation".
To 120-anniversary of S.Kamal, article by F. BASHIROV.
Al Quran in the Tatar language.
90-anniversary of Farit Yarullin is marked in this issue.
New members of the union of writers.
From a photoarchive of the magazine.
Diary of a public-cultural life.
On our covers: Sergey SHIROKOV. "Gone on a spree" from collection of Raul Mirkhaidarov; poet Nijaz Akmal.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 20.01.2004 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8029. Заказ Э—34
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2004 ел.



## Фәнис Яруллин

### ТУГАН ЯК ТӨСЕ

Туган якларыма кайтып барыш,
Яшел әле кырда бодай, арыш.
Урманнардан, кыр һәм басулардан
Күзләремә тула яшел балкыш.

Якынайган саен авылыма,
Таныш тавыш ишетелә ныграк.
Дулкын-дулкын булып кайнар тавыш
Җанга тула тамырларым буйлап.

Шушы тавыш мине биләп ала,
Мин кушылам аңа эчтән генә.
Туган якларымның тавышы да
Тора, ахры, кайнар хистән генә.

Тиктомалдан йөрәк ярсый башлый,
Күмелеп яткан хатирәләр ташый.
Һәр хатирә әверелә дә кошка,
Юлларыма ап-ак каурый ташлый.

Каурыйларны җыям учларыма,
Каурый түгел, гүя моңнар җыям.
Туган якларымның моңнарына
Никадәрле кайнар уйлар сыйган!

Хәер, нигә кайнар булмасын ул,
Суынырга юк бит аның хакы.
Без яшьлекне ягып калдырдык бит
Җылытырга туып-үскән якны.

---

Фәнис ЯРУЛЛИН (1938)–*Татарстанның халык шагыйре; прозаик, драматург, публицист; күпсанлы китаплар, шул исәптән 3 томлык Сайланма әсәрләр авторы. Казанда яши.*

Туган якларыма кайтып барыш,
Өлгермәгән әле кырда арыш.
Изүләрне киереп ачып куям—
Йөрәгемә тула кайнар тавыш.

*

Болытларга яшен тамыр җәйде,
Яшен тамыры кандай кып-кызыл.
Кызыл җепне йомгак итеп урап
Булыр төсле, күккә тик сузыл.

Укмаштырды җилләр болытларны,
Һаваларда төсләр куерды.
Ниндидер көч кара йодрык белән
Яшен болытына тондырды.

Күкрәде күк. Кара калын тавыш
Дер селкетте биек тауларны.
Ә аннары, ташлар коелгандай,
Бүлгәләнде тавыш, таралды.

Сибелеп китте бөтен тирә-якка
Кызыл, сары, зәңгәр тамчылар.
Йокымсырап яткан барлык гөлләр
Сискәнешеп торып бастылар.

Кинәт кенә булды болар барсы—
Әйтерсең лә тик бер минутта.
Төсле челтәр булып эленеп калды
Салават күпере ерак офыкта.

Уйнады да тынды зур оркестр,
Дирижеры әллә ялгышты—
Озак кына ишетелеп торды
Чәчәкләрнең флейта тавышы.

*

Су буенда көй өйрәнә
Сынган камыш.
Кыл булып күккә сузылган
Нәзек тавыш.

Камыш эчендә гүяки
Нәни бер кыз.
Ыңгырашып аваз сала
Чиртеп кубыз.

Көй көчәеп китә кайчак—
Көрәя моң.
Һаваларга агыла башлый
Аксыл дулкын.

Сайрар кошлар моң-дулкында
Йөзә башлый.
Җыр елгасы ярга сыймас
Булып ташый.

Сынык камыш бер тына да
Тагын сыза.
Ниләр булды икән соң бу
Камыш-кызга?

Нәни кызчык, сынык камыш—
Моң оясы.
Әллә китеп югалганмы
Су анасы?

*

Кызыл алма җырлый икән
Карап кичке кояшка:
—Син батасың, мин каламын
Төнгә, сиңа алмашка.

Эчтем синнән кызыл нурлар,
Кызыл җырлар, ал җырлар.
Мин җырлармын ул җырларны,
Һәрбер уяу җан тыңлар.

Аккан сулар алып китәр
Җырларымны еракка.
Җилләр элеп куяр аны
Былбылы юк куакка.

Җилфер-җилфер итеп торыр
Яфракларда җырларым.

Ал нурларга манармын мин
Төннең кара уйларын.

...Шулай дип җырлаган алма
Уянганчы таң кошы.
Таралган җиһанга аның
Сопрано тавышы.

*

Урман авызында сынык усак,
Ватык гармун кебек тавышы.
Яфрак булып өзелә каты җилдә
Тамырлардан килгән сагышы.

Тик яфраклар җиргә төшеп җитми,
Җилләр ала барсын күтәреп.
Җиде төскә мана җилләр аны,
Салават күпере аша үткәреп.

Очып китә усак яфраклары
Кошлар кебек тезелеп, чөй ясап.
Җырлый башлый башка тавыш белән
Давылларда сынган бу усак.

Көй җәелә катлам-катлам булып,
Көй тарала күккә, киңлеккә.
Күзе барлар аны күрә ала,
Колаклары барлар ишетә.

Ә мин шушы сынык усак җырын
Әйләндерәм серле келәмгә.
Һәм уйларны төяп җибәрәмен
Таралсын дип бөтен галәмгә.

*

Эзләдем сине, эзләдем,
Таба алмадым озак.
Син үтәр, дип сукмакларга
Җырлардан кордым "тозак":

Шул "тозак"ның өсләренә
Иң матур гөлләр аттым.
Гамьсез генә барган чакта
Син шунда китереп бастың.

"Зың" итеп куйды йозагым,
Чыгарып тимер чыңы.
Сизми дә калдым, үзгәрде
Синең җаныңның моңы.

Тоткын мәхәббәт тавышы
Билгеле, елак иде.
"Тозагым" кулда булса да
Син миннән ерак идең.

*

Елга—ярсу симфония,
Дирижеры—таллар.
Мең төскә бай музыканы
Сыйдыра алмый ярлар.

Күккә сикерә миллион тамчы,
Нурга манып ярны.
Сибелә җиргә музыканың
Барлык ноталары.

Ә ноталар бик күп монда,
Түгел җиде генә.
Һәрбер тавыш бер төс булып
Сеңә күңелемә.

Күккә суза муеннарын
Басудагы гөлләр.
Тавышны төсләргә манып
Нота яза җилләр.

Иң югары ноталарны
Ала былбыл гына.
Барып куна былбыл җыры
Таулар кыегына.

Елга—таулар, басу—кырлар,
Мәгърур симфония.
Таулар җырлый, алар да бит
Бас тавышка ия.

*

Көтмәгәндә бер болытны
Яшен килеп кисте.
Таралды бөтен һавага
Тәмсез көек исе.

Бу ис йөрде җир өстендә
Булып кара шәүлә.
Кемнәрнеңдер гөнаһлары
Яндымы соң әллә?

*

Тауларның иң биегендә
Кызынып яттым.
Кулларны җәеп як-якка
Болыт булып актым.

Күкнең зәңгәр диңгезендә
Чайкадым җанны.
Беразга бөтен тәннәрем
Җиңеләеп калды.

*

Урманда аю, бүреләр
Беткән инде, беткән.
Тик тимер тешле аждаһа
Кимерә аны төптән.

Тимер аждаһа тавышы
Ачы, шомлы, зәһәр.
Һәрбер яфрак дер калтырап
Укый аңа каһәр.

Кара урманнар юк хәзер,
Ул агарып бара.
Кытыршы тел белән гүя
Ул яланып бара.

Кошлар оя корыр өчен
Урын таба алмый.
Туган ояларның җирдә
Мамыклары ауный.

Ул мамыклар мышык-мышык
Елап ята төнлә.
Тишелмәгән йомыркалар
Ауный тирә-юньдә.

*

Туган якларымнан китеп барыш,
Урылып беткән инде бодай, арыш.
Шәрәләнеп калган басу-кырлар,
Башка уйлар инде, башка сагыш.

Басу-кырга юеш җилләр хуҗа,
Юеш җилләр елак җырлар суза.
Җилләр тавышын ераккарак куып,
Тезелешеп ак торналар уза.

Кабалана-кабалана яшәп,
Гомер агышын ашыктыра кеше.
Җыр-моңнарга яңа төсләр өстәп,
Кызулана Җирнең әйләнеше.

*Баулы, 2003*

**Рауль Мирхәйдәров**

## КАРГА КОРОЛЕ

**РОМАН**

Прокурор сүрән яктыртылган бүлмәгә килеп керде, лампалар балкыган коридордан соң күзе тышта калгандай иде, ул хәтта стена янындагы курпачта хәл җыеп яткан кешене абайламады. Күзләр бераз ияләшә төшкәч, сәламләү өчен якынлаша башлауга, тегесе, авыр гәүдәсен җиңел генә ыргытып күтәрелде һәм каршы атлады. Йөзендә алтын тешле елмаю чагылды.

Карден, Хуго Босс, Бернард ле Рой, Ги ля Рош, Карвеннарың бер якта торсын,—дип эчтән генә көлемсерәде Сенатор. Аксайда моданы менә кем кертә икән. Аксай номенклатурасының ник алтын тешле булуы аңлашылды. Алар бүлмә уртасында очраштылар һәм кул кысыштылар.

—Дастарханга рәхим итегез,—дип, хуҗа кыска бармаклы кулы белән табынга ишарәләде.

Шул арада Сухроб тирә-ягына күз ташлап өлгерде. Бүлмә шәрекъчә бизәлгән, ник бер өстәл яисә урындык булсын, монда, гомумән, мебель юк, тирә-якта келәмнәр, курпачлар, мендәрләр патшалыгы. Розарийга караган зур тәрәзәләр шар ачык, күрәсең, хан кондиционер яратмыйдыр, ләкин залда салкынча иде, көндез, мөгаен, борынгы гадәт буенча, идәнгә бозлы су тутырылган ләгәннәр куеп торганнардыр.

—Алла хакы өчен, көттергәнем өчен гафу итегез,—диде Акмал-әкә стена яныннан элеккеге урынын алып.—Эш муеннан, барысын кайгыртырга кирәк. Нишлисең, үзгәртеп кору заманасы. Яңа хакимият тә безгә байракларның юкка гына бирелмәгәнлеген аңласын, дип тырышабыз инде.—Һәм ул башы белән кунак утырган яктагы стенага ымлап куйды.

Сенатор ирексездән борылып карады, җете кызыл төстәге келәм асылган стена янында бихисап байраклар тезелгән иде, уканы җәлләмичә алтын җепләр белән чигелгән бәрхет комачларны идәндәге сапларыннан гына санап булыр иде, ләкин санамыйча да аларның күплеге хәйран калдыра, беренче тәэсир шундый иде. "Әйе, очрашу урынын шәп сайлаган бу,—дип уйлап куйды прокурор.—Авторитеты белән авызны томаларга телиме? Шайтан белсен..."

—Сезнең килүегез турында әле генә әйттеләр, иртәдән бирле обкомда... Наманганга барырга туры килде, әле генә кайттым. Үпкәләмәгез, һәркемнең

---

*Дәвамы. Башы 1 санда.*

үз начальствосы. Аларга миндә ҮК кешесе бар дип әйтә алмыйм ич инде, казынуларын яратмыйм, кем ул, нишләп йөри, нишләп без ул хакта белмибез, дип төпченә башларлар.—“Күз бууучы” җанын бораууларга теләгәндәй итеп прокурорга карап алды, сүзләренең кунакка ничек тәэсир итәсен бик беләсе килә иде аның.

Сенатор ваемсыз тыныч кыяфәтен саклап кала алды, чөнки ханның өстенлекне үз ягына аударырга җыенуын, сүзләр белән бик оста капшап маташуын сизенгән иде инде. Акмал-әкәгә, шиксез, бу визит артында кемнәр торуын чамалау мөһим. Әле кибеп тә җитмәгән чәчләре, бераз шешенкерәк төс алган йөзе директорның ял итеп ятуы, күптән түгел генә бассейнда коенып чыгуы турында сөйли иде. Ләкин, ни генә булмасын, прокурор аңа ышанган кыяфәт чыгарды.

—Аңлыйм, Акмал-әкә, аңлыйм, иң башта эш, шунсыз булмый. Хәер, мин сезгә шәхси йомыш беләнрәк килгән идем. Ә болай үпкә-сапкам юк, вакытны бик матур уздырдым, рәхмәт яусын. Сездәгедәй шакккаткыч бассейн белән сауна Ташкентта да сирәктер.

—Тырышабыз инде. Аксайда безгә һәр кунак кадерле, нишләп, Сухробҗан, элегрәк килеп чыкмадыгыз?—диде “Күз бууучы”. Сорау төбендә икенче мәгънә дә ачык тәгаенләнә иде.

Сенатор сүз башында ук йорт хуҗасын төпкә утыртырга җыена иде, шуңа күрә, боргаланмый гына җавап бирде:

—Элек килә алмый идем. Вазифам кушмый иде. Сез бит барысын да болай куанып каршы алмый идегез. Хәзер менә миңа да Аксайга килеп күренер вакыт җиткәндер дип белдем. Ничек яшәвегезне күрәсем килеп китте, сезнең хакта күп ишеткән бар...

Аның җавабы “Күз бууучы”ны уйга калдырды булса кирәк, ул әйтергә сүз таба алмыйчарак торды. Прокурор Аксайда мода урнаштыручы ханның тагын бер йомшак ягын сизеп алды.

Җавапны шактый озак көтәргә туры килде.

—Кунакларга без һәрвакыт шат, үзегез дә ышанырсыз, диде, ниһаять, хан.—Яңа заман, яңа кешеләр... Кызганыч, сезне элегрәк белмәгәнмен. Дөрес, мәкаләләрегезне газеттан укыганым бар. Алар монда да шау-шу кубардылар. Сезнең өчен сөенеп туя алмадым, бездә дә хокук гыйлеме сүрелмәгән икән дип горурландым да әле. Барысы да Мәскәүдән генә килергә тиеш түгелдер бит. Мин һәрчак сезнең кебек кешеләр өчен тау булып күтәрелдем, булышып яшәдем. Монда булмавыгыз сезнең гаеп түгел, сәләтле кешене алып килә белмәүчеләр гаебе, юкса андыйлар бездә һәрчак ярдәм һәм аңлау таба иде. Борын төбендәгене генә күрә белүчеләр Аксай республика өчен үзенең мәгънәсен-кирәклеген югалтты дип, нык ялгышалар, андыйлар еракка карый алмый... Сезнең килүегезгә мин чынлап та шатмын, Сухроб.

Һәм, аек баштан сөйләшүнең куркыныч төс ала башлавын чамалап булса кирәк, ул учын учка сукты, шул ук минутта бүлмәгә Мәүлидә һәм тагы бер чибәр кыз килеп керделәр. Алар тиз генә чәйнек-чынаякларны җыештырдылар, шакмаклы ашъяулык өстенә тагы берне, кардай ап-агын җәйделәр һәм дастарханга төрле кабымлык, салат, җиләк-җимеш тезә башладылар. Иң соңыннан подноска ике шешә затлы коньяк һәм рюмкалар куеп телсез карт килеп керде. Шәригать кануннары кызларга хәмергә кагылырга кушмый. “Ханның инсафлылык күрсәтергә азаплануы инде монысы,—дип эчтән генә көлемсерәде аның гадәтләрен яхшы ук белгән Сенатор—Коръәнне йөз тапкыр гына бозмагандыр инде, юкса”. Күрәсең, тамаша аның өчен уйнала иде, әйдә, янәсе, шәһәр корты, Акмал ханнан өйрән чын халык йолаларына.

Берләшмә директоры коньякны үзе бүлде, мөлдерәмә тулы рюмканы кунакка таба этәреп әйтте:

—Ни генә булмасын, сез минем кунагым, йортыма юл табуыгыз әйбәт булган. Илгә болгавыр заманнар килгәндә танышуыбыз да аерым мәгънәгә ия. Үзгәртеп кору дошманнарының чамадан тыш күп икәнен яхшы беләсездер. Бу чорны да узарбыз, иншалла, партиянең куәте-көче җитәр! Танышу

өчен, хәбәрдарлык һәм демократия чорында яна хәл-гамәлләрдә эшләп килүче партия өчен!

"Сөйләшүне бигрәк тә каттә башлады бу. Алда тагын ниләр генә ишетмәбез!"—дип уйлап алды кунак, ләкин тостны елмаеп кабул итте. Ул эчеп куюга хуҗа лимон салынган тәлинкәне аңа таба этәрә төште.

—Авыз итегез, үзебезнеке, лимонариебез бар. Елга ярты миллион сум табыш алабыз. Ташкентка, теге Фәхретдинов атлы галимгә өйрәнергә кешеләр җибәргән идек. Хәзер үзебез түләүле курслар булдырдык, лимон үсентеләре сатабыз. Акча булдыклы кешеләрнең аяк астында, бары көнчехөсетлеләр генә чит кеше кесәсендәгене санарга ярата.

"Бу сүзләр нидән әле?—дип уйланды прокурор.—Әллә мине лимонарийдагы урлау-үзләштерүләрне тикшерергә килгән дип уйлыймы икән?" Акчаны йөзәр мең сумнар белән генә исәпләүче кеше буларак, лимонарий аны тамчы да кызыксындырмый иде, шулай да лимонны тәмләп капты. Ул бар ташкентлылар кебек үк Италия, Марокко, Греция, Грузия лимоннарына шаккатмый иде, ә бәлки йомшак кабыклы, аеруча баллы җирле лимоннарны үз күрә төшә. Ташкент хатыннары аннан әллә нинди тәмле кайнатмалар ясарга остарып беттеләр инде.

Прокурор тәлинкәсенә иң элек ни салырга икәнен чамалап бай дастарханга күз төшерергә дә өлгермәде, "Күз буучы" аңа ат колбасасы—казы тәкъдим итте:

—Күптән түгел генә яшь җылкы суйдык. Билләһи дим, ирләрнең дәрт-дәрманын унлата арттыручы мондый казыны Аксайдан башка җирдә мәңге таба алмассыз.—Һәм кычкырып көлеп җибәрде. Бу сүзләрнең бер генә тапкыр әйтелмәгәнлеге дә аңлашылып тора иде.

Җылкы рәтен Аксай ханы теләсә кемнән дә яхшырак белә, казы-казылык ясау өчен яшь атларны ул махсус технология буенча симертә иде. Прокурор аңа рәхмәт әйтеп, тәлинкәсенә берничә кисәк салды, ә тегесе бәллүр рюмкаларны тагы мөлдерәмә тутырып та өлгерде, күрәсең, кунакны тизрәк җылытасы килә иде.

—Дулкын Назарович ничек яшәп ята?—дип сорады ул кинәт кенә, яңа тост алдыннан үзе өчен кайбер нәрсәләрне ачыкларга теләгәндәй.

—Бишенче катта мин сирәк булам, анда зур кешеләр, зур мәшәкатьләр. Эш буенча очраштыргалыйбыз, ул, Аллага шөкер, исән-сау, көче ташып тора. Безгә, яшьләргә, кемнән үрнәк алырга дигәндә, ярый әле, андый кешеләр бар,—дип читләтебрәк җавап бирде Сенатор, үзенең элемтәсен афишалап торасы килми иде.

—Тыйнаклангмагыз инде, Сухроб Әхмәдович, без бит бишенче катта күпләрнең ишеген аяк тибеп кенә ачканыгызны, бүген ин перспективалы хезмәткәр икәнегезне дә чамалап торабыз. Шунысы яхшы: мин-минлеккә бирелмәгәнсез, иске кадрлар турында да җылы сөйлисез, хәзерге яшьләргә үткәннәрне сүгәргә дә кәләргә генә булсын. Без дә бит тик кенә утырмаган, байракларны юкка бирмиләр... Тагы менә нәрсә Сухробҗан, дөньяны өч кит өстендә тора диләр, тамырдан килешмим, дөнья дуслыктан тора, ирләрнең ныклы дуслыгыннан...

—Ирләрнең һәркайчан "Мин—сиңа, син—миңа" дип яшәвеннән,—дип төрттереп алды мәҗлестәш, әмма "Күз бууучы" астыртын мәгънәне аңламады, күтәреп үк алды:

—Ай, шәп әйттең, дөрес әйттең. Шуңа күрә, дуслар өчен тотыйк әле. Кайчандыр Дулкын Назаровичны күтәрергә без дә ярдәм иткән идек, менә шулай ярдәмләшү җирне-тормышны тота да инде ул...

"Көндез аның белән сөйләшеп өлгерде микәнни?"—дип борчылып куйды прокурор, ләкин тынычланды, чөнки "Күз бууучы"ның, гадәтенчә, зурдан кубып, купшы сөйләшергә яратуын аңлап алган иде инде.

Дуслар өчен эчтеләр, үзара ярдәмләшү өчен дә җибәрделәр. Акмал ханның тостларда озын башлавының сәбәбен ул чамалаган иде инде. Кайнар кабымлыклар кертелде, тагы тандыр-кебаб, нарын, нечкә итеп түгәрәкләп киселгән, бавыр кушып пешерелгән, өстенә ит һәм казылык, пычак йөзе

калынлыгында гына туралган суган салынган, кара борыч сибелгән токмач... Биш минут та үтмәде, Мәүлидә манты салынган кечкенә табак алып керде. Урыс пилмәне белән грузинча хинкалига охшаган бу нигъмәт сарык итенә курдүк мае кушып, суганлап, борычлап парда пешерелә. Мондый кабымлык белән исерүе шактый авыр нәрсә.

Ике Гертруда иясе сүз арасында кебек кенә әле бу, әле теге кеше турында сораштырды, әле берсе, әле икенчесе өчен тост әйтте. Шулай итеп, прокурорны элеккеге берәр "дусты"—аның хисабына яшәгән адәм җибәрмәде микән дип тә белергә маташты. Ул бит юләр түгел, баш очында болытлар куерганын белә, дөрес, соңгы төгәллекләр җитенкерәми, чөнки Ташкент белән элемтәсе начарланды. "Күз буучы" көтә иде, менә-менә бу исем-фамилия артыннан... көтелмәгән кунак әйтеп ташлар кебек: "Ә мин, Акмал-әкә, сезгә аның үтенече буенча килдем дә инде!" Ләкин фамилияләрне колодадагы кирәкле кәртләрне сакланып-сайланып чыгарган кебек кенә әйтсә дә, теләгенә ирешә алмады, алар барысы да галстуксыз, әллә нинди сәер пиджак кигән бу кешедән, стенага аткан борчак шикелле, чәчрәп кенә төшә бардылар. Ул инде яхшы аңлый иде—моннан берни дә ала алмассың, ә ул болай өйрәнмәгән, шуңадырмы, акрынлап ачуы кабара башлады. Ә кем һәм ни өчен җибәргәнен турыдан-туры сорарга ана минминлеге кушмый иде, яхшы, кунакчыл хуҗа буларак вакыйгаларны ашыктырырга да ярамый.

Дәрәҗәле кунакка килгәндә, ул сүзгә кирәгенчә генә кушыла белде, теге яки бу дәрәҗәле кеше өчен эчте, үзе эченнән генә Акмал хан тезгән фамилияләрнең һаман югарыга үрләгәнен дә абайлап барды. Менә-менә Беренченең дә исеме аталыр дип көтте, чөнки алар Рәшидов белән дус булган кебек, аның белән дә әшнәләшкәннәр, ханны моннан ике ел элек нәкъ менә ул коткарып калган иде. Ләкин Арипов ашыкмады, башка кәртләрне чыгара торды.

Прокурор "Күз буучы"ның күпләргә биргән кыскача бәяләмәсенә шаккатты: төгәл, үткен иде алар һәм бу кешеләр аның алдында яна яклары белән ачылып киттеләр. Бер-ике фраза белән ул Сенаторны аяктан ега язды, ә бит алар ана мәңге сатылмас, акчага кызыкмас, шуның өстенә, гадел, туры сүзле булып тоелалар иде, баксаң, алар күптән инде "Күз буучы" белән "дуслык"та икән. Чыннан да, "Дустың кем икәнен әйт, үзеңнең кем икәнеңне белермен..."—дип юкка әйтмиләр икән шул!

Сүздә өстенлеккә ирешмәгән йорт хуҗасының кәефе күзгә күренеп төште, күп эчә башлады, визитның максатын ачарга да ярый иде кебек инде, тик һаман унайлы форсат чыкмады, ә директорның гасабилануы унайлы фал иде. Ул вак-төяк сорарга килмәде. Шуның өстенә, Акмал хан табигате белән "ябалак", төннәр буе эчеп чыга, димәк, ашыгырга ярамый.

Икенче шешәдә калган коньякны бүлгәндә Акмал хан вакыйгаларны үзенә зыян ясап ашыктыруын аңлады, Ташкент кунагы эчә белә, ашауда да хәтәр, аның үзенең бүген ашыйсы килми, эчке усаллык та җанын буып тора һәм исерә баруын сизенде, инициативаны ычкындырды. Югыйсә, ул күп эчсә дә исерми торган иде. Әле чынлап сөйләшү булмады, бераз җылындылар, көчләр нисбәтен чамаларга тырыштылар. Димәк, ял итеп алырга, чыгып һава сулап керергә, фикерләрне тупларга кирәк булыр. Ләкин беренче раундта ул җиңелде.

Шунамы, ул кинәт кенә күңеле күтәрелеп, әйтеп куйды:

—Әйдәгез, Сухробҗан, төнге паркта йөреп керик, ял да итәрбез, теләсәкайсы ботаника бакчасы кызыгырлык сирәк агачларны, куакларны күрсәтим әле. Мина экзотик агачлар, куаклар, чәчәк орлыклары бүләк итүчеләр күп. Бәлки сез дә күңелемә юл табарсыз, Гагра, Цхалтубо, Форос, Ялта кебек җирләрдә ял иткәнегез бар. Ял иткән арада кызлар табын әзерләр, пылаучылар казанга дөге салыр. Ни генә ашамасак та, ни генә капмасак та, үзбәк өстәленең ханы—барыбер пылау, Аксайда аны әзерли беләләр. Гәрчә ташкентлылар иң яхшысы үзләрендә генә дип уйлый булыр...

—Юк, юк, башыма да кереп карамады. Бигрәк тә сезнең тандыр-кебаб

белән джиззалы кабартманы авыз иткәннән соң. Кызларыгыз кебек чибәрләрне атаклы "Бахор" бию ансамблендә дә таба алмассың,—дип ачыктан-ачык төчеләнде Сенатор. Турыдан-туры мактау йорт хуҗасына уңай тәэсир итте. Аның күңеле шуңа өйрәнгән, һәркемнән ул шуны көтә иде.

—Рәхмәт, бәя бирә белдең. Зәвыклы кеше икәнең күренеп тора. Юкса, кайчак бер авыл мокыты килә дә һәрнәрсәгә борын жыерып йөри, монысы ошамый, тегесе ошамый. Әйдә, Сухроб, кадерлем, артыш куаклыгында сулап килик әле, ул гомерне озайта диләр, әгәр без аны коньяк белән кыскартканбыз икән, кирәк кадәр итеп кире кайтарыйк. Әгәр дә эчмәсәк, тартмасак, изге артышлар һәм атлар янында утырып, гомерне никадәр озайтыр идек, ә?

Кунак Аксай ханының яраткан айгыры Саман янында ат сараенда төннәр уздыруын да белә иде. Кемдер аны өч кит турындагы теориядән тыш, атлар белән аралашкан, жылкы ите ашаган кешенең озын гомерле булуы турындагы матур әкияткә ышандырган, чабышкыларны үлеп яратуы, жылкы көтүен һаман үстерүе дә шуннан, күрәсең.

Аксайда атлар кешеләрдән яхшырак яши, ул аларга игътибарлы гына түгел, чын мәхәббәт тота иде.

Парк үтә яхшы уйланылган, табигать үзенчәлеген оста файдаланучы архитектор кулы сизелә, моның өстенә, яктылык уены җәлеп итә, күрәсең, театрдан ут осталарын чакырганнардыр, гади электрикларның башына да килмәстәй кыландыруларны каян табар идең. Хан Акмални көткәндә балкыган яктылык, фонарьлар уены эшнең башы гына булган икән! Йорт хуҗасы төнге бакчаның теләсә кемнең һушын җибәрерлек эффект ясаганын үтә яхшы белә иде. Тәбәнәк, көчле прожекторлар җирдән үк кеше кочагы җитмәс имәннәрне, төз Япон фейхоа агачларын кочаклап алалар да карангылы-йолдызлы күккә чөяләр. Әле геометрик төгәллек белән яктыртылган юл борылышлары, әле куе агачлыктан ут кояшы янып торуы—барысы, барысы да бакчаны тылсымлы итәләр, парк яңа утлары белән уйный башлый, боларның берсен дә көндез күрә алмыйсың. Кинәт ялгыз бер агач зур планлы экранга элеккәндәй кабынып китә дә игътибарны шашындыра, йә яшел абрис кәүсәсенең, ботакларының камиллеге-матурлыгы күзгә ташлана, төнлә яфракларның лепелдәве-пышылдавы да бөтенләй янача ишетелә икән. Без бит ландшафтлы архитектураны белмибез, бездә паркларга адәм рәтле игътибар юк, ә Акмал хан бакча-паркы кебек могҗизаны ябык дәүләт дачаларында яисә хөкүмәт йортларында гына табарга мөмкиндер. Хәтта кайлардадыр булган, ниләрдер күргән Сухроб та чын ихластан әйтеп куйганын сизми дә калды:

—Фантастика!

—Без сезгә Ташкент түгел, сезнең бетле дәүләт дачагыз,—диде борын төбеннән генә "Күз буучы" бик тә канәгать тавыш белән, кунакка зур тәэсир ясый алуы аның үзенә бик ошый иде.

Сенатор бу паркта ханның туган көнендә, йөзләрчә дәрәҗәле кунаклар алдында нинди иллюминацияләр, фейерверклар, салютлар оештырылуын, төсле петардлар шартлавын, сигнал ракеталарының күккә ыргылуын күз алдына китерде. Хан туган көнен, уңайлырак булгангамы, яисә башка минминлектән чыгыпмы, беренче майда билгеләп үтә, шулай итеп, кыштан соңгы бәйрәми демонстрацияне дә ул үз хөрмәтенә оештырылган дип чын күңелдән кабул итә иде. Ә бу чакларда шау чәчәктә утыручы гүзәл паркның матурлыгын сөйләп-аңлатып бетерерлек булмый.

"Аның карнаваллары үтте инде, замана башка",—дип уйлап алды прокурор төнге миләүшә чәчәкләренә иелгән "Күз буучы"га карап. Акмал ханның туган көнендә бер генә тапкыр да була алмавы җәл иде. Юк, күңелендә Ариповка карата жылы хисләр уянмаган, аның бары тик шундый бай, колачлы, фантазиягә мул бәйрәмне күрәсе килеп киткән иде.

—Телисезме, мин сезгә парктагы иң яраткан урынымны күрсәтәм,—дип, кинәт кенә сорап куйды Акмал.

Төнге миләүшәләр исе шундый да көчле аңкый, гүя ул кабара, калка, дулкынландыра, хет исер-егыл, Сухробның бу гүзәл почмактан китәсе

килми, ләкин кызыксыну өстенлек алды, бакча хуҗасының тагы нинди яраткан урыны бар икән. Һәм ул, миләүшә исенә манылган тынлыкны бозудан курыккандай, акрын гына әйтте:

—Бик рәхәтләнеп, Акмал-әкә, бик рәхәтләнеп...

Алар юлдан сулга борылдылар, зәңгәр чыршылар утыртылган почмакны урап үттеләр. Яктылыкка чумган чыршылар көмешләнеп балкый, алар хәтта җирнеке булып тоелмыйлар, әйтерсең лә, Марстан төшкәннәр дә ботакларын селкетеп шыбырдыйлар, инәләренең бер-берсенә ышкынып шышылдавы да нindидер йомшак-җинел металл тавышын хәтерләтә иде.

Хуҗа үз паркын үтә яхшы белә икән, кактус плантациясе яныннан да уздылар. Көндез монда ханны көтеп ул берүзе йөргән иде инде. Ләкин төнлә бу урынны танырлык түгел, караңгыда зур ачык-кызыл чәчәкләр аткан кактуслар бөтенләй башкача күренә икән. Аның кактуслар янында тукталасы килгән иде, ләкин хуҗа аларга күз дә салмады, тагы уң якка, кипарислар аллеясенә каерды. Шунда гына прокурор салкын дымлылык һәм агымсу исен тоеп алды. “Нинди дә булса мәрмәр бакалар утыртылган төсле фонтандыр”,—дип уйлады ул һәм бик нык ялгышты. Хәер, су һәм бака “савытлары” бар иде.

Өчесе дә җидешәр метрлы, бер-берсеннән юка стеналар белән бүленгән “бака оялары”, чыннан да, аквариум тәэсире калдыралар, алар эчтән, яннан, өстән яктыртылганнар. Аквариумның өч бүлеге дә, бигрәк тә, аларның төпләре яхшы глазурьланган кызгылт керамик плитә белән балкый, стеналары, бассейндагы кебек, зәңгәрсуга төрелгән иде.

Һәр өч диләнкәдә лилияләр, лотослар чәчәк атып утыра, мондый могҗизаны Сенаторның беренче күрүе иде әле. Ак йомшак лилияләр, сары, алсу, шәмәхә төсле лотослар—мондый камиллек-бөеклектән күзенне дә алырлык түгел иде. Төптә кешеләрдән курыккан йокылы алтын карплар селкенә башлады, алар ялкау гына үз галәмнәрендә йөзәләр, лилия һәм лотосларның сабакларына тиеп-тиеп үтәләр, чәчәкләр чайкалып куя, алар тирәсендә вак дулкынчыклар хасил була.

Артта чыкырдаучы компрессорлар бака оясына даими рәвештә кислород биреп торалар һәм төптән күтәрелүче вак күбекләр табигатьнең хәйрани бер тере почмагын хасил итә, аның кеше кулы белән ясалганына ышанырлык түгел. Хлорофиллга туйган каты лилия яфраклары кувшинкаларның ипле-затлы төсен киметә, әмма алар икебанадагы кебек композицияне тулыландыралар гына, монда өстәсе дә, кочәйтәсе дә юк. Ләкин табигать биредә дә кешедән көлү җаен тапкан. Лилиянең бер яфрагында бака күренде, ул, умарта корты кебек, чәчәктән нектар эчте, аннан соң аптырашта калып төнге кунакларга карап торды да, суга чумды, шуның белән кызыл йөзгечле, алтын сыртлы зур гына сазанны куркытып куйды.

Табигать шулай инде, кеше кулы ясаганын тиз генә үзенеке итә: чикерткәләр чырлый, су куышлыгы өстендә утка жыелган черки өере кайный, болары аквариумны “йорты” иткән бакалар өчен тере азык иде. Бу күренешләр шулкадәр тылсымлый иде ки, прокурор үзенең кайда икәнен, ник килгәнен, кая килгәнен дә оныта башлады. “Бу нindидер гипноз”,—дип уйлады ул һәм фотоаппаратсыз килүенә бик нык үкенде, гаҗәеп кадр булыр иде.

—Менә шушы, җирдәгечә булмаган чәчәкләр җанымны айкый.—Ханның колак төбендә яңгыраган каты тавышы аны реаль тормышка кайтарды.—Кызганыч, монда әз булырга туры килә, паркта иң яраткан урыным шушы инде.

Прокурор аквариумга каршы йомшак мүккә төренгән эскәмия күрде, саф һавада утыру комачауламас, әле аның һаман төнге лотосларның чәчәк атуын күрәсе килә иде, ләкин йорт хуҗасы аны кулыннан тотты:

—Вакыт, дөге салырга кушып киткән идек, пылау көттергәнне яратмый. Пешекчене дә үпкәләтү килешмәс, тырышкан бит. Җәйге кухнядан ике тапкыр фонарь белән сигнал бирде инде,—диде Акмал әкә һәм алар ашыкмый гына байраклар белән тулы бүлмәгә таба кузгалдылар.

Янартылган дастарханга утыруга, тагы Сабир-баба күренде, шул ук

подноста ике “Двин” коньягы утыра иде. Йөреп керү икесен дә айныткан, бигрәк тә, директор шәпләнгән, аның кәефе күтәрелгән, ачуы чыгып беткән иде.

—Төнге бакчада ял итәргә теләвегез әйбәт булды әле, хәзер сез мина, Сухробжан, ничектер якынайдыгыз, анлашыла башладыгыз. Әйдәгез, сезнең килүегез, эшләрегез уң булсын дип эчик. Уңышлар өчен!—диде “Күз буучы”, үгезне мөгезеннән алып, моның белән ул кунакны ачыктан-ачык сөйләшүгә чакырды, шәрекъчә утырулар вакыты узган, сынау-сыналу да үтеп киткән иде.

Прокурор йотып куйды, ул да, йорт хуҗасы кебек, эшкә тотынырга вакыт дип уйлый. Төн узып бара, “Күз буучы” үзен тыныч тота иде, ләкин шулчак Мәүлидәгә булышып йөргән чибәр кыз бер табак пылау китерде, ризык өстенә Дашнабад анары төшләре сибелгән иде. Чыгып барганда, ул прокурорга шундый шаярып-уйнап карап куйды ки, көтелмәгәнлектән битенә кызыллык йөгерде, хәтта әңгәмәне башларга әзерләгән сүзләрен дә онытып җибәрде. Пылау коткарды, икесе дә аңа җиң сызганып тотынганнар иде инде.

Йорт хуҗасының да тамак ягы шәптән, куй ите һәм сарыклар турында сөйли-сөйли ул тәмле-сусыл калҗаларны сузды. “Мәсәлән,—диде ул,—иң мөхтәрәм кунакларны мин сарыкның уң як түшкәсе белән сыйлыйм.— Кунакның гаҗәпкә калуын күргәч, тагы аңлатты:—Сарык гел сул ягына ята, шуңа күрә уң як кояш нурларын күбрәк җыя, сеңдерә, аның ите дә йомшаграк, тәмлерәк, организм өчен файдалырак була. Уң як беркайчан да авырлыктан басылмый, бездә Гиссар тәкәләренең авырлыгы алтмыш-сиксән килограмм тарта”.

Боларны белү яисә уйлап табу өчен нинди тәмле тамак, ашау колы булырга кирәк! Кайбер кешеләр айлар буе тундырылган ит тә авыз итә алмый бит, дип шаккатты кунак, ләкин пылаудагы итнең шулкадәрле дә йомшак, татлы, тәмле икәнен сизмичә кала алмады. Акмал ханның ачышын Шубаринга сөйләргә кирәк булыр, аның дусты Икрам да тәмле тамак, бу яңалыкны бәяләми калмас, зур бүләккә хисаплар.

Шулай җылы гына сөйләшә-сөйләшә алар бер табак пылауны юк иттеләр, шуны гына көтеп торгандай, комган һәм бакыр ләгәннәр күтәргән ике кыз килеп керде, ирләр җылы су белән кулларын юдылар. Мәүлидә суны хуҗага, иптәш кызы прокурорга салып торды, нәрсәгәдер өметләндергәндәй һаман шаярып елмайды, сөлге биргәндә юри икәнен сиздерерлек итеп ике тапкыр кулына да кагылып алды.

“Хан нинди план кора, нишләп шулай юмарт кылана?”—дигән дулкынландыргыч уй узды аның башыннан, ләкин бу фикер шундук югалды. ҮК кешесе алда торган эшен искә төшерде һәм маңгаенда матур миңле, зифа буйлы, озын чалбар кигән кыз аның башыннан чыгып та очты.

Сүзгә керешер алдыннан кунак директорга тартып алырга тәкъдим итте, үзе кабызып та җибәрде, сигарет белән утырганда, ул үзенең планын Арипов өчен артык оятсыз тоелмас дип уйлый иде.

—Кадерле Акмал-әкә, сезнең дустыгыз саналмасам да, ике сәбәп аркасында Аксайга килдем,—дип кыю гына башлап җибәрде кунак.—Беренчесе, ҮКда аерым бүлекне җитәкләүче буларак, мин иске дусларыгызның сездән йөз чөергәннәрен, язмыш кочагына ташлаганнарын күреп торам. Алардагы бу үзгәрешнең төп сәбәпләрен белмим, бәлки болгавыр заманда үзең өчен куркудыр, күпләр хәзер исен-ушын җыя алмый, бәлки башка сылтаулары да бардыр, әмма алар элеккеге кебек сезнең тормышта актив катнашмыйлар, мин моны күреп-белеп әйтәм.

Икенче сәбәп, турысын әйтәм, сезнең баш очыгызда кара болытлар куера, депутат кагылгысызлыгын алу өчен документлар әзер, килүемнең төп сәбәбе дә шул.

—Мин боларны беләм, кадерле Сухроб,—дип бүлдерде аны кинәт кенә Арипов.—Әйдәгез тагы берәрне күтәрик, алда җитди сөйләшү, анысы да минем язмышым хакында, минем дастархан янында... Барып җиттем.—

"Күз буучы" югалып калды, әллә ничек авыр-саңгырау итеп әйтте. Күрәсең, беләм дисә дә, яңалык аның өчен көтелмәгән булды.

Икесе дә пылаудан соң исерткеч кулланырга ярамавын, күбрәк яшел чәй эчәргә кирәклеген беләләр иде, әмма гадәт-йоланы, традиция-ритуалларны искә төшереп тормадылар—эчәр өчен сәбәп артык җитди иде. Эчәргә тәкъдим ясап, сүзне бүлеп Акмал хан тайм-аут алды кебек, чөнки ул үткен акылга ия түгел, шунлыктан аңа фикер туплау өчен һәрвакыт күпмедер вакыт кирәк була. Әгәр аның урынында Шубарин, Миршаб яисә яндырылып та янып юкка чыкмаган Дулкын Назарович утырса, алар яшен тизлеге белән җавап табарлар иде.

Коньяк бүлә-бүлә, ул астан гына кунакка күз төшергәләде, гүя ул аңа ышанып бетми иде, шулай да кирәкле фикер җебен тапты булса кирәк, сак кына сорап куйды:

—Әгәр шундый дәрәҗәле урында утырган кеше буларак, югарыдагыларның мәрхәмәтеннән мәхрүм ителгән Аксайга килергә батырчылык иткәнсез икән, уйлавымча, сез үзегез сурәтләгән караңгы кыен хәлдән чыгу юлын да беләсез булыр?—Бу озын, борылмалы, әйләнгеч сорауда янау да, шантаж да яшерелгән иде. Хан элеккечә, бер үк вакытта һәм мактаулы, һәм мәкерле эслүбтә сөйли иде.

Кунак дастархан аша үрелеп, юка итеп туралган лимонлы тәлинкәне үзенә таба тартты, юкса хуҗа күңелсез хәбәрдән соң кунакчыллыгын оныта язган иде. Прокурор юри вакытны сузарга тырышты, директорны төп яңалыкка әзерли торды, чөнки алда буласы сөйләшүнең уңай нәтиҗәсе аның ничек кабул ителүенә бәйләнгән иде.

Җавап җинелләрдән түгел, чама хисен югалтырга ярамый, Акмал хан "минем дастархан янында минем язмыш турында" дип юкка гына әйтмәде. Аксак Тимер заманында начар хәбәр китергән кешеләрне җәзалап үтерә торган булганнар. Үзен шул нәселдән санаган Арипов борынгы йоланы яхшы белүен сиздерде түгелме соң?! Бүген прокурор нәкъ менә шундый чапкын хәлендә ич.

—Кызганычка каршы, чыгар юл күренми кебек,—дип сак кына башлады ул.—Сезнең эшне аеруча мөһим эшләр белән шөгыльләнүче тикшерүче карый. Аңа КГБдан булышалар, алар информациянең читкә китүеннән саклана белә, хәтта мин булып мин дә әйткәнемнән артыгын белмим. Бәлки кемнәрнең кулга алынуын ишеткәнсездер инде, аларның сезне һәм дустыгыз Рәшидовны нинди буяуларда сурәтләгәне безгә караңгы. Дустыгызга хәзер суык та, эссе дә түгел, ул теге дөньяда, яткан җире мамык, гүре якты булсын. Хәзер бар уклар сезгә төбәлгән, чөнки үз-үзенә харакири ясап, Кара Түбә ханы теге дөньяга китеп барды, ә Әнвәр Абидович гаепләреп таныды, эшләгәннәренә үкенеч белдереп, үзен исән калдыруларын ялварды, менә ул сезне дә аямый, сазга тарта, сез аның белән көндәшләр идегез ич...

—Сволочь!—дип ачу белән әйтеп куйды "Күз буучы".—Берчак аңа камчы белән тамызган идем инде, хәзер менә үкенәм, үтергәнче ярасы калган икән!—Ханның тавышы шартлау булып яңгырады, бөтен кич буена беренче тапкыр аннан нидер бәреп чыкты, әмма шундук тынып, бөрешеп калды. Ефәк халат астындагы түгәрәк-тыгыз җилкәләре салынып төште, кырдырылган башы аска иелде, бар кыяфәте язмышка буйсынуын күрсәтә иде кебек һәм прокурор төп сүзне әйтер вакыт җитте дип уйлады.

—Бер юл бар анысы, сонга калганчы сезгә моннан китәргә кирәк.

—Кая?—Аксай хуҗасының буйсынучан тавышы прокурорның игътибарын йомшартып җибәрде.

—Вариантлар җитәрлек, теләсә кайсын сайларга була,—кунак җанланып китте.—Сезнең өчен иң кулае үзбәкләр тупланып яшәгән районнар, алар Көньяк Казакъстанда, Чимкент, Җамбул, хәтта Алма-Ата өлкәләрендә, Таҗикстан тупрагында, моңа хәтта Дүшәмбе дә керә, андый урыннар Кыргызстанда да җитәрлек, бигрәк тә Ош өлкәсендә, Төрекмәнстанда да үзбәкләр яши, алар Хорезм һәм Чарҗау тирәсендә күп. Анда тамырларыгыздан аерылмассыз, тел үзбәкчә, аларның холык-табигате таныш, яшәү рәвешләре

дә безнеңчә, алар арасында, шул мохиттә сезнең барлыкны да сизмәячәкләр. Тагы бер вариант бар. Әфганстанда сугыш дәвам итә, ә Термез фронтка якын шәһәр, мин сезне Аму-Дәрья аша җибәрә алам, контрабандистлар бу юлны яхшы белә. Анда ике миллион үзбәк бер тирәгә җыелып яши, моннан сезгә теләсә кайсы мөселман иленә юл ачыла, сөнниләр яшәгән илләргә китәргә мөмкин, Төркиягә мәсәлән, яисә Кувейтка, бәлки Согуд Гарәбстанына, ә анда изге Мәккә. Ләкин бу юл, алдан әйтеп куйыйм, сезгә кыйбатка төшәчәк.

—Юк, Әфганстан вариантын сызып ташлыйбыз, минем үз җиремдә үләсем килә, анда сагыштан-саргаюдан харап булачакмын. Башка берәр җирдә пенсиягә кадәр завхоз яисә төнге каравылчы булып эшли аламмы?—дип Сенаторның сиргерлеген йомшартты ул.

—Мин монысын да уйлаган идем.—Кунак Акмал хан кармагына капканын сизми дә калды.—Мин сезгә шәрекъ кешеләренә хас фамилия белән паспорт кына түгел, пенсия кенәгәсе дә әзерли алам, барысы да закон кушканча булыр, моңа гына көчебез җитә. Хезмәт иянәренең күбесенә хас зур булмаган, тыйнак пенсия рәтләрбез. Алдан ук яхшы бакчалы күркәмрәк берәр йорт та карап куярбыз, шулай итеп, үзгәртеп кору, хәбәрдарлыкның узуын тыныч кына көтәрсез. Илдә тәртип үзгәргәч, бу турыда күпләр хыяллана, дошманнарыгызга үч итеп, исән-сау һәм зыян-зәүрәт күрмичә генә кайтып та төшәрсез.

—Начар фикер түгел бу, әйе, начар түгел, һәрхәлдә ышандыра,—диде "Күз бууы" җилкәләрен кинәйтеп-җәеп һәм күнеле күтәрелеп.—Әйдәгез, Сухробҗан, йотып куйыйк әле, юкса сезнең сүзләрдән мин айнып ук киттем.

Эчеп куйдылар. Прокурор озак һәм тырышып капкалады, нидер хакында баш ватучы йорт хуҗасына уйланырга мөмкинлек бирергә кирәк иде. Дөрес, ул әле җәелеп сөйләшергә җыенмый иде бугай, әмма сораулары ышандырырлык иде.

—Ә нишләп сез, Сухробҗан, үз эшендә күтәрелеп баручы функционер, яңа вакыт агышына эләккән кеше, янача фикерләү иясе мине коткарырга уйлыйсыз, юридик тел белән әйткәндә, мине җаваплылыктан, кылганнарым өчен җавап бирүдән йолып калырга җыенасыз? Ни пычагыма сезгә бу куркыныч эш? Читтә качып йөргәндә мин сезгә булыша алмыйм ич. Башкалар миннән йөз чөергәндә, язмышның кара кочагына ташлаганда, нигә кирәк минем турыда кайгырту? Хәтта кайчандыр мине коткарган һәм мин күтәрелергә ярдәм иткән Беренче дә, мине беткән кешегә санап, ярдәм кулы сузмый. Сезнең алга куйган планнарыгыз нинди, сезнең артта кемнәр тора? Ялгышмасам, бүгенге иң көчлеләр дә сезнең өчен авторитет түгел, алар кызыктырмый бугай, сезнең максат-мәсләгегездә аларга урын юк. Тагы үзеннән-үзе сорау туа: ни сәбәптән мине сайладыгыз, иске кәрт колодасыннан бит мин, әле аның да төсе кара—пики төсе.

"Менә сиңа авыр зиһенле кеше,—дип уйлап куйды прокурор.—Сораулары турыдан-туры маңгайга, аларга шулай ук туры җавап бирергә кирәк. Юкса ышанмаячак, нинди дер капкын куя дип уйлаячак".

Сухроб сигарет кабызды, монысы җавап уйлау өчен күпмедер вакыт кирәклектән иде һәм ашыкмый гына, ләкин нык рәвештә иске, күптән башында йөргән фикерен дәвам иткәндәй, сөйли башлады:

—Сез хаклы, күзәтүчәнлегегез шаккаттыра, бүген кәнәфидә утыручылардан сез атап киткән беркемне дә мин санга суга алмыйм. Турыдан ярып, ачыктан-ачык сөйләшү киткән икән, шунысын да әйтәм, мин алар рәтенә үзем ихтирам иткән Дулкын Назаровичны куймыйм, әмма минем планнарымда ана да урын юк, югыйсә монда килүемне башта аның белән килештерермен, киңәшер идем. Барысы да кичәге көн, узган заман кешеләре, ул чорга кайту юк. Алар тормышта көрәшнең ни икәнен дә белмәде, көндәшләре юк иде, барысын да алтын тәлинкәгә салып китереп бирделәр. Кемгәдер туганнары, кемгәдер якташлары ярдәм итте, кемдер нәселе белән көчле иде, кайсыберләрен югары постка сезнең кебекләр утыртты. Чөнки аларга да югарыда үз кемсәләре кирәк иде, дөресрәк әйтсәк, "курчаклары". Бүген

алар шулкадәрле югалып калдылар, бөтен илдә андый каушап калган башка катлау юк. Бөтен уйлары ничек тә исән-сау калу, өстенлекләрен югалтмау. Үзгәртеп кору өчен уй-фикер, зиһен-фәһем, белем һәм теләк кирәк, ә алар өстән төшкән фәрманны үтәп ятырга гына күнеккән, яңача яшәгәндә исә әзер рецептлар булмый. Күренеп тора бит, иске канун-догмалар үлеп бара. Сүз тыңлаучанлык та чын яхшылык түгел, инициатива, фикер йөртү, күнелендәгесен халык алдында ачыктан-ачык әйтә белү—менә бүгенге көн өчен иң кирәк нәрсәләр. Шундый хәлдә алар сезнең турында уйлыймыни, Акмал әкә, һәркем үзенекен каера, соңгысын тартып ала. Кемгә машина, кемгә йорт, дача—үзе өчен, балалары өчен. Төп шөгыльләре шул. Арипов яисә Ватан кайгысымыни? Мин мондый бәндәләргә таяна аламмы?

Кунак, сигарет көлен җилпеп төшереп, кырын гына йорт хуҗасына карап алды, аның хискә бирелеп сөйләве ханга ничегрәк тәэсир итте микән дип уйлады ул, тегесенең йөзе ком дәрвишенеке кебек берни аңлатмый иде, әмма анык игътибар белән тыңлавы сизелеп тора: йомылган күз кабаклары йокы турында сөйләми, ә бәлки киресенчә—ул битараф түгел, бары вакытыннан алда бу сөйләшүгә үзенең реакциясен белдерүдән курка.

—Хәзер сезнең хакта. Нишләп мин сезне сайладым соң әле, нишләп ярдәм кулы сузарга булдым? Инглизләрдә бер әйтем-мактау бар "Селф мейд мен", ягъни үз-үзен ясаган кеше. Нәкъ сезнең хакта әйтелгән кебек, ләкин никадәр матур яңгырамасын, ул сезне тулысынча характерлап бетерә алмый. Сез үзегезне үзегез ясап кына калмадыгыз, җәмгыятьтә дә шулкадәрле югары күтәрдегез, моннан да югары күтәрелеп тә булмый торгандыр. Шуның өстенә, башкаларга күтәрелергә ярдәм иттегез, аларны үзегезгә ошаганча тудырдыгыз. Сезнең Шәрәф Рәшидовка булган тәэсирегезне дә беләбез, хәзер аның урынында утыручыны да сез күтәрдегез, соңгы ун елда бездә сезнең катнаштан башка гына югары үрләүче булды микән? Юктыр! Профессиональ сәясәтче булмасагыз да, сез чын сәясәтче, республика сезнең кул астында иде. Бүгенге тотрыксыз заманда сезне судка бирү, зур хата, төзәтеп булмаслык ялгыш. Әле бер генә нәрсәдә дә тулы ачыклык юк. Бәлки барысы да үз урынына кайтыр, дөнья куласа, бер әйләнә дә бер баса, шулчакта көчле кеше кирәк булыр, "каты кул"га өмет белән карарлар. Аны каян алырга? Тагы дефицит туа, бүген дә әнә инициативалы, намуслы, үзбашка эшли торган кешеләр житми бит. Без бүген телгә алган кемсәләр исә теләсә кайсы властька, идеягә хезмәт итәргә әзер, бары өстенлекләре булсын да тормышлары җайлы-уңайлы барсын. Бу бәндәләргә социализм ни, капитализм ни, фашизм ни, алар сезне саткан кебек, теләсә кемне теләсә кайсы минутта сатачаклар.

Мин сәясәттә, хуҗалык алып баруда, милли мәсьәләдә барлык идеяләрегезне белмим, әмма сез үзегезнекен эшләдегез, уйлавымча, үзгәртергә дә җыенмыйсыз, миңа бу ошый, чөнки буыны сыек, мәсләксез кешеләр куркыныч алар. Сез илдәге чын вәзгыятьне беләсез, халыкның җанын аңлыйсыз, гореф-гадәт, йолаларны хөрмәт итәсез, гади кешеләрнең омтылышларын яклыйсыз. Сезнең һәм сәяси, һәм финанс ягыннан да көчегез җитәрлек.— Салпы ягына салам кыстырып, прокурор кармакны сиздерми—сак кына салырга тырышты.

Акмал хан күзләрен яртылаш йомып тыңлый бирде, аз гына, сизелер-сизелмәс кенә дерелдәгән кулларында бертуктаусыз тәсбих уйнады, әмма иреннәре арасыннан ни хуплау, ни каршы төшү җәһәтеннән ник бер сүз чыксын. Аның сүзсез калуын үзенчә, үз файдасына аңлаган прокурор исә тезде дә тезде:

—Сезне коткарып мин анык бер максат куймыйм. Дөрес, минем сездән сорыйсы әйберем дә бар, ләкин ул хакта соңрак әйтермен. Ышанам, сездәй кешегә, хәтта гаепләр тапкан очракта да, ярдәм итәргә тиешләр, ялгышулар, властьтан файдаланулар артында зур максатлар да торырга мөмкин бит.

Хәзер сезнең сорауның иң авыр һәм соңгы, җаваплы өлеше: минем артта кемнәр тора һәм мин үзем нинди максатларны күздә тотып килдем? Ни генә әйтсәм дә ышандыра алмам, бәлки минем сүзләр сезгә ялган булып та тоелыр. Мине шөһрәт сөюче бер адәм дип уйлыйсыз икән, уйлый бирегез.

Ләкин мин инде үзем уйлаганнарга таба хәлиткеч адым ясадым һәм менә алдыгызда утырам. Сез, Акмал әкә, яхшы беләсез, илдә тотрыклы, ышанычлы хакимият юк, дөрес, ул үзен бар итеп, булдыклы итеп күрсәтергә тырыша, кыяфәт саклый белә. Ләкин тотрыксызлык тиз генә бетмәс әле, аныкачык фикерле, максатлы инсаннар әлегә күренми. Шулай булгач, мине беркем исеменнән дә килмәгән, артында беркем дә юк дип саный аласыз. Мин бүген сезгә үземне үзем тәкъдим итәргә килдем.

Көтелмәгән бу сүзләрдән Акмал хан тәсбихын төшереп җибәрде һәм исереклектәнме яисә эчке бер тетрәнүдәнме томаланган күзләрен аңа текәп усал итеп сорады:

—Башкаларны кимсетеп, үзегезне шулай югары күтәрергә кем соң сез?

Сенатор сүзләренең ханга ничек тәэсир итәсен, аның мөнәсәбәте ничек буласын да чамалый иде инде, ханның ярсуын басар өчен капта калган соңгы сигаретны алды, кабызып акрын гына төтенне эчкә алды һәм дәвам итте:

—Кем соң мин?—диде ул акрын гына.—Мин бүгенге хәлләрне яхшы белгән һәм югалып калмаган, алга таба вәзгыятькә йогынты ясау мөмкинлекләре булган бер кешемен. Элегрәк ул йогынтыны сез ясый идегез. Төгәлрәк итеп әйткәндә, минем сезне алыштырасым килә, табигать бушлыкны яратмый ул, сәясәттә дә шулай, сезнең урынга барыбер кем дә булса килергә тиеш. Моңа минем көчем дә, сәләтем дә җитә, дип уйлыйм. Сезгә дә варисыгызны йөзгә-йөз күрергә кирәктер бит. Дусларыгыз, хакимият башында утырсалар да, дилбегәне үз кулларында тота алмадылар, ике дә уйламый сезне корбан тәкәсе итәргә әзерләр. Инде килеп, ярдәмгә беренчеләрдән булып мин ташланганмын икән, миңа фатиха бирү, варисыгыз санау мантыйкка сыя түгелме?

Аксай Крезы башта тыныч кына, ирен чите белән генә елмаеп куйган иде, әмма тора бара ул аяз көнне күк күкрәгәндәй тыелгысыз шаркылдауга әйләнде. Аның сүзләреннән кызык табып чынлап көлү идеме бу, әллә аларны уенга борып җибәрергә тырышуы идеме, йә булмаса, аптыраушта калдырыр өчен махсус әзерләнгән бер кылану идеме, кунак аңлый алмады. Инде барысы да әйтелгән, күңелдәгеләр тышка чыккан, артык сәерсенмичә һәм кызыксынуыңны сиздермичә тыныч кына көтәргә кала. Мөмкин булган бердәнбер юл шул иде.

Туйганчы көлгәннән соң, хуҗа күзенә чыккан яшьләрен сөртте һәм елмаеп ихлас күңелдән әйтте:

—Бер иске вакыйга искә төште әле, бу хакта моннан егерме еллар элек газетларда язып чыкканнар иде. Хәтерлисез микән, Конгода хакимият башында Чомбе утырган заманда “Известия” газетының андагы үз хәбәрчесе Николай Хохловны кулга алдылар. Төрмәдә камерадашы белән сәясәт турында сөйләшеп утыра икән бу. Тегесе аңа үзе әгъза булып торган партиянең максатлары, бурычлары, программасы турында хәтәр-хәтәр сүзләр сөйли икән. Алар шулхәтле матур, ышандыргыч һәм күңелгә ятышлы була, журналист ачылып китеп, үкенечкә каршы, мондый да шәп партиянең кайда икәнлеген, күпме әгъзасы барлыгын да белмәвен әйтеп бирергә мәҗбүр була. Юкса, үзе ничә еллар буе Браззавильдә яшәгән кеше бит. Камерадашы бер дә аптырап калмый, төрмәгә ябылган журналистның белмәве бер кәррә дә гаҗәпләндерми, “Белмәвегез табигый хәл”, дип кенә куя. Тәмам аптыраушта калган Хохлов сорарга мәҗбүр була, “Берәр яшерен партиямени ул”, ди. “Юк, ди,—төрмәдәше,—ул партияне мин үзем төзедем, аның бердәнбер әгъзасы да мин үзем, хәтта генсекретарь вазифасын да үзем башкарам”, ди. Сезнең амбицияләр дә шул кешенекенә охшаш түгелме, иптәш Әкрәмхуҗаев?

—Әйе, чыннан да кызыклы вакыйга. Безнең илдә дә шундыйрак хәл бугай. Демократия, сүз иреге, төрле идеяләргә битараф тыныч карау сез әйткән генсекныкы шикелле бер кешелек партияләрне барлыкка китерде. Тик, шулай да, калганында мин сезнең белән килешмәс идем. Мин, мәсәлән, төрмәдә түгел. Рәшидовтан калган ат сарайларын чистарту барган бу көннәр-

дә күпләр алай дия алмый, чөнки үзләренең дә куллары терсәктән нәжескә баткан. Никадәр танышларыгыз, элемтәләрегез, акчаларыгыз булып та, хәтта сезнең иректә калу ихтималы юк дәрәҗәсендә. Бусы мәгълүм нәрсә. Башкаларга ни сан?

Крезның йөзе агарып китте, ул нидер әйтергә, аны бүлдерергә дә теләде кебек, ләкин нәрсәдер аны телен тешләргә мәҗбүр итте булса кирәк. Чөнки сенатор нәкъ үз вакытында һәм шактый ук каты итеп бәрдерде. Аксай ханы, бәлки, "ашыккан—ашка пешкән" дигәнне дә истә тоткандыр.

—Инде килеп, Конгодагыга охшатып әйтсәк, партия әгъзалары һәм программа турында бер-ике кәлимә. Кабатлап әйтәм, фикердәшләр туплау, стратегияне ачыклау вакыты җитмәде әле. Барысы да вакыт сынавын узарга тиеш. Әгәр сират күперен кичә алсалар, менә шунда кемгә таянырга кирәклеген чамалармын да. Минем бүгенге эшем рентгенологныкы кебек, кемне телим—барысын да үтәли күрә алам. Программа белән дә ашыгырга ярамый, илнең кая борылачагы ачык түгел.

Прокурор сөйләшүнең үзе өчен уңай якка авыша баруын байтактан сизгән иде инде, моны ханның югалып калуы да раслады, шуңа күрә үз-үзенә нык ышанган тавыш белән дәвам итте:

—Алдагы хәлләр, кадерле хан, стратегияне һәм тактиканы да ачыкларга ярдәм итәр, кешеләрне дә урынына куяр. Сез хөкүмәтне һәм партия аппаратын үзегез теләгәнчә, үзегезгә охшаганча төзегән идегез, хәтта бүген сезне саткан кешеләргә ставка ясадыгыз. Хәер, алларына зур максатлар куйсалар, сезне сатуларын да аклар идем әле, ә болар югалып калганнан, куркаклыктан, үзләре бер тиенгә дә ярамаганлыктан саттылар. Аңлыйсыздыр шәт, ничә еллар буе сез күтәреп йөрткән кешеләр чын мәгънәсендә мескен мәхлук булып чыктылар, Ватан турында уйлау кая, үз-үзләрен дә саклый алмыйлар. Гомерләре буе рәсми курс белән сезнең теләкләр арасында бәргәләнеп йөрделәр, ә хәзер бу ярга да, теге ярга да сыена алмыйлар, монда да, анда да куркыныч, беркайда да гарантия юк, ә алар үзләренә әләгәчәк калҗага катгый гарантия булганда гына яши алалар. Өстенлекләр өчен көрәшергә, һичъюгы аларны сакларга икәнен оныталар, моңа өйрәтелмәгәннәр, алар кояшлы көндә һәм җил аркан килгәндә генә йөзә белә, ә бүген тормыш дингезендә давыл...

—Монысында сез хаклы, Сухробҗан, ставканы дөрес куймаганбыз, кирәкмәс нәсел чыгарганбыз,—дип тыныч кына әйтте "Күз буучы".

—Нәкъ шулай, бик үткен әйттегез, кирәкмәс нәсел. Аларны халык та яратмый, хакимияткә дә туры килмиләр, шуңа ярсыналар, үзгәртеп коруга каршы төшәләр, яңалык юлында бүрәнә булып, юк... тимер-бетон тау булып яталар.

—Үзгәртеп кору юлында?—дип көлемсерәде Акмал хан.

—Нигә, шулай түгелмени? Бары шушы юлда республиканың чын мөстәкыйльлегенә, бәйсезлегенә ирешергә була, ирек-хөрлек буш сүз түгел. Барлык революцион үзгәрешләр этаплап бара, Октябрь инкыйлабына кадәр февраль түнтәрелеше булган. Башта үзгәртеп кору трамваенда күпмедер юл үтик әле, аннан соң күз күрер. Үзбәкстан мөстәкыйль була калса, уйлавымча, без илнең ышерен хуҗалары түгел, сез, кадерлем, шундыйлар рәтенә керәсез, ачыктан-ачык чын хуҗалары булырбыз. Суверенитет күп нәрсә бирә, Мәскәү кубызына биемичә, үз дигәнеңне тормышка ашыру да ул. Мондый юлны үзгәртеп кору гына бирә ала, аны алыштырыр нәрсә юк, Акмал әкә, ул безнең максатлар белән туры килә.

Политика нечкә, нәзберек эш, дөресен әйтсәм, мин бу эштә әлегә зур белгеч түгел, ләкин мин үземә башлы киңәшчеләр табачакмын, консультантларым да булыр, берәү, минемчә, бар инде—Сенатор сиздереп-сендереп йорт хуҗасына карап куйды һәм сөйләшүнең шундый борылыш ясавына аның канәгать икәнен аңлады.—Хәзер, Акмал әкә, никадәр неформаль берләшмә ярaлды, кайчагында программаларында революцион орлыклар да күрәм, аларның иң яхшыларын үземә җыя барам, алга таба исә иң амбициоз идеологларны маңгайга-маңгай бәрелештерәчәкмен, ызгышканда

кемнең кем икәнен яхшы таныйсың, алар чыгарган яшеннән сигаретка ут кабызу кыен түгел. Бәхәсләрдә өстен чыккан идеяләрне туплап эшкә җигәчәкмен.

Шулай булгач, мин бер конкрет программа турында сөйли аламмы? Сезнең теге Конго генсекына кайтсак, шуны әйтим, иң әүвәл лидер кирәк, партия һәм программа табылыр.

—Ышандырып бетерә алмадыгыз, ләкин фикерләрегездә таза орлык бар. Эх, һичьюгы ике-өч ел сезгә легаль рәвештә киңәшләр бирә алган булсам, без туган ягыбызны тамырдан үзгәрткән булыр идек,—Хан сигарет алырга пачкага үрелде, капның буш икәнен күреп:—Мин хәзер алып керәм,—диде дә бүлмәдән чыгып китте.

Ул ун минутлар чамасы югалып торды һәм нәкъ менә Сенатор яраткан ике кап "Кент" сигареты белән әйләнеп керде, кирәкмәс нәрсәдәй дастарханга ташлады.

Сигарет кабызганчы Аксай Крезы болай дип куйды:

—Сез мине бүген уттан алып ялкынга ташлыйсыз, шайтан алгыры, белсәгез иде, туган ягыбыздагы вакыйгаларга актив йогынты ясый алмавым шулкадәр үкендерә, кызганыч, бик кызганыч! Үзгәртеп коруны бүген сезнең күзләрегез белән күрдем, максатларыбызга ирешер өчен нинди көчле этәргеч булыр иде ул. Әйдәгез, янача фикер йөртү өчен эчеп куйыйк, безнең хисләнергә яратучан генсек мөнбәргә басып шулай дияргә ярата ич.

Алар эчеп җибәрделәр, хуҗа тагы кунакчыл кешегә әйләнде, тагы капкаларга чакырды, әле тегесен, әле монысын аның алдына этеп куйды. "Димәк, мин үзсүзле хан йөрәгенә юл таптым",—дип уйлады прокурор куанып, ләкин "Күз бууччы" яңа сорау ташлады:

—Тик шулай да, Сухробҗан, минем тормышымны саклап калырга тырышып, сез үзегезне куркыныч астына куясыз, мин һәрнәрсәгә түләргә өйрәнгән, шул бәяне беләсем килә. Идея—идея инде ул, ә акча—һәрвакыт акча булып кала. Әйткәнегезчә, сез мине алыштырасыз, шул рольдә буласыз ди, моның өчен кесәгездә нидер булырга тиеш, акчасыз политика мәет кебек ул, бигрәк тә безнең шәрекъта. Коры идеягә бездә балык чиртми, тәҗрибәмә ышаныгыз,—диде Аксай Крезы һәм кычкырып көлеп җибәрде, чөнки ул хан тәхетенә дәгъва кылучының йомшак ягын сизеп алган иде инде.

—Үзегез беләсез, сәясәткә акча табыла ул,—дип, ерактан суктырды ҮК кешесе. Аңа әле финанс ярдәме сорарга да кирәк булачак, әмма бу мескен рәвештә килеп чыгарга тиеш түгел, аласың икән, зур сумма алырга.—Кешенең табигате шундый инде, ул акчасыз тора алмый,—дип дәвам итте Сенатор.—Яшел байрак идеясе һавада, күктә очып йөри инде һәм ул бик күпләрнең күңеленә якын, бу эшкә акча җәлләмәячәкләр, безнең якларда, нык кына киметеп әйткәндә дә, ике миллиард законсыз кергән акча бар. Фәкыйрьрәк безнең яклар өчен искиткеч зур сумма. Әйткән идем бугай инде, без бәндәгез бүген рентгенолог ролендә, миңа йөзләрчә кешеләрне үтәли яктыртырга туры килде, ул мәгълүматлар компьютерга салынган. Аларның күбесе әлегә иректә, үзләренә компромат җыелганы башларына да килми, чөнки алар аптырамый торган үшән затлардан, бәлки көчләренә артык нык ышаналардыр. Ләкин, койрыкларына күптән утырдылар инде. Миллионнарга ия бу кемсәләрнең һәркайсыннан шул мәгълүматларны алыштыру яисә юкка чыгару хакына мин зур суммалар сорый алыр идем. Ләкин бу мине алар белән бәйләячәк, шуның өстенә, кайберләрен чын күңелдән җәллим дә әле. Әгәр максатлар өчен принципларны читкә куеп торырга кирәк икән, монысын да эшләячәкмен, акча да табачакмын.

Тагы бер сорау туарга мөмкин, ни өчен алар акчаларыннан җиңел генә аерылачак? Монысы мәкерлерәк вариант, бәлки ул мине начар яктан күрсәтәдер дә, әмма мин, булачак төп киңәшчемә анысын да әйтергә тиешмен. Инглизләрдә: "Политикада бар гамәлләр дә яхшы", дигән сүз бар. План мондый: КПСС Үзәк Комитеты бланкысында яшерен документ, табигый ки, ялган документ әзерләячәкмен, анда томанлы рәвештә генә акча реформасы көтелүен, иске акчаларны яңага алыштыруның бик каты кыса-

ларда, декларация төзеп, катгый рәвештә эш урыннарында гына барачагы искәртеләчәк. Кешене шөбһәләндерү, күңеленә шом салу авырмыни. Шул документны һәркайсына аерым-аерым шәхсән күрсәтсәм, бу кеше моның өчен "яхшылыгыңны мәңге онытмам" ди-ди, акчалары белән шатлана-шатлана уртаклашачак.

—Сухроб, син—чын иблис! Мондый фикер башыма да килмәс иде, син чыннан да, политик, шәрыкъ сәясәтчесе. Дөресен генә әйт әле, нишләп операцияне миннән башламадың, кабачак идем бит!

Сорау шулхәтле урынлы яңгырады, күңеле күтәрелгән Сенатор дәвам итте:

—Беренчедән, акчадамыни хикмәт, аңлыйсыздыр, кирәксә, мин аны таба алам. Нишләп мин сезне алдарга тиеш ди әле, без бергә буласы, алда сезнең финанс ярдәмегез дә, башкасы да кирәк булачак... Шуның өстенә, сез реформаның котылгысыз икәнен аңлыйсыз, инфляция адымнарын да сизәсез.

—Акылга сыя бу! Тик, шулай да, Аксайда ничә сум әләктерергә уйлаган иден?

Ике Гертруда иясенең акча турында шулай турыдан-туры соравы прокурорны беркадәр читенсендерде, хәтта саграк булырга кирәклеген кабат исенә төшерде, ләкин ул моны ханның комсызлыгыннан дип уйлады. Аның үтә саранлыгы хакында риваятьләр йөри. Ачыктан-ачык сөйләшүләр вакытында "Күз буучы" кызып китеп, яхшылыклары турында сөйләгәндәй, алтын тешләрен ялтыратып: "Әйе, мин комсыз, бик комсыз кеше, минем өчен түләп бетермәү—акча табу белән бер ул",—дип, көлә-көлә мактана икән.

—Сүз башында, бер үтенечем булачак дибрәк әйткән идем, минем планнарымда ул акчадан кыйммәтрәк йөри.

—Акчадан да кыйммәт ни булыр икән, бөтен нәрсәне акчага сатып алып була,—диде хан, күрәсең, коньяк башына бәргәндер, алар Сабир-баба алып килгән яңа шешәләрне дә очлап бетереп киләләр иде инде.

—Юк, андый нәрсәне димме, бернинди акчага да сатып алып булмый. Бу мәсьәләдә сездән башка ярдәм итәрдәй кеше юк. Мин сезнең картотека һәм досьеларыгызны күздә тотам, аларда мине кызыксындырган кешеләр турында үтә мөһим мәгълүмат тупланган. Аларны сез бераәмтекләп, егерме ел буе җыйгансыз икән, дип тә сөйлиләр. Мин аларның КГБ кулына эләгүен теләмим, алар сездә андый документлар барын беләләр. Кәгазьләр сезгә булышмас, бары хәлегезне генә мөшкелләндерер, аларны тоту бүген аеруча хәтәр. Әгәр вакыт булса, мин монда өр-яңа компьютерлар алып килер идем, белгечләр ике-өч айда, иң күп дигәндә дә, ярты елда бар мәгълүматларны компьютер хәтеренә салыр иде. Сезнең данлыклы җир асты мәгарәләрендәге бүлмәләрдә, мәгълүматларга күз салу хокукына ия күп санлы штат тоту кирәге дә калмас иде. Хәтта, берничә копия алып, аларны яшерен урында сакларга була, кирәксә аларны юкка чыгару секундлык эш, клавишага гына басасы.

—Әйе, компьютерның мөмкинлекләрен мин вакытында бәяли алмадым, тормыш, көнкүреш, информатика—барысы да бик тиз үзгәрә, күп нәрсәгә житешеп булмый, ләкин, искечә уйлавым белән дә яшерен архивымның зурлыгын, жайсызлыгын аңлый идем, куркынычлыгы да бар, шуңа да иң кызыклы материаллардан фотокүчермәләр ясаттым. Минем бар материалларны юкка чыгару өчен кимендә ике атна вакыт, авыр физик эштән тайчанмаган биш кеше кирәк булыр иде.

—Үзегезнен яраткан "эшегез" турында сөйли башлагач, мине күптән борчыган мәсьәлә буенча сорау бирергә мөмкинме?

—Рәхим ит!

—Рәшидов сезнең досьегызның һаман үсүеннән шикләнми идеме?

—Юк, мине кызыксындыручы иң бай материалны нәкъ менә аннан алдым да инде. Икәүдән икәү калып сөйләшеп утырганда гына да түгел. Бервакыт Аксайга аннан пичәтләнгән бер контейнер кәгазь килеп төште. Шурик мина ышана иде, кем белә, бәлки ул досьеларны минеке дип түгел, үзенеке дип санагандыр.

—Нинди Шурик?—дип сорады югалып калган Сенатор, ул “Күз буучы” исерде һәм тузга язмаганны сөйли башлады дип уйлый иде.

—Шурикмы? Ишеткәнегез юк идемени, мин аңа шундый кушамат тактым ич, күптән инде, үзе югында мин аны гел шулай дип кенә йөртә идем.

Кунак жинел сулап куйды, юкса исерек кеше белән төнне юкка уздырдым дип курка башлаган иде. Ләкин, ничек кенә булмасын, сүз ул теләгәнчә бара иде.

—Жыелган мәгълүматлар белән уртаклашунын акчадан да кадерлерәк икәнен анладыгызмы инде хәзер?—дип сорады ул, тавышына ялагайлану кертеп, һәм дәвам итте:—Ләкин финанслата ныгытылмаган мәгълүмат та барысын да эшли алмый. Ә алырга теләгән акча, иң беренче нәүбәттә, сезне легаль тормышка кайтару өчен файдаланылачак. Илдәге хәлләр, хакимият, аның максатлары искечәгә таба үзгәрсә, сезнең өчен барысы да үз урынына кайтачак, ләкин шулай булсын өчен кешеләр, акча, мәшәкатьле озак эш һәм, табигый ки, уңышка ирешә белү дә зарур.

—Дөрес, уңышка ирешә белү, аерым хәлләрдән, вәзгыятьтәге уңайлы вакыйгалардан файдалану политикада соңгы чаралардан түгел. Димәк, кадерле прокурор, минем досьены, аның белән бергә акчаларымны да кулга төшерергә ниятлисез?—дип сорады Акмал хан артык шат тавыш белән һәм нигәдер урыныннан күтәрелде.

“Менә төп максатка барып життем,—дип уйлады Сенатор.—Хәзер инде шушы кәгазьләр бәрабәренә гомерен сатып алганда комсызлыгы, үз-үзенә артык ышануы гына комачауламасын. КГБ ОБХСС түгел, анда сатулашмыйлар, досьедагы һәр яшерен сүзгә бәйнә-бәйнә аңлатма бирдерерләр, гөнаһларың өчен хөкем каршына басарга туры килер, андагыларны миллионнарың белән кызыктырып булмый. Акча куәтенә артык ышануы бу юлы һәлакәткә илтәчәк. Моңа охшаш кешеләрнең иң йомшак урыны—аларның катгыян инануынча: барысы да сатыла, барысы да сатып алына, хикмәт бәядә генә”. Бу фикер аның үзенә дә кызык тоелып китте, бу аның үзенә күрә бер ачышы иде, өйгә кайткач моны көндәлеккә төртеп куярга кирәк дип уйлады ул.

Хан каядыр аның артында йөренә иде, озын йонлы әфган келәме аның аяк адымнарын йота, ләкин ул чамадан тыш майлы ризык ашауданмы, күп итеп эчү һәм тартуданмы авыр сулый иде. Прокурор эченнән генә күпме акча бирү турында баш вата дигән фикергә килде һәм көрән-зәнгәр “Кент” сигарет кабына үрелде.

Һәм шунда көтелмәгән хәл булды. Байраклар куелган стена буенда йөрүче авыр гәүдәле Акмал хан кинәт, яшен тизлегендә дастарханга таба ыргылды, йомшак мендәргә янтайган прокурорны сикереп чыкты, тупас итеп сүгенде һәм аның сигаретка үрелгән кулына китереп типте. Сигарет кабы катапультадан очыртылган кебек тәрәзә пыяласына барып бәрелде. Сухроб берни анларга өлгермәде, хан аны типкәли дә башлады:

—Жүләрләрне эзлисенме, пычрак мент? Ташкентта кемнәр белән көнетөне әже-гөже килеп, яңа прокурорның әшнәсе булып яхшатланып йөргәненне, әллә белмиләр дисеңме? Республикадагы иң хөрмәтле кешеләрне төрмәгә утыртуда синең кулың уйнамадымыни?! Менә хәзер берни яшерми сөйләрсең, кем белән минем бөтен барлыгымны: акчаларымны, яшерен досьеларымны кулга төшерү планын төзедегез? Кем булышты? Кемнең башына килде! Ислам, яшел байрак, ирекле Үзбәкстан өчен акча кебек сафсатаны кемнәр уйлап тапты? Мәскәүләрме, тикшерүчеләрме, прокуратурадагы дусларыңмы, әллә кэгебэләрме?..

Ә мин, жүләр, чүт кенә капмадым бит. Ничек шәп бит, ә—барысын компьютерга тутыралар имеш! Копиясен КГБга, прокуратурагамы? Менә хәзер кирәкле кеше килер, синең кебек адәм актыкларыннан сорау ала, сөйләттерә белә ул. Авызыңны йомсаң—моннан исән чыга алмассың! Синдәй хаинга үлемнең дә хәтәрен табарбыз. Тандыр-кабаб белән бассейн ошаган идеме? Менә шунда рәхәтләнеп үләрсең: йә зәңгәрсу залда юкка чыгарырбыз, яисә тандыр-кабабта тереләй кыздырырбыз. Аннан соң пычрак

эзең дә калмасын өчен дуңгызларга ыргытырбыз. Үлемең алдыннан мине тыңла, акыллы баш. Син закон прокуратура, суд, юстиция, МВД, КГБ кулында дип уйлыйсың инде, әйеме—чүп сүз бу, эт өрүе, иллә кем хуҗа икәнен аңламаган мингерәүләр өчен ул. Хуҗа бер генә, ул—баш та, түш тә, закон да, аның исеме—партия! Белеп тор, селәгәй, мин Үзәк Комитет әгъзасы, Югары Совет депутаты, мин хаталанырга да мөмкин, җинаятьләр дә кылырмын, ләкин минем кебекләрне хөкем итмиләр. Иң зур җәза—эштән алалар, пенсиягә җибәрәләр, анысы да персональ привелигияләр белән, сезнең бу төшегезгә дә керми. Син башта, җүләрбаш, кызыксыныр идең, Мәскәүдән кемнәр Аксайда булган, анда, башкалада мин кемнәр белән булган, Шәрәф Рәшидович белән кем дачасында кунак булганбыз. Алар бит исерек баштан бездә ни генә кыланмыйлар иде, миндә барысы да теркәлгән. Миндә бухгалтер җаны, исәбен дә хисабын да яратам. Шулай булгач, җанкисәккәем, әлеге кешеләр белән мин бер обоймада, бер арбага җигелгән, кем мине утыртырга рөхсәт бирер? Ә син миңа үз илемдә иммигрант булырга тәкъдим ясыйсың. Барып чыкмас! Әле партия дилбегәсе минем дуслар кулында чакта, син дә, кулдашларың да, КГБ да мине ала алмый, тешегез үтмәячәк, моны мыегыңа чорнап куй. Ә хәзер курыктыммы мин синнән, юкмы, анысын үз тиреңдә татырсың, хәтта ҮКның бүлек мөдире булсаң да...—һәм ул кычкырып тавыш бирде:—Ибраһим! Ибраһим!!

Прокурор коридордан йөгереп килүченең итек шыгырдавын ишетте. "Күрәсең, иртәнге чәйдәшләрнең берседер",—дип уйлады һәм ялгышмады, бүлмәгә, кулындагы тимерләрен шылтыратып, аны ошбу бүлмәгә озаткан бәндә килеп керде, көн ахырында, ниһаять, аның да исеме мәгълүм булды-Ибраһим атлы икән. Ул аның янына йөгереп килде дә дагаланган итеге белән янтыгына китереп типте, прокурор куырылып катты, кабырганы сындырды бугай дип уйлап куярга гына өлгерде, шулчак арка сөягенә типтеләр, авырту үткен пычак белән яргандай булды, Ибраһим тагы берне өстәде һәм Сенатор кыргыйларча кычкырып җибәрде.

—Кычкыр, кычкыр, монда сине КГБ да, МВД да ишетмәячәк,—диде шатлыклы усаллык белән "Күз бууучы" һәм көлеп җибәрде, аңа алтын тешле иярчене кушылды.

Ибраһим аның сул кулын кинәт кенә үзенә таба тартты, шунда гына кунак чыңгылдаган теге тимернең богау икәнен күреп алды. Әлеге адәм, аның сул кулына богауны кигертеп, йозагын бикләмәкче иде, әмма сәгать беләзеге ирек бирмәде. Ибраһим аны ычкындырырга азапланып карады, тик барып чыкмады. Чөнки "Ролекс" яшерен җайланмасы булган ике каптыргычлы иде. Хуҗа аның озак маташуын ошатмыйча, ярдәмгә ташланды, ләкин саллы алтын беләзеккә кагылуга, аптырап һәм күпмедер куркынып сораганын сизми дә калды:

—Сухробҗан, бу сәгатьне каян алдыгыз?—Сорау шундый хис һәм курку белән бирелгән иде ки, Ибраһим, ниндидер аңлашылмаучанлык килеп чыкканны сизенеп, ирексездән читкәрәк китте.

Сенатор хуҗаның югалып калуын сизде, исән калу өчен берданбер өмет туганын аңлап алды, чөнки, кызып китсә, ханнан әллә ниләр көтәргә була, шуңа тыныч кына җавап бирде:

—Япон бүләк итте.

—Нинди Япон, чын японмы, Кояш чыгу иленнәнме?—дип сорады тирле мангаен сөртеп Акмал хан.

—Артур Александрович дигән кеше бар, ул Әнвәр Абидовичның якын дусты, Шәрәф Рәшидовичны да яхшы белә иде. Япон—аның Мәскәүдәге кушаматы.

—Артур Александрович сезнең танышмыни?—бу сорауны Акмал хан бөтенләй мингерәүләнеп бирде һәм башы белән изәп Ибраһимны чакырды, богауны салдырырга кушты.

—Әйе, без аның белән якын дуслар, ул миңа күп яктан бурычлы,—дип тыныч кына җавап бирде кыйналган кунак һәм берни дә булмаган кебек икенче кап сигаретка сузылды.

“Күз буучы” ярарга тырышкан хезмәтчедәй аңа чакма сузды, үзе дә тартып җибәрде.

—Әллә ничек килеп чыкты бит әле бу, мин бит сине сарык тиресе ябынган бүре дип уйлаган идем.—Акмал ханның һаман икеләнүе бүртенгән йөзендә сизелә иде әле, башында исә бер генә уй-шик бәргәләнә: нишләргә, нишләргә?—Прокурор моны һич көчәнми генә укый алды, кинәт Акмал ханның йөзе яктырып китте һәм ул хезмәтчесенә карап әйтте:

—Ибраһим, тиз генә Артур белән тоташтыр, хәзер төн уртасы, гаилә кешесе бит, өйдәдер, әйт, сезне Әкрәмхуҗаев сорый диген.

“Ниһаять, мине ничек тикшерергә кирәклеген аңлады”,—дип уйлады прокурор һәм зур канәгатьлек белән сигаретын суырды, дагалы итек типкән янтыгы авырта иде. Ибраһим тәрәзә төбеннән телефон аппаратын алды һәм аны прокурор алдына куеп чыгып та китте. “Өйдә булса гына ярар иде”,—дип, дога укыгандай күңеленнән бер үк сүзләрне тәкрарлады кунак. Акмал ханның котырынкы холкы аның алга таба ни кылачагын күз алдына китерергә дә ирек бирми иде. Ул тыныч кына тарта бирде, килеп чыккан алама хәлне төзәтер өчен ханга фантазия җитми, ә кунакка төрле юк-бар хакында акыллы сүз алышу өчен нервы киеренкелеге комачау итә иде. Алар шулай җиде-сигез минут утырганнардыр, шуннан артык түгел, ләкин алар прокурорга сәгатьләрдән дә артык тоелдылар.

Ниһаять, ишек ачылып китте, тупсада икенче алтынтеш күренде, иртәнге мәҗлестәш, кунакка йомшак кына эндәшеп, болай диде:

—Сухроб әкә, трубканы алыгыз, зинһар, элемтәдә Ташкент.

Ничек кенә тыныч булып күренергә теләмәсен, прокурор трубкага артык каударланып ташланды, аның бу борсалануы хуҗалар күзеннән ычкынмый калмады, әлбәттә.

—Исәнмесез, Сухроб Әхмәдович,—трубкада Шубаринның һәрвакыттагыча көр тавышы яңгырады.—Сезне һәрчак, хәтта төнлә ишетүемә дә шатмын, ләкин, дөресен әйткәндә, сезне шулай еракка барып чыгарсыз дип башыма да китергәнем юк иде. Минем дусларымда вакытны күңелле уздырасыздыр, дип ышанам.—Япон аңа гына хас манерада сөйләшә иде: сүзләре кыскатөгәл, һәркайсына яшерен мәгънә салынган, ул прокурорның бәлагә юлыкканын, телефонны тыңлап торуларын да аңлаганын шулай сиздерде.

—Әйе, төн әкияттәгечә, сезне дә үзем белән бу сәяхәткә кодаламавыма үкенәм, тылсымлы, шаккаткыч парк, бассейн, сауна... хуҗа да ханнарча каршы алды.

—Кызыклырак булсын өчен берәрсен терелләй утта кыздырмыйммы? Бу аның рухына туры килә,—диде Артур Александрович, барысын шаяруга аудару өчен үзе көлеп тә җибәрде.

—Мин монда үзем генә, алда әле төн, күңел ачу программасы миңа билгесез, мин Аксайда беренче тапкыр, бәлки андые да кителәдер.

—Аңладым, яхшылап ял итүеңне, хушлануыңны телим, ә хәзер, трубканы Гречкога бирсәнче.

—Исәнме Артур, гафу ит, төн уртасында күтәрдем, монда синең исәнлеккә дә эчтек,—диде “Күз буучы” Сенатордан күзен алмыйча.—Миңа күктән көтмәгәндә кунак килеп төште, синсез генә булу бик җәл. Безнең арада бераз гына тавыш чыкты, син гафу ит инде, ул синең дустың икән.

—Әйе, ул минем дустым, кадерле Акмал, аның тормышының бәясе юк, игътибарлырак бул, шунысын да онытма, дүшәмбе ул эштә вакытында булырга тиеш! Ул сиңа кайда эшләгәнен әйттеме?—Шубарин шулай итеп, гәрчә прокурорның Аксайга ни өчен килгәнен белмәсә дә, аңа тагын бер коткаргыч бау ыргытты.

—Әйтте, әйтте, борчылма, ялт итеп үзем илтеп куям. Артур, соңгы вакытта аз очрашабыз, дусларыңны белеп бетермим.—Йорт хуҗасы ризасызлыгын белдереп тә өлгермәде, сөйләшү өзелде.

Шубаринның сөйләшүне үзе өзүен Сенатор яхшы аңлады, чөнки телефоннан озын-озак сөйләшүләр төнге телефонисткаларның кирәкмәс кызыксынуын уята иде.

—Әйе, ялгышлык чыкты,—диде ихластан "Күз буучы".—Сез, Сухробжан мине, зинһар, гафу итегез, күрәсең, картайганмындыр ахрысы, дусларны дошманнан аера алмый башлаганмын, элек андый хаталар ясамый, кешеләрне китап урынына укый идем. Ләкин сез дә анлагыз, вакыйга бит гадиләрдән түгел, сүз йә үлем, йә яшәү турында барды, сайлар өчен вариантлар да юк диярлек иде.

—Исмәт!—дип кычкырды ул кинәт кенә. Богау тотып кергәннең төстәше пәйда булды.—Ибраһим керсен һәм кадерле кунак алдында гафу үтенсен, ул анын белән үзен итагатьле тота алмады.

Исмәт дигәне әйтте:

—Акмал әкә, ул Сухробжанның Артур белән зур дуслыгын белүгә үк, куркуыннан кая керер урын тапмый. Кунакның күзенә күренмәс өчен өенә китте, мин аны тыя алмадым, болай да нишләргә белми ул.

—Ярый, иртән гафу үтенергә килсен,—диде борын астыннан гына хуҗа.—Ә хәзер фәрман бир, саунаны жылытсыннар, пешекчеләр егермеләп бытбылдык кыздырсын, бавырдан шашлык ясасыннар. Өстәлне һавага, тышка куегыз, кунак күнелсез минутлар турында искә төшермәсен, Сухробжан белән без бассейнда коенабыз. Су кешене чистарта, көр күнелле итә, суда үпкәләүләр тиз уза, үземнән беләм. Барысын да аңладыңмы?

—Әйе, хуҗа,—диде Исмәт хәрбиләрчә һәм коридорда итекләрен шыгырдата башлады.

—Торыгыз, Сухроб, бу унышсыз-жайсыз урыннан китик, бүлмәгезгә кереп халат алыгыз, төннең калган өлешен күңеллерәк уздырырбыз. Сез дә минем кебек төн кешесе, ябалак икән, ә бәлки без икебез дә таң алды сәгатьләрен яратабыздыр, мин сезне коену залында көтәм.

Йөзү залына килеп кергәндә, "Күз буучы" анда, үкчәләренә житкән ачык-кызыл төстәге капюшонлы балахонда йөренеп тора иде. Кунакны күрүгә, ул халатын келәм-юлга ташлады һәм бассейнга чумды. Сенатор да анын аерым чакыруын көтеп тормады, су аны кичәгедән дә ныграк тарта иде.

Берничә сәгать кенә элек бассейнда куркуын хәтерләп, прокурор тандырны да искә төшерде, аны бит тере килеш кыздырмакчылар иде, шикләнүләрем дөрес булган икән дип, уйлап куйды ул. "Күз буучы" ана гүзәл су коену залында матур үләчәксең диде, шулай булгач, электр тогы беләндер. Ләкин хәзер ул куркуны белми иде, юк, юк!—Акмал хан анын белән бергә коенганга түгел, аны Артур Александровичның яклавы бу хистән арындыра иде, ни генә димә, Шубарин канаты астында курыкмасаң да була.

Сенатор алтынсу төстәге йомшак халатын ашыкмый гына салып атты да Ибраһим типкәннән калган канлы эзгә күз төшерде һәм Акмал хан шикелле үк тавышлар чыгарып, суга чумды.

Бассейнның икенче ягына житкәч кенә калкып чыкты, "Күз буучы"ның су коену оештыруына бик тә мәмнүн калды, чөнки салкынча су тынычландырды, хәтта сул янтыктагы авырту да кимегән кебек булды, кызыл байраклы бүлмәдәге хәлләр дә онытыла төште. Акмал хан, суны эре-эре генә куллары белән ишеп, анын янына йөзеп килде, кунакның тынычланганын күреп әйтә салды:

—Сухробжан, ярый әле кулыгызда теге сәгать булды, ул сине коткарып калды, дөресен әйткәндә, мин рәнжүдән һәм кайгыдан башымны югалткан идем. Мине ташлаганнарын, сатканнарын беләм, Ташкент белән элемтәне өзделәр, Шурик вакытындагы кебек бар нәрсәне белеп торсаммы, мин синең Артур белән дус икәненне генә барыбер чамалар идем. Ә ул егет кеше, андый колачлы кешеләр сирәк, менә кемгә бирергә кирәк ул экономика министры портфелен, хәтта ислам республикасы булса да. Шубарин халыкны ничек ашатырга, киендерергә икәнен барысыннан да яхшырак белә, аннан идеяләр фонтан кебек атып тора. Аксайда мин анын күп проектларын тормышка ашырдым һәм сезнең янәшәдә шундый кинәшче булуга бик шатмын. Анын имансыз Тилләхужаевка бирелгәнлеген, тугрылыгын гына күз алдына китерегез, шуна гына анын гаиләсенә бәйләнүне туктаттылар да. Мин барысын да белеп торам ич, тагы теге төнге сакчыны искә төшерегез, ниндидер мистика бу.

—Ариф тавышйомгыч куеп ата, биш зарядлы "Франчи"енда төнлә күрү приборы бар, ул кыштырдауга, шыпырт кына сөйләшүгә карап та ата, аны тренировкада күргәнем бар—фантастика!

—Әйе, Артурның барысы да беренче классны: бухгалтерлары да, плановиклары да, осталары да, хәтта кеше үтерүчеләре дә, ә тән сакчылары, мин аның Костасын үз ягыма аудармак булган идем, барып чыкмады,—диде "Күз бууы".—Аның бүләк бирүе генә дә ни тора, балаларча шатланасың, менә аның бүләге сезнең гомерне саклап калды, мин дә гөнаһлы булмадым. "Ролекс"ны ул миңа моннан биш ел элек бүләк иткән иде, очраклы рәвештә генә Мәскәүдә очрашкан идек. Шәрәф Рәшидович белән СССР Югары Советы сессиясендә идек, Артурның яраткан ресторанында, "Советская" гостиницасы ресторанында әбәтләп алдык, ул аны искечә "Яр" дип атый.

Өстәл янында бүләген биргәндә ул болай дигән иде: "Акмал әкә, менә сезгә атаклы Швейцария фирмасы сәгате, алар минем өчен шәхси заказ буенча махсус ясала, ак алтын телле, ак алтын циферблатлы мондый сәгатьләр санаулы, әгәр кемнеңдер кулында күрәсез икән, онытмагыз—алар безнең кешеләр, алар да сезне аңлар һәм ярдәм итәр."

—Сезнең кулда "Ролекс" булмавы кызганыч, уртак телне тизрәк тапкан булыр идек,—кунак көлеп җибәрде.

—Әйе, мин аны сирәк тагам, безнең караңгы якларда артык күзгә ташлана, ул сәгать миңа бер генә кирәк булыр иде,—диде "Күз бууы".

—Бер тапкыр, әмма минем өчен ул гомер өзелүгә торды,—дип куйды рәнҗүле тавыш белән кунак.

—Әйдә искә төшермик, кадерле Сухробҗан, барысы да әйбәт бетте, мин гаебемне юармын. Ышана күр, мин бит җәза бирүче генә түгел...

Сауна ишегендә таныш мунчачы күренде:

—Сухроб әкә, йөз дә ун градуска җитте инде, саунага керергә ярый...

—Сауна шәп нәрсә, тиз айныта,—дип көлде йорт хуҗасы һәм алар икесе ике тарафка, ике басмага таба йөзеп киттеләр. Прокурор үзен ток биргән дип санаганына таба йөзә иде.

Саунада тирләп утырганда, Акмал хан үзен борчыган уйларына кайтты:

—Әйе, мине тиз оныта башладылар, тиз генә сызып ташламакчылар. Шурикның юклыгына өч кенә ел, ул бетүгә, барысы да чәчелеп китте, таралды, нинди дер нәсел-нәсәпсез яңа кешеләр күренә башлады. Русча әйтсәк: с глаз долой, из сердца вон. Артур да мине ташлады, хәер, аның эшләре ничек баруын мин үзем белергә тиеш идем, сезгә килеп чыгар идем. Шубаринга мин сирәк мөрәҗәгать иттем, бары Шурик соравы буенча гына, әле анда да эшләр читтә булса. Японның Мәскәүдә элемтәләре бик зур, аны кайда да беләләр. Сезнең инглиз истребителе "харриер" кебек вертикаль күтәрелүегезне мин күз уңыннан ычкындырдым, күрәсең, чыннан да картайганмындыр, вакытны аңламыйм. Белсәгез иде, иң авыры вәзгыятне кулында тота алмау икән, нәрсәнедер аңлап бетермисең. Әгәр дә мин үзсүзле, кире булмасам, замананы аңласам, ике ел элек үк инде архивымны компьютер хәтеренә кертеп куйган булыр идем.

Миңа Мәскәүдән бер ышанычлы кешем ике шәп "спец" җибәргән иде, ул мине күп еллар инде видеофильмнар белән тәэмин итеп тора, алар "ИБМ" компьютерында син әйткән эшне башкармакчы булдылар. Миңа ул вакытта натурада, кәгазьләрдә ышанычлырак, бөтенрәк тоелды. Менә бүген генә аңладым: тормышымда иң кыйммәтле нәрсәне—бөтен байлыгымның асылын тәшкил иткән архивымны бер чемоданга сыйдырып алып китәрлек итәсе булган бит. Ул чемодан белән мин элеккечә көчле, үз тормышымны саклап калырдай гайрәтле булыр идем, чөнки ул досьелар үземдә булыр иде. Кайбер информация кеше гомереннән дә кыйммәтрәк була. Кайчакта кеше үтерү өчен мин акча түләп тормыйм, ике-өч кәгазь салынган канцелярия папкасы гына бирәм, акчага риза булмаска да мөмкиннәр, ә кирәкле хәбәрләр, документлар акчадан кыйммәтрәк йөри. Алар күп тапкыр ышанычлырак, нәтиҗәлерәк. Менә нәрсә ул, Сухробҗан, син кызыккан һәм кулыңа төшерергә теләгән архив.

—Беләм, кадерле директор, шуна да хәтәр адымга барам. Мин хәтта ул кәгазьләрнең яртысы кирәк тә булмас дип уйлыйм, яңа заман иске кешеләрне себереп түгә, алар артыннан төрле кланнарны мәңгегә сөрә. Ышаныгыз, ике-өч елдан номенклатура мәгънәсе дә югалыр, бүген күп нәрсә аларга бәйле бит, үзгәртеп коруны да алар тоткарлый, юлны бикли, ә сезнең досьеда күбесе номенклатура кешеләренә җыелган документлар. Чамалыйм мин, партиягә кысрыкланырга, кайбер хокукларыннан ваз кичәргә туры килер, әле партиясез министрлар заманында да яшәрбез. Шунысын да онытмыйк, кайчакта бер досье йөз-мең досьены алыштырырга мөмкин. Әнә шул бер досье политик бәхәсләрне чишәргә юл ачарга да мөмкин бит. Нинди генә хокукый дәүләткә омтылмыйк, нинди генә тәрәккый пәрвәр кешеләр һәм демократлар булмыйк, безнең якларда теләсә кайсы режимда, нинди байрак күтәрсәк тә, шәрекъчәлек сакланачак, мин политиканы һәм вазифалар бүлешүне күздә тотам, менә шунда сезнең досьелар кирәк булачак та инде. Мин моны төгәл белеп әйтәм.

—Әйе, сез дөрес нәтиҗәгә килгәнсез, түрәлек кәнәфиләре һәм акчаны бер генә демократия дә юкка чыгарачак түгел, чөнки алар һәрвакыт кешеләрне тартып торачаклар,—дип, ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое яңа политикның дан-шөһрәт сөючелеген үзенчә яклаган булды.

Сауна һәм бассейнда аларга артык рәхәтләнергә ирек бирмәделәр, Исмәт килеп, бакчада өстәл әзерләнгән әйтте, кыздырылган бытбылдыкларны да ун минуттан бирәчәкләр икән. Алар тагын бер кат бассейнда коенып алдылар да халат кигән килеш кенә айванга юнәлделәр. Анда аларны сый-нигъмәтле дастархан көтә иде инде.

Бассейнда һәм саунада Сенатор үзенә яңа көч, күңел көрлеге инүен сизде, бу, күрәсең, кызыл байраклы бүлмәдә булган тетрәнүдән соң эмоциональ янарыш иде, ул хәзер таңгача мәҗлесләп утырырга риза, гайрәттә һәм тормыш сөючәнлектә бер дә Акмал ханнан ким буласы килми. Ләкин йомшак курпачларга утыруга, яндагы мендәргә таянуга, аңлап алды: ул эт булып арыган иде, аны өстәлдәге бай тәгам дә, Мәүлидәнең дус кызының елмаюлары да шатландырмый башлады.

Менә тагы Сабир-баба күренде, кулында икенче поднос иде, коньяк шешәсе дә бер генә—карасу-шоколад төсендәге “Ахтамар”. Ханның “Двин” запасы калмаган микәнни дип, машиналь рәвештә генә уйлап алды ул, ләкин директор, аның уен сизгәндәй әйтте:

—“Двин” йомшаграк, аның белән мәҗлесне башларга яхшы, ә йокы баса башласа, “Ахтамар” шәбрәк тә, ышанычлырак та, үзегез дә сизәрсез.

Эчеп куйдылар. Коньяк, чыннан да, күңел көрлеге кертте, кәефне күтәреп җибәрде, кунак мона сөенде, әлбәттә, ләкин көенечкә охшаш бер корт та бәгырен тырный иде, инде якшәмбе иртәсе дә җитте, ә эш турында һаман ләм-мим.

Ләкин сүз һаман читкә китте, Шубарин белән сөйләшкәннән соң йорт хуҗасы архив һәм акча турындагы сүзне үзе башлар дип көткән иде прокурор, ә ул һаман атлар, хатыннар, Шурик турында сүз куерта бирде. Сенатор үзен кызыксындырган нәрсә турында сүз кузгатырга уйлап кына куйган иде, хан көтмәгәндә әйтеп ташлады:

—Күрәм, сез ардыгыз, төнге мәҗлесләргә дә күнекмәгәнсез, ләкин политика белән шөгыльләнергә уйласагыз, өйрәнергә туры килер, кирәк булачак ул. Мәсәлән, мин үземә кирәкле иң мөһим имзаны тан атканда гына суырып алам, көндезен исә мин аны мәңге ала алмаган булыр идем. Визитыгызның сәбәбенә килгәндә, күзләреннән күрәм, сезне эшнең ахыры кызыксындыра, ярый, мин булышырмын. Артур Александровичның нәрсә майтарырга җыенганыгызны алдан белмәве кызганыч, әлбәттә. Аның артында һәрчак бик зур кешеләр тора, аларны санламау—гөнаһ булыр. Әнә, таң атты инде, барыгыз, ял итегез, Зөлфия сезне озатыр, сәгать көндезге өчтә әбәд ашарбыз, шул вакытка мин сезне кызыксындырган нәрсәләрне әзерләп куярмын һәм кеше күзенә күрсәтмичә генә озату турында уйлармын. Артур сезне эшкә сонга калмасын дип борчыла. Ул үзегезне нинди хәтәргә этәргәнегезне

анлады, хәзер минем белән элемтәдә булу шактый куркыныч. "Зөлфия!"—дип карангыга карап кычкырды ул, артыш куаклары артыннан елмаеп Мәүлидәнең дус кызы килеп чыкты:—Бар кунакны озат, юкса, бакчада адашмаса да, коридорларда буталып йөриячәк ул. Карават янына минераль су һәм суык чәй куярга онытма, мондый мәҗлестән соң тамак кибә ул.

Зөлфия ханны сүзсез генә тыңлады да кунакка күзләре белән ымлап үз артыннан барырга кушты. Әзме-күпме читкәрәк китүгә, Сенатор аның кулыннан тотты:

—Кич буе баш ваттым, сиңа исем уйладым, син Зөлфия икән—матур исем, бу исем сиңа бик килешә, Зөлфия,—дип пышылдады ул, әз генә көйләп.

Кыз аңа борылды, шаярып җавап бирде:

—Ник интектегез, Сухроб әкә, сорасагыз, сезгә исememне алдап әйтмәс идем.

Ул аңа тагы берәр иркә сүз әйтмәкче иде, ләкин өй янында алтын тешле Исмәт көткәнен күреп Зөлфия кинәт кенә житдиләнде, кызу-кызу атлап алгарак китте, алар арасында дистанция зурайды. Бүлмәгә кергәч, ул кызны кочакламакчы булган иде, ләкин Зөлфия атлас күлмәген кыштырдатып тиз генә аның кулыннан ычкынды да елмаеп әйтте:

—Минераль су белән яхна-чәй турында ни әйтерсез, сезнең тамак кибәчәк ич?

—О, бу минем бер төндә икенче үлүем булачак, Ибраһим мине тере килеш кыздырырга җыенган иде, чәйсез, минераль сусыз үлүен үлмәм, мине башка нәрсә—сине уйлап саргаю газаплаячак,—дип шаяртты ул.

Бер мизгелдә коридорга карап алып, кыз кинәт кенә пышылдады:

—Әзрәк көтегез, хәзер Акмал әкә белән Исмәт китәчәкләр, мин аларның сөйләшүләрен ишеттем, шуннан соң мин үзем карармын...

Зөлфия аның яныннан киткәндә таң атып беткән иде инде.

Ул көндезге сәгать икедә генә уянды һәм бассейнга китте. Өй эчендә үле тынлык иде, бары тик бакчада гына кошлар сайрый, әйтерсең, алар Аксай ханының бакчасын мактап җырлыйлар иде. Сауна ишеге төбенә кадәр ачык, ләкин мунчачы үзе юк иде, димәк, бүген парланып чыгу булмаячак. Бер генә мизгелдә хан тагы бер юньсезлек уйламый микән дигән фикер дә уянып алды. Ләкин Шубарин белән сөйләшүне искә төшерү тынычландырды, чөнки аны яклаучылар бар. Инде аны "Күз бууччы" ислам байраклы яңа дәүләт төзү, яисә каты куллы Сталинча-Брежневча дәүләтне торгызу хакына күпме акча атар икән дигән уй борчый башлады. Акмал хан андый дәүләттә тагын турылыклы ленинчы үрнәге саналыр иде.

Ул бассейнда шактый озак юанды, инде кызыл кирпеч стенадагы сәгать өчне сукты, нәкъ шулвакыт яшел капка янында кара "Волга" сигналы ишетелде, хан Акмалның музыкаль итальян клаксоны тавышын әллә кайдан ишетеп танырга була иде.

"Кайтып житте",—дип уйлады Сенатор, ләкин бассейннан чыкмады, хуҗа аны дулкынлана дип уйламасын. Таныш итекләрнең шыгырдавын ишетеп, прокурор борылып карамыйча булдыра алмады, ләкин бассейнга таба директор түгел, Исмәт килә иде.

—Әссаләмегаләйкем, Сухроб әкә,—дип кунакны коры гына сәламләде ул.—Ничек ял иттегез, кәефегез ничек?

—Рәхмәт, бары да әйбәт, яхшы ял иттем. Акмал хан кайда? Ул минем белән сәгать өчтә әбәтләп алырбыз дигән иде, ә өйдә сездән башка беркем юк.

—Әйе, бөтенесе шулай, әбәт инде әзер, ләкин Акмал хан аның икенче җирдә буласын әйтергә оныткан, анда сезне көтәләр, мин сезне алырга килдем.

Прокурорга бассейннан чыгып, ашыгып киенергә туры килде. Зур йортның коридорларыннан барганда ул як-ягына каранды, аның Зөлфияне күрәсе, бер уңайдан саубуллашасы килеп китте, бәлки, ханның планнары нилектән үзгәргәнен аннан белеп булыр иде.

Алма бакчасын чыгуга "Волга" еракта күгелҗемләнеп торучы тауларга

таба борылды. Шлагбаумны үттеләр, кичә мондагы сакчы вертолетны күрүгә, каравыл өенә ташланган иде, күрәсең, ул йә Ибраһимга яисә Исмәткә шуннан шылтыраткандыр. Бүген дежурда изелгән кыргыз эшләпәсе кигән юан кеше иде. Ярты сәгатьтән тагы бер постны уздылар, тау юлы аулак, каршыга ник бер машина очрасын.

"Нык саклана торган тыюлык кебек икән",—дип уйлап алды прокурор һәм як-ягына карана башлады. Тауның сөзәк янтыгына күп еллар чалгы күрмәгән үлән үскән, кечкенә елгачыклар, текә ярдан аска ыргылган шарлавыклар суга-дымга туендырып торгангамы, үлән тыгыз һәм куе иде. Чикләвек бакчалары, кыргый алмагачлар, алар арасындагы арча куаклары шау чәчәктә утыручы альп болыннарына ук төшеп җиткәннәр, монда бер генә дә кәгазь, целлофон, пыяла кисәге күрмәссең, бу урынга халыкны кертмиләр, монда ышанычлы умартачыларга, егерьләргә, ау белгечләренә генә килү тыелмый. Акмал хан территорияне үз ирке белән тыюлык дип игълан итте, һәркайда кисәтү такталары куелды, алардагы ат башы чаклы хәрефләр зур штрафлар хакында кычкырып торалар иде, кайбер урыннарда биләмәләрне чәнечкеле тимерчыбык белән дә бүлеп алганнар. Тынлык, иплелек һәм кешесезлек бу урыннарга кыргый җәнлекләрне тарткан, кошлар күпләп очып килгән һәм таулар ханның сунарчылык биләмәләре булып киткән. Монда куянга, төлкегә, боланга, кабанга, җәйранга, кыр кәҗәләренә, бүрегә, хәтта аюга да ау оештырырга була иде.

Тау елгаларында форель уйный, күлләрне ондатралар, кондызлар үз иткән. Ун ел элек Себердән кеш, сусар, тиен алып кайтканнар, алары да кеше саклавы астында яхшы ук үрчеп киткән.

Юл таудагы аучылар йортына илтә, Сенатор аңлаганча, алар нәкъ менә шунда баралар да, әмма юл ул ачыктан-ачык беленми диярлек. Кайчагында туп-туры гына барган асфальт юкка чыга да алда "Тупик" билгесе күренә, аннан соң ике чакрымлап юлсыз сукмактай тоелган җирләрдән барасың, бераздан тагы яхшы түшәлгән трасса. Аның барлыгын санаулы кешеләр генә беләдер. "Күз буучы" монда да осталык, хәйләкәрлек күрсәткән. Бер якта шлагбаумнар, тыючы тамгалар, шулар артында ук яшерен сукмаклар һәм юллар. Күрәсең, мондагы яшерен-ябылган тормыш турында беркем дә белергә тиеш түгел. Аңа кунакка иң югарыдан кемнәр генә килми, ә "халык хезмәтчеләре"нең күңел ачуы гади халык күзеннән ерак булуы хәерле.

Таштан салынган галәмәт зур йортны шартлы рәвештә генә аучылар өе дип атарга мөмкиндер дә. Аучы йорты диюгә, күз алдына, гадәттә, уңайлыклардан мәхрүм, бары тик җил-яңгырдан сакларлык түбәсе булган гап-гади алачык килеп баса. Хәер, аучылык үзе дә шундыйрак инде ул. Кеше табигать белән аралаша, алачык исә андый максат өчен иң кулай нәрсә. Һәм мондый бәхет бик азларның гына өлешенә тия дә. Ләкин күккә ыргылган чирәп түбә өстеннән сурайган алагаем зур ике морҗа, йортның ике ягында да камин-мичле заллар барлыгын тәгаенларга мөмкинлек бирә иде. Ике каминлы йорт хуҗаның дөньяга бөтенләй башка күзләр белән каравы турында сөйли. Монда, күрәсең, кәрт уйнаучылар өчен дә, телевизор карарга, яисә музыка тыңларга теләүчеләр өчен дә махсус заллар бардыр. Шулайдыр, дип уйлап куйды прокурор. Монда үзләрен дөнья кендеге санаучылардан кемнәр генә булмаган да, кемнәр генә ял итмәгәндер!

Чем кара җөйләре белән игътибарны җәлеп итеп торучы кызыл кирпеч бинага якынрак килгәч, прокурор монда сауна белән бассейн да булырга тиешлеген, йортның бер архитектор кул астында эшләнгәнлеген дә чамалады. Ау йортының проектын берәр ялтыравык, затлы журналдагы рәсемнән, сызымнардан, бәлки берәр атаклы төзелеш фирмасы яисә архитектура мастерское каталогыннан алганнардыр, дип фикер йөртте ул. Соңгы елларда мондыйлар дөньяны басып китте. Хәтта кием-салым, аппаратура каталоглары санап бетергесез. "Идән асты" миллионерларына бик шома кешеләр тарафыннан шул катологлар буенча хезмәт күрсәтелә, Акмал хан да, әлбәттә, шулар санына керә иде. Аксайга видеофильмнар ташучы коммивояжерлар,

директор үтенсә-сораса, катологларны үзләре үк алып килә алалар. Әгәр шәрекъчә веранда, чуарлап-матурлап эшләнгән озын ишекләре булмаса, болары Урта Азия архитектурасыннан, Акмал хан йортын Швейцариядәге Альп тауларында, яисә Франция белән Испания чигендәге Пиренейда, Балкандагы Черногория, Косово, ә бәлки Грециядәге Салониктагы шундый биналар белән бик җиңел бутап булыр иде. Таулар бар җирдә дә бер төслерәк, алардагы үзенчәлекләрне бары бик тәҗрибәле, күзәтүчән кешеләр генә аерымлый ала, аның өчен тирә-юньне аңлый белергә дә кирәк бит әле. "Беретта", "Франчи" кебек иң яңа карабин ияләренең ни өчен ауга нәкъ монда килергә яратуларын да абайлады прокурор. Башка җирләрдә мондагыдай мөмкинлекләр һәм саңгырау-телсез Сабир-бабаны табу авырдыр шул.

Биек таш койма белән тотылган ихатага керделәр. Аның борынгылыгы шунда ук күзгә ташланды. Аны өстендә тигез-шома булып үсеп утырган вак асылынкы-үрмәле үсентеләр раслый, алар язларын бар дөньяны яшеллеккә төреп балкый башлыйлар. Менә шушылай тигез һәм шома хәлгә килсен өчен аларга дистә еллар кирәк. Ихтимал, бу бина башкасы, искерәге урынында утырадыр. Урынының җайлылыгы, табигатьнең гаҗәеп матурлыгы хуҗаны инде таләпләренә җавап бирми башлаган йортны сүтеп, утызынчы еллар стилендәге шушы псевдомодерн йортны салырга мәҗбүр иткәндер. Каты, яшел бәрхет белән төрелгән бу коймалар, йортның архитектурасы Акмал ханның таулардагы утарына бу якларга хас булмаган төсмер бирәләр иде.

Кояшта янган калай түбәле җәйге кухняда учак утлары дөрли, учакка авыр, җылыны күп бирүчән карагай агачы ягалар икән, кухня тирәсендә пешекчеләр тыз-быз килә. Алар арасында Сабир-бабаның ябык-нык гәүдәсе күренеп китте, ул элеккечә үк ап-актан киенгән. Якынрак килгәч, йортның шәп проект белән төзелгәне күзгә ташланды, бу якта мондыйларны төзимиләр, өй өчен, гадәттә, тигез мәйдан эзлиләр. Алар кергән яктан ук парад ишеккә туры килделәр, ләкин бу икенче кат иде, бина ике төрле биеклеккә салынган булып, аның беренче катына эләгү өчен икенче ягына чыгарга кирәк икән. Аннан югары катка яхшылап шомартылган имәннән эшләнгән бораусыман киң баскыч илтә.

Алар машинадан чыгып, "Волга" яр астындагы гаражга юнәлүгә, ишектә "Адидас" спорт костюмы, йомшак кроссовка кигән "Күз буучы" үзе күренде. Әле генә йөреп кайткан булса кирәк. Монда, кая гына барсаң да, чишмәләр, шарлавыклар, кечкенә елгачыклар, ямь-яшел болыннар... Бу хакта аңа юлда Исмәт сөйләгән иде инде, ә ул бу урыннарны биш бармагы кебек белә.

—Тоткарланасыз, тоткарланасыз, кадерле Сухробҗан,—дип каршы алды хуҗа һәм сәгатенә күз төшерде, шунда Сенатор Акмал ханның биш ел элек "Советская" кунакханәсе ресторанында Шубариннан алган "Ролекс" алтын сәгатен күрде. Аның карашын сизгән "Күз буучы" дәвам итте:—Әйе, әйе, шул сәгать, мактанырга булдым әле.—Һәм күрешергә сул кулын сузды, сәгать өр-яңа иде, чыннан да, ул аны бик сирәк тагып йөридер.—Әйдәгез өйгә, мин әле генә йөреп кайттым, иң ерактагы Очан-суга кадәр барып җиттем, ачыктым, сез дә өстәл янына утырмагансыздыр әле, кичәгедән башыгыз да авыртадыр, төзәтергә кирәк.

Акмал хан бүген ягымлы, елмаючан иде, аннан кунакчылык хәтта бөркелеп тора. Шулай да Сенаторның миендә бер сорау бәргәләнде: өч-дүрт сәгатьтән юлга кузгалырга кирәк, нишләп мине бу кадәр еракка, тауларга алып килергә уйлаган икән, самолеты юк бит. Нигә инде артыгы, мин бит аның модерн стилендәге аучылар йортын күрергә килмәдем, кабан, болан ише киек җанвар йөргән урман-болыннары да кирәкми.

Кара агач белән тышланган киң өйалдыннан коридорга үттеләр, коридорда беренче катка төшү өчен бронза белән чолганган, исерекләр аска тәгәрәмәс өчен түгәрәк тоткычлар куелган имән баскыч бар иде. Акмал хан киң ишекне ачып җибәрде һәм каминлы залга килеп керделәр. Зал бик тә киң, аңа Порт Сәеттә кулдан эшләнгән ике ашханә гарнитуры да бик иркен генә кереп утырган иде. Әмма җирле партия түрәләре аеруча яраткан унике персонлык авыр, шыксыз мебель бу киң-иркен залга килешеп тә тора икән

әле. Бәлки, бу ерак түр стенада нәкъ мебель түсендәге ачык-алтын тонлы зур гобелен эленеп торудан шулай тоелгандыр. Гобелен ау йорты өчен махсус эшләнгән диярсең, ауга чыккан патша, ау этләре, яраннары, вельможалар, матур хатыннар, кавалерлар... Ул, чыннан да, матур иде, туйганчы карыйсың, аннан гына күзең каминга төшә, анысы тыштан китек-чатык ташлардан эшләнгән, авыр тимер рәшәткә артында кызуга чыдам кирпечтән ясалган кызыл эче күренеп тора. Ике метр озынлыктагы каминның өстендә үтә зур поши мөгезе, бусы, ихтимал, берәр аучының бүләгедер, чөнки бу якларда пошилар юк. Мондый зурлыктагы мөгезләр Халыкара аучылар союзы тарафыннан теркәлә, иияләренә исә аларның дөнья стандартында булуын раслаучы сертификат бирелә.

Жирле номенклатураның гобеленга исе китә иде, хан кунакның мөгез белән әсәрләнгәнен сизенде, горурлыгын яшермичә әйтә салды:

—Чын мәгънәсендә чемпион мөгез! Минем аңа документым да бар, сертификат дип атала, немецчә язылган. Мондый экземплярларны аукционда меннәрчә доллар тора дип сөйлиләр, аны миңа бер зур кеше бүләк итте, бу йортка алар килешеп торачак, диде.

Сенатор аны хәзер йортын, ике катны күрсәтә башлар, мылтыклар коллекциясе белән мактаныр дип уйлаган иде, алай булмады, ул аны кинәт кенә өстәл янына чакырды, анда ике кыз мәш килә иде инде. Сенатор үзенчә хан каядыр ашыга, бәлки минем белән Ташкенткадыр дип гөман кылды. Ләкин "Күз буучы" да кунакның уйларын сизенә иде, прокурорда ышанмау хисе уяткачны, башта ук ачылырга булды. Чөнки аның ышанмавы, икеләнүе бүген кирәк түгел иде инде. Бер уйлаганда, сәнәктән көрәк булган бу кемсә, политикада беренче зур адымнар ясаган кеше кай ягы беләндер аның үзенә охшаган иде, бары укыганрак, белемлерәк, моның каптыруы да катырак, стратегиясендә дә логика бар, яңа заманга да ул барысыннан да алда яраклашкан.

—Сез төшке ашны аучы йортына күчергәнгә, бәлки, гаҗәпләнгәнсездер, әмма хәл үзгәрә төште, сезне кисәтеп тә куя алмадым, уятырга да өлгермәдем. Хикмәт шунда, кичкә миңа Дулкын Назарович килә...

Ах, күзгә карап астан пычак белән кисмәкчеме?! Прокурорның башыннан яшен тизлеге белән шундый уй йөгереп узды. Мине фаш итеп эштән кудырмакчымы, әллә, киресенчә, мине һәмишә күз уңында тотар өчен Дулкын Назаровичны такмакчымы? Прокурор өчен ике вариант та кабул итәрлек түгел иде, ул беркемнең дә күзәтүе астында булырга теләми, вакытыннан элек беркем белән дә планнарын уртаклашасы юк! Тынычлыгын җуймаска тырышып, ул алма чистарткан булды, сорау да биреп тормады, көндезге дүртне суккан камин сәгатеннән күзен ала алмады диярлек.

Тынлык озаккарак сузылды, хуҗа аның сүзләре нинди тәэсир ясар икән дип көткән иде, ләкин барып чыкмады, телиме-юкмы, сүзне дәвам итәргә калды:

—Ул Наманганга, иртәгә билгеләнгән ниндидер киңәшмәгә килә, анынчы минем белән очрашып алырга тели. Ул сезнең монда булуыгыз турында белмиме?—дип сорады аптырашта калган хан.

—Юк, белергә тиеш түгел, мин сезгә әйттем ич инде, бу минем шәхси инициативам,—диде Сенатор каты гына һәм үзен вокзалда кемдер күреп калгандыр дип пошынып куйды.

—Борчылмагыз, сезнең эшләрне тәртипкә салдым мин, барысы да әзер,—дип ашыгып сөйләп китте хан, кунакның ризасызлыгын сизенеп.—Киту мәсьәләсен хәл иттек, Исмәт Наманганда ике урынлык купега утырачак, ә сез поездга беренче тукталышта керәсез, анда ул кузгалганнан соң сәгать тә егерме жиде минуттан килеп житәчәк. Станциягә сезне минем кешеләр илтеп куяр.

—Исмәтне нигә борчырга инде?—дип бүлде хуҗаны кунак.—Билетын бирсен дә, шул-шул станциядә хатыны белән туганым утырачаклар, дисен. Ышандыру өчен берәр бишлек яисә унлык төртсен, юлда аларны чәй эчертергә онытма, дисен.

—Мин алай эшли алмыйм. Артур да сезнең өчен бик борчыла, вагонга минем кешеләр утыртыр, купеда Исмәт каршылар. Кайтып житеп, ишегегездән кереп киткәч кенә Исмәт Артурга шылтыратачак, кайтып житкәнегезне әйтәчәк. Минем бурыч шунда гына тәгәлләнә, безнең кагыйдә шундый. Сезгә дә миннән килгән кешеләрне шулай озатырга туры киләчәк. Бу сүзләрне, зинһар, онытма. Яныгызда нинди документлар, никадәр сумма булачагын белмисез бит әле. Әйе, Исмәт Коста белән Ашотка охшамаган, ләкин ул үз эшен биш бармагы кебек белә, ышанычлы сак астында булырсыз.

—Рәхмәт, мин моны башыма да китермәгән идем.

—Ә хәзер әйдә бераз йотып куйыйк, әйбәтләп капкалыйк, аннан соң яраткан шарлавыгымны күрсәтермен, эшләр хакында шунда сөйләшербез, тагы кайчан күрешәсебезне бер Алла белә... Хәзер Ташкентка сирәгрәк барыла...—Хан Акмал бәллүр савытларга коньяк коя башлады.

Эчтеләр, капкалап алдылар, ләкин сүз ябышмый, кичәге йөгереклек юк иде. Хәтта коньяк та ярдәм итмәде. Дулкын Назарович нигә киләсе итте икән, әллә иске дусты өстендә болытлар куерганны әйтергә телиме?—Сенаторның миендә мең төрле сорау бәргәләнде. Хан аның визиты турында Дулкын Назаровичка әйтмәсме, әйтә калса, ул карт интриган кармагына үзе үк эләгәчәк ич?! Бәлки аны Акмал хан үзе чакыргандыр? Прокурор Әкрәмхуҗаев сөйләшмичә, киңәшмичә нәрсәдер болгатып йөри, Аксайдан ярдәм аласы килә дисә? Шулай эшләсә, ул үзенә карата кызыксыну уята алыр, игътибарның үзәгенә кайтыр иде. Хәер, болар аңа нәрсәгә?! Мин аңа элеккеге түрәләрнең барысының кичәге көн икәнен төшендерә алдым кебек. Ул хуҗаны тыңласа да тыңлады, тыңламаса да тыңлады, күзләре сунар күренешләре төшерелгән инглиз тәлинкәсендә, чәнечкесе ризыкта ялкау гына казына, башында исә борчулы уйлар.

Аның башыннан һич кенә дә Дулкын Назарович чыкмый, чөнки аның яшерен генә Аксайга килергә теләвендә нидер бар иде, ханга ул мондыйрак сорау бирде:

—Кунак без кичә мәжлес корган йортка киләме?

—Юк, ул үзен монда, шушы йортта каршыларга кушты, Шәрәф Рәшидович белән бергә килгәннәре бар иде. Монда, хәтта очраклы рәвештә дә, өстенә беркем дә килеп керә алмый. Ул да, сезнең кебек, визиты турында беркемгә дә әйтмәскә кушты.

—Мине аста, иске йортта калдыру яхшырак булмас иде микән, дөресен генә әйткәндә, минем аны бер дә күрәсем килеп тормый,—диде прокурор. Ул һаман нинди дә булса мәкер юкмы, дип шикләнә иде.

—Борчылмагыз, аның белән очрашырга туры килмәс, аның да сезне бу өстәл янында бик күрәсе килеп тормыйдыр. Көтмәгәндә өстенә килеп керсәгез, билләһи, дим, иң ким дигәндә дә, инфаркт алачак. Ул сезнең ҮКда нинди бүлек җитәкләгәнне белә бит. Мин дә аның белән сөйләшүдән нәрсәдер көтмим, бары бер кызыксынуымны җиңә алмыйм, ул сезнең кебек минем өстә болытлар куерганын әйтерме, юкмы? Бәлки зарланырга, бәлки иске гадәте буенча—акча сорарга киләдер? Аның нинди мәсьәлә белән килгәнен мин сезгә хәбәр итәрмен, сынап карыйм әле, ә болай... Хәзер мин бар өметемне сезгә багладым. Ашны монда ник кучердемме? Аңлату җиңел. Сез сораган нәрсәләр барысы да шушындагы тау куышларында. Дулкын Назарович килү хәбәрен дә монда җиткерделәр. Әгәр фотокопияләр алып, сезнең белән поселоктан читтәге йортка кайтып, шуның өстенә яңа кунакны каршылап йөрсәм, берсенә дә юньләп өлгермәс идем. Шунлыктан, барысы да аучылар йортында хәл ителәчәк. Күптәннән инде монда кунак кабул иткәнем юк иде, үземнең дә йортны да күрәсем килеп китте. Ике сәгатьтән юлга чыгабыз, машинада телефон бар, берәр посттан кунак турында хәбәр итәрләр, ул горизонтта күренүгә, мин төшеп калырмын, ә сезне станциягә алып китәрләр.

Сенаторның ышанып җитмәвен, һаман шикләнүен күреп хан кайбер нәрсәләрне үзгәртергә булды.

—Мин сезнең шикләрегезне аңлыйм, Сухробҗан, сезнең урыныгызда булсам, Дулкын Назаровичның килүе мине дә сагайтыр иде, ләкин хәлне үзгәртеп булмый, ашавыгыз ашау, утыруыгыз утыру булсын өчен, мин вәгъдә иткәннең барысын да кулыгызга тапшырам, бәлки ышанычыгыз артыр.— "Күз буучы" берничә минутка залдан чыгып китте.

Ул бүлмәгә Сабир-баба белән әйләнеп керде, кулында ышкылып беткән күн чемодан, акка киенгән карт исә атташе-кейс һәм ниндидер тартма тоткан иде. Ябышкак тасма белән аркылы-торкылы чорналган тартма күрер күзгә әлләни авыр тоелмый иде. Кейс белән тартманы өстәл янына куеп, Сабир-баба тавышсыз гына каминлы залдан чыгып та китте. Аксай Крезы авыр чемоданны өстәлгә ташлады, кунакны янына чакырып, кечкенә йозакларны ача башлады.

—Менә изге эшләргә тотыласы акча, өстебездә ислам байрагы күтәрелсен,—диде хан һәм чемоданны ачып җибәрде, аның эче тулы йөз сумлык акчалар иде.

"Ничә миллион микән, аста унлыклар гына түгелме, ханнан барысын да көтәргә була", дип эчтән генә уйланды Сенатор, ә үзе хәйләкәр генә сорап куйды:

—Мин сезгә расписка бирергә тиешме?

Аның бу соравы башында кайнаган сорауларга җавап эзләүдән генә әйтелде дә, мәсәлән, ул төгәл сумманы шул "расписка"дан белә алыр иде, бүләк иткән атның тешенә карамыйлар.

—Әйе, гадәттә, мин расписка алам, ләкин сездән алмам, ышануымны шулай күрсәтергә телим. Кылган гамәлем алдагы мөнәсәбәтләребезнең нигезе булсын. "Дипломат"та досьеларның фотокопияләре, иң өстә Беренчегә кагылышлы документлар, кирәге чыгар... аны мин өзгәләп ташларга рөхсәт итәм. Кичә мин гаебемне юарга вәгъдә иткән идем, менә бу бүләк сезне бер генә шатландырмас дип ышанам. Бик хикмәтле нәрсә, кирәге чыгар, аны видеофильмнар ташучы кеше алып килгән иде. Япон приборы ул, кечкенә дә, төш кенә дигәндәй, илле метр ераклыктагы сөйләшүләрне тынларга мөмкинлек бирә. Җитмәсә, теләсә нинди стена аша, һәм теләсә кайсы телефонга ялгана ала. Мондыйлар КГБда да юк бугай. "Дипломат"ик каналлар буенча алып киленгән әйбер, шикләнмә, артыннан койрык юк. Шәп уенчык, әмма ул миңа кирәк түгел инде. Өченче каттагы кабинетыгыздан Беренченең кем белән ни хакта сөйләшеп ятуын рәхәтләнеп тыңлый аласыз. Теләсә кайсы яшерен кинәшмәдә сезнең колак булыр. Техника—үтә куркыныч корал, кызганыч, элегрәк болар юк иде.

Акмал хан әллә ничек дулкынланып китте, хәтта курткасын салып атты.

—Җәл, Шурик үлгәнче танышмаганбыз, өч-дүрт ел элегрәк белгән булсам, ставканы сезгә куйган булыр идем, тәхеткә утыртыр идем, барысы да кулымнан килә иде, бу аяныч хәлдә дә калмас идек. Андропов заманында батырчылык итмәсәк тә, ул үлгәч куллар чишелгән иде бит, бу фиргавеннәрне Үзбәкстаннан куып чыгара ала идек. Бер без генә гөнаһка батмаган. Кавказ белән чагыштырганда, без бала-чага гына.

—Әйе, сез хаклы, Акмал әкә. Черненко вакытында да бер ел әрәм китте, көчләрне тупласак Мәскәү тикшерүчеләреннән җилләр исәчәк иде. Костаның патроны, ягъни хуҗасы безнең якларны ярата, Шәрәф Рәшидович белән дә дус булган, ул беркайчан да моннан Ленчик белән бәйле начар хәбәрләр чыгуын теләмәгән, шул ук ният аның кияве генерал Чурбановка, кызы Галяга да кагыла.

—Куркаклар, надан тәреләр, вакытны кулдан ычкындырдылар, хәзер үзләре ут эчендә, ул уттан беркемгә дә котылу юк. Җир йоткырлары, аларны онытып торыйк. Сухробҗан, тост әйткәнче, сезгә тагы бер бүләк ясыйсым килә. Анысы—сезнең хактагы досье. Төп нөсхәсе. Без аны күптән түгел генә, сез Югары судта күренгәч кенә ачкан идек әле. Җыелган белән мактанып утыра торган чак түгел, бу минем сезгә ышанычым, сезгә таянуым, якын итүем. Башкаларның досьеларын укыгач, миндә нинди кызыклы материаллар җыелганын күрерсез. Кайберсендә мин мәгълүматның кемнән

алынуын да теркәп бардым, ул агентураның да кирәк булуы бар.—Акмал хан тагы өстәл яныннан торып чыгып китте.

Ул озак кына югалып торды, Сенатор үзе турындагы досьены хан ана иң соңгы минутта гына бирер дип уйлый иде; "Күз буучы", чыннан да, кунакның ышанычын казанырга тели иде кебек.

Хужа юка гына папка тотып әйләнеп керде. Прокурор ханның кичәге: "Кайбер үтерүләргә мин акча белән түләмим, документлар тутырылган папка гына бирәм" дигән сүзләрен тагын бер кат исенә төшерде. Ул бу сүзләрнең мәгънәсен аңламады түгел, ә менә бүген Акмал хан бухгалтерлар эш итә торган егерме тиенлек гап-гади "Скоросшиватель"не Япон аппараты салынган тартма өстенә битараф бер кыяфәт белән куйганда, тетрәнеп китте. Бу инде мәкере буенча да иң сирәк очрый торган гамәл иде.

Менә хәзер генә ул акча белән эшләп булмаганны ничек итеп башкача хәл итү мөмкинлеген төшенде кебек. Әйе, үзеңнеке белән чагыштырганда, хәтта ике гомер бәясе бер юка папкага да тормый икән. Үзе дә иксез-чиксез мәгълүмат туплаган Сенаторның әле беркайчан да мондый алымга барганы юк иде. Хан кеше кулы белән мичтән кайнар күмер алдыра белә, менә сиңа тормыш тәҗрибәсе! Шунда ул ОБХСС капитаны Кодрәтовны исенә төшерде, ул да Сәлим белән аның өчен мичтән утлы күмер алган, ягъни Костаны коткару операциясенең иң куркыныч өлешен башкарган иде бит.

—Тормыш һәм карьерагызны куркыныч астына куеп, үз теләгегезгә ирешкәнегез өчен күтәреп куйыйк! Уңышлар сезгә!—диде Акмал хан һәм кунак зур канәгатьлек белән бокалын күтәрде.

Искиткеч тәмле итеп әзерләнгән һәм ике чибәр кыз тарафыннан өстәлгә матур итеп бирелгән төшке аш вакытында прокурор, никадәр генә теләмәсен, тартма өстендә яткан папкага карамаска тырышты. Бик каты түземлелек сораган шушы тырышлык бөтен сый-нигъмәтнең тәмен бозды, тик шулай да ул "Күз буучы" оештырган сынауны тиешенчә узды—кызыл фломастер белән дүрт урынлы сан сугылган папкага күз дә ташламады. Ашау-эчү тәмамланып килгәндә ул тагы, ирексездән, стенадагы сәгатькә карап алды, хуҗа ике сәгатьтән китәбез дигән иде, димәк, бер сәгать вакыт калган. Көн тыгызланганнан тыгызлана бара иде. Алда тагын юл, тагын поезд, каршыга Дулкын Назаровичның килеп чыгу ихтималы...

Кунакның сәгатькә күз төшерүен Акмал хан да күрде:

—Әле безнең карамакта бер сәгать вакыт бар,—диде ул.—Барысы да график буенча. Үзем яраткан шарлавыкны күрсәтергә вәгъдә биргән идем, шунда барып килербез.—Ул алдындагы бәллүр кыңгырауны шылтыратып куйды, күп тә үтми залга Сабир-баба килеп керде.

—Без йөреп кайтабыз, мин Сухробҗанга йорт тирәләрен күрсәтәм, мәскәүлеләр мондагы матурлыкны Швейцариянекеннән ким түгел дип мактыйлар. Кунакның әйберләрен Җәлил машинасына ташып куй, Аксайга кадәр мин аның белән барам, минем "Волга" арттан иярер, Дулкын Назаровичның якынлашуы турында хәбәр булуга, мин аңа кучеп утырырмын. Яңа кунак белән өч сәгатьтән әйләнеп кайтырмын. Хәер, ул хакта телефоннан шылтыратып әйтермен, барысын да элеккечә эшләргә тырыш. Дулкын чәүчәләк кеше, шуның өстенә, тәкәбберлеге дә житәрлек. Ул сөяркәсе—Нәкыяме, Нажияме әле—шуның белән килә, исемен кызлардан төгәл сорап куй. Алар белә, бүлмәгә ак розалар куярга онытмагыз, Нәкыяме, Нажияме алар өчен үлеп китә. Шаукымлы хатын, теге вакытта паркта лилия белән лотослар арасында шәрәтән коенмакчы. Дулкын да туктата алмады, үзе һаман такылдый: "Йә, кем матуррак, минме, лилияме, имеш",—Хан рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Бер ел элек булган вакыйга хәтеренә нык сеңгән иде, күрәсең.

Акка киенгән карт баш иеп тыңлады һәм, бер сүз дә әйтмичә, бүлмәдән чыкты. Аның нишләп гел сүзсез булуын прокурор тәки сорый алмады, әмма бу картка йортта зур җаваплылык йөкләнгәнлеген бүген генә аңлады.

Ишегалдына коридор уртасындагы баскычтан беренче кат аша чыктылар, кунакның, нигәдер, аны күрәсе килгән иде. Баскыч бильярд залына алып төшә икән. Инде зур банкет залын, йокы бүлмәләрен күрмәсә дә, алар

турында “Күз буучы” әйтеп китте, прокурор өйнең тулы картинасын күз алдына китерә алды, ян яклардан да ишекләр булуын чамалады. Аксай ханы биналарда әллә ничә яшерен керү-чыгу юллары ясап бетергән, монысы югарыдан килгән кадерле кунакларын һәрвакытта да контрольдә тотар өчендер, күрәсең.

Эчке ишегалды алгы яктагысына караганда күпкә зур иде, ул ерактагы сөзәк үзәнгә барып тоташа һәм ике гектар чамасы җир били, аны да әлеге дә баягы таш койма чолгап алган. Лилияләр үскән парктагы кебек көязлек юк, әмма монда да һәркайда кайгыртучан кеше кулы сизелә, ләкин, ни хикмәт, ул табигатьне үзгәртмәгән, киресенчә, аны матурлый төшкән иде. Акмал ханга юк-бар кешеләр эшләми шул.

Алар янәшә баралар һәм пышылдабрак сөйләшәләр иде, ә икенче кат тәрәзәсеннән алар артыннан ак киемле сүзсез кара карт озак кына карап торды. Ул күктән җәйге көндә кар булып төшкән, хуҗасының тормышын болгап-болгатып ташлаган кешене хәтеренә сеңдереп калырга тели иде кебек. Картны акчалы чемодан да борчый иде. Аксайдан бик күпләр акча белән китте, ләкин әле беркемнең дә бу кадәр сумма алганы юк иде. Әле кичә генә, Акмал хан сигаретка чыкканда аңа һәм Ибраһимга ташлаган бер-ике сүз бу кешенең гомере сукыр бер тиенгә тормый дигәнне аңлата иде. Ә бүген хан аңа хәтта досьесын да кертеп бирде. Дөрес, анда хәйран калырлык берни дә юк. Монысы да кешене ачык күрсәтә торган фал. Хан берни дә таба алмагач: “Эзен шәп себерә, моны ялан кул белән алып булмый”,—дип, тирән мәгънә белән әйтеп куйган иде. Ул аның белән дусларча, хәтта Шәрәф Рәшидович заманындагыча аралаша башлады. Галстуксыз бу кеше белән әле тагын очрашулар булачагын карт күңеле белән сизә, шуңа ул аны хәтеренә салып кую өстенә анларга да тырыша иде. Көнкүрештәге күп кенә гадәтләр тәҗрибәле кешегә күп нәрсә турында сөйли бит.

Мәсәлән, төшке аш вакытында ул аны камин өстендәге поши мөгезләре арасына махсус уелган кечкенә тәрәзәчектән күзәтеп торды. Хан досьены махсус рәвештә аның кулы җитәр арага куйды, ә тегесе үзен кабат тикшерүләрен аңладымы, документларга күз дә салмады. Бу аның ихтыяр көче, үз-үзен тота алучанлыгы, культурасы, акылы турында сөйли иде. Хан чемодан капкачын ачкач, ул акчага ничек битараф карады—ничә сум икәнен дә сорап тормады бит. Күпләр мондый вакытта комсызлыктан башларын югалталар, акча белән сынау Аксайда кешене тануның иң-иң оста оештырылган формаларыннан берсе булып, күпләрнең чын йөзе ачылмый калмый иде. Ә бу галстуксыз үзен бик тә, бик тә тәрбияле, итагатьле тотты.

—Без, күрәсең, тиз генә күрешә алмабыздыр, телефоннарга мин ышанмыйм, аларның күбесе, органнар кушуы яисә прокурор санкциясе буенча гына түгел, болай да тыңлана, бигрәк тә синең кебек югары урындагы кешенеке. Сезгә дәүләт серләре дә кагыла бит,—диде Акмал хан.—Шуңа күрә, хәзер сорап калыгыз, сезне нәрсә кызыксындыра. Юкса, безнең шәрекъ тотанаклыгы, тыйнаклыгы кайчак эшкә зыян да китерә. Без күп нәрсәне килешеп куярга, эчендәгеләрне бер-беребезгә әйтергә тиешбез. Мин дә сездән берничә нәрсә турында сорамакчы булам. Әгәр миңа сезнең өчен берәр ашыгыч хәбәр җибәрәсе булса, махсус кешедән файдаланырмын, сезнең хәзер анда, ҮК ишек алдында, зарланып килүчеләр буа буарлык, миңа шулай диделәр, шуңа күрә минем “атчабар” башкалар күзенә бик үк ташланмас, ул кеше Аксайныкы булыр, шуңа моннан киткәнче, миндә күргәннәрнең барысын да хәтерегездә яңартып алыгыз, Акмал ханда теләсә кем, урамнан килеп кергәннәр эшләми. Кирәк булса, мин сезнең ҮКдагы эш көннәрегезне файдаланырмын, шуңа күрә, киткәндә коридорга күз салырга онытмагыз, бәлки анда миннән булачак юлчы торыр.

Бары хәзер генә Сенатор “Күз буучы” сүзләрендә берниндә этлек юклыгын аңлады һәм Дулкын Назарович килү аркасында үзен дулкынландырган, борчыган мәсьәләләр хакында җәелеп сөйләшеп булмаганлыкка үкенеп куйды.

—Аппаратурагыз өчен бик зур рәхмәт, ләкин мин, иреңгә карап кеше

ни сөйләгәнне аңлый белүче "белгеч"егезне дә алыр идем, аның турында Шубарин миңа шаклар катып сөйләгән иде. Нindirәк кеше ул? Гаиләсе белән башкалага күчерсәк, начар булмастыр, кирәк булса, аңа Ташкентта аерым йорт та алып була. Аның минем кул астында һәрчак булуы кулай. Кеше, дөресен генә әйткәндә, теләсә кайсы техниканы орып бирә ул.

—Аңа йорт хәтле йорт ук кирәк булмас, дип уйлыйм, квартира житәрдер. Чөнки ул буйдак егет, аңа әле егерме сигез яшь кенә. Шунын да биш елын төрмәдә уздырган, үзенең бик тә сирәк һөнәренә шунда өйрәнгән дә. Месхет төрекләре нәселеннән килгән бу егет минем кулга уйламаганда-көтмәгәндә, дигәндәй, килеп эләкте һәм мин аны төрмәдән коткарып калдым. Ул, чыннан да, искитмәле кеше, бер-ике тапкыр сынап карадым мин аны. Утырам кемдер белән сөйләшеп, алдымда магнитофон, ә Айдын бинокль алып утыз метрлар читтәге агачка менеп утыра, аның муенында да магнитофон, монысы контроль тикшерү өчен. Соңыннан ике язманы чагыштырып карыйбыз, төгәллек хәйран калырлык, әле шул ягы да бар, ул үзбәкчә дә, русча да бик яхшы сөйләшә, гүя икесе дә үз ана теле. Сөйләшкәндә, үзең беләсең, без юк-юк та бер телдән икенчесенә сикерергә яратабыз, партия хезмәткәрләре, шәһәр интеллигенциясе бигрәк тә шулай кыланырга тырыша. Янәсе, культуралык билгесе...

—Рәхмәт, Акмал әкә, алайса аны алдым дип исәпләгез, яшәр урын тапкач та аны алырга кеше җибәрермен. Анынчы сез сөйләшеп куегыз, аңлатыгыз, алда торган эш җитди, хәтта дәүләт югарылыгында, дип тә әйтә аласыз. Эш хакы профессорлар көнләшерлек. Минем таләпләр дә Артур Александровичныкыннан ким булмас. Ләкин бу әле беренче үтенеч кенә. Кайчакларда сезнең кеше гомерен кыскарта белүче табибыгыздан да файдаланырга туры килмәгәе. Шубарин бервакыт нindiдер сигарет турында искә алган иде, аны тарткан кеше икенче көнне үк дөнья белән саубуллаша икән, һәм иң мөһиме—бернинди экспертиза нидән үлгәнен ачыклый алмый, имеш. Алай-болай ул агуны әзерләүче дә сезнең табиб түгелдер бит?!

—Юк, минеке түгел, Артурнын сораганы булмады, мин белер идем. Ә сигаретка килгәндә, аңа бернәрсә салмыйлар. Фирменный сигаретлар бик нәзберек, затлы итеп, пөхтә эшләнә, хәер, кешене шул ягы белән җәлеп итә дә инде ул. Моны болай эшлиләр, сигаретны агу сеңсен өчен бер тәүлек чамасы махсус савытта тоталар, әлеге агу тәмәкенең тәмен дә, исен дә үзгәртми. Андый савыт миндә дә бар. Сезгә дә берне табарбыз. Кешене теге дөньяга җибәрү алымнары бик күп ул, күпмедер вакыт узуга инфаркт, йә булмаса яман шеш китереп чыгара торганнары да бар. Ләкин алдан белгеч белән киңәшләшергә кирәк, мин шулай итәм дә. Теге дөньяга ничә кешене җибәргәнеңең төгәл санын үзе дә белмидер инде ул, сезнең белән хезмәттәшлеккә каршы килмәс. Ләкин ул Аксайда түгел, монда ул җәйләрен төрле үлән-сәлән җыярга гына килә, яшәве сезнең борын төбендә генә—Ташкентта. Аның координатларын Айдынга биреп җибәрермен. Сезнең эшкә шулай колач белән, җитди итеп алынуыгызга мин бик шат.

Алар түшәлгән тау сукмагыннан атлый-атлый аучы йортыннан шактый ерагаерга өлгергәннәр иде инде, ләкин сүзләре бетәрлек түгел иде әле. Инде шарлавык тавышы да ишетелә башлады, алар аңа колак салмады, чөнки уйлары башкада иде. Кунак үзе өчен табышмак булган ханның ачылып сөйләвеннән файдаланып калырга ашыкты.

—Гәрчә расписка алырга теләмәсәгез дә, акча мәсьәләсенә кайтмый булдыра алмыйм,—дип Сенатор һаман үзенекен сукалады.—Ялгышмасам, анда алты миллион чамасы, артык түгел...

—Әйе, өстенә баса яздыгыз, барлыгы биш.

—Бишме, алтымы, әлләни аерма юк, тегесе дә, бусы да зур сумма түгел. Үзегез беләсез, җитди эшне башлар һәм дәвам иттерер өчен, нульләре тагын да күбрәк булган акча берәмлекләре кирәк. Мин сезнең сәмәнне беренче взнос дип саныйм, өметле, әмма хәтәр эшкә аванс булсын,—диде Сенатор һәм ханның ярсып китүен, рәхмәт тә әйтә белмисең, дип сүгенүен, битәрләвен көткән иде, әмма ялгышкан булып чыкты.

—Әйе, бәлки, биргән хәтлесен аванс дип түгел, бәлки бер пособие дип кенә карарга кирәктер. Сез башлаган эшкә зур акчалар кирәген аңлыйм мин. Кичә әйттем бугай инде, яшьләр, студентлар хәрәкәтен оештыру өчен генә дә күпме кирәк буласы, политика белән беркем дә бушка шөгыльләнми. Барысы да акча сорый. Һәм сез аны алдым, дип исәпләгез. Ләкин мин сезгә архивны һәм бар акчаларымны кичекмәстән, берьюлы бирсәм, үземнең кирәгем каламы?—Хан кунакка текәлеп карап куйды, ләкин карашында аңа гына хас усаллык та, мәкер дә тоемланмый, күрәсең, ул ихластан сөйли иде.—Шуны ук күздә тотып, мин документларны да тулаем бирмәдем, сездә—якын арада кирәк булырдайлары гына. Чемодандагы акча бер елга житәргә тиеш. Әгәр эшегез максатчан, нәтиҗәле булса—финанс өчен борчылмагыз. Акчаны күп җыйдым мин, аларны сезнеке шикелле үк анык бер максатка тотарга тели идем, монда безнең арада фикер каршылыгы юк.

—Ә минем эшнең нәтиҗәлеме, түгелме икәнен каян белерсез? Аны чамалау авыр, сәясәт кыска арага узышу түгел. Әгәр сезгә качып китәргә туры килсә, яисә, гафу итегез, сезне кулга алсалар?..

—Менә монысы өчен инде сезнең башыгыз авыртмасын, мин, һичшиксез, барысын да белеп торачакмын, ә инде үлә калсам, ышанычлыларым белеп торыр, алар күп, һәм сиңа ярдәмгә килү юлын табарлар. Алга таба да шулай булыр. Эшегезне дә игътибар белән күзәтеп барырлар, мин бит еллар буе тик утырмадым, нәрсәдер бар, нәрсәдер оештырылган. Әгәр барысын да тәфсилләп, киштәгә чыгарып салмаганмын икән, үпкәләмәгез, сез бит, күктән төшкәндәй, юктан бар булдыгыз, минем планнарымда сез бөтенләй юк идегез, ә хәзер төп рольне үтисез һәм бу, онытмагыз, бер тәүлек эчендә... Стратегияне үзгәртеп кору шактый вакыт сорый, сез киткәч мин шул эшкә чумачакмын. Бәлки, Дулкын Назарович белән очрашу да кайбер нәрсәләрне ачыклар.

—Әгәр дә сезгә ул-бу булса, миңа нишләргә соң?—дип ачыктан-ачык сөйләшүгә күчте прокурор.

—Урынлы сорау, шуңа күрә үпкәләмим. Әгәр ашыгыч ярдәм кирәк булса, Сабир-бабаны табарсыз.—Кунакның йөзендә аптырау галәмәтләре күреп, ул тагы кабатлады.—Әйе, әйе, Сабир-бабаны, аны минем рухи остазым, дип санагыз. Корыч ихтыярлы кеше, дансөяр түгел, ятлар игътибарын җәлеп итмәс өчен инде унбиш ел шулай хезмәтче сурәтендә йөри. Аз сөйләшә, күпне ишетә торган кеше. Ул-бу була калса, аңа мөрәҗәгать итәрсез, ул минем дусларымны, фикердәшләремне, кыскасы, озак еллар буе мин туплаган кешеләрнең барысын да белә. Ә алар күп. Бүген чемоданга акча тутырганда ук ул инде сезнең Ташкентта аеруча ышанычлыбыз булачагыгызны аңлагандыр.—Хан кинәт кенә тукталып калды һәм колакларга янәшәдәге шарлавык тавышы килеп керде.—Минем Мәскәүдәге дусларым бу шарламаны Очучы Су дип йөртә, суына гына кара, тирә-юньгә шампан шәрабе атыламыни, күбекләнә, шаулый, очкынлана. Данлы, затлы эчемлек шулай күбекләнеп чыга ул. Артур бик ярата аны.—Акмал хан кемнедер көткән кебек як-ягына каранып алды һәм тәкъдим ясады:—Әйдәгез, Сухробҗан, ташка утырып торыйк әле, су шавында берни дә ишетелмәс, минем сезгә әйтәсе сүзләрем бар әле.

Шарламаның якынлыгы, очкын тау елгасының көче сизелә иде инде, алар утырган валуннар кояш җылысын җыеп тота алмый, хәтта алар—ничектер салкынча дымсу булып тоелдылар.

—Дулкын Назаровичның визиты арага керде,—дип сүзен дәвам итте директор.—Без бүген генә чып-чын уртак тел таптык, туйганчы сөйләшергә дә өлгермәдек. Күрше республикаларга иммиграциягә китәргә тәкъдим итүегез өчен рәхмәт. Чын күңелдән әйтәм, мондый вариантны мин үзем дә уйлаган идем инде һәм кичә-бүген генә түгел, шактый элек, күптән инде... Минем резерв йортым да, ялган паспортым да, хәтта, янәсе, балаларым юклыктан аерылган ялган хатыным да бар. Ул йортка минем төстәшем кергәләп йөри, әлбәттә, бүләкләр белән, шулай булгач, мин ул якларда

беркемнең дә игътибарын җәлеп итмәячәкмен, берсе өчен дә бу көтелмәгән хәл булмаячак. Миндәге акылны, фикер йөртү сәләтен шахмат уены өчен яралган дип саныйлар, болары көтелмәгән һәр нәрсәгә алдан ук төрле юллар уйлап куюдан, күп вариантлы фикер йөртүдән киләдер... Алай дисән, мин шахматчы түгел, нард һәм кәрт уенныннан башканы белмим, хәтта бильярд уйнаганым да юк, ләкин шулай да әле биш ел элек үк, томансыз-болытсыз заманнарда ук, үземә чигенер урын әзерләп куйдым. Кичә, сез ял итәргә киткәч, мин бассейнга кайттым, сауна ягарга куштым, массажист чакырдым һәм сезнең тәкъдим турында уйланып яттым—качаргамы миңа, юкмы?

Өстемдә болытлар куерганын сизенәм, куркыныч турында хәбәрләр миңа ни дисәң дә килеп тора, сезгә ышанмаска нигезем юк, күрәсең, мин үзем дә ут белән уйныйм. Ә шулай да бүген менә монда, шарлама янында, сезнең белән хушлашканда, мин качмаска дигән катгый уйга килдем. Акылсызлык дисезме? Бәлки. Ләкин тормыш тәҗрибәм буенча беләм, минем дәрәҗәдәге кешеләр, аларны ничек теләсәгез, шулай дип атагыз, хөкемгә тартылмый. Минем кебекләрне утыртмыйлар. Бу партиягә күләгә төшерү булыр иде. Сез бәлки бу фикерне тагы бер дәлил белән ныгытуны таләп итәрсез. Бик рәхәтләнеп. Шурик шәһәр уртасында үзе төзеткән Ленин музее каршындагы каберендә тыныч ятканда, Шәрекътә Ильич эшен дәвам иттерүче һәм аның тугрылыклы шәкерте саналганда, аның исеме белән аталган шәһәрләр, мәйданнар, урамнар булганда, берәү дә миңа бармак белән дә кагыла алмас. Кичәге тугры ленинчыны, Политбюро әъзасы диярлек кешене, орденнар алган кешене партия тарихыннан чыгарып ташламаслар, андый мәгънәсезлекнең булганы юк иде әле.

Бәлки бер егерме-утыз елдан, Сталинның кылганнарын тикшергән кебек аның исеменә дә кагылырлар, кадерен белмәгән буыннар аның гәүдәсен күчереп күмү, аның исемен йөрткән шәһәр, мәйдан, урам исемнәрен үзгәртү буенча ямьсезлек башлар, бу бездә була торган хәл, әмма бүген һәркайда аның шәкертләре, яраннары, дуслары утырганда, андыйга беркем дә бармас.

Миңа кагылсалар, Шурикны казып чыгарырга кала, мин берүзем җавап бирергә җыенмыйм, ярый, Шурикны калдырып торыйк, аңа хәзер барыбер, үлгәннәр оят һәм яманлыкны белми диләр, бугай; минем белән бергә бу йортның тынлыгын һәм мондагы табигатьне яратканнар да хөкем каршына басачак бит.—Акмал хан, башы белән ишарәләп особнякка таба күрсәтте.—Алар барысы да менә монда!—"Күз буучы" үзенең калынча-кабарынкы кулын каты итеп кысты.—Сез, кадерле прокурор, ҮК аппаратында яңа кеше, партиянең реаль көчен белмисез, алар мине рәнҗетергә юл куярга тиеш түгелләр, юкса аларга да исән-саулык тәтемәс, без барыбыз да бер казаннан ашадык.

Менә шушы нәрсә мине күчеп китүдән тыеп тора, мин яшь кеше түгел инде, ниндидер томаннарга яшеренгән ак хыялларга исәп тота алмыйм. Аннан соң... Сез менә уйлап карадыгызмы, минем качып китүем күпләр өчен күктән төшкән бәхет булыр иде, бөтен бәлане миңа тагарлар да, аннан инде мәңге котыла алмассың. Минем башкалар өчен җавап бирәсем килми.

Һәм соңгысы. Бәлки мине кулга да алырлар, мин үземне моңа да әзерләдем, нинди козырьларым барын да беләм. Ни булса да булсын, жиде бәлагә бер җавап. Аксайдан башка беркайда да мин үзем булып кала алмыйм, монда гына үземне башкалар өчен Алла һәм патша саныйм. Ә бүген, сезнең белән дуслыкны истә тотып, юкка чыгасым килми, әгәр мине батыра башласалар, Артур белән төрмәдән коткаруны оештырырсыз, менә шунда бер хатыныма китәрмен, ул мине, үз Одиссеен, биш ел көтә инде, ләкин эшләр шуңа кадәр барып җитәр дип уйламыйм. Үзем турында шуларны әйтергә булдым.—Акмал хан аягына басты, сәгатенә карады, тыныч кына тәкъдим итте:—Әйдәгез, иплəп кенә кайтыйк, вакыт кыса, юлда мин сезгә тагы берничә сүз әйтермен, ләкин монысы шәхсән миңа кагылмый, ә безнең уртак эш турында.

Һәм алар кире борылдылар, икесендә дә табигать гүзәллеге белән хозурлану, шарламага сокланып тору кайгысы калмаган иде инде. "Күз буучы"ның

Аксайда калырга теләге прокурорның планнарын бутап ташлады. Аны ахырга кадәр тыңламаска кирәк булгандыр. Японнарның ташлардан торган бакчасын хәтерләткән һәм шарлама янында бик тә матур-кызык тезелгән зур ташларны әйләнеп узып, алар артык ерак та булмаган һәм күңелле калкып торган аучылар йортына илтүче сукмакка борылдылар.

—Сез политикада беренче адымнарыгызны атлыйсыз әле, ә вакыт ашыктыра, куа, шуңа минем сезгә берничә тәгаен акыл бирәсем килә. Беренче карашка алар сезнең максат өчен бик кирәкле дә күренмәсләр, ләкин төптән уйласаң, анализ ясасаң, сезнең идея өчен эшлиләр. Без бүген берничә тапкыр Шурикны искә алдык, мин сезгә ант итеп әйтәм, әгәр дә ул исән булса, республика СССР прокуратурасының тикшерү органнары микроскобы астында калмый иде. Гаепләме без, гаепсезме—анысы башка мәсьәлә. Бәхәссез, минем өчен дәүләтнең, республиканың күтәрелү еллары, бүген пародокс булып яңгыраса да, Рәшидов һәм аның дусты Брежнев идарә иткән чорга туры килә. Андый уңышларны, тормыш дәрәҗәсенең күтәрелүен, торак төзелешен республика озак еллар белмәячәк әле. Ул идарә иткән чорда административ-партия аппараты гына барлыкка килмәде, ә үз зыялыларыбыз үсеп чыкты, шушы ике катлау, ике даирә милли аң күтәрелүгә ярдәм итүче төп чыганаклар. Аппарат та, интеллигенция дә үз сүзләрен әйтәчәк әле. Иске уңышлар фонында Шурикның уңышсызлыклары, ялгышлары тиз онытылыр, күргәнемчә, ил кризисларга кереп бара, алар шулкадәр күп, санап торасы да килми, хәбәрдарлык, демократия дигән нәрсәләр дисциплинаны, тәртипне какшаталар гына. Алар бернинди системага сыймый.

—Сез нәрсә тәкъдим итәсез? Дустыгыз һәм яклаучыгыз булган кешегә мәдхия язып бастырыргамы?—дип көлемсерәде Сенатор.

Акмал хан иронияне колак яныннан гына уздырып җибәрде һәм тыныч кына дәвам итте:

—Әйе, бүген аның турында бер генә газет, яисә журнал да пасквильдән башка әйбер бастырмаячак. Ләкин сез башыгызны эшләтегез, уйлагыз, Сталинга нинди генә пычрак өймәделәр, ә аның исемен халык барыбер ярата, кадерли, саклый.

—Чөнки ул исем мифлар, легендалар белән төренгән, халык кайда дөреслек яисә ялган ятканын белми.

—Дөрес,—дип шатланды "Күз буучы".—Сез шундук дөрес диагноз куйдыгыз, безгә дә нишләп оттырышсыз шундый алымны кулланмаска?—Әңгәмәдәшенең аптырап калуын күреп, дәвам итте:—Шәрәф Рәшидович турында да мифлар, легендалар кирәк, бу турыда буш вакытыгызда уйлап карагыз әле. Башлап җибәрү өчен ике-өч идея да әйтә алам. Мәсәлән, ул үлмәгән, Әфганстанда, Иран яисә Согуд Гарәпстанында әйбәт кенә яшәп ята дип "әкият" чыгарып булмыймыни?! Термез янындагы чик буен үтеп чыгу ана кыен эш идемени? Сез кичә миңа да шундый вариант әйткән идегез бит. Икенче версия фаҗигалерәк яңгырарга мөмкин. Ул инфаркттан үлмәгән, аны үтергәннәр, дип язып чыксаң ни була. Ике чабата—бер кием. Әмма "үтергәннәр" дисәң, күз алдына фаҗига килеп баса. Димәк, аны харап иткәннәр. Харап ителгәннәрне халык кызгана белә. Аның ялгышларын кире кагып булмас, алар күренеп тора. Өстәп язганмы? Язган. Ул Мәскәүгә хисап биргәндә өстәп язуларның республикага бер миллиард сум акча китергәнен белә идеме? Әйе, белә иде. Нишләп урлаган, нишләп бөтенсоюз казанынннан казна урлауга юл куйган? Чөнки, ул мамык өчен республикага коточкыч аз түлиләр дип саный иде. Халык аңламас дип беләсеңме? Аңлар, аңлар—мамык кырларында кол хезмәте өчен хәзергечә түләү мыскыл итү ул. Бәлки, Мәскәүдә, башка җирләрдә аңлап бетермәсләр, монда аңласыннар, егерме миллион төп халык аңласын, калганнарга төкерергә. Ә дехкан үз сүзен әйтер әле, моны хәтерләгез, хәтта мин дә аларны көч-хәл белән генә тотып торам, бүгенге дилбегәләр бушатылган заманда барысының да асты өскә киләчәк әле.

Шулай итеп, республика мәнфәгатьләре хакына, аның тормыш хәлен

яхшырту хакына урлаган дигән фикер халыкка сеңәчәк, бу исә бик күп казна каракларын, шул исәптән, мине дә коткарып калачак. Кире каккысыз дәлилләр бит! Нишләп урладың, дип сорыйлар, ди. Ватан өчен, мамык басуларында изелгән егерме миллионлы халкым өчен, дисең. Ул миллионнар белән ватан һәм милләт өчен нәрсә эшләдең, диләр. Монысына да җавап бар. Күпләп яхшы мәктәпләр, хастаханәләр салырга иде исәп, өлгермәдек— барысын Мәскәү тартып алды, дисең. Шулай итеп, без җәһәләт корбаннары булып чыгабыз. Ә андыйларны, әйткәнемчә, кызганалар, аңларга тырышалар, гафу итәләр. Вакыйгаларны тиешле яктылыкта бирә белергә генә кирәк. Менә шушыларны аз-азлап кына халыкка сеңдерә барырга, республикада һәм аннан тышта да таратырга кирәк.

—Әйе, мин бу хакта башыма да китереп карамаган идем,—дип ихлас күңелдән әйтте Сенатор.

Юлның калган өлешен дәшми генә уздылар, һәр икесенә уйланырга сәбәпләр җитәрлек иде. Бильярд залыннан мәрмәр баскычтан күтәрелделәр, алар кайтуга каминлы залда табын яңартканнар иде. Акмал хан юл аягына эчеп алырга тәкъдим итте. Кечкенә тартманы, чемоданны, досьеларны алып киткәннәр иде инде. Прокурор ишегалдына күз төшерде, анда бер үк номерлы ике кара "Волга", берсенең багажнигына акчалы чемодан салганнар, тынлый торган аппаратураны арткы утыргычка куйганнар, ни дисәң дә, ул ватылучан нәрсә. Китеп барырга барысы да әзер иде.

Акмал хан бәйләнергә сәбәп эзләгәндәй табынга күз йөгертеп чыкты, гүя аңа нидер җитми иде һәм кинәт кенә сорап куйды:

—Сез якын көннәрдә Артурны күрәчәксез, минем аңа да бүләк җибәрәсем килә. Мин инде аның белән тиз генә күрешә алмам, ә бүләкне ятлар аша җибәрәсе килми. Ул әйберне ят күзләр күрмәү хәерлерәк, юкса аннан файда булмас.

—Мин аның белән сишәмбе көнне очрашырга тиеш, рәхәтләнеп тапшырырмын. Бүләк тапшыру, нинди дер йомыш әйтүгә караганда мең мәртәбә күңеллерәк,—дип көлеп куйды Сенатор.

—Юк, аңа йомышым юк, хәер, бүләк соңында нидер сорау йоласы барбарын.

«Күз буучы» өстәлдән бәллүр кыңгырау шылтыратуга залга Сабир-баба килеп керде, кулында ак тастымал белән капланган саллы гына кәрзин иде. Ул аны чынаяк-савытлардан читкәрәк илтеп куйды.

—Теге миңа ярап бетмәгән әйберне алып керче, зинһар, миңа калса, ул Шубарингә ярарга тиеш. Аңа бүләк итәрбез дә.

Картлач тавыш-тынсыз гына чыгып та китте. Ул күздән югалгач, Акмал хан кәрзингә күрсәтте:

—Бусы сезгә, юлга... Бәлки поездда яхшы компания туры килер, кирәге чыгар. Киткәндә онытa күрмәгез.

Сабир-баба бик тиз әйләнеп керде һәм хуҗага, гадәттә, свитер, пуловер, жилет кебек йон әйберләр сатыла торган, ачык төстәге пакет сузды. Прокурор дөрес чамалаган икән, Акмал хан пакеттан перламутр сәдәфле, караңгы-көрән төстәге яхшы материалдан тегелгән, ярыйсы ук ыспай, әмма иске модалы жилет тартып чыгарды. Муен уемы артык тар булганлыктан галстукны тырпайтып, ямьсезләп торачагы да ачык күренә иде. Шуның өстенә, ике бортлы, җитмәсә, артык озын иде. Инглиз жилеты булса да, Японны артык сөендермәстер, чөнки ул киенү тәмен белә торган кеше.

—Йә, бүләк ничегрәк? Мондый яңа модалы кием Ташкентта беркемдә юктыр әле, Артур дустымны шатландыра алырмынмы?—диде елмаеп Акмал хан.

—Әлбәттә тапшырырмын,—дип, итагать саклабрак җавап бирде Сенатор, аның бер дә Аксай хуҗасының кәефен бозасы килми иде.

Йорт хуҗасы прокурорның бүләкне бәяли алмавын төшенде һәм жилетны, уалучан әйбер тоткандай, сакланып кына пакетка сала-сала әйтте:

—Бу бит кевлардан тегелгән әйбер, үзе бер әкият. Артур тәвәккәл-кыю кеше, язмыш белән шаярырга ярата. Мондый жилет шәрекъта алтын бәясенә йөри. Дөресрәге, аңа бәя куеп та булмый. Сез, гадәттә, арттан атканнарын,

пычакны калак сөяге астына батырганнарын беләсез. Моның белән Япон икенче тапкыр атканны көтеп тормый инде, хәтта тән сакчысы булмаса да.

“Пуля үткәрми торган жилет!”—Прокурор моны хәзер генә аңлап алды һәм читенсенгәндәй елмаеп куйды.

—Американыкы, анда һәр полицейскийда бар ул, аларда кеше тормышы кадерле бит. Мина дип алып кайтканнар иде дә, кечерәк булып чыкты, күкрәк турысы кыса, сезгә дә нәкыс булыр,—диде ул, чөнки кунакның күзләре яна башлаганны ачык күргән иде.—Артурга таман гына булачак, без аны әллә Айдынга бирербезме дип тә уйлаган идек, ул да гәүдәгә безнең дустыбыз белән бер чамадарак.

—Сез, чыннан да, Крез кебек юмарт, үземнән һәм Артур Александрович исеменнән рәхмәт укыйм.

Бер-берсенә уңыш теләп тост күтәрергә, юньләп капкаларга өлгермәделәр, каминдагы сәгать сукты, бер сәгать вакыт узып та киткән иде инде.

Директорның алтын “Ролекс”ына карап алуы китәргә вакыт җиткәнне дә аңлатты, чөнки бу якларда хуҗа кеше бервакытта да табын янынннан беренче булып кузгалмый. Бу якларда кунак барысыннан да өстен, монда кеше кадерле беләләр.

Прокурор табын янынннан күтәрелде һәм соңгы мизгелдә үзенең яхшылап, уйлап төзелгән, кызыл чирәп түбәле бу җайлы-рәхәт особняктан китәсе килмәвен аңлап алды. Пыскак яңгырлы көзге көннәрдә ул үзен ягылган камин алдында утыра дип күз алдына китерде, өстендә сырылган җылы халат, кулында бер бокал виски имеш. Янәсе, ул йортта берүзе генә, дуслар, хатын-кызлар да юк, бары Сабир-баба кебек тавышсыз-тынсыз, сабыртыныч, барысын да карашыннан аңлый торган хезмәтчеләр генә... Ул кинәт кенә уйлап куйды: әгәр планнарым тормышка ашып, Ак йортның бишенче катындагы кабинетка менеп утырсам, өстендә нинди төстәге әләм җилфердәүгә карамастан, особнякны үземә калдырам, ауга киләчәкмен, эчке ишегалдында, тарлавыкка кадәр сузылган ачык мәйданда баллар оештырачакмын әле.

Аның уйларын сизгән диярсең, Акмал хан сорап куйды:

—Нәрсә, бу йорттан китәсең килмиме әллә?

—Китәсем килми, монда һәрнәрсә матур, гүзәл! Сулыш алулары иркенәя...—дип җавап бирде прокурор, тавышында көтмәгәндә дулкынлану һәм сагыш сизелде.

—Әйе, мин дә бу диварларның тылсымын тоям, йортның сезгә дә сөенечле минутлар китерүенә шатмын,—диде Акмал хан һәм, аягындагы “Адидас”ны алыштырып та тормыйча, ашыгып чыга башлады, күрәсең, вакыт нык кыса иде инде. Юлга ризык салынган, коньяклы вә шампанлы кәрзинне эләктереп, Сенатор да аңа иярде.

Акмал хан, өйрәнелгән гадәте буенча, шофер белән янәшә, алга утырды, прокурор артка, аппаратура салынган тартмачык янына чүмәште, тагын досье кул сузымында гына иде. Төшеп калмасын дипме, папканы капны бәйләгән бау арасына кыстырып ук куйганнар, ләкин прокурор инде болай да бу документларны бер генә минутка да исеннән чыгармый иде, кая инде ул югалту! Кунак кереп утыруга Сабир-баба ишекне япты, “Волга” үкереп алга ыргылды, шофер да вакыт тарлыгын яхшы белә иде, күрәсең.

—Наманганга командировкага килергә җай чыкса, баш тартмагыз, мин сезне яшереп кенә Аксайга алып килү җаен табармын, бәлки танытмыйча гына үзем дә килеп чыгармын, уртак эшебезгә җанлы әңгәмә, шәхси элемтә бервакытта да комачау итмәс, сезнең идеология бүлеге көнләшерлек әллә ниләр уйлап чыгырырбыз әле,—дип, Акмал хан шарлавык янында башланган сүзне дәвам итте.—Мамык буенча гына да берсеннән-берсе хәтәр дистәләп проблема күтәрергә була. Дефолиант куллану аркасында җирнең һәлак булуы дисеңме, торак-йорт темасы дисеңме. Кая карама мамык, хәтта деханнар уларына йорт салырга җир таба алмый газаплана бит.

Йорт кынамы соң, кайбер җирләрдә зират өчен җир бирми аптыраталар. Азык-төлек проблемасы да шуннан килеп чыга. Еллар буе безне илнең

"мамык бәйселеге"н хәл итсәгез, яшелчәгә, җиләк-җимешкә, ит-сөткә күмәрбез, дип ышандырып килделәр. Республика үз алдына куелган бурычны үтәде, илне генә түгел СЭВ илләрен дә мамык белән тутырды, моның өчен ни алдык...—ачлы-туклы яшәү һәм эшсезлек, бу бит оҗмах җирләре кебек бай якларда. Менә шулай итеп "байлыкка күмделәр" безне. Әле хәзер дә башкалар җилкәсендә яшибез, читтән килгән ит, бәрәңге ашыйбыз, дип такылдаучы акыллыбашлар табыла тора. Ялгышлыкларны, килгән бәлане оста файдаланып, халыкны үз артыңнан теләсә кая алып барырга була. Дәүләт машинасы авыр, борылуны белми, аның акрынлыгын да истә тотарга кирәк, Сухробҗан...

—Акмал әкә, сез әлбәттә, ярылып яткан чынбарлык, бәхәссез хакыйкать турында сөйлисез, ләкин без партия җыелышы президиумында утырмыйбыз, чын күңелдән әйтегез әле—нишләп хәбәрдарлык белән үзгәртеп кору башлангач кына күзегез ачылды? Нигә элегрәк дәшмәдегез? Сез бит дәүләт тарафыннан иркәләнгән кеше, депутат, орденнарыгыз чутсыз, Социалистик Хезмәт Герое. Сез трибунадан гына түгел, патшаларча оештырылган аусунар вакытында, яисә Мәскәү янындагы дәүләт дачаларының аулак почмакларында мәскәүле "олуг" дусларыгызга үзбәк халкының бәлаләре, газаплары хакында әйтә ала идегез, сезне тыңлаган булырлар иде. Мамык чәчү мәйданнарын, зиратларга да урын калмаслык итеп, сезнең дустыгыз Шурик киңәйттермәдемени? Халык иң тыгыз урнашкан республикага тоташ мамык игүнең ни белән янаганын ул аңламый идеме? Мамык өчен халык, балалар сәламәтлеге белән түләвебезне, балаларның бишектән төшүгә мамык кырына чыгуын белми идеме? Мәктәп балалары, студентларның вакытны дәрескә караганда, күбрәк басуда уздыруын белмәдеме? Леонид Ильичның безнең якларны яратуыннан яисә аның Шәрәф Рәшидович белән дус булуыннан халык ни отты?

"Күз бууčы", башын утыргыч өстенә ташлап, чын күңелдән шаркылдап көлеп җибәрде, юк, бу кыланып көлү түгел иде, ә чын-чынлап кабынып көлү иде.

—Ах, нинди хисле, үтергеч сораулар бирдегез, Сухробҗан, кызганыч, магнитофон булмады, соңыннан үзегезне тыңлап карар идегез. Нәфрәт утларында яндыгыз, гаепләүче роле килешеп тора икән. Сез нәрсә, чынлап та политика халыкка хезмәт итә, аның мәнфәгатьләрен кайгырта дип саныйсызмы? Политик карьерагыз башында ук шуны онытмагыз, кадерлем, массалар аерым бер политиканы тормышка ашыру өчен генә кирәк, бүген халыкка минем сорауларны, мин әйткән тәртиптә бирергә, мин әйткән җавапларны алырлык итеп бирергә кирәк. Шәхсән миңа һәм минем дустым Шәрәф Рәшидовичка төбәлгән мондый кызыксынуны халык арасында тудырырга ярамый. Киләчәктә һәм Шурикның, һәм минем ялгышларны кабатламас өчен сезнең ул сорауларны бирергә хакыгыз бар, аңа җавап итеп, совет чиновниклары искәрткәнчә, искәрмәләр белән мин болай әйтер идем: хәтта тоташ хәбәрдарлык чорында да болар матбугат өчен түгел, бары сезне агарту өчен генә.

Шулвакыт машинада телефон шылтырады, "Күз бууčы" трубканы үзе алды, тавыш-тын чыгармый тыңлады да ахырдан гына әйтте:

—Ибраһим, барысы да уйланганча бара, мин сезне Кызылташ янында каршылыйм, Җәлилнең "Волга"сына игътибар бирмә, аны туктатмагыз, ул поездга ашыга. Бетте, очрашканга кадәр.

Акмал хан кунакка борылды, тавышына үкенеч билгеләре чыкты:

—Кызганыч, биш минуттан Кызылташ янында булабыз, мин анда төшәм, ә сезгә, сорауларыгызга җавап табу өчен, тагы Аксайга килергә туры килер, шунда Шурик турында да күбрәк сөйләрмен, аны чынлап белүчеләр аз, хәтта язучы буларак та китапларында ул ин кадерле, эчке уйлары турында язмады, нindидер йомыграк кеше иде ул.

Машина туктады, ишектән чыкканчы Арипов арткы тәрәзәгә күз төшереп алды, ерактагы таудан икенче "Волга" төшеп килә иде инде. Гади-гадәти булмаган, тыгыз тәэссоратлы тәүлекләрне бергә үткәргән хуҗа белән саубул-

лашыр өчен Сухроб та салоннан чыкты. Һәр минуты күңелгә уелып калырлык хәтәрлекләр белән тулы бу көннәр тулы бер романга яисә киносюжетка нигез була алыр иде. Йола кушканча, алар саубуллашып кочаклаштылар һәм соңгы минутларда гына Сенатор аңлап алды: Акмал хан муенында элмәк кысылып килгәнен сизенә һәм Кызылташ янында икәүдән-икәү калгач, вөҗдан газабы дигәнне төшендә дә күрмәгән Аксай Крезы прокурорга үзенең аңа ышануын, өметләр баглавын аңлатырга теләгән иде. Тик шулай да аның соңгы сүзе барыбер акча булды:

—Акчаны җәлләмәгез, акча бар. Ун мең алмасалар, иллене бир, анысына икеләнеп торсалар—йөзне төрт! Уңышлар телим!

Акмал хан машина ишеген үзе ачты һәм кисәтеп куйды:

—Каршыга килүче ике ак "Волга" күрсәгез, иелегез, сез бит Дулкынның нинди хәйләкәр кеше икәнен беләсез, мин сезнең визитыгызның сер булып калуын телим.

Бер кара "Волга" Кызылташ янына килеп җиткәндә шундый ук номерлы икенчесе кузгалып китте. Һәм үзенең серләре, яшеренлеге, гадәти булмаган мөнәсәбәтләре белән Кыек көзгеләр иле артта калды. Прокурор шоферның үзен күзәтүен белә иде, шуңа күрә йөзенә битараф кыяфәт чыгарып утыргычка авышты һәм күзләрен йомды, бөтен кыланышы белән арыганлыгын, бернәрсәгә исе китмәгәнлеген күрсәтәсе килә иде. Ә башында туктаусыз теге кәгазьләр турындагы уйлар әйләнде дә әйләнде. Әнә ул кул сузымында гына, ләкин түземсезлек күрсәтергә ярамый. Үзендә гөнаһлар юк дип санаган, үрнәк тормыш алып барган кеше үзе хакындагы ниндидер кәгазьләргә игътибар итеп тормаска тиеш. Ул шулай эшләде дә. Икенче көнне исә Җәлил Акмал ханга нәкъ шулай җиткерде дә.

Авыр көн мәшәкатьләреннән арыну, ашказанын җылытып торучы коньяк аны йокыга этәрә, әмма баш миендә кайнаган уйлар черем итәргә дә ирек бирми. Папканы алып карау өчен нинди сылтау, сәбәп табарга соң?! Тынычланыр иде, ичмасам. Акмал хан аның турында ниләр белә, кем кемгә бурычлы һәм бәйле булып калган икән?

—Кунаклар күренде,—дип битараф кына кисәтте Җәлил.

Прокурор күзләрен ачты һәм каршыга зур тизлектә килүче ике ак "Волга"ны күреп алды. Сенатор алар үзләре акрын баралар дип уйлады, шуңа Җәлилгә дәште:

—Зинһар, тизлегеңне арттыр әле, юлы җайлы, урын җитәрлек, безне туктатмасыннар тагы.

Шофер газны арттырды, спидометр угы "120" саннары янында тирбәлә башлады, хан кешеләре әмер-приказларны үти беләләр шул. Алдагы машиналарга ике йөз метрлар калгач, Сухроб иелә төште, шул ук минутта куәтле двигательләр куелган, салондагы кешеләре күренмәсен өчен кара тәрәзә куелган ак "Волга"лар выжт итеп, сызгырып узып та киттеләр. Җәлил һәм беренче машинадагы Ибраһим бер-берсен сәламләп клаксонга бастылар, югары, кискен ике тавыш бергә кушылып ерактагы тауларда кайтаваз булып яңгырады.

—Узып киттек,—диде шофер, чөнки кара "Волга" иңкүлеккә чумган, ә кунаклар тау артына кереп югалган иде инде.—Ибраһим шашкан кебек чаба, кая ашыга инде?—дип әйтеп куйды Җәлил.

Ибраһим исемен искә алуга ук Сенаторның уң янбашы авыртып куйгандай булды, куллары ирексездән авырткан җиргә үрелде. "Кабахәт, җае гына чыксын, төрмәдә черетәм мин сине",—дип усал уйланып куйды бер генә рәнҗетүне дә гафу итә белми торган прокурор. Гафу үтенергә дә килә белмәде, ә хан шуны оештыра алмады, ул аны муенына элмәк тагып, арканда сөйрәп алып килергә тиеш иде, кәефе төшкән, нишләргә белми, имеш. Ул алтынтештән ничекләр үч аласын күз алдына китереп ләззәтләнде, хәтта үзе турындагы кәгазьләрне дә онытып җибәрде. Алар Аксай биләмәләренең чигенә җиткәннәр икән, машина шлагбаум янында туктап калды. Постта изелгән кыргыз эшләпәсе кигән, аның вертолетта килүен хәбәр иткән сакчы иде, ул машинага туктарга кушмады кушуын, юлны буй-буй сызыклы тимер

торба белән дә япмады, әмма Җәлил машинадан чыкты һәм борылып әйтте:

—Мин бер секундка гына, журналда билгеләнеп чыгам, бездә шундый тәртип. Кайчан киттен, кайчан кайттын, билгеләп баралар ...

Сенаторның кулы үзеннән-үзе папкага үрелде, хәтта ачарга да өлгерде, әмма иң соңгы мизгелдә тыелып кала алды, урынына куйды, ләкин беренче сикертмәдә үк төшеп китәрлек итеп куйды. Ул моны эшләп кенә өлгерде, шофер кабина ишеген ачты. Кузгалып киттеләр. Сухроб берни дә булмагандай башын утыргыч аркасына терәде һәм күзләрен йомды, гүя аның бернигә дә исе китми.

Көтмәгәндә генә үзен күн итек белән типкәләгән Ибраһимга булган ачуы Акмал ханга күчте. Бер сәбәпсезгә, тиктомалдан ачуы кабара торган прокурор багажниктагы биш миллион акчаны да, республиканың иң югары идарәче даирәләренә компромат тупланган атташе-кейсны да, тынлый торган аппаратураны да онытты, хәтта ханның, гәрчә, тереләй утта кыздырырга мөмкинлеге булып та тормышын саклап калуы, гомеренә кагылмавы хәтереннән очып чыгып китте, юкса, ул боларның уен-муен гына түгеллеген, кем белән эш иткәнлеген яхшы белә иде бит.

“Һы, вәгазь остасы, мулла табылган, республикадагы хәлне тотрыксызландыру, дип акыл саткан була,—дип тагы да кыза төште ул.—Юкса, без белми идек. Мамык халыкның үзәгенә үткән анысы, бер үзбәкнекенә генә дә түгел, күз житсә, шәһәр халкы да кырдан кайтып керми. Мамык җыю майлы ботка ашау түгел шул. Августтан декабрьгә кадәр каторга хезмәте бит, мамыктан башка бернәрсә дә күзгә күренми. План! Теләсә нинди бәягә план!”

Гомумән, бу илдә риза булмаганнар, кимсетелгәннәр, изелгәннәр азмыни? Кая төртмә, бәла килә дә чыга. Соңгы утыз елда, Хрущев идарәсе чорларыннан гына да егерме биш миллион кеше төрмәләр аша узган, тагын шул кадәресе тегендә-монда акча төртеп, йә булмаса, хокук саклау органнарының көчсезлегеннән, тешсезлегеннән, наданлыгыннан файдаланып котылып калгандыр. Илдә Аллага да, муллага да, патшага да, еллар буе вәгъдә ителгән якты киләчәккә дә ышанмый торган җинаятьчел катлау яши. Аларның үз этикасы, үз әхлак законнары, үз теле, үз культурасы.

Менә шушы катлау кешеләре теләсә кайсы хакимиятне бәреп төшерергә сигнал гына көтә, чөнки алар явызлык кына күрә, үзләренең уңышсызлык сәбәпләрен дә шул хакимияттән таба. Мәйданга ни сәбәпле чыксалар да, янган шырпыны, Акмал хан, менә кая төртергә кирәк, анда күптән бензин сибелгән. Органнарда эшләүче буларак, ул бу явызлыкка каршы көрәшерлек көчләр югын да белә, профессионаллар бармак белән генә санарлык, партаппарат монда да үз кешеләрен тутырды, ул номенклатураның бәясе бер тиенгә тормый, болар бит башка урыннан эшен алып бара алмавы өчен куылган өер, мондый ышанычсыз коммунистларга соңгы эш урыны—хокук органнары һәм күпне күргән-кичергән, ил белән бергә үзе дә җимерелгән культура-мәдәният өлкәсе генә калды.

Ибраһимга булган үпкәсеннән прокурор үзеннән-үзе Аксайга баруын анализлауга күчте. Монда плюслар да, минуслар да күзгә күренеп тора. Әлбәттә, ул буш кул белән китмәде, теләгәнен алды, ләкин җанына канәгатьлек килмәде. Бердән, бу сәяхәт Шубаринга билгеле булды, телисеңме, юкмы, аңа бу турыда нидер сөйләргә, күпмедер ачылырга туры киләчәк. Артур Александровичны алдый алмассың һәм бу кирәкми дә. Үзеңә шундый дошман табарсың, тормышыңнан колак кагарсың, ул синең “эшләр”ең турында Акмал ханга караганда күпкә яхшы белә, сиңа карата тиешле кәгазьләре булмаса да, аяк эзеңә басып килә.

Ә Дулкын Назаровичның көтелмәгән визиты?—Ник килгән ул, аның планнарын иснәнеп белгәнме, аны акча чыганагыннан аерып ташларга телиме? Акмал хан аның белән ныклы элемтәгә кермәсме, ни дисәң дә, Дулкын күптәнге аппарат төлкесе. Менә кемнән яшерен серләренне күмеп тотарга кирәк. Димәк, ул әле берни дә кырмады, ә төрле яктан Япон, Дулкын Назарович, хәтта Акмал хан да аңа “кулларын салдылар”, ханны

гына кара: "эштән читтә каласы килми", эмиграциягә китәргә дә каршы, аңа эчке һәм тышкы мөһажир булу ошамый. Прокурорның планнарында боларның берсе дә юк иде. Аксай Крезы карталарны бигрәк тә бутап ташлады. Бер уйлаганда, барысы да дөрес исәпләнгән иде—аның акчасын, архивын ала да үзен чит якларга, Пенелопасы көтеп яткан җирләргә олактыра. Юк бит, төрле дәлилләр таба, тәҗрибәсе, мәкере җитәрлек булган шушы кеше дә хөкем каршына басачагына ышанмый. Ниндидер күз буу бу, билләһи!

Прокурор монда нык ялгышты шул, ханның үзе кебек шапырына да белергә иде бит. Юкса, ул Акмал ханның төп калканы булган Шурикны вафатыннан соң барлык дәрәҗәләреннән һәм хөкүмәт бүләкләреннән мәхрүм итүгә документлар әзерләнүен белә. Аннан соң инде аның исемендәге урамнар, мәйданнар, шәһәрләрнең икенче исемгә күчүен көтәргә генә кала. Болар барысы да аның тарафдарлары, элеккеге яраннары тарафыннан җинел генә эшләнә. Дөресрәге, үз җанының саклау хакына теләсә кайсы гамәлгә баручылар тарафыннан. Димәк, озакламый мәрхүм Шурикка мәһабәт Ленин музее янында да урын калмаячак, җәсәден күчереп башка җиргә күмәчәкләр. Бу турыда ул төгәл белми һәм артык әһәмият тә бирми иде, күрәсен, Рәшидов үле килеш тә күпләрнең язмышын үз кулында тота.

Андый мәсьәләләр турында Мәскәү эмиссарлары Беренче белән күзгә-күз генә сөйләшәләр, хәзергә барысы да яшерен, Акмал хан әйтмешли, бу тема хәзергә матбугат өчен түгел. Менә хәзер ул—прокурор—тынлый торган аппарат белән барысын да белә алыр. Шурикның хәле мөшкеллеген ишеткәч, "Күз бууч"ы да үзенең иректә калу мөмкинлегенең тарайганнан-тарая баруы турында уйламый калмас, эмиграциягә җинелрәк риза булыр. Иректәге хан исә аңа комачаулык тудырачак, нинди комачаулык кына әле! Ул бар чакта теләсә кайчан аркаңа пычак көт, ул бервакытта да ярдәмче, киңәшче, сәяси амбицияләрдән азат финанс магнаты роленә риза булмаячак, ул үз вакытын көтә, беренче уңайлы очракта ук прокурорны кирәкмәс йөк урынына бер якка очыртачак яисә теге ят табакеркадан сигарет суыртачак.

Аксайда очрашуны җентекләбрәк карасаң, хан аңа түгел, ә ханга аның кирәклеген чамаларга була иде, бүген аның иректә калуы прокурорның эшчәнлегеннән, тырышлыгыннан, көч куюыннан килә бит, акчаны да ул аңа өстенә күтәрелгән йодрыкны читкә этәрү өчен бирде, нәрсәгә аңа синең идеяләр, планнарың, перспективаларың. Ханга котылып калу кирәк. Әгәр ялган паспортка риза булса, Ариповны коткарып калу да ярый һәм аны шушы адымга төрлечә этәрергә кирәк. Беренченең кабинетында Шурикның үлеменнән соңгы язмышына кагылышлы беренче яшерен язманы ук Аксайга җибәрәсе булыр, мин кагылгысыз дип, хыялга бирелеп ятмасын.

Акмал ханның эшләрен аның рухи остазы, акка киенеп йөрүче, сөйләшми торган хезмәтчесе Сабир-баба никадәр белә икән? Хан аңа үзенең миллионнарча-миллионнарча сумлык байлыкларын ышанып күрсәтте микән? Бусы сорауларның да соравы! Барысын җентекләп анализларга кирәк, кечкенә генә ялгыш һәм йөзләрчә миллион сумнар сере хан белән китәчәк, ул Пенелопасының адресын беркемгә дә калдырмаячак.

Гомумән, барысын да уйларга кирәк, ләкин уйлап бетеререлек кенә түгел, кайда гына орынма, һәрнәрсәнең икенче катламы бар, һәр җөмләдә яшерен мәгънә ята. Шәрекъ—читләтеп әйтү, аллегория, әйтеп бетермәү, символлар ул, барысын да исәпкә аласы, чөнки ялгышның бәһасе—синең тормышың.

Аксайдагы ике көнлек визиты турындагы уйларга баткан Сухроб күпмедер вакытка Сабир-баба тарафыннан аппаратуралы тартмага беркетелгән папка турында онытып җибәргән иде. Ләкин озакламый ул үзен искә төшерде, бер текә борылышта утыргычтан төшеп китте һәм идәндәге резина келәмчеккә мәталде, аннан очып чыккан бер сары кәгазь бите Җәлил алдына барып төште. Җәлил аны кунакка сузды, менә шунда прокурор, ниһаять, үзе теләгәнчә папканы ачып карый алды.

Биографиясе ифрат төгәл бирелгән иде, аны студент елларыннан ук

яхшы белгән кеше язгандыр, дусларын атаган, хатыны ягыннан туганнарын да искә алган. Шәрекътә күп нәрсә кан-кардәшләр, үз нәселең кешеләре белән эшләнә. Миршаб белән бергә хезмәт итүе дә калмаган, Хашимовнын прокурор тормышын иң яхшы белүче икәне дә күрсәтелгән. Калганнары аның "Шәхси эш" папкасыннан күчерелгән, ул вакытта прокурор Югары судта эшли иде, тагы нindидер детальләр, штрихлар, характеристикалар бар, аларны яшерен дип тә әйтеп булмас, шул ук вакытта теләсә кемгә күрсәтер өчен дә түгел. Бусы шикләндерә иде һәм ул Сәлимне кисәтергә булды: шәхси эшләрдәге информация читкә китә, шулай икән, Аксайда эшләүче кешенең эзенә төшәргә, җае чыкса, стенага терәргә һәм ике яклы агент ясарга кирәк булыр. Кызык бит—кем аның белән кызыксына икән?

Машинкада басылган юллар, ә алар "Аерым игътибар сорый" грифында бирелгән иде, прокурорны утка салгандай итте. Үзенең уй-прогнозларында ничек дөрес булган ул! Әйе, иртәгә кинәт-капылт үзгәрешләр булса, властька пантөркиләр, панисламчылар яисә дини фанатиклар килсә, яисә яшел байрак астында мөселман республикасы калкып чыкса, аны беренче фонарь баганасына асып куячаклар иде. Юк, алай җинел үләргә дә ирек бирмәсләр, кайчандыр бөек шагыйрь Хәмзәне үтергән кебек, таш белән атып-бәреп теге дөньяга озатырлар иде.

Сенатор өч битле текстны игътибар белән укып чыкты һәм аерым бер төркем адәмнәр аны үлемгә хөкем итәргә әзер икәнен аңлады. Шулай булгач, ул Аксайга юкка һәм юктан гына килмәгән, мөнәсәбәтләрне юкка ачыкламаган, Акмал ханга үз кеше икәнен юкка расламаган. Әгәр югарыда эшли, кемнәргәдер ошамый торган карарларга килә икән—бу бит зур эшләр хакына кылынган гамәл. Яшел байрак хәрәкәтен рухи җитәкләүчеләр аның белән горурланырга тиешләрдер, ул да алар арасында, аның бишенче катка менеп утырырлык мөмкинлекләре җитәрлек.

Аның турында ниләр генә әйтелмәгән иде монда! Имеш, ул яшерен рәвештә КГБ полковнигы званиесен йөртә, имеш, ул "десантник-руслар" белән бергә милләтнең бар каймагын утыртып бетергән. Рәшидов вакытында үзен властька якын китермәүчеләрдән явызларча үч ала, дип тә язганнар. Бернинди исбатлауларга корылмаган усал демагогия иде бу. Ләкин алар арасында тынны кысылып куярга мәҗбүр иткән берничә генә юл да күзгә чалынып үтте. Документны төзүче, дәлилләре булмаса да, шактый тирәнгә каерган иде. Янәсе, Әкрәмхуҗаев яклаган докторлык хезмәте һәм матбугатта ул чыгарган кызыклы мәкаләләр аның авторлыгы турында сөйләми, чөнки аны белгән кешеләрне бу шикләндергән, аптырашка калдырган. Партиянең югары эшелоны өчен докторлык диссертациясе "әвәләүчеләр" дә ул хезмәтнең авторын күрсәтә алмаганнар, кире какканнар, хәтта хезмәтне язган кешенең кем булырга мөмкинлеген дә әйтә алмаганнар. Республикадагы хокукый проблемаларны шулай тирәннән һәм белеп кем яктырта алыр микән дә, квалификацияле рәвештә бәяләр микән, дигән сорау һавада эленеп калган иде.

Соңгы язмада аның ОБХСС капитаны Кодрәтовны төрмәдән коткаруы турында әйтелгән иде. Капитан бик билгеле кешенең кияве булып, Әкрәмхуҗаевның гуманлык акты атаклы гаиләгә шактый кыйбатка төшкән, имеш. Ләкин бу "кыйбатлык" саннар белән күрсәтелмәгән иде. Ләкин галстуксыз джентельменны сумма дигән нәрсә бөтенләй борчымый, ул капитанның больницадан прокурор Азлархановны үтергән Коста Джиоевны урлап чыгуы турында бирәр мәгълүмат юкмы, дип борчыла иде. Хатын-кыз итәге тирәсендә чуалырга яратучы фырт Кодрәтов прокурорга әйтеп бетергесез хезмәт кылган иде бит. Сенаторның сөенеченә, андый язу юк иде. Андый мәгълүмат булса, алар аны политик аренадан гына түгел, иялңгән эш урыныннан да тавыш-тынсыз гына китәргә мәҗбүр итәрләр иде. Монда, кәрт шулерлары әйтмешли, капларлык кәрт юк, ә туймас корсаклы капитанны бераз "тунавы"н беләләр икән, куркыр нәрсә юк, Шәрекътә кайсы гына түрә ришвәт алмый икән!

Прокурор искитмәгән кыяфәт белән папканы янына ташлады, йөз

чалымнарында бу документларга битарафлык чагылырга тиеш иде. Юкса, укый башлар алдыннан ничек кенә шүрләгән иде әле. Бармаксыз калкып чыгар, Кощей кушаматлы Ростов карагы да төптә ятмас, прокуратура ишегалдында үтерелгәннәрнең дә аның өстендә икәнен чамалаганнардыр, дип курыккан иде. Әйе, аның хакындагы мәгълүматлар күпкә тулырак булырга мөмкин иде бит! Кәрт уеннарын кая куясың? Фантастик отышлар һәм оттырышларны! Прокурорның икейөзле тормышы машинкада басылган йөзләрчә битне тутырырга җитәрлек иде.

Шубарин белән ике елдан артык якын дус булуы турында да бер сүз юк, ә аның белән алар шактый "эш" майтарып өлгерделәр. Бер уйлаганда, алар аның турында берни дә белми һәм бу шатланырлык фал иде. Ул бит гомере буе диярлек күләгәдә яшәде, үзенә карата берәүдә дә кызыксыну тудыра алмады, күрәсең, мондый позициянең дә үз плюслары бар икән. Жан киеренкелеге сүрелде, ул иркенәеп калды, юкса бу папка аңа тыныч суларга ирек бирми башлаган иде инде. Хандагы мәкернең ни дәрәҗәдә икәнен белгән Сенатор аның ни-нәрсә кылырга мөмкинлеген ачык чамалый иде. Менә хәзер бөтенесе дә үз урынына утырды. Аксай Крезы аның кулында һәм ул ана үзенә этлек эшләргә ирек бирмәс. Шунда кылт итеп Сабирбаба юлга дип биргән кәрзин исенә төште, күнеленә канәгатьлек дулкыны йөгерде, визитның уңышлы тәмамлануын "юарга" кирәк иде.

Сенатор көтмәгәндә генә үзен шулкадәрле яхшы хис итә башлады, хәтта авыз эченнән нindидер көй көйләргә тотынды, ә бит студент елларыннан соң җырлаганы юк иде диярлек. Кунактагы бу үзгәрешне Җәлил дә күрми кала алмады һәм ул астыртын гына аны өске көзгедән күзәтә башлады. Прокурор кинәт кенә папканы алды һәм аны вак кисәкләргә erткалап, ачык ишектән җил уңаена тузгытып җибәрде, әле күпмедер элек кенә аны борчыган нәрсәләр тузанлы канауга барып төштеләр, юл кырыендагы куакларга кундылар.

Шоссе тимер юл янәшәсенә килеп чыккан иде инде. Кирәкле станциягә ярты сәгать чамасы барасы калган. Прокурорның кәефе элеккечә күтәренке иде, ул поездның Ташкентка иртә таңда килүенә үкенеп тә куйды, вагоннан төш иден дә берәр җирдә уңышлы эшне билгеләп үт идең. Ләкин аны ҮКда эш көтә, дүшәмбе көнне ике киңәшмә, берсе КГБда, икенчесе прокуратурада. Кичен сылу Нәргиз янында Сәлим һәм Артур Александрович белән очрашып утырсаң да ярап куяр иде. Бәлки аларга бүләк бирергә дә кирәктер—һәркайсына кесә чыгымнарына иллешәр мең ташласаң да була, чемоданда биш миллион ята ич. Ләкин илле мең аларны артык шатландырмас шул. Ә аның аларны бик сөендерәсе килә иде. Менә шунда ул Шубаринны аңлады да: ул бүләкләрне сирәк бирә, ләкин алар бик кыйммәтле, кадерле була, шуңамы бүләкне кабул итүчеләр шатлык давылы кичерәләр, бу турыда бик озак онытмыйлар. Аксайдан ул беркемгә бүләк алмады, кевлар жилет аныкы түгел, Акмал ханныкы иде.

Кешеләрне шатландыру өчен юмарт булу гына җитми, нечкә зәвыклы булу да кирәк. Бу исә үзе бер сәнгать. Таныш-белешләре арасында андый кеше берәү генә. Ул да булса—Шубарин. Узган кышны ул аның "Жигули"енә дип, "Пирелли" дип аталучы шиплы шиннар бүләк итте, өстәвенә табигый сарык йонынннан ап-ак чехоллар! Бу инде игътибар билгесе генә түгел, синең тормышың, сәламәтлегең турында кайгырту дигән сүз дә.

Аның фикерләре Аксай сәяхәтен анализлауга әйләнделәр дә кайттылар, әйләнделәр дә кайттылар. Күнеленә якын нәрсәләр турында, һич югы, акча хакында төпләп уйлый алмады. Әле тауларга визитка кадәр үк Сенатор аз белемле, надан бу кеше ничек итеп озак еллар буе нечкә тоемлы Рәшидов кебек инсанга тәэсир итте икән, аңа ничек йогынты ясады икән дип баш ваткан иде. Ул җавапны Аксайда табармын дип уйлаган иде, ләкин бу теләк булып кына калды, анлауга таба бер адым да ясый алмады. Хәзер дә, күрәсең, берни дә аңламас, серне Шурик үзе белән кабергә алып киткән инде. Шәрәф Рәшидович белән бергә-бер очрашсан, берничә мәртәбә очрашсаң, бу йозак-сорауга ачкыч табып булыр иде, бер караганда әлеге

дуслык-бергәлек башка сыймый ич. Хәер, политикада нинди генә берлек-бергәлекләр булмас! Кайчан да булса киләчәк буыннар туган якның Рәшидов идарәсе чорындагы егерме еллык тарихын яхшылап өйрәнгәндә Аксайның соры кардиналын да онытмаска тиешләр, элеккеге трактор бригадасы хисапчысы шактый зур эшләр майтаруга сәбәп булган бит. Кыек күзгеләр иленнән сәяхәттән кайтып килгәндә, ханга кушамат бирергә кирәк булса, гәрчә Арипов төрле эффектлар ясарга яратса да, ул аны "Күз буучы" дип атамас иде инде. Акмал хан, ни дисәң дә фигура, аны аңлату өчен икенче кеше фамилиясен—икенче бер монарх, хәтта тулаем держава язмышында куркыныч һәм зур роль уйнаган Распутин фамилиясен атарга кирәктер. Алар арасында барыбер охшашлык, күпмедер туры килү, тәңгәллек бар иде. Акмал ханга бары тик яңа сыйфатлама гына өстәргә кирәктер: ул—Шәрекънеке, шәрекъ Распутины.

Еракта тимер юл станциясе манзарасы гәүдәләнә башлауга Сенатор Акмал ханның үзенең дусты Шәрәф Рәшидович турында белгәннәрен иркенләбрәк сөйләрмен дигәнен исенә төшерде. Ул аны хәзер дә, үлеменнән соң да, һаман мыскыллаган шикеллерәк иттереп, Шурик дип кенә атый иде әле. Бәлки, кайчан да булса бу дуслыкның сере ачылыр, менә шунда гына ул кышлакта яшәп яткан, рәсми постка ия булмаган кешенең егерме миллион халыклы республикада гаҗәеп зур тәэсир көчен аңлар. Моны белү, шуңа җавап табу аның хакимият өчен аяусыз көрәшендә юл күрсәтүче йолдыз—ориентир булып торыр иде.

Бер-берсенә бөтенләй охшамаган бу ике кешене бәйләп торган яшерен серне аңларга теләп ул шулкадәрле тирән уйларга баткан иде, хәтта юлдагы бернәрсәне дә күрмичә-сизмичә барды, бары Җәлилнең тавышы гына аны чынбарлыкка кире кайтарды:

—Домулла, борчыганым өчен гафу итегез, поезд станциядә өч кенә минут торачак,—диде шофер ашыккан шикеллерәк иттереп.

Ул башында бәргәләнгән табышмаклы уйлардан теләр-теләмәс кенә аерылды һәм керфекләрен күтәреп тирә-якка күз салды. Ул утырган "Волга" провинциаль шәһәр вокзалының буш перронында тора иде инде. Аксайга, шәрекъ Распутины янына хәтәр сәяхәт шуның белән тәмамланды.

## Өченче кисәк

### ТРОЯ АТЫ

Төн уртасындагы сөйләшүдән соң Шубарин, гәрчә урынына барып ятса да, яңадан йоклап китә алмады. Телефонның төнлә шылтыравына күнегеп беткән хатыны хәтта шөбһәләнеп сорап куярга мәҗбүр булды:

—Берәр нәрсә булганмы әллә?

Ул хатынының йокыдан җылынган битенә иреннәре белән кагылды, юрганын ипләбрәк япты һәм тынычландырырлык итеп әйтте:

—Йокла, сөйкемлем. Гадәти шылтырату. Сухроб сиңа сәлам юллый, бу минутларда ул Акмал хан биләмәләрендә күңел ачып йөри.

Ул тагы ярты сәгать күзе ачык килеш ятып торды һәм йокының инде тәмам качуына ышанды. Хатынын борчымас өчен, акрын гына торды, гәүдәсенә килешеп торган куе кызыл төстәге, алтын җепләр белән чигеп ниндидер Британия спорт клубы гербы төшерелгән велюр халатын киде дә беренче катка төшеп китте, ванна бүлмәсенә терәп зур булмаган бассейн салынган иде. Бу йортны ул Шәрәф Рәшидович вакытында моннан унбиш еллап элек төзеткән иде, борынгы, инде күптән оешып бер гаилә булып яшәүче үзбәк мәхәлләсендәге зур участокны да ул Беренче ярдәмендә алган иде. Йорт төзер өчен иске җәйге кинотеатрны сүтәргә туры килде килүен, хәер, ул бина сугыштан соң ук төзелгән иде. Ул, әлбәттә, төзелеш өчен урынны,

интекми-борчылмый гына икенче бер районнан да таба ала иде. Ләкин Бохарадагы әти-әниләре кебек үк үзбәк мәхәлләсендә яшәүне өстенрәк күрде, үзе дә шунда тәрбия алган кеше буларак, мәхәлләнең өстенлекле якларын яхшы белә иде. Мәхәлләдәге күрше туганыңнан артык, анда кешенең әхлакый нормаларга нигезләнгән тәртибен бәяли беләләр. Мәхәлләдә яшәгәндә син йорт хуҗасы гына түгел, бәлки гасырлардан килүче традицияйола кушканча яшәүче күмәклекнең бер әгъзасына да әвереләсең. Монда сине беркемнән рәнҗеттермәсләр, лаеклы адәм булсаң бигрәк тә. Мәхәллә кагыйдә-тәртипләрен, гадәтләрен Шубарин белеп кенә калмыйча, аларны җаны белән кабул иткән иде инде. Мәхәлләдә хакимияттән йорт салырга рөхсәт алу гына җитми, хакимият бер нәрсә, ә күрше-күлән бөтенләй башка. Шуна күрә, кинотеатрны сүткән чакта ук ул Бохарадан мөхтәрәм өч аксакалны чакырып китерде. Болар аның туган мәхәлләсендәге иң хөрмәтле кешеләр иде, алар аның әтисен, бабасын беләләр, гасыр башыннан бирле яшәгән туган-тумачасын хәтерлиләр; шул ук мәхәлләдә аның әнисе, сеңлесе, туганнарының туганнары яшәп ята. Шушы күпне күргән, күпне белгән картлар мәхәллә чәйханәсендә даими утыра торган булып киттеләр, чөнки мәхәллә җәмгыятенең күп мәсьәләләре, нигездә, шушында хәл ителә. Бохаралылар чәйханәнең мөхтәрәм кунакларына әверелделәр, ә инде өченче кичне Артур Александровичның үзен дә мәхәллә җыенына чакырдылар. Өстәлдә бохарача әзерләгән пылау иде. Шунда ул ташкентлыларны чәйханәгә Герат осталары тукыган чын әфган каләме бүләк итеп кенә түгел, үзбәк телен менә дигән итеп белүе белән дә шаккатырды. Бу алар өчен теләсә кайсы бүләктән дә кадерлерәк, мәхәллә кассасына бирелгән зур взнос та алай зур хөрмәт тудырмас иде. Мәхәллә халкы алар янына тагы бер җитди һәм үзбашка яшәүче кеше урнашканына ышанды. Ничек ышанмыйсың ди, икенче көнне үк кинотеатр урынын чистартканда Артур Александрович әзер проект һәм ике яшь архитектор белән килде. Проект күптән бар иде инде, ул аның өчен байтактан бирле ярашлы җир эзләде, ләкин беркайда да борын төртә алмады, чөнки йә урыны ошамады, йә бакча мәйданы җитми иде. Ә бакчасыз йортны ул күз алдына да китерә алмый.

Шул ук көнне әлегә дувал белән әйләндереп алынмаган буш җиргә өч бакчачыны эшкә алдылар, аларны да аңа мәхәллә комитеты тәкъдим итте, болар өчесе дә бүгенгә кадәр аның ишегалдында эшләп яталар. Бакча йортның, ихатаның иң матур җиренә, Шубаринның горурлыгына әйләнде. Аның янында особняк та бик күзгә ташланмый иде. Тыштан артык бизәлмәсә, чуарланмаса да, эчтән бар яктан җайлы вә унайлы булды. Ул мәхәлләдәге башкалар кебек үк "тәрәзәләре ишегалдына" караган йортта яши, кемгәдер особнягын күрсәтү өчен түгел, ә үз тормышы, үз рәхәте өчен! Шәрекъта кешеләр үзләрен җәмгыятьтә башкачарак раслыйлар, тирә-юньдәгеләр белән гармониядә яшәп кенә үзләренә хөрмәт тудырып булганын, үзләренә һәм "оялары"на куркынычка урын калдырмаганнарын аңлыйлар. Бу хикмәтләргә Шубаринны әле үзе дә мәхәлләдә яшәгән әтисе өйрәткән иде. Шул көзне ул йортына күченде дә, ялтырап торган ак калай түбәне йомшак яшел төскә буяп күршеләрен тагы бер шаккаттырды, чөнки яшел түбәле особняк яшел бакчада гына түгел, мәхәлләнең башка йортлары арасында да эреп юкка чыккандай булды. "Бу йорт үзенең хуҗасына охшаган", диде бер бакчачы,—ул күренеп тора, әмма күзгә ташланмый, күзеңне ертып керми".

Гүя бүгенге йокысызлыкны алдан сизенгәндәй, ул кичә бассейнга су тутырып калдырган иде, халатын салып атты да суга чумды, рәхәтләнеп йөзәргә керешге. Өйдә кунган чакларында ул гел шулай эшли. Дөрес, бүген берничә сәгатькә иртәрәк булды булуын. Ул бассейнга юри җылы су җибәреп тормады, йөзеп туйгач, кайнар душ алырга кирәк булыр, кайнар һәм салкын суны шулай алмаштырып файдалану сәламәтлеккә аеруча файдалы. Ул берничә еллар шулай эшли һәм авыруны белми диярлек. Авырып яту аның өчен үзенә рөхсәт итә алмаган бердәнбер "зиннәт", сырхап ятарга вакыт юк, чөнки аның көннәренең ничек үтәсе берничә атна алдан ук уйлап

куелган була иде. Андый кешеләрне Көнбатышта "уларга дә вакыты юк", диләр. Шубарин да шулар токымыннан иде.

Бассейннан Артур Александрович кухняга күчте, анысы да беренче катта иде. Зур чәшкә кофе әзерләп, икенче катка, тәрәзәләре бакчага карап торган кабинетка күтәрелде. Күзләрен иртәнге сәгатьләрдә ул тәрәзәдән карап торырга ярата, мондый вакытта яңа көн җәйдәгечә ачык һәм якты булып түгел, ә томаннар аша ничектер өстерәлеп һәм ашыкмый гына атлап туа. Мондый мизгелләрдә хәтта шәһәрдә дә ниндидер тантаналы тынлык урнаша, барысы да яшеллеккә күмелгән, әйтерсең лә, йөзем куаклары белән йөзләрен эсседән каплагандай тоелучы алар мәхәлләсендә бигрәк тә шулай иде. Кинәт кенә аның бакчага күз саласы килеп китте һәм ул бүлмәдәге кнопкага басты, аллеяларда, тәрәзә төбендәге яшел болынчыкларда ут кабынды. Күз алдында гаҗәеп күренеш ачылды, кешеләр кулы белән тудырылган сихри бакча иде бу! Бакчага инде унбиш еллап булыр, агачлар өчен, бигрәк тә сирәк реликт һәм җимеш агачлары өчен бу үсү-ныгу, чәчәк ату чоры. Әгәр кемдер аннан үз җаның-күңелең өчен ни белән шөгыльләнергә теләр идең дисә, җавап бер генә—бакча булыр иде. Шуңа да ул бакчачыларга аерым хөрмәт белән карый, аларның бәясен белә, мәхәлләдә аралашкан кешеләренең дә күбесе бакчачылардан булып, алары да аны аңлыйлар, чөнки бакча белән кызыксынуын, хәтта мәхәббәтен сизәләр иде. Ул Шредер ботаника бакчасыннан белгечләр чакырды, алар бакчачыларга агачларга бәйле әллә нинди серләрне ачтылар, куаклар, чәчәкләр турында белем бирделәр, тегеләр үзләре дә хәйран калды; әлбәттә, ни талантлы булса да, үзешчәнлек бер нәрсә, ә галим белгеч—бөтенләй икенче. Шубарин шундый кешеләрне таба һәм очраштыра белүдә маһир иде. Бакча белән бакчачылар да үсте. Ничек кенә арыган, гасабиланган булмасын, өйгә кайткач аңа бакча аллеяларында ун минут йөреп алу җитә—җан киеренкелеген, тән аруын кул белән алып ташлагандай була иде. Биек дувал белән әйләндереп алынган бакчадагы һава дәвалы, шифалы үзенчәлекләргә ия дип саный ул һәм беркем дә аны бу фикереннән кайтара алмас иде.

Ләкин бакчасы никадәр сөйкемле һәм кадерле булмасын, ул анда сәгатьләр буе гүзәллеккә сокланып йөри алмый, андый көннәр бик сирәк эләгә. Ул теләр-теләмәс кенә утны сүндерде, эш өстәле янындагы торшерны кабызды һәм ирексездән үзалдына елмаеп куйды, башына мин автоматик режимда яшим бугай, дигән уй кергән иде. Аның эш кабинеты киң һәм иркен, ул ниндидер карар кабул иткәнче, фикер туплап ишекле-түрле йөренергә ярата, урын җитәрлек. Кайчагында монда елына өч-дүрт мәртәбә ашыгыч киңәшмәләр дә булып ала, гадәттә биш-алты кеше җыела, ләкин берәү дә тарлык-кысанлык сизми иде.

Менә хәзер дә кофе чәшкәсен тотып, соңгы вакытта аеруча кызыксына башлаган картиналар эленгән стена буенда йөри, ләкин бүген ул аларны күрми, чөнки җавап табылмаган бер мәсьәлә башын бораулый: Сухроб нишләп Аксайга барып чыккан? Акмал хан өстендә кара болытлар куерганын әз-мәз фикер йөртүче дә абайлый бит инде. Бу сорау беренче карашка тоелганча, артык гадиләрдән түгел иде. Аның рәсми рәвештә баруы турында сүз дә булырга мөмкин түгел, заманалар башка, субординация буенча да бу мөмкин түгел, әгәр дә инде хезмәте буенча барган булса, аны Наманган өлкә комитеты кешеләре озатып йөрер иде һәм берниндн куркыныч, хәтәрлек булмас иде. Аксайда Сенаторның муенында элмәк тартылганын ачык сизде ул, хәер, прокурор үзе дә моны яшермәде. Берничә ел аралашу дәверендә алар бер-берсен ярты сүздән аңлый башлаганнар иде инде. Акмал хан да яшереп тормады, бераз тавышланганнарын әйтте. Ханның характерын искә алсаң, "бераз тавышландык" дигәне прокурорның әле үтерелмәгәнлеген аңлата иде. Прокурорга бу сәяхәт нигә кирәк булган, нишләп башын элмәккә тыккан һәм, дөресен әйткәндә, могҗиза белән генә исән калган? Әгәр прокуратурада, КГБда яисә ҮКда аның хан янына барганын белсәләр, аның карьерасына тәре сугарга була, бүген андый нәрсә белән шаярмыйлар. Тагы бер сорау—нишләп ул, хет рәсми визит булсын, хет

яшерен булсын, сәяхәтен аннан яшергән? Ханнның еш кына Беренче үтенече белән ана мөрәҗәгать иткәнен яхшы белә бит ул.

Визит нигә яшерен, аның астында ни ята? Шубарин буш чәшкәне тәбәнәк өстәлгә куйды, үзе картиналар янында атлавын дәвам итте, ләкин аларга күз атмады. Һәм кинәт кенә күз аллары яктырып киткән кебек булды, тотты да Сәлим Хәсәновичның телефон номерын җыйды. Югары судта эшләүче буларак, ул да көтелмәгән телефон шылтыратуларга ияләнгәндер, әмма бу минутларда Шубаринда әдәп кайгысы юк иде.

—Тыңлыйм сезне,—диде Хашимовның йокы әсәре дә сизелмәгән тавышы.

—Сәлам, Артур, бу мин, хәерле иртә дип тә әйтергә авырсынам, Алла хакы өчен, вакытсыз шылтыратуым өчен гафу ит, ләкин мин икенче көн инде безнең дустыбызны эзләп таба алмыйм, ә ул миңа муеннан кирәк.

—"Лидо" белән берәр нәрсә булдымы?—дип куркынып сорады Миршаб.

—Юк ла, "Лидо"да барысы да шәп, чәчәк ата, уңышлы эшли. Ул миңа башка мәсьәлә буенча кирәк, белмисеңме, ял көннәрен ул кайда уздыра?

—Юк, ул миңа шәһәр читенә яисә башка якка чыгу турында әйтмәде, без аның белән җомга көнне төштән соң күрешкән идек, күрәсең, шәһәрдә ял итәдер. Хәер, ул миңа да кирәк, ләкин минем эш көтәр, табылсын гына.

—Әлбәттә, табылыр,—диде аптырамый гына Япон һәм трубканы куйды.

Якын дусты һәм тарафдарының да Сенаторның Аксайга баруын белмәвенә ул шикләнмәде. Акмал хан янына шулай ашыгып чыгып китүнең артында ни ята? Төнге шылтыратуның да аның теләгеннән башка эшләнгәнен Шубарин төшенми калмады, әлбәттә. Сухроб ике яклы уен алып бармыймы? Ләкин нигә? Аларны хәзер шулкадәр күп нәрсә үзара бәйләгән ки, аннан яшереп эш итүнең мәгънәсе юк. Табышмак булды бу төнге шылтырату.

Артур Александрович Сальваторе Розның зур полотносы янына туктады, бу картина аның коллекциясендә иң кыйммәтлесе иде, тик шулай да ул ана бер караш та ташламады, ә бит ул әлеге әсәрне ярата, аның белән горурлана иде.

Бүгенге вәзгыять, иң беренче чиратта, Сенаторга игътибарлырак, таләпчән караш булдыруны сорый иде, бәлки биографиясендә, аның сәхнә арты гамәлләренә җавап бардыр? Рәшидов үлгән елда кылган гамәле аңа карата бар шикләнүләрне алып ата, Шубарин картеле мәнфәгатьләре орбитасына эләккән барлык кешеләрне тикшергән кебек, аны да энә күзеннән үткәрү турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде. Чөнки прокурорда аның бөтен империясенә компромат бар иде, һәм әгәр ул җәмәгатьчелеккә, бигрәк тә Андропов чорында, барып ирешсә, аның империясенең көле күккә очкан булыр иде.

Барысы да шулай, ләкин фактлардан, кичәгесеннән дә, бүгенгесеннән дә китеп булмый, әгәр үткәннәренә ышандырырлык аңлатулар бар икән, димәк, бүгенгеләренә дә табарга кирәк. Алар, әлбәттә, табылыр, ул бу турыда бөтенләй шикләнми, ләкин аның Сенатор тормышында казынасы да килми иде, чөнки күпмедер дәрәҗәдә ул аны үзе барлыкка китерде бит.

Теләсә дә, теләмәсә дә, хәзер аның артыннан караштырырга, күзәтергә туры киләчәк һәм бу эшне кемгәдер йөкләп тә булмый. Артык шикләнү зур гаугa белән тәмамланырга мөмкин. Сенатор соңгы елларда кинәт, күзгә күренеп үсте, власть аңа файдага булды, ул төрле яклап ачылды, бу күпләрне, хәтта вакыт-вакыт аның үзен дә гаҗәпләндерә иде. Тумыштан килгән йөгерек акылы белән ул бер күз ташлауда ук республикада нинди көчләрнең ничек урнашуын сизә, Шубарин зур гына дәрәҗәле кешеләрнең, уңайлы хәл туганда, киләчәктә аңа таяначакларын белә иде, хәтта аның иске дусты, "утта янып тере чыккан" сәясәтче Дулкын Назарович та Әкрәмхуҗаев язмышында шундый борылыш булуын кире какмый. Аның өчен гүя күк капусы ачылган иде.

Әйе, Сенаторның кинәт кенә күтәрелеп китүе күпләрне шаккатырды, әмма район прокурорының карьерада мондый "очыш"ка ирешүенең асыл сәбәпләре ана билгеле.

Шубарин аның хокук темасына язылган барлык мәкаләләрен кемгә караганда да зуррак диккать белән укып чыкты. Аларда кыюлык та, теоретик эшләнмәләрдә тирәнлек тә, янача фикер йөртү дә, үз сүзеннең дөреслегенә ышану да, эмоциональлек һәм дәрт тә җитәрлек иде. Монысын кире кагып булмый. Кем әйтмешли, сабынлап юып биргәндәй чиста хезмәт, аткан саен унлыкка тидерү, авырткан проблемаларның үзәгенә кадалу. Публикацияләр генәмени—Шубарин прокурорның докторлык диссертациясен дә кулга төшереп укып чыкты—барысы да дөрес, бер сүз әйтмәслек, югары профессиональ эш! Ләкин, нишләптер, мәкаләләр сериясе шикләнү уятты, элеккеге район прокурорының докторлык диссертациясенә дә ул, нишләптер, чын күңелдән шатлана алмады? Юкса, ул аның кыйммәтен аңлый, авторның гражданлык кыюлыгын да бәяли иде.

Чөнки Сенаторның эшләре белән кызыксынып йөргәндә, алар белән танышканда, ул боларның барысын да теге яки бу формада кемнәндер ишеткән кебек тоя иде, ул аның исемен дә төгәл-төгәен белә—Әмирхан Даутович. Әйе, әйе!—үтерелгән прокурор Азлярханов. Ләкин Сенаторның беркайчан да, аңа төнге озын-озак мөсәхәбәләр вакытында да, хокук өлкәсендә фәнни эзләнүләр белән шөгыльләнәм, дигәне булмады. Әгәр, чыннан да, эшли икән, яшереп тору нигә кирәк булгандыр. Ул каршы төшәргә теләмәс, киресенчә хуплар гына иде. Шикләнүләргә урын калгач, ул белешеп карады—кайчандыр ике прокурорның юллары кисешмәгәнме? Җавап бер генә булды—бервакытта да. Хәер, белемле, киң эрудицияле прокурор Азлархановны гап-гади район прокуроры, житмәсә, төнге талаулардан да чирканмаучы Сенатор белән ни бәйләсен, ди.

—Әмирхан Даутович...—Шубаринның иреннәреннән шушы исем ычкынды һәм ул ыңгырашып куйды. Аны хәзергә кадәр бер сорау газаплый иде—үлгәндә Азлярханов үзен үлемгә Шубарин хөкем иткәнен белде микән?

Әле дә бүгенгедәй хәтерли, тәкъдирендә фәлакәт булып язылган көнне ул Шәрәф Рәшидовичның үле гәүдәсе яткан Нукустан Ташкент аэропортына кайтып кына төшкән иде, кайгылы кара хәбәр шунда килеп тә ирешге, Коста Азлархановны атып үтергән. Бераз аңына килгәч, вәзгыятьне үзгәртер көче булмаса да, гүя аны тупикка кертеп куйдылар, кеше ышанмас хәлгә тап булганын, Коста Джиоевның котылгысыз рәвештә атарга мәҗбүр булганын аңлап алды. Костаны яхшы белә ул, үзен коткарыр өчен генә беркайчан да андый адымга бармас, тән сакчысы аның прокурорга мөнәсәбәтен белә. Коста элеккеге өлкә прокуроры белән күләгәле икътисадның зур эшкуары арасында үзара сәер симпатия барлыгын аңлый иде. Аларның икесенә дә үз даирәләрендә легаль рәвештә талантларын үстерергә юл куймадылар. Костаны, Шубаринның үзе кебек үк, алдау мөмкин түгел, ул аларны күптән белә, читтән күзәтергә мөмкинлеге дә, вакыты да булды. Димәк, вакыйгалар агышы тәкъдирдә фәлакәт булып язылган, кара язмышка китергән. Соңыннан Сенаторның сөйләвенчә, әгәр прокурор Костаны җибәрсә, ул, ишектән керүче полковник Чураевны атып үтереп, ишек алдындагы ак "Жигули"да китеп барган булыр иде.

Прокурор үлеп, ярты ел узуга, Шубарин Лас-Вегаска бертуган сынчыларны—Григоряннарны чакыртты, алар Азлархановның хатыны Лариса Павловнага кабер ташы-һәйкәл ясаганнар иде инде. Бертуганнарны алып килүне йөкләгәч, тән сакчысы Ашот моның ни өчен кирәклеген шундук аңлап алды һәм аңа хас турылык белән сорап куйды:

—Сез ул сатлыкка һәйкәл ясатырга телисезме?

Шубарин аның усал сүзләрен тыныч кына тыңлады һәм әйтте:

—Дөрес аңлагансың, мин чыннан да һәйкәлгә заказ бирәм, андый кешенең кабере исемсез булып, өстендә чүп үләннәр үсәргә тиеш түгел. Бу минем йөрәгемә тия. Дәүләт аны яшәгән чагында ук онытты, үлгәч аны кем искә алыр? Без аның белән фикердәшләр идек, хәтта бу сүзләр сәер яңгыраса да. Мин аның кешелек сыйфатларына баш ия идем, шул тугрылыгы, намусы аны һәлакәткә илтте, кабергә тыкты. Әгәр дә ул бер кабих җан булса, озак һәм бай яшәр иде. Ихтирамга лаек, сокланырлык кеше иде ул.

Шулай түгелме?—Әйткәннәренең Ашотның авыр аңында нидер кузгатканын күреп, ул болай тәмамлады:—Ә хәзер кушкан жиргә бар һәм башка мәнсез сүзләр сөйләмә, үпкәләвем бар, мин аңа яратып каравымны беркемнән дә яшерми идем.

Ул прокурор үлеменең бер еллыгын исенә төшерде, ул көнне алар Фәйзиев белән Ташкентта, Госпланга киләсе ел өчен заявка биреп йөриләр иде. Ел азагында кемнәрдер алып бетерә алмаган фондларны һәрвакыт кулга төшерергә була. Шубаринда бу яктан аучы сизгерлеге бар. Әлеге тактиканы да ул үзенчә исәпләп чыгарды, аңа, яңа елга бер атна калгач, берәр нәрсә бүлеп бир—тартып алачак. Кыскасы, ул көнне эшләре муеннан иде. Госпланнан чыгуга, Артур Александрович бер генә минутка Алай базары янында туктарга кушты. Базардагы чәчәк сатучылардан ул чиләге белән бер кочак ак розалар күтәреп чыкты.

—Әче таңнан гүзәл букет, димәк, чынлап гашыйк булгансың ахры,—дип шаяртты Фәйзиев, шефының сәер гамәленә аптырап.—Хәзер инде бәллүр ваза алырга да керәсе булыр. Сүзгә оста компаньон туктый алмый иде. Ләкин Япон шаяртуны күтәреп алмады, ә иске шәһәргә, эшли торган мәчеткә юл тотарга кушты, һәм шулай итеп, коллегасын тагын бер кат гажәпләндерде.

Мәчет янына килеп житүгә, Шубарин Икрам Мәхмүдовичның башыннан кулдан эшләнгән кыйммәтле Наманган түбәтәен салдырып алды һәм биш минут көтәргә кушты. Түбәтәй пижон урынбасарның ак "Мерседес"ы, башка нәрсәләре кебек үк затлы һәм кыйммәтле иде. Мәскәүгә очканчы эшләре шактый күп иде әле. Жомга көн, мәчеткә картлар елга булып агыла, капка төбенә хәерчеләр жыелган. Артур Александрович дувал ягына күз салды һәм андагы жиде саилчене күреп, юлы уңганга сөенеп елмайды. Мөселман ининуынча, хәерне нәкъ менә жиде хәерчегә, жиде карт кешегә бирергә кирәк. Һәркайсына берәр кызыл унлык төртеп, аларны гажәпләнүдән телсез калдыргач, Шубарин саф үзбәк телендә алардан дусты Әмирхан рухына дога кылуларын үтенде. Аннан соң ул тиз-тиз атлап мәчеткә керде, эчке ишегалдында картлар намазга әзерләнә, тут агачы күләгәсендә жиде карт тора, ә жиде намаз карты хавызда комганнарына су тутыра. Ул инде башка якка карап та тормады, тиз-тиз генә барысына да унлыклар биреп чыкты һәм тагын чиста үзбәк телендә үтерелгән дусты Әмирхан рухына дога кылуларын сорады. Биш минуттан ул берни дә аңламаган Фәйзиев янында машинада утыра иде инде. Башындагы түбәтәен дә аңа кайтармыйча үзе әйтеп куйды:

—Ә хәзер Чиготай зиратына.

Иске шәһәрдәге зират янында аңарга ияреп шофер да чыгарга теләгән иде, ләкин шеф аны бик мәгънәле итеп туктатты:

—Утыр, безнең икебезгә бер түбәтәй, ә мазарстанга яланбаш керү гөнаһ.

Компаньон "Мерседес"та калды, чәчәкләрнең кемгә икәнен ул һаман да белми, шулай да берәр хатын-кызгадыр дип гөман кыла иде.

Чиготай зираты кечерәк калкулыкта урнашкан һәм шәһәр йортлары килеп тәрәлгәнче бик күп еллар элек үк мазарстан булып торган. Жир тетрәгәннән сон нык үскән Ташкент аны күптән кочагына алган иде инде. Ул хәзер торак йортларның үзәгендә үк калган һәм күп катлы йортлар әйләнәсендә ничектер чит-ят булып тоела иде.

Көз ахыры булуга карамастан, жәйгечә якты, кояшлы көн тора иде һәм Артур Александрович машинадан чыгуга, кесәсеннән кара күзлеген алды, чөнки аңа кояшка каршы тауычыкка менәсе булачак. Мазарстанның балчык дувалы янында хәерчеләр күп түгел, нибары биш-алты кеше, Шубарин аларга да хәер өләшеп чыкты. Бер үткен күзле малай, күрәсең, ул монда вак-төяк йомыш үтәп акча эшлидер, Артур Александровичның затлы кыяфәтенә су чиләге бик үк туры килмәгәнлеген абайлап алдымы, чиләкне күтәреп барырга алынды. Прокурор белән очрашу хакында уйланып барган Шубарин чәчәкләр тулган чиләкне аңа сузды, малай шундук йөзенә зиратта булырга тиешле кайгылы, мескен кыяфәт чыгарды һәм аның артыннан

иярде. Ул белми түгел, белә бит, күрмәде түгел, күрде бит: әлеге аксыл тройка костюм кигән кеше хәерчеләргә мул гына сәдака бирде. Аңа да төшәчәк!

Һәр башкала зираты кебек үк, Чиготай бик зур мәйданны били иде, илле ел вакыт эчендә ул сагышлы зур паркка әйләнгән, аның үз аллеялары, урамнары, тыкрыклары, аркылы юллары, тупиклары бар. Шәрекътә, башка җирләрдәге кебек үк, кабер өстенә агач, куак, чәчәк утырталар. Соңгы бер-ике елда Чиготай ябылган санала һәм күмәргә рөхсәтне шәһәр башкарма комитеты гына бирә иде, шуңа карамастан, республика прокуратурасы үзенең элеккеге хезмәткәре өчен ике квадрат метр җиргә ордер ала алды һәм бу кабер мазарстанның эчендә, мул сулы арык янында, дувал буенда урнашкан иде. Артур Александрович әле ай ярым элек кенә бертуган Григоряннарның эшен кабул итәргә килгән, шуңа күрә юлны яхшы хәтерли иде.

Русларның якшәмбесе, яһудиләрнең шимбәсе булган кебек, җомга—мөселманнар көне. Шуңамы, зиратта кеше күп иде, хәер, башка көннәрдә дә халык аз булмый. Соңгы борылышка атлауга биек гранит стела күренде. Шубарин малайдан чиләкне алмакчы гына булган иде, күзе кабер янында торучы озын гәүдәле, милиция формасындагы таза кешегә төште. Ул адымын акрынайтты—шиксез, теге инсан да ул барасы кабер янында тора иде. Формалы кеше кызыксыну уятса да, аның беркем белән дә очрашасы, беркем белән дә сөйләшәсе килми иде. Шуңа күрә прокурор белән бер рәттәге икенче кабергә—танылган яшь балеринага куелган ак мәрмәр сынлы-һәйкәлле кабергә таба борылды. Бертуган Григоряннар мәрмәр сынны бик ошатканнар, аны югары профессиональ скульптор ясаган дигәннәр иде. Соңыннан кабер янына килүчеләрдән һәйкәлнең авторы автокатастрофада үлгән балеринаның ире икәнлеген белделәр. Бу кабер янында һәрвакыт кешеләр күп була, Шубарин шикләнми шул якка атлады. Һәйкәл итәгеннән корыган-кипкән чәчәкләрне алып маташканда, милиция формасындагы кешенең җинаятьләрне ачу бүлеге башлагы полковник Чураев икәнен танып алды. Полковник кулына фуражкасын тоткан килеш кабер каршында тора, әмма йөзенә чыккан сагыш та аның нык гаҗәпләнүен яшерә алмый иде. Гаҗәпләнерлек тә. Кабер өстендә буй-буй кызыл юллар сузылган куе яшел төстәге гранит һәйкәл, аста да шундый ук гранит плита. Плитаның уң ягында бик тә матурлап эшләнгән һәм гранит эченә кисеп кертелгән бронза монограммада өч хәреф балкый— А. Д. А. Прокурорны якыннан аралашкан кешеләр әлеге хәрефләрнең аның имзасы, култамгасы икәнен яхшы беләләр иде. Стелада әле прокурорның рәсеме астына болай дип язып куелган:

*Азларханов Әмирхан Даут улы*
*1932-1983*
ПРОКУРОР

Ә прокурор сүзе өстендә инде бронза белән түгел, ә гранитка чокып "чын—хак" дип тә өстәп язылган иде.

Һәм менә шушы бер "чын—хак" дигән сүз күнегелгән гадәти язуга бөтенләй икенче мәгънә, яңгыраш кертә иде. Күрәсең, аны соңыннан гына, кемнендер таләбе буенча эшләгәннәрдер, яисә сынчының җан сискәнүе-этәрүе сәбәп булгандыр. Ләкин, иң беренче чиратта, нәкъ менә шул сүз күзгә ташлана иде. Көн-төн чабып йөргән, кабер өстендәге калкулыкта язулы фанер тактадан гайрене күрмәм дип килгән полковникка гаҗәпләнер урын булгандыр. Полковник почетлы каравылда торгандай үрә баскан, күрәсең ул теге көздәге каһәрле көндә ике минутка гына соңга калганын исенә төшерәдер. Бер генә минутка соңга калмаса да, прокурор исән калачак иде бит. Ул Коста атканнан соң гына килеп керде һәм иптәше алдында үзен гаепле саный иде.

Мундирлы кеше кинәт кенә плитә өстенә иелде, кызыл канәфер чәчәкләрен төзәтеп куйды, тәртипкә кертелгән кабергә янәдән бер караш ташлап кайту ягына борылды. Кабер янының күпмедер китүгә, аның җилкәләре

асылынып төште, җиңел адымнары авырайды, кыска чәчле ак башы аска иелде. Фуражкасын култык астында тотып, ул ерагая барды, үтерүче һәм рецидивистларның иң усал дошманы булган полковник күз яшьләреннән оялмыйча елый иде. Артур Александрович, ул сагышлы паркның төп урамына борылганчы, аның артыннан әле озак кына карап торды. Алар икесе дә бер кешене уйлап хәсрәтләнәләр иде.

—Әмирхан Даутович...—дип әйтеп куйды ул тагын.—Белсәң иде, сезнең уй-фикерләрегез ни сәбәпле Сенаторныкы белән туры килгәннәр дә, нәкъ менә ул аларны матбугатта халыкка чыгарды һәм нинди данга иреште, тирә-юньдә башка юристлар азмыни?

Кинәт кенә аны бер ачыш кисеп үтте: болар барысы да аның тирәсендә әйләнә, хәтта рух-җан ягыннан бер-берсеннән бик нык аерылып торган бу ике кешенең бәйләнешендә дә үзенең катнашы булуын тоя башлады кебек. Бу интуитив ачышта нидер бар, ләкин аяк астында ныклы җир, барып тотынырдай урын юк, таянырга яисә этелеп китәргә дә берни күренми. Ләкин ул үзен белә, һәр шигенә җавап табарга тырышачак—нишләсен, табигате шундый. Аның фикерләре тагы Сенаторга әйләнеп кайтты, ул, мөгаен, дүшәмбе көнне кайтып җитәр һәм аның белән очрашырга ашыгыр, чөнки яшеренеп кенә Аксайга, Акмал хан янына баруы сер булып калмады бит.

Аксайның хәтергә ышкылып китүе, моннан берничә ел элек таныш булмаган район прокурорыннан документлар тутырылган дипломатны алгач, шатлыктан, алдын-артын уйламыйча, аны үзенә якын җибәрүнең хата булганлыгын чамалый башлады. Хата шунда иде, ул үз кагыйдәләренә тугры калмады—ныклап төпченеп, тикшереп тормады.

Тикшерүнең бик гади юлы бар иде—моның өчен бары тик Акмал ханга үз кешенне җибәрергә һәм ярдәм сорарга гына кирәк иде бит. Ул чакта аларның мәнфәгатьләренең дә үзара чапырылшкан чоры иде. Ә Аксай Крезының кемгә генә компроматы юк, Сухробка да булгандыр ул. Шулай иткән булса, хәзер ул аның Аксайга яшерен визитының максатын да аңлар иде. Ләкин терсәк якын да, тешләп кенә булмый дигәндәй, инде үткәнне кире кайтырып булмый. Бүген исә "маршал Гречко"га борын тыгу мәгънәсез, аларның анда ни турында килешкәннәрен кем белә. Шәрекъ—нечкә эш, бу юлны да кире кагарга туры килә. Акмал ханның яшерен документларына аның үзенә дә ике тапкыр мөрәҗәгать итәргә туры килгән иде, ике тапкырында да Аксайга үзе барды, чөнки серле-гөнаһлы кешеләр шундый биектә, Арипов аларны берниндн арадашчыга да ышанып тапшырмаячак иде.

Әле теге тыныч заманнарда Акмал ханда ике көн кунак булуы искә төште. Кич белән аудан кайткач, атылган киектән кичке аш әзерләгәннәрен көтеп, фәлсәфи темаларга әңгәмә кора-кора йомшак курпачларга таянып ял итәләр иде. Иннәренә киң, җылы чапан салып, әз-әзләп кенә кыйммәтле француз коньягы "Камю"ны йота-йота, күбрәк ул сөйли, Акмал хан кунакны игътибар белән тыңлый иде. Шунда йорт хуҗасы аны кинәт кенә бүлдерде:

—Әгәр календарьда җитмешенче еллар ахыры булмаса,—дип, эчпошыргыч бер төрле тавыш белән башлап китте ике Гертруда иясе.—Әгәр мин сине күп еллар белмәгән булсам, мин сине Англия шпионы дип уйлар идем.—Японның беркайчан да борчылу билгеләре сиздермәгән йөзендә аптырау галәмәте күреп, Акмал хан көлеп җибәрде.—Син үпкәләмә, мин синең шпион түгеллегеңне беләм, син—безнеке, төп Бохараныкы. Ләкин нишләп башыма шундый уй килде соң әле? Аңлатам. Сөйләүләреңә карагында, Җунаид-хан белән ингә-иң сугышкан минем әти янында бер инглиз дә булган, ул да синең кебек безнең телне, гадәтләрне белгән, хәтта Коръәннән яттан өзекләр китергән һәм безнең надан муллаларны шуның белән сөендергән, шаккаттырган. Синең дә Коръәнне белгәнеңә шаккатмыйм. Хәзер син минем белән саф үзбәк телендә сөйләшеп утырасың, Шәрекъ философлары турында сүз катасың, ә аларны безнең интеллигенциядән

күбесе белми. Ә большевикларның бар аңлашылмаган яисә авыр аңлашыла торган нәрсәне империализм һәм шпионнар тыкшынуына сылтау гадәте бар. Шулай булгач, син—шпион!—Ул тагы кычкырып көлеп җибәрде.

Бусы Аксайга икенче тапкыр килгәч булды. Беренче тапкыр килгәндә аудан йөреп кайткач әйтелгән "шпион" сүзен йомшарту өчен булса кирәк, Акмал хан аңа үзенең шулхәтле ышануын, яратуын әйтте, хәтта ислам байрагы астында Үзбәкстан мөселман дәүләтенә әйләнсә дә, теләсә кайсы хөкүмәттә иң мөһимнәрдән саналган икътисад яисә финанс министры портфелен уйлап та тормыйча сиңа гына тапшырыр идем, диде. Сиксәненче елларда әле аерымлану, мөстәкыйльлек турында күпләрнең уенда да булмаганга күрә, Шубарин ислам дәүләтенә дә, яшел байракка да, аңа портфель бирәчәк хөкүмәткә дә игътибар итеп тормады, премьер роленә Акмал хан үзен тәгаенли икән, "шпион" дип әйтүен йомшартырга теле бу дип кенә уйлаган иде.

Баксаң, Акмал хан шулвакытта ук еракка караган, акылында-уенда аерым бер программа тоткан, ә бит бик күпләр бүген генә, хәбәрдарлык һәм үзгәртеп кору чорында гына, милли мөстәкыйльлек хакындагы уйлар калкып чыкты, исламның яшел байрагы астына җыелу башланды дип уйлыйлар.

Менә шул чорларда ук Артур Александрович агропромышленность берләшмәсе директорының нинди куркыныч, үтергеч көчкә ия корал белән эш иткәнен чын мәгънәсендә тойган иде. Әйтик, кайбер кемсәләр турында төрле-төрле материаллар тупланган канцелярия папкалары, Акмал хан кулыннан ычкынып башкалар кулына килеп керсә, бигрәк тә зур куркыныч көчкә әйләнәчәк иде. Бу уйлар аны утка салды. Әгәр кемдер Аксайга килеп, аның шундый кәгазьләрен алса? Шушы минутларга кадәр ул бу хакта башына да китереп карамаган иде. Теге чакта кирәк документны караганнан соң ул китәргә теләгән иде, ләкин Акмал хан сорагач, кунып калды. Ханның кунакларга тартылуы бер чир сыман иде, чөнки ул ялгызлыкны яратмый, күтәрә алмый, ә өстәл янында үзгәрә, чын тормыш белән яши башлый, мәҗлесләп утырганда гына башкаларны тыңлый ала. Артур Александрович аның әлеге сәер гадәтен күптән аңлап алды. Ләкин ул Ариповның күңелен күрү өчен калмады, аңа кәгазьләрне үзе белән алып китәргә кирәк иде, чөнки әлеге папка аның турында, аңа тутырылган иде.

Ул көнне табын янында, ул исәпләгәнчә, алар икәү генә булмадылар. Көтмәгәндә Аксайга Мәскәүдән бер журналист хатын килеп төште, аңа агропромышленность берләшмәсе турында чираттагы панигирик язарга кирәк икән. Бу Японның карталарын бутап ташлады ташлавын, ләкин артык борчылыр сәбәп тә юк иде.

Алма бакчасындагы кунак йортында мәҗлес башланырга ун минут кала Акмал хан аның бүлмәсенә килеп керде һәм журналисткага бирәсе бүләген күрсәтте.

Бик матур эшләнгән, корым-кара төстәге замша белән тышланган тартмачыкта ни ятканын чамалаган иде инде ул, һәм ялгышмады да—ачып җибәрүгә зур бриллиант кашлы йөзек күзләрне чагылдырырлык уйнак нурларын сипте.

—Үзәк матбугатта чыкса да, бер мәкалә өчен артык кыйбат түгелме?—дип сорады ул аннан.

—Фотография белән,—дип аны төзәтте Акмал хан һәм көлеп җибәрде.—Хатын-кыз буларак та ярыйсы бит, Мәскәүдән, язучы...

Артур Александрович ефәк бауга эленгән бәя кәгазен карады һәм сызгырып куйды.

—Монысын, минемчә, өзеп алырга кирәк,—диде ул.—Мондый бәя кемне дә куркытырга мөмкин.

—Үзеннән үзе аңлашыла,—диде хан эшлекле кыяфәттә.—Бу нәрсә кирәк урынга язып куела, бәя кәгазе "дело"га тегелә, минем исәп-хисап ятратканны беләсең. Барысы да Ленинча: "Социализм—иң беренче чиратта хисап ул!"

—Әйе, Ленин васыятьләренә турылыклы син,—диде кунак, икесе дә күңелле генә көлеп җибәрделәр, кичә бик матур башланып китте.

Язучы хатын яшь түгел иде инде, ләкин Мәскәү дамаларына хас булганча эшлекле, булдыклы булып күренергә, булмаган энергиясен ташып торган итеп күрсәтергә маташты, ул мондагы зәңгәр күзле ир кешегә нindiрәк роль бирелгәнен дә сизенмәде, ә бит үз-үзен тоту манералары, киенә белүе ягыннан ул бер дә провинция кешесе түгел иде. Аны Акмал ханның итагатьле сүз әйтәм дип бик нык дулкынлануы да бутый, әле бит хан, ярдәм сорагандай, үзбәкчәгә күчә дә зәңгәр күзгә мөрәҗәгать итә. Анысы үзбәкчә берничә реплика әйтә дә русчага тәрҗемә ясый, шул ук вакытта игътибарлы булырга, матур сүзләр әйтергә дә онытмый, ләкин әлеге элегант тәрҗемәче, ул аны гарәп Лоуренсы дип атады, атаклы директорның дәрт-дәрманын сүндерергә тырышуын да чамалый. Чөнки тегесенең йөзендә мәрхәмәт билгеләреннән тыш аның белән хатын-кыз буларак чын-чынлап кызыксынуы да ярылып ята иде. Хатын-кыз бу мәсьәләдә беркайчан да ялгышмый. Вакыт-вакыт ул бу үзен бик матур тоткан гарәп Лоуренсының баш иеп чыгып китүен дә тели, ярты төн узды бит инде, ләкин салкын зәңгәр күз үзен иртәнгә кадәрле мәҗлесләп утырырга җыенган кебек тотты. Менә шунда язучы ялган энергиясен сипми башлады, үз яшенә хас булмаган уенчаклыгын да онытты, юлда арыганлыгын әйтте, аннан сәгать поясы турында нидер мыгырданды, адаптация-акклиматизация турында нидер өстәде һәм ял итәргә китте. Зәңгәр күз белән тартышу аңа кая инде! Соңлап булса да, шуны аңлады.

Аның артыннан ишек ябылуга, Акмал хан үз-үзен белештермәстән әйтеп салды:

—Нинди хатын! Нинди генә кешеләр белән аралашмый!! Кайсы гына ишекләрне аягы белән генә тибеп ачмый!!!

Артур Александрович башта аны суытмакчы булды, исәбе бер-ике фраза белән аны гөнаһлы җиргә бастыру иде, әлеге сүзләр авызыннан ычкына да башлады, әмма кәефен бозарга теләмәде, шул фикерендә калсын дип уйлады һәм шуңа аны сүзеннән бүлмәде:

—Әйе, ул бүләккә лаек, хәтта бәя язылган кәгазе белән.

Шундук ике Гертруда иясе аның исәнлегенә тост тәкъдим итте. Эчеп куйдылар, менә шунда Япон төшенде дә инде, Акмал хан Мәскәүдәге югары кабинетлар ишеген тибеп кенә ачучы әлеге хатын белән очрашудан эйфория кичергән минутларда ана үз проблемаларын хәл итеп калырга кирәк иде.

—Акмал, син миңа Шубаринга төзелгән кәгазьләрне бүләк ит әле...

Йорт хуҗасы бер минутка аптырап калды, ләкин соңыннан көлеп җибәрде.

—Артур, ышанам, син шаярасың, сиңа нәрсәгә ул, әнә дошманнарыңныкы белән кызыксын.

—Юк, Акмал, бүген мин үзем теләгәнне алырга телим.

Сөйләшү куркыныч төс ала башлады, бу якларда Япон белән беркемнең дә дошман буласы килми, моны Акмал хан да яхшы белә, Шубаринның мөмкинлекләре чиксез, шуңамы ул вакыт сузу, фикер туплау өчен коньяк бүлә башлады.

—Әгәр андыйлары юк, мин дуслар өстеннән компромат җыймыйм дисәм?

Шунда кунак көлеп җибәрде, җитди дәлилләрсез Акмал ханның документларны бирмәячәген ул яхшы аңлаган иде, шуңа төп козырьны сайлады:

—Акмал, безнең синең белән мөгамәләләр шундый, мин сине авыр хәлгә куя алмыйм, ләкин кемгәдер мишень дә буласым килми. Әгәр сиңа ышанам икән, бу бит теләсә кемгә ышанам дигән сүз түгел, кемдер минем кәгазьләргә дә күз салырга мөмкин бит.

—Саллы булды бу,—дип бүлдерде аны Акмал тыныч кына, ул акыллы Японның үзенә чигенү өчен юл калдырганын сизеп алды.

—Әгәр мин кәгазьләрне бүген алмасам, бер атнадан миңа үз кешеңне җибәр, мин сиңа тиешлесен җибәрермен. Әлбәттә, копиясен, ә төп нөсхәсе Лас-Вегаста калыр, син дә миңа ышанасың бит?

—Әйе, Артур, ышанам, башлы кеше син, сине юкка гына "Англия шпионы" дип атамаганмын икән теге вакытта, хәтерлисеңме?—дип кычкы-

рып көлеп җибәрде Аксай Крезы, үзе шундук уч төпләренә сугып алды, ишектә Ибраһим күренде.

—Бар әле, Артурның кәгазьләрен алып кил, ул безнекеләрнең профессиональ эшләүләренә ышансын, житмәгән урыннарына үзем өстәп язам ди.—Үзе көлүен дәвам иттерде. Арадагы кискенлек шуның белән бетте, Акмал хан шактый оста дипломат та иде шул.

Шубаринга калын канцелярия папкасын биргәндә Арипов болай диде:

—Ярый, минем өстән компромат җыю мәшәкатьләреннән коткарыйм әле. Аны хәтта миңа да бер атна эчендә генә җыеп булмый, тәҗрибәмә ышан, моны алырга кеше җибәрмәм. Без бит бер-беребез турында күп беләбез.—Акмал хан өстәл аша кулын сузды һәм икесе дә иркен сулап куйдылар, чөнки нинди куркыныч дошманлыктан котылганнарын аңладылар...

Артур Александрович кабат тәрәзә янына килде, таң атып килә иде инде, кинәт кенә аның бакчада йөрисе килеп китте, иртәләрен йөрү сирәк эләгә, тиз генә спорт костюмын киде дә түбәнгә төшеп китте.

Бакча өстен дымлы томан элпәсе каплап алган, ул күренми дә диярлек, бәлки ул яктылык җитмәүдән шулай тоеладыр, чөнки люминесцент лампаларның көче кимүгә бара иде, ләкин ул "тургай" буларак вакыт күчешен тиз тойды, бу вакытта төн табигатьне кочагында соңгы тапкыр тота, болар өстенә ул үз бакчасының томанын да яхшы белә. Ике сәгатьтән юкка чыгасы дымлы һавадан ул бөрешеп куйды, ләкин соңыннан таң алды һавасының чисталыгы белән ләззәтләнү өчен, вак керамик плиталар салынган аллея буйлап йөгереп алды. Инженерлык белеменә ия кеше буларак, ул эчке ишегалдына асфальт та, бетон да кертмәде. Алдан уйлап әзерләнмәгән килеш йөгереп алу, озаклап бассейнда йөзү кебек үк, бакча хуҗасына ныклык, кәеф көрлеге өстәде һәм ул гимнастика залларында сәгатьләр буе ятучы Коста белән Ашоттан хәтта көнләшеп куйды, ә андый заллар кооперация игълан ителгән Ташкентта бихисап иде.

Бакчага ул тән күнегүләре ясарга яисә йөгерергә дип төшмәде, аның яраткан агачлары яныннан әйләнеп узасы, чәчәкләр кисеп аласы, артыш куаклары янында утырасы килгән иде. Артыш куакларын аңа Акмал бүләк иткән иде, алар гомерне озайта дигән иде. Гомерне озайтамы-юкмы, әмма артыш бар зарарлы бөҗәкне үз тирәсеннән куа икән, моны аңа ботаника бакчасы галимнәре дә расладылар.

Ләкин... кабинетында атлап йөргәндә картиналарны күрмәгән кебек, ул аллеяда йөргәндә яраткан агачларын, куакларын, чәчәкләрен дә күрмәде, ҮК кешесе турында уйлар аны кабат биләп алды.

Арендага ресторан алу идеясе башка югары түрәләрдән алдарак кооперация мөмкинлекләрен чамалап алган Сенаторныкы иде. Артур Александрович та күп кенә идән асты предприятиеләрен яктыга чыгарган иде. Бәлки ул идея шуннан тугандыр да. Кооперативлар турында указ чыгасын Шубарин Мәскәүдәге дуслары аша ярты ел элек үк белгән иде инде һәм ул законны җентекләп анализлады. Баштарак ул күләгәдәге икътисад акчаларын юу максатын гына куйган иде. Үзе өчен күзгә кырып салырдай акча гына саналган налогларга декларация тутырды һәм кулында законлы акчалар пәйда булды. Бервакыт шәһәр читендәге бер чәйханәдә әбәтләп утырганда Сенатор әйтә салды:

—Артур, нишләп син үз эшчәнлегеңне үзгәртмисең, аны күп тармаклы итмисең?—Мәҗлестәшенең кызыксынуын күреп дәвам итте:—Мин сиңа Ташкентта бай, зиннәтле ресторан ачарга тәкъдим итәм. Капитал салуның иң отышлы юлы булачак ул.

—Әйтеп тә карадың, Сухроб, миннән нинди ресторатор чыксын инде?!—дип Шубарин сүзне көлкегә бормакчы иде, әмма табындашы сүзендә нык торды:

—Ә нигә? Мин бит сиңа ресторанны үзең җитәклә димим. Синең Лас-Вегастагы ярдәмчең Икрам Мәхмүдович бар, ну, теге ак "Мерседес"та йөри торган егетне әйтәм. Ул бит тумыштан кулинар, тәмле тамак, андыйларны эзләп тә таба алмассың. Ресторан эше, минемчә, аның стихиясе, хәер,

аның хатын-кызга ябышкак булуы аркасында ул бу эштә беренче кеше була алмас, житәкче буларак тартмас та, вәләкин яхшы компаньон булыр. Мин бай интерьерлы, яхшылап өйрәтелгән, энә-җептән киенгән хезмәт күрсәтүчеләр булган беренче классны ресторанны күздә тотам. Аңлашыла ки, ул кыйммәтле ресторан булырга тиеш.

—Интерьер белән униформадан тыш синең тәгаен-төгәл башка тәкъдимнәрең бармы?—дип сорады мәжлестәш, әлеге тәкъдимнең житдилегенә һаман төшенеп житә алмыйча.

—Әлбәттә! Синең каныңның яртысы саннардан тора, син тумышың белән банкир, эшкуар, бары тик кирәк урында яисә вакытында гына тумагансың... Ә бәлки соңга калып тугансыңдыр,—дип шаяртты ҮК кешесе һәм, аның жавабын да көтмичә, сүзен дәвам итте.—Бу идея минем башыма юкка гына килмәде, чөнки бу эшкә Сәлим белән без синең белән тигез пайда катнашырга телибез. Безнең акчалар да хәрәкәткә килсен. Мин эшнең практик ягын да уйлап куйдым инде: жиде ел мин прокурор булып эшләгән районны игътибар белән карап чык, телесә кайсы бинаны—ресторанмы, кафемы, ашханәме—сайла, алары ошамый икән, башкасына күз төшер, үзең исәпләгәнчә, өч-дүрт айда үзгәртеп корып, менә дигән ресторанга әйләндерерлек кенә булсын. Без аңа Лас-Вегастагага кебек "Лидо" исеме кушарбыз. Ул сүздә ниндидер яңгыравыклы тәм, шарм бар—"Ли-до"! Алга таба эшкә Сәлим белән мин кереп китәм. Мин район властьларын бинаны арендага бирергә мәжбүр итәрмен, бу нәрсә хөкүмәт карарларында да бар. Бинаны үзгәртеп кору өчен ташламалы кредитлар мәсьәләсе дә минем өстә. Әле бит мебель, савыт-саба, суыткычлар, бар сәүдә жиһазлары өчен дә кредитлар кирәк булачак, шунсыз беренче классны ресторан юк. Бинаны тиз, сыйфатлы итеп үзгәртеп кора алган подрядчиклар табам, ә менә проект өчен акча жәлләмәскә кирәк, кесәдән чыгарып түләргә дә талантлы архитекторларны чакырырга кирәк, андыйлар Ташкентта күп, безнең университетта архитектура факультеты бар бит.

—Архитекторлар табылыр,—дип бүлде ул аны, чөнки мәжлестәшенең идеясенә бәя биреп өлгергән иде инде.

—Ләкин моның белән генә безнең өлеш бетми әле. Район прокуроры булып эшләгәндә общепит белән якыннан торып шөгыльләнергә туры килде, бу эшнең нечкәлекләрен беләм, ә алар, барыннан да элек азык-төлеккә, спиртлы эчемлекләргә фондлар алуга кайтып кала. Монысын да үз өстебезгә алабыз. Иң мөһиме—без Сәлим белән "Лидо"ны каплыйбыз, беркем дә зур салымнар түләмәс. Ну... ничек, без компаньон була алабызмы?

—Тулысынча,—дип күңелле генә жаваплады Шубарин, район прокурорында мондый да каптыру-йоту сәләте барлыгын көтмәгән иде ул.

Шубарин бер минутка Сенатор турындагы уйларыннан арынып торды һәм иртәнге томанның эреп югалганын күрде, биек дувал артында утлар сүнде, инде бакчаның ерактагы аллеяләре дә ачык күренә, әле мөэзиннең намазга чакырып азан әйткәне ишетелмәсә дә, койма артында хәрәкәт башланганы сизелә иде. Шәрекъ кешеләре шулай иртә торучан ул.

Мәхәлләдә тавышлар ишәйгәннән-ишәя, әнә шәһәр яны кышлакларыннан сөт сатарга килгән хатын-кызларның бидоннары чылтый, чәйханә һәм базарга кабартма алып китүчеләрнең велосипед моторчыклары чырылдый, начар майланган капкалар шыгырдый, көн үз көченә керә бара.

Иртәнге аштан соң үзенең кабинетында чираттагы кәгазьләрне карап утырганда беренче тапкыр телефон шылтырады, "Лидо"дан Нәргиз икән.

—Артур Александрович, безгә ике-өч машина шампан алып килмәсәләр, берсекөнгә миндә берни калмый.

—Ак аракы, коньяк эчсеннәр,—дип шаяртмакчы булды ул.

—Грузиядән туристлар агыла. Хажга киләләрмени. Турлары бер атналык. Һәр группа өстәлне бер атнага, нәкъ жиде көнгә ала. Алардан соң килүчеләре Тбилисидән үк тагын берәр атнага заказ бирәләр. Барысы да шампан ярата, шулай булгач, коткарыгыз, "Лидо"ның маркасы өчен кызарырлык булмасын инде.

—Яхшы, Нәргиз, шампан булыр, хәл итәрбез, Ташкентта безнең "Лидо" ны яратканнар икән, исәнлекләренә эчсеннәр.

Моннан ике ел элек, ул Парижда чакта, Сухроб Ак йортка үрмәләгән, аның дусты Миршаб Югары судта дәрәҗәле кәнәфигә менеп утырган. Ул Франциядән кайткач Хашимов аларны сөяркәсе Нәргиз йортына чакырган, һәм алар шушы вакыйгаларны билгеләп үткәннәр иде. Йортның хуҗасы да, ул оештырган табын да Японга үтә яхшы тәэсир калдырды. Элек данлыклы бию ансамблендә эшләгән әлеге ханымда такт та, зәвык та җитәрлек иде, холкы яхшы, дөньяны аркылыга-буйга гизгән кеше. "Лидо" ны оештыру эшләре кызып киткәч, инде администраторлар сайлый башлагач, Артур Александрович аны искә төшерде. Һәм ул ялгышмады, Нәргиз эшлекле иде, барысын да тиз эләктерә торган булып чыкты, аны гомер буе ресторанда эшләгән дип уйларлык иде. Нәргиз официантларны үзе сайлап алды, болар элеккеге фольклор ансамбленең биючеләре иде, ә ирләрне Фәйзиев җыйды, чөнки ул Ташкенттагы адәм рәтле кафе-рестораннарны биш бармагы кебек белә һәм кемнең кем булуында ялгышмый. Нәргиз белән Икрам Мәхмүдович бер-берсен тулыландырып торалар, мондый җитәкчелекне тирә-юньдә табып та булмас.

Ниһаять, ак "Мерседес" хуҗасы үзенә ошаган урынны тапты, монда ул кемнендер өйрәтүеннән башка да йөзәчәк иде, чөнки "Лидо"да аның бар йомшак яклары—өстәлне сый-нигъмәт белән тутырып, мәҗлесләп утырулардан алып һәр гүзәл кызга, хатынга гашыйк була белүе дә ресторан файдасына гына иде.

Артур Александрович, кулына каләмен алып, тагы бер мәртәбә игътибар белән көндәлек эшләрен карап чыкты һәм шампан мәсьәләсен Госснабтагы утырышка кадәр үк, иртән иртүк җайга салырга икәнен аңлады. "Лидо"га шампан җибәреп торучы кеше пунктуаль-төгәл түгел, үз кесәсенә шактый тамып торуга да карамастан, берничә мәртәбә авыр хәлдә калдырды инде, бу аны шикләндерә төште һәм ул аның начальствосына ультиматум куярга булды: йә сез безгә икенче кешене куясыз, йә без килешүне өзәбез. Мондый килешүне өзү үкенечле булыр иде, чөнки ул һәр шешә шампанга "баш на баш" кыйммәтрәк торучы бер шешә "Столичная" биреп бара. Мондый килешүгә теләсә кайдан компаньон табып булыр иде. Ләкин ул үзенә товар бирүчеләрне алыштырырга яратмый, конкуренция—куркыныч нәрсә. Тагын бер уңай як та бар иде: ул шампан ала торган складлар Сенаторның элеккеге биләмәләрендә.

Бар нәрсәне исәпләргә яратучы Япон алыш-бирештә нишләп шундый юмартлык күрсәтте соң әле? Алкоголизмга каршы көрәш башланып, аракы заводларын җимерергә, башкача җиһазландырырга керешкән көннәрдә ул бик зур туйга эләкте һәм шунда аракы-ликер берләшмәсе директоры белән йөзгә-йөз очрашты. Нишләп кара болыттан да каралыбрак йөрисез диюгә, тегесе Шубаринга үзенең проблемалары турында тезеп китте. Әлбәттә, хәсрәтләнерсең, файдалы эш хуҗасы, һәркемгә кирәкле кеше, димәк, хөрмәтле түрә көннәрдән бер көнне аракы урынына компот чыгарып ятсын әле. Компот чыгару предприятиесен рәткә китерәсе бар, ә аның монтажниклары да, слесарьлары да юк, эш бар, анысы—"демонтировка". Моның өстенә, план төшергәннәр, алдагы кварталда зур гына күләмдә металлом, сүтелгән заводның тимерләрен тапшырасы. Хәсрәтләнерсең! Компот чыгару өчен алма, хөрмә, слива кирәк, алар җыелмаган, әле бит алып кайтасы, урнаштырасы, иң хәтәре—саклыйсы бар, чөнки җиләк-җимешнең тиз бозылуын кем дә белә. Аракы икенче эш! Черми, аны саклап торасы юк, кирәкле чималы да аяк астында аунап ята, рентабельлеге турында сөйләп тә торасы юк, бәясе югары. Шубаринның беренче уе металлом тапшыруда бәлагә эләккән бу кешене коткару иде, план үтәмәгән өчен баштан сыйпамыйлар. "Вторчермет" белән эшлекле, тыгыз элемтәләре күптәннән бар. Металлом тапшыру буенча алардан кәгазь алу авыр түгел, ләкин кинәт кенә анда эшкуар азарты кабынды һәм ул аракы заводының җиһазларын кулына төшерергә булды, соңыннан күз күрер. Директор әнә барысын да узган ел гына

янарттык дип тора! Менә шунда ул оста тылсымчыдай танышының йөзеннән кайгысын сыпырып кына төшерде, чөнки җиһазларыңны үзем сүтәм, металл тапшыру кәгазен алып килеп бирәм диде. Директор шатлыгыннан:

—Артур, моның өчен миннән күпме тиеш?—дип ычкындырды.

Шубарин да бер мизгелгә аптырап калды, ләкин үзен бик тиз кулга алды һәм елмаеп әйтте:

—Һы, туган көнгә бер ящик компот куярсың инде.—Һәм алар икесе дә канәгатьләнеп бер-берсенең кулларын кыстылар.

Лас-Вегастагы гигант рудокомбинатның промышленность мәйданнарында аракы заводы ясау зур мәшәкать түгел иде. "Актив күмергә якынрак булсын",—дип шаярткан иде шулчак Коста. Аракы заводларын ябып бетергәннән соң, бу эшнең осталары урамда калган иде. Шубарин андыйларны күрше республикадан табып кайтты, чөнки Чимкент аракысы һәм сырасы бөтен Урта Азиягә танылган иде. Шулай итеп, эчми һәм күп сөйләшми торган, өчесе дә Берг фамилиясе йөртүче өч немец элеккесеннән дә яхшырак сыйфатлы аракы куа башладылар. Сенаторның беренче классны ресторан турында идеясен тиз генә йотып җибәргәндә ул боларны да күздә тоткан иде. Шунлыктан ул күз дә йоммый аракыны шампанга "баш на баш" алыштыра. Лас-Вегас куәтләре бу чыгымны гына рәхәтләнеп күтәрә ала.

* * *

...Самолет Ташкентка өч сәгатькә соңга кала иде һәм Үзбәкстанга көтмәгәндә генә зур урынга җибәрелгән Хөршид Азизович Камалов, тәрәзә почмагына елышып, газета кисемтеләре тутырылган калын папкасын тартып чыгарды, ул аны ике көн генә элек СССР прокуратурасыннан алган иде. Аның вакыйгалар һәм проблемаларның үзегенә керәсе килә, ни генә димә, Үзбәкстан—аның туган җире. Кырык алты яшьтә кем дә үз тормышын кинәт кенә үзгәртми, Хөршид Камалов та үзгәрешләр булыр дип уйламый иде, барысы да, көтмәгәдә, ике атна эчендә хәл ителде дә куйды, юкса әле ун көн элек кенә Вашингтонда яши һәм эшли иде. Яна урынга билгеләүне ул төрлечә анализлап карады, әлбәттә, аның элек угрозыскта эшләве, кандидатлык диссертациясе, КГБ уку йортларында укытуы, Ташкентта һәм Мәскәүдә прокурор булып торуы—берсе дә аңа ниндидер өстенлек бирми иде, ә ана илдәге иң катлаулы республиканың прокуратурасын җитәкләргә тәкъдим ясадылар. Төбәкнең элекке җитәкчелеге баштанаяк диярлек җинаять җаваплылыгына тартылган. Ләкин Кремльдәге әңгәмә вакытында барысы да ачыкланды, аннан яшереп тормадылар, хәлләрне ачыктан-ачык әйттеләр, беренче кулга алулардан соң, урындагы тузлар берләшеп, крайны тәртип-җайга салуга бик нык каршылык күрсәтә башлаганнар. Менә шуңа мафиягә каршы көрәшү өчен органнарда эшләү тәҗрибәсе булу өстенә, шунда туып-үскән, төбәкнең гореф-гадәтләрен яхшы белгән һәм җирле халыкка таянырдай кеше кирәк икән.

Вакытның соң булуына карамастан, аны каршы алдылар. Кара "Волга" самолет трапы янына ук килеп туктады, аннан озын буйлы, мәгърур кыяфәтле ир кеше чыкты. Күрәсең, кыяфәтен тәфсилләп сурәтләгәннәрдер, чөнки Камаловны күрүгә ул, аны туган җиренә кайтуы белән котлады, үзе белән таныштырды:

—ҮКның административ органнар бүлеге мөдире Сухроб Әхмәдович Әкрәмхуҗаев.

Хөршид Камалов җанланып китте, сорап куйды:

—Әллә мәкаләләре "Правда Востока", "Совет Үзбәкстаны"нда басылган Әкрәмхуҗаевмы? "Хокукый дәүләт булырбызмы?", "Фемида үлчәве" кебек язмаларыгыз республикада зур яңгыраш тапкан кешеме?

—Рәхмәт. Минем эшләрем белән таныш булуыгызга мин бик шат, закон һәм хокукка карата минем фикерләрем сезгә билгеле, димәк,—дип кин елмаеп җавап бирде каршылаучы һәм кунакчыл хуҗа шикелле машинага

утырырга чакырды.—Баштарак ҮК кунакханәсендә яшәрсез, ул Анхор буенда гына. Яшеллеккә күмелгән, яхшы, төзек район. Илнең барлык якларыннан килгән тикшеренүчеләр бөтенесе шунда тора, сезгә алар белән тыгыз элемтәдә эшлисе булыр. Квартира эзли башладылар инде, якын арада берәрсен тәкъдим дә итәрләр, ләкин киңәшем бар, сез бөтенләйгә дип кайткансыз икән, ашыкмагыз, сайлагыз.

Начар яктыртылган урамнар буйлап кунакханәгә килеп житкәндә ул утларга чумган иде инде, гүя бәрхет—кара азиат төнен эретеп ташлаган, монда караңгы тәрәзә юк та иде бугай. Кунакның йөзендә гажәпләнү күреп озата килүче әйтте:

—Эш күп, бик күп, көн дәвамында эшләп бетерерлек кенә түгел, шуңа төнлә дә эшлиләр, кайберәүләр таңга кадәр утыра, сезне дә шул ритмдагы эш көтә.

Камаловны номер ишеге янына кадәр озаткач, ул саубуллашты:

—Бүген сезне арытып тормыйм инде. Кичке ашны оештырырлар, килгәнегезне беләләр. Ә иртәгә прокуратурада очрашырбыз. Мин сезне коллектив белән таныштырырмын һәм вазифаларыгызны үтәүгә керешерсез, эш муеннан.—Сенатор үзе хакында яхшы тәэсир калдырып хушлашты да китеп барды.

Беренче эш көне шундый да тыгыз иде ки, гәрчә моның туган-тумачага илтифатсызлык дип саналачагын яхшы аңласа да, хатынының әти-әнисенә, үзенең туганнарына шылтыратырга җай таба алмады. Телефон көне буе, туктаусыз шылтырап торды, бөтенләй көтелмәгән сораулар бирделәр, кеше ышанмаслык әллә нинди эшләргә катнашуны сорадылар, үтенделәр, күбрәк таләп иттеләр, ул инде тәҗрибәсе булуына карамастан, шаккатты, вакыт-вакыт аңа һәркайдагыча бер тиенгә ярамаслык юлларны төзәтүдән башлап, Урта Азия тимер юлы тупикларындагы вагоннарны бушатуга кадәр барысы белән дә прокуратура шөгыльләнергә тиеш сыман тоела башлады. Кичен кунакханәгә кайткач, ул, беренче эше итеп, үзенең яңа эшкә билгеләнүе, тиздән гаиләсенең торырга Ташкентка кайтачагы турында туганнарына хәбәр итәргә җыенган гына иде, ишекне дә ябып өлгермәде, телефон шылтырады. Башта ул миңа түгелдер, ялгышалардыр дип уйлаган иде, әмма аның бүлмәдә икәнлеген белгәндәй телефон өзлексез шылтырады. Камалов трубканы алырга мәҗбүр булды.

—Ярый әле өйдә туры китердем, юкса туганнарыгыз, дусларыгыз эләктерсә, ничек җай табарга белмәс идем,—диде трубкадан әле көндез генә аерылышкан Сухроб Әхмәдәвич тавышы.

—Миннән ни ярдәм кирәк иде?—диде Камалов, алдан ук аның кунакка чакыруыннан качарга теләп, ләкин ул ялгышкан булып чыкты.

—Иртәгә төштән соң без Беренче белән очрашырга тиеш идек, ләкин аны Мәскәүгә чакыралар. Ул анда өч көн булачак һәм аннан соң хөкүмәт делегациясе составында бер атнага Һиндстанга очачак. Егерме минут элек кенә ул мине чакырып алды һәм Мәскәүгә киткәнче сезнең белән танышырга һәм сөйләшергә теләвен әйтте. Бүгенге хәлдә, илнең бөтен игътибары Үзбәкстанга төбәлгәндә, прокуратурага ифрат зур җаваплылык йөкләнә, сезнең Мәскәүдән аерым вәкаләтләр белән килгәнегезне чамалый, күрәсең, аңа Кремльдән шылтыратканнардыр инде. Шуңа ул сезне кичке ашка чакырды, ул кунакханә белән рәттән генә тора, аның көненең һәр сәгате минутлап бүленгән, сезнең белән очрашу өчен башкача мөмкинлек күренми.

—Кичке ашта сез буласызмы?—дип тиз генә сорады прокурор, очрашуның берничә вариантын уйлап.

—Юк, мин андый зурлауга лаек булмадым әле, аның сезнең белән күзгә-күз сөйләшәсе килә, табигый, мин рәхәтләнеп сезнең компаниягә кергән булыр идем. Ярты сәгатьтән сезне алырга килерләр, мин сезгә хәерле кич телим.

Чакыруны кире кагу, житмәсә, ул эшлекле сөйләшү бит әле, мәгънәсезлек булыр иде һәм ул ризалашты. Трубканы куюга, тыныч кына уйлап куйды: менә шушы минуттан ул зур уенга керә һәм аның кагыйдәләрен тәгаен

чамаларга, өйрәнергә кирәк булачак! Кырык минуттан ул Рәшидовның дәвамчысы булган кешенең кунак бүлмәсендә утыра иде инде. Бер атна элек кенә Мәскәүдә республика прокуратурасын җитәкләргә тәкъдим иткәндә, озак кына әңгәмәдән соң, аны байтак еллар белгән кабинет хуҗасы хушлашканда әйткән иде:

—Алла Хакы өчен, гафу итегез, кич буе мине бер дилемма борчый: әйтергәме, юкмы? Хезмәтем буенча, законнан чыкмыйм дисәм, мин моны әйтергә тиеш тә түгелмендер. Минем урындагы кешегә алдан ук ниндидер нәтиҗә-йомгак чыгарып кую ялгышлык икәнен дә беләм, ләкин биографиягезне әйбәт белүче кеше буларак, кая барганыгызны аңлап, дәшми дә кала алмыйм, бәлки бу берәр ситуациядә сезнең тормышыгыз бәясенә торыр. Шушы көннәрдә мин үтә яшерен информация алдым, анда коррупциядә, өстәп язуларда, дәүләт властен үз мәнфәгатьләренә файдалануда Рәшидов дәвамчысының да кулы уйный дигәне дә бар. Аның дуслары һәм ул үзе сезнең һәр адымыгызны энә күзеннән үткәрәчәк, сезгә "туры" юл күрсәтергә тырышачак. Менә шуны әйтәсем килгән иде, сезгә чын күңелемнән уңышлар телим! Һәм менә ул хәзер шул кеше алдында утыра.

Тыштан караганда ул бик тә игелекле, ипле кыяфәтле иде, гүя киң күңелле профессор яисә мулла, манералары йомшак, күпмедер астыртын, тавышы тыныч һәм күңелгә ятышлы. Шәрекътә кыяфәт һәм сүзләр алдаучан, беренчесендә дә, икенчесендә дә ялгышырга ярамый. Йорт хуҗасының ягымлылыгыннан эреп китмәс өчен ул гел шуны исенә төшереп торды. Сонрак, сорау алу вакытында Акмал хан белән танышкач, Беренчедән алган тәэсиренең дөрес булганлыгына үзе дә шаккатыр әле ул. Һәркемгә кушамат тагарга яраткан Арипов Шәрәф Рәшидовның дәвамчысын Фәрештә дип атаган булган икән. Аксай ханының күзе үткен шул!

Алга таба Камаловка мондый сөйләшүләргә өйрәнергә, үзенә хас эслүбманера булдырырга туры киләчәк әле, чөнки Шәрекътә күп нәрсә ачыктаначык әйтелми, кайчагында иң мөһиме юллар арасына яшерелгән була. Ә хәзергә төп максат игътибарлы, җыенкы булу, мөмкин кадәр үзеңне җинел генә "укырга" ирек куймау. Шәрекътә еш кына "Кеше ачык китап ул",—диләр. Теләсә кем өчен ачык китап булырга ярамый.

Табын янына утырганчы, йорт хуҗасы аннан гаиләсе, балалары, Ташкенттагы туганнары турында сорашты, кайда яшәячәген белеште. Квартир мәсьәләсе хәл ителмәгәнен ишеткәч, иртәгә үк Эшләр идарәсе башлыгына әйтермен, ҮКның торак фондыннан, ә ул янәшә генә, махсус зонада, ордер бирергә кушармын, диде. Соңрак, аның бу игелеге сәбәпләрен анализлап, ул бернәрсәне аңлады: мондагы һәр адымы контрольгә алыначак, кайчан киткән, кайчан кайткан, янына кемнәр кергән—барысы да билгеле булачак. Бу бит сакчылар куелган махсус территория. Юк, фәрештәдәй йөзле, профессорга охшаган бу кеше гади-садә түгел, махсус вәкаләтләр белән килгән яңа прокурорны контрольдә тотарга кирәклеген ул яхшы аңлый. Кунак бүлмәсендәге әңгәмәдән соң залга күчтеләр, Мәскәүдә яшәп, ул күптәннән болай күпләп, тәмләп, озаклап ашауны оныткан иде инде, моңа да күнегергә кирәк булачак. Табынга алар икәү генә утырмады, кичке ашка өйдәгеләрнең барысы да җыелды, ләкин сүз җебе барыбер хуҗа кулында иде. Мәскәү турында да, Ташкент хакында да сөйләштеләр, озакламый ул барачак Һиндстан да игътибардан читтә калмады. Соңрак, сөйләшүне хәтереннән тагын бер кат үткәргәндә ул тотынырлык бер генә нәрсә дә таба алмады һәм үзен иплән кенә капшап караганнарын аңлады. Нинди кеше бу? Асылында ни бар? Өстәл янында үзен ничек тота? Прокурорны бер генә нәрсә тынычландырды: күңелгә ятышсызрак узган бу кичтә ул бу кеше турында юньләп берни белә алмаган кебек үк, үзе турында да ачык фикергә килерлек берни дә калдырмады. Әгәр спорттагыча бәяләсәң, ничья килеп чыга.

Соң гына кунакханәгә кайткач, ул яп-якты булып янучы тәрәзәләргә күз сала-сала күпмедер вакыт ишегалдында йөреп алды, шул чакта кинәт кенә анын баш миен бер уй кисеп үтте:

“Хәзер менә шушы якты тәрәзәләр артында кемдер эшләп утыра, бәлки ул Рәшидовның дәвамчысы булган кешенең серен беләдер инде һәм ул сернең бәясе—аның гомере икәнен дә аңлый торгандыр, ләкин ул барыбер туктап калмаячак, чөнки ул эзтабар—гаделлек сакчысы. Ул да алар белән бер сафта. Алар өчен бер генә Алла бар, ул—Закон”.

Гомерендә беренче тапкыр шундый югары рангтагы кеше белән очрашкан Хөршид Камалов менә хәзер генә, берүзе калгач кына, власть гипнозының ни икәнен аңлады, моннан ике көн элек кенә СССР прокуратурасында ясалган кисәтү, нишләптер, исенә төшмәде.

Хата һәм иллюзияләр монда миналанган кырдагы кебек сагалап кына тора, моны бер генә минутка да истән чыгарырга ярамый. Хаталар булырга тиеш түгел.

Камалов өчен барысы да бер-берсенә охшаган, эш белән күмелгән көннәр башланды, Сухроб Әхмәдович хаклы булып чыкты, кунакханә тәрәзәсендә ут таң атканчыга кадәр сүнми иде. Берәр айдан квартира тәкъдим иттеләр, ул аны ике атна буе барып карый алмады. Гаиләсенең күченеп килүе дә май бәйрәмнәренә кадәр сузылды. Әгәр туганнары якыннан булышмаса, аның нормаль тормышы кайчан башланачагы да билгесез иде. Шәрекъта туганнарга таянып яшиләр, монда үзеннекеләрне ярдәмнән ташламыйлар. Беренче көннән үк ул шундый тәгәрмәчкә эләкте ки, тын алырга да вакыт җитми иде.

Күп еллар буе кемнеңдер каты кулы прокуратураны тәртип салудан тотып-тыеп килгәнгәме, ул чын тәҗрибәгә ия түгел иде, реаль чынбарлыкка таянып эш итә белми, ә хәзер буа ерылгач, ул төрле якка ташланды һәм, беренче кат күргәндәй, тирә-юньне чолгап алган җинаятьчелеккә хәйран калды, үзе үк алып барган хисапсыз эшләреннән тончыга башлады. Хөршид Азизович прокуратура турында баштарак менә шундый уйларга килде.

Эшендә ул тагы бер үзенчәлеккә игътибар итте: бар буталчык, кайнар эшләр аның кул астына эләгә, тагы, күп кенә эшләргә ул “раслыйм” дигән имза салырга тиеш булса да, аларны укып чыгарга да вакыт табу мөмкинлеге юк иде. Кулга алу өчен бирелгән санкцияләрдә нигәдер гел дә аның исеме тора иде. Прокуратураның һәр ялгышына, һәр хатасына халыкның игътибары икеләтә арткан бу көннәрдә нинди дер документтагы бер “култамгасы”ның бик-бик кыйммәткә төшүе дә мөмкин. Ләкин кул куюлардан да читкә китә алмыйсың, имзадан башка ул документлар сукыр бер тиенгә дә тормый.

Бүгенге эшләр ерак үткәннәргә барып тоташа иде, ул аларга берничек тәэсир итә алмый, бер генә мөмкинлек кала, суд бу эшләрне кабат тикшерергә кире кайтарганда гына нәрсәдер эшләп буласы. Ә соңгы айда Югары судтан “кабат карарга” тамгасы белән кире кайткан эшләр агымын туктатырлык түгел, ул уылдык чәчәргә ашкынган балык өерен хәтерләтеп, прокуратурага килеп тыгылды. Судның кайбер нәтиҗәләре Камаловка беренче караштан ук нигезсез кебек тә тоела башлады. Югары суд соңгы карар кабул итүдән кача, “эшләр”не футбол тубы урынына һаман бер капкага—республика прокуратурасына юнәлтә торды. Кайчагында аңа кемдер аны вак процедур мәсьәләләрдә һәм иске эшләрдә батырырга, шулай итеп, кабинеттан борынын да күрсәтмәслек хәлгә җиткерергә тели, дәрәҗәле кешеләрнең җинаятьләрен яңа катламда күзәтып маташырга вакыты да теләге дә калмасын өчен тырыша кебек тоела башлый иде.

Берәр эш белән артыграк кызыксынучанлык күрсәтүгә, әфсен укып өргәндәгедәй, аның белән ул материал арасында кәгазь тавы барлыкка килә, прокуратура бинасында көненә ундүрт сәгатьтән дә ким эшләмәвенә, һәркөн кунакханәгә берничә папка кыстырып кайтуына карамастан, ул шул кәгазь өеменә кереп батканнан-бата иде. Шундый эшләрнең берсе Аксай ханыныкы иде. Аны бу эштән өч тапкыр “рәсми” аерырга маташып карадылар. Аның республикага булган тәэсире хакында легендалар Үзбәкстанда гына түгел, Мәскәүдә дә йөри, Камаловның бу фамилияне беренче ишетүе түгел, хәтта туганнары да аннан Акмал ханның хәлен сораша иде. Әллә бу юлы да кармактан ычкынырмы? Менә шушы эштән аны бик оста гына читләштермәкче булдылар.

Камалов моны да аңлый. Күрәсең, Акмал ханны кузгату кырмыска оясын туздыру белән бердер, күпләр моннан үзләрен шактый җайсыз хис итәчәк. Ул беркөнне хәтта Сухроб Әхмәдович белән дә кинәшеп карады: Рәшидовның Аксайдагы дусты-теләктәше белән ныклабрак шөгыльләнергә вакыт түгелме? Элегрәк бик күпләрнең югары күтәрелүе аннан торган бит.

Әкрәмхуҗаев "ә" дә димәде, "җә" дә димәде, бары арыган кыяфәт белән кая китсен ул ниндидер агропромышленность берләшмәсе директоры, чиратта өлкә һәм ҮК секретарьләре тора бит, диде. Бу сүзләре белән ул гүя төрттерел куйды: син әле ситуацияне өйрәнмәгән, җинаятьләрнең үсеш баскычын абайламыйсың. Гомумән алганда, Камалов аяклары тышауланган, күзе бәйләнгән ат хәлендә калган иде. Ул кая кушсалар, шунда гына бара ала. Ул, әлбәттә, үзенә стратегик мәсьәләләр белән шөгыльләнүче кыяфәте чыгарды, ә аны читкә тибәргән мәсьәләләр, әйтерсең, аның өчен вак, кызык түгел. Акмал хан материалларын иң мөһим эшләр буенча өлкән тикшерүче алып бара, прокурор аны Мәскәүдә эшләгән елларыннан ук белә иде. Ә эшне республика КГБсы башлап җибәргән һәм ул мәскәүлеләр белән бергә алып барыла.

Бер көнне иртән кулга алу буенча берничә санкциягә кул куйгач, ул Арипов эшен тикшерүчегә телефоннан шылтыратты да Дзержинскийга куелган тәэсирләндергеч һәйкәл янындагы бинага китте. Җәяүләп кенә өченче катка менеп барганда кемдер шатланып кычкырып җибәрде:

—Хөршид Азизович!

Камалов борылып карады һәм аксыл костюм кигән таза гына кешене күреп алды.

—Танымадыгызмыни?—диде ул аңа кулын сузып.

—Ничек танымыйм ди—Бәхтияр Саматов. Хәер, сезне тану җиңел түгел, ун ел узды бит инде, ныгыгансыз, остаргансыз, шомаргансыздыр инде, зур начальник булгансыз, сез бит элек укытучыларны тупикка кертергә ярата идегез.—Һәм алар икесе дә көлеп җибәрделәр, кочаклаштылар.

—Бер мин генә түгел, сезнең бик күп шәкертләрегез монда, төп эштә утыралар. Минем кабинет аста, керегез, сезгә теләсә кайчан булышырга әзербез, мин рәис урынбасарларының берсе булам.

Арипов эшен тикшерүче янында ул нәкъ бер сәгать булды, аннан соң икенче катка, үзен көткән бүлмәгә төште.

Генерал Бәхтияр Саматов белән төшкә кадәр сөйләшеп утырдылар, ләкин ни ул, ни генерал Мәскәүдә узган еллар турында искә төшермәде. Ә төшерердәй нәрсәләр күп иде, мәскәүле буларак, Камалов, һәрвакыт якташларын канат астына ала белә, кирәксә булыша, ярдәм итә иде.

Прокурор баштан ук эшлекле сөйләшүгә күчте:

—Минем модель буенча прокуратурада җинаятьчелеккә каршы көрәш буенча махсус бүлек булдырыла, мин кешеләр белән ярдәм итүегезне сорар идем. Техник хезмәткәрләр дә артык түгел, машинисткалар да кирәк. Документлар, архивлар канцеляриясендә мин тулысынча ышанган кешеләр генә эшләргә тиеш.

—Мин нәкъ менә кадрлар буенча җаваплы кеше,—дип җавап бирде генерал.—Бу мәсьәләне хәл ителгән дип санагыз.

—Шәрекъtә остазга каршы төшмиләр, әйеме?—дип шаяртты кунак.

—Сез бик тиз өйрәнәсез, домулла, сездә дә шәрекъ каны уйный башлаган,—дип, елмаеп җавап бирде кабинет хуҗасы һәм дәвам итте:—Бүген безнең дә күп нәрсәләргә күз ачылды, күпчелек профессионаллар илдә дәүләт куркынычсызлыгына янаучы реаль көчләр барын аңлый, җайлы ситуация туса, алар хәлне тотрыксызландыру өчен барысын да эшләячәк, җинаятьчел дөньяга таяначаклары да көн кебек ачык. Шуңа күрә без дә республикадагы җинаятьчел хәлнең ниндилеген белеп торырга тиешбез. Хәзер политик мотивка корылган авыр җинаятьләр бар, ә политиканнар уголовщина белән элемтәгә керүдән чирканмыйлар, алар уртак телне тиз табалар икән, димәк, безгә дә берләшебрәк эш итәргә кирәк.

—Тагы бер үтенеч, Бәхтияр Саматович, ул көчсезлектән түгел, ә вакытны

җәлләүдән. Мин һәрвакыт информациянең читкә агуын тоям. МВД хезмәткәрләре белән яисә партия органнары белән кинәшмәләрдән соң да шул ук хәл, ничә башлангычым шуның аркасында юкка чыкты. Бу күренеш белән көрәшүдә күпмедер тәҗрибәм бар-барын, теләсә кайсы операция алдыннан сатлыкларны каптырырлык капкын куя беләм, барыбер эзләренә төшәчәкмен. Тик шулай да, белсәгез иде, информацион ярыклар шулкадәр комачаулый, кулны тота һәм киң масштабта операцияләр алып барырга ирек бирми. Информация белән танышу мөмкинлеге булган кешеләрнең исемлеген төзеп, сызгалап куйдым инде мин. Аларның күбесе югарыдагы кешеләр, гадәти үлчәүләр белән килгәндә, Цезарь хатыны кебек, аларга шик төшмәскә тиеш, кайберләре, минемчә, җинаятьчел дөньяның элитасы белән бәйләнештә, болар: эшкуарлар, цеховиклар, яшерен икътисад миллионерлары... Уголовниклар күптән инде үз теләкләре белән аларга хезмәткә күчте. Логика буенча килсәк, дәүләт куркынычсызлыгы максатларын күздә тотып, югары урындагы кешеләрнең әлеге элемтәләре турындагы информация сездә булырга тиеш, анда минем күгәрченкәйләрем юкмы?

—Сез хаклы, бездә андый информация булырга тиеш ул, ләкин сез моңа кадәр Рәшидовның нинди чикләнмәгән власть белән файдаланганын күз алдына да китерә алмыйсыз. Үз вакытында минем өлкән коллегаларым аны МВДның югары чиннары арасында җинаятьчеләр белән элемтәләр барлыгы турында кисәтмәгәннәр дип беләсеңме, кисәткәннәр һәм катгый усал күрсәтмә алганнар—милициягә кагылмагыз, үз эшегез белән шөгыльләнегез! Озак еллар буе милицияне аның дусты һәм ышанычлы кешесе җитәкләгән бит. Сонрак ул дәүләт иминлеге комитетына да үз кешесен утыртты, без дә партия органнарына буйсынабыз, ул күрсәткән якка гына карарга мәҗбүр идек. Шунлыктан безнең уртак нәтиҗә ясаган, гомумиләштерелгән материалыбыз юк, хәлбуки, бу тема буенча сигналлар була торды, ләкин, кызганычка каршы, аларга юл бирелмәде.

Ул өстәл артыннан чыкты һәм элеккеге остазының уй-фикерләрен сизенгәндәй, бөтенләй көтелмәгән сүзләр әйтте:

—Акмал ханның архивын кулга төшерә алсак, безнең картотекадан да баерак нәрсә булмас иде!

Камаловның башында кинәт кенә яңа план туды, бу хакта ул бер сәгать элек кенә, өченче катта тикшерүчеләр янында утырганда әле уйлап та карамаган иде.

—Мин әле генә Аксай ханының эше белән җентекләп танышып чыктым һәм бернәрсәне аңлый алмыйм: нишләп ул һаман иректә? Аны җаваплылыкка тарту өчен материаллар хәттин ашкан, кулга алырга шушы минутта ук санкция бирә алам. Әгәр вакытны югалтсак, аның досьесы һәм акчалары җинаятьчел дөнья табышына әйләнмәгәе, аның байлыгы турында алар бездән ким белми. Шулай була калса, хәтта берләшеп тә, без ситуацияне үз кулыбызга ала алмаячакбыз.

Генерал, әйтәсе сүзләренең һәркайсын бизмәнгә салып үлчәргә җыенгандай, озак кына тәрәзә янында йөренеп алды.

—Бу безне дә бик борчый, аңа юл салырга тырышучылар хакында сигналлар җитәрлек. Байлыгы кайнар башлар кулына төшсә, бәла туасын көт тә тор. Әле ул байлыгын төяп юкка чыгарга да мөмкин бит. Ул иблистән дә хәйләкәррәк, шома кеше, һәркайда әшнәләре бар. Термез ягына күпер салырга маташуы, Әфганстанга юл эзләве турында да озын колаклар җиткерде. Хәзер анда сугыш бара, чыгып таярга берәр ярык тапмаслар дисеңме. Ләкин без аны депутат кагылгысызлыгыннан мәхрүм итүне берничек тә тизләтә алмыйбыз, Ташкентта да, Мәскәүдә югары түрәләр арасында да дуслары бар, яклаучылары күп. Прокуратураны әйдәкләп булмый, без аңа указ түгел... Әгәр без вакыйгаларны ашыктыра башласак, аны хәтта сезнең исемлектәге кешеләрдән берәрсенең кисәтеп куюы ихтимал.

—Беләсезме,—прокурор үз планын ачып салырга булды.—Бәлки миңа чамалап карарга кирәктер, җаваплылыкны үз өстемә алырга? Мин бит яңа кеше, вәкаләтләрем шактый, шундук артка типмәсләр. Тәҗрибәсезлегемә

сылтармын, ҮК рөхсәтеннән тыш өлкә комитеты секретарен кулга алмадым бит, ә гап-гади хуҗалыкчыны, диярмен.—Һәм алар, бер-берсенә хәйләкәр карап, елмаеп куйдылар, чөнки икесенең дә уйлары бертөрле иде.

—Ни әйтим,—диде кабинет хуҗасы,—без сезнең рангтагы кешегә каршы төшә алмыйбыз, ҮК ны искә алмасаң, бу тулысынча прокуратура компетенциясендә... Хәтта сезнең үтенеч буенча Акмал ханны кулга алуда катнашырга әзербез. Аның белән КГБ тикшерүчеләренең күптән шөгыльләнгәнен беләләр. Бөтен ваклыкларын искә алып операцияне әзерләү өчен ничә көн кирәк? "Маршал Гречко"ның кораллы кешеләре бар һәм Аксай җир асты коммуникацияләре белән телгәләнеп беткән. Аны бары тере килеш кенә кулга алырга кирәк, юкса беребезнең дә башы муенында калмаячак, чөнки безне халыкның сөекле депутатын үтерүдә гаепләячәкләр.

—Миңа ике көн кирәк,—диде Камалов.—Кырык сигез сәгатьтә без операциянең бар детальләрен эшләрбез, Ариповны тавышсыз гына һәм табигый ки, тере килеш кулга алырга тырышырбыз, ләкин бүген кич ярдәмгә бирергә уйлаган кешеләрең белән мин очрашырга тиешмен, аларны операция планына кертеп җибәрергә кирәк.

—Килештек. Бүген көн азагында ул кешеләр прокуратурада булыр, ә ике тәүлектән соң сезне операция планы белән көтәм.—Шулай сүз куешкач, алар саубуллаштылар.

Берничә көннән прокурор Наманганга очып килде, бу рәсми командировка иде. "Зур ау" дип аталган операциянең дүрт варианты эшләнде. Һәр вариантта төп роль Камалов өстендә, чөнки ул "Маршал Гречко"ны үзе кулга алырга тели иде. Арадашчы да табылды, обкомда эшләүче бу хезмәткәрнең Арипов тәлинкәсеннән ашаучы икәне билгеле иде инде. Аны серне ачмыйча гына кисәтеп куйдылар: республика прокуроры ашыгыч һәм яшерен рәвештә Акмал хан белән арадашчы йортында яисә Наманганның Аксай кешеләре тәкъдим иткән теләсә кайсы җирендә очрашырга тели, диделәр.

Югары дәрәҗәле арадашчы яшерен очрашуны гадәти хәл санап, бер дә аптырамыйча гына кабул итте, Мәскәү куйган яңа кешенең бу җирләрнең чын хуҗасы Акмал хан белән очрашуын, килешеп сөйләшүен ул табигый хәл исәпли иде булса кирәк. Чиновник шул көнне үк җавап та алып кайтты. Акмал хан очрашырга риза, ләкин үз биләмәләрендә, Аксайда гына... Хәер, монысына, ханлыктан читтә очрашырга ризалашасына исәп тотмаганнар да иде. Әмма үз биләмәсендә булачак очрашуга да Акмал хан үз кагыйдәләрен куйган булып чыкты: арадашчыдан башка прокурор янында бүтән беркем дә булырга тиеш түгел, килү бары тик аның машинасында, бернинди эскортфәлән кирәкми. Шартлар кабул ителде һәм иртәгә төн уртасыннан соң арадашчы йорты янына Акмал хан машинасы киләчәк, ә алар өлкә прокуроры янында кунакта булганнан соң туры шунда, машина янына чыгачак, дип килештеләр. Ташкенттан килгән дәрәҗәле кунакны дастархансыз гына озатып булмый ич. Барысы да иске, торгынлык заманының күнелле йолаларын истә тотып башкарылачак иде. Черки дә борынын тыга алмас! Өлкә прокуроры йортында ни хакында сүз барганын хан һәр ярты сәгать саен белеп торачак иде. Монысын да онытмадылар.

Аксайда яшерен очрашу өч бинада: хуҗа резиденциясендә, кунак йортында яисә таудагы аучылар йортында булырга мөмкин иде. Очрашуның дәрәҗәсен искә алсаң, иң кулай урын таулардагы йорт иде, әлбәттә, ләкин бу вариант батып бетмәс, чөнки анда бару өчен вакыт күп кирәк. Димәк, ике бина кала, мантыйк буенча, алма бакчасындагы кунак йорты очрашу өчен иң кулае иде, чөнки сөйләшү яшерен һәм шунлыктан Камалов үзе үк резиденциядә очрашуга каршы килергә тиеш була.

Операциянең төп вариантында каралганча, Акмал ханны кунак йортында кулга алырга булдылар. Барысын да соңгы бөртегенә кадәр исәпкә алдылар, йортның урыны җайлы, кайбер хәлләр дә алар файдасына эшли иде. Йорт хезмәтчеләре арасында чекистлар ягына авышкан, элек әфган сугышында катнашкан кеше дә бар икән. Бу егет сауна белән бассейнга җаваплы булып,

эшен шулкадәр яхшы башкара икән, Акмал хан аны бик югары бәяли һәм Аксайдан читкә чыкканда һәрвакыт шәхси сагына ала, ди. Ләкин төп таяныч элеккеге десантник түгел иде. Алма бакчасы белән янәшә зур булмаган консерв заводы төзелеп ята, анда күтәрү краны килгәнен генә көтәләр, якында гына төзүчеләрнең вагоннары урнашкан. Йөз тонналы кранны һәм аның юлларын гадәттә егерме слесарь монтажлый. Камалов бу бригадага үз кешеләрен билгеләтте, башняның кәүсәсенә исә корал тутырдылар, анда хәтта пулеметка кадәр бар иде. Кунак йортына һөҗүм була калса, аның юлын кисү шуларга йөкләнде. Оперативниклар башняга корал тутырганда, аны "Троя аты" дип шаярттылар. Сугыш припаслары, бронежилетлар, башка кирәк-яраклар, җиңел дюраль баскычлар...—барысы да яшен тизлегендә узарга тиеш операция өчен кирәкле иде. Көннең икенче яртысында "Ураган" хәрби "тягач"лары сөйрәгән ике куәтле трейлердан, өч авыр автокраннан, автоном эшләүче электр станциясеннән, техник ярдәм һәм көнкүреш машиналарыннан торган кәрван артык игътибар җәлеп итми генә Аксай җиренә килеп керде. Төнгә кадәр "төзүчеләр" йөк бушаттылар, урнаштылар. Камалов өлкә прокуроры өеннән чыкканда, ул "монтажчылар"ның тулы әзерлектә икәнен белә иде. Җенле Акмал хан казыткан җир асты юлларын да онытмадылар, "әфган" ярдәмендә аларның икесен—елга ярына һәм тауларга чыга торганын табарга мөмкинлек туган иде, аларны да күзәтү астына алдылар. Караңгы төшкәч, төзү техникасы һәм җиһазлары рәвешенә кертеп яшерелгән алты бронетранспортерны төягән ике трейлер да Аксай ягына чыгып китте. Бронежилет кигән десантниклар барысы да әфган сугышын узган тәҗрибәле сугышчылар иде. Камалов аларны Аксайга килеп җитәр алдыннан узып китте. Хәрбиләр билгеләнгән һәр плацдармга вакытында барып җитәчәкләр иде. Арадашчының туктаусыз сөйләнеп баруы аңа хәрби вертолетларның тавышын ишетергә мөмкинлек бирмәде, алар да Аксайдан ерак булмаган позициядә урнашырга тиешләр. Һавага җибәрелгән өч кызыл ракета десантниклар өчен тревога дигәнне аңлата, алар шунда ук "монтажниклар"га ярдәмгә ташланачак. Икенче бер геликоптер аерым сигнал—ике яшел ракета очыртканны көтә, операция уңышлы чыкса, ул Акмал ханны тиз генә Аксайдан алып та китәчәк иде.

Арадашчы ике тапкыр Исмәт дип эндәшкән алтын тешле шофер юл буе сүзсез барды, сорауларга кыска-кыска җавап бирде, гомумән, ул сөйләшүдә катнашырга теләми, ә прокурор акрынлап, сакланып кына аны да әңгәмәгә тартырга һәм, шулай итеп, аудиенциянең кайда булачагын ачыкларга тели иде. Унбиш-егерме минут кына алдан белү дә операциянең уңышында хәлиткеч роль уйнаячак, чөнки төп вариантны эшкә җигәргә мөмкинлек туа, резерв көчләрне кая куясы ачыклана. Наманган юлында чакта ук очрашуның кунак йортында булачагы ачыкланса, Камалов бу турыда хәбәр итәргә өлгерә иде әле. Чөнки Аксайга керү-чыгуда тәртип каты, машина йөртүчеләр аны махсус журналда билгеләп баралар. Бу Акмал хан утырган машинага гына кагылмый. Шулай булгач, Исмәт, теләсә кайсы очракта да шлагбаум янында туктарга, каравыл йортына кереп чыгарга тиеш. Исмәт каравыл йортына йөгерүгә Камалов машинадан чыга, менә шушы гапгади хәрәкәт очрашуның кунак йортында буласын аңлатачак иде.

Теләгенә берничек тә ирешә алмаячагын аңлагач, ул ачыктан-ачык ялганларга кереште, обком түрәсенә карап яшерен үкенеч барлыгын әйтеп ташлады:

—Акмал әкәнең гаҗәеп саунасы белән бассейны бар икән, диләр, рәхәтләнеп бер тирләп утырырга, чумып чыгарга иде. Ташкентта андый мөмкинлек бик юк, шуның өстенә вакыт җиткерә алмыйм...

—Мин дә сезнең фикерне хуплыйм, шуның өстенә, ул сезне, алдан сөйләшенгәнчә, кунак йортында кабул итәчәк, сауна белән бассейн да шунда. Хуҗага әйтербез, кире какмас, дип уйлыйм. Ул үзе дә төнлә су коенырга ярата, бигрәк тә гүзәл затлар белән...—Обком кешесе чын күңелдән, көкләрне күкрәтеп көлеп җибәрде.

Шунда көтмәгәндә генә Исмәт сүзгә кушылды:

—Сорап торасы да юк, мин Аксайдан киткәндә, “әфган” бассейндагы суны алыштыра иде инде, саунага ул чех сырасы да кертеп куйды.

—Менә рәхмәт! Шәп бит ә!—диде сөенеп прокурор һәм шоферның җилкәсенә сугып алды.—Яхшы хәбәрең өчен миннән сиңа тиеш.

Машина каравыл йорты янына килеп туктаган иде инде. Шоферга ияреп Камалов та машинадан чыкты.

Шлагбаум янында аларны көтүче кеше, Камаловны күрүгә, сөйләшү аппаратына ярымпышылдап бер генә сүз әйтте: “Кунак йорты”.

Дәрәҗәле кунакны хөрмәт йөзеннән Акмал хан капка янына ук чыгып үзе каршы алды. Ни дисәң дә, Камалов республика прокуроры, ул Ташкентка дусты Шурикның мирасын барларга-ачыкларга килгән кеше. Ул килер алдыннан гына алар Сабир-баба белән озак кына киңәшкәннәр һәм Камаловны Ташкентка Мәскәүдәге дусларыннан берәрсе юллагандыр дигән фикергә килгәннәр иде. Йа Алла, ниһаять, “Ак башкала”дан да ярдәм кулы суздылар. Мәскәүдәге дуслары гади кешеләр түгел, аларга аны суд хөкеменә тапшырудан ни мәгънә. Акмал әкә республика прокуроры белән очрашуны бик дулкынланып көтте. Камаловның кечкенә генә хезмәтен дә алар миллион сумга бәяләделәр һәм “юмарт бүләк” салынган дипломатны алдан ук әзерләп куйдылар.

Кунак йортында хезмәтчеләр күренми, пыяла галереягә кергәндә генә каршыларына чәчен кырдырган, шәрекъчә асылынкы мыеклы, сөйкемле-матур егет очрады. Ерактан ук аларны күрүгә, дәрәҗәле кешеләргә күз сирпергә дә читенсенеп, ул стенага сеңде һәм уң кулын йөрәк турысына куйды. Бу хәрәкәт Камалов игътибарыннан читтә калмады. Аз генә тырпайган бармаклар борчылыр урын юк, мин беренче адымны ясарга әзер дигәнне аңлата иде. Димәк, чиктән тыш шикләнүчән Акмал ханның уяулыгын баштан ук томалый алганнар дигән сүз иде бу.

Галерея буйлап барганда арадашчыны капка төбендә үк ап-ак киемле ниндидер арык карт тоткарлап калды һәм алар каршыдагы зур булмаган бинага кереп киттеләр, күрәсең, обком кешесе күзгә-күз сөйләшү тәмамлангач, табын янында гына аларга кушылыр.

Акмал хан дәрәҗәле кунакны кайчандыр Сенаторны сыйлаган кызыл байраклы залга алып керде. Монда да тактик алым кулланылды, Мәскәүдә яшәгән Камаловның агропромышленность берләшмәсенең уңышлары турында ишетүе икеле, үзәк матбугатта басылып чыккан мактаулы мәкаләләрне укымаска да мөмкин, монда исә бар уңышларны җыеп, туплап була. Залга кергән һәркемне алтын белән чигелгән саллы-авыр байраклар хәйран калдыра иде. Акмал хан моны яхшы белә. Прокурор да шаккатты һәм байраклар сөяп куелган стена буйлап китте. Очрашуның башы Акмал ханны сөендерде, чөнки прокуратура кешесенең гаҗәпләнүен сизеп алган иде. Ә предприятие уңышларын Акмал хан барысын да үзенеке дип саный иде.

—Рәхим итегез!—Хуҗа ым белән кунакны тыйнак кына итеп җиләк-җимеш тезелгән, ике кешегә чәй эчү савытлары куелган дастархан янына чакырды. Йорттагы тынлык әңгәмә корып җибәрергә чакырып тора кебек.

“Синең белән чәйләп утырырга вакыт юк, хризантемаларың шиндә инде”,—дип, эчтән генә көлемсерәде прокурор Камалов һәм Акмал хан ишеккә арты белән утырырлык итеп, стена янындагы курпачка сөялде. Коридор бушап калуга, ягъни бер ун-унбиш минуттан “әфган” килеп керергә тиеш иде. Аны баштан ук Акмал ханның күрмәве хәерле. Йорт хуҗасы чәй салып, һәрвакыттагыча үз-үзенә нык ышанган хәлдә сүз башлады, Мәскәү хәлләрен сорашты, ул чәчләре агара башлаган бу прокурорның дусларыннан килгәнме-юкмы икәнлеген, “ак башкала”дагы якыннары ярдәм кулы сузамы икәнен тизрәк ачыкларга тырыша иде. Акмал хан мәҗлес дипломатиясендә шомарган булса да, каушауданмы, әллә артык дулкынланудан, ашыгуданмы, беренче сүзләрендә үк ялгыш адым ясады, ике Гертруда иясенең яшерен өмете шунда ук ачылды да. Аның игътибарын читкә юнәлтү өчен җайлы булды бу. Һәм Камалов иплэп кенә сүзне Мәскәүдә Арипов таяна алырдай кешеләр ягына борды, Акмал ханның йөзе шунда ук яктырып китте.

Акмал ханның җаны ахыргача тынычланып беткәч, Мәскәү прокуроры алдагы күңелсезлекләрдән коткаручы икән дигән фикер тугач кына, бүлмәгә йомшак кроссовкалары белән бер тавыш та чыгармый "әфган" килеп керде.

—Гафу итегез,—диде ул йорт хуҗасының артына баскан хәлдә кунакка карап.—Исмәт сезне сауна ярата, диде. Ачыклыйсым килә, сезгә нинди температура кирәк?

Башка вакыт булса мөһим әңгәмәне бүлгән егеткә Акмал хан бер генә кычкырыр иде, ләкин хәзер борылып карады һәм яраткан хезмәтчесен хуплагандай елмаеп кына куйды. Ә егет кинәт кенә аңа таба иелде һәм иягенә кыска-тиз итеп сугып куйды. Камалов күз йомарга да өлгермәде, "әфган" һушын югалткан Акмал ханның авызына алдан ук әзерләп куелган чүпрәкне тыгып ята иде. Прокурор сикереп торды, кулына пистолетын тотып, ишеккә ташланды, коридорда беркем юк иде. Алар икәүләп таза-юан Аксай Крезын кызыл байраклы залдан өстерәп алып чыгып киттеләр. Берничә адым атлауга, "әфган" келәм түшәлгән коридордагы икенче бер ишекне ачып җибәрде, бүлмәнең тәрәзәләре бакчага чыга икән. Бүлмәдәге тәрәзәләр каерып ачылган, ә аста аларны алыптай дүрт "монтажник" көтә иде инде. Алар авызына чүпрәк тыгылган кешене җиңел генә эләктереп алдылар да бакча буйлап тәзүчеләрнең вагоннарына таба чаптылар. Анда тиздән вертолет төшәргә тиеш иде.

Камалов "әфган"ның аркасына җиңелчә генә төртеп куйды:

—Син дә, егет, вертолетка йөгер, сиңа Аксайда калырга ярамый, ә анда берәр нәрсә уйлашырбыз, синең катнашуыңны болай беркем дә күрмәде.—Һәм кырган башлы, җиңел сөякле егет десантниклар артыннан чабып китте.

Яктыртылган аллеядан бакча эченә борылган "әфган" кинәт кенә кычкырып куйды да егылды. Аның артыннан йөгерүче Камалов, табигый ки, үз артыннан очып килгән пычакны да, ниндидер ак киемле күләгәнең караңгылыкка кереп югалганын да күрә алмаган иде. Прокурор егет өстенә иелде, пычак егетнең йөрәген тишеп чыккан, аның очы күкрәгеннән чыгып тора иде. Пычакны атучы, һичшиксез, бу эшнең остасы булырга тиеш. Алма бакчасы коймасы яныннан кыска көпшәле автоматлар тоткан десантниклар йөгерә, һавада вертолет тавышы, йокыдагы Аксайга бәреп кергән бронетранспортерлар гөрелди. Камалов "әфган"ны каяндыр табылган носилкага салды һәм бер десантчы белән аны кранга таба алып китте. Калганнары егеткә пычак аткан кешене эзләп киттеләр. Ләкин буш йортта, иң почмактагы бер бүлмәсендә намаз укып утыручы ак киемле арык карттан, обком таныклыгы күрсәткән куркынган адәмнән гайре бер кеше дә юк иде. Ак киемлегә кемнәрнендер "әфган"ны явызларча үтерүләре турында әйткәч, тегесе кулларын намаз укырга әзерләгәндәй итте дә җавап бирде:

—Ул минем туганымның улы иде, эшкә алырга мин тәкъдим иткән идем,—диде. Карттан башка берни турында да сорамадылар. Сабир-баба бик яраткан туганының ханны сатуын гафу итә алмады.

Операция башланып егерме минут узуга, бортында Акмал хан да булган вертолет күккә ыргылды.

Ул күздән югалуга, алма бакчасыннан ерак булмаган тауда өч шартлау тавышы ишетелде, прокурор Камаловка тагын берничә сәгатькә Аксайда тоткарланырга туры килде. Хәер, ул моның ни икәнен ачык аңлаган иде инде, Акмал ханның генерал Саматов кулга төшерергә теләгән данлыклы досьеларын шартлаттылар. Салкын канлы Сабир-бабага яраткан пләмәшенең үлеме дә төп архивларны юкка чыгаруда комачауламады, бу хакта алар Арипов белән күптән сөйләшеп-килешеп куйганнар иде. Вертолет күккә күтәрелүгә яңгыраган шартлау тавышлары белән рухи остаз Акмал ханга архивларын юкка чыкты, үзенне яклау өчен теләсә нинди тактиканы сайлый аласың дигәнен белдерә, партия һәм хуҗалык элитасының бар серләре хәзер синең хәтереңдә генә.

Ташкентка кайткач, Камалов бары ярты сәгатькә генә өенә кереп чыкты, киемнәрен алыштырды һәм партия Үзәк Комитетына китте. Башта ул икенче катка, Сенатор янына күтәрелде, ләкин туры китерә алмады,

секретарь кыз аның Беренче янында икәнлеген генә әйтте. “Яхшы булды әле бу, ике тапкыр доклад ясап торасы юк”,—дип уйлады ул һәм җәяүләп кенә бишенче катка күтәрелде. Кабул итү бүлмәсендә күренүгә үк ярдәмче Беренчегә хәбәр салырга кереп тә китте, озакламый аны киң һәм иркен кабинетка чакырдылар. Сенатор чыннан да анда иде, алдындагы ике калын папкага карасаң, шактый утырганын чамалап була иде. Беренче өстәл артыннан чыкты һәм елмаеп каршы атлады, прокурор аларның икесенең дә әле Аксай ханын кулга алу хакында белмәүләрен аңлап алды.

Традицион сәламләүләрдән соң Беренче аңа игътибар белән күз төшерде һәм хәленә кергәндәй итеп әйтеп куйды:

—Кыяфәтегез бик үк шәптән түгел, төне буе бандитлар аулап йөргән кешегә охшап калгансыз. Миңа әле генә әйттеләр, сездә оешкан җинаятьчелек белән көрәш бүлеге бар икән, алар йөрсен, ә сез көрәш стратегиясен эшләгез, тактика булдырыгыз, гомуми җитәкчелекне алып барыгыз.

Өстәлгә таба атлаган җиреннән Камалов кинәт кенә туктап калды һәм Беренченең күзенә туп-туры карап әйтте:

—Ә сез күрәзәче икәнсез, чыннан да, мин бүген төне буе ауда булдым, ләкин бандит дигәнебез берәү генә иде, әмма шунысы бар, ул үзе генә дә йөзләрчә җинаятьчегә тора.

—Ау уңышлы булдымы соң?—дип, кызыксынып сорады Беренче.—Мәскәүдән аерым вәкаләтләр биреп җибәрелгән кеше ауларлык төп бандит кем була инде?

—Мин Акмал Ариповны, Шәрәф Рәшидовичның элеккеге ышанычлы кешесен кулга алдым.

—Хезмәт Героен, Югары Совет депутатын, Үзәк Комитет әгъзасын, Дәүләт премиясе лауреатын, күренекле җитәкче-хуҗаны кулга алдым димәкче буласызмы?—дип сорады Беренче гаять тә битараф һәм тыныч тавыш белән, аның ни уйлаганын, кай якка борганын аңларлык түгел иде.

—Мин яңа кеше бит, гап-гади хуҗалыкчыда шундый мактаулы исемнәр барлыгын каян белим... Ләкин аңа бар бүләкләреннән, титулларыннан, мактаулы исемнәреннән колак кагарга туры килмәгәе...

Кабинет хуҗасының керфеге дә селкенмәде, ачыктан-ачык битараф кыяфәт белән аны бүлдерде:

—Кулга алгансыз икән, яхшы булган, сез яхшырак беләсез, без хокук саклау органнары эшенә таяк тыгарга теләмибез, шулай бит, Сухроб Әхмәдович?

Сенатор үзен ничек тотарга белмичә, аягүрә басты һәм Беренчегә мөрәҗәгать итте:

—Сез рөхсәт итсәгез мин прокурорны үзем белән алып китәм, кулга алу материалларын карап чыккач сезгә житкерермен.

Алар тәрәзәләреннән Гагарин исемендәге скверның матур бер почмагы күренеп торган кабинеттан чыгып киттеләр. Табигый калкулыкта беренче космонавтка куелган мәһабәт һәйкәл, көмеш тамчылар сибеп утыручы фонтаннар урамга кабатланмас ямь өсти иде. Янәшәдә генә Шәрәф Рәшидович йөрергә яраткан “Пахтакор” стадионы җәелеп ята.

Бишенче каттан җәяүләп кенә төштеләр. Келәм җәелгән мәрмәр басмалардан сүзсез генә атлаганда, икесе арасында ниндидер күзгә күренмәс киеренкелек пәйда булганын прокурор аркасы белән диярлек сизде. Мантыйк буенча уйласаң, Әкрәмхуҗаев шатланырга тиеш иде кебек, әмма аның йөзендә сөенүнең әсәре дә юк иде. Киресенчә, көенүгә охшаш нәрсә чалымлана, хәтта Беренче дә “завотдел”нын үз-үзен тотышыннан канәгать калмады кебек. Камалов боларны сизмәде түгел, сизде, аның үткен күзеннән берсе дә читтә калмады. Әнә республика хуҗасы үзен тота алды, ул да Аксай ханның кулга алынуы никадәр куркыныч тудырганын аңлый, кем белә, үзен яклап калмаган өчен Арипов бар карталарны

өстәлгә чыгарып салса, нишләрсең... Ул барысын да үз артыннан ияртергә сәләтле. Акмал хан аларны да батыра ала. Арипов үлеп калган булса Ак йорт хуҗасына яхшырак булыр иде, ә Сухроб Әхмәдович нигә борчыла, нигә йөзе караңгы соң әле? Кабинетка барып җиткәнче Камалов шуларны уйлап өлгерде.

Кабинетка кереп тә җитмәделәр, аның хуҗасы папкаларны өстәлгә ыргытты һәм ризасызлыгын яшереп тә тормыйча әйтеп салды:

—Хөршид Азизович, сез нишләп болай эшлисез?

Камалов, аның тавышындагы усаллыкны сизмәгәндәй, ашыкмыйча гына урындыкка утырды һәм тыныч тавыш белән сорады:

—Мин сезне аңламыйм, сез нәрсә турында әйтәсез?

—Республикада иң абруйлы, мөхтәрәм бер затны кулга алу турында әйтәм. Аны җинаять җаваплылыгына тарту безнең эш түгел, бишенче каттагыларның да кулы җитми ана. Арипов белән Мәскәү үзе шөгыльләнә.—Һәм ул күп мәгънәле итеп имән бармагын өскә күтәрде, ләкин бу ишарә шактый көлке килеп чыкты.

—Ә сезнең хокук турында мәкаләләрегез, хөрмәтле фәннәр докторы, законнарның идеологиядән өстенлеге, телефон хокукы һәм башка номенклатур шырдый-бырдый турында сез язмадыгызмы? Сез бит шул тәҗрибәне тар-мар итеп чыккан кеше!—Камалов кабинет хуҗасын юри кыздырырга тырышты, аның республикадагы бу популяр юристны аңлап бетерәсе килә иде.

—Ах! Ташлагыз әле,—диде тегесе гасабиланып.—Теория бер нәрсә, практикада бөтенләй башкача. Сезгә аңлатып торыргамы, генерал погоннарына ирешү җиңел булмагандыр.

—Әйе, җиңел генә түгел...—дип уйланып җавап бирде Камалов һәм шуның белән әңгәмәдәшен ялгыш юлга кертеп җибәрде.—Хәер...—дип дәвам итте ул, шактый озак сүзсез торганнан соң.—Миңа калса, Беренче минем ул гамәлемне хуплады, ул, күрәсең, Ариповның иректә калуы нинди зыян саласын чамалыйдыр. Шуның өстенә, хәтерлисезме, ул, Үзәк Комитет хокук саклау органнары эшенә катнашмый, диде. Ә сез нигә борчыласыз әле? Бу бит сезнең белән безнең компетенциядә, мин сезгә шундый документлар күрсәтермен, минем үзешчәнлеккә карата бар шикләрегез, борчуларыгыз югалыр.—Эш өчен җанын да җәлләмәүче беркатлы кеше шикелле сөйләнеп, Камалов ачыктан-ачык ялганлый иде.

Шеф озаклап һәм ачылып көлде, ул, чыннан да, Камалов әйткәннәргә ышанган иде.

—Әйе, мин сезне мондый наив кеше дип уйламаган идем, хәер, Мәскәү бер нәрсә, Шәрекъ—бөтенләй икенче. Беренче сез кылган гамәлдән разый дип, соклана дип уйлыйсызмы? Шуңа ышандыгызмы?

—Әлбәттә, ул бит җитди бер нәрсә дә әйтмәде, хәтерлисездер, "кулга алгансыз икән, алгансыз", диде. Ниндидер совхоз директорының эшләренә тыкшынып йөрмәс инде,—дип, һаман үзенекен сукалады прокурор.

—Ә хәзер Арипов кайда?—дип, каударланып сорады Әкрәмхуҗаев, күрәсең, анда ситуацияне кинәт кенә үзгәртерлек ниндидер план туып өлгергән иде.

Камалов, сәгатенә карап, әйтте:

—Хәзер ул, минемчә, Мәскәүгә җитеп килә, ә ике сәгатьтән КГБның тикшерү изоляторында булыр...

Менә шунда Сенатор сынатты, йөзе күзгә күренеп агарынды, бер мизгел эчендә түрәлек мин-минлеге югалды, күрәсең, аяклары тотмый башлагандыр, ул кәнәфигә сенде һәм арыган кыяфәттә сүзен тәмамлады:

—Сезнең белән безгә күңелсез булмас, хет Беренчегә аның белән сөйләшү мөмкинлеген бирәсе иде... Хәер, бәлки сез хаклыдыр, хәзер нәрсәгә кирәк ул очрашу...—Ниһаять, ул үзен кулга алды, өстәл артыннан торып, ихлас күренергә тырышып сөйли башлады:—Гафу итегез! Бездә

андый капылт гамәлләр сирәк була, хисләремне тыеп кала алмадым. Тотанаксызлыгым өчен гафу итегез. Чын күнелдән котлыйм, тормышыгызны куркыныч астына куйганыгызны яхшы анлыйм, җаваплылыгы гына да ни тора.—Һәм ул сөйләшүне тәмамланган санап, Камаловка кулын сузды.

Ак йортта Акмал ханны кулга алуын белдергәннән соң үткән бер сәгать эчендә Камалов әйтерсең лә янадан туды, башында кайнаган уйлар өермәсе бер эзгә төшә башлады сыман. Әнә шулар киләчәктә анын Сенаторга мөнәсәбәтләрендә төп урынны тотачак иде. Прокурорны Беренченең Ариповны кулга алу турындагы хәбәрне кабул итүе аптыраштa калдырды. Тыштан битарафлык күрсәтеп ул нинди тактика кора? Бәлки хәзер, Арипов Мәскәүгә якынлашып килә дигәнне ишеткәч, республика хуҗасының реакциясе үзгәргәндер? Уйландырган икенче нәрсә дә бар иде. Ариповны кулга алуга ҮКның административ бүлек мөдире нигә шулай бик тискәре мөнәсәбәт белдерде? Ирексәге Акмал ханның куркыныч кеше икәнен белмимени ул? Аны кулга алуны нигә ул йөрәге белән авыр кабул итте? Анын нервлануы һәм агарып китүе астында ни ята? Тоткынны Мәскәүгә җибәрдек дигәч, ник шулай кәефсезләнде ул? Беренченең Арипов белән очрашуы ни бирер дә, ни китерер иде? Бу сорауларның берсенә дә ул адәм рәтле җавап тапмады—берсе дә ул билгән түрә урынына, юридик яктан дөньяны күзаллауга, ул бастырган мәкаләләргә туры килми иде.

Прокурор тагы анын мәкаләләрен искә төшерде, алар шәп иде, аларның кайберләрен ул ике-өч мәртәбә укыды, алар оригиналь, фикерләре кыю, яна, юридик яктан тел-теш тидерерлек түгел иде. Һәм кинәт: “Теория—бер нәрсә, практика—икенче”, бу сүзләр язмалар авторы авызыннан ишетелдеме соң? Кайчандыр бәгыреннән өзелеп төшкән фикерләре шартлауга, янартау атылуга тиң иде бит! Андый әйберләрне тун йөрәкле кеше яза алмый, анын өчен якты акылга ия булу кирәк, шунын өстенә, аналитик фикерләү сәләте булу мәҗбүри. Бергә эшләү дәверендә ул ҮКның бүлек мөдире авызыннан теге язмаларда очраган бер генә җөмлә дә ишетмәде. Гүя Әкрәмхуҗаевны алыштырып куйганнар иде. Шундый көтелмәгән әверелеш нәрсә анлата? Тагы... “Генерал погонын алу җинел булмагандыр...” дигән сүзләре колакны ярып үтте. Элек мондый сүзләр өчен янакка менеп төшәрләр яисә дуэльгә чакырырлар иде. Анын черек фәлсәфәсе закон һәм хокукны яклап чыккан автор фикерләре белән туры килми дә килми бит. Мескен, хәсис кеше андый юридик проблемаларны күтәреп чыкмас, моның өчен җан һәм акыл яктылыгы кирәк. Кайдан сон бу кешедәге шәхси икейөзлелек? Бәс шулай икән, анын мөдир булып утыруы Акмал ханның ирекә калуы кебек үк куркыныч. Җаны ике яклы пычакны хәтерләткән бу адәм үз урынында түгел, мәгълүматлар анын кабинетыннан саркылып чыкмый микән?—Башына килгән шушы уйфикер аны тетрәндереп җибәрде.

Гоголь урамындагы прокуратурага кайткач, ул оешкан җинаятьчелеккә каршы көрәш бүлеге башлыгын кичекмәстән чакырып кертте, алар анын белән Аксайдан бергә кайтканнар иде. Намангандагы өч көнлек операция Камаловка КГБ генералы Саматов “кодалаган” үз кешеләрне эштә күрергә мөмкинлек бирде һәм ул алардан разый калды, сынау өчен башка нәрсә кирәкми, Аксай эш һәм тикшерү урыны булды. Бүлек башлыгы кабинетка кергәч, Камалов сәркәтип кызга үзен телефоннан беркем белән дә тоташтырмаска кушты, хәтта Үзәк Комитеттан шылтыратсалар да. Арипов кулга алынгач, андый шылтыратулар булырга мөмкин иде. Коллегасы белән сөйләшү кадерлерәк, кирәгрәк, мөһимрәк һәм ул Ак йорттан качып торырга карар кылды.

—Йә, безнен операциягә ничек карыйлар анда?—дип сорады полковник, ул бу акциянен югарыдагылар белән сөйләшми-килешми эшләнгәнен

белә һәм прокурор Камалов өчен борчыла иде. Генерал аны прокуратурада яңа эшкә кодалаганда, Камаловның ниндирәк кеше икәнен сөйләгән иде инде, менә хәзер ул аны эштә дә күрде.

—Килешергә мәҗбүр булдылар,—дип елмаеп куйды прокурор.—Бер яхшысыз яман булмас, дип әйтәләр түгелме. Анда очрашу көтелмәгән, уйламаган фикергә китерде, шуны аңлатып карыйм әле. Дөресен әйтим, яңалык йомшак нервылылар өчен түгел. Башта кечкенә генә кереш сүз. Мин КГБда моннан бер атна элек булган идем. Арипов эше материаллары белән танышу өчен генә түгел, ә иң беренче, сездән ышанычлы кешеләр алу өчен дә барган идем. Инде мине борчыган тагын бер мәсьәлә бар: бездәге информация читкә саркып чыга. Акмал ханны кулга алу үтә яшерен сер итеп сакланды, шуңа гына уңышлы узды да. Ләкин бу операция, уйлавымча, кемнендер кайбер планнарын да бозды. Берәүнең, ишеткәч йөзенә шулкадәрле дә аптырау-борчылу чыкты, ул хәзер, мөгаен, үзенең тотанаксызлыгына бик тә үкенәдер.

—Сез бит Ариповны кулга алу турында ҮК коридорында теләсә кемгә сөйләп йөрмәгәнсездер,—дип бүлдерде аны полковник.—Әгәр дә сез Беренчене күз алдында тотасыз икән, ул башкача булдыра да алмаган булыр иде,—дип дәвам итте ул, күрәсең, Камалов мондагы катлаулы чапырылышларны белми дип уйлады булса кирәк.—Алар Акмал хан белән күптәнге әшнәләр һәм Беренче аны бер генә тапкыр коткарып калмады инде.

—Бар хикмәт тә шунда шул,—диде Камалов йомшак кына.—Беренче бу хәбәрне битараф кабул итте.

Хәзер әңгәмәдәше аптырап калды.

—Бишенче катта, сез доклад белән кергәндә, тагы кем булырга мөмкин соң?

Камалов коллегасын газапларга теләмәде:

—Сухроб Әкрәмхуҗаев.

—Ә аңа ник борчылырга, ди? Ул шатланырга гына тиеш,—дип тагы аптыраашта калды полковник.

—Мин дә шулай уйлый идем дә бит. Ну, яңалык ничегрәк?

—Чыннан да, йомшак нервылылар өчен түгел.

—Сизеп торам, безгә аның тормышын микроскоп астына алырга кирәк булыр, информация югалтуның берәр каналы анда түгел микән...

—Бер атнада ике законсыз акция күбрәк булмасмы?—дип, шаярып сорады полковник.

Ләкин прокурор аның бу сүзенә игътибар итмәде, бары сүзен генә дәвам итә бирде:

—Ситуация ачылып беткәнче, аны кызыксындырган нәрсәләргә анализ ясарга кирәк һәм, мөмкин булганча, якындагы планнар белән аны таныштырмаска. Һәм соңгысы, аны халык арасында иң популяр юрист итеп таныткан атаклы мәкаләләр авторы булуында да шигем бар. Сез ипләп кенә аның докторлык диссертациясен табыгыз әле, докторлыкны яклауның ничек барганын белешегез, кайда яклаган, оппонентлары кем булган, материалны кайсы китапханәләрдә җыйган, анда, мәсәлән, бик сирәк китаплардан цитаталар китерелә, миңа калса, аларны аның кулында тотып караганы да юктыр. Тагы шунысы... Аның докторлык диссертациясенә коллегаларының реакциясе нинди булган, ҮК аппаратына ничек эләккән, белүемчә, ул бит партия эшендә бер көн дә эшләмәгән кеше, юкса аппаратта юристлар буа буарлык, бу эшкә аны кем "кодалаган?" Болары рәсми яктан. Башка теләсә кайсы мәдәни үзәктәге кебек, Ташкентта да фәнни эш язып бирүче кешеләр җитәрлек, алар югарыдагы түрәләргә заказ буенча, мәгълүм бер бәягә, кандидатлык, докторлык эшләре әвәләп бирәләр. Бу каналларны тикшереп карарга кирәк, бәлки җеп шуннан сузыладыр. Мәкаләләре басылып чыккан Сухроб Әхмәдович белән фәнни

темаларга бер сүз дә әйтә алмаган Сухроб Әхмәдович арасында аерма җир белән күк арасыдай ерак. Гомумән, идән асты үзәкләре турында әйтәм, алар белемсез кешеләргә фәнни хезмәтләрне коймак урынына пешереп кенә торалар. Бүген аларга үрелергә вакытыбыз юк-югын, ләкин бу да оешкан җинаятьчелекнең бер төре, хокукый нигилизмның үтә куркыныч формасы, цинизмга барып җиткән интеллектуаль юньсезлек. Анда катнашучы һәр ике як та җәмгыятьне таркаталар, аның әхлакый шәкелләренә зыян ясыйлар. Вәгъдә бирәм, әгәр мин монда эшләп калсам, мондый кабахәт һөнәрне юкка чыгарачакмын, закон нигезендә йөзләрчә кандидатлык, докторлык диссертацияләрен гамәлдән чыгартам, кабат бу эшкә тотынмаслык итәм әле.

Шул ук көнне, эштән кайтырга җыенганда гына кабинетында шәһәрара телефон телгә килде, СССР прокуратурасыннан шылтыраталар иде.

—Мәскәүнең астын өскә китердегез тәки. Менә әле генә инде икенче кинәшмәдән кайтып кердем. Сезне якладык, хәер, безнең иң мөһим эшләр буенча тикшерүче дә сынатмады, кире каккысыз шәп дәлилләр җыйган, Ариповның Мәскәүдәге саклаучы фәрештәләрен дә белә икән. Ә сездә ничек анда?

—Бездә, уйлавымча, бәхәсләр алда булачак әле, хәзергә һушын җыя алмый. Минем телефонны тик тотмыйлар, һәркайдан Ариповны кулга алу турында сорыйлар. Күпләр ышанмый, бу мөмкин түгел диләр, ничек инде Хезмәт Герое, СССР Югары Советы депутатын кулга алып була, диләр, һәм башкалар, һәм башкалар...

—Кыенга килә башласа, безгә хәбәр салыгыз, якларбыз, рәнҗетә алмаслар. Мин сезгә әйткән кешене онытмагыз,—һәм сөйләшү шунда ук өзелде дә.

—Минем телефонны тынлыйлар микәнни?—дип уйлап куйды сәер өзелүнең сәбәпләрен аңламаган прокурор.

* * *

Акмал ханны кулга алуның бөтен нечкәлекләрен ишеткәч, ә аларны аңа прокурор Камалов сөйләп бирде, Сенатор Шубарин белән элемтәгә керде:

—Артур, берәр җирдә әбәтләп алсак яхшы булыр иде, син каршы түгелме?

Шубарин күзгә-күз сөйләшү булырга тиешлеген бик тиз аңлап алды һәм үз тәкъдимен кертте:

—"Лидо"да өстәлгә заказ биримме?

—Мин анда сирәгрәк булырга тырышам, Нәргиз янына инспекцион визитлар гына ясыйм. Әйдә, иң яхшысы, Чимкент ягына китәбез, анда күңелгә хуш килерлек берәр чәйханә табылыр әле. Минем янга ярты сәгатьтән кил, гадәттәге кебек, арткы ишектән чыгармын...

—Берәр нәрсә булдымы әллә?—дип сорады Шубарин, Сенатор арткы капкадан килеп чыгуга, Әкрәмхуҗаевны аның мондый мескен, югалган, аптыраган хәлдә күргәне юк иде әле, һәрвакыт үз властен тоючы, түрәләрчә мин-минлекле Сухробмы бу?

—Минем сине юк-бар өчен чакырганым бармы?—дип, сорауга сорау белән җавап бирде Сенатор һәм Японның машинасына кереп чумды.

Артур Александрович София проспектына чыкты, моннан Чимкент трактына кул сузарлык ара. Сенатор хаклы, дендропарктан башлап Черняево исемле иске рус поселогына кадәр арада чәйханә өстендә чәйханә. Алар, унайлыкта бер-берсе белән ярышкандай, барысы нинди дә булса су буена утырырга тырышкан, берсе тирәклектә булса, икенчесе таллы яр буенда, өченчесе арык яисә хавыз тирәсен сайлаган. Юл буендагы бистәләрдә ит лареклары, анда шашлыкка сарык ите, бавыр һәм думба (күрдүк мае) алырга була. Теләсә кайсы чәйханәдә ун-унбиш минутта

шашлык та әзерләп бирәләр. Көтелмәгән фикерләрдән Шубаринның никтер бик тә шашлык ашыйсы килеп китте һәм ул, дустының кәефе юклыкка да игътибар итмичә, шаяртып куйды:

—Мин сине, Сухроб, бавыр шашлыгы белән сыйлыйм әле, бөтен кайгы-хәсрәтләреңне онытылыр. Нигә бу хәтле борыныңны салындырдың? Бер әрсен үтерденме әллә? Хәтта алай булса да, чыгу юлы бар бит—акча бир, куркыт, болгат, соңгы чиктә үз урыныңа төрмәгә берәрсен тык, хәтта үз теләге белән төрмәгә кереп утыручыны да табып була, Әфганстанда сугыш башланганнан бирле елның теләсә кайсы фасылында чик аша чыгып качарга да була, резервта андый юл да бар, бары акчаң гына булсын. Акмал хан биргән биш миллионны туздырып бетермәгәнсеңдер бит әле? Андый акчалар белән Көнбатышта да югалмассың, безнең сумны "неконвертируемая валюта" дип атыйлар икән, ышанма, күпләргә безнең агач акчалар да кирәк.

Сенатор кинәт көлеп куйды, йөзендәге борчылу югалды, җанланып китте һәм Шубаринның җилкәсенә сугып куеп, җанланып әйтте:

—Хәйран калырлык кеше син, Артур. Синең янында ун минут кына булдым, бернәрсә турында да сөйләмәдем, ә җандагы авырлык эреде дә бетте. Синең белән иң четерекле ситуациядән дә чыгып булганына ышана башлыйсың. Көчең-куәтең бөркелеп тора, синнән көч алам мин.

Юл читендәге ларекта марля белән капланган сарык түшкәсе күреп, Шубарин машинасын туктатты.

—Мин хәзер. Менә бу түшкәдә бик тә шәп бавыр булырга тиеш. Андыйны танырга мине тәмле тамак Икрам Мәхмүдович өйрәткән иде, берәрсе бездән өлгеррәк булып, инде бавыр очмаган булса.

Ул кулына төргәк тотып бик тиз борылып та килде, инде шашлык кыздыра торган чәйханә табасы гына калды. Ун чакрымлап юл үттеләрме, юкмы, Казакъстан белән Үзбәкстан чигендәге бер авылда күңелгә хуш килерлек чәйханә дә күренде. Ул бу яктагы авыллардан берние белән аерылып тормый иде кебек, ләкин күзләре шунда тукталды. Шуның өстенә, монда атаклы Чимкент аракысы белән шундый ук данлыклы Чимкент сырасы да саталар икән.

Карап торырга бик елгыр адәмгә охшаган шашлыкчы Шубариннан төргәкне алгач, уң кулын йөрәк турына куеп әйтте:

—Утырыгыз, ял итә торыгыз, хәзер чәй китерерләр, шашлык унбиш минуттан әзер булыр.—Юл кырыендагы ирләрне ул күптән күреп алган һәм аларның зур нәчәлниклар икәнен дә чамалаган иде инде. Шәрекъ тә бу мәсьәләдә сирәк ялгышалар.

Кул юып, иркенрәк, җайлырак айван сайлап маташкан арада мангалдан авыз суларын китереп кыздырган шашлык исе дә чыга башлыды, шашлыкчы чыннан да өлгер, эшен әйбәт белүче житез кеше икән. Шашлыкка өстәп, ваклап туралган, шәраб соусында мәмрәгән, Корея борычы кушылган суган китерделәр, моңа аччик-чучук салаты да өстәлде, аны китергәндә елгыр егет күз кысып, шыпырт кына пышылдады:

—Мондый тәмле шашлык янына, бәлки, бик шәп аракы да куярга ярыйдыр?

Кунаклар илтифатлы итеп баш тартты. Һәр икесенең күңел төбендә кымыржып торса да, эш турында сөйләшмәделәр. Чәйгә күчкәч, Артур Александрович телгә килде:

—Тамак ялгадык, хушландык, хәзер инде эшкә күчсәк тә була,—диде.

Сүзләренең Шубаринга ничек тәэсир итүен күрәсе килепме, табындашы иситмәгән кыяфәт белән турыдан-туры ярды да салды:

—Акмал ханны кулга алганнар.

Анысы исә күзләрен кыса төшеп Сенаторга карап алды һәм көлемсерәп куйды.

—Син белми калдыңмы, бәлки ҮКда да белмәгәннәрдер, рөхсәт тә

сорап тормаганнардыр.—Мондый мәсьәләнең кайда һәм кем тарафыннан хәл ителгәнен яхшы белгән Шубарин ышанмый иде шикелле.

—Күз алдына гына китер, әйе, мин белми дә калдым, хәтта ҮК белән киңәшмәгәннәр, ул гына да түгел, Мәскәү рөхсәтеннән башка... Менә шулай, дустым, шундый юлбасарлар заманасы килде. Моны законның идеологиядән, ягъни партиядән дә өстен булырга тиешлеге белән аңлаталар.

—Карасана, хәбәрдарлык белән демократия бездә дә бик алга киткән икән бит,—дип сызгырып куйды Япон.—Кем инде ул андый кыю кеше? Мондый башбаштаклыктан соң урынында аны озак тотарлармы?

—Ниндидер Хөршид Азизович Камалов,—диде Сенатор, аны үчекләгәндәй иттереп.

—Нишләп ниндидер, дисең? Камалов—республика прокуроры, син хәзер Ак йорт биеклегеннән беркемне дә санга сукмыйсың, ә юкка... Шәрекътә теләсә кайсы чинның, ә мондый чинның бигрәк тә, көче бар аның.—Шубарин әңгәмәдәшен җиңелчә шелтәләгәндәй итеп әйтте.

Бу сүзләрдән Сенаторда өмет уянгандай булды, йөзенә сөенү галәмәте чыкты.

—Бәлки синең аңа ачкычларың да бардыр...

—Юк!—дип, шундук өзде Япон, ләкин Сенаторның йөзендә эчке куркыну күреп, дәвам итте.—Ләкин, кадерле Сухроб, кирәк булса, аңа ачкыч табып булмый дигән сүз түгел. Үз гомеремдә акчага битараф булган бер генә прокурорны күрергә туры килде.

—Кызык, анысы кем инде? Аның турында бервакытта да сөйләгәнең булмады,—Юридик фәннәр докторы тагы җанланып китте.

—Себер татары Әмирхан Даутович Азлархановн, мин аны бик нык хөрмәт итә идем.

—Сине сатуына да карамастанмы?—дип сорады, соң чиккә җитеп аптыраган Сенатор.

—Юк, ул мине сатмады, ләкин бусы инде икенче мәсьәлә. Әйдә үзебезнең проблемага кайтыйк әле, прокурор Камаловны җайлау юллары эзләргә кирәкме һәм кирәк булса, ни өчен?

—Эзләргә кирәк булыр. Мин инде гафу ителмәслек бер хата ясадым. Акмал ханны кулга алуларын ишеткәч, үземне тыя алмадым, хисләрем битемә бәреп чыкты. Ул моннан үзенчә нәтиҗә ясамый калмас. Бәлки республика прокуроры минем яшәү рәвешемне микроскоп астына алыр, прокуратура серләрен миңа ачмаска тырышыр. Ә минем вәзгыятьне даими рәвештә үз кулымда тотасым килә, максатымны беләсең, Аксайга барып кайткач, мин сиңа барысын да ачыктан-ачык сөйләдем. Шулай бит?

—Әйе, җитди хата җибәргәнсең. Мин аның кысымы астына эләгергә теләмәс идем, ул прокуратурада мафия белән көрәш бүлеге оештырган, бүлек җитәкчелегенә КГБ кешеләрен җыйган. Иң кирәкле җирләрдә кэгэбэшниклар утыра.—Шубаринда кинәт кенә бер идея туды ахрысы, ул тиз генә сорап куйды:—Акмал ханны кайда тоталар, кайсы төрмәдә?

Әңгәмәдәшенең уйларын аңлап алган Сенатор авыр сулады:

—Акмал ханга хәзер безнең теш үтми, әллә нинди акчаларга да аңа әйбер тапшырып булмый инде.

—Әйе, каты тотынган Камалов!

—“Минем кебекләрне кулга алмыйлар. Мин суд эскәмиясенә утырмыйм”, имеш. Карт идиот, мин бит аңа югалып торырга куштым, хет безнең илдә, хет чит илдә. “Төркиядә мин сагынудан саргаеп үләчәкмен”,—диде Әкрәмхуҗаев, Акмал хан булып кыланып.—Менә хәзер совет төрмәсендә йөзгә кадәр яшәрсең инде!—Сенатор кинәт кенә кабынып китте, бераздан ярсуын тыя алды һәм инде тыныч тавыш белән сорады:—Менә хәзер минем кайгы-хәсрәтләремне аңладыңмы?

—Акмал ханны кулга алу күпләрдә курку, шикләну уятачак, республикада нинди паника күтәрелгәнен чамалыйм, югарыдагы һәр түрә тирәсендә аның кулы уйнады. Аның белгәннәре чәчелсәме...

—Синең турында да, минем хакта да... шул кәһәр суккан Аксайга барырга шайтан котырттымы, миллионнары чәнчелеп киткере!—Сенатор тагы кызып китте, ләкин Шубаринның кискен карашы астында юашланып калды, Япон чәүчәләкләрне, ваклануны яратмый.

—Вакытыннан алда төшенкелеккә бирелмә. Акмал хан Мәскәүдә син күз алдына да китерә алмаслык зур кешеләр белән бәйләнгән, аларга аны суд хөкеменә бирү кирәк түгел.


Бәлки Мәскәүгә алып китүләре яхшырактыр да әле, башыннан сыйпап торучыларга якынрак булыр, ә монда аны үтереп ташлаулары да бар. Рәшидовның урынына менгән кешене дә ул куйган иде бит. Болгавыр заман, үлчәүнең кай ягы тартыр бит әле. Бәхәсләшә алам, аның эшен, ким дигәндә дә, биш елга сузачаклар, ә алга таба мәсәлдәгечә: йә ишәк үлә, йә арба ватыла. Аның тормышы теленә бәйләнгән, моны гына ул аңлый да аңлый инде.—Бераз гына тын торды һәм соравы белән мөсәхәбәнең юнәлешен үзгәртте:—Рас мине чакыргансың икән, димәк, синең планың да бардыр...

—Әйе, план бар анысы. Миңа калса, сиңа озакка сузмый гына Мәскәүгә очарга, андагы элемтәләреңне кузгатырга, үз кешеләреңне аякка бастырырга, Камаловның кем икәнен ачыкларга кирәк. Аның артында кемнәр тора? Көчле һәм йомшак яклары нидә? Бары Камаловка ачкыч табып кына, аны үзебезгә ияләндереп кенә без Акмал ханны тикшерү эшләре ничек барганын белә алырбыз, моның белән күпләр кызыксына. Дөресен әйткәндә, Артур, без Сәлим белән сине күптән политикага да, җинаять эшләренә дә катнаштырмабыз, дигән идек. Син чиста финансист һәм бизнесмен, шулай булып кал да, калганын без үзебез эшләрбез, ләкин Мәскәүдә безнең керер-чыгар юлларыбыз юк, безгә ярдәм ит. Ә алга таба Камалов белән без үзебез шөгыльләнербез. Сәлим белән мин үзем.

—Ышанычың өчен рәхмәт, минем тынычлыкны кайгыртуыгыз да ошый, ләкин бу планга кайбер өстәмәләрем бар. Камаловның Ташкенттагы бар тормышын энә күзеннән үткәрергә кирәк, моның өчен теләсә нинди юлга барырга да ярый. Прокуратурада, милициядә кешеләребезне активлаштыр, эшендә дә, өендә дә сөйләшүләрен тыңлауны оештыр. Кирәк икән, янына Айдынны куй, ул иренгә карап, кеше сүзен укый ала, Акмал ханнан алган аппаратураны эшкә җик—ни сөйли, ни уйлый, сез барысын да белергә тиеш. Безнең дуслар өчен иң куркыныч кеше шул.

Вакыйгаларның сәер чуалуы булдымы, Чимкент трактында төшке аш тәмамланып килгән минутларда, Камалов кабинетыннан мафия белән көрәш бүлеге начальнигы Уткур Рәшидович чыгып бара, аңа да Сенаторның тормышын энә күзеннән үткәрү бурычы куелган иде.

*Ахыры киләсе санда.*



## Мөдәррис Әгъләм

# КУЛЬТУРАЛЫ КАТЛАМ

### Мин таяндым сиңа

**Бер өн килде миңа чәчәннәрдән—**
**Әйткән сүзе мәңге яшәрләрдән.**
**Ераклардан килде,**
**Әллә каян:**
**—Миңа таян!— диде,—**
**Миңа таян!**

**Ул җан белән иңде,**
**Һәм кан белән**
**Актарылды минем бала чакта,—**
**Әллә каян килеп алып китте**
**Әллә кая алып барачаклар.**

**Күзләремнән тамды яшем генә,**
**Ул ургылып керде яшьлегемә...**
**Аянычым,**
**Таянычым булды—**
**Аның белән бергә**
**Яшим менә!**

**Ул төш кенә булып килгән иде,**
**Инде хәзер менә өнем булды,**
**Көнем булды,**
**Янә төнем булды,—**
**Югыйсә бит килде әллә каян:**
**—Миңа таян!— диде.**
**—Миңа таян!**

---

Мөдәррис ӘГЪЛӘМ (1946)—*шагыйрь; "Киләчәккә кайту", "Мин әйттем", "Ка[н] тамырын кистем" һ. б. китаплар авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияс[е] лауреаты. Казанда яши.*

Мин таяндым...
(Ә Ул әйләнгән бит
Кемнәрнеңдер һөнәр, шөгыленә!..)

Мин таяндым аңа:
Барыбер дә
Рәхмәтлемен татар шигыренә!

...Әйләнмәсәм дә бик әллә кемгә—
Мин таяндым Ул чакырган өнгә.

## Каен җиләге

Табигатьнең үз теләге, дисәм,
Аңарда да Ходай теләге—
Аның теләгеннән яратылып
Пәйда булган Каен җиләге.

...Дөнья мине тегермәндә тартты,
Нечкә иләгендә иләде.
Үз вакыты белән өр-яңадан
Каршы алды Каен җиләге.

Әнкәм кулы белән вакыт мине
Биләүләргә салып биләде.
Мин үрмәләп киттем. Көтеп торган
Алсуланып Каен җиләге.

Китеп барыр көннәрем дә җитә,
"Бик ашыкма, диләр, син әле?!"
Бик тә беләм, Каен җиләге мин,
Тик вакытлы Каен җиләге.

Килер язлар,
Канат җәер җәйләр.
Кабатланачакмын мин әле
Туган телем барда—мин бит анда.
Шул аланда—
Сез җыячак Каен җиләге.

## Нәҗми көлүе

*Нажар ага Нәҗми истәлегенә*

Юк, ул көлми иде, әйтерсең лә
Кояш нурларында чарланып,
Дөнья матурлыгын бергә җыеп
Өскә төшә иде шарлавык.
...Әле ярый җәйгор икәнлеген
Үзе исән чакта аңладык.

Аның көлүе гаҗәп шигырь иде,
Беркайчан да арып-талмадык.
Тәгәрәшеп көлдек шул арбада,
Беркайда да төшеп калмадык.
Дөнья кадәр иркен дөнья булган,
Төшеп булмый,
Хәзер аңладык.

Шигърияттә Казан сөлгеседәй
Җилфердәде—чите чалмалык.
Без көрәштек уртак милләт өчен,
Бер-беребезгә аяк чалмадык.
Кирәкләр дә, төбәкләр дә төрле,
Тик бер мәсләк—шуны аңладык.

Аның көлүе көлү генә түгел,
Хасил була иде шарлавык.
"Татар теле" шигыренә карап
Атладык без—
Бардык,
Армадык...
Туфан киткәч, ул—кыйблабыз булган,
Бара-бара шуны аңладык.

Дәрт кузгатыр өчен хәмер эчтек,
Шәраб эчтек, әмма "салмадык".
Бик еш кына,
Бик күп мәсьәләдә
Аек булып кала алмадык.
Әмма барган,
Алган юлыбызның
Хаклы икәнлеген аңладык.

Кичер, Хода! Кайчак, бик акыллы
Сүзләреңә колак салмадык,
Уйлап китсәң уйлар уелып китә,
Уелып китә, таңга калмалык...

Инде килеп...
Үлеменең дә бары... үлеменнән
Көлү икәнлеген аңладык...

...Бу ил мәнфәгате
Кая бара?
Барыбер дә аңлый алмадык...

## Яшә!

Кайчак шулай кирәк була:
Сүнмә дә ки, янма да!
"Мин хаклы!"— дип,
үз-үзеңне
Күпме генә алдама,
Алланыкы Аллада ул,
Алланыкы Аллада.

Баш иярлек,
Бил бөгәрлек,
Тез чүгәрлек хәлдә дә
Ходай биргән бу җаныңны
Ыргытма да, бәрмә дә—
Бәндәнеке бәндәдә ул,
Бәндәнеке бәндәдә.

Кул салырлык чаклар була,
Син ул хакта уйлама—
Үз-үзеңне таптама да
Һәм югары куйма да...
Дөньяныкы дөньяда ул,
Дөньяныкы дөньяда.

"Ялан тәпи йөгер!"— диеп
Күрәмсең, үлән дәшә.
Язын, җаен үзе дәшә,
Ә көзен бәхилләшә.
Алла, бәндә, дөнья сине
Яшәргә генә дәшә—
Яшә!
Яшә!

## Дөньяви мәхәббәт
### (баллада)

Әллә табигать үземе,
Әллә язмыш кушты:
Бер-беренә гашыйк булды
Каен белән пычкы.

Каен зифа, гүзәл иде,
Булмагандыр ише!
Ут кебек ялтырый иде
Пычкының да теше.

Затлы иде, дәртле иде,
Сылу иде каен...
Калтыранып куя иде
Пычкы күргән саен.

Пычкының да баш әйләнгән,
Күздә төтен иде...,
Ике кулы күккә ашкан,
Тешләр үткен иде.

Менә кинәт чынга ашты
Аның өметләре—
Ике кулына тотынды
Кияү егетләре.

Өсләренә авар булды
Зифа буйлы каен.
Аңын җуйды, пычкы теше
Ялтыраган саен.

Ахыры кая барганын
Аңлап та бетмәде—
Пычкыны сайрата иде
Кияү егетләре.

Аккан кебек йөрәк мае
Зөфаф кичәсендә,
Акты каен... тик белмәде
Тәмуг кичәсен дә.

Турап ярдылар, яктылар,
Төтен булып очты...

...Үтте вакыт... инде ята
Металломда пычкы.

## Культуралы катлам

*Казанның 1000 еллыгы уңае белән*
*археолог Фаяз Хуҗинга*

Тарихи чынбарлыкка бит
Югыйсә бер атлам.
Һәммәсен дә каплап тора
Культуралы катлам.

Ачканың ачык капкадыр,
Тора кырык капкан—
Сине саклап тора бары
Культуралы катлам.

Дөнья кыса, вакыт кыса
Кыса төрле яктан—
Җылы биреп сулый эчтә
Культуралы катлам.

Болгар чорын, Казан чорын
Актарып ал астан—
Күрсәт ачып:
яткан качып
Культуралы катлам.

Мең гасырлык тарих синең
Күз алдына баскан,—
Ә ул бары актарылган
Культуралы катлам.

Шигырь кебек шәхесләрнең
Эшен беләм яттан:
Алар—килер гасырларга
Культуралы катлам...

## Ярты юлда

Бөтенесе ярты юлда,
Эшләнәчәк яңа эшләрем,
Өзелделәр татлы йокыларым,
Йокыдан да татлы төшләрем.

Бөтенесе калды ярты юлда,
Тотынуга кулдан эш төшә.
Ярты юлда калган хәтта кояш,
Тау артына төшеп китмичә.

Бөтенесе калды ярты юлда,
Кырык эшем тора тезелеп...
...Күз алдыма килдең,
Бу җырым да
Ярты юлда кала өзелеп.

## Вакыт—дала

*Җил—Вакыт ул (Р. Ф.)*

Сәҗдә китеп дога кылганнар да,
Баш китәрлек эшләр кылганнар...
Вакыт—дала.
Һәрберсенең, әнә,
Баш очында шаулый кылганнар.

Кабер ташлары да куелмаган,
Һәммәсенә берәр кылган бар...
Вакыт—дала.
Безгә дә бер бөртек
Калды микән?!
...Эшләр—кылган—бар.

## АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ

# КЫЛДАН НӘЗЕК, КЫЛЫЧТАН ҮТКЕН

РОМАН

Нигә бүген очрашыр кешесе итеп Гафур Бикчуринны сайлады Асаф? Гөлсинә хакында сөйләшерме ул аның белән? Йомык күңеленең биген ватып серләрен ачып салырмы?

Күп санлы танышлары арасыннан Гафурны сайлаганда ул максатының йомгагын уйлап тормады, аңа, рульсез калган ватык көймәгә, дулкыннарда кагылып-сугылып ихтыярсыз агып барганда тукталып, аз гына сыенып торыр урын кирәк иде. Уй юнәлешен югалтмаска күнеккән Асаф Сәхипович, үз юнәлешенә бүтәннәрне дә ияртә ала торган көчле кеше бүген сабый бала хәлендәрәк калган иде. Әйе, бүген Асаф Сәхипович барып керүгә бик күпләр сөенер, берәүләр гаҗәпләнер иде. Ә ул аларны шәһәрнең ару ягын калдырып Восстание урамында эзли. Иртәдән-кичкә кадәр сасы төтен, газ аккан урамда, Хрущев бабайның әлегә бердәнбер һәйкәле булып утырган эт биеклеге ике бүлмәле квартирасында өч баласы һәм хатыны Нәфисә белән яшәп ятучы яшьлек дусты, яшьтәше Гафур Бикчурин катына бара...

Суфия бу хакта ишетсә бот чабып көләр иде. Эдуард исә: «Ну ты даешь, старик!» дип шаккатыр иде. Суфия белән Асаф Гафурны онытмыйлар, тормышын кора алмаган булдыксыз бер кеше мисалга кирәк булганда нәкъ менә тормыш юлын өметле генә башлап, мөмкинлекләрдән файдалана алмаган кеше итеп телгә алалар иде.

Тар баскыч, ике кеше кара-каршы килгәндә бер-берсенә орынып китә торган коридор. Эчтә звонок шалтыравы да, ашыккан аяк тавышлары ап-ачык ишетелеп торган юка ишек... Эчке якта көлеп Гафур карап тора. Шакмаклы күлмәгенең итәген чалбарга тыкмаган, җиңнәр сызганулы, авызын каймалап, ияген төргән дага сакал чаларган, бөдрә баш тоташ көмешләнгән, бераз эчкәрәк батып торган чем кара күзләр генә элеккечә ягымлы, көлемсерәп карыйлар. Ул керә-керешкә Асафның ике кулын да кысып-кысып әләктереп алды, кочаклады.

Өйгә юеш кер, порошок исе таралган, кулларын түгәрәк ак алъяпкычына сөртә-сөртә чибәрлеген югалтмаган Нәфисә килеп чыкты. Хуҗалар ни арада кунакны чишендереп, түргә, өстәл артына кертеп тә утырттылар. Гөж итеп

---

*Ахыры. Башы беренче санда.*

самовар кайнап чыкты, табынга әллә ничә төрле варенье, бал, бүтән төрле ризыклар тезелде.

Сүз урам, шәһәр хәлләреннән, һава торышыннан, «озон катлавы кими башлаган»нан, шушы йортка, гаиләгә әйләнеп кайтты. Гафурлар олы улларын өйләндереп кооперативный квартирага башка чыгарганнар, томырап торган кызның бабасы-әбисе булганнар. Икенче уллары да башлы-күзле булырга җыенып йөри. Кече уллары Свердловскида аспирантура бетереп ята икән. Анын да кәләше булып, кыз Гайнә татарларыннан икән, «алар ягында хатын-кызлар чәчрәп торган матур булалар икән»...

Гафур шул элекке урынында эшли, канәгать, күнегелгән эш, җаны тыныч, нәфесен котыртып зурга үрләми, кешедән көнләшми, бар булганына риза, тамагы тук, гаиләсе бөтен, тормыш юлдашы Нәфисәсе янында. Нәфисә былтыр кыш пенсиягә чыкса да, больницадан чакырып алганда бер-ике ай эшләп ала икән, «өстәмә акча эчне тишми». Гафурның сон-сон гына иптәшләре белән җыелышып шахмат уйнавы да, Карпов-Каспаров ярышлары вакытында күрше-тирәнең «клуб итеп» шушында җыелулары да, Нәфисәнең бәйләргә яратуын, өч улына гына түгел, киленнәренә, оныкларына свитерлар бәйләп кидерүен, җәй көне бакчадан күпме карлыган, кура җиләге, алма җыюларын да, ничә банка гөмбә тозлауларын да белеп бетерде Асаф...

Йортта, гаиләдә, тормышта сер калмады шикелле, Гафур белән Нәфисә бер-берсен бүлдермичә, сүзләрен тулыландырып, күпчелек белешмәләрне көлеп, юмор белән сөйләп, Асафка һәммәсен селкеп күрсәттеләр, «бурада бүтән нәрсә калмады да бугай»?.

Чират Асафта иде... Йола буенча хәзер кунак сөйләргә тиеш, ул нинди йортка, кемнәр арасына килүен хәзер бик яхшы белә, инде хуҗаларның сусынын төкәндерергә вакыт: ничә еллар күренмичә, эндәшмичә йөргәннән соң нигә ишекләрен шакыдың аларның? Нигә монарчы читләттең безне, квартирадан-квартирага күчеп тә бер тапкыр өй туена чакырмадың? Яна еллар күпме алышынды, котламадың, алай да бүген килеп кергәч алар сина рәнҗемәде, үпкә белдермәде, аерылышканда, соңгы күрешкәндә мөнәсәбәтләрегез нинди булса, бүген дә шундый ук риясыз, киң күңел белән сине түргә утырттылар... Нәфисә Гөлсинә өчен үтә нык әрнесә дә бер сүз белән дә аны да ачмады! Йә, сөйлә...

Ләкин Асаф ачылмады, эше ягыннан бер-ике эпизод сөйләп, заманның тиз үзгәрүеннән, кешеләрнең начарлана баруыннан зарланды, эше күплеген, вакыт җиткерә алмавын өстәп куйды. Гафурның: «Әти-карт сихәтме әле? Әнкәннең вафаты колакка чалынган иде», дигән сорауны да колагы янынннан үткәреп җибәрде.

Нәфисә белән саубуллашып ишеккә таба барганда баядан бирле тик торган күрше бүлмәнең ишеге ачылды һәм аннан бик пөхтә киенгән, көмеш тажы өстенә кап-кара бәрхет түбәтәй бастырып куйган карт килеп чыкты. Ярым караңгы коридорда ул Асафны танымагандыр, алай да түбәнчелек белән сәлам бирде, кулын кысты. Бу карт Ибраһимнар түрендә «Тәбәрәк» сүрәсе укыган, Асаф белән өйлә намазыннан соң татар зиратында очрашырга вәгъдәләшкән бабай иде. Шул икән инде Гафурның әткәсе! Монда алып килдек дигән иде ич. Монда сыйдырганнар икән, монда... Кысан гына өйгә... Әлбәттә, картны тануын, аның белән элек очрашканы булуын Асаф Гафурга сиздермәде, ләкин йорттан чыкканда аны бер сорау борчырга кереште: «Картның мәчеткә йөрүен, Корьән укырга алынуын Гафур беләме? Ризамы? Рөхсәт итәме?»

Сорыйсы килде, ләкин Асаф Сәхипович артык-портык сораулар бирергә күнекмәгән сак кеше иде. Тиешле бирелмәгән сорауның араны ертуын, яра ясавын ул чамалый иде. Гомумән, җитәкчеләр сак булалар, алар һәр уйны ярты юлда туктаталар, теге яртысы турында, әйдә, әңгәмәдәш теләсә ни уйласын.

—Нигә юньлерәк квартира дауламыйсың? Нигә мина чыкмадың?—дип әйтмичә түзмәде Асаф урамга чыккач. Гафурга бу сорауны бер генә бирмәгәннәр иде ахрысы, бер дә исе китмәде.

—Минем квартира ние белән начар? Тукталышка якын, мәктәп ишегалдында, кибетләр дә үз тирәбездә, эшкә мин җәяү йөрим.

—Карт атаң монда. Шулай да ике бүлмә!..Шулай да...

—Ә ул өйдә тормый диярлек, кунарга гына кайта. Мәчеттә активист ул!

Бу темага кереп торырга базмаган Асаф Сәхипович иплəп кенә тормышның бүтән якларын әңгәмәгә чәлмәштереп китереп ялгады, яшәп калырга тырышуның беркем өчен дә әлегә зыян булмавын яшьлек дустына аңлатырга һәм рәхәт яшәргә өндәргә тырышты.

—Җитәкчеләргә ияреrгә өндисең инде?

—Җитәкчеләр кеше түгелмени? Аларның кешечә яшәргә хаклары юкмы?

—Аларның халыктан аерылырга хаклары юк. Аерылалар икән, халык алдында абруйлары калмады дигән сүз. Торыр урыннары аерым, юлга чыкса-лар вагоннар аерым, шифаханәләр аерым, санаторийлар үзләренеке, арага кара халык килеп кысыла алмый. Кибетләр аерым, гомумән, алар бер юлдан, иркен юлдан бара. Ә миллионлаган халык тар сукмакка куып кертелгән.

—Син бу фикерләреңне эштә дә сөйлисеңме?

—Эштә бер төрле, өйдә бер чамада, җыелышта өченче кыяфәткә кергәнем юк.

—Мондый уйлар белән яхшы квартирага тиенмәссең.

—Аның мина кирәге дә юк. Балалар үз тормышларын башлый. Мин аларны оядан очыртып торам. Үз йөзен саклаган җитәкчеләр безнең заманда да бар, сирәк булса да очрый алар.

—Мәсәлән?

—Мәсәлән, Эдуард Амвросиевич Шеварднадзе. Безнең яшьтәш. Бер кояш астында яшәдек. Тбилиси горкомының секретаре булып сайлана, шул ук ике бүлмәсендә кала. Мин аңа рәхмәт әйтеп хат яздым. Безгә дә карап чукынырга почмак калсын инде, үзгәрмәгез дидем. Югыйсә, кая карасаң да халык өлешенә керергә яратучы крокодиллар. Авызлары алып кадәр, бармаклары корыч тырнаклы, хәзер кабып йотарга торалар.

—Син шул төркемгә мине дә кертәсеңме?

—Ә синең кай ягың ким?..

Бераз дәшмичә торгач, нәни генә бакчага кереп, җимерек артлы, какшаган аяклы эскәмиягә утырдылар, эскәмия урысның бик популяр өч сүзе белән юмарт чуарланган иде.

—Мин сине аңлыйм, үпкәләмә, Асаф... Элек керәшен авылларында бәйрәмнәрдә агай-эне, дус-иш бергә «төйнәлеп» йорттан-йортка уйнап-көлеп йөри дип үзең сөйләгән идең. Хәзерге җитәкчеләр бергә төйнәләләр дә, бер-берсен калдырмыйлар, яклыйлар, җинаять эшләгәннәр дә күләгәдә кала, аларны да үзләреннән калдырмыйлар. Әнә, Казан шәһәрен чүпкә батырган шәһәр советы җитәкчесен эшеннән алдылар, әмма еракка җибәрергә курыктылар, яңа должность уйлап чыгарып, «беренче урынбасар» итеп билгеләделәр. Аны читкә җибәрергә ярамый, чөнки ул әллә кайчан «төйнәлгән», «күпне белә!»

—Син артык туры һәм аяусыз хөкем йөртәсең.

—Хөкем йөртәм икән—үзгәрүен телим. Телим икән—үзгәрүенә ышанам. Гел болай булмас. Ленин тыйнак булган, гадел яшәгән дип юлбашчыбыз җилкәсенә ышыкланып илдә ничә буын җинаятьчеләр алышынганын халык белеп тә, аңлап та бетерми әле. Чөнки безнең төп фаҗигабез шунда: халык фикерләргә өйрәнмәгән, гадел фикер алышырга гадәтләнмәгән. Россия кешеләре, гомумән, уйларга иренәләр. Шәһәрдә хәзер кемнәр яши: күпчелеге кичәге крестьяннар. Крестьяннар егерменче гасырда ничә революцияне үткәрсәләр дә әле коллыктан чыгып җитмәгәннәр. Әле кайчан гына алар коллыкта яшиләр иде. Колхозда ел дәвамында эшлиләр, бер тиен хезмәт хакы алмыйлар, үз хуҗалыкларыннан баш бетәрлек күләмдә налог түлиләр. Чыгып китә алмыйлар—кулларында паспорт та, бернинди документ та юк!..Ял юк, хезмәт кенәгәсе юк, стаж юк. Экономик законнарны еллар буе бозу, саннамау хезмәт кешесен рухи гарип ясый, аның хезмәткә хөрмәтен, эшкә ышанычын бетерә. Хәзер яшьләр авылдан кача дип зарланабыз. Дөрес

эшлиләр—калдырасың килә икән крестьянны коллыктан чыгар, аны җирнең хуҗасы, ягъни илнең хуҗасы итеп сана.

Бүген бу сүзләр Асаф өчен артык, бөтенләй кирәксез иде. Шушы кыска гына ара эчендә аның шәхси тормышы әлләничә чатнап ярылганда ул бүген үзеннән ерак китәргә тиеш була иде. Гафур аны бүгенгегә, ил гаме уртасына, ил кайгысын кайгыртышырга чакыра, ул әзер түгел, ул бөтенләй бүтәнчә уйласа да Гафур белән ныклы бәхәскә кереп торырга теләми иде.

Һәм ул Гафурга карап-карап алды да «Да-а, заман һаман үзгәртмәгән икән егетне!» дип уйлап, аны кызганды. Һәм хәзер, шушы минутта гына, ул үзенең Гафурдан читкә тартылганын аңлады... Әйе, егерме ел элек тә, аннан соң да шулай уйлый иде Гафур, шушы ук сүзләрне әйтә иде, илдә барган гаделсезлекне күреп-аңлап күп санлы мисаллар белән Асафны әңгәмәгә чакыра торган иде... Асаф аның әңгәмәләреннән курка, ишетмәс өчен колакларын кулы белән каплый, дустын күрмәс өчен күзләрен чытырдатып йома иде... Үзгәрмәгән Гафур, ахыры үзгәрмәс тә. Чөнки соңгы вакытларда мондый фикерләрне ара-тирә Асафка да ишеткәләргә туры килә, җитәкчеләр арасыннан да кайберәүләр заманны аңларга тырышып карыйлар иде...

—Безгә моннан ике-өч атна элек Гөлсинә кереп чыкты,—диде Гафур.

—Гөлсинә?

—Нәфисә әйтмәскә дә кушкан иде. Гөлсинә үзе дә кергәнен белдермәүне үтенгән.

—Сез һаман аның белән хәл белешкәләп торасызмыни?

—Бик сирәк кенә! Инде өч-дүрт ел күрешкән юк иде. Бу юлы ул бераз безне гаҗәпләндерде.

—Ничек?

—Бик нык үзгәргән.—Гафур Гөлсинәнең кай якларының сәер икәнен күңеленнән кабат кичергән сыман, беравык уйлап торды.—Юк, картаймаган, элекке кебек үк ягымлы, сөйкемле. Ләкин аның фикере, уе үзгәргән. Уй үзгәрә икән, җан тынычсыз дигән сүз. Ул бөтен дөньяга ачулы. Ирләрне каһәрли, җәмгыятьне сүгә; сиңа да авыр сүзләр әйтте.

—Нәрсә диде?

—Әйтте инде, ник аларын кабатлап торырга...

—Бәхет күрә алмады бичара,—диде Асаф кинәт, үзе дә көтмәгәндә. Гафур аңа күтәрелеп карады һәм карашын озак кына Асафның йөзеннән алмады.

—Мин сине гаепләргә җыенмыйм,—диде Гафур.—Ахыр чиктә соңгы хөкемне һәркем үзенә үзе чыгара. Дөрес, үзләренең ничек яшәүләре турында уйламыйча бу дөньядан киткәннәр дә күп. Ә менә мин, илле бишне үтүгә, үткәннәр хакында еш уйлыйм. Бик еш!..Әйе, Асаф дус, ялгышлар күп булган. Кемнедер хаксызга рәнҗетәсең, кемнедер аңлап бетермичә аңа кыен ясыйсың. Хәзер уйлыйсың: ул хаклы булган!

—Гөлсинә хакында сезгә берәр җирдән шалтыратмадылармы?

—Юк. Ә нәрсә?

—Болай гына... Ә мин авылга кайтып килергә уйлыйм.

—Керәшеннәрең янынамы?

—Тагын кая булсын?..

—Йөреп кайткач мине күрергә тырыш әле.

—Мөмкинлек булса, керермен.

—Бүгенге авылдан нинди тәэсирләр алып, нинди фикерләр белән килерсең икән.

—Сине ни кызыксындыра?

—Авыл бетә. Авыл кешесендә, крестьянда яңа психология тусын өчен берничә буынның алышынуы кирәк. Хәзерге крестьянның генофондына җиргә нәфрәт кенә салынган. Нәфрәт! Ә син житәкче кеше. Эшең, хезмәтең турыдан-туры җиргә карамаса да, бер генә оешма да, бер генә министрлык та җиргә битараф була алмый. Без моңарчы күзне йомып яшәдек, бала булып, күзне йомдык исә, безне күрмиләр янәсе...

«Мин авылга бүгенгене эзләп түгел, үткәннәремне барларга, үткән

гомерем белән саубуллашырга кайтып барам», дияргә теләде Асаф, кулларына власть эләккән кешеләр арасында уралып яшәгән Асаф телдән ычкынган җайсыз сүзнең бәла китерәчәген белә иде.

Моннан берничә ел элек, комсомолда бергә эшләгән иптәше килеп чыгып, Асафның мөмкинлекләренә кызыгып:»Эх, синең урында булсаммы мин!» дип әйтеп салды. «Минем урында нишләр идең?» дип сорады Асаф. «Белер идем!Фәләнне эшләр идем, төгәнне үзгәртер идем!» дип әрсез генә санап китте. Асаф көлемсерәде: «Үзгәртергә әзер торуыңны белгәнгә күрә сине беркая да сайламыйлар да, бер җиргә күтәрмиләр дә!» дип җавап бирде.

Бүген ул Гафур белән бер дә килешмәде, килешү кая, аның авызын каплардай булып утырды, гадәттә, соңгы сүзне ул әйтеп, әңгәмәгә ноктаны куярга яратса да, бүген соңгы хөкемен иптәшенә җиткерергә көче җитмәде, чөнки соңгы көннәрдә Асаф Сәхипович, унбиш елдан артык югары дәрәҗә алып күкрәк киереп, дөп-дөп басып йөргән кәттә кеше түгел иде. Элекке гадәтләрне сакларга тырышса да, җаны гадиләшкән, бүген ул кеше белән арадашлыкка мохтаҗ җан иде.

Ул, әлбәттә, Гөлсинәне эзләп бармады, психоневрологический больницага шалтыратмады, борчылып бер-ике көн көтеп йөрде. Ваклыкларны белешергә йөрәге җитмәде.

Ул мондый кискен борылышка бөтенләй әзер түгел иде. Эше дә алга бармады, күнеле ятмады хезмәтенә, «сәламәтлеге какшавын сәбәп итеп, ике атнага ял сорады. Карышмадылар, рөхсәт иттеләр, эштә кирәгеп караштырып, вак-төякләрне барлап бетергәнче тагын атна чамасы вакыт үтте.

Врач аша даими белешеп торган Суфия ханым пошаманда иде. Врач та өзеп кенә сүзен әйтә алмады, министрларга диагноз куярга кыюлыгы җитмичә ул да өч нарат арасында буташтырып йөртте. Йөрәк диде, нервлар какшаган диде. Ялга Кавказга барыгыз, йә булмаса чит илгә чыгып күңел ачып кайтыгыз, дип киңәш бирде. Болгарияне, Алтын комлы ярларны мактады.

«Ял алдым, ике атнага» дип хәбәр алып кайткан кичне аш бүлмәсендә гадәттәгедән озаграк утырдылар.

—Бик яшьләй болай күксеп йөрүең ошамый мина,—диде Суфия үзенең коры, колакны тырный торган тавышы белән.—Беләм. Авылдашың сиңа күңелсез хәбәр китерде, әтиең дөнья куйган икән.

Асаф таң калды. Бераз аска карап утырганнан соң гына:

—Ә син каян беләсең?—дип сорады.

—Җәен колагыма чалынган иде.

—Нигә шунда мина әйтмәдең?

—Тиеш тапсалар хәбәр итәрләр иде, белдермәделәр. Нигә аны мин ишетергә тиеш? Үлгән кешене җир өстендә калдырганнары юк әле. Мин ишеткәндә дә күптән җирләгәннәр иде.

—Алай да...

—Әтиеңне яратмый идең... Хәер, үлгәннәр хакында сөйләшеп утырмыйк әле. Исәннәрнең тумас борын картаеп китүе эчне пошыра.

—Мина тәгәрәттең инде бу ташны!

—Сина!—диде Суфия тагын да суыграк тавыш белән.

—Олыгаеп барам,—диде Асаф Сәхипович күңелсез генә.

—Политбюро члennары һәм министрлар картаймыйлар, дигән сүзне синең авыздан ишеттем түгелме?

—Ни әйтергә теләвең бу, Суфия? Теләсәң, теләмәсәң, картлык киләчәк... Әгәр мин вакытынннан элек пенсиягә чыксам син ни әйтер идең?

Суфияның болай да шыксыз чырае тагын да ямьсезләнде, иреннәре юкарып кысылдылар.

—Беркөн тормыйча сине аерып чыгарыр идем.

—Нигә?

—Пенсионер хатыны булып, тормышның бер тотам рәхәте өчен ялынып йөри торган лашманчы карчыгына әйләнәсем килми. Министр хатыны булып картаясым килә...

—Пушкин әкиятендәге балыкчы карчыгына охшадың!..

Ялгыш ычкындырды Асаф Сәхипович, «карчык» дигән сүзне, элеп алып китте, селкеп илтеп салды Суфия. Асаф басып торган җирдән башлап аның туган авылына, нәселенә, якыннарына—һәммәсенә каргыш эләкте...

—Миңа авылга кайтып килергә кирәк,—диде Асаф, ниһаять.

—Ниең калган анда?

—Әтинең каберен карарга кирәк. Таш куярга.

—Өлгерерсең. Үлгән елында таш куймыйлар әле. Кабернең инәсе, басыласы бар.

«Әлләниләр белә бу хатын!» дип уйлады Асаф чит кеше турында уйлаган кебек итеп. «Әллә ниләр!»

—Менә шул. Кайтмыйсың. Әгәр кайтасың икән, мине дә ияртәсең.

—Сиңа кайту бик кирәкме?

—Доктор синең ялгыз йөрүеңне хупламый. Күз-колак булырга кирәк, ди.

—Хәл шулай мөшкел икән, тиздән пенсиягә чыгарга туры килмәгәе, Суфия.

—Пенсия дигән сүзне оныт.

—Авыл минем туган җирем, Суфия.

—Син авылда яшәсәң әллә кайчан эчеп-күпчеп дөмегә идең. Син монда, безнең йортта, минем туганнар арасында тудың.

—Кеше ике тапкыр туа анысы... Сезнең арада да туганмындыр. Горький да шул хакта әйтә...

—Каткан керәшеннәреңне онытырга вакыт!

—Тормыш онытырмый икән шул, һаман-һаман искә төшереп тора.

Алар тагын озак кына сөйләштеләр, Асаф Сәхипович кызып китмәскә тырышты. Хәзер әз генә кызып киттеңме, Суфия ханым аның кайда, кем гаиләсендә туганын да телгә алачак. «Мина килгәндә киярենә ыштаның да юк иде бит!» дип йөзен ертачак. Ул мөмкин кадәр сабыр, акыллы һәм дәлилле булырга тырышып кич буе Суфияны көйләде, түбәнсенде, «тиз генә пенсия хакында сүз башламаска, гомере буе Суфияга тугрылыклы һәм түбәнчелекле преданный булырга» вәгъдә бирде, иелеп кат-кат хатынының коры, сөякчел һәм усал кулларын үпте...

Асаф Сәхиповичның Татарстанның иң кара, надан, артта калган керәшен авылында яшәвеннән Суфия ханым яшьрәк чагында мыскыллап көләргә ярата иде. «Атаң юньле булса, шул авылда гомере буе череп ятмас иде, беткәнмени күчеп китәрлек шәһәрләр, район үзәкләре... Ә ул шуннан кузгалырга курыккан!» Асаф Сәхиповичның туганнары арасында бер генә кеше дә җитәкче булып китә алмады, һәммәсе дә үз хезмәтләре, үз көчләре белән гомер кичерделәр, гади эштә булдылар. Күпчелек авылда торып калды. Суфия өчен болары да «артталык, наданлык галәмәте» иде...

Өйләнешеп чибәр генә тора башлаганда аларны Суфияның Займищеда дача салып кергән туганнары җәйге кунакка дәштеләр... Алар шулай күнелле генә чәйләп утыралар, Суфияның әти-әнисе дә шунда, түрдә, алар почетлы кунаклар. Нәкъ шул көнне Асафның әти-әнисе, алдан хәбәр итмичә генә, Казанга килеп чыкканнар (әнкәсен больницага күрсәтергә кирәк иде). Күршеләреннән Асафларның кая киткәннәрен белешеп картлар да дачага килделәр. Суфия Асафны чакырып чыгарды һәм әти-әнисенең тимер юл янында, урман кырында көтеп торуларын әйтте. «Нигә чакырмадың аларны?»—диде гаҗәпләнеп Асаф. «Әтиләр янынамы?»—диде кашларын дугаландырып...

Асаф тиз генә әти-әнисе янына барып килде, алдап-йолдап ачкыч биреп аларны Казандагы фатирларына кайтарып җибәрде. «Бигрәк гадиләр шул, кеше арасына утыртырлык та түгел»,—дип үзенекеләрне гаепләде... Суфиялар гаиләсенә сүз кайтарырга көче җитмәде...

—Үзем генә кайтам. Озак тормам!—диде кинәт Асаф нык ук карышып.—Ялгыз ял итәсем килә. Ял! Минем гомеремдә дә ял итә алганым юк.

Суфия иренә күтәрелеп карамады, дәшмәде, карышмады.

Асафның авылга улын алып кайтасы килде. Нигә Эдуард, Зәкиевләр нәселенең бердәнбер варисы бабасының каберен белмәскә тиеш?

Хәзер ана утыз... Кайчан гына Асаф та үзенең «утыз тулды!»сы белән мактанып йөргән иде. Гомер үтә дә китә икән. Эдуард та олыгаер, акылы үзгәрер, берзаман үзенең кайсы сукмаклардан килеп чыгуын уйлар, бабаларының кем булганлыгын белергә теләр. Картлыкта берәүнең дә яшьлеккә кайтмый калганы юк, диде түгелме Гафур?..

Эдуардның авылга кайтканына ничә ел үтте соң әле? Асаф Сәхипович хәтерләргә тырышып карады, хәтерли алмады, Эдуардның үзеннән сорады. Эдуардка бу сорау бер дә ошамады, ул, үзе артыннан ишекне ныгытып ябып, әтисе янына кабинетка керде һәм якын ук килеп:

—Старик, сиңа нәрсәгә ул?—дип сорады.

—Мин авылга кайтып килергә җыенам.

—Син әлерәк кенә анда булып кайттың түгелме соң?

Суфия әйтмәгән сүзне ул әйткәч аның күңеле өшеп китте.

—Анда мин үтешли генә... Ай күрде, кояш алды. Хәзер өч-дүрт көн торырга җыенам.

—Мин нишләрмен анда?

—Казан тормышыннан, сөременнән, иптәшләреңнән чак кына аерылып торырсың.

Эдуард кукрәгеп сул кулы белән чәпәли-чәпәли көлеп җибәрде.

—О-о, юк, старик. Авыл сукмагында түгел мин... Без хәзер тимер рельсларда. Теләгән җиреңә борыла ала торган түгел. Алдагы юлымны диспетчерлар, стрелочниклар билгели.

—Алары кем була инде?

—Син аларны белмисең, старик. Белсәң дә алар синең өчен авторитет түгел. Кыскасы, старик, авылга кайтмыйм, сиңа да киңәш бирмим. Артыңны тундырып җилдә әбрәкәйдә йөрерсеңме? Министр башың белән ярым тиле Шукарь карт кебек көнбагыш сабаклары арасында утырма инде!

—Шолоховны беләсең үзең тагын...

—Мин күпләрне беләм.

Үгетләүнең файдасы юк иде, улының кемлеген, кирелеген белә Асаф Сәхипович. Хатыны-улы белән уртак бер сүзгә килә алмыйча, юктан барны ясап, мәшәкать табып, көннәрен үткәрә алмыйча изаланып китүен тагын өч көнгә сузды. Ашыкмавының сәбәбе бер иде: Гөлсинә хакында бер-бер яңа хәбәр килеп ирешмәсме дип көтте. Бер көнне Петровның телефонын да җыйды, лейтенант урынында булмады, трубканы алган Галләмов:

—Кем бу? Аны кем сорый?—дип кызыксынса да Асаф трубканы тиз-тиз урынына ыргытты.

Авылга аны тугры Тәлгать илтеп куйды. Казан-Чаллы арасында юл түзәрлек иде, урын юлга чыккач ул юка кар-боз белән түшәлгән булып чыкты, борылышларда арт тәгәрмәчләр салулап читкә тайпылдылар. Бүтән чакта тиз йөрешне, җилдәй җилдергәнне яраткан Асаф бүген төксе һәм сак иде. Ул Тәлгатькә берничә мәртәбә:

—Ипләбрәк, ипләп!—дип кисәтү ясады.

—Курыкмагыз,—диде Тәлгать.—Көне-сәгате белән исән-аман илтеп житкерермен

Авылга караңгылык куера башлаганда барып керделәр. Асаф шуны теләгән иде, кеше аяк эзе тынып, сукмаклар суынгач кына барып керергә, күргәннәр күреп калыр, күрмәгәннәр күрмичә калса да ни зыян?! Болай да авыл гөж килер инде, «Әткәсен жирләргә дүрт-биш ай сонга калган зур начальник Асаф кайткан!»

Авылга кергәч, сирәк-сорак ут көлтәләрен кисеп үтә башлагач Тәлгать икеләнеп хуҗасына карады: кая таба барабыз? Асаф үзе дә туры җавап таба алмыйчарак утыра иде, ата йортына сугылыргамы, әллә туп-туры Җәгүрләргә барыргамы?.. Ата йорты җәй буе буш торган, анын тәрәзәләрен каккалап, томалап бетергәннәрдер, бикледер, хәзер авылда да халык бозык, йортжиреңне сүтеп алып китеп юк кына бәһагә сатып та җибәрерләр... Алай да

ул әүвәл үз йортларына кагылып үтәргә булды... Җәгүрләргә барырга җитешер...

Капка бикле түгел иде, тавышсыз гына ачылды, ишегалды өйалды тирәләре әйбәтләп себерелгән иде, Асаф сәерсенеп китте. «Кайтам!» дип берәүгә дә хәбәр салмады ләбаса! Үзе кайтканчы ук күңелсез хәбәрнең йорттан йортка йөрүен теләмәде. Оялды ишеге дә бикләнмәгән, өй ишеген шакымыйча гына ачып кереп, ут кабызгач ул тәмам аптыраашта калды, ялгыш кермәдемме, дип як-ягына каранды. Юк, өстәл шул ук, ак җәймә өстенә мендәрләр тезелгән, агач карават та үз урынында, сул як чөйдә әтисенең таушалган кожаны эленгән. Ис тә шул ук! Малай чакта ук канга сеңгән үз өенең исе! Яна пешеп чыккан ипи исе... Сөт кайнаган ис! Тары боткасының исе...

Кеше-кара яшәмәгәнгә бер дә охшамый иде монда, өй ягылган, май кебек җылы, бөтен җир җыештырылган, пөхтә, һәр нәрсә урынында. Өстәлдә зур агач табакта эре-эре айбагырлар, аның янындагы кечерәк коштабакта сап-сары урман чикләвекләре. Ул ике учын батырып айбагыр белән чикләвек көрәп алды да шыбырдатып, күз белән озатып аларны табакларга кире койды.

Әллә колхоз идарәсе йортка берәр кеше кертеп куйганмы?

Ул кече якка чыкты. Ботинкасын салмавына уңайсызланды, әнкәсенең «чиста кар идәнне үзе юа, аяк киемен салып тормагыз» дип шаяртканын хәтеренә төшерде...

Кече як киштәсендә кызыл, шакмаклы тастымалга төрелгән бер бөтен ипи тора. Ул тастымалны чишеп ипине иснәп-иснәп карады. Әллә самовар да куйганнар инде? Вәт могҗиза! Кап-кайнар. Бәләкәй ак чәйнек янына өсте ябулы калай чәй савыты, ярты литрлы банка белән сөт тезеп куелган. Ул холодильникны ачып карады, анда да ризыклар, кисәк-кисәк пешкән ит калҗалары, пешкән йомыркалар... Димәк монда кемдер яшәп ята. Асафның иң элек шул кешене күрәсе килде. Яши икән, мөгаен, ул чит авылдан килгән кешедер, колхозның берәр белгече мазардыр, чисталыкка караганда хатын-кыз булса кирәк... Һәм ул Асафның кайтасын белеп торган?!

Ул машинада кагаеп утырган Тәлгатьне чакырып кертте, алдына сөтле чәй ясап утыртты, ит калҗалары, ике күкәй куйды. «Хуҗа белән ничек тә килешербез!» дип уйлады...

Тәлгать кыстатып тормады, әле төне буе кайтасы бар. Асаф хәбәр иткәч кенә ул аны килеп алырга тиеш. «Өч-дүрт көннән», диде ул аңа. Салкын калҗа белән ике йомырка ашап, бер савыт каймакны ялт иттергәч, Тәлгать тук корсагын сыпырып хуҗасына текәлде. «Тегендә илтимме, әллә монда каласыңмы?» дип соравы иде. «Ярый, кайт син, Тәлгать»,—диде Асаф, — кирәк икән, җәяү дә барып җитәрмен, монда хәзер ерак түгел!»

Тәлгать иңбашын сикертеп куйды, китәргә икән китәргә, хушыгыз, ипитоз өчен рәхмәт! Асаф аны озатып калды, машина утлары күздән югалганчы капка баганасы янында сөялеп торды. Пальтосын, пирчәткәләрен өйдә калдырган иде, үткер октябрь җиле аның ачык муенын, кулларын чеметкәләде. Ләкин ул өйгә керергә ашыкмады. Нигезгә вакытлыча хуҗа булып калган кешене көтеп уңына, сулга карады: бер якта да җан иясе күренмәде, бик ерактан тоныкк кына булып музыка тавышы ишетелеп китте. Түбә кыекларына кунган җил ара-тирә сызгырып ала, ябылып бетмәгән капка нидер мыгырдый иде. Аркасына суык йөгерә башлауга ул өйгә керде, Тәлгать артыннан өстәлне җыештырды, самоварны яңартып үзе дә бер чынаяк чәй эчте.

Менә ул ата йортында. Өч-дүрт авылда аз-аз гына укытучы булып эшләп алган Сәхип Зәкиев Акъюл авылына килә дә шушында төпләнә. Ул авылны, авыл халкын ярата, халык та аны бик тиз үз итә, ярата. Олысы-кечесе аңа киңәшкә керә, тантаналарда, бәйрәмнәрдә кунакка дәшә, Зәкиевләр авыл белән туганлашып бетә... Сармандагы төп йортны сатып җибәргәч Сәхип Зәкиев шушы урман асты авылда төпләнә, бура сатып алып, йорт җиткерә. Ындыр артына инешкә якын урынга мунча утыртып куя. Тора-бара лапас, чиннекләр корып җибәрә, кар базы казый, умарта үрчетә...

Асаф Сәхиповичның иң күңелле еллары шушы авылда үтте...

Әгәр ул Гөлсинәгә өйләнеп, Гафур кебек тормыш юлын үзе сызып, үз бәхетен тырышлыгы белән табып, хатынына баш, гаиләсенә ата булып яшәсә, мөгаен генә аның иманы, дөньяга карашы, табынганы бөтенләй бүтәнчә булыр иде. Шушы уй күңеленә килгәч ул куркып китте. Әйе, бүтәнчә булыр иде! Кайчагында язмыш кешене бөтереп алып кереп китә дә, бөтенләй яңа кешегә әйләндерә. Ул әкиятләрдәге чал сакаллы картларның сөт казанына чумып, кодрәт белән яшәрүләрен, яңаруларын исенә төшереп куйды.

Бөтенләй бүтән булыр иде!..

Бәхетлеме Асаф Сәхипович?! Аның бу хакта чынлап уйлап караганы да юк иде шикелле. Ничектер, бер тапкыр Гөлсинә аннан «Син үзеңне бәхетле дип саныйсыңмы, Асаф абый?" дип сорады. Ул уйнап-көлеп, җиңел генә җавап биреп котылды: «Дөньяда синең кебек хәзинәгә ия булган кеше бәхетсез буламыни?»

Гөлсинә шаяртмый иде, уенчак сорау-җавап аны рәнҗетте, ул кимсенеп, башын иеп мышкылдап елап та алды...

Бәхетлеме ул? Кеше яшьлегендә бу сорауга җавап бирә алмый әле, бу сорауга җавап эзләми дә, мондый тынгысызлык анда гадәттән тыш язмыш вакыйгаларына тап булганда күңелендә туа. Туа икән, күңелдән китми. Әнә шул сорау кешегә артына борылып карарга куша, эзләндерә, онытылып беткән, әллә кайчан очрамаган, каберләре ничә тапкыр үлән белән түшәлгән кешеләрне хәтергә кайтара. Онытылган кешеләр берчакта да бөтенләйгә күңелдән китмиләр икән, алар шунда, уяну чиратларын көтеп тын гына саклаларлар һәм төннәрнең берсендә, күңелгә шом, олыгаю, картлык кереп утырганда бик ерактан, үткәннәрдән тавыш бирәләр, аваз салалар... Кылган гамәлләр, яхшылыклар түгел, яманлыклар, гөнаһлар искә төшә. Яхшылыклар түгел, чөнки яхшылыкларны адәм баласы йә теге очрак белән, йә бу уңайдан исенә төшергәләп яши... Үлчәү табасына салып карасаң һәркемнең кылган яманлыклары яхшылыкларга караганда күбрәк була. Кеше үзе яшәгәндә, эшләгәндә, тормышының сиксән процентын беркемгә дә күрсәтми. Кешенең кем булуын берәү дә ачык кына белми. Кеше үзе дә әле белеп бетерми. Ләкин, килә бер көн, яки шомлы төн, ул үз-үзенә отчет бирә башлый. Кылган яхшылыкларын унга куеп, сулга яманлыкларын тезәргә тотына да коты чыгып туктала, тизрәк бу уйлар бәрелешеннән качарга, онытылырга, бүгенге вак-төякләр белән юанырга омтыла. Ләкин көн үтә, ыгы-зыгылы көннән соң, төн җитә, төн—хатирәләр заманы. Төн—кешене караңгылыкта калдырса да аның хатирәләр дәрьясы яктырып алга түгел, артка ага башлый...

Асаф Суфияга өйләнгәч елдан артык алар йортында яшәргә мәҗбүр булды. Ул Островский урамында, тетя Нюра дигән урыс хатынының тәрәзәсез, караңгы бер бүлмәсендә, тар гына тимер караватка ия булып яши иде. Гафур Нәфисәсе белән шул фатирда яшәп калды. Асаф фанер чемоданын, агач кашыгын, төбе ямалган кәстрүлен күтәреп, Сталин томнарын төйнәп Фазыйла карчыклар фатирына күчеп килде. «Бездә торсын кияү,— диде Фазыйла карчык, —Безнең тәрбияне үтсен!»

Йорт алардан, ашау алардан, кияү булып килгәч үк Суфияның әтиәниләре Асафны баштан-аяк киендерделәр:кышкы пальто, яхшы бүреккә кадәр алдылар. Туйга чакырылмасалар да Сәхип агайлар да тик ятмады, алар да туйга дип мең сум акча салдылар... Ләкин Суфиялардан күргән яхшылык, игътибар янында мең сум чагыштыргысыз дәрәҗәдә мескен бүләк иде. Һәм бу хакта Суфияның әнисе җай чыккан саен искә төшереп торды. «Улын өйләндереп, башка чыгара алмаган атаның кем икәнлеге бик тиз аңлашыла!»

Асаф Суфиялар йортында, йорт бусагасын атлап чыгып аның туганнары белән аралашканда, олысыннан алып кечесенә кадәр үзен кимсетеп, килмешәк итеп карауларын тоя иде. Шуңа күрә аның тизрәк күтәреләсе, зур дәрәҗәләргә ирешәсе, Суфияның туганнарына да өстән генә карау

хокукын аласы килә иде. Әйе, ул тиз үсте, тиз күтәрелде. Кемнәрдер, ул сизми калган җепләр сузып, аны үз иттеләр, нәкъ кирәк чагында гына ярдәм кулы суздылар. Ул өметле кеше саналып, аңа ышандылар, кирәген белеп кенә ул да ярдәм итә башлады, тавышы үзгәрде, йөреше, кыяфәте. Ләкин болар һәммәсе дә ул Суфияга өйләнгәнгә тормышка ашты. Асафның үз исеменнән алда Суфия, аның әтисенең исеме юл ярып йөрде. Башта моңа нык ук кыенсынган Асаф яши-яши бу халәтенә дә күнекте, күнде, чөнки аның яшьтәшләре, чордашлары һәммәсе дә шушы юлны үтәләр иде. Шул юлга кермисең икән, әнә Гафур кебек кеше кулы астында ярым кол хәлендә яшисең дә яшисең. Шәп квартирың да, татлы ризыкларың да, мөмкинлекләрең дә юк... Әллә Гафур талантсыз идеме? Асафка караганда күп тапкырлар талантлырак, сәләтлерәк, белемлерәк, зиһенлерәк иде. Киртә ватып алга ыргылырга маташканнарны, җәмгыятьнең язылмаган законнарын бозып, серне читкә чәчкәннәрне, телләренең урыннарын белмәгәннәрнең чәчрәп егылып төшүләрен Асаф күреп торды, күрде дә ачы сабак алды. Аның ялгышлары да булгалады, андый чакта аны читкә тибәрмәделәр, ярдәмгә килделәр, төзәттеләр, йомшак кына аркасыннан кактылар һәм ул барырга тиеш юлны гел күрсәтеп тордылар.

Кул-кулны юды, ике кул битне...

Әгәр тормыш рәхәтләрен ике куллап умырырга сәләтең бар икән, безнең кебек бул!

Үзе белмәгән, гомерендә бер тапкыр да күрмәгән әллә кемнәргә байтак ярдәм күрсәтте Асаф, яхшылык эшләде. Тора-бара элек вак-төяк саналган кешеләр калкып, ныгып килеп чыктылар һәм шул чакта да Асафка кылган яхшылыклары өчен рәхмәт әйттеләр. Рәхмәтләре бер чакта да коры сүз булып кына калмады. Алар илне, дәүләтне ачыктан-ачык таладылар, милләт байлыгын теләгәнчә бүлештеләр, күпчелек халык өлешеннән иң зур калҗаны умырып, халыкка калган вак-төякне зур бүләк итеп тапшыра белделәр. Без иң алдынгы, иң бай, иң рәхәт илдә яшибез, иң якты кояш бездә генә, безнең илдә генә иркен сулап була...

Сулышынны Казанның йөзләгән химия заводлары, фабрикалары буыпбүлеп торса да гыжлаган бугазлар һаман тартар кебек бер җырны суздылар: безнең илдә генә иркен сулап була...

Халык Асаф ишеләрне данлап, аларга мәдхия җырлап яшәде. Аларның портретларын күтәреп, бик бәхетле булырга тырышып, мәйданнарда «Урра!» кычкырып йөрделәр, аларга табындылар...

Асафның бердәнбер юанычы, куанычы Гөлсинә булган икән...

Аның кара язмышының күгендә бердәнбер якты йолдыз булган икән авылның гап-гади шәфкать туташы... Шәфкать-мәрхәмәт, яхшылык дигәнне тәмам онытып, аны үзгәртеп аңлаган, эшендә-хезмәтендә гарипләндереп кулланган Асафны чын тормыш белән бәйләп, тоташтырып торган бердәнбер җеп булган икән. Ефәк җеп, саф җеп!..Асаф эченнән генә Гөлсинәнең мәхәббәте белән куана да иде. Суфиянын чырае көл төслегә әйләнеп ачуланганда, карлыккан тавышы белән аңа җикеренгәндә, ул башын тилегә салып, аңа чекерәеп сүзсез генә карап тора ала иде. Аның күңелендә: «Синең беркемең дә юк бит, ә мине менә дигән кыз сөя! Ул меңнәр арасыннан мине сайлады! Ул миңа тугры! Ә мин чын мәхәббәткә хуҗа!» дип уйлый иде.

Гөлсинәнең мәхәббәте аның коралы, күтәрәм дип үзен изгән бик күпләргә ачы җавабы да булган икән...

Асафның тормыштагы тотанагы шул, бердәнбер изге җан булган икән!

Суфиялар оясы аркасында ул ата-анасыннан ераклашты, тора-бара бөтенләй аерылды. «Оныт аларны!» диде аңа язмышы һәм ул аларны онытты. Ата-ана белән янәшә балачагы хәтердән төшеп калды. Үткәннәре, яшьлеге, үсмер чагы, авылы хәтер чоңгылында юкка чыкты... Чордашлары, зур дәрәҗә алып, җитәкче урыннарда утырганнар үз яшьлекләре белән, вакытын белеп кенә горурланганда, Асаф авызына су кабып кына утыра торган булды. Кемнәрдер яшьтән үк бәхетле йолдыз яктысына эләккәннәр. Берәүләр чит илдә туган, икенчеләренең ата-аналары профессорлар, күренекле врачлар.

Генераллар белән аралашканнар, махсус мәктәпләрдә укыганнар, өч-дүрт яшьтә шәһәрнең иң яхшы белгечләре аларны музыка дөньясына алып кергән, опералар тыңлаткан, балетлар белән таныштырган. Алар шәп-шәп киемнәр киеп бик яшьли шугалакка барганнар, хәлләре китсә кайнар кофе белән ак май яккан күмәч ашаганнар, шуу ярышларында катнашканнар, күбәләк булып бөтерелгәннәр, бассейннарда коенганнар, җәйләрен гаилә-гаилә булып төйнәлеп Кырым, Кавказ якларына киткәннәр, Кара диңгезнең шифалы җилен иснәп бакча күләгәләрендә ятканнар, оҗмах җимешләре ашап, дәвалы сулар эчеп сәламәтлекләрен ныгытканнар. Шулай итеп киләчәк тормышларына әзерлек чараларын күргәннәр.

Мескен Асаф!Бераз төшереп алгач аның да мактанасы килә, аның да яшьлеге булган ич, яшьлегендә ул да кемнәр беләндер аралашкан... Ләкин алар арасында бер генә мәшһүр кеше, атаклы шәхесләр булмавы да аны кимсетә иде. Яшьлегендә аңа беркем дә: «Син шулай бул! Шулай яшәргә әзерлән! Шул сукмактан барсаң гына туры юлга чыгарсың!» димәгән. Беркем дә аның яшь чагындагы әвәслеген, һөнәрләрен күреп «Синнән фәлән һөнәр иясе чыгар!» дип дәртләндермәгән...

Гомер үткән, Асафка хәзер кире кайту юк, яшь гомер ике килми, ул бәхетле чордашлары яшьлектә татыганны берчакта да күрмәячәк. Шушы көнчелек корты аны гомере буе явызландырды, ул үз балачагына, яшьлек юлдашларына җирәнеп, кимсетеп карый башлады. Нәсел-нәсәбеннән югары белемле ник бер кеше булсын ичмасам! Берсе умартачы, икенчесе балта остасы, өченчесе яшелчәче, дүртенчесе... авылда аяк киемнәре ямаучы... Мичкә ясау, тугым бөгү осталары бар, тире иләүче дә юк идеме икән әле, хәзер онытылган. Бүтәннәр Европа, Кырым, Кавказ, Сәмәрканд, Бохара манаралары белән мактанганда бер күзе чалыш атаклы тимерче Мифтахетдин белән мактанып кара инде син! Исеме үк ни тора... Мифтахетдин? Тьфу!

Шуңа күрә малаена ул Эдуард исеме кушты, чит илдә ясалган ялтыр тәгәрмәчле арбада, ефәк арасында чумдырып кына яткырды, алдыннан Америкадан килгән ананас, бананнарны өзмәде. Көчләп-көчләп баласының авызына кара икра, кызылын тыкты, кәнфитнең Мәскәү фабрикаларында эшләнгәнен, Казанның кат-кат киштәләр астында сакланганнарын гына ашатты. Рәчәй туфрагында тегелгән кием кигермәде. Бик кыйбат бәягә укытучы яллап чит тел өйрәтте. Спорт мәктәбенә машина белән илттерде, алып кайтты. Улын слетларда байракчы итәргә кушты, барабан кагарга, быргы кычкыртырга күндерде. Һәммәсен эшләде. Тик бер нәрсәгә ирешә алмады: бала атаны яратмады. Бала зиһенле иде, әткәсенең бу дөньяда хезмәтче, лакей министр булуын яшьтән төшенде. Ир бала атанын бил бөгүен, ялагайлыгын бер чакта да кичерә алмый, аңа батыр әти, матур әни генә кирәк. Асаф улы белән артык мавыгып, Эдуардның үзеннән ераклашканын абайламады. Ул улының ераклашканын абайлаганда бик соң иде инде. Үсә төшкәч Эдуард әйтеп салды: «Старик, үз тормышыңны да юньләп кора алмагансың, министр булсаң да плебей син, чабатаңны салырга онытып түргә узгансың, миңа сабак биреп маташма инде син!Кирәк икән, киңәш сорап кил!» диде.

Суфиядан, аның ата-анасыннан, туганнарыннан, әрсез танышларыннан күпме түбәнсенгән, авыр сүзләр ишеткән, чыгышы өчен мең тапкыр ялгыз кыйналган Асаф Сәхиповичның болай кимсенгәне юк иде. Күлмәк якасы муенын буа башлады, кигән киемнәре гәүдәсен кысты, ул шартларга җитте... Әле Суфия белән талашып була, «Син үзең дә шундый!» дип тел чыгарып кимсетергә була, ләкин колга буе үскән, чит телләрдә шытырдатып сөйләшкән, Гоген белән Сесләйны аера белгән, музыкада бүгенге көндә өстенлек иткән бөтен ансамбльләрне, аларның үзенчәлеген, өстенлеген яки түбәнлеген су кебек эчкән яшь егеткә каршы чыгарлык дәлилләр үзендә юклыгын Асаф Сәхипович аңлады...

Малай да әкрен-әкрен читкәрәк китте, югалды, яши-яши алар атналар буе сөйләшмәс булдылар. Квартирасынын сабан туе мәйданы хәтле булуына Асаф Сәхипович шунда куанды, теләмиләр икән—очрашмыйлар...

Кеме калды Асафның? Нинди куанычы бар аның бүгенге көндә? Алтмышка ике адым калган, гомер тәгәрмәче иллedән соң тиз әйләнә, хәзер барып җитәчәк ул аңа. Яшь чагында хисчән булган кешеләр картлыкка авыр барып керәләр. Алар картлыкта ялгыз калудан, очраклы чир-чорлардан, иртә үлемнән курка башлыйлар...

* * *

Суфия һич тайчанмыйча, каушамыйча үзенең эч серләрен ачты да салды, димәк бүген чыгарган уйларын ул байтактан әзерләп килгән, уйланган, нигезләгән, дәлилләгән, һәм Асаф Сәхиповичның кыен вакытын көтеп торган. Мә, сиңа! Каршы килеп кара, ни эшли аласың? Кая барасың? Аңа нибарысы министр ир генә кирәк! Һәр иртәне кара «Волга» килеп ала торган, тормышта быел башагын, киләсе елда шалканын умыра торган, басымчак, телсез-тешсез, матур, мәһабәт, чит ил киногеройлары, банкирлар, эре фабрика хуҗалары кебек киенгән, өч сәгатькә өч акыллы сүз генә әйтә торган акыллы ир кирәк... Яшь чагында ул Асафның нинди кыяфәткә керергә тиешлеген ярым шаяртып аңлатып биргән иде. Хәзер туп-туры күзгә карап, кан качкан юка иреннәрен кыса-кыса әйтеп салды... Хәзер Асаф, алтмышка килеп җиткәндә, аннан беркая да китә алмый, ул хатынының бәйдәге эте, кулга ияләштерелгән маймылы. Теләсә үзен сакларга боера ала Суфия, теләсә мәтәлчек аттыра...

Асаф чордашлары, яшьтәшләре турында уйлады. Аның тирәсендә, аның дәрәҗәсендә, яки аннан югарырак, түбәнрәк кешеләр җитәрлек иде. Мисалларга таянсаң тынычланырга да була, күпчелек нәкъ Асаф яшәгәндәй яшәде, балда-майда йөзде, дөнья дилбегәсен кулыннан ычкындырмады. Тик нигә соң Гафур бүтән юл сайлады?.. Нигә Шеварднадзе ике бүлмәдә яшәп яткан? Үзәк комитет секретаре? Асаф аңламаган нинди бәхет белән куанганнар алар, тормыштан нинди ләззәт тапканнар? Нинди Аллага, Иманга баш органнар? Җүләрме алар? Әллә Асаф Сәхиповичлар тилеме?

Балачагына, яшьлек дусларына, нәселенә хыянәт иткән булып чыгамы әллә? Кайчаннан башланды бу хыянәт? Әллә яшь чагында ук хыянәткә әзер идеме инде ул? Бер гадәтләнгәч хыянәт тә рәхәтлек кенә китерә диләр бит. Хыянәт тә аракы кебек, наркомания сыман үз богавыннан җибәрми, хыянәт кешенең иманына, аның табигатенә әйләнә диләр.

Бәхет дип юанып йөргәнең газап булып чыгып, корган ташпулатның нигезе ком булса, сайлап алган, ышанып барган сукмагың упкынга барып төртелсә, кеше нишләргә тиеш?

Нинди юанычы калды Асаф Сәхиповичның?..

Ата-ана аңа гомерлек газап-ымнар, ишарәләр калдырып бу дөньядан күчтеләр. Атасы өчен махсус зират—Акъюл авылының читендә, керәшен качалары янәшәсендә аерым зират ясаганнар! Яшь чагында урман юлы читендә, известь базлары казыганнар иде берзаман. Шунда, метр ярым тирәнлектән, кызыл, үзле балчык катламыннан кеше скелеты килеп чыккан иде. Бала-чаганы куркытып, өлкәннәрне уйлы сискәндереп баш сөяге, тешләрен ыржайтып күз урыннары белән күзгә карап баз кырында шактый уралып йөрде әле. Кем гәүдәсе булган ул? Ни өчен аны ят җиргә, тау битенә, кызыл балчык катламына тыгып калдырганнар? Авылда моны берәү дә белә алмады...

Онытылган иде! Истә дә сакланган икән! Асаф Сәхипович тирән базны, базның бер читеннән агарып торган кеше сөякләрен бүгенгедәй күз алдына китерде.

Әллә Гөлсинә мәхәббәте белән алданып, юанып яшәдеме ул?..

Хәзер менә Гөлсинә дә юк. Әллә больницага барасы калганмы? Юк, юк! Больницасы больница булса икән! Аннары, эш милициядә дә ята бит әле! Анда Асаф Сәхиповичның Гөлсинә белән булган мөнәсәбәтләре апачык... Хәзер аны күзәтеп торсалар, барып тикшереп йөрүен гаепкә алсалар?! Юк,юк.

Төне буе йокламады Асаф Сәхипович атасы йортында. Тәрәзәләргә сак кына кагылып җил исте. Җил туктаган араларда йомшак кар яуды. Капка төбендәге машина эзләрен кар күмде. Асафның нык, авыр гәүдәсе калдырган чуар эзләрне дә төнге кар ялмап йотты. Керәшен зиратының бер читендә, киртә белән әйләндереп алган аралыкта тыныч кына йоклап яткан Сәхип Зәкиевнең йорт-курасы ак шәл ябынды. Бу йортта җан иясе бардыр дип беркем дә уйларлык түгел иде. Кичтән мич ягып, өйне май иткән, тәмле ризыклар әзерләп калдырган, Асаф Сәхиповичны хөрмәтләп, кадерләп көткән әдәми зат кайтмады. Ул да юк иде...

Балачакка, яшьлеккә кайтыр өчен бер төн җитәме?..

Яктылык тизлеге диләр... Физикларның хыялы шул: яктылык тизлегенә хуҗа була алсалар әллә кай планеталарга китеп, әйләнеп кайтырлар иде алар. Галәм серен, җирнең-күкнең җиде катлавын тапкырлау җәдвәле кебек исәпләп бирерләр иде...

Уй тизлеге дигән төшенчә дә бар, аңа бар нәрсә дә иярә, тигезләшә алмый, уй—галәмнәрне, ерак планеталарны әллә кайчан гизеп кайткан инде, гашыйкларның уе бер кичтә айга менеп төшә, йолдызларга барып житә. Сагышланганнарның уе бер мизгелдә таулар кичә, дингез-дәрьяларны бар дип тә белми... Аналарның уе уллары кайда булса да теләгән минутларында алар янына барып җитә. Уй тизлеге кешеләрне яшәтә, аларга өмет өсти...

Дөнья йөзендә бүгенгә япа-ялгыз калган, ялгызлыктан куркынган Асаф Сәхипович уйга тотынып яшьлегенә кайтып китте... Башта хатирәләр өзек-өзек кенә булса да ул аларны тоташтырырга, ялгарга тырышты.

* * *

Алар Акъюл авылына көзгә таба күченеп килделәр. Әтисе көне-төне диярлек мәктәптән кайтмады, әнисе җәй буе буш торган мәктәп квартирасын кышка әзерләде, бүрәнә җекләрен эчтән, тыштан сылады, мичне агартты, мәктәп җыештыручыларны чакырып түшәмне кырып юдылар... Аннан кыш башланды. Кыш бик озын һәм салкын иде. Асафларның өйләре өстендә дәү-дәү ботакларын сузган иләмсез зур тупыллар кыш буе яман уладылар. Ят авылда, ят кешеләр арасында Асафны үзен генә урамга чыгармадылар да диярлек. Аларның өйләре мәктәп ихатасында, ишегалларында ат сарае, пожар мичкәсе куелган лапастан башка бер нәрсә дә юк диярлек. Ә, кое бар икән! Ул шундый тирән! Кое янына да җибәрмиләр Асафны, Аманат исемле алаша да тешли икән, тибә дә ди...

Яз җитте, көндезләрен тып-тып тамчы тамды, тәрәзә пыялалары кар абагалардан, сихри чәчәкләрдән арынып, тәрәзәләр ялт итте. Иртәләрен өй кыекларына тезелешеп боз сөңгеләре асылынды. Асаф чыга да читәннән озын таяк суырып алып шул сөңгеләрне шыбырдатып коеп ватып йөри. Үзе бертуктаусыз тыелгысыз кычкыра:

—Иһи, һи!

Бер мәлне таяк озынаеп китте дә боз арасына челтер итеп пыяла коелды. Малай ялт итеп кабык бәдрәф артына барып качты. Тәрәзә пыяласының ике каты да челпәрәмә килгән иде. Әнисе тишектән нидер кычкырды да, тәрәзәне мендәр белән томалап каядыр чыгып китте. Тиз арада зур якалы чикмән кигән, авызына кап-кара ямьсез челем капкан, сары бөдрә сакаллы кешене ияртеп кайтты. Кеше култык астына юка гына киң тартма кыстырган иде. Ул тартмасын болдырга куеп, аннан пыяла тартып чыгарды. Пыяланы ипләп болдыр тактасына куйды һәм өлгене кат-кат үлчәгәч пыяла кисәргә тотынды. Аннан алар өйгә керделәр. Асаф та мыштым гына аларга иярде. Кешенең чикмәненә дә, пыяла кискеченә дә әлләни исе китмәде Асафның, аның игътибарын Кешегә ияреп килгән малай биләде. Ләкин малай Асафка әйләнеп тә карамады, әтисе тирәсендә маташкан булды. Аның башында дәү колакчын куян бүрек, өстендә билле тун, кулында да дәү-дәү бияләйләр иде.

Бөдрә сакал пыяла куярга тотынды, кылыч борын өстенә бөрчек-бөрчек тир чыкты. Малай борынын мышкылдатты.

—Улым,—диде бөдрә сакал.—Бар урамда уйный тор.

Малай белән баскыч төбенә Асаф та чыкты. Алар каш астыннан берберсенә шактый вакыт карашып тордылар.

—Синең исемең ничек?—дип сорады Асаф.

—Сатый,—диде малай.

—Андый исем булмый,—диде Асаф киреләнеп.

—Ә синең?—дип кызыксынды малай ачуы чыгып.

—Асаф.

—Китчәли,—дип чәрелдәде малай кыюланып.—Андый исем безнең авылда юк та әле. Ә Сатый бар, Сатукай да бар.

—Син керәшенме?—диде Асаф.

—Керәшен.

—Ә без татарлар. Минем әти укытучы!—Малайның Сатыйдан өстен каласы бик килә иде. Сатый танавын тартып тәрәзәнең теге ягында бик житди, бик кирәкле эш белән маташкан әтисенә карап куйды һәм Асафның кабыргасына китереп төртте: «Күрәсеңме минем тәтәнең кем икәнлеген!»

Кызык, ул әтисен «тәтә», ә әнисен «нәнә» дип йөртә икән...

Гаҗәп тоелды бу Асафка! «Тәтә, нәнә!»

Алар килеп төшкән авыл тоташ керәшеннәр икән, моны улына кич белән әнисе сөйләп бирде. Асафка бу хәбәр бер дә ошамады, ул:

—Нигә, без монда торабызмыни инде?—дип сорады.

—Укытырга әтиеңне монда җибәрделәр,—дип аңлатты әнисе елмаеп.—Ияләнерсең, улым.

Җәй житте, Асаф урамнарга чыгып йөри башлады, бер көнне Сатый аны су чумырга алып төшеп китте. Инеш тар гына елга, кызу ага, борылышларда таллар, тал асларында шактый тирән тугайлары бар икән. Малайлар якынлаша башлагач бакалар чулт та чулт суга сикерешә башлады. Башта малайлар аларны таш ата-ата куып йөрделәр. Асаф бакаларны бик кызганса да яңа юлдашларыннан, керәшен малайларыннан куркып аны-моны әйтеп тормады. Көн эссе, жилсез, кояш аяусыз кыздыра, күлмәк-ыштаннар чөелеп һавага очты, малайлар тугайга кереп тулдылар. Китте су чәчрәтү, әүмәкләшү, төртешү, чуму, елга өсте чыр-чу белән тулды. Су чумынып аргач малайлар берсе артыннан икенчесе тәжел-тәжел ишелеп ярга чыктылар һәм авызларын учлары белән каплап ярыла-ярыла көлергә тотындылар. Күзләр Асафның бот арасына төшкән иде.

—Күр!

—Кара!

—Кискән!

—Әй, гарьлек!

—Татар бит ул!

Асафның теше тешкә тиеп калтыраса да сер бирмәскә тырышты, тизтиз киенеп өенә чапты. Сатый белән алар көненә биш талаштылар, биш татуланыштылар. Бер талашканда Сатый:

> Татар, татар, тарама,
> Кермә безнең арага,
> Кысылырсың, үләрсең,
> Биш тиен акча түләрсең,

—дип такмаклады.

Асаф үкереп елап өенә кайтты.

—Әни, нигә без бу авылда торабыз?

—Тагын ни ошамады?

—Керәшен малайлары мине ижекли.

—Үзең керәшен сүзе отып кайткансың әле. Татарлар «үрти, үртәшә, үчекли»,—диләр. И-и, балам, керәшеннәр шул ук татарлар, бик әйбәт халык, Аллалары гына башка!

Малайның колагы үрә торды.

—Син Сатыйларга кергәч түр почмакларына кара, шунда тәре почмагына

куелган сакаллы бер бабайны күрерсең. Керәшеннәрнең Алласы әнә шул булыр.

Асаф, әлерәк кенә пыр тузып талашып кайткан булса да Сатыйларга чапты, башта ишек катыннан гына серле почмактагы сурәтләрне тамаша итеп торды, кыюланып түргә атлады. Төрле үләннәр, кәгазь чәчәкләр белән мул бизәлгән киштәдә, пыялалы рамнар эченнән ике бармагын югары күтәргән моңсу бабай белән, бәбәен күкрәгенә кыскан олы күзле чибәр апа ана текәлеп карап торалар иде. Киштә астына уртасына нәни генә кара тәре чигелгән ак чүпрәк эленгән иде. Алача күлмәк, өр-яңа ак чабата кигән Ипис түти—Сатыйның әнисе, япа-ялгызы тәре почмагына текәлгән малайны сәерсенеп күзәтте.

—Болар кемнәр?—дип сорады Асаф курка-курка.

—Алла бабаң белән Мәрьям ана,—диде дини мәгълүматләре шуннан узмаган Ипис түти.

—Ул чүпрәк нигә?

—Чүпрәк түгел, тәре алъяпкычы, күңел аклыгының билгесе!

Ишегалдында Асаф белән Сатый тагын очраштылар.

—Керәшеннәр шул ук татарлар,—диде Асаф мактанып.

—Каян белдең?

—Әни әйтте.

Сатый сүзләшеп тормады, мактанырга ук кереште.

—Без керәшен, чиркәүгә йөрибез. Нәнә мине дә алып барды. Әй җырладылар анда! Түрдә Алла бабайның балавыздан койган сыны бар. Шундый дәү! Поп миңа дару эчертте. Шундый тәмле. Алтын чәркәдән көмеш калакка сала да тел өстендә йөгертеп җибәрә. Бөтен балаларга эчертте. Ә мин ике тапкыр элдердем!..

Малай Сатыйларга күнегеп китә, Сатый өйдә юкта да барып керә. Бер баруында Ипис түти чәчен тараган да тәрәзә пыяласына көзге итеп карап мәләнчеген бәйләп маташа. Асафның хатыннарның ике мөгез кебек бүлтәеп торган мәләнчекне элек тә күргәне бар иде, хәзер Ипис тутасының һәр хәрәкәтен йотылып күзәтеп торды.

—Бу нигә?

—Матур булсын өчен.

—Болай матур буламы?

—Бүген урыс атнасы, бәйрәм көн!

Асаф тәре почмагына борылып карады. Сурәтләрнең ике ягында да шырпыдан әз генә юанрак сары шәмнәр яна, Аллаларының күзләре тагын да моңсуланып, серләнеп калган иде.

Түр почмактагы тәреләр, ава-түнә утырган шәм утлары, мәләнчек бәйләгән Ипис түти генә түгел, бәләкәй, елгыр керәшен баласы Сатый да Асаф өчен үзенә бер төрле серле табышмак иде хәзер. Ул әнисеннән:

—Ә татарларның Алласы кайда?—дип сорады.—Минем аны да күрәсем килә.

Асафның әнисе, заманында Кәшер кызлар мәктәбендә иң зиһенле, иң акыллы саналып йөргән Мөнәвәрә, хәзерендә татарча чыккан китап-журналларны су кебек эчеп бара торган ханым тере җанлы улының туптуры куелган соравы алдында читенсенеп калды. Ипис түти кебек «Бусы Алла бабаң, бусы Мәрьям ана» дип җавап бирә алмады. Ул Мөхәммәт пәйгамбәр хакында сөйләргә җыенды, мәгълүмате җитмәде, Гайсә пәйгамбәр, күкләр, оҗмах-тәмуглар хакында сөйләргә тырышып карады, барып чыкмады. Чыннан да татарлар Аллаларын кая куйганнар сон?..

Асаф әтисенең мәктәптән кайтканын түземсезлек белән көтеп торды, ләкин ул көнне инспекторлар килеп төшкән икән, директор педсовет үткәргән, әтисе бик соң гына кайткан. Иртәнгә Асаф бу сорауны оныткан да иде инде. Таннан күзен ертып Сатый килеп җитте, яңа урыннар, яңа уеннар, яңа иптәшләр малайны бөтереп үз арасына алып кереп китте.

Сатыйның әтисе Парпылый дәдәй инбашы түбәнгәрәк төшеп торганга яны белән йөри, башта аның һаваны сөзеп, «менә егылам, менә егылам» дип атлап баруы Асафка көлке кебек тоела иде. Бара торгач алар бик

якынаеп киттеләр. Парпылый дәдәй мәктәп атын карый, Асафларга мичкә белән су китерә, ишегалларын себерә, бер дә тик кенә тора алмый иде. Конюх та ул, завхоз да ул, шулар өстенә колхоз эшенә дә чыгарга өлгерә.

Бер көнне Асаф Сатыйларга барып керсә өйдә Парпылый дәдәй берүзе генә утыра иде. Тәрәзәне ачкан, тәрәзә каршысына урындык китереп куйган да гармун уйнап утыра. Гармунын да үзеннән ерак тота, тез башына куйган. Унике телле, өч бакалы тальян. Асаф гармун тавышын урамнан ук ишетте: матур иде тальянның тавышы, моңлы иде, көе дә әллә ничек күңелне тетрәндереп, жирсетеп жибәрде. Кем уйнар икән шулай матур итеп?..

Парпылый дәдәй гадәттән тыш җитди иде, аның куе кашлары җыерылып кушылган, күзләре билгесез бер ноктага карап текәлгәннәр. «Нәрсә күрә икән анда?»дип Асаф Парпылый дәдәсенең күзе юнәлгән якка тырышыптырышып караса да берни күрмәде... Менә ул көен уйнап бетерде, иненә салган гармун каешын салып, күрек өстенә өреп алды, аннан соң гына малайга карады.

—Бу көй «Казанны яу алу» көе дип атала... Матурмы?

—Матур,—дип пышылдады Асаф.—Тагын уйна әле, Парпылый дәдәй.

Хуҗа ялындырмады, тагын каешны иңенә чөеп, гармунны тезе өстенә генә тотып уйнарга тотынды. Шул ук тетрәндергеч көй яңгырады.

—Син бүтән көй белмисеңмени?—дип сорады Асаф.

—Моннан башка көй була да алмый... «Казанны яу алу»көе дип атала бу. Безнең бабайларның бабалары Казан тирәсендә яшәгән. Грозный патша килеп яу белән Казанны алгач татарларны ул яклардан куганнар... Безнекеләр шушы якларга качкан... Монда ул чагында кап-кара урман булган әле... Бабайлар ышна әрчегәннәр, агач егып өйләр салганнар, төпләрне яндырганнар. Умарта асраганнар, тереклек итә башлаганнар. Бер заман ак патша солдатлары безнең авылны килеп тапканнар. Солдатларга ияреп поп та килгән, авылны көчләп чукындырганнар. Чукынырга теләмәгәннәр безнең бабайлар. Көндез аларга поп вәгазь укыган, төннәрен бабайлар ындыр артына җыелып Коръән укыганнар, «коткар безне бу бәладән!» дип Мөхәммәт пәйгамбәргә ялынганнар... Тик пәйгамбәр ерак булган, аларны ишетмәгән. Акпатшага баш бирмәгәннәрне, попны тыңламаганнарны авылдан сөреп алып киткәннәр. Чукынмасагыз авылыгыздан сөрәбез дип куркытканнар... Шулай итеп без керәшен булып киткәнбез.

Парпылый дәдәй сөйләүдән тукталып тагын гармунын тез башына күчерде һәм гарип иңен чак-чак сикертеп тагын бер кат «Казанны яу алу» көен уйнап җибәрде...

—Әти,—диде кич белән Асаф.—Минем гармун уйныйсым килә. Ата белән ана бер-берсенә караштылар, алдагы якшәмбедә үк, атаклы Биш авыл базарыннан Сәхип Зәкиев улына унике телле, өч бакалы, шушы якның атаклы гармун остасы Шәрифҗан ясаган тальянканы алып кайтты. Бер уйнар да куяр дип уйлаганнар иде, алай булмады. Асаф атна-ун көн гармуннан аерылмады, йоклаганда янына куеп йоклады, өй түбәсенә менеп тә шырылдатты, мәктәп бакчасына да кереп уйнады... Иң беренче чыгарган көе «Дулкын» булды... Ул Парпылый дәдәсе янына барды:

—Миңа да теге көйне өйрәт әле, Парпылый дәдәй,—диде.

Парпылый малайга сокланып карап торды, аның кыска итеп алынган башыннан сыйпады.

—Ул көйне отарга, уйнарга чак кына үс инде... Ул көй бит, ни... Бабайдан отып алдым мин аны! Чак кына үсә төш, мин сиңа өйрәтермен аны.

Әле вакыт көннәргә, айларга бүленмәгән чак, еллар да саннар белән беркетелмәгән хәлдә үтә тора. Асаф кышын Акъюлда яшәсә дә, язга чыккач аны Туганай авылындагы бабасы алып китә. «Әйдә, татар ягының исен дә иснәсен!»—дип шаярта бабасы. Татар ягы—кыр ягы, анда мичкә кизәк, торф ягалар. Текә бер тауны менеп җитеп, киң үзәннәр, арыш уҗымы калкынган инкүлекләргә керүгә үк кыр ягы исе—кизәк исе, кизәк төтене исе килә башлый. Туганай авылына якынлашкан саен бу ис куера, борыннарны рәхәт кытыклап әллә ниләр уйлата. Авыл очына кереп бара башлауга

ук мәчет манарасы , мәчет янындагы биек-биек тал-тирәкләр күренә башлый, чәүкәләрнең чыркылдавы ишетелә...

Акъюл авылында хәзер алар үз кешеләр. Әтисе көне-төне мәктәптә, аны завуч итеп тә куйдылар, әнисе керәшен апаларына җөй тегә. Асафның энесе тугач әнисенең мәшәкате күбәйде. Алар малайны Туганай авылына иртәрәк тә җибәрә башладылар. Туганай авылында әнисенең әтисе яши. Бик карт инде ул. «Үзем исән чагында безнең өй тәртипләрен дә күреп калсын!»—дип Зариф карт Асафны кар китүләргә үк алып киткәли башлый. Акъюлдан, уймакланып җитез аккан инештән, Сатыйлардан бер дә аерыласы килми Асафның, бабасына каршы да килми. Әбисе пешерә торган биш тиенлек бакыр акча хәтле тәмле коймаклар да хәтергә төшә. Хәтергә төшә дә авызга сулар килә...

Җәй уртасы җиткәч кенә әйләнеп кайта Асаф Акъюл авылына. Ә Сатый, ә Сатый... Курешүгә тәтелдәргә тотына, һич туктатыр әмәл юк. Туктатасы да килми Асафның, Сатый кызыктырып әллә ниләр сөйли белә...

—Әй, малай, Олы көнне булмадың син!

—Нинди Олы көн?

—Бәйрәм! Олы көндә Исус Кристус терелеп туган. Бөтен кеше бәйрәм итте. Күкәй маналар, шишара пешерәләр. Ә мин караңгыдан ук күкәй җыярга чыгып китәм. Өй борынча очтан-очка йөрим... Учып дәдәйләргә кадәр барып җитәм. Аларның этләре... Коерыгы көлтә хәтле. Башы ярма ташы дәүлеге. Бөтен кешене тешли, пучты Учтинәнең ботын тешләп канаткан. Миңа тими! Учыпларга бирәү дә керми, ә миңа алар ике күкәй бирделәр. Киндер капчыкны тутырып ук алып кайттым.

Асафның күз алдыннан бер капчык күкәй җыеп кайтучы Сатый үтеп китте, боекланды, көнләште.

—Аннан, аннан...—Тагын ниләр булды анда?

—Аны кем сүләп бетергән? Менә киләсе Олы көндә авылга кайт. Татарларда Олы көн буламы?

—Юк.

—Безнең Аллабыз Исус түгел бит.

—Нәнә әйтә, татарларның Алласы юк, алар тере кешегә башыралар ди. Бармы сезнең Аллагыз?

—Белмим,—диде Асаф тагын боегыбрак... —Ул киләсе елда Олы көндә ничек булса да монда калырга күңеленнән ныгытып куйды. Сатыйга:— Яренгә мин дә күкәй җыярга чыгам. Бергә чыгабызмы?—диде.

—Бергә ярамый. Һәр кеше үзе генә йөри.

—Сезнең авыл этләре мине танымый шул.

—Ә мин сине бүгеннән этләр белән таныштырып бетерәм...

Һәм Сатый Асафны өй борынча диярлек йөртеп, этләр белән таныштырып, дуслаштырып куярга булды. Әшне Учыплардан башларга булдылар. Учыпларның өе елгага янәшә, бакчалары авыш, аргы баштагы киртәләрне язгы ташу алып китмәсен өчен, ул якка тыгызлап агач утыртылган, тал-тирәкләрнең кайберләре киңәеп үсеп киткәннәр, бүтәннәре кысрыкланып шунда, аста калган, кәкрәйгән, бөкрәйгән.

Учыплар капкасына барып кагылулары булды, эчтән яман өреп, ярсып сикерә-сикерә эт килеп тә җитте. Сатый гаярьләнеп капканы ачкан иде, Асафның күзе этнең ачык авызын, ырҗайган тешләрен күреп өлгерде. Малай йом булды, үкчәләре генә ялтырый.

—Әни-и!—дип кычкырды.

Сатыйга нәрсә, көлтә коерыгын болгап янында йөргән этнең сыртын сыйпап авызын ерып тора.

—Юк,—диде Асаф,—мин күкәйне мәктәп тирәсендәге өйләрдән генә җыям.

Сатый аны куркаклыкта гаепләде, бүтән этләр белән танышырга кыстады, алар Югары очка менеп киттеләр. Югары оч Аклан чирәме дип аталган болынга чыга, ә болында кузгалаклар, әнисләр үсә. Киттеләр. Авылны чыгуга ук юл читендә ялгыз каен үсеп утыра иде. Каен янында гына агач баганага

шалаш кебек кыеклап такта кадаклаганнар, аның авызын кара тәре чигелгән яулык белән томалаганнар. Асаф гаҗәпсенеп иптәшенә карады:

—Нәрсә бу?

—Чәчәүник. Юлга чыгарга баручылар Алла бабайга баш ыралар, иман сорап чәчәүниккә акча куялар.

—Акча?—Асаф аны-моны уйлап тормастан тәреле яулыкны бер якка каерып эчкә карады. Чыннан да такта өчпочмак киштәсендә байтак акча җыелган иде, бакырлары бар, сирәк-мирәк көмеш тәнкәләр дә елтырый.

—Тимә!—дип акырды Сатый.—Кагыласы булма. Күтең кутырлар. Телсез калырсың. Алла бабай акчалары алар.

Асаф пәрдәне япканын сизми дә калды.

—Бу акчаларны беркем дә югында, айның ундүртенче кичәсендә фәрештәләр генә килеп ала.

—Алар аны кая куя?—диде куркып Асаф.

—Кая куйганнарын әйтеп тормый алар, анысын берәү дә белми. Минем нәнә дә белми әле,—диде Сатый.

Асаф чәчәүникнең авыл тирәсендә берничә булуын белде, зират янында да бар икән ул, чишмә башында да кыйгаеп утыра. Чишмә янындагысының акчалары юк иде.

—Менә, фәрештәләр алып киткән!—диде белдекле төс белән Сатый. Бик тырышып та гармуннан бер көй чыгара алмаган малай, Асафның тальянкада ару гына сиптерә башлаганыннан бик көнләшә иде, хәзер үз сүзен өстен чыгарырга форсат табылгач, ул Асафка бу хакта кат-кат сөйләде.

—Әйдә, берәр төнне сагалап торыйк,—диде Асаф.

Сатыйның күзләре түп-түгәрәк булды:

—Учыплар этеннән коты ботына житкән кеше фәрештәләр күргәч табутка кереп ятыр,—дип көлде.

Малайлар ике көн сөйләшмәделәр, аларның болай озакка әчелешле булганнары юк иде...

Асаф өй түбәсенә менеп гармун тартырга ярата, кыек башында нәни генә тәрәзә бар, ул шуны ачып куя, ачык тәрәзәдән гармун тавышы, бакча янынннан үткән тыкрыкка барып ишетелә. Үзе уйный малай, үзе күз кырые белән генә тыкрыкны күзәтә. Үтеп йөрүчеләр аның уйнаганын ишетәләрме? Кем уйнаганын беләләрме икән? Ишеткәннәр кай арада тынлап тукталып калалар. Малайның йөрәге сикерә башлый, шундый нык сикерә, Учыплар этеннән сыпыртканда да болай ук сикермәгәндер...

Асаф күреп тора, Сатый аларга таба килә. Асаф тәрәзә янынннан кача, гармунын тагын да ныграк кычкыртып уйный башлый, бакалар аның бармаклары астында сикерешүдән туктамыйлар. Әле бер көн шома көпшә ашаганда бер бармагын үткер пычак белән ярмаса тагын да катырак басып уйнар иде Асаф. Аның уйнавы тыкрыкка гына түгел, урта урамга, инеш буйларына ишетелеп торыр иде. Сатый ишетмәмешкә салышып бакчада тора, балчык кисәге белән тәрәзәгә ыргытты.

—Әй, Асаф.

—Нәрсә бар?

Сатый берәр нәрсә уйласа Асафка баш бирми иде, теге «төшмим, яңа көй өйрәнәм», дип кабатласа да Сатый китмәде.

—Шырылдатып туймагансың икән,—диде.—Йомыш бар.

Асаф юри бераз ялындырып торгач кына төште.

—Әйдә, Югары оч чәчәүнигенә барып кайтабыз.

—Бармыйм,—диде Асаф, юри киреләнеп. «Гармунын шырылдата» дип рәнжеткәне өчен иптәшеннән үч алып.

—Барыйк инде. Фәрештәләр килдеме икән?!

Барсалар, акчалар кимү түгел, артканнар гына, иң кырыйда таушалып беткән бер сумлык ята.

—Син татар,—диде Сатый.—Сезнең Аллагыз юк.

—Нигә булмасын? Бар безнең Аллабыз!—диде Асаф кызарынып.

—Нигә бу акчаларны сиңа алмаска?..

—Нәрсәгә ул миңа? Кирәк булса әни миңа акча бирә.

—Сина бирә дә, минем нәнә акча арттыра алмый. Син акчаларны ал. Без синең белән берәр урында акча җыя башлыйк. Чүпрәкче килгәч сагыз алырбыз, чуклы кәнфит тә була анда, кызыл билле прәннек тә...

—Кая җыябыз?—дип сорады Асаф уйланып.

—Мәктәп чормасына менәбез дә яшерәбез,—диде шатланып Сатый.

Сатый читкә карап торды, Асаф чәчәүниктәге акчаларны җыйды да учлап-учлап чалбарының бердәнбер кесәсенә тутырды. Кесә бүлтәеп килеп чыкты.

Малайлар иң башта фанер кисәкләрен шома таякларга кагып «копилка» ясадылар, тыгыз гына авыз-тишек калдырып акчаларны берәм-берәм, саный-саный агач тартмага тутырдылар:

—Тапкан бер акчаны шушында җыя барабыз,—диде Сатый.

Серне беркемгә дә ачмаска, берәм-берәм генә чормага менмәскә антлар бирешеп, мәктәп түбәсенә менделәр һәм иң аргы почмакка, чормага кертеп куйдылар. Монда тузаннан һәм күгәрчен тизәгеннән башка берни дә юк иде. Тузанлы чормада үрмәкүчләр арлы-бирле үрмәләделәр.

—Үрмәкүчләр кәгазь акчаны ашамасмы?!—дип әйтеп салды Асаф.

—Акча нәрсәгә аңа?

Тузанга батып, маңгай-битләренә кат-кат пәрәвез ябыштырып чормадан кояшка чыккан малайлар беркавым берни күрә алмыйча басып тордылар.

Август аена керделәр. Олылар көне-төне кырда, Сәхип абый белән Мөнәвәрә апа да уракта, Асаф та алар янына барып чыккалый, олылар керт тә керт урак белән арыш ура, ә балалар чүмәлә төбенә җиләс күләгәгә чумган әбәд чиләге тирәсендә урала. Әбәд чиләгендә сап-салкын әйрән. Чиләк янындагы капчыкта катлама, пешкән күкәй. Бер дә Сатый сөйләгән Олы көн күкәеннән тәмсез түгел. Йортта ашалмаган ризыклар да кырда, урак өстендә шуалар гына! Асаф әти-әнисе янына сыйланырга килә. Килүен аклап әз-мәз эш тә тота, көлтә бавын урап тора. Әй, әнисе мактый, әй, әтисе мактана, «минә улыбыз үсеп кул арасына керә башлады!»—дип күршекүләннәрдә эшләүчеләргә дә сөйләп алалар. Асафның мактаганны тагын да тынлыйсы килә, әмма көн эссе, кояш аяусыз кыздыра, әйрән дә бетеп килә, арыш кылчыгы юлын табып күлмәк астына үтеп керә, кычыттыра, тырмый, интектерә. Күлмәген салып карый Асаф, кылчыкны табып ала, киюе була—үткен, җитез кылчык тагын җилкәгә менеп куна. Ә Сатый... хәзер су чумынып ятадыр...

Акъюл авылы халкы тырыш, иген уңа, арыш, бодайдан тыш «Ленин юлы» колхозы мәк һәм киндер чәчә. Аклан чирәменә башлаш кырга шалкан утырталар, инеш буендагы яшелчәлектә кәбестә, кишер, кыяр котырынып үсә. Зират тавы өстендә айбагыр басулары. «Таба, таба айбагыр башлары бар, тәтә белән печәнгә менгәч күреп кайттым», дип мактана Сатый. Ә Асафны анда еракка, тау өстенә үк җибәрмиләр. «Я елан чагар, бүре килеп чыгар», дип куркыта әнисе. Сатыйның рәхәт, тәтәсе белән атка утырып кына бара да печәндә тирбәлеп кайта. Күлмәк итәге астында дәү таба хәтле айбагыр!

Бер вакыт айбагырны кага башладылар һәм авыл уртасындагы мөгәҗә амбарына кайтардылар. Кибеп җитмәгәннәрен амбар алдындагы такырга тараттылар.

Кай арада күргән диген, Сатый ике кесәсен тутырып эре-эре, өлгергән айбагырны чәлдереп тә кайткан.

—Каравылда Мәндәй Ибаны тора! Амбар артына, җилсез якка тәмәке тартырга керүе булды, ялт кына килдем дә айбагырны тутырып та алдым. Әйдә, берәр капчык чәләбез дә базарга чыгарып сатабыз. Акчасы булыр!

Акча дигәч Асафның да күз кызды, чормадагы «копилка»лары да үрчеми, тик ятып акча артмый, ә Сатый «акчаны күп җыйсак, Эзигә, я Чаллыга ук барабыз», ди. Чөнки быел җәй буена авылга чүпрәкче кермәде. Акъюл хатыннары каен тузыннан сагыз кайнатып лач-лоч шуны чәйнәп йөриләр, кызлар да чәйни, мәгәр һәммәсе бер авыздан чүпрәкче Камал сагызын сагыналар.

Асафның кесәсе бер генә, аңа ике учтан ары сыймый... Сатыйның җиң очлары чачакланган пинҗәге бар, пинҗәкнең итәгенә буйдан-буйга эчтән тирән кесә тегелгән. «Басудан гел буш кайтмыйм мин, я борчак, я арыш тутырып кайтам!» дип мактанганы да бар иде. Хәзер айбагыр бурлыгына барыр алдыннан шул пинҗәген кигән, эсселәгән, әлсерәгән, маңгае шабыр тир. «Минем бу кесәгә бер батман айбагыр сыя!» дип мактанып пинҗәк итәген әйләндереп күрсәтте Сатый. Асаф әнисе күрмәгәндә генә өйдән нәни генә янчык кыстырып чыкты. «Әйдә, ике-өч тапкыр алып кайтсаң, синең дә сатарлык була», дип тынычландырды аны Сатый.

Киттеләр. Айбагырның көшелдәгесе дә бар, җиргә дә киң итеп тараткannar, киндер алъяпкыч бәйләгән, алъяпкычын кайтарып биленә кыстырган Мәндәй Ибаны, аксыл чәчле, кызыл йөзле, үшән генә кеше пыр-пыр очкан чыпчыкларны учын шапылдатып куа-куа йөрде дә сырлы себерке белән җирне арулап, җиргә җәелгән айбагырларны тарата төште.

Малайлар мөгәҗи амбары артына сеңделәр. Имән бүкәннәр өстенә утырткан бура амбар астыннан туктаусыз суык җил исә, айбагыр көшеленә һөҗүмгә әзерләнеп тавыклар тузанда коеналар.

—Көшелдә корырагы, көшелдән умырырга тырыш,—дип пышылдады тавышы үзгәргән Сатый.

Мәндәй Ибаны як-ягына күз салды, авызын чүлмәк авызы хәтле ачып иснәде, чыпчыкларга тагын бер эндәште: «Көш, каһәрләр!»

Аннары алъяпкыч кесәсенә тыгылып чиккән янчыгын, газета кисәген суырып чыгарды, күләгәгә, шыкка керде. Амбарның артында торган малайлар почмактан йомылып кына чыктылар, көшел янына тезләнделәр, Сатыйның куллары күз иярмәс тизлек белән көшел белән төпсез диярлек дәү кесә арасында очып йөри башладылар. Асаф башта куркып чыкмый торды, иптәше күзеннән утлы нур коеп амбар почмагын көйдереп алгач кына көшелгә якынайды. Ул арада Сатый йом булды, Мәндәйнең көрәк кебек көчле кулы Асафның җилкәсеннән эләктереп алды. Эләктереп тә алды, икенче кул авырттырып җилкә чокырын төйде. Асаф елап җибәрде һәм:

—Әтигә әйтәм, әтигә әйтәм!—дип кычкырды.

—Кем малае син?—диде Ибан әзрәк кыза төшеп.

—Сәхип абый малае мин.

—Учитель малаемы?

—Әйе.

Муен тамырын эләктергән кул тиз генә язылды, күр инде, Мәндәй Ибаны Асаф кулындагы янчыкка айбагырны үзе тутырып маташа. Тутырып та бетерде, янчыкны малайга биреп, бик юаш, гаепле тавыш белән:

—Мә,—диде.—Алай да әтиеңә әйтеп торма...

Мәндәйнең кыланышын амбар артыннан күзәтеп торган Сатыйның кәефе бик нык кырылган иде, ул бу социаль гаделсезлекне үзенчә бәяләп шыңшырга ук кереште:

—Мин учитель малае булсам, Мәндәй минем кесәне дә тутырыр иде, ие, сиңа рәхәт.

—Рәхәт!—диде Асаф.—Җилкә чокырын төйделәр, ә син яклашасы урында, тайдың.

—Учитель малае булсам мин акчаны тәтәдән генә сорап алыр идем, әнә, Мәндәй дә сиңа айбагырны тутырып бирде.

Бу мизгелне алар икесе дә онытмадылар, айбагыр бурлыгыннан соң иптәшләрнең арасы күзгә күренеп үзгәрде, ерак урам малайлары Асафка кагыла башласалар, Сатый чәрелдәп кычкыра иде: «Тимәгез, аның атасы учитель!» Асафның да борыны күтәрелә төште: «Әһә, дип уйлады ул, укытучы баласы булу файдалы икән лә! Ул авылда, бөтен җирдә сиңа өстенлек бирә икән! Әгәр ул председатель малае булса? Әгәр... Ул чагында айбагырны урлап йөрисе дә булмас иде, барыр иде дә, теләгәнчә ашар иде..»

Әтисе шикле янчыкны эштән кайткач ук күреп алды:

—Бу нәрсә?

—Айбагыр.

—Каян алдың?
—Мөгәҗи амбарыннан.
—Хәзер үк илтеп бир! Бар, бар!
Әтисенең бу кадәр кызганын күргәне юк иде Асафның, ул урламавын, Мәдәй Ибанының үзе тутырып бирүен дә аңлатырга тырышып карады, әмма Сәхип Зәкиев нык куллы иде. Айбагырны бөртегенә хәтле илтеп бирергә туры килде. Мәндәй Ибаны сорашмады, аңлады, малайның аркасыннан кагып озатып калды...
Җәй мажаралары белән үтеп китте. Ничә чыпчык оясы туздырганнардыр алар, санап бетергесез... Киндер күлләре тирәсендә күпме баканың башына житкәннәрдер, анысы да билгесез. Хәзер чәчәүниктә акча тотмыйлар дуслар, Сатый Асафны ияртеп бара да үзе читкә карап тора. Чормага менеп йөрү кыенлашты, мәктәптә ремонт бара, парталарны ишегалдына көнгә чыгарып буйыйлар. Парпылай дәдәй бертуктаусыз урманнан утын ташый. Утынны өлкән класс укучылары кисеп яралар һәм рәтләргә тезеп өяләр. Беркөн караңгы чормага менгәндә, өрлектән чыгып торган күгәргән кадакка тиеп Асафның маңгае тишелде. Каны агып яңа күлмәгенең түшен буяп бетерде... Әй әләкте әнисеннән!..

Асаф белән Сатый укырга керделәр. Асаф хәзер керәшеннәрнең шул ук татарлар булуын белсә дә, арада аермалар барын да белеп бетергән иде инде. Керәшеннәр өй түрләрендә Алла бабаларының рәсемнәрен тоталар, өлкәннәр ашап бетергәч шуңа карап баш ияләр, чукыналар. Яңа туган бәбиләрен дә чукындырып исем кушалар. Хатын-кызлар кияүгә чыккач кына мәләнчек бәйлиләр... Аларның бәйрәмнәре дә бүтән, Сабан туе дигән сүз юк, Сабан туена охшаган бәйрәмне алар «мәйдан» дип атыйлар һәм аны Аклан чирәмендә үткәрәләр. Ләкин Акъюл авылының иң зур бәйрәмнәре «мәйдан» түгел, аларның иң олы бәйрәме Олы көн белән Троыйсын. Әле Асафның берсен дә күргәне юк. Аның Май чабуны, Микуланы, Элженне, Покрауны күргәне бар, әмма Сатый сөйләгән кызыктыргыч Троыйсынга, Олы көнгә туры килгәне юк...
Күп белә иде Асаф, шулай да барын да белеп бетермәгән икән. Балачага ишле, авылдан гына ике беренче класс җыелды, Асафлар беренче «б» да, аларга класс мәктәп ихатасыннан бераз читтә Үтәмиләр өендә әләкте. Үтәмиләрнең үзләрен бакча яктагы мунчага күчергәннәр дә өйләрен класс иткәннәр. Үтәми үзенең биш малае, төпчек кызы Нәчтүк белән шунда яшәп ята... Ни өчен Үтәмиләрне үз өйләреннән чыгарганнар, Асаф әлегә ул мәсьәлә белән кызыксынырлык яшьтә түгел иде. Аны башка гаҗәп хәлләр бөтереп алды...
Сатый белән Асафны өч кешелек партага икесен утырттылар. Укытучы абый исемлек тикшерә башлады, Асафның исемен атады, «Зәкиев Асаф», диде. Класста тагын бер татар кызы бар икән, Нурания исемле. «Аның әтисе дә учитель» дип пышылдады Сатый кыз торып баскач. Укытучы «Муханов Егор» дигәч нигәдер Сатый сикереп торды, танавын тартып авызын мыймылдатып алды. Бүтәннәр көлде, Асаф аптырап китте. «Нинди Егор? Сатый ич ул!»
Тәнәфескә кадәр түзеп утыра алмады Асаф:
—Синең исемең Сатый бит,—диде ул иелеп.
—Сатый,—диде малай.
Укытучы шауламаска кушты, мәктәптәге тәртипләр белән таныштыра башлады. Укытучы тәртип хакында сөйләсә дә Сатый тик кенә утыра торган түгел, шуклана башлады, Асафка карамыйча гына:
—Читәнме, бүзме?—дип сорады.
—Читән,—диде аны-моны уйламыйча Асаф.
—Бер чеметәм дә китәм,—диде Сатый һәм сузылып Асафның ботын чеметеп алды. «Әл-ләл-лә!» дип кычкырыр иде бүтән вакыт булса Асаф, монда курыкты. Ә Сатыйның гамендә дә юк, иң гөнаһсыз кыяфәт белән колакларын торгызып укытучыга текәлгән, иреннәре тагын селкенде:

—Читәнме, бүзме?—дип тагын әйтеп салды ул. Ачы сабак алган Асаф:

—Бүз,—диде. Чеметү тагын кабатланды:

—Бер чеметкәнгә түз,—диде малайның елмаюын кысып тоткан иреннәре.

Аларның чыш-пышлары укытучы күзеннән читтә калмады, ул алар арасына иң арткы партага барып утырган юаш кына Миңнеш исемле кызны китереп утыртты.

—Өчегезнең дә урыны шул булыр, әгәр шауласагыз, тагын аерым-аерым утыртырмын,—диде укытучы абый.

Ике елгыр малай уртасына кысылып утырган Миңнеш кып-кызыл булды, карашын түбән төшерде һәм дәрес беткәнче күтәрелеп тә карамады. Асафның да кызлар белән шулай якын утырганы юк иде, нигәдер аның тәне кызышты, ул Миңнешкә кагылырга, тиеп китәргә куркып кыймшанмыйча утыра бирде. Бер парта арасында кагылмыйча күпме утырырга мөмкин? Менә алар дәфтәр битенә кыеклап таяклар яза башладылар, терсәкләр үзләренә урын таба алмыйча, аска-өскә менә-төшә башладылар. Сатый карасын чак кына түгеп җибәрмәде. Миңнеш аркылы үрелеп Асафның дәфтәренә карады. Мәктәпкә кергәнче үк бу «таяклар чорын» үткәргән Асаф тиз генә кушкан эшне үтәде. Сатый Миңнеш аркылы аңа дәфтәрен сузды: «Миңа да тиз генә сызгалап бир әле, малай,»—диде. Асаф аның дәфтәрен дә таяклар белән бизәде...

Тәнәфескә чыккач кына Миңнешнең дә Миңнеш түгеллеген, чын исеме Анна булуын белде Асаф. Сандра—Александра икән, Тәтүк—Татьяна, Начтук—Настасья икән... Берьюлы хәтерләп бетерерлек тә түгел. Ул шушы яңалыгын өенә алып кайтты. Әтисе аңлатып бирде:

—Бик. Бик борынгыдан калган җола. Бала озак яшәсен, чир-чорларга бирешмәсен өчен аның исемен яшерәләр, кушамат белән йөриләр. Кушаматлар татарларда электән үк килә, тик алар керәшеннәрдә ныграк сакланган. Чукындырганда кушамат фамилия булып күчкән. Исемен язып утыручы татардан кушаматын сораган да ана яңа, христиан фамилиясе язып куйган. Олы Мимуннар—Бальшаков, Кечкенә Ибаннар—Меньшиков, Үткен Раманы—Байков... Кайчагында тәрҗемә итеп тә тормаганнар, әйтик, Кара Пидырлар—Каракаевлар...

—Ә Парпылый дәдәй кем?—дип сорады Асаф.

—Парфирий!

Асаф көлеп җибәрде, Парпылый дәдәй дип йөреп шул кадәр күнегелгән иде, Парфирий чын исем түгел, кушамат кебек яңгырады...

Класста Сатыйның ике исеме йөри башлады, кызлар малайны Җәгүр дип йөртсәләр, малайлар өчен ул һаман Сатый иде. Укытучылардан Зәйнәп апа гына балаларның исемен дөрес итеп, авызын тутырып әйтсә дә балалар үзләренең яңа исемнәренә күнегә алмадылар. Филарет Пилюрук, Моисей Мучый, Арсентий Әрчәнти булып йөрде. Асаф тора-бара бу исемнәргә күнекте, яратты да...

Мәктәп балалары чиркәүдә ата-аналар өчен концерт күрсәттеләр. Асаф беренче тапкыр сәхнәгә менеп гармунда уйнады. Уенын ошаттылар, гөрләтеп кул чаптылар...

Сәхнәгә, халык алдына чыгып басу малайга зур тәэсир ясады, ул төне буе йоклый алмады, борсаланып ятты. Аның шулай тәэсирләнеп кайтуын сизгән ата белән ана шыпырт кына сөйләшсәләр дә сүзләре ара-тирә Асафка да барып җитте.

—Асаф сәнгатькә тартым юл салмасмы икән,—диде әтисе.

—Бәлки шагыйрь булыр?—диде әнисе сөенеп.

—Юк, юк,—дип каршы төште әтисе.—Берүк язу эше белән шөгыльләнә күрмәсен... Авыр эш! Аннары, чак кына ялгыштыңмы, шундук язучының башын кисәләр.

—Кая таба китсә дә, укысын да сәламәт булсын!—дип йомгаклады улы өчен борчылып һәм сөенеп әнисе.

Класстәшларның да мөнәсәбәте күзгә күренеп үзгәрде... Дәрескә кергәнче үк Миңнешнең үзенә таба карап-карап алуын тойган Асаф дәрестә дә аның куе керфекләр арасыннан балкыган кара күзләренең үзендә тукталуын сизде.

Сатыйга да шулай карыймы Миңнеш дип күзәтә башлады, карамый икән, Сатый ягына кыз бөтенләй карамый да әле! Югыйсә Сатый да сәхнәгә менде, фокус күрсәтте, биш тиен бакыр акчаны учына салды да авызына якын китерде, йоткан булды, аннары кулын җәеп, бармакларын чәчеп һавада озак кына селкеп торды, акча төшмәде, авызда да юк иде бакыр, бала-чага шаккатты! Шуннан Сатый нык кына төчкереп җибәрде һәм акча аның учына сикереп төште. Сатыйның уч төбен сагызлап куюын бер Асаф кына белсә белгәндер... Аңа да кул чапканнар иде, шулай да Миңнеш аның ягына әйләнеп тә карамый...

Озын тәнәфестә түбән класс балаларын колхоз ашата, шактый зур калын бер телем ипи белән бер тәлинкә аш бирәләр. Үтәмиләр ихатасы иң еракта урнашкан, Асафлар классы барып җиткәнче, гадәттә, әйбәт урыннарны якында урнашкан класслар алып бетергән була, ипинең дә кибән башы калмый. Шуның өчен өченче дәреснең азагы җитә башлагач малайлар кыбырсый, бер-берсенә төртешә башлый... Зәйнәп апалары үгетләсә дә бу юлы аны тыңлап торучы калмый... Звонок тавышы чак кына ишетелүгә дәррәү сикереп торалар да чыгып чабалар. Капкадан кысылышып, бер-берсенә комачаулап чыгалар да урам кинлегенә җиткәч йөгереш тагын да кыза, ашханәгә җанып-көеп, мышнап барып керәләр...

Җиргә ап-ак кырпак төшкән. Салкынча, кояшлы көн. Асафлар классы малайлары тырсылдашып чабып чыктылар да узышып, сызгырып, мәктәп ишегалдына кереп киттеләр. Сатый белән Асаф рәттән чабалар, бер-берсен узмаска, бүтәннәргә баш бирмәскә сүз куешканнар. Барып та керделәр, ипи телемнәре өеменнән икешәр кибән башны эләктергәч кенә бер-берсенә карадылар.

—Нигә ике телем алдың?—дип кычкырды Сатый.

—Ә үзең?

—Мин Миңнешкә алдым.

—Мин дә.

—Синең кибән башың җимерек,—диде Сатый һәм үз телемен ипи кунасына илтеп куйды. Асаф та кире куйды, ул арада бүселеп бүтәннәр килеп керде, Миңнешкә тагын кибән баш калмады. Ул иң арттан килеп керде дә, өстәл почмагына урындыгын тартып китереп аш тәлинкәсенә иелде. Ул да кызарган, ике бите янып тора, чәчүргечләренең берсе алда, берсе җилкәсендә. Чәчүргечләрен карый торгач Асафның күзе кызның түшенә төште. Кызның ситса күлмәгенең түш туры түгәрәкләнеп калкып тора иде. Асаф чәчәде, ашы ялгыш юлга китте, ул гаеп өстендә тотылган кыяфәттә куркынып як-ягына карады, «аның кая караганын күрмәделәрме?»Карарга да курка Асаф кыз ягына, карыйсы да килә, Миңнеш класста иң чибәр, иң юаш кыз икән. Асаф белә инде, алар Акъюл авылының Эзигә чыга торган очында, әнисе, ике энесе белән генә яшиләр, аларның аталары юк, урман кискәндә агач басып үтергән. Классташлар Асафка карыйлармы соң, алар итле кәбестә штиен уралар гына, малайның эчендә нинди ут кабынганын Миңнеш кенә сизә, ул күзен күтәреп карамаса да Асафның үзенә текәлгәнен, игътибар иткәнен сизә...

Сатый тагын бер тәлинкә аш сорап алган икән, шуны ашый калды, Асаф белән Миңнеш бүтәннәрдән арткарак калып янәшә кайттылар. Артка кал, димәде Асаф, кыз үзе калды. Шактый озын юлда ул бер сүз әйтте:

—Асаф, син бик матур уйнадың,—диде.

Малай горурланып, мактанып як-ягына карады. Инде Үтәмиләр өенә кайтып, класска кергәндә генә Миңнеш тагын бер сүз әйтеп куйды:

—Безнең тәтә дә гармунчы булган, гармуны да бар иде, налугка түләргә акча булмагач нәнә сатты...

Асаф аңа бик кызганып карады. Ул налуг хакында монарчы да ишеткән иде ишетүен, мәгәр налугның әшәкелеге белән беренче тапкыр очрашты. Начар нәрсә икән ул налуг! Ятим хатынның өенә дә килеп керә икән, хатирә итеп сакларлык гармунны да саттыра икән. Үз гармунын Миңнешләргә илтеп бирердәй итеп кайгырды Асаф. Тик гармунның барыбер Мин-

неш тәтәсенеке булмаячагын исәреп кенә ниятеннән кире кайтты. Барыбер Миңнеш аңа кадерлерәк булып калды, дәрес бетеп, кайтырга кузгалганда ул беркем сизмәгәндә генә Миңнешнең чәченнән тартып куйды... Аның кызга ничек булса да ярдәм итәсе, аның күңелен күрәсе килде. «Безгә килеп утыр, мин озак итеп гармун уйнармын», диясе килде, әнисеннән шикләнде, яратмас...

Нишләргә соң? Ни кылырга? Берәр малай Миңнешне кыерсытсын иде, Асаф килеп җитеп тегенең кирәген бирер, салма савытын җимереп төшәр иде. Үзенең көче җитмәсә Сатыйны чакырыр иде, Сатый мәктәпкә кергәч буйга калкынып, Асафны узып китте. Алар да атна саен диярлек үлчәшеп торалар иде. Хәзер Асаф үлчәшми, эченнән генә: «Ие, икешәр пурцы ашагач үсмичә нишләсен! Ә тәтәсе конюх, завхоз, колхоз келәтеннән итне, ипине ул ташый, чиләге белән балны да ул алып кайта, Сатыйга ашның куесын салалар, калҗаның иң дәве дә аңа эләгә!» Ашчылар Сатыйны аермыйлар иде аеруын, әмма көнчелекнең ачылыгын Асаф әнә шулай беренчедә укыганда ук татыды...

Аның класска барырга ашкынып торуы, уйчанлыгы, җитдиләнеп, олыгаеп китүе ата-ана күзеннән дә читтә калмады. Ял көннәрендә дә Үртәмиләр ихатасыннан әйләнеп-әйләнеп кайтуын да белделәр.

Бер көнне кичен, алар икәүдән-икәү чәй эчеп сөйләшеп утырганда Асаф юрган астыннан үзенә чыккан яңа хөкемне тынлап ятты.

—Сәнгать кешесе булачак безнең Асаф,—диде әтисе.—Кызлар белән бик иртә мавыга башлады. Укытучысы Зәйнәп сөйләп торды, Миңнеш белән икесе бер-берсеннән күзен алмыйлар, ди...

—Бала чакта мавыгулар була инде,—диде әнкәсе.

—Мин үзем бу җәһәттән соң өлгердем.

—Шуңа укытучы гына булып калдыңмы?

—Асаф я артист, я язучы булачак...

Асаф бәхетле иде, ул юрганын баш очына тартып китереп, калын мамык юрган эченә чумды, ул сөенә иде! Әйе, ул гармунчы-артист булыр, бик атаклы кеше булып китәр. Миннешне бер чакта да ташламас, алар бергә булырлар... Тик менә хәзер, менә бүген аның күңелен ничек күрергә?.. Ята торгач аның башына бер фикер килде, ул Сатый белән бергә җыйган акчаларын исенә төшерде. «Копилка»ны шыпырт кына менеп алырга да кибеттән Миннешкә берәр бүләк сатып алырга! Менә шәп булачак!..

Икенче көнне Асаф, кичен, карангы төшкәч, җыештыручылар эшләрен бетереп, классларны ябып кайтып киткәч пожар баскычыннан курка-курка гына өскә үрмәләде, карманып чорма төбендәге такта тартманы тапты, өстәге фанерын җиңел генә каерып акчаларны бишмәт кесәсенә тутырды һәм «копилка»ны читкә атып бәрде. Ике-өч көн акчаларны кая куярга белмичә аптырап йөргәч, Сатыйларның тәтәләре белән мунчага киткәнен күреп торгач, ул эшлекле кыяфәт белән кибеткә китте. Керде. Ләврәнти дәдәй белән күреште, киштәләрдәге товарларны карап-карап чыкты. Малайның акчасы өч сумга якын иде. Хәзер шуңа нинди бүләк алырга? Товар бәяләрен күзәтә башлагач Асаф үзенең шактый суммага хуҗа икәнлеген аңлады, өч сумга «Ясмин» дигән хушбуй белән яулык алып була икән! Ул көч-хәл белән телен әйләндереп, кибеттә кеше юк чакны көтеп алып, Ләврәнти дәдәсеннән «Ясмин» белән яулык сорады.

—Сигезенче мартка әзерләп куясыңмы?—диде сатучы һәм артык төпченеп тә тормыйча малайга сораганнарны төреп тә бирде...

Хәзер бу бүләкләрне Миннешкә тапшырырга кирәк иде...

Икенче көнне Асаф «башым авырта», дип ашханәгә чапмады, класста калды, Миңнеш дежур иде, ул форточкаларны ачып куеп, кара тактаны сөртеп арулагач кына ашханәгә барырга тиеш. Зәйнәп апа Асафның маңгаена кулын куеп, аны-моны сорашып торды да ишеккә юнәлде, чыгар алдыннан парта артыннан кузгалмаган Асаф белән Миңнешкә карады, елмайды.

Кичәдән бирле кулны яндырып торган бүләкләр Миннешнең киндер букчасына күчте. Такта сөртеп торган Миңнеш ялт итеп борылып карады һәм Асаф янына килеп җитеп, букчасына тыгылды.

—Кешегә күрсәтмә,—диде калтыранып Асаф.
—Нәрсә бу?
—Бүләк.
—Кемгә? Миңамы?
—Сиңа инде, сиңа!
—Кемнән?
—Миннән.
Миңнешнең алсу йөзе тагын да чибәрләнде, ул сулкылдап җылап җибәрде.
—Ник җылыйсың?
—Белмим.
Асаф эшне тәмамланган санап атылып класстан чыгып чапты һәм ашханәгә кош булып очты. Ул барып җиткәндә ипи кунасында кибән башлар беткән, малайлар-кызлар озын такта өстәлгә сырышып тары өйрәсен шопырдаталар иде. Сатый янында ике тәрилкә аш торса да бүген Асаф аннан көнләшмәде. Миңнеш тә ашарга килмәде.
Яңа ел алдыннан кибеткә Сатый бик көтәннән көткән чуклы конфетлар кайтты һәм ул Асафны ияртеп чормага «банк»ка менеп китте, ухылдап, шаулап:
—Ну сыйланабыз бүген, рәхәтләнәбез!—дип кабатлады. Асаф менмәде, астан авыр баскычны гына тотып торды. Бераздан кызарынып-бүртенеп, кашын җимереп Сатый килеп төште.
—Урлаганнар!—диде ул ярсып.—Безнең акчаны урлаганнар!
—Чынмы?—диде агарынып Асаф.
—Тартмасын ватып читкә ыргытканнар... Ичмасам бер бакыр да калмаган.
Өченче көн генә физкультура кабинетыннан өр-яңа камыш чаңгы таяклары югалган иде, шушы ике бурлыкны бергә бәйләп, Сатый бик озак сүгенде, карганды, бик каты үч алырга булып сүзен бетерде.
—Таякларны урлаган кеше алган аларны. Кеше бер бурлыкка салындымы, чиргә сабыша, урламыйча түзми,—ди минем тәтә.
—Ну тотсам! Тотам да мин аны! Чаңгы таягы бер чыкмыйча калмас, авылда бүтән кешедә камыш таяклар юк!
Алар бамбук таякларны күзәтер өчен көн дә чаңгы шуарга чыга башладылар, шуа-шуа Сарсаз янына барып җитәләр, тау өстеннән, Дуңгыз сыртыннан шуып тегермән буасы янына ук килеп төшәләр. Сатыйның чаңгысы киң, тәтәсе өрәңгедән бөккән шоп-шома чаңгылар. Чаңгыларның борыннарына бау бәйләнеп, шул «дилбегә»не эләктереп ала да, аякларын ерып Сатый теләсә нинди таудан эз салып аска төшеп китә. Асафның «хөкүмәт чаңгысы», бара торгач ул да остарды, кыюланды...
Беркөн, зират тавы өстенә менсәләр аларга авылның атаклы сунарчысы Аксак Ибан очрады. Җилкәсенә аркылы ике куян аскан.
—Атып алдыңмы, Ибан дәдәй?—диде Сатый.
—Юк, буанакка эләккәннәр...
—Ә-ә,—диделәр малайлар сокланып.
Ибан дәдәй аксак кына түгел, чулак та, сул кулы терсәктән өзелгән, шулай булса да ул авылның атаклы куянчысы, ара-тирә төлке дә тотып кайта, үзе тире или, колакчыннар тегә, базар саен Эзигә бармыйча калмый, аракы эчәргә дә ярата. Кибет—элекке таш амбар, анда өч-дүрт кеше һәр көн диярлек Ибанның аудан кайтканын көтеп торалар, Ибан да аларны күрергә ашкынып кайта, шешә төбе кагып урманда «арган сөякләрен җылыта», төрле хикмәтле хәлләрне сөйләп, шешәдәшләрен көлдерә...
—Әйдә без дә буанак салабыз!—дип кычкырды кинәт Сатый.
—Буанагын каян алабыз?
—Ибан дәдәйнең буанакларын җыябыз да бүтән урынга, ул белмәгән сукмакларга салып куябыз!
Асаф башта курыкса да Сатыйның сүзеннән чигенә алмады, алар Аксак Ибанның чаңгы эзе буйлап урманга барып керделәр, җиде-сигез җирдә,

агачка бәйләнгән тимерчыбык буанакларны сүтеп алып, әллә кая еракка, Карама куыш ягына ук илтеп, куян сукмакларына салдылар. Сикергәләп үз эзеннән юртып баручы куяннар алар буанагына да килеп керергә тиеш ләбаса!

Өч көн урманга бара алмадылар, бер көн үтә суык булды, икенчесендә Сатый тәтәсе белән мунчага су ташып йөрделәр, бер көн Асаф ютәлләп торды...

Көн гаҗәп матур иде! Кояш офык өстеннән диярлек тәгәрәп барса да кырларны суык нуры белән күмгән. Меңләгән кар бөртекләре тып-тын кырга кунып ял итә, күзләрне камаштырып җемелди, төрле-төрле нурлар чәчеп ялтырый. Эскерт тирәләрендә йөзләгән куян эзләре! Бер куркагы эскерт янындагы кар көртенә чумган да малайлар чаңгылары белән чожлап килеп чыккач, ул колагын артка ташлап томылып чаба башлады.

—Эх, шушында салган булсак буанакларны!—диде үкенеп Асаф.

—Басуда куян тимерчыбыкны күрә, ә урманда ул аны нәзек ботак дип белә, абайламый да кала. Сикерә дә килеп эләгә...

Төп сукмактан аллы-артлы икәү баралар, буанак карарга Сатый гына керә, «эз күп була», дип ул Асафны кертми. Берзаман, өченче буанакка җиткәч, бәсәргән куаклар ешлыгыннан Сатыйның тантаналы тавышы ишетелә.

—Асаф, Асаф!..

Тавыш артыннан озак та тормады дәү, йомшак куянны кочаклап малай үзе килеп чыкты, авызы колагында, ашыкканга куакка эләгеп бүреге төшеп калган, кыска итеп алдырган чәчләреннән пар күтәрелә. Куян буанакка төшкән, әмма үлмәгән, исән иде. Ул зәңгәрсу олы күзләрен тутырып Асафка карап тора иде, тешләшми дә, тибешми дә. Үзенең актыкы сәгате җиткәнен чамалый иде ахрысы бичара.

—Сатый, җибәрик без бу куянны!—диде кинәт Асаф.

—Җибәрде диярләр.

—Җәл бит.

—Җәл диярләр. Бар, бүрекне кереп ал.

Асаф Сатыйның бүреген кереп алып чыгып, башына кигертте дә ялынырга кереште:

—Йөрсен инде.

—Йөрде диярләр. Без ычкындырсак та, Аксак Ибан җибәрәме аны?

—Юк, бусы хәзер буанакның ни икәнен белә, якын да килмәс. Җибәрик әйдә, йөрсен рәхәтләнеп.

—Йөрде диярләр...

Асафка куян шулкадәр кызганыч, шулкадәр мескен иде ки, ул аны җәлләп балавыз сыга башлады. Тәмле теле белән ялынып-ялварып теләгенә иреште, Сатый куянны җиргә бастырды. Асаф аның аркасыннан кагарга да өлгермәде, куян томылып чапты, күздән юк булды...

Сатый юл буе Асафны пешекләп кайтты, үзен «җүләр» дип атады, тик Асаф искиткеч канәгать һәм шат иде.

Сатыйның кырык җирдән ямалган тунына куянның берничә бөртек ак мамыгы ябышып калды...

Мамыкны Асаф җыйды һәм күңеленнән генә «Миңнешкә күрсәтермен» дип бияләе эченә тыгып куйды.

Иң аянычы шул булды: алар буанагына куян төшүгә, аның исән калуына беркем дә ышанмады. Хәбәр Аксак Ибанның колагына да барып кергәч, ул чиркәү тирәсендә малайларны очратып, әшәке сүзләр әйтә-әйтә әллә кая кадәр куды. Аягы нык ук аксак булса да Ибан йөгерешчеләрдән бер дә ким чапмый икән әле...

Кыш узды... Яз җитте. Кызык, татарлар «язга чыгалар», «җәйгә чыгалар», ә көз белән кышка керәләр... Нигә алай? Көз—мәшәкатьләр чоры, мал курмысы, утын хәстәрләп, бураларга кышлык азык-төлек тутырып, базларга бәрәңге салып «көзгә керәләр». Көз—мәшәкатьләрнең беренче буыны,

тәүгесе. Ул һәркемнең әзерлеген, көчен, егәрен, өенең нык каралганмыюкмы икәнен, абзар-кураларның ныклыгын тикшерә торган чор. Күздән чыгып тормыйлар, «кышка барып керәләр». Ә кышның «корсагы озын», ул крестьяннан бик күп көч сорый, җәй—өмет чоры булса, кыш бик күп өметсезлекләр алып килә: курмы җитәр-җитмәс кала, базда бәрәңге кими, буралар да бушап яңгырап торалар, тавыкларның күпчелеге күкәй салмый, сыер ташлана—сөт бирми башлый, сугым итләре дә күзгә күренеп эриләр, кышка кергәндә ит крестьянга калҗа-калҗа эләксә, кыш уртасыннан чибәр апалар итне кулъяссуы калынлыгы гына салалар, ашны табакларга бүлгәч, ярка-ярка бәрәңге арасыннан ит кисәкләре күренми дә кала...

Ниһаять, крестьяннар «язга чыгалар». Бу әле өметләр янарды, тормыш җиңеләйде дигән сүз түгел, ләкин тормыш тиз-тиз үзгәрә, мичкә ике көнгә бер генә ягасың, мал-туарга азык җитмәсә дә алар көне буе лапас шыгында, кояш нурында торып, язгы җылы җилләрне күши-күши җан саклый алалар. Өстән калын кием төшә... Чабатачылар язга чабата табанын калынрак итеп үрәләр, биек-биек каен шакмаклардан ясалган күтәртмәләр тагалар. Өй түбәләреннән кар ишәләр, кар базларына юеш, дымлы авыр карны төятөя тутыралар. Кыш буе өйнең җылылыгын саклаган һәм тышның яктылыгы белән өйне тәэмин итеп торган тәрәзәләрдән эчке катларын алып, тыштан сырмаларын киптереп киләсе ел өчен саклауга куялар, ишектән авыр чыпталар төшә. Яз белән бергә табигатьнең ямен арттырып җан ияләре үзләрендәге үзгәрешләрне сиздереп аваз сала башлый. Һәр җирдә шатлык авазлары: ата казлар дөньяга ямь биреп каңгылдаша, сыерлар мөгри, иртәрәк туып ныгып калган бозаулар саламнары ачыла башлаган аранда койрык чәнчеп чабалар.

Акъюл авылы иң күңелле язгы бәйрәмнәрнең берсенә Олы көнгә әзерләнә башлый. Һәркем күпме кунак киләсен, ничә аш уздырасын чамалап келәтенә, чоланына, эчәгеләр асылынып торган өрлекләргә карый башлый. Мич араларында быҗырдап, күңелле тавыш биреп бал мичкәләре утыра. Кемнәрдер ярты авылга әчкелтем-төчкелтем исләр таратып көмешкә кайнаталар. Кибетләрдә чират: Акъюл җиңгәчиләре күбесенчә алача күлмәк кисәләр дә, яшьрәк кызлар, килennәр ситсы күлмәк кияләр, үзләре бәйләгән шәл түгел, чачаклычуклы яулык бәйлиләр. Кыш буе өйгә хуҗа булып утырган киндер станнары сүтелеп оялдына, чоланга чыкты. Язның үз мәшәкатьләре—киндер сугып утырырга көн бетте. Олы көнгә кадәр өйне юып чыгарырга кирәк, ә ул җиңел эш түгел. Һәркемдә үк булмаса да күп йортларда тегү машиналары келтери, биш итәкле алача күлмәкләр тегелә, ир-атларга зәңгәргә манылган тыгыз сугылган киндердән ыштан... Чалбарны бу якта «урындагы кешеләр», «укытучылар» гына кия. Колхоз председателе Җәпим дәдәй белән авыл советы хуҗасы Озын Микайла икесе дә күн төпле гәләфиләрдән чиртерәләр...

Иртәгә Олы көн. Акъюл авылына Олы көндә кунак сирәк килә, якын араларда күрше авылларга кияүгә киткән кызлар кайта да, ятим-ялпы килеп тула. Хәерчеләр дә Акъюл авылы керәшеннәренең юмартлыгын ишетә белеп Олы көн тирәсендә шушы авылда өч-дүрт көннәрен үткәрәләр. Өйдә урын җитмәсә, җылы мунчаларга кереп куналар.

Тирә-күршеләрдә, урам-тыкрыкларында, кое яннарында барган гомуми тантана Сәхип Зәкиевләр өенә дә килеп керде. Кеше рәтеннән калып буламыни? Асафның әнкәсе дә суган кабыгы суында күкәй манды, әнә алар, яңа пешеп чыккан ипиләр белән янәшәдә тәгәрәшеп сәкедә яталар. Парпылый дәдәй хатыны Ипис түти дәү генә янчыкка тутырып сары майдай тәмле урман чикләвеге кертте, фәлән апа ана чуар-чабарлы баш яулыгы бүләк итте. Кичкә фәлән апа бәлеш пешерде.

Бәлеш, бәлеш! Аның исе, авыздан сулар китерде. Бәлеш ашап, фәлән апаның осталыгын мактап, кинәнеп утырганда Асаф әнисенә:

—Әни, иртәгә Олы көн. Мин дә күкәй җыярга чыгам,—диде.

—Әй, улым,—диде дә әнкәсе Сәхипкә карады.

—Нигә, чыксын әйдә. Дөньяның гаҗәп якларын күреп кайтсын.

Әле карангылы-яктылы чак, көн яралып килә. Ләкин авыл әллә кайчан

уянган. Бөтен йортларда ут яна, кое чыгырлары күңелле җырлап әйләнә, кое сиртмәләре бер төшәләр, бер менәләр. Морҗалардан тәмле исләр таратып сыек кына төтен күтәрелә. Бала-чагалар ару киемнәрен киеп, нәни янчыкларын тотып йорттан-йортка керәләр, хуҗаларны бәйрәм белән котлыйлар. «Исус-Кристус терелеп торган!» Хуҗалар да авыз читләрен ару тастымал белән сөртеп балаларның янагыннан үбәләр: «Чыннан да терелеп торган!» Шуннан балаларның янчыгына бәйрәмнең иң олы бүләге—төрле төсләргә манылган күкәй тәгәри, юмартрак хуҗалар күкәйгә өстәп шишара, кабартма ише әйберләр дә сала.

Өйдә чакта «чыгам-чыгам», дип бик гайрәтләнсә дә урамга чыгып бер башы калгач Асафны ниндидер курку биләде. Этләр талар дип курыкты ул, үзенең керәшен түгел, татар малае икәнен дә искә алды, хуҗалар ничек каршылар, ни диярләр, куып чыгармаслармы?..

Кичтән «күршеләрдән йөри башлармын» дип ныклы маршрут төзеп куйса да, иртән, урамга чыккач, бу карарын кинәт үзгәртеп, өч-дүрт йортны үтеп китте һәм эт асрамаган Мекетә дигән кешеләргә кереп китте. Күрер күзгә юаш кына Мекетә дәдәй тәмәке тартырга гәҗит сорап гел аларга кагыла торган иде. Шук кеше, Асаф белән очрашканда кашларын уйнатып, янагын бүлтәйтеп «маймыл була», такмак әйтә, гомумән, күрер күзгә бик әйбәт кеше иде. Бәйрәм уңаеннан майланган капка тиз генә ачылып китте, бәләкәй ишек аркылы үтеп Асаф, кан калтырап өйгә керде. Мекетә хатыны сакау Барбара корымлы янагын чүпрәк белән сөртә-сөртә елмаеп Асафка карады, малай керде дә телсез калып бусага янына басты. Мекетә битен сөлге белән сөртә-сөртә мич арасыннан килеп чыкты.

Тынлыкның озакка сузылганын да сизде малай, әмма хуҗалар да сүз кушарга ашыкмадылар, алар бөтен күзләре-йөзләре белән бәйрәмчә елмаеп малайга текәлеп торалар иде. Укытучы малаеның күкәй җыярга чыгуын кулындагы ак янчык раслап тора иде.

—Йә,—диде Мекетә, көлүен чак тыеп.—Нәрсә дияргә кирәк?

—Ярар, баланың башын тинтерәтмә,—диде Барбара түти.

—Юк, юк, бәйрәм икән сүзен әйтсен!

—Булышма бала белән!—Барбара түти тәре почмагына, ян сәкегә тезелгән күкәйләр арасыннан иң эресен, буявы тигез төшкәнен алды да малайга таба китте.

—Юк, сүзен әйтсен... Яле, яле... Теле калмас, әйтсен!—диде үҗәтләнеп Мекетә.—«Исус Критус терелеп торган». Кабатла әле.

Малай янып-пешеп, авырайган телен чак кузгатып, хәрефләп-иҗекләп Мекетә кушкан сүзләрне кабатлады. Барбара түти аны кочаклап алды, аска ук төшкән картузын күтәреп Асафның маңгаеннан үпте.

—Чыннан да терелеп торган!

—Татар малаеның иманын алдык!—дип шаркылдады Мекетә.—Чукындырдык татар баласын.

Ничек чыгып киткәнен дә сизми калды Асаф, күзеннән яшьләре елга булып акты. Мәктәп ишегалдына кереп, теләр-теләмәс аякларын сөйрәп, оятыннан янып-көеп кайтып килгәндә аңа Парпылый дәдәй очрады. Ул да бәйрәмчә киенгән, Асаф беренче тапкыр аның яңа чалбар киюен, тезенең дә төзек икәненә игътибар итте.

—Бәйрәм көнне әллә җылап кайтып килә инде?

Парпылый дәдәй малайның ике иңеннән яратып тотып алды.

—Җыламыйм да...

—Ни булды?

Парпылый дәдәсенең болай гына түгел, яратып соравын аңлаган малай Мекетәләрдә булган хәлне сөйләп бирде. Пырпылый чынлап торып ачуланды.

—Тапкан икән уйнар кеше... Мин аны тотып пешекләрмен әле бер. Ә син җылама, Мекетә сүзен дә сөйләп йөрмә. Тасма тел ни сөйләмәс! Иманына берәүне дә кагылдырма, шул гына... Әйдә, ахмакның сүзен җил ияртеп китәр. Хәзер туп-туры безгә кер!

Ипис түти малайны ай да кояш тик каршылады.

—Мин сине көтәм, мин сине көтәм. Сатый да кайтып җитми... Түргә уз, чәй эч! Эчәсеңме?

Ипис түтинең мәтрүшкәле, җиләк яфраклы, кырлыганлы чәен бал белән эчмиләрме соң!? Борыны җебегәнче эчте Асаф. Ипис түти аның янчыгына өч күкәй тыкты: берсе кызыл, берсе зәп-зәңгәр, берсе сары күкәйләр.

—Нигә өчәү, Ипис түти?—дип сорады Асаф читенсенеп.

—Былтыр Олы көндә син Акъюлда булмадыңмы? Булмадың. Кызылы шуңа. Быелгысына зәңгәре. Киләсе елга син олы буласың инде. Олы балалар күкәй җыярга чыкмый. Шуның өчен аларга тагын бирәү тиеш... Көлә Ипис түти, малайның башыннан сыйпый, Асафка рәхәт булып китте. Каян Пырпылый дәдәй очраган да, каян бу дөньяда Ипис түти бар...

Ул җиңеләеп очып өенә кайтып керде...

Олы көн!

Өлкәннәр урамда бер-берсе белән кочаклашалар, бәйрәм сүзләрен кабатлап үбешәләр. Бөтен кеше иң ару киемнәрен кигән. Чабаталар өр-яңа, сирәк-мирәк кенә яшьрәк киленнәрдә елтырап торган кунычлы галушлар да күренә. Ике председатель—Җәпим белән Озын Микайла кунычларын сыдырып хром итекләр кигән. Быел солдатка караласы егетләр арасында да ката кигәннәр бар. Керәшеннәрдә «ботинка» дигән сүз юк икән... Асаф аны шул Олы көнне белде. Никрутлар Кирушлар турындагы калкулыкта акчалы уйныйлар. Акча нурларга күмелеп зыңгылдап бөтерелә-бөтерелә күккә менеп китә дә күзләрне кызыктырып җиргә килеп төшә. Җыелганнар шунда ябырылалар: «күн», «иләк!»- дигән тавышлар дөньяны яңгырата.

Сатый Асафны шунда эзләп тапты.

—Нигә мине көтмәдең?—диде ул үпкәләп.

—Өйгә кайтасы бар иде лә!

—Эх,—дип үкенде Сатый.—Теге акчаларның бер-икесенә тамга салган булсак, хәзер белеп ала идек каракны!

—Нинди тамга?

—Игәү белән сыртына бер-икене сызасың да эшең бетте кодагый.

Акча дигәч Асафның исенә Миңнеш килеп төште. Ул да күкәй җыярга чыккандыр, ятим бала дип аңа бүләкне мулрак та биргәннәрдер әле... Сатый кесәсеннән ике-өч бакыр чыгарып акчалы уйный калды, Асаф аңа сиздермичә читкәрәк китте дә, иплән кенә Миңнешләр ягына, Эзи очына таба китте.

Олы көн... Аның дини бәйрәм икәне турында берәрсе ныклап уйлады микән ул чакта? Акъюл авылында Олы көн—Язгы балалар бәйрәме! Барыюгы, ярлысы-ябагасы балаларын чуктай итеп киендергән, иске ыштаннар юылган, күлмәкләр үтүкләнгән, әти-абыйлардан калган пинҗәкләрнең җиңен кыскартып үсмерләргә кигерткәннәр.

Ирләр дәү чүпрәк туп тәгәрәтеп күкәйле уйныйлар. Һәркем үз паен—күкәйне бер сызыкка тезеп утырта да, ир-атлар чиратлап тупны тәгәрәтәләр. Ега алсаң—күкәй синеке. Катнашучылар алмашынып тора, бу юлы син беренче булып туп тәгәрәтсәң, икенче триттә син актыккы, монда үпкәләш юк. Күкәйле уйнаучылар янына карчык-корчык, карт-коры җыелган. Итәге җиргә тиеп торган биш итәкле алача күлмәкләренең билен киндер ыштан бөрмәсенә тыгып җибәргән симез артлы, былкын имиле җиңгәчәйләр дә күкәйле уйнаучы ир-атлар арасына чаяланып барып керәләр, инде иртәдән бирле бал мичкәләре янында айкалган ирләрнең күзләре аларган, алар тупны әллә кайларга кыекка җибәрсәләр, җиңгәчәйләрнең күзе үткен, алар бер юлы дүрт-биш күкәйне тәгәрәтеп салалар. Катырак куллар бәргәндә күкәйләр ватылып та китә. Ватык күкәйне шунда ук шул тирәдә уралган балачагага бирәләр. Балалар да чират тора, талаш-ызгыш юк, бөтен җирдә тәртип, бөтен җирдә бер-берсенә тирән хөрмәт. Асафка да бер ватык күкәй эләкте, ул аны әрчеп шундук ашады. Мондый да тәмле күкәйне ашаганы бар идеме икән малайның? Ул монда озак юанмады, һәрбер йорт турында җыелган кыз-кыркыннарны күзәтеп Эзи очына таба атлады. Олырак кызлар

чәчүргечләре, тасмалары, чиккән кулъяулыклары белән мактаналар. Иреннәре өстенә куе булып төк чыккан егетләрнең берсе ике рәтле гармунны тарта, бүтәннәр иреннәрен көйдереп тәмәке пыскыта-пыскыта кызларны күзәтәләр. Кемдә нинди кулъяулык бар да, кемнең күлмәге нинди? Бәләкәйрәк кызлар ат ябагасын җыеп ясаган шактый каты, нык тупны чөя-чөя сагалы уйныйлар. Иң бәләкәй кызларга да эш житәрлек, алар сызыклы уйный. Тешсез әбиләр лач та лоч сагыз чәйниләр, урамнан үтеп торган яшьләрнең, яңа өйләнгәннәрнең гайбәтен саталар. Картлар көрәк сакалларын тарап, язгы чикмәннәрен җилбәгәй җибәреп, дәү-дәү кара челемнәрен пыскытып Акъюл урамын зәһәр «түтәлтрест» дип аталган бакча тәмәкесе исенә күмеп утыралар. Бөтен кеше урамда, бөтен күзләрдә рәхәт елмаю, туганлык, Акъюл кешеләре олысы, кечесе бүген бертуган булып беткән, урам бүген урам түгел—ул өй, өйнең дәвамы ишегалдың! Шул тантаналарның уртасыннан күңеле нур белән тулып бәхетле Асаф төшеп бара... Инде шактый китте, байтак төркемнәрне карап узды. Миңнеш бер җирдә дә күренмәде...

Инде күперне узды, күпер төбендәге чәчәүник янынннан ул тиз-тиз үтеп китәргә тырышты, почта ишеге дә бикле иде, аның янында да карчык-корчык кына утыра икән, алар кулларын каш өсләренә терәп ят малайны танырга теләп, бик жентекләп карап калдылар. Инде Миңнешләр өенә җитәргә дә өч өй генә калды, авыл очында урам буш, ике ап-ак бәрәнен иярткән арык сарык кына юл читендә чирәм кыркып йөри.

Калын саламы череп-каралып ишелергә торган өч тәрәзәле өй алдында бүрәнәдә утырган япа-ялгыз Миңнешне күргәч аның йөрәге сулкылдап куйды.

—Нишләп монда утырасың?—дип сорады ул олыларча.

—Нишлим соң?

—Ник уенга менмисең? Кирушлар турында уен! Бөтен авыл җыелган. Чирлисеңме әллә?

—Чирләмим...

—Нәнәң кайда?

—Нәнә Озын Микалайны эзләп китте, председательне.

—Нишләп?

—Нәнә бүген иртүк Бәчели дәдәйләргә өч тәнкә акча илтергә киткән. Бурычы булганмы шунда... Без йоклап калганбыз. Кайтса, күргән, кемдер кереп безнең киемнәрне урлап чыккан.

—Киемнәрне?

—Миңа яңа күлмәк теккән иде нәнә... Син биргән яулык та шунда иде...

Асафның йөрәге жу итеп китте... Тик алданрак жу иткән икән малайның йөрәге, Миңнешнең сүзе бетмәгән икән әле.

—Безнең авыллар урламаган аны,—ди нәнә.—Безнең авылда бурлык юк, ишекне дә бикләп йөрмиләр бездә, амбар-келәтләр дә ачык... Кенәгән күрше авылда чегәннәрне күргәннәр, я шулар килеп чәлдереп киткәннәр инде аны, я бәйрәмгә төшкән хәерчеләр арасыннан берәрсе шаярган.

Асаф Миңнешнең ике сүзен генә аңлады: «Акъюлда бурлар юк», «Безнең авыллар урламаган аны»...

Ул Миңнеш янына бүрәнәгә утырды.

—Күкәй җыярга чыктыңмы соң?

—Юк. Нәнә чыгармады. Ул бик курыкты...

—Миңнеш!—диде кинәт Асаф.—Әйдә безгә!

—Нигә?

—Безнең әни дә күкәй манды. Төш тә пешерде, сез аны шишара дисез. Чәкчәк тә катырды. Менәсеңме?

—Нәнә кайтсын инде.

—Аннары менерсеңме?

—Менермен.

Алар тынычланып, килешенеп сызыклы уйнарга керештеләр. Миңнешнең сагасы да бар икән: сага чөйделәр, ул арада Пикла түти дә кайтты. Иң

әүвәл ул Асафка манган күкәй чыгарып бирде, ике битеннән үбеп алды. Озын Микайла нәрсә дигән, бурны табарбыз дигәнме—балалар аны белмәделәр. Алар житәкләшеп диярлек мәктәп ягына таба юл тоттылар. Урам гөрли, урамда тантана, бөтен тәрәзәләргә тал бөресе—бәрмәнчекле ботаклар эленгән. Күпер төбендәге кашлакта сап-сары кимәшә башлары сибелеп утыра. Капка алларына йомшак бәбкәләре белән ана казларны чыгарганнар, гаярь, киң күкрәкле ата казлар Асафка башларын чөеп кенә карап алалар да бәбкәләре тирәсенә сакка басалар. Монда күкәйле уйныйлар, гармун тавышлары ишле булып, аннан да-моннан да янгырый, бөтен кешеләр бүген бертуган булып беткән. Алай да малайның күнел төбендә бүген ачы су тора: кемдер кергән дә ятим хатын Пикланы талап, Миңнешне матур күлмәксез калдырып чыгып киткән...

Һәм «Акъюлда бурлык юк», «Безнең авыллар урламаган аны».

Аның Сатыйны күрәсе, бөтенесен сөйләп бирәсе килде. Ләкин дөресен әйтергә көче житмәслеген сизенде: әти-әнисе ни дияр? Парпылый дәдәй? Ягымлы Ипис түти? Миңнеш ни уйлар? Бүләк яулыкның урланган акчага икәнлеген белсә ул бик нык рәнжер, бик нык!..

Асаф алып чыгып биргән чәкчәк кисәген Миңнеш бик яратып ашады һәм бик житди кыяфәт белән:

—Үскәч без өйләнешәбезме?—дип сорады.

Асаф мондый сорауны көтмәгән иде, аптырап калды.

—Яулыкны кайтарып биргәч нәнә сөенде, сөенеп бетергәч болай диде: «Бел, татарлар керәшен кызы алмый»,—диде. Син мине алырсыңмы?

Бүген Миңнешнең күңелен кайтарырга ярамый иде, малай ирләрчә ныклык белән:

—Мин сиңа гына өйләнәм дә!—дип әйтеп салды.

* * *

Нинди матур көннәр! Хыялга манылган балачак көннәре! Бер гөнаһсыз аңлашулар! Асаф бик яшьли аулак өйләргә йөри башлады. Аулак өйләрдә уйнаганда, бигрәк тә «Авыллы уеннарында» ул оялдына гел Миңнешне чакырып чыгара торган иде. Оялдына чыгасың да бер-береңә кагылырга куркып караңгыда янәшә басып торасың... Хәер, чираты житкәндә, Миңнеш тә гел Асафны чакырып чыгара торган иде... Күңелле көннәр! Ник сез болай тиз үтеп китәсез икән?..

Авыл гөр килде: сайлау якынлаша, сайлау!..Асафның әтисе агитатор, авыл унар-унар өй итеп бүленгән, хәзер һәркөн дәрестән соң Сәхип абый шушы ун өенә йөреп чыга, сайлауның ни икәнен сөйли, тәртибе белән таныштыра, депутатларның рәсемнәрен һәр өйгә таратып чыкты. Акъюл авылыннан Отто Юлиевич Шмидт белән Михайлов дигән кандидатлар тавышка куела икән. Мәктәпнең иң зур классын аерып куеп аны бүлемнәргә бүлделәр, сайлаучылар кереп-чыгып йөри алсын өчен өстәмә ишек тиштеләр... Сәхип абый көне-төне шуны тукыды: бер ишектән килеп керәсе дә бюллетеньнәр алып аерым кабинага үтеп тавыш бирәсе, аннан сайлауга килүчеләргә комачауламас өчен икенче ишектән чыгып китәсе...

Яхшы атлар жигелгән кош кебек очып торучы кашавайларга утырып, ниһаять, авылга депутатлыкка кандидат Михайлов килеп төште. Агитаторлар көне-төне йокламадылар, авылны бизәделәр, чиркәү-клубка лозунглар язып элделәр, бөтен урам чатларында кызыл әләмнәр жилферди.

Тантаналы җыелыш президиумында әллә нинди дәһшәтле кешеләр арасында Михайлов утыра. Куе яшел гимнастерка кигән, билен, иңен аркылы-торкылы сары каеш чорнаган, ә түшендә, түшендә... Кызыл Йолдыз ордены... Менә кеше дисәң дә кеше! Сатый белән Асаф малайлар төркемендә—сәхнә алдына ук килеп бөялгәннәр, салкын клуб җылынып киткән: җылы, җылы гына түгел, эссе, чөнки агитаторлар клубка олыларны гына түгел, бала-чаганы да җыеп китергәннәр. Алар да күрсен Совет демократиясен!

Башта мәктәп директоры Вәлиев сүз алып сөйләде. Аннан берәм-берәм

башкалар: колхоз председателе Җәпим дәдәй, аннан соң Озын Микайла, авыл активистларыннан Учып, кибетче Ләврәнти, Гәрәч Бәчелие, Чыпчык Марина тагын бер-ике кешене чыгардылар. Җыелышны алып баручы «Дуңгыз көтүчесе, колхозның алдынгы терлекчесе Прохор Маловка сүз бирелә»,— дигәч рәтләр гөжләп куйды...

Кышын-җәен башыннан малахае, иненнән шомарып беткән, төсен аермаслык кыптыр туны төшмәгән бу үтә юаш, басынкы кешенең сәхнәгә менеп түгел, кеше арасында да кыеп сүз әйткәне юк икән. Прыкул тирәякның иң намуслы, иң кече күңелле, карышусыз эшләп йөрүчесе булса да Ходай тел бирмәгән иде бичарага. Халыкның аерым игътибар белән йомылып калуын сәхнәдәгеләр дә чамаладылар. Районнан килгән вәкил Михайловның колагына нидер пышылдады, кандидат каешларын рәтләп, чак кына янтая төшеп атаклы терлекченең речен тыңларга әзерләнде.

Чыкты Прыкул, куе зәңгәр ыштан кигән, туры якалы күлмәге дә бөрчекле-бөрчекле, малахаен гына калдырмаган, ике кулы белән шуны бөтерә. Шактый басып торды Прыкул, депутатлыкка кандидат көтә, районның кәттә җитәкчеләре «Әйдә, әйдә!» дип көч биреп торалар, Җәпим белән Озын Микайла арттагы рәтләр дә ишетерлек итеп алдынгы терлекчене кыстыйлар, тик аңардан сөт тә, йон да юк. Сәхнәне каймалаган пәрдәләр артыннан кул сузыла һәм янып-пешкән көтүче күз алдыннан юк була. Тагын кемдер сөйли, күрше авылдан килгән кунаклар кандидатны яклап речьләр белән чыгыш ясыйлар. Алып баручы тагын «Прохор Маловка сүз бирә». Прыкул чыга, утырма якасын чишеп җибәргән, малахае тирләгән уч төбендә әвәләнеп юешләнеп беткән, зал көтә, залда шылт иткән тавыш юк. Прыкул бу юлы алгарак чыга, тамагын кырып, авызын йодырыгы белән томалап тавышы барлыгы-юклыгын тикшереп карый. Тавышы бар, сүзе чыкмый. Тагын сәхнә артына тартып кертәләр бичараны, анда нинди хәлләр булгандыр, нинди өйрәтмәләр яңгырагандыр, тарих анысын хәтерләми, мәгәр өченче тапкыр этеп чыгаргач Прыкул судан ярга ташланган кебек авызын ачып торды-торды да нәзек тавыш белән чиркәүне яңгыратып:

—Яшәсен иптәш Микайлов!—дип әйтә алды.

Депутатлыкка кандидат торып аңа кулын бирде, Җәпим белән Озын Микайла икесе ике яктан аның арык җилкәсен төйделәр. Зал котырынып бик озак кул чапкач кына:»Хезмәт ияләренең иң алдынгы вәкиленнән соң сөйләп тору кирәк микән?»—дип сүзне Михайловка бирделәр...

Депутатлыкка кандидатлар бөтен җирдә дә бер төсле, бер үк сүзләрне сөйләгәнгә күрә без монда Михайловның тантаналы чыгышын китереп тормыйбыз, чөнки безне алда тагын бер гадәттән тыш вакыйга көтә. Бу вакыйга чак кына укытучы-агитаторның, Сәхип Зәкиевнең башына җитмәде...

Сайлау участогы гөр килде, сайлау участогы кайнады. Акъюл кешеләре сүз тыңлаучан, алар таңнан килеп бәхетле тормышларына рәхмәт әйтеп тавыш бирерләр. Иртән үк килеп бетегез, диде колхоз рәисе Җәпим, аннары һәр ун өй, бергә җыелып әбәд ашый. Колхозчыларны сыйлар өчен колхоз ике печкән үгез суйды, итне кичтән үк тараттылар.

Прыкул таңнан дуңгызлар янына төшеп китсә дә, онытылып китеп шактый юанды, малларының астын тазартты, ризык бүлеп чыкты, арада бер-ике чирле дуңгыз да бар иде, аларны аерып ашатты. Эше беткәч кенә сайлауга барасы исенә төшеп, тирләп-кабаланып мәктәпкә барып керде, аны дүрт күз белән көтеп торалар иде. Сәхип Зәкиев агитатор буларак аны сайлау кабинасына хәтле озата барды. Уку-язуы чамалы булган Прыкул чүпрәк ишекле кабинага кереп кулындагы кәгазьләргә аптырап карап торды да, шул чак аның исенә «бер ишектән керәсең дә, икенче ишектән чыгасың» дигән катгый сүзләр килеп төште. Ул шушы чүпрәк эленгән ишектән керде... Каян чыгарга кушылды соң аңа? Алдынгы терлекче ни каранса да икенче ишекне тапмады. Кабина мич кырындагы, соңгы кабина булып, мич белән стена арасында шактый тар аралык калган иде. «Әһә»—дип уйлады «зирәк сайлаучы», табылды,—чыгар җире монда икән моның!

Һәм алагаем дәү, калын кыптыр туны белән кысыла-кысыла Прыкул аралыкка кереп китте. Бераз барды да туктады, тын алды. Мич төне буе ягылган, кирпечләр кызулыктан сикереп төшәрдәй булып кызганнар, стена да кызган, Прыкул тагын әзрәк алга күчте, аның бөтен тәненнән шыбырдап тир ага башлады, күз аллары караңгыланды. Эндәшергә дә курка, эндәшмәсә дә чыдар әмәле калмаган. Уттай мич белән җып-җылы стена арасына кысылып шактый торды бичара, тунын салырга уйлады, тырышып-тырышып карады, тунны чишеп тә, салып та булмый икән.

Биш минут үтте, ун минут, чыкмый гына бит кабинадан сайлаучы Прохор Малов! Ә сайлау яшерен, һәркем үзенең гражданлык бурычын аулакта башкарырга тиеш. Сәхип Зәкиев сайлау комиссиясе председателе. Ул ферма мөдире, партоешма секретаре Җаграп янына барды. Икәүләшеп кабина ишегенә эленгән чүпрәк янына барып басып Прыкулны көттеләр, тавышкара ишетелмәде. Кайдадыр, эчтә саңгырау гына нидер кыштырдый иде... Бик кирәсе, ярамый! Районнан килгән вәкил бөркет күзләре белән залны карап-тикшереп тора. Прыкул чыкса, сайлаучылар йөз процент тавыш бирде дигән сүз, районга шатлыклы рапорт очачак!

Мич арасыннан ыңгырашу авазлары килә башлагач кына Сәхип Зәкиев белән Җаграп мичнең икенче ягына чыгып, арага кысылган, хәлсезләнеп һушын җуйган сайлаучыны күреп алдылар...

Нишләргә? Ни кылырга? Прыкулның югары күтәрелгән кулында аның хокуклары беркетелгән ике бюллетень! Кабинадагы урнага аларны ул үз куллары белән салырга тиеш. Аларга кагылырга беркемнең дә хакы юк.

«Алгарак тартыл, артка чиген» дип шыпырт кына өйрәтеп карыйлар, юк, Прыкул нык кысылган, алга да бара алмый, чигенергә дә җай калмаган. Тыны-өне юк, ыңгыраша гына, бюллетень тоткан кул гына аның исәнлеген белдереп һаман кыймыл-кыймыл килә.

Районнан килгән вәкил Җаграп белән Сәхип Зәкиевне бер читкә чакырып алып: «Бу сезгә болай гына узмас... Күрәчәгегез алда әле! Мич арасына сайлаучыны юри кerткәнсез!» дип янап, райкомга шалтыратырга телефонга китте. Телефонны сайлау участогына күчермәгән өчен Озын Микайлага эләккән иде эләгүен.

Районнан: «Сайлаучы янына кермәскә... Бюллетеньнәргә кагылмаска... Мичне сүтәргә!» дигән фәрман килде. Дөньяны тузан белән тутырып, кулларны пешереп, бияләйләрне яндырып мәктәп мичен сүтеп кенә хәлдән тайган, һушын югалткан сайлаучыны кысылган җиреннән тартып чыгардылар. Хәле бөртек тә калмаса да алдынгы колхозчы, аңлы терлекче Прыкул Малов берсе ак, икенчесе зәңгәр кәгазьләрне кулыннан ычкындырмаган, явыз язмыш иркенә бирмәгән иде. Җаграп белән Сәхип Прыкулны култыгыннан тотып тордылар, һәм ул калтыранган, хәлсез кулы белән урнага, ниһаять, илгә—бәхетле Советлар иленә демократик юл белән сайлауны тәэмин иткән бюллетеньне урнаштырды.

Прыкул эләккән ун йорт кешеләре Күчтәләрнең шактый зур өенә җыелып, түземсезлек белән соңгы сайлаучының ашка килеп җитүен көтеп утырдылар. Күчтә хатыны Җәблинҗә генә «токмачымның рәте калмый инде!» дип эчтән сыкранса да, бер кем тавышын күтәрмәде, ә Прыкулга ашның иң куесы, итнең иң дәү симез калҗасы эләкте.

Ике көннән тимеркүк юртакны карага буялган өр яңа кашавайга җигеп Эзидән тикшерүчеләр килеп төште. Алар башта Сәхип Зәкиевне чакыртып кыска гына сөйләшеп алдылар. Аннан сайлау комиссиясе вәкилләре белән берәм-берәм дә, күмәкләп тә очраштылар. «Гаять зур политик актны тормышка ашырганда, мич арасында кысылып калган Прохор Малов аркасында Акъюл авылында сайлау кампаниясе чак кына өзелмичә калган! Мич арасына кереп китәргә Сәхип Зәкиев әзерләмәгәнме аны? Шул юл белән Зәкиев сайлау кампаниясен өзәргә теләгәнме?» иде вәкилләрнең сораулары, эчке борчылулары. Сәхип Зәкиев өч көн ашамады-эчмәде, ябыкты, йокысыз калды. Соныннан тикшерүчеләр киткәч кенә беленде, акъюллылар бер авыздан:»Юк, укытучының гаебе-мазары юк, терлекче Прыкул

үзе кыешрак адәм, акылы керделе-чыктылы, каушап китә торган гадәте дә барлыгын иптәш Михайловны каршылаганда бөтен авыл күрде, бу юлы да шулай саташып куйгандыр», дип аңлатма биргәннәр.

Тикшерүчеләр артыннан кар-бураны басылгач, күңелле кичке чәй янында, сап-салкын карлыган вареньесы белән сәйлүн чәен эчеп утырганда, Сәхип Зәкиевнең авызы йомылмады. Ул кат-кат:

—Гажәп мәрхәмәтле халык икән бу керәшеннәр!—дип соклануын белдерде.—Алдан килешенеп тә йөрмәгәннәр, ә һәммәсе бер сүздә булганнар. Кысып та караганнар тегеләрне, берәү дә яла ягарга ризалашмаган... Куркып та тормаганнар диген! Шушы керәшен авылында нинди якты кешеләр бар икән!

—Гаебең юклыгын барысы да беләләр ич!?—дип хатыны тантананың сәбәбен үзенчә ачарга маташты.

—Юк!—дип аңа каршы төште Сәхип.—Алар гел шулай бер-берсенә ярдәмчел, игътибарлы, кече күңелле халык икән. Белдем, авыл кешеләре арасыннан кулакларны табып, һич кичекмичә Себергә сөрергә районнан фәрман килгәч тә алар берәүне дә йолкып алырга ирек бирмәгәннәр! Җыелыш җыеп хәллерәк кешеләрне өйләреннән мунчага күчергәннәр дә, аларны аяп калганнар. Ә районга: «Кирәкле кешеләргә тиешле дәрәҗәдә җәза бирдек»- дип хәбәр иткәннәр. Районнан прокурор үзе килеп киткән, мәгәр алар сүзләреннән кайтмаганнар.

Чәй эчү тагын да күңелләнде. Сәхип үзенең җиденче чынаякны эчеп утыруын да онытып җибәрде. Асафка карлыган вареньесын бармак калынлыгы ягып бирделәр, ул да дүртенче телемен бөкләп бетереп килә иде.

—Мин аларны фәкать Олы көндә генә туганлашалар дип белгән идем,—диде әнисе сигезенче чынаякны ясый-ясый.

—Урыс патшасының аларны озак еллар эзәрлекләве, кара урман уртасына кереп качсалар да килеп табып, аларга тынгылык бирмәве, көчләп чукындыруы, чукынмаганнарына көн күрсәтмәве аларны шулай бердәм булырга өйрәткәндер бәлки?—дип дәвам итте Сәхип Зәкиев.—Көчсез халык газаплардан соң таркала, бирешә, ә нык халык җәбер-җәфалардан соң да рухи—эчке көчкә ия булып кала...

Бу әңгәмәдән соң Асаф байтак нәрсәләрне аңлап калды. Мона кадәр Туганай авылындагы яшьтәшләреннән, усалрак малайлардан отып кайтып «керәшен-керәшен керкәле, баш түбәсе серкәле!»—дип үртәшеп куйгаласа да бүген авыл халкы турында бүтәнчәрәк уйлады: «Алар аның әтисен саклап калганнар!» Бу бик мөһим иде. Дөрес, Туганай авылы малайлары «керәшен» дип Асафка кушамат тактылар һәм бу җырны аның үзенә багышлап такмаклаганнар иде.Житез малай ике авылда да чәкәләшергә ярата торган иде.

Дуслары да җитәрлек иде Асафның. Акъюлда Сатыйдан тыш үзләреннән бер класс түбән укучы Гәрәч Бәчелие белән аерата нык дуслашты Асаф. Бу юаш, төптән таза-юан чыккан, җиз чәчле, олырак авызлы малай, Олы суга төшә торган күпергә якын гына, бакча артындагы мунчада яши иде. Җиде баласы, карт әтисе белән гәрәчнекеләрнең дә өен алганнар. Районнан килеп аларны колхозга кермәгәннәре өчен үз йортларыннан мунчаларына күчергәннәр иде. Бәчели белән Асаф тиз дуслаштылар. Акъюлга килгәч туган энесе Азат калкынып, аякка йөри башлагач бу дуслык тагын да артып китте, үз өе тулы бала-чага булса да Бәчелинең бәләкәй балаларга мәхәббәте чамасыз-чиксез иде. Энекәшләре генә түгел, якын-тирәдән биш-алты малай аңа көннәр буе тагылып йөриләр, ул аларга сыбызгы ясап бирә, суга чумганда батмасыннар дип яр башыннан сагалап тора, кышын табанчалары астына калай кага, бозда шуарга сөңге хәстәрли. Язын бәрәңге утыртканда, көзен казып алганда Асафлар ызанына иң әүвәл ул килеп җитә... Асафның энесе Азатны ул аерата яратты...

Бер тапкыр аларның өй эчен тетрәндергеч бер вакыйга булып алды. Мөнәвәрә апа Бәчелинең мич арасына кереп песи табагында калган ашны ашап бетергәнен күреп алды. Башта каушап, читенсенеп малайга бер сүз дә әйтмәде, көндезге аш вакыты җиткәч ишегалдында Азатны уйнатып

йөргән малайны өстәл янына чакырды. Бәчели бик озак үгетләгәч кенә өстәл янына килеп утырды һәм шунда, аш янында Мөнәвәрә апа иплән кенә сораштыра башлады. Ничек яшиләр, ни ашыйлар, ипи салалармы? Оннары калганмы?..

Бәчели башта ык-мык килеп, өч сорауга бер җавап кына биреп утырса да Мөнәвәрә апа гәрәчнекеләрнең тормышы үтә кыен хәлдә, өзелер бер җиргә җиткәнен аңлады... Ипи салмыйлар икән, сыерлары быел кысыр калган, налугка акча җиткерә алмагач кышлау бозауларын базарга алып чыгып сатканнар, бер әтисе эшләгән була, ләкин аның эшенә киртәләр тупас рәвештә җимерә алмаслык итеп корылган икән. Былтыр лесничествода печән чабып байтак акча эшләсә дә, быел районнан «аерымнарга эш бирмәскә», дигән боерык килеп, әтисе эшсез дә калган икән...

Шул көннән Асафның әнисе—Мөнәвәрә апа гәрәчнекеләрне үз итте. Асафтан калган вак-төяк кием-салымның күбесе Бәчелинең энекәшләренә күчте. Сәхип абый базарга, ярминкәгә барса, болай, мәктәп йомышлары белән Эзигә кагылса да, үзләренеке янына гәрәчнекеләргә дә күчтәнәчләр кайтты. Бәчелинең нәнәсе күз яшьләрен түгә-түгә Мөнәвәрә апага рәхмәт укыды:

—Шул тиклем күчтәнәч алып кайтмаса инде, шоннык... Рәхмәт инде сезгә, гомерегез якты булсын, бала-чагаларыгызның рәхәтен күрегез...

Марпа түти дә бурычлы булып калмады, Асафларның өйләрен җыештыргалап чыгарды, йонын егерләде, җеп катты, вак-төяк бүтән йомышларын үтәде. Шулай кул алмаш бер-берсенә булышып яшәделәр. Бала-чаганың татулыгы, дуслыгы ата-аналарга да күчә икәнлегенә тагын бер мисал булды.

Халык бердәм, тату булып, тормышның кыенлыкларын бергә-бергә үткәреп җибәрсә дә, авыл халкының көчсез, аптырашта калган очраклары да була икән.

Асафның тузган бишмәтен, иске колакчын бүреген киеп бик дәртләнеп укый башлагач Гәрәч Бәчелие, кышның иң салкын көннәренең берсендә, декабрь урталарында үлеп китте. Бәчели, кичә-бүген тап-таза йөргән бала, мәктәптән кайткач «башым авырта» дип сәкегә ятып тора да, кичкә таба тәне кызышып саташа башлый, төне буе ыңгырашып чыга, иртәнгә таба, тыгызланып күккә сарган йолдызлар агарып сүнгәндә җан бирә...

Моны ишеткәч Мөнәвәрә апа бик нык елады. Асафның өр яңа чиста күлмәк-ыштаннарын алып гәрәчнекеләргә китте. Ишле балалар табутка куелган Бәчелигә карап куркып, почмакка сеңгәннәр, тар, тәбәнәк мунчада кеше күплектән тын алырлык та һава калмаган иде. Ул Бәчелинең туганнарын җыеп үзләренә алып кайтып китте, балаларга солы коймагы пешереп ашатты, исле сабын белән бит-кулларын юдыртты, һәрберсенә бүләк-күчтәнәчләр өләшеп чыкты. Бәчелинең табутын мәктәп аты Аманат атлы алаша җигелгән чанага салып зират тавына алып киттеләр. Сатый белән Асаф та чана артыннан иярделәр.

Үлем белән беренче тапкыр очрашулары түгел иде аларның. Беренче класста укыганда Пидыр эч авыртуыннан егылып, Эзи больницасында җан биргән иде. Пидырны озатырга да, күмәргә дә бармадылар алар. Пидырның үлеме түгел, үз хәлләре гаҗәп иде... Бар иде Пидыр, хәзер аны «юк»диләр... Ничек алай? Нигә алай? Сөйкемле генә, бераз сакаурак, сипкелле малай иде Пидыр! Сул ягында, яңагыннан түбәнрәк бик яшь чакта кичергән олы авырудан калган яра эзләре дә бар иде. Юк кына мәзәктән дә чәчелеп көлә торган шат күңелле иптәш иде!..Менә хәзер юк! Сатый белән Асаф Пидырның үлеме хакында бер сүз дә алышмадылар, ул хакта бөтенләй сөйләшмәделәр, мәгәр аларның күбрәк шымып йөрүләре, карашларының сүрәнлеге бу гаделсезлекне кабул итә алмауларының билгесе иде...

Гәрәч Бәчелие үлеме, инде исәя башлаган, дөнья төтененең исе борынын туктаусыз кытыклаган Асафка ифрат дәрәҗәдә авыр тәэсир итте. Әнисенең Бәчелине җәлләп, аның мич арасында мәче табагыннан калган ашларны җыештырып йөрүен искә алып елавы да анда үткән, кыска гына тормышындагы хатирәләрне исенә төшереп куйды.

Бервакыт Бәчели иңенә Азатны утыртып, урам чирәмендә әрле-бирле йөгереп йөри иде. Азат, куанычыннан нишләргә белми, аяклары белән Бәчелинең күкрәгеннән төя, туктаусыз көлә, рәхәтләнә иде... Юлда нәни генә таш очрап Бәчели абынып егылган. Азатны кулыннан ычкындырмаган, ипләп кенә икәүләшеп барып төшкәннәр. Чирәмдә таш берәү генә булмаган икән, икенчесе Азатның маңгаен тишеп, сызып кына кан чыккан. Асаф, аларның тавышын ишетеп, якын барса, Бәчели яргаланып беткән аякларын бөкләп чирәмдә утыра, аның янына Азат сыенган, аның җылагы беткән, әмма Бәчели үксеп-илереп һаман елый иде. Ул шул тиклем курыккан, йөзе агарган, күз яшьләре олы авызына кадәр агып төшкән иде...

Асаф шунда, кызып китеп, Бәчелинең яңагына бер-ике тапкыр чапылдатып суккан иде. Бәчели каршы килми, кая ул, «тагын сук, ичмасам миңа җиңелрәк булыр», дигән сыман Асафка таба тартылган иде...

Нигә сукты шул чагында Асаф? Бәчелинең ни гаебе бар иде? Ярата иде бит ул Азатны, чиксез ярата иде. Гаебе бар дип уйлап күңеленнән үксеп елый иде. Малайның әз генә тишелгән маңгаена, (сыдырылып кына киткән икән!) бака яфрагы өзеп ул кан саркуын туктаткан иде бит! Ул барып җиткәндә Азат еламый да иде бит! Бәчелине кызганып, аңа сырылып утыра иде ул. Елаучы Бәчели иде!Кайгыручы ул иде! Нигә кыйнады аны Асаф!? Нигә сукты!?

Ул декабрь җиленнән ышыкланып муенын бишмәт якасы белән капларга тырыша, шарфын тартып-тартып куя, шарф аны тыңламый, бара-бара тагын бүселеп чыга, җил малайның куенына үтеп керә, арттан бишмәт итәген күтәрә...

Алар барып җиткәндә каберне казып куйганнар иде инде. Шунда ук имән агачыннан юнылган, тасланган авыр хач та тора. Хачка «Раб божий Урамов Василий Герасимович» дип язылган... Нигә «Раб божий?» Бәчели кол идемени? Асаф як-ягына каранды һәм керәшен зиратындагы бүтән хачларга да шуңа охшашлы сүзләр язылуын күрде. Башта ул моны аңламады, шыпырт кына әтисеннән сорады: «Алла колы!» дип язылган икән хачларга, әтисе аңлатып бирде. Асаф Ипис түтиләрнең тәре почмагында утырган моңлы күзле Алла бабайны күз алдына китерде. Шул кешенең колы булып чыга инде Гәрәч Бәчелие... Нигә «кол» икәнен генә аңламады ул...

Дөя сырты, дөя сырты булып яткан кар таучыклары арасындагы кызыл сандык кебек яңа кабергә карагач ул имәнеп китте. Хәзер шунда, җир куенына Бәчелинең табутын төшерәләр. Бәчели шушы салкында, балчык арасында калачак. Кечкенәрәк табутның сап-сары нарат такталардан ясалган булуын да, табут өстенә кемнендер кап-карадан тәре сызып куюын да ул хәзер генә күреп алды бугай. Бераздан баш-башыннан бистәрләр белән тотып табутны кабергә төшерделәр... Һәм такта өстенә дөбердәп-шаулап туң балчык ява башлады. Алла колы Бәчелинең баш очына имән хачны утыртып калдырдылар...

Табут анда калгач чана киңәйде, юл тау түбән, дәү тире бияләйләре арасына дилбегә кыстырган Парпылый дәдәй янына Сатый белән Асаф менеп кунакладылар. Асафның әтисе дә шунда сыйды. Юл таудан түбән төшсә дә чана әкерен генә шуа, зират юлы карлы, җәяүле буран кузгалып, бая ясаган юлларны томалап бетереп килә.

—Аманат Җәкәүләрнең атымы бу, тәтә?—дип сорады Сатый. Парпылый дәдәй, дилбегәне чанадагы саламга ташлап тәмәкесен төрде, чакма чагып ут кабызды, җил тау битенә ачы тәмәке исе таратты.

—Шуларныкы,—диде байтак баргач Парпылый дәдәй.—Әле менә Бәчелине уйлап кайтам... Үлде, котылды.

—Нигә алай дисең, Парпылый дәдәй?—дип сорады Сәхип.

—Дөресен әйтәм. Менә, пример: аның тәтәсен алыйк. Гәрәчне әйтәм, аның кебек уңган кеше авылда бар идеме икән?!Безнең Акъюлда ындырның бер өлешенә киндер чәчмәгән кеше юк. Бәрәңге дә киндер. Корсакны бәрәңге белән алдасак, өс-башка шул киндер җитеп бара. Киндер мае да тамак туклыгы. Гәрәч җир тырмап яшәде, сыер сатып алды, йортын бөтәйт-

те. Бала баскач алты почмаклы йорт салып керде. Җиде баласын ничек бер өйгә сыйдырсын? Хәлдән таеп өй салып кына кергән иде, «такта түбәле, алты почмаклы йорт хуҗасы» дип мунчага күчерделәр аны. Дүрт почмаклы ару гына өйгә сыймаган семья мунчага сыйды. Балалар идәндә тәгәри, өс-башлары юк, нигә чирләмәсен Бәчели? Үлмәде ул, котылды! Ни рәхәт күрер иде дип беләсең? Күрденме, Гәрәчләр ирле-хатынлы еламады да... «Кодай бирде, кодай алды», диләр алар. Җидедән берәү киткән икән, алтысы калган әле. Сигез җанның тамагын туйдыр, киемен юнәт... «Әллә Себергә чыгып китәсе калганмы?»—дип уйлый Гәрәч. Менә син учитель, гәҗитләр укыйсың: нигә илдә хәерчеләр күбәя? Нигә арта алар? Ә-ә, белмисеңме? Мин дә белмим...

—Балалар алдында алай сөйләшмә инде, Парпылый дәдәй,—диде Сәхип.

—Балалар булмаса мин моны сөйләшеп тә тормас идем. Синең белән миңа дөнья хәлләре нигә инде? Балалар күреп-ишетеп үссен... Зиратка да юри алып бардым мин аларны. Дөньяны белим дисәң зиратын да күреп яшәргә кирәк. Олыларга сөйләп ни файда?

Шытырдап каткан инеш бозын кичеп тыкрыкка кергәч алар чанадан сибелеп калдылар, юл үргә менә башлады. Асаф белән Сатый янадан чанага утырып та тормадылар, өйләренә таралдылар.

Көн кичкә авышты, тиз-тиз карангыланды, Асаф дәресләрен әзерләргә утырды, аннан-моннан гына китапларын караштырып, өйгә эшләрен тәмамлагач, катлы-катлы боз каткан тәрәзәгә карап утырды. Салкын кабер, каткан кызыл балчык, сагызланып торган сары табут такталары күз алдына килде. Ул Бәчелине җәлләп шыпырт кына елап җибәрде. Төне буе саташып ятты, иртән тәне кызышты, әнисе мәтрүшкәле чәй эчертеп аны калын юрганга төреп яткырды. «Суык тигән» дип аны өч көн рәттән мәктәпкә җибәрмәделәр. Өченче көнне аның янына классташлары Сатый белән Миннеш кереп чыктылар. Мөнәвәрә апа аларны кура җиләге вареньесы һәм шишара белән сыйлады.

* * *

Бәйрәмнәр ни өчен кирәк?

Моны өзеп кенә әйтеп булмыйдыр... Акъюл авылында Октябрь бәйрәмен дә, Беренче майны да ел саен диярлек билгеләп үтәләр. Май бәйрәме Олы көн тирәсенә туры килгәнгә аны тыйнаграк кына бәйрәм итсәләр, Октябрь бәйрәмен олылап үткәрәләр.

Якын-тирәдәге керәшен авыллары үзләренә бер Төп бәйрәмне—престольный дип сайлап беркеткәннәр кебек хис кала торган иде. Сарсазлар Птрауны олылый, бүтән авылларда йә Элҗен, йә Көҗмә-Демиәнне бәйрәм итәләр, ә Олы көн, Пыкрау бөтен авыллар өчен дә зур бәйрәм.

Һәр бәйрәмнең үз төсе, үз җолалары, үз тәртибе булган кебек совет бәйрәмнәрен дә үз кагыйдәләренә яраштырдылар Акъюл кешеләре. Чиркәү алдындагы мәйданга дүрт озын багана утыртып, багана башларын кайчы ясап такталар каккаладылар. Шул аркадан ерак та түгел, мәйдан башында агачтан трибуна ясадылар, аны акка-зәңгәргә әйбәтләп буядылар. Май бәйрәмендә арка очына Кызыл әләм эләләр, баганаларны иртә чыккан урман чәчкәләре белән бизиләр. Октябрь бәйрәмендә иртәнге чәйдән соң, авылның ике очыннан демонстрация кузгалып китә: яше-карты, олысы-кечесе бәйрәмгә чыкмый калмый. Трибуна алдына җыелып басалар, трибунага авыл-колхоз активлары, укытучылар чыгып тезелә. Бәйрәм саен җитәкчеләрдән берәү ялкынлы сүзләр сөйләп бәйрәм белән котлый. Акъюллылар игътибар белән тыңлыйлар, гөрелдәтеп кул чабалар да айбагыр чиртә-чиртә өйләргә таралалар. Бу бәйрәмдә кунакка йөрүләр юк. Кичен тагын клуб-чиркәүгә җыелалар, ике сәгатьлек доклад тыңлаганнан соң, сәхнәгә уен-көлке менә. Концерт бик озак, ярты төнгә кадәр дәвам итә...

Акъюл авылының ел дәвамында сагынып көтеп алган бәйрәме Троыйсын! Аны керәшенчәләп «Яфрак бәйрәме» дип тә атап йөртәләр...

Әгәр Олы көн Акъюл кешеләре өчен яз, балачак һәм балалар бәйрәме

икән, Троыйсын яшьлек тантанасы, мәхәббәт бәйрәме дә. «Яфрак бәйрәме» диюләре белән дә хаклылар. Троыйсын урман-болыннар яшәргәч, басуларда арыш уҗымы күпереп калкынгач, шомырт чәчәк атканда май азагына туры килә. Бу инде бернинди тантаналар белән чагыштыргысыз гүзәл бәйрәм! Туганлык, кардәшлек, юмартлык, игелек бәйрәме!..

Әгәр шундый мәгънәле, акыллы бәйрәмнәр булмаса Акъюл халкы шушы кадәр юмарт күңелле, сабыйларча беркатлы һәм гадел булыр идемени? Кемнәрдер дини бәйрәм итеп исәпләп аны үткәртмәскә тырышып караганнар, бәйрәм алдыннан бик акыллы, күп-күп калын китаплар укып акылларын ныгыткан, тешләрен үткерләгән, бәхәсләрдә җиңеп чыга алмаганда әңгәмәдәшен: «Ну. Син... чамалап!» дип сүз белән, шуннан ике бармагын ике бармагы өстенә аркылы куеп рәшәткә ясап туктатырга гадәтләнгән шома кешеләр килгән. Алар кичке бәйрәм буласы урынга мөгәҗи амбары шыгына кызыл эскәтер җәелгән өстәл чыгарып куйганнар. Өстәл тирәсенә акыллы кешеләр тезелгән, сөйләүченең сүзләре үтемлерәк һәм дәһшәтлерәк булсын өчен өстәл янына биек кафедра чыгарып бастырганнар... Ләкин бәйрәмне беркем дә тыя да, туктата да алмаган. Тыярлар иде—авылдагы һәр йортка, һәр ишегалдына якындагы утыз-кырык авылдан кунак килеп тулган, иң ярлы, иң фәкыйрь саналган Кытлык Пумаларда да (бала баскан) унбиш-егерме кунак утырган.

Әле Троыйсын урыс атнасы көнне, якшәмбедә генә булачак, ә татар атнасы—җомга көнне Акъюл авылына бөтен яклардан яу төшә башлый. Моңарчы тын гына яткан урмансыз Сарман, Зәй яклары гына түгел урман юллары да уяна, аты барлар атка төялешеп, ат җикмәгәннәр җәяүләп, төркем-төркем, берәм-берәм, өер-өер Акъюл ягына карап юл тоталар. О-о, ул кабык арбаларга ике яклап төялеп, аякларын салындырып тирә-юньне моңга, сөенечле хәбәрләргә күмеп Яфрак бәйрәменә килүчеләрне хәзер күрергә иде!..Кайлардан гына килмиләр иде Акъюл авылына! Ерак Сәрәпәледән, Якты Күлдән, Ләке, Сармашбаштан, Мәлемнән һәм Кабаннан һ.б... Ерак шәһәрләрдән дә сирәк-мирәк кунаклар кайта иде. Ул чагында әле авыллардан шәһәргә күчеп киткәннәр әз, әмма булганнарының кайберләре кайта. Керәшен генә түгел, Яфрак бәйрәменә урысы, татары өерелеп килә. Туганнарың юк икән—туганлашырсың! Белешең юк икән—белешерсең! Акъюлда капкалар киң итеп ачылган! Ат тугарырга ишегалларында урын бар икән, теләсә кемгә барып кер, атыңны тугар, кунакларың шыбырдап коелсын, ишле булсыннар алар, сансыз-исәпсез булсыннар, монда һәркемгә урын җитәрлек. Хуҗалар сине сөеп, сөенеп каршы алачак. Татармы син, урысмы—әйдә кил генә. Троыйсын Акъюлда яз тантанасы! Яфрак бәйрәме—мәхәббәт бәйрәме! Кем булсаң да син монда өлешсез кала торган түгел. Акъюл кешеләренә бәйрәм—мәшәкать, чагыштырып булмый торган рәхәт мәшәкать, бөек мәхәббәт. Алар бөтен авыл берләшеп, бер сүздә булып тирә-юнь авыллардан җыелган атлы-атсыз кунакларга капкаларын, түрләрен генә түгел, күңелләрен дә ачып җибәрәләр... Тукта, кер, утыр, кунак бул. Казанда бер туктаусыз тозлы иттән пешергән мул аш кайный, кемдә калҗа, кемдә тозлы каз-үрдәк түшкәсе. Сирәк-сирәк кенә булса да тәкәләр дә суела, алары да уртак табынга чыга... Мич ягылган, анда чуен-чуен кабыклы, әрчелгән бәрәңге утыра, кәбестә штие пешә. Борчак боткасы да, талкан да, эремчек пирогы да, дурычмак та, көрнек тә—кабартма белән коймак та кунак сые. Пешкән күкәйләр бәләкәй чүмәлә булып агач табакларда көлешеп яталар. Күпереп пешкән арыш ипиен киндер, мәк маена мана-мана пешкән күкәйне әрчеп, йолдызлар кебек ялтырап яткан эре-эре тоз бөртекләрен сибеп кинән... Хуҗаларның мангаеннан тир ага, кат-кат ягылган мич өйне кыздырган, кече якта бертуктаусыз самовар кайнап утыра, берне эчеп бетерәләр дә, икенчене куялар, хуҗа кызларына ияреп кунак кызлары су юлына төшәләр, нәзкәй билләр сыгылып-сыгылып кала, Олы су йомгакланып, дулкынланып, җырлый-җырлый ага... Чүке, Чуал болыннарыннан, Олы су буеннан чәчәкләрдән үрелгән такыялар ага, көннәр ага, еллар ага... Бүген бәйрәм, бүген мәхәббәт бәйрәме, авыл арасында булып алган вак-төяк

талашлар, үпкәләр, кинәләр онытылган, иң саран кешеләр дә бүген юмарт. Аксак Ибаннның ике кулы, бер аягы бар, ул да сынар балагын җилфердәтеп йорттан-йортка чаба... Йөзәрләгән, меңәрләгән халык җыелган Акъюлда Яфрак бәйрәмендә берчакта бер исерекнең булганы юк, күңелләр аек, тәннәр саф, арадашлык эчкерсез. Әйе, бал коялар, күмешкә кайнаталар, ләкин Троыйсында ишле табыннарга да эчемлек куелмый, бу аек бәйрәме! Меңләгән кешене чын күңелдән җыйган Акъюл халкы бәйрәмне эчемлек сөреме белән пычратмый, эч әнә, чәйне теләгәнчә эч, чишмә суы, әйрән әзерләнгән, чүлмәк-чүлмәк чөгендер суы кар базы авызында сине көтеп утыра. Катык бар, эремчек бар, мул булмаса да акмай бар, кунаклар ризыкның дәрәҗәсен беләләр: акмай белән балны чәй калакларының очына гына эләктереп кабалар, күз күргәч шул җиткән, карынны ярмаланып торган бәрәнге белән дә туйдырырга була. Ә Акъюл бәрәңгесе! Андый бәрәңге хәзер төшкә дә керми. Үзе эре, кабыгы чубыркаланып, шадраланып тора, күзәнәге сай, каерып ачуга һәр төптән бер итәк бәрәңге тәгәрәп чыга. Үзе ак, үзе ярмаланып таралып тора, ашта озаграк кайнатсаң тәмам эреп бетә. Симез калҗа янына турап, өстенә өре сибеп җибәрсәң, әллә ит ашыйсың, әллә бәрәңге шул кадәр дә тәмле... Мөгаен, бөек Тукаебыз ашап мактаган бәрәңге дә шуңа охшаган булгандыр...

Әле татар атнасы гына... Әле бәйрәмгә тагын ике көн бар, ә кунаклар инде шактый күренә. Иң әүвәл кунакка йөрергә яраткан ялгыз-йолгыз, тәрбиячесез калган ятим-ялпы карчык-корчык килә башлый. Алар җомга көн мунча кереп, кергән бер йортта кайнар көлчә белән чәй эчеп, белешләрен йөреп чыгалар. Акъюл авылының яңалыклары белән танышалар. О-о, Акъюлда яңалыксыз бәйрәм буламы соң?.. Быел гына җиде кыз кияүгә чыккан... Кызганыч, берсе озак та тормыйча әйләнеп кайткан, кыз анасы дулап барган, аның алдына уртасы тишек коймак куеп сыйлаганнар. Акъюлда әхлак мәсьәләсе бик каты куелган, кызлар саф, егетләр сабыр, җимешен ашыйсың килә икән агачын үз бакчаңа күчереп утырт, үзеңнеке ит. Кемнәр яңа йорт җиткереп кергән, кемнәр бәйрәмгә яңа капка торгызган, Югары очның Сырпиун килене игез бәбәй тапкан. Баланың анасы авыл советына төшеп: «Улымның берсенә Микайла, икенчесенә Миша исеме языгыз», дигән. Килен-җиңгәчәйгә: «алар икесе дә бер исем!» дип әйтеп караганнар, юк кына бит, тәки бер улын Микайла, икенчесен Миша дип яздырып кайткан... Бу да яңалык!Кемнең сарыгы өч бәрән китергән, кемнең сыеры кысыр калган, кемнең ата казын күрше авыллар урлап киткәннәр дә, хуҗалары танымасын өчен муенын зәңгәр буяуга манганнар... Колхоз хәлләре дә телгә алына, Кирушлар турындагы подвалда бәрәңге быел тоташ чергән икән. Пешереп дуңгызга ашатып караганнар, кабып та карамыйлар икән хайваннар... Язгы ташу Учыпларның су ярына бураган мунча бурасын агызып, Илайлар ындырына китереп чәчкән, Илайныкылар суык суда бата-бата бүрәнәне җыйганнар. Аталарының үпкәсенә суык тиеп, хәзер дә корык-корык ютәлләп йөри, ди...

Инде атна алды... Бу көндә кардәш-ыру килә башлый, агыла гына. Туган-тумачалар елашып күрешәләр, бер минуттан күздән яшь кибә, күз чокырларына сөенеч килеп тула, сүз китә, хәбәрләр алмашына. Кардәш-ыру атна алдыннан килеп бетә, чөнки иртәгә килеп туласы кунакларны каршылаганда Акъюл халкына, хуҗаларга булышырга кирәк. Суын ташыйсы бар, казан астына ягарга чыбык-чабыгын әзерлисе бар, онны иләп, камыр куясы, пирог пешерәсе, дурычмакка бәрәңге әрчисе, мал-туарга үлән-мазар хәстәрлисе бар. Көтү чыкса да ул иртә кайта, кечке уенга көтүчеләр дә катнашырга тиеш. Меңләгән кеше читтән килгәндә көтүчеләр дә мәхрүм калырга тиеш түгел. Көтү иртә кайтты. Көтүчеләр дә тантаналарда катнашты.

Үткән гомере турында шулай уйланды Асаф. Аның яшьлек дусты Сатый-Җәгүр шушы мөхиттә тәрбияләнде һәм халкына, авылына, диненә, туганнарына, дусларына тугрылыгын саклап кала алды. Дустының әтисенә, нигезенә хөрмәт, ихтирам күрсәткән бу бөек затны нинди гамәлләр белән олылап була икән?—дигән сорау аның баш миендә айкалды. Акъюл халкы хуҗасыз

калган авылдашының йортын да ел дәвамында бакый дөньяга киткәннәрнең рухы рәнҗемәслек итеп карарга ниятләгән икән!

Билгеле бер яшькә җиткәч анның улы да яшьлегенә борылып кайтыр. Яшьлегенә борылып кайту—ана күңел тынычлыгы өчен кирәк. Ә нәрсә хәтерләр ул? Кешелекне нинди юллар үтеп, нинди вакыйгалар белән аралашып аңлый алыр? Очрашкач, дус-ишләре сорагач ул да тост әйтә торган иде: гел бер үк тост: «Мин олыгайгач минем янымда әтиемнең дуслары кебек дуслар утырсын иде»,—дип әйтә иде. Бу тостны ул да белә, бәлки утырдашлары да берничә мәртәбә ишеткәннәрдер, әмма беркем дә аны кабатлауны искә алганы булмады, җыелганнар һәммәсе дулкынланып, әллә чынлап, әллә юри генә хисләнеп «Менә молодец!» «менә әйбәт!» дип тулы чәркәләрен туклыклы ризыклардан кабарынган кызыл иреннәренә якын китерәләр иде.—Кем булыр анның улы?—Нишләр?—Үз улларына ни сөйли алыр?

Һәркем сират күперен үзе кичәргә тиеш. Ә ул үз баласын кочагына алып сират күпереннең зур бер өлешен уздырды инде.

Ул шунда гына улының бәхетсез икәнен һәм ул бәхетсезлекне ата кеше үзе китерүен аңлады. Бәхет китерәм дип бәхетсезлек китергән икән!..

Асаф Сәхипович күп тантаналарда катнашкан кеше, ул анның тышкы һәм эчке механизмнарын яхшы үзләштергән, ничек башланасын, ничек тәмамланасын яхшы белә. Моңарчы шундый тантаналардагы үзенә күрсәтелгән хөрмәтне ул үзенең дәрәҗәсе, яулап алган казанышлары өчен дип ышанып килсә, бүген мактау сүзләренең бары тик анның биләгән урынына, креслосына гына юнәлдерелгән икәнен аңлады. «Гөлсинә янына кагылыргамы, юкмы?» дигән сорау газаплаган мие кинәт ачылып китте. Ул үзенең гади кеше булуын сизде, һәм шушы мөнәсәбәт анның икеләнүләренә ахыргы чикне куйды: кагылып чыгачак!

*7 март, 1988 ел. Переделкино.*

---

## Авторлар игътибарына

***Кульзма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:***

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
7. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
8. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)



**Илсөяр Иксанова**

# КҮҢЕЛ ДИГӘН ДӨНЬЯДА...

## Дөнья

Бәхет белән бәхетсезлек—янәшә.

Асылъярны әчкечегә ярәшә.
Зыялы ир,
Җаһил хатын—бер оя.
Каршылыкка корылгандыр бу дөнья?

Күңел дигән Дөньяда да
Ак-кара.
Дәфтәреңне
Фәрештә дә, Иблис тә актара.

## Сөембикә манарасы

Манаралар түгел,
Күңелләр дә
Айсыз калган чакта боегып,
Син яктыртып тордың күңелләрне
Тарихлардан килгән нур булып.

Бүген, шөкер,
Аең балкып тора...
Җанны тартып торган манара.
Син—безнең җан,
Авышсак та ялгыш,
Хакыбыз юк безнең аварга.

---

Илсөяр ИКСАНОВА—*шагыйрә; "Ышанасы килә", "Кышкы канәферләр", "Син язган язмышым" исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

## Алдану

Гыйнвар.
Плюс биш, плюс өч...
Бөрегә тулышкан агачлар.
Күкләрдән
Ак хыял шикелле
Ишетелә,—
Ишелә юеш кар.

Бик тиздән ак чәчәк күлмәген
Кияргә җыена алмагач.
Алдагы зәмһәрир суыклар
Калдырыр бөтенләй ялангач.

Гыйнвар.
Агачлар бөредә.
Саташып ымсыну бу бары.
Хәтердә яңарды милләтнең
Яз, диеп алданган еллары.

⁂

Нинди елак кыш булды бу?
Кайда суык-зәмһәрир,
Адаштыргач бураннары?..
И, Табигать,
Бир әмер!

Туктат, туктат бу елакны.
Кемгә җиңел, и җаным?
Кыш лабаса...
Мин түгел бит.
...Хәтта мин дә еламыйм.

## Үзгәреш

Тигез иде дөнья кар астында—
Ап-ак иде күз күреме ара.
Язгы ташкын килде бөтерелеп,
Ташкын сулар актарылып ага.

Калкып чыга өскә, чыга бары—
Кипкән яфрак, үлән, чүбе-чары...
Ап-ак иде дөнья кар астында,
Чуарланды...
Эреп бетте кары.

⁂

Мәхәббәттә гөнаһ юк, дип
Үзеңне аклап була.
Бәлки гөнаһсыз кабынган
Хисеңне яклап була.

Әрнүдән торган җаныңны
Беркемгә ачып булмый.
Кешедән качып буладыр,
Үзеңнән качып булмый.

## Яшерен йөрәк

Йөрәгеңне яшергәнсең
Ахры хәтта үзеңнән.
Күпме генә яшерсәң дә
Күреп алдым күзеңнән.

Күреп алдым, куркып калдым—
Нечкә икән йөрәгең.
Шаяртканда, мин бит синдә
Йөрәк барын белмәдем.

Үртәдем... үзем үртәлеп
Бик текә йөргәнеңә.
Гафу, кагылсам уйламый
Яшерен йөрәгеңә.

## Аерма

Ул—кош,
Син—кош.
Тиң дип әйтеп кара,
Тиң тоелса әгәр
Аккош белән карга...

## Тормыш

Кемгәдер—уй,
Кемгә—уен.
Уеннан—уймак,
Ачы коймак.

## Тол хатын

"Без дә гөлләр кебек идек
Гөл булып яшәр идек.
Кадерлем дип, бәгърем дип,
Җаным дип дәшәр идек...

Без дә гөлләр кебек идек,
Каерылды канатлар.
Тагын күпме ялгыз җаннар
Бу сүзләрне кабатлар...

Без дә гөлләр кебек идек..."—
Үрсәләнә ялгыз хатын
Ялгыз хатын, тол хатын.
Усал телле, парлы ярлар
Хаклап тормый тол хакын.

Нахак сүзем рәнҗетер, дип
Уйламый шул ялгыш та,
Гаебе дә, гайбәте дә
Тол хатынга ябыша.

Аһ, болай да баскан иңне
Язмышның көянтәсе!
...Чәйни тәмләп ир хатыны
Һәм... бишнең сөяркәсе.

Ир исеме мир каршында
Төшерми шул күләгә.
Аңа төшәр күләгә дә
Тол хатынга эләгә.

"Без дә гөлләр кебек идек..."—
Өзгәләнә тол хатын.
Сагышыннан сулган гөлнең
Кем бәяләр саф хакын?!

Миңа шундый сөю бирде Күкләр!
Сөю бирде,
Сине алды Күкләр.
Мине синсез иткән Күкләремә
Зурдыр, дисәң, күңелемдә үпкәм,
Ялгышырсың.
Дөрес, әрнүем зур.
Тик юк йөрәгемдә рәнҗеш, үпкә.
Кемнәрнеңдер беркемен дә алмый:
Һәм... Сөю дә бирми,
Бирми Күкләр...

## Бәргәләнү

Күкрәгеңә авыр башым куйсам,
Куркам,
Башларымны җуярмын.
Күкрәгеңдә башларымны җуйсам,
Оятларын кая куярмын!

Аһ, авыр шул башым,
Авырлыкны
Бер ялгызым ничек күтәрим?!
Минем авыр башны
авырсынмый
Күтәрергә ачык күкрәгең.

Ачык,
Ләкин ачык кына итеп
Язылмый ла икән бу язмыш.
Син теләсәң ничек укы аны,
Дөрес диеп укы,
Һәм ялгыш...

Ялгышлардан курка-курка күпме
Ялгышынган.
Бәгырь кыелган.
Авыр—күкрәгеңә башым куйсам:
Башларыңны куркам җуюдан...



## Фирүзә Җамалетдинова

# ТУКТАЛЫШ

хикәя

Цинк табутны мәктәп ишегалдына кайтарып куйдылар. Погонлы кешеләр, әйбәт егет үстергәнсез, дип мактадылар, акыллы иде, диделәр. Хатын-кызлар сулык-сулык елашты. Ата белән ана өнсез калды. Аларның сүзләре дә, күз яшьләре дә кипкән иде. Чечен иле кара кан булып бәгырьләренә укмашты.

Анын да йөрәге урыныннан кубарылды: әле сызлады, әле әрнеде.

—Башсыз иде бәләкәйдән,—дип кычкырды ул.

Нииндидер ят кешеләр пәлтә чабуыннан эләктереп халык төркеменең арткы ягына өстерәп чыгардылар.

—Салгансың икән, тик кенә тор, абзый. Ато пәгүнлеләр ошатмас,—диделәр.

Килеште. Арттан гына:

—Без тере көе жибәргән иек. Элек тә герой иде ул. Геройлыгын бөтен авыл белә. Дүрәк ие,—дип үз-үзенә сөйләнеп, төкеренеп алды.

Берничә айдан мәктәпкә егетнең исемен бирделәр.

Ул анда да килде. Анда да салмыш иде.

—Ару гына йөргәндә кинәт әллә кемгә охшап калгансың. Салгансың икән тик кенә тор,—диделәр.

—Мин бер генә жөмлә әйтәм. Герой иде күршем болай да,—дип кычкырды халык арасыннан. —Ә менә исән түгел. Әрәм булды яп-яшь башыннан... Дүрәк...

Аны тагын иске пәлтә чабуыннан эләктерделәр, артка тартып чыгардылар. Ун кулын күтәреп селтәнеп алды да урам буйлап асылмалы күпер ягына төшеп китте ул.

—Бар иде егет,—диде,—инде юк. Әзмәвердәй иде. Баһадир иде...

Янә анын йөрәгенә кан саугандай булды. Башы чатнады. Теле кипте.

---

Фирүзә ЖАМАЛЕТДИНОВА—*шагыйрә һәм прозаик. Әсәрләре республикабыз матбугатында даими рәвештә басыла. Чаллыда яши.*

* * *

Аяклары асылмалы күпер тактасына орынгач, кинәт туктап калды. Яр кырыена төшеп утырды. Кайдан кайтып барышы иде соң әле? Хәтерләми дә инде. Гомернең берәр тукталышы булгандыр. Кем кая тукталмый...

—Син башлап төрттең.

—Син...

Өч такталы тар күпернең кыл уртасында ике малай сугыша иде.

—Әй, калай әтәчләр! Житте сезгә!—дип кычкырмакчы иде ул. Өлгерә алмый калды. Мизгел эчендә "әтәчләр"нең берсе аска очты. Ир ике кулы белән чигәсен кысып ярга чүгәләде.

—Бетте,—диде ул. —Бетте бала. Эсбидител булырга калдым...

Ул котырып куерган таллыкта нидер шыгырдаганны ишетте. Күз каршысында гына иң зур талның иң олы ботагына малайның сынар аягы эленгән иде. Аяктан аста арык гәүдәсе чайкала...

—Хәзер,—диде ул, —хәзер алам мин сине калай әтәч. Хәзер, хәзер имансыз герой... —Һәм ярдан аска тәгәрәде.

Ул арада малай, тал буйлап шуышып, чишмәдәй челтерәп аккан елга суына төшеп басты.

—Куркыттың... Мине бинауат диярләр. Карап торып коткармагансың, диярләр...

Һәм аксый-аксый ярдан үрмәләгән малайның колагына чиртте.

—Берәр жирең авыртмадымы?

—Бер аяк озынайган,—диде малай, мыш-мыш борын тартып.—Ботакка эленеп калганы.

Малай, кул сырты белән генә сыпырып, тырналган бите буйлап йөгергән пычрак тирне сөртеп алды. Күз төбе кара янып, күгәреп килә иде.

—Ни булдегез инде, жә?

—Ул башлап төртте.

—Аннан...

—Аннан мин сдача бирдем.

—Шуннан...

—Шуннан ул сукты... Аннан мин. Аннан...

—Син очтың... Их, герой, герой! Шунда тал булмаса, эләгеп калмасаң, беткән идең бит. Мине бинауат итәрләр иде. Олы башы белән карап торган диярләр иде. Ә дошманың куркак... Ташлады да качты. Кем малае ул?

—Зиннәтнеке. Дошман түгел лә. Дус ул минем.

—Ничә яшькә олы соң синнән?

—Өч.

—Хәзер аксап йөр инде менә, картлар кебек.

—Сыңар аяк озынайган,—диде малай, янә борынын тарта-тарта.

—Шулай да бүтән юлы яргарак чыгып сугыш.

—Күпер уртасында төртте лә ул...

Капка төбендә алар аерылыштылар.

—Әтигә әйтмә,—дип пышылдады малай, бармагын иренենә тидереп.

* * *

...Инде ярда ялгызы басып тора. Герой икәнлеген болай да белəм лә аның, дип кычкырасы һәм үкереп елыйсы килә. Еласа да килешмәс. Салган баштан диярләр. Ә илдә-көндә дошман бетәмени? Юктан гына төрткәләшеп башлыйлар да, ахыры начар тәмамлана. Ата-анасының, авылның кадерлесе дип тә тормыйлар. Берни булмагандай, табутка салып кайтарып бирәләр.

Аның жаны бүген авылга гына сыя алмады. Капка келәсен күтәрүгә:

—Карчык,—дип эндәште ул.—Киттем Чаллыга. Сөт-май жибәрәсең булса, тутыр сумканы.

—Кияү бу атнада үзебез кайтырбыз дигән иде лә.

—Атна бетәргә тулы ике көн бар. Кайтырлар соң. Ә мин барам әле...

—Салып алгансың түгелме? Жөрмә шул көе. Пәгүнлеләр эләктерер...

Ул хатынын ишетмәмешкә салышты.

—Мәктәп Таһирның исемен жөртә диген, ә... Шуңа гына мин дә... Йөрәк әрнегәндә генә... Талда эленеп торганы күз алдына килде дә. Аннан аксый-туксый кайтканы... Кереп чыктым кибеткә... Юлда үтә ул. Әллә ничек күнел чирләп тора бүген. Юлга дәшә никтер.

* * *

Шәһәргә житкәнче бер сәгать буена тәрәзәгә карап уйланып барды ул. Беркемгә күтәрелеп бакмады, беркем белән сөйләшмәде. Автобустан төшеп калды да озак итеп тукталыш исеме язылган тактага карап торды. Аннан үз-үзенә сорау бирде: “Кем микән соң бу Комаров дигәне? Автобуска керүгә сорарга кирәк. Бәлки аны да армиядән цинк табутка салып кайтарганнардыр. Бик күпләрнең йөрәге әрнегәндер. Ә тукталышы нинди котсыз, көнбагыш кабыгы катыш чүп-чар... Болай ярыймы соң инде, жә?” Уйларының кыл уртасында автобус килеп туктады. Кысыла-кысыла баскычына кереп басуга һәркем ишетерлек итеп, кычкырып сорау бирде:

—Жә, кайсыгыз белә, кем инде ул Комаров?

Гажәпләнүдән тибрәнгән керфекләрне, шардай зур булып ачылган күзләрне күреп, бермәлгә уңайсызланып баскан урынында таптанып торды. Көя тишкәләп теткәләгән, әмма гомере буена яратып кигән иске эшләпәсен күзенә төшеребрәк куйды. “Салгансың икән, тик кенә тор агай”,—дигәннәрен котте. Ыгы-зыгы килгән халык кинәт тын калды. Этешү-төртешүдән туктады. Тынлыкны ул тагын файдаланып алырга тырышты:

—Жә, жә кем була инде Комаров?

—Очучы түгелме соң, —диде ике кулына ике сумка күтәргән юан түти. Бер сумкасын аяк арасына кыстырып чәчен сыпырып алды да, аңардан ераклашу жаен карады. Әллә күпме кешенең күн плащлары жыерылып олы сумка артыннан тартылды.

Кисәтү ясаучы булмады. Халык уйда иде.

—Бәлки Советлар Союзы героедыр?

—Нинди Советлар Союзы? Әллә кайчан юк бит инде ул,—дип төзәтте кайсыдыр.

—Күп эшләгәндер бәлки. Станок артында, КамАЗда, ягъни мәсәлән. Ике нурмы деталь кыргандыр. Ә кәк же. Бәлки өчне... Дүртне булуы да бар. Ә кәк же...

—“Дер” дә “бәлки” яшьти,—диде ул үзенеке төслерәк эшләпәле агайга.

—Ә миңа тучны кирәк. Тучны беләсем килә.

Арткы ишек ягында яшьләр көлеште.

—Шагыйрьдер ул, агай, йә жырчыдыр,—дип кычкырды кайсыдыр.

Шул арада автобус икенче тукталышка якынлашты. Кемнәрдер төште, кемнәрдер менде. Ул култык астына затлы һәм юан папка кыстырган күзлекле егеткә өметле карашын төбәде:

—Йә, йә син әйтерсең шәт, кем була инде ул Комаров?

Тегесе гажәпләнеп жилкә сикертте. Күзлеген күтәреп куйды.

—Ә бу папкаңда берәр кәгазеңдә юкмы соң? Язылмаганмы диюем...

Тегесе янә сәерсенеп, ямьсез караш ташлады.

—Салгансыз икән тик кенә торыгыз,—диде.

Кинәт аның йөрәген умарта корты чаккандай булды. “Монысы тучны прафисыр инде моның. Сез ди. Интилигин. Салганны да сизде. Ә үзе шәһәрнең геройлары турында сөйләмәгән була.” Ул “профессор”лы автобустан төшеп калу ягын чамалады. “Акыллылар булган жирдән качарга кирәк. Алар тәртип ярата, пәгүнлеләргә биреп жибәрергә дә күп сорамаслар... Анысы булыр”.

* * *

Барып кергәндә көн кичкә авышып килә, кызы кер юып йөри иде.

—Нинди жилләр ташлады, әти? Ничек кузгаласы иттең?—дип кызыксынды.—Бер-бер хәл булмагандыр бит? Әнкәй чирләп китмәгәндер?

—Үземнең күңел чирләп тора,—дип җаваплады ул.

—Алай чирлегә охшамагансың, салып та алгансың түгелме? Әйдә уза тор,—диде кызы һәм кер эләргә чыгып китте.

—Күңел чирлегә шулай күренәмдер... Исерек кебек...—Бераз үпкәле тавыш белән сөйләнә-сөйләнә ике оныгын күтәреп алып тез өстенә утыртты.—Күршемдә үсте Таһир абыегыз... Батыр егет иде,—диде.—Инде мәктәпкә аның исемен куштылар бүген. Түлке җәл менә, йөрәк өзелә...

Ике оныгы аны тын да алмый тыңладылар.

—Медале ничәү иде? Ордены да бармы?—дип сорадылар.

—Мәктәптә орденнарны үттек без,—диде олырагы.

Елады да сөйләде ул. Елады да сөйләде. Аны тыңлаучы бар, ишетүче бар, кушылып искә алучы бар. Шуңа бераз җиңелрәк булып китте.

—Балам,—дип эндәште ул, балконнан кер элеп килгән кызына,—ә Комаровыгыз кем соң сезнең?

—Безнең подъездда торамыни?

—Юк инде. Шундый тукталыш бар сезгә килгәндә.

—Кем белгән инде аны, әти. Шәһәр зур бит. Тукталышлар да күп. Берәр батырдыр, күрше Таһир кебек.

—Юктыр,—диде ул.—Таһир кебек булса белерләр иде. Елый-елый сөйләрләр иде әле... Юктыр, юктыр.

Аның шунда башына бер уй килде. Теге тукталышка төшәргә дә, күн папкалы "профессор"ны көтеп торырга һәм әйтергә: "Комаровны барыбер беркем дә белми. Әйдә бу тукталышка Галимов Таһир исемен бирәбез",—дияргә. Папкасы калын иде. Күп белә булыр ул... Ә нигә? Безнең авыллар монда көн дә сөт сатарга килә. Сөйләрләр иде. Бөтен кеше белеп бетерер иде. "Герой булып туган иде ул",—диярләр. "Авылда мәктәп тә аның исемен йөртә",—диярләр иде.

Ул урындыгыннан торып ике оныгын идәнгә бастырды да, иләктәй вак тишекле эшләпәсен басып киде.

—Ник кидең әле, әткәй?

—Китәм, кызым. Әниең дә көтәдер.

—Чәй дә эчмәдек бит әле.

—Ялга үзегез кайтырсыз, Алла Боерса. Киттем әле,—диде көрсенеп.

* * *

Уйларында буталып, ялгышып янә "Комаров" тукталышына килеп төшкәнен аңлады ул.

—Ә тегесендә очрады бит әле прафисыр. Хәл итәрдәй егеткә охшаган иде,—дип, үз эченнән генә сөйләнеп алды. Һәм җәяүләп, өметле җиңел адымнар белән икенче тукталышка табан атлап китте.

## ПОЧТАЛЬОН, КАРТ ҺӘМ МӘХӘББӘТ

ХИКӘЯ

—Мәсрүрә әби!—дип кычкырды Айзирә.

Ачык тәрәзәдән картның бәрхет түбәтәе күренде.

—Кер, кызым, кер.

—Кереп тормыйм, бабай, Мәсрүрә әби кирәк иде...

—Пушты тарата ул, кызым. Иртәнге пуштыны... Нигә кирәк соң ул?

—Әни чакырган иде... Бозавыбыз чирләп тора...

Карт зәңгәр күккә карап кет-кет көлде. Ачык капка келәсен берничә кат күтәреп төшергәч Айзирә кайтыр юлга борылды. "Почтальон Минсылу апа чирләп китте микәнни?"—дип уйлады эчтән генә.

Өйдәгеләргә:

—Мәсрүрә әби өйдә юк, почтага эшкә кергән,—диде дә, көянтә-чиләкләрен асып, су юлына төшеп китте. Һәммәсе пырхылдап, авызларын каплады.

—Тәки бала-чаганың башын әйләндерә бу Халиулла бабай,—диештеләр.

Мәсрүрә карчык картының әче теленә әлләни әһәмият бирмәскә өйрәнгән инде. Кирәк чакта һәр сүзен колак яныннан җилләр иркенә юллый белә.

Бүген карты һич көтмәгәндә авыл кибетенә җыенды.

—Тәмәке көйрәтәсе иде бер! Яшьлек искә төште әллә нәрсәгә. Төннәрен күзгә йокы керми,—дип сөйләнде үзалдына, һәм карчыгына эндәште:

—Синайтәм, кибеткә сугыласың юкмы? Анда бүген пуштальон кермәгән ди...

—Көлмә кешедән, үзеңне бел,—диде карчыгы исе китмичә генә.—Күлмәгең бик тузган. Берәр күлмәк карасак ярыйсы... Әйе, ярый!—Һәм картына ияреп урамга чыкты.

—Бүгенге пуштыда бер хәбәр бар,—дип сүз башлады Халиулла урам чатын борылганда,—Әмерикә турында язалар. Хәерчеләр әз түгел диләр. Берсе бай ил ди. Икенчесе хәерчеләр күп ди. Анламассың бу гәҗитләрне...

—Күптер, күптер,—дип килеште карчыгы.—Син баемагансыңдыр бит алай-болай? Лотарыйга отмадыңмы берәр нәрсә? Ату башыңа кибет кергәне юк иде лә...

—Шаулама,—диде карт,—күп сөйләшмә...

Кибеттә исә ул үзе сүз башлый алмый газапланды. Әрле-бирле йөренде.

—Кызым,—диде аннан кибетчегә шыпырт кына,—тәмәке ише көйрәтә торган берәр нәрсәң юкмы?

—Нигә ул сиңа, Халиулла бабай?

—Духтырлар кушкан иде. Йоклап булмый...

—Сигаретлар гына калды шул,—диде кыз,—кыйммәтрәк була инде әзрәк.

—Синайтәм, җүнлерәк әйбер карар идең ичмаса. Күлмәгең тузган, әнә,—диде карчык ризасызлык күрсәтеп.

—Ә-ә, күлмәк дисеңме...

Карт кибетче кулыннан яшереп кенә алган затлы капны кесәсенә шудыртты.—Тузган икән шул... Карале кызым, синдә бер дә юмый торган күлмәк юкмы сон?

—Нинди була ул, бабакай?

—Минем карчык пуштальон, юарга вакыты юк...

Кибетче күзләрен шардай тәгәрәтеп төбәлеп торды да яңгыратып көлеп җибәрде.

Мәсрүрә картына ачулы итеп карады:

—И-и, шуны әйтер идем, мыскыл иткән була тагын. Көлгән була бит, әй! Әнә, тун киеп йөр. Бер дә юмыйлар ди аны...

Картка күлмәкнең ак якалысын сайладылар.

—Ак күлмәк гәүдәсенә килешә менәтерәк, теленә килешми,—диде карчык.—Агач телле булды гомер бакый... Нишләмәк кирәк, юнып алалмыйсың.

Өйгә кайткач алар кара-каршы утырып, баллап-лимонлап тәмле итеп чәй эчтеләр.

—Хәлимәләрнең бәрәне кичәгенәк көтүдән кайтмаган,—дип сүз башлады карчык.

—Кайтыр әле. Нәрсәгә сиңа ул бәрән?

—Җәлке бит. Күпме үстер дә...

Бер мизгелгә тынлык урнашты. Өстәлдә самовар гөжләве, картның өфөф чәенә өрүләре өйгә моң булып таралды.

—Халисәнең сыеры көненә ике чиләк сөт бирә икән бит. Тана чакта бик хөрти күренә иде...

—Пушты килдеме әле?—диде Халиулла аны ишетмәмешкә салышып.

—Иртән кереп чыкты Минсылу. Йоклый идең. Уятмадым инде. Алдагы көннәрнекен китергән. Кичкә яңасы кайтасы диде.

Карчык өстәл почмагына бер төргәк гәзит китереп салды.

—Әмерикәне язалар,—диде карт.—Халкы бик ялкау икән шул... Пулуфабрикат ашап яшиләр, ди.

—Анысы ни була тагын?

—Аш пешерергә яратмыйлар дигән сүз.

—Вакытлары юктыр.

—Юктыр, юктыр... Синең дә юк. Пушты таратасың...

Ул төргәкне култык астына кыстырып караватына барып ятты.

—Сөйләшеп буламыни моның белән,—диде карчык, сулы табагында чынаякларны тәгәрәтеп.—Ашарына пешкән югыйсә...

Ул гырлап йоклап яткан картына күз салып алды да, аяк очларына гына басып өйдән чыкты һәм Хәлимәләргә табан сыптыртты... Бәрәннәре табылмады микән? Кайта күрсен инде берүк. Бөтенләйгә югала күрмәсен... Халисәгә дә кереп чыгасы булыр. Сыерын саугандыр бәлки. Берәр стакан кичке сөтен арттыра алмасмы. Иртәнгә боткага шәп булыр иде...

Карт уянып киткәндә карчыгы бөгәрләнеп, пыш-пыш сулап татлы йокыга талган. Халиулла бик озак тәрәзәгә карап ятты. Ай яктысы көлтә-көлтә булып ургылып керә дә күнелне кузгата. Әллә нинди сәер төш күрде житмәсә. Карчыгының яшь чагы имеш. Жилкәсенә почтальон Минсылуның сумкасын аскан. Эче тулы гәзит. “Өзелепләр яратам бит мин сине Халиуллам”,—диде дә каядыр юк та булды.

Карт ай нурларыннан һәм күргән төшеннән айный алмыйча исәнгерәп, татлы уйларга баткан көе терсәге белән карчыгының кабыргасына төртте:

—Сиңайтәм, кайчан да булса яратканың булдымы синең, юкмы?..

Карчык сискәнеп күзләрен ачты:

—Нәрсәне? Болай да тилемсәрәк идең. Әллә бөтенләй... Төн уртасында уятмасаң...—Ул караватын шыгырдатып әйләнде дә, картка арты белән борылды.

Халиулла чалкан яткан көе, башын кыңгырайтып, бик озак айга карап торды. Гомер үтеп бара. Бер кат та сөям сүзен ишеткәне юк икән бит каһәр! Ә үзе?.. Үзе дә әйткәне юк икән шул. Ярата торып корткасына белдерми яшәлгән. Ә мондый айлы төннәр булгандыр. Нурлары гел шулай ургылып-ургылып төшкәндер. Ае да хәйләкәр. Аны миңа, мине аңа тоташ нурга чумдырып күрсәткәндер әле. Күзләренә карап “Кара, нинди нурлы ул минем сантыем”, дип уйлаганмындыр. Бөтенесе онытылган, артта калган.

—Гәжитләре дә бинауат,—диде карт,—өйрәтмәделәр ничек сөйләшергә. Сөт саварга, тирес түгәргә өйрәттеләр... Ә төше матурые. Көн дә керсә дә туйдырмасые...

Ул караватыннан шуып төште. Бер төргәк гәзитне култык астына кыстырды да ишегалдына чыкты. Юл уңаенда аягына олы галушын элде. Күнелен илһамлы жил кубарды. Бу мәлдә нигәдер аның капка төбендә, тал астындагы эскәмиядә ай нурына коенып утырасы килде. Бер-ике адым атлауга чыркылдап көлгән тавыш ишетеп тукталып калды. Лаштыр-лоштыр тузан ерып сөйрәлгән галушы кыңгыраудай тавышның чыңын тоныкландырды. Аны аяк очына элеп очырып жибәрде дә, оекбаштан капка ягына атлады.

—Яратам мин сине, Айзирәм!

—Жүләр син,—диде кыз.—Жүләр булсаң да яратам мин дә...

Картның колаклары үрә торды. “Их заманалар! Яшьләр шул алар, тилибизыр карыйлар, китап укыйлар... Булмады безгә, булмады...”

Елмая-елмая карт кире борылды, болдырга барып утырды. Кинәт зәһәр шыгырдап ишек ачылды.

—Төнлә жөрмәсәң,—дип сукранды карчыгы кулындагы комганын шалтыр-шолтыр китереп.—Тупсаларын майлап куяр идең. Күршеләр уяныр жә...

—Гырлап йоклап калдың ласа...

—Унсигез яшьтә ди мин гырлап йокларга... Төне бигрәк матур,—диде карчык тавышын йомшартып. —Хәлимәләрнең бәрәннәре кайтмаган тәки... Шәфыйкаларның сыерлары бозаулаган.

Карт култык астындагы гәзитләрне болдырга җәеп салды.

—Ай яктысында гәҗит укымакчы әллә?.. Тилемедер бу...

—Укыйм!—диде карт.—Ник укымаска?!

Ул чалбар кесәсеннән кереш бәйләнгән күзлеген алып киде.

—Күренми икән шул. Эреләре генә шәйләнә. "Ворошилов" калхузы җинүче,—диде ул иҗекләп җыеп.—Бусы сөт турында. Укып торасы да юк. Ә чит илләрдә... Әмерикәдә ниләр бар икән?

Кыштыр-кыштыр китереп ул нидер эзләде дә табалмагач гәзитләрне кире төреп куйды.

—Укырлык әйбер язмыйлар,—диде рәнҗүле тавыш белән.—Картайгач сөт нигә безгә. Яшь чакта эшләдек. Тиресен дә түктек. Җинүче дә булдык. Балалар да үстердек. Кызыграк әйберләр кирәк өлкән кешегә... Укып күнел юатырлык. Яшьлеккә кайтырлык итеп язсыннар иде...

Карт билен тотып, һич турая алмыйча өйгә атлады. Кесәсенә тыгылып ачылмаган затлы капны тартып чыгарды. Озаклап текәлеп ялтыравыклы язуына карап торды да һич кызганмыйча мич авызына ташлады. "Без яшь чакта мондый нәрсә юк иде... Тәмәке дә хуш исле иде",—дип сөйләнеп алды. Ә тәрәзәдән көлтә-көлтә ай нурлары ургылды. Яктысы пәрдәләрне селкеткән язгы җилдәй күнелнең кайсыдыр почмагын канатландырды. Карт килеп тәрәзәгә карады. Тал төбендәге эскәмиядә үбешеп торучы кыз белән егетне күрде.

"Үбешеп кенә яшәрсез бик... Өйләнешеп карагыз әле менә,"—дия-дия өйгә ут кабызды. Өстәл янына килеп утырды. Очлый торгач шактый кыскарып калган карандаш алып эскәтер астында кайнар табадан саргайган иске дәфтәрне тартып чыгарды.

"Гәҗиткә хат язам",—диде ул.

Һәм йөрәк сүзләрен сары кәгазьгә тезде: "Туганым редакция! Минем карчык пуштальон. Бөтен авыл хәбәре анарда. Кем күпме сөт сауганны болай да белеп торам. Ә менә сез мәхәббәт турында да берәр нәрсә язмассызмы. Ату төннәр бик озын, күзгә йокы керми." Конвертын төкерек белән ябыштырып өстенә китап бастырып куйгач, берара монсуланып уйланып утырды.

"Юк, булмады әле. Иң кирәген әйтмәдем",—диде ул. Китапны читкә этеп конвертны кубарды, саклык белән янә дүрткә бөкләнгән хатны туздырды. Һәм: "Язгыз инде, пажалысты. Халиулла бабагыз," дип өстәп куйды. Шул мәлдә комганын шалтыратып ишектән карчыгы керде:

—Хәлимәләрнең абзарын карап әйләндем. Бәрәннәре кайтмаган...—дип сөйләнде.—Ә-ә, оныткамын, пушты килде,—диде ул һәм көзге артына кыстырган гәзитләрне алып картына сузды.

—Терелгәнмени Минсылу? Кич китергәниемени?—дип сорады карт.

—Кич. Әйттем әле, моннан ары иң беренче Халиулла бабаңа китер гәҗитләренне дидем. Пуштаны көтеп житкерәлми ату. Пуштальоннарны ярата ул дидем...

—Әйбәт иткәнсең,—диде карт житди кыяфәттә.—Әйе, бик дөрес әйткәнсең... Әйе...

Һәм карчыгының күзләренә туп-туры карап тәрәзәдән кергән айдан да яктырак итеп елмайды.

⁂

*Роза Хафизовага 75 яшь*

# ЯШЬ БУЫНГА МАЯК УЛ

Узган гасырның 70-80 елларында, мәктәпләрдә пионер-комсомол оешмалары гөрләп торганда балалар язучысы Роза Хафизованың берсеннән-берсе мавыктыргыч әсәрләре дөнья күрде. Китапның бик кадерле вакытлары иде ул. "Тантаналы вәгъдә", "Кашкарыйлар озын гомерле", "Курай-малай мажаралары"н малайлар-кызлар кулдан-кулга йөртеп укыдылар, дәресләрдә фикерләр алыштылар. Балаларның эчке дөньясын тоемлап, нәкъ менә алар укый торган әсәр иҗат итүчеләр ул елларда да, бүген дә бармак белән санарлык кына. Аларның берсе, шиксез, Роза Хафизова.

"Ялкын" журналының баш редакторы Роза Хафизованың повесть-хикәяләрендә, мажаралы әкиятләрендә төгәл бер максат ярылып ята. Ул да булса—яшь буынны дөрес, матур итеп тәрбияләү. "Кирлемән" кебек кире образлар аша да, Тал-Сылу һәм Курай-малай кебек уңай геройлар ярдәме белән дә Роза ханым шушы игелекле максатына тугрылыклы кала алды.

1929 елның 6 февралендә Бөгелмә шәһәрендә туган Роза Сәет кызы Хафизова мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә югары белем ала. 1951—52 елларны Ерак Себердәге Тобол шәһәрендә мәктәптә укытучы булып эшләргә дә туры килә аңа. Хәер, булачак язучы өчен бу елларның файдасы һичшиксез тигәндер, югыйсә балалар тормышының үзәгендә кайнамый гына шундый гүзәл әсәрләр иҗат итеп булыр идемени ул?!



*ВЛКСМ Өлкә Комитетының IX пленумында Роза Хафизова баш редактор эстафетасын Роза Туфитуллловага тапшыра. 1986 ел.*

Р. Хафизованың шуннан соңгы хезмәт юлы журналистика белән бәйле: "Яшь сталинчы" (хәзерге "Татарстан яшьләре"), "Сталин байрагы" (Чистай өлкә газетасы), "Төзелештә" (ул чорда Казандагы күп тиражлы газета) әдәби хезмәткәр, Партия тарихы институтында фәнни хезмәткәр һәм Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшли.

1962 елда ул "Ялкын" журналына баш редактор итеп билгеләнә һәм шушы җаваплы постта 1986 елга кадәр эшли. Ул елларда Роза ханым белән эшләүчеләр аны хөрмәт белән искә алалар. Әйткән сүзен вакытында, төгәл үтәүче, эшен жиренә җиткереп башкаручы һәм бүтәннәрдән дә шуны таләп итүче кырыс җитәкче буларак хәтерлиләр аны.

Уйлап карасаң, безнең әдәбиятыбыз гаҗәеп дәрәҗәдә бай бит! Бүтән милләтләр көнләшерлек дәрәҗәдә бай. Татар әдәбиятын бер генә тематика, бер генә жанр да читләп узмаган. Әйтик, лирика жанрының үз осталары булса, детектив яисә фантастик әсәрләр арасында да дөнья әдәбияты югарылыгында торырдайлары бар. Бүтәннәр белән чагыштыру нисбәтеннән балалар әдәбиятына да күз салсак, биредә дә горурланырлык әкият-хикәяләребез, геройларыбыз байтак. Ләкин... чагыштыра башласаң, күңелне әрнү, кимсенү тойгысы биләп ала икән шул. Әйтик, ни өчен инглизләрнең Гарри Поттерларын, русларның Белмәмешләрен бөтен дөнья белә дә, ни өчен безнең Шәвәлиләр, Кирлемәннәр дөньяга таныла алмый? Шул ук Курай-малайны алыйк. Әлеге мавыктыргыч әкият-повесть буенча менә дигән мультфильм яисә балалар өчен кинофильм эшләп булыр иде.

Роза Хафизованың әсәрләре бүген дә популяр. Аның әкиятләрен, хикәяләрен, шигырьләрен татарлар гына түгел, башка телләрдә дә яратып укыйлар (Роза ханымның берничә китабы башка телләргә дә тәрҗемә ителгән).

Без исә хөрмәтле язучыбызны юбилее белән тәбрик итәбез. Кызыклы әсәрләре белән өлкәннәрне дә, балаларны да тагын сөендерер әле ул!

**Алмаз ГЫЙМАДИЕВ**

Роза
Хафизова

# КАРТЛЫКТАМЫ ХИКМӘТ?!

ХИКӘЯ

Сәкинә карчыкның күптәннән бирле кеше арасына чыкканы юк иде. Ахирәте Маһинурның коръән ашына чакыруын алгач, үзалдына бер ашкынып куйды. Чакырылган көнгә әле бер атналап вакыт булса да алдан ук хәстәрен күрә башлады. Яхшыга кия торган кулмәген, юка ак ефәк яулыгын барлады. Ахирие белән күптән күрешкәннәре юк, буш кул белән йөрү килешмәс, дип, күп итеп чәкчәк пешерде. Кунакта кемнәр буласын алдан ук уйлап үзалдына сөенеп йөрде. Җан теләгән кешеләр белән бер күрешү үзе бер гомер диләр ич.

Ниһаять, көткән көне дә килеп җитте. Сәкинә карчык затлы киемнәрен киенеп, мамык шәлен ябынып, кунакка барырга чыкты. Ахирәтенең адресын кат-кат карап, күңеленә беркетте. Карты исән чагында бармадылар түгел, күп тапкырлар бардылар аларга. Ул чакта әле аралар ерак булса да күңелләре якын иде.

Ай-һай, быел карның күплеге хикмәт икән! Сәкинәнең мондый ерак арага чыгып йөргәне юк иде. Автобус тукталышына барып җиткәнче шабыр тиргә батты. Юлларны, сукмакларны тәмам көрт баскан. Әле калкулыкка үрмәләгәндәй менәсе, әле төшәсе. Подносы белән кижеле ашъяулыкка төреп күтәргән чәкчәк тә һаман авырая бара. Күңелендә дуслары, яшьтәшләре белән күрешү куанычы булмаса, һич кенә дә бу газаплы юллардан атламас, җылы өендә генә утырыр иде. Уф! Ниһаять, карчык, көч-хәл белән тукталышка килеп җитте. Төенчеген эскәмиягә куйды, кулларын язды һәм автобус көтә башлады. Тукталышта кеше шактый җыелган иде. Ярый әле барысы да Сәкинә бара торган якка түгел икән. Кайсы троллейбуска, кайберләре автобуска утырып, берәмберәм тарала тордылар. Шактый озак көтте Сәкинә үзенә кирәк автобусны. Озак тора торгач, Суык бабай боз бармакларын очлайтып, карчыкның тирләгән тәненә үк үрелә башлады. Ул, әзрәк җылынмаммы дип, бер урында таптангандай итте, мамык шәлен мангаена ук төшереп куйды. Дүрт күз белән автобус көтте, тик юк та юк. Әллә инде, гөнаһ шомлыгына каршы, бөтенләй йөрмиме икән дип шикләнә үк башлаган иде, шулчак күзләрне камаштырып, сары көяз автобус күренде. Күңеленә җылы йөгерде. Карты белән нәкъ шундый автобусларда баралар иде алар Маһинурларга.

Бу автобуска да кеше байтак калган икән шул. Яшьләр аны-моны уйлап тормыйча, Сәкинә карчыкны төенчеге-ние белән читкә этеп, автобуска ыргылдылар. Бик рәнжеде карчык яшьләргә. Әмма ул турыда уйлап торырлык ара юк иде. Төенчеген бер кулына күтәреп, иң соңгы булып автобуска күтәрелгә булды, машинаның ишекләре шаплап ябылды.

Төенчеген бер кулы белән баш өстендә күтәреп бару ифрат кыен иде карчыкка. Ярый әле, бер-ике тукталыштан соң автобуста кеше кимеде, Сәкинәгә дә утырыр урын табылды.

Кышкы салкыннар шул. Сәкинә тыны белән тәрәзә пыяласын җылытып, тышка карарга, кай тирәдән узуларын белергә теләде. Кая ул! Бер-берләренә охшаган йортлардан, кар өемнәреннән башка берни күрә алмады. Автобус йөртүче дә никтер тукталышларны атамый иде. Сәкинә, сигез тукталыштан соң, "Парковая" дигән урында төшәргә тиешлеген дә белә. Каһәр, бара торгач, тукталышларның санын бутады. Әллә алты, әллә жиде тукталыш уздылар шунда. Каршысында басып торучы, бите-күзе таш курчакныкы кебек буяулы бер хатыннан тукталыш исемен сорап та карады. Тегесе исә, Сәкинә карчыкка: "Син дә кешемени әле?!"—дигән кыяфәттә үтергеч итеп карады да арты белән борылып басты. Бик хәтере калды Сәкинәнең. Башка беркемгә дә мөрәҗәгать итәргә базмады. Тагын бер тукталышны узгач, Аллага тапшырып, автобустан төшеп калды.

Бу тукталышта бер-ике генә кеше төште. Алары да Сәкинә карчык исенә килеп өлгергәнче, юлның икенче ягына чыктылар да китеп югалдылар. Ул моның нинди тукталыш икәнен сорашырга өлгерми дә калды.

Юлның һәр ике ягында чүмәлә-чүмәлә булып кара-кучкыл кар көртләре өелгән. Юл уртасыннан выж-выж килеп машиналар уза торды. Бөтен шәһәр, шәһәре генә түгел—дөньясы Сәкинә карчыкка битараф иде. Ул кая бара, кем ул—беркемнең дә анда гаме юк. Нинди тукталыш икәнен әйтеп барса, теле тотлыгыр иде мени, дип, ачынып куйды Сәкинә автобус йөртүче турында. Аннары төенчеген ипләбрәк күтәрде дә юлны аркылы чыгып, чокырлы-чакырлы тар сукмак буйлап каршыдагы йортларга таба юнәлде. Кышларын еракка чыгып йөрмәгәч, Сәкинә шәһәрнең болай җыелмыйча тоташ кар астында калуын күз алдына да китерә алмый иде. Үзәктә мондый галәмәт юк ич. Анда карны җыеп, машиналар белән шәһәр тышына чыгара торалар. Бу урамнарга, күрәсең, кышның буеннан буена юлларга кеше кулы тимәгәндер.

Сәкинә үзе атлый, үзе йортларны күзәтә. Бу хәтле бер-берләренә охшарлар икән! Һәммәсе соры кирпечтән салынган бишәр катлы йортлар. Тәрәзәләре, подъезд ишекләре, балконнары—һәммәсе бертөсле. Йортларны бер-берләреннән аерыр өченме—кайберләренең аркылы диварларына буйдан-буйга төрле сурәтләр төшереп куйганнар. Әнә, бер йортта кыршау күтәргән кыз бала сурәте, берсендә футболчы рәсеме. Исенә төште, Маһинурлар яши торган йортның стенасына самолет сурәте төшерелгән иде. Аңа кирәкле йорт шушы тирәдәдер. Сәкинәгә көч кергәндәй булды, ул адымнарын кызулата төште. Бигрәк озакладым, кунакларны көттереп торам, дип тә пошынды. Син ашыкканда—ул кабалана дигәндәй, җил көчәеп, җәяүле буран башланды. Җил аңа каршы исә иде. Юлдан күтәрелгән җил эре-эре кар бөртекләрен карчыкның битенә китереп-китереп бәрә. Кулындагы поднос җилкәсен баса. Аяк атлаулары авырая бара. Әллә йөрәге дә чәнчергә итә инде, каһәре. Кайдарак булды соң әле бу Маһинурларның йорты?! Сорар кешесе дә юк бит. Мондый буранда кешеләр җылы өйләрендә утыралар булыр. Уф, аяк атлаулары бигрәк авыр!

Шулчак нидер булды... Аның аркасына кемдер бик каты итеп китереп төртмәсенме?! Карчык сөрлегеп китте һәм кулыннан төенчеген алга ташлап, йөзтүбән капланды. Башта исен җыялмый торды, аннары кыймылдап, башын күтәреп караса—ике яшүсмер малай, аның төенчеген эләктереп, йортлар арасына кереп шылды. Карчык еларга да, кычкырырга да белмәде. Үрмәләп диярлек урыныннан торды, өстен-башын сыпырды. Аркасы авырта, йөрәге чәнчи, бер адым атлар хәле юк иде. Ничек инде бу кыяфәттә, буш кул белән корьән ашына бармак кирәк?! Ул аптырап тирә-юньгә карап торды. Ирексездән күзләреннән яшь тамды. Көпә-көндез бот буе малайлар сине талап китсеннәр инде, ә! Кайдарак булды соң әле бу йорт?! Әнә ич, 7 саны чекерәеп тора. Шул йортта инде ахирәте, беренче подъездда яши... Карчыкка көч кергәндәй булды. Ахирәте аңлар әле аның хәлен.

Ул үзе белән булган хәлне уйламаска тырышып, тагын атлады. Бисмилла әйтеп, подъездга керде. Бишенче катка күтәреләсе дә бар бит әле. Хәл җыя-җыя икенче катка менеп җитте. Каядыр өстә малайлар көлешкән тавыш ишетелә. Ул туктап хәл алды, өченче катка менәргә дип борылгач, өнсез калды. Аны карга егып, төенчеген алып качкан малайлар, подъезд тәрәзәсе төбенә куеп, чәкчәк кимереп маташалар. Сәкинәнең кичәге ашъяулыгын аяк астына салып таптаганнар, үзләре көлешәләр. Карчык бер мәлгә урыныннан кузгала алмый катып калды. Аннары андый гайрәт карчык кешегә кайдан килгәндер, яшелле-күкле тавышлар чыгарып, кычкырып җибәрде.

—Һай, юньсезләр, җир битләр!..

Малайлар, кисәк борылып, Сәкинә карчыкка карадылар да баскычтан түбән томырылдылар. Берсе калдык чәкчәкне дә эләктерергә онытмады. Карчык, аларны тоткарларга теләп, кулларын җәйде. Кая инде ул?! Көчләре ташып торган яшүсмерләр сәлперәйгән карчыкка тоттырамы соң! Малайлар аны стенага китереп сыладылар да баскычтан түбән атылдылар.

—Каһәр генә суксын сезне, хәерсезләр!—дип артларыннан кычкырып калырга гына өлгерде Сәкинә. Ярый әле аягында басып кала алды. Таш идәнгә егылса, бигрәк тә начар буласы иде. Ул сукрана-сукрана өченче катка күтәрелеп, идәннән ашъяулыгын җыеп алды. Нихәл итәсең, насыйбы булмагандыр, дип, үзен-үзе юата-юата, иншалла, бишенче катка менеп җитте.

Йортта тып-тын. Бер дә алай кунак-төшем булганы сизелми. Башка вакытларда Маһинурларга кунакка килгәндә, затлы гөбәдия, чәкчәк, коштеле исләре подъездга керүгә үк хушларны ала иде. Бүген нихәл соң бу? Әллә ахирәте авырып-нитеп киткәнме?

Сәкинә, күнелен биләргә торган шомны тизрәк таратырга теләп, ахирәте ишегендәге төймәгә басты. Бу нихәл бу? Ишектә тынлык. Кыңгырау кат-кат зынлады. Бер җавап та юк. Борчылып, озак-озак итеп тә басып карады. Ишек ачылмады. Сәкинә аптырагач, Маһинурлар күршесенә хәбәр бирде һәм кетә башлады. Бераздан ишектә чәче-башы тузган, каткан халат кигән урта яшьләрдәге хатын күренде.

—Что тебе?—дип тупас итеп сорады хатын. Сәкинә аңа татарчамы, урысчамы эндәшергә белми аптырап калды. Карап торуга кап-кара чәчле татар хатыны, әмма күзендә нур юк, теле дә урысча.

—Соседка ваша не знаете, не болеет?—дип кенә әйтә алды.

—Откуда мне знать! Ходят тут всякие, людей беспокоят!—дип, хатын ишеген шапылдатып ябып куйды.

Сәкинә карчыкны чәченнән тотып, бәкегә салдылармыни! Аның бөтен тәне куырылып китте. Хурланды. Күнелендә ахирәте Маһинурга карата рәнҗү туды. Соң, кунак җыймаска уйлагансың икән, күршеләренә кереп телефоннан әйттерергә, һич югы кош теле хәтле генә хат язып салырга була бит. Кеше интегеп йөрмәс иде. Ахыр чиктә, чакырылган вакытта өйдә утырсаң да була ич инде.

Карчыкның аяклары тотмас булды. Ул тәмам хәлсезләнеп баскычка утырды. Күзләреннән мөлдерәп яшь акты. Үзен-үзе кызгану яшьләре идеме бу, әллә теге хатынның тупаслыгына хәтере калуымы, көтеп алган көненең шулай ямьсез тәмамлануымы, әллә барысы бергә җыелдымы—Сәкинә карчык эчтән генә үксеп, рәхәтләнеп елап алды. Аңа ничектер җинел булып китте. Ярый, кунак табынында утыра алмаганнан гына дөнья җимерелмәгән ич. Ул үзалдына гайрәтләнеп, урыныннан торды, булдыра алганча ашыгып баскычтан төште дә, урамга чыкты.

Алланың рәхмәте, тышта буран тынган, бөтен тирә-юньне ап-ак яна кар баскан. Карчык, әлеге көрт баскан сикәлтәле сукмакны кармалап диярлек, автобус тукталышына барып житте.

Автобус озак көттермәде. Бер килсә килә бит ул. Бу яктан барганда автобуска кеше дә күп булмый икән. Сәкинә карчык берүзе бер утыргычта утырып кайтты. Юлда ул мең төрле уйлар уйлап бетерде. Ни булган аның ахирәтенә? Үзе өйдә булмаса, кызы белән кияве, оныклары булырга тиеш ич! Менә сиңа табышмак!

Автобустан төшкәч, өенә кайтып житкәнче, шактый барасы бар. Сәкинә карчык үз уйларына чумып бара торгач, үзенә бәрелеп үк туктаган таксига карап катып калды. Кулыннан ашъяулыгы төшеп китте. Әле мыек та чыгып өлгермәгән яшь кенә таксист, машинадан башын тыгып, усал итеп ысылды:

—Что, старая карга, жизнь что ли надоела?!

Сәкинә ашъяулыгын иелеп алды да артка чигенде. Таксист, аңа йодрык күрсәтеп, "вжжт!" итеп үтеп китте.

Сәкинә карчык озак кына урыныннан кузгала алмый торды: "Менә инде каргага да әйләндем!"—дип ачынып куйды.

Өйдә аны гаять борчылган кызы белән оныгы каршы алды.

—Әни, кайда йөрисең син?! Маһинур апалар әллә ничә шылтыратты инде. Өйдән чыгуыңа дүрт сәгать вакыт үтте бит. Милициягә мөрәҗәгать итәргә уйлаган идек инде,—дип тезде кызы.

Сәкинә карчык, гадәтенчә, эчендәгесен тиз генә туарып ташламады.

—Булды инде, бала, күрәчәкләр булгандыр,—диде.

Маһинур күршеләреннән шылтыраткан. Үзләренен телефоны юк. Алар Сәкинә килгәнне бер сәгать буе көтеп, табынга утырмый торганнар.

"Бәй, өйдәләр иде микәнни алар, ишекләрен ачмадылар ич!"—дип, Сәкинә карчык үтә дә гаҗәпсенгән иде. Шырпы тартмалары кебек бер-берсенә охшаган, халык телендә "хрущевкалар" дип аталган йортлар арасында буталып, үзенең 17 нче номерлы йорт урынына 7 нче йортка кереп, адашып йөрүен һаман анламый иде әле. Барысына да Сәкинә үзе гаепле икән ич.

Ул юлда күргән хикмәтләрен кызына сөйләп тормады. Картлык шушы буладыр инде, дип, тирән сулап көрсенеп кенә куйды...

Publisistika
# Публицистика

**Мирфатыйх Зәкиев**

## МИЛЛИ ХӘРӘКӘТНЕҢ МАКСАТЫ— МИЛЛӘТНЕ ТЕРГЕЗҮ, САКЛАУ ҺӘМ ҮСТЕРҮ

### Милли хәрәкәт турында гомуми мәгълүмат

Милли хәрәкәтне гадәттә икегә бүлеп йөртәләр: милли-азатлык һәм милли-демократик хәрәкәтләр. Милли азатлык хәрәкәте күбрәк милли сепаратизм юнәлешендә алып барыла, аның төп максаты буйсынган хәлдә яшәгән милләтнең мөстәкыйль дәүләтен төзүгә юнәлтелә. Бу хәрәкәтнең нәтиҗәсе буларак, 1991 елда капиталистик дөньяда колонияләрнең юкка чыгарылуын санарга кирәк.

Милли-демократик хәрәкәт исә күп милләтле дәүләтләр эчендә милли азчылыкларны саклау һәм үстерү максатына хезмәт итә, ләкин аның әкренләп милли-азатлык хәрәкәтенә әйләнү мөмкинлеге дә бар.

Милли-азатлык һәм милли-демократик хәрәкәт ул бары милли азчылыкларда кузгала һәм төп, зур милләтнең шовинизмына каршы алып барыла.

XX гасыр башында Россиядәге милли хәрәкәт шул дәрәҗәдә көчәйде ки, ул хәтта революция ясауга, дәүләт системасын шактый нык үзгәртүгә китерде. СССР да бу милли-демократик хәрәкәт 30 нчы елларга кадәр дәвам итте. 1930 нчы елда Сталин аерым бер илдә коммунистик җәмгыять төзү идеясе белән чыккач, милли хәрәкәт бөтенләй сүндерелергә тиеш булды, чөнки төзелергә тиеш дип уйланылган коммунистик җәмгыятьтә бер генә—бары төп милләт кенә калырга, милли азчылыклар аның телен кабул итеп юкка чыгарга тиеш дип уйланыла иде. Милләтне, аның телен, мәдәниятен үстерү өстендә эшләүчеләр, милли тарихны милли аң тәрбияләрлек итеп объектив төзергә омтылучылар коммунистик җәмгыять булдыруга аяк чалучылар, ягъни халык дошманнары дип, гулаг лагерьларына җибәрелделәр, физик юк ителделәр.

Ватан сугышы чорында бераз туктап торган мондый шовинизм сугыштан соң үзен тагын бик нык сиздерә башлады. Бу чорларда алга киткән капиталистик илләрдә нык җәелгән милли-азатлык хәрәкәтен дә халыктан яшерделәр, аны "тимер пәрдә" белән ябып куйдылар.

XX гасырның 60 елларында Аурупаның алдынгы саналган илләрендә һәм Канадада төп милләтләрнең шовинистик сәясәтенә каршы милли азчылыклар күтәрелде. Алар үзләренең алга киткән дип саналган илләренең төп милләтләре югарылыгында яшәүне таләп иттеләр, милли азчылыкларга

социаль-икътисадый, милли-мәдәни үсешне дәүләт гарантияләргә тиеш дип чыктылар. Шундый таләпләр канәгатьләндерелмәсә, милли азчылыклар, алга киткән капиталистик илләрдән аерылып чыгып, үз мөстәкыйль дәүләтләрен төзү таләбен куйдылар. "Вак милләтләрнең олы милләтчелеге" дип аталган бу хәрәкәт озак бармады: тыныч яшәргә өйрәнгән капиталистлар милли азчылыкларга таләп ителгән хокукларны, нигездә, бирделәр. Хәзер бу халыкларда үз милләтләрен саклау өчен милли-азатлык хәрәкәте түгел, ә бары милли хәрәкәт кенә алып барыла. Алар тәҗрибәсен Россиянең милли азчылыклары да бик еш файдалана. Мәсәлән, Испаниядә Каталон өлкәсендә яшәүче каталоннарның милли хәрәкәт тәҗрибәсе бездә бик теләп файдаланылды. Телләр турында Законнар чыгару, милли телнең кулланылыш сфераларын киңәйтү тәҗрибәсе, СССР да үзгәртеп корулар башлангач, әнә шул каталоннардан алынды.

XX гасырның 80 еллары уртасында иҗтимагый тормышның барлык өлкәләрендә дә үзгәртеп корулар башланды. Милли азчылыкларда милли хәрәкәт яңадан ныклы урын алды. Моның кирәкле һәм гадәти бер күренеш булуы халыкара күләмдә дә танылды. Мәсәлән, 1990-1994 елларда БМО ның, Европа Советының, Европада эш берлеге һәм тынычлык оешмасының милли азчылыкларның хокукларын тәэмин итү турында декларацияләре һәм башка документлары кабул ителде[1]. Милләтләрне саклану хокуклары белән тәэмин итү юнәлешендә 1992 елның 5 ноябрендә Европа Советы "Европейская Хартия региональных Языков и Языков Меньшинств" дигән әһәмиятле документ эшләп чыгарды. Шулай итеп, милләтләрне саклау хокуклары өчен көрәш, ягъни милли хәрәкәт, милли азчылыкларда халыкара күләмдә законлы күренеш буларак танылды.

СССРда һәм аннан соң Россия Федерациясендә милли азчылыкларның милли-демократик хәрәкәтенә башка илләрдә күзәтелмәгән бер үзенчәлек өстәлде: милләтне саклау һәм үстерү белән бергә аны тергезү (возрождение) дә кирәк булып чыкты. Чөнки Советлар Берлегендә милли азчылыклар үлемгә дучар ителгән иде, саклау һәм үстерү эшен оештырганчы, аларны иң элек тергезергә, савыктырырга кирәк иде.

Менә бу җаваплы эшне татар милли хәрәкәте, һичшиксез, чит илләр тәҗрибәсенә һәм әле генә искә алынган халыкара документларга таянып алып барырга тиеш.

Татар милли хәрәкәтенә һәм аның төп максатларын тормышка ашыру юлларын тасвирлауга кучкәнче, татар халкының бердәм милләт булып оешуы турында да төп мәгълүматны бирү дөрес булыр.

## Татар милләтенең бердәмлеге

Хәзерге теорияләрнең болганчык чорында *халыкны* һәм *милләтне* аерып күрсәтүне бик өнәмиләр. Ләкин без бу ике күренешне аерып карау кирәк дип саныйбыз.

Мәгълүм булганча, татар халкы, бердәм милләт булып, бик зур авырлыкларны җиңеп формалашты. Гадәттә, теге яки бу халык милләт булып оешсын өчен, аның үз дәүләте булырга тиеш, диләр. Татар милләте оешу процессы бу гомуми кагыйдәләргә буйсынмаган.

XIX гасырның икенче яртысында Патша Россиясендә милли хәрәкәтне бастыру, милли азчылыкларны тизрәк руслаштыру сәясәте аеруча көчәеп китә. Халык мәгарифе министрлыгы "Россия бары руслар өчен!" дигән принцип белән эш йөртә: милли телләрдә эшләүче мәктәпләргә хөкүмәт бер тиен дә акча бирмәскә тиеш була; милли телдә газета, журналлар һәм китаплар чыгару да хөкүмәттән финансланмый. Менә шуңа җавап итеп, татар байлары, руслар белән бозылышып, әрепләшеп тормастан, татар мәктәпләре, мәдрәсәләре ачалар, вакытлы матбугат эшен юлга салалар, күпләп китаплар чыгаралар, татарларның төрле төркемнәре арасында сәүдә, мәдәни мөнәсәбәтләрне көчәйтәләр, нәтиҗәдә татар бердәм милләт булып оеша. Үз дәүләте булмаган килеш, авыр шартларда оешкан татар милләте, бердәмлекнең кадерен белеп,

төрле ассимиляцион йогынтыларга бирелмәскә тырышып үсүендә, саклануында дәвам итә.

Татар милләте бердәмлеген анык түбәндәге үзенчәлекләрен аерым алып күрсәтү хәзерге көндә тагын да әһәмиятле, чөнки татар милләте бердәм милләт булып оешып җитмәгән әле, яисә ул таркалу алдында тора торган оешмаган бер массаны хәтерләтә дип уйлаучылар соңгы елларда шактый күренә башлады. Татар милләте бердәмлеген, ныклыгын Юлиан Бромлейның милләткә биргән билгеләмәсеннән чыгып, түбәндәге үзенчәлекләрдә күрсәтергә мөмкин.

1. Теләсә нинди милләт билгеле бер территориядә озак тарихи үсеш нәтиҗәсендә оеша. Татар милләте дә Идел-Уралда, Көнбатыш Себердә, үзенең хуҗалык итүен һәм мәдәният үсешен шушы җирләрнең табигый шартларына яраклаштырып, төрле катлаулы чорларны үтеп бүленмәс милләт булып оешып җитә, һәм һәрчак бердәмлеген саклап үсүен дәвам итә.

Татар халкы, Үзәк Азиядә формалашып, әзер килеш Идел-Уралга һәм көнбатыш Себергә монгол-татар яулары буларак килгән диган миф та яши, ләкин бу фикер—шул миф дәрәҗәсеннән үтмәгән уйдырма булып кала, бер генә тарихи факт белән дә раслана алмый. Билгеле, монгол-татар яуларыннан да кемнәрдер калганнар, ләкин алар төрле җирле төрки кабиләләрдән формалашкан болгар халкы эчендә бик тиз эрегәннәр, болгар халкы үзенчәлекләренә сизелерлек йогынты ясый алмаганнар. Җирле төркиләр үз җирле үзенчәлекләрен аз гына да югалтмаганнар. Болгарның менә шул җирле диалекталь төркемнәре XIX йөздә бер милләт булып оешкан, һәм милләт *татар* исемен ала башлаган, шуңа күрә ул, читтән кергән этноним булса да, милләтне формалаштыруда катнашкан этноним.

2. Милләт ул кешеләрнең буыннарара ныклы бердәмлеге, гомумилеге. Бу билге татар милләтенә дә хас, анык да уртак милли үзенчәлекләре буыннан буынга күчеп үсеп килә, һәм иң әһәмиятлесе: бу уртак үзенчәлекләр, буыннарны үзара тоташтырып, милләтне саклау һәм үстерүдә зур роль уйныйлар. Нәкъ менә буыннарара мөнәсәбәтләрнең ныклы булуы безнең этник тамырларның (халыкча әйтсәк, милләт кендегенең) шушы Идел-Уралга һәм Көнбатыш Себергә береккәнлеген бик ачык күрсәтә.

3. Милләт барлык диалекталь төркемнәргә уртак булган чагыштырмача тотрыклы мәдәни үзенчәлекләргә ия була. Татар милләтенең дә барлык диалекталь һәм дини-региональ төркемнәренә уртак булган чагыштырмача тотрыклы гомуми мәдәнияте бар. Мондый уртак мәдәнияткә Болгар дәүләте чорында ук нигез салына, хәзерге диалекталь төркемнәр шул чорда ук, үзара аралашу нәтиҗәсендә, үз мәдәниятләрен бер-берсенә яраклаштырып, аларда уртак сыйфатларны үстереп киләләр.

4. Милләт барлык диалекталь төркемнәргә уртак булган чагыштырмача тотрыклы тел нормаларына ия була. Болгар халкының барлык диалект вәкилләренә дә уртак булган тел Болгар дәүләте чорында ук нормага салына башлый. Ә татар милләте оешу чорында әдәби телнең уртак нормалары язма сөйләмдә ныгытыла. XX гасырда уртак мәдәни нормалар да, уртак әдәби тел нормалары да диалектлардан яңалыклар табу, башка халыклардан уңай күренешләрне алу хисабына баеый, шомара бара. Хәзер татарның һәр диалекты вәкилләре өчен укытучылар әдәби телдә тәрбияләнә, уртак мәдәният традицияләрен үзләштерү юлы белән әзерләнә.

Ләкин бу әйтелгәннәр безнең әдәби тел һәм уртак мәдәният барлык диалектлардан да уңай күренешләрне алып бетерде инде дип әйтергә мөмкинлек бирми. Телне, мәдәниятне бу яктан баету кирәклеге диалектларны төрле яклап өйрәнүне көчәйтергә һәм тирәнәйтергә өнди.

5. һәр милләткә үзен аерым милләт итеп тану уе, фикере булырга тиеш. Татар милләтендә бу үзенчәлек һәрчак булып килде һәм хәзер дә бар.

6. Үзен башкалардан аерылып тора торган аерым милләт дип тану милләтнең төрле-төрле түгел, ә бер үзатамага көчүе белән беркетелә. Бердәм үзатамага күчү һәрбер милләттә дә, башка үзенчәлекләр белән чагыштырганда, иң соңыннан гамәлгә кертелә. Татар милләтендә дә бердәм үзатаманы, ягъни *татар* атамасын, барлык диалекталь һәм дини төркемнәрдә дә үзатама итеп

куллану мәсьәләсе башта ук проблемалы була һәм хәзер дә әле төрле бәхәсләр уята. Моның берничә объектив сәбәбе бар.

Беренчедән, безнең этнос (халык) Болгар дәүләте чорында гомуми *болгар* исемен, Казан ханлыгы чорында *казан* яки *казанлы* атамасын ала башлаган, Рус дәүләте эчендә русларның *татар* дип атауларына каршы үзен *мөселман* дип танытырга тырышкан җирле төрки кабиләләр кушылмасыннан гыйбарәт, аның соңгы атамасы гына монгол-татарлар белән килгән *татар* этнонимыннан тора. Алтын Урда чорында ул шушы дәүләт эчендә калган төрки халыкларның өстенрәк катламнарына табигый рәвештә керә бара, чөнки югарырак дәрәҗәгә һәм байлык туплауга омтылган һәр кеше үз нәселен Чыңгыз хан татары нәселеннән килә дип күрсәтергә тырыша, шулай булмаса, аның үзенең һәм балаларының өстен катлауга үрмәләргә хокукы булмый. Бу хәл казакъ, үзбәктә, каракалпакта, башкортта, әзәрбайҗанда, карачай-балкарда, комыкларда гына түгел, безнең халыкта да күзәтелә. Алтын Урда чорында татар атамасының халыкка керүе нинди генә тизлек белән барса да, ул халыкларның барлык катламнарына да кереп урнаша алмый. Әзәрбайҗаннар, балкарлар, казакълар, башкортлар, үзбәкләр ул исемнән гомумән баш тарталар. XIX йөздә *татар* исеме, җирле төркиләр үсешеннән милләт формалашканда, безнең халыкка башта *читатама* буларак, аннан соң *үзатама* буларак та нигездә үтеп керә.

Икенчедән, *татар* читатамасын ни өчен бездә тулысынча һәм бәхәссез үзатама булып китмәгән, чөнки бу исем руслар, көнбатыш халыклары, фин-угорлар, фарсылар, гарәпләр, кавказлылар һәм күп кенә төрки халыклар, шул исәптән төрекләр аңында үзенә тискәре караш саклый. Татарны алар монгол-татар басып алучылары, үз илләрен талаган, үз дәүләтләрен җимергән халык итеп күз алдына китерәләр. *Татар* исеменә шундый тискәре мөнәсәбәтне бу халыклар хәзерге болгар-татарга да, Кырым татарларына да, Добруҗа татарына да күрсәтәләр, чөнки исеме татар булгач, бу хәзерге татарларны да шул монгол-татар басып алучылары калдыклары дип уйлыйлар. Татарның бу ярасына безнең кайбер тарихчылар да тоз сибеп тора: татарның бөеклеген күрсәтү өмете белән аны монгол-татардан үсеп килгән "бөек" басып алучы дип исбатларга тырышалар.

Менә ни өчен безнең халыкта *татар* исеме, читатама буларак танылса да, һаман әле үзатама булып урнашып җитмәгән.

Шулай итеп татар милләте үзенең югарыда саналган биш үзенчәлеге буенча таркалмас ныклы бердәм милләт булып оешып җиткән, аның бары алтынчы үзенчәлеге—бердәм үзатама булдыруы гына төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә каршылыкларга очрый.

Билгеле, милләтебезнең бердәм үзатамасы булсын өчен көрәшү кирәк, ләкин бу тырышлыкны милләтебезнең бердәмлеге өчен тырышлык дип, төрле ялгыш юлларга кереп китүдән, милләтебезне сан һәм сыйфат ягыннан кубәйтүгә, үстерүгә зыян салудан сак булырга кирәк. Милләтебез бердәм булып оешкан, ул *татар* үзатамасы урнашып җитмәүдән генә таркалырга тора торган аморф-таркау берәмлек түгел.

## Татар милләтен тергезү, саклау һәм үстерүнең төп юнәлеше

Милли азчылыкларның милләт буларак сакланышына яный торган төп иҗтимагый күренеш—күп кенә яшьләрнең, үз телләрен онытып, күрше милләтләргә күчә баруы. Мондый күренеш татарлар арасында да бар. Руслашу, украинлашу, үзбәкләшү, казакълашу, төркмәнләшү, әзәрбайҗанлашу, төрекләшү кебек күренешләр шул регионнардагы татар яшьләре арасында еш күзәтелә. Татарны саклыйк дисәк, милли хәрәкәтнең төп көчен яшьләрнең башка милләткә күчү тенденциясенә, ягъни аларның ассимиляцияләнүенә каршы юнәлдерергә кирәк.

Татар милләтен тергезү, саклау һәм үстерүнең төп юнәлеше XX гасырның 90 еллар башында ук билгеләнде, һәм шул чордан башлап, милли хәрәкәт татарның руслашуына, казакълашуына, үзбәкләшүенә, украинлашуына, әзәрбайҗанлашуына, башкортлашуына каршы төрле юллар белән көрәш алып бара.

Татарның төрле регионнардагы титул милләтләр арасында эрүе аның сан һәм сыйфат ягыннан кимүенә китерә. Татарның гомуми саны һәр халык санын алудан соң бераз артып бара, ләкин тиешле дәрәҗәдә артмый, чөнки татар яшьләре арасында, татарлыгыннан ваз кичеп, башка милләт булып язылучылар да күп. Татар булып язылганнарның да шактые татарча начар белә, аның балалары да шулай булачак, бу татарның сыйфат ягыннан кимүе була. Милли хәрәкәт татар милләтен тергезү, саклау һәм үстерүне татарларның сан һәм сыйфат ягыннан кимүенә каршы чаралар күрү юнәлешендә алып барырга тиеш була.

2002 елгы халык санын алуга әзерлекне башлаганда, милли хәрәкәтнең төп бурычы итәрәк, татар милләтен тергезү, саклау һәм үстерү эшен милләтне сан һәм сыйфат ягыннан киметүгә юл куймау, ягъни ассимиляцияләнүне киметү юнәлешендә алып бардылар. Милләтебезгә *татар* этнонимын үзатама итеп кертүне төгәлләргә тырышу да шушы төп бурыч эчендә, аның бер өлеше буларак каралды. Дәүләт Советы депутатлары һәм гуманитар фәннәр галимнәре Себер татары, Әстерхан татары, керәшен, мишәр һәм болгар булып язылырга җыенучыларга махсус хатлар белән мөрәҗәгать иттеләр: сез, халык санын алганда, үзегезне электән килә торган тар исемегез белән атамагыз, гомуми *татар* исеме белән атагыз, дип үтенделәр. Бу үтенечкә уңай җавап бирүчеләр дә, тискәре җавап бирүчеләр дә булды. Соңгыларын күз алдында тотып, татарның төрле диалекталь һәм дини төркемнәре арасында эш алып бару һәм аларның Мәскәүдәге тиешле структураларга рәсми хат язу кирәклекләре, ул хатта халык санын алу нәтиҗәләрен төзегәндә, Себер татарлары санын да, керәшеннәр, Әстерхан татарлары, мишәрләр, болгарлар санын да татар милләте саны эченә кертүне сорарга тиешләр иде. Элекке халык санын алулар нәтиҗәләре татарлар өчен шулай эшләнә иде.

Ләкин кызганыч ки, боларның берсе дә эшләнмәде, татар төркемнәре эчендә түземле, тыныч эш алып барасы урында, аларны төрлечә куркыту, мыскыл итү юлы белән *татар* этнонимын барлык халыкка үзатама итеп урнаштыру тырышлыгы башланды. Нәтиҗәдә, татарның төрле төркемнәре арасында ризасызлык тудырылды, татарлыктан качу очраклары ешрак күренә башлады.

Җитмәсә, фәнни төшенчәләр буташтырылып, бердәм үзатама алу төшенчәсен татар милләтенең бердәмлеген тәэмин итү төшенчәсе белән алмаштырып куйдылар; татар яшьләренең башка милләткә күчүенә каршы көрәш бөтенләй онытылды. Тагын да зарарлысы шул булды: хәзерге татар милләтен монгол-татар яуларыннан калган дип күрсәтергә тырышып, яшьләр арасында татар исеменнән читләшүчеләрне тагын да арттырдылар.

Шулай итеп, милли хәрәкәтнең төп максаты—татар милләтен тергезү, саклау һәм үстерү, тагын да төгәлрәк әйтсәк, яшьләрнең башка милләтләргә күчү очракларына, милләтнең сан һәм сыйфат ягыннан кимүенә юл куймау. Менә шушы төп бурычны үтәүгә бәйле рәвештә милләтебезгә *татар* этнонимын үзатама итеп урнаштырып бетерү дә карала. *Татар* этнонимының татар милләтенә бернинди зыяны тимәс, әгәр безнең халыкны монгол-татар яуларыннан үсеп килгән халык итеп күрсәтмәсәләр. Алай күрсәтелсә, *татар* этнонимы милләтебезне үстерү өчен түгел, ә акренләп юкка чыгару өчен хезмәт итәчәк. Моны безгә һич онытырга ярамый.

## Татар милләтен сан һәм сыйфат ягыннан киметмәү юллары

Алда әйтелгәнчә, башта СССР да, ул таркалгач, Россия Федерациясендә бердәм совет халкын төзү һәм киләчәктә Россиядә бер генә милләт калдыру программасы милләтләрне тергезү, саклау һәм үстерү сәясәте белән алмаштырылды. Россиядә бу программа "Народы России: возрождение и развитие" дип аталды. ТР ФА гуманитар гыйлемнәр бүлегендә без аны "Татарский народ и народы Татарстана: возрождение и развитие" дип формалаштырдык. Ләкин бу без Татарстандагы барлык халыклар мәсьәләләре белән дә шөгыльләнергә тиеш дигән сүз түгел иде. Без бары татар милләтен тергезү, саклау һәм үстерү проблемаларын гына өйрәндек. Татарстандагы башка милләтләргә, мәсәлән, чуаш, мари, удмурт, рус, украиннарга бу халыкларның

үз республикаларында эшләнгән программаларны гамәлгә куярга ярдәм иттек.

Россиядәге милләтләр эшләре министрлыгы кушуы буенча, милли азчылыкларны тергезү һәм үстерү эшләрен планлаштыру, аны гамәлгә кую программаларын төзү башланды. Мәскәүдә 1992 елда "Концепция государственной программы национального возрождения народов РФ", 1994 елда "Государственная программа национального возрождения и межнационального сотрудничества народов России *(Проект)*" исемдәге брошюралар дөнья күрде.

Татар милләтен тергезү һәм үстерү программасын төзү буенча да бер төркем галимнәр җиң сызганып эшкә керештеләр. Бу программаның бер өлеше "Возрождение и развитие этнокультурной жизни татар, проживающих на территории РФ" исемендә аерым брошюра булып басылып та чыкты *(К., 1994)*. Ләкин тел буенча закон, аның үтәлешен тәэмин итү өчен дәүләт программасы, мәгариф, мәдәният һ. б. законнар кабул ителеп, аларны гамәлгә ашыру эшләре башлангач, милләтләрне тергезү һәм үстерү буенча гомуми программалар төзү туктатылды, дөресрәге, бу эш башка формаларны алды.

Тел, әдәбият һәм тарих институтында, ТР ФА гуманитар гыйлемнәр бүлегендә татар халкын тергезү, саклау һәм үстерү проблемаларын экология фәне югарылыгында хәл итү юллары табылды. Нәтиҗәдә Татарстандагы экология фәне үсешендә татар милләтен тергезү һәм үстерү юлларын тулы бер система итеп өйрәнә торган этноэкология юнәлеше барлыкка килде. *Кеше экологиясе, Мәдәният экологиясе* дигән терминнар белән янәшә яңа юнәлеш һәм аның *этноэкология* дигән атамасы тәкъдим ителде.

Милләтне тергезү һәм үстерү проблемаларын экология фәне югарылыгында хәл итүнең төп юнәлешләрен билгеләгәндә, ИЯЛИ галимнәренә чит ил, бигрәк тә Америка, белгечләре белән тыгыз элемтәгә кереп киңәшләшергә туры килде. Татар милләтенең этноэкологиясе буенча эшлекле фикер алышулар Казанда үтә торган экологик конгрессларда да регуляр рәвештә үткәрелә башлады[2]. Менә шундый бәхәсләрдән соң татар этноэкологиясенең бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән түбәндәге юллары билгеләнде.

1. *Татарлар яши торган регионнарда* ***табигый мохитне*** *саклау һәм камилләштерү*. Әгәр бу мохитне яхшыртуга игътибар бирелмәсә, милләтебезнең сәламәтлеге түбән дәрәҗәдә булып, үлүчеләр саны туучылар санынннан артып китәргә мөмкин. Кызганычка каршы, без хәзер бары Татарстандагы табигый мохиткә генә тәэсир итә алабыз. Татарлар күпләп яши торган башка регионнарда табигый мохитне саклау һәм камилләштерү мәсьәләләрен Россия күләмендә уңай хәл итүгә Бөтендөнья татар конгрессы аерым әһәмият бирә алыр иде. Бу эш табигый мохит бик нык бозылган регионнарда, мәсәлән, Чиләбе өлкәсендә татарларның үзләрен Россия дәүләт органнарына тәэсир итәрлек итеп оештыру юнәлешендә, конгрессның бу органнар белән турыдантуры бәйләнешкә керүе тәртибендә алып барылырга мөмкин. Билгеле, Татарстан дәүләтчелеге дә Россия каршында мондый мәсьәләләрне күтәрә алыр иде.

2. *Татарлар яшәгән регионнарда аларның* ***социаль-икътисади мохитен*** *саклау һәм камилләштерү*. Бу мохит канәгатьләнерлек булмаса, милләтне сыйфат ягыннан да, сан ягыннан да үстерү мөмкин түгел. Шуңа күрә милләт яшәешенең социаль-икътисади шартларын камилләштерүне дәүләт оешмалары эшчәнлегенә генә кайтарып калдырырга ярамый, татар эшкуарлары да бу юнәлештә актив эш алып бара алырлар иде, аларны оештыру эше Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетында төзелгән махсус төркем тарафыннан уңышлы башкарылыр иде. Үрнәк өчен тәҗрибә бар: XIX гасыр ахырында XX йөз башында татар байлары татар милләтен бүленмәс бер бөтен итеп формалаштыра алганнар ич.

Социаль-икътисади мохитне камилләштереп, аны халык санын үстерүгә юнәлдерү буенча безгә чехлардан үрнәк алу урынлы булыр иде. Алар гаиләдә күп бала булдыруга һәм балаларны дәүләт хисабына (Төркиядә—зәкят хисабына) тәрбияләүгә бик күп чыгымнар тоталар һәм халык санын арттыруга сизелерлек өлеш кертәләр.

3. *Татарлар яшәешенең* ***милли мәдәни мохитен*** *саклау һәм камилләштерү*. Информация чараларының үсеше һәрбер халык арасына мәдәниятнең халыкара формаларын күпләп кертә бара. Бу мәдәниятләрнең уңай яклары

белән бергә, милләтнең традицион яшәешен таркату, яшьләргә мораль бозыклык йоктырып, халыкларның киләчәк тормышын юкка чыгару, аларның ассимиляцияләнүләрен тизләтү максатында пропагандалана торган тискәре яклары да бик нык сизелә. Ул милли мәдәни мохитне әкренләп юкка чыгаруга илтергә тырыша. Менә шуның өчен дә милли мәдәни мохитне саклау һәм аны халыкара мәдәниятнең уңай яклары белән генә бизәү кебек эшләр милләтне саклауда һәм милләт буларак үстерүдә аерым әһәмияткә ия. Бу эш бездә мәдәният министрлыгы тарафыннан һәм аның җитәкчелегендә алып барыла. Татар халкын сан һәм сыйфат ягыннан үстерүне аның милли мәдәни мохитен камилләштерү аркылы алып бару турында информация чараларында аерым бер фикер алмашу оештырганда да зыян итмәс иде.

4. *Татарның* ***конфессиональ мохитен*** *саклау һәм камилләштерү*. Советлар берлеге чорында халыкның дини мохитен юкка чыгару эше җәелдерелгән иде, барлык милләтләрне дә бердәм атеистик юнәлештә тәрбияләү кабул ителде, бу һәр халыкта да яшьләрнең мораль сыйфатын түбән төшерүгә китерде. Шуңа күрә дини тәрбиянең яңадан кайтарылуын халык бик теләп кабул итте. Бу эшне оешкан төстә алып бару өчен, мөфтиятнең күп тармаклы эше җәелдерелде. Керәшеннәрнең дә үз конфессиональ оешмалары булдырылды. Дини оешмаларның эшен тагын да җанландыру һәм диннәрне милләтебезне сан һәм сыйфат ягыннан үстерү юнәлешендә файдалану буенча мөфтият газеталарында фикер алышуларны еш кына күрергә туры килә.

5. *Татар яшәешенең* ***милли мәгариф мохитен*** *саклау һәм камилләштерү*. Мәгариф һәм тәрбия системасы да үзгәрешсез тормый, дөньякүләм уңай тәҗрибәне алып, һәрчак баеп, камилләшеп тора, шушы процесста ул үзенең миллилеген дә югалтмаска, уңай сыйфатларын үстереп, дөнья мәгарифенә, педагогикасына аз булса да үз өлешен кертергә омтылыш күрсәтә. Киләчәктә татар милләте яшәрме, милли үзенчәлекләрен саклармы, сакласа, ни дәрәҗәдә саклар, болар барысы да милли мәгарифебезнең үсеш дәрәҗәсенә бәйле.

Мәгарифнең контрольсез һәм җитәкчесез өлеше—гаилә тәрбиясе һәм урам тәрбиясе. Балалар бакчасы, башлангыч мәктәп, урта мәктәп, профессиональ урта уку йортлары, вузлардагы мәгарифне кирәк юнәлештә оештырып була, билгеле, моңа теләк булса һәм ихтыяр көче житсә.

Татарда мәгариф мохитен дөнья күләм югарылыкка күтәрү, шуның белән бергә милли үзенчәлекләрен дә үстерә бару бары мәгариф министрлыгының гына түгел, ул барлык татар зыялыларының изге эше. Хәзергә әле без милли мәгарифебез, тәрбия системасы, милли педагогика фәне тиешле югарылыкта тора дип әйтә алмыйбыз.

6. *Татар яшәешендә* ***милли тел мохитен*** *саклау һәм камилләштерү*. Татар булып яшәү өчен, кеше татар телен белсә житә, дигән караш хәзерге чор өчен кабул ителә алмый. Хәзерге тәрбияле дип саналган кеше рус телен дә яхшы үзләштерә, бер чит тел (көнбатыш йә көнчыгыш теле, яисә икесен дә) белә, ә үз ана телен су кебек эчә алырга тиеш. Шул очракта гына татар кешесе Россиянең һәм Татарстанның дәүләт структураларында да, иҗтимагый оешмаларында да коммерция юнәлешендә дә әйдәп баручы белгеч була ала. Ләкин шунысы аяныч, татар яшьләре өчен үз ана телен өйрәнү, аны куллану авыр проблемага әйләнеп бара. Шуңа күрә татар телен тормышның барлык сфераларында да кулланырлык дәрәҗәдә белүне тәэмин итү милләтне саклау өлкәсендә төп бурыч булып кала бирә.

Татар баласының теле татарча гына ачыла дигән чорлар үтте. Баланың теле татарча ачылып, рус телен һәм чит телне соңыннан өйрәнү очраклары авыл җирләрендә, сирәгрәк шәһәрләрдә сакланган. Баланың теле русча яки русча да, татарча да ачылып, ана телен соңыннан өйрәнү яисә татарчаны соңрак шомарту очраклары шәһәрләрдә, район үзәкләрендә еш күзәтелә; болар белән бергә татарчасын бөтенләй өйрәнмичә калучылар да бар, шуңа күрә, бездә татар телен ана теле буларак кына түгел, чит тел буларак укытуга да житди игътибар бирелә. Татарстанда бу мәсьәлә аз булса да чишелә. Башка регионнарда аны чишү бик авырга туры килә. Бу мәсьәләне хәл иткәндә, татарлар компактлы яшәгән регионнарда укытучылар әзерләүне юлга салу, моңа Татарстан вәкиллекләре ярдәмен арттыру уңай роль уйнар иде. Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты да бу изге эштән читтә кала алмый.

Министрлар кабинетында телләр проблемасы белән шөгыльләнүче бүлек тә мондый эшләргә әледән-әле игътибар биреп тора.

2002 елның декабрь ахырында Дәүләт Советы үзенең XIII пленар сессиясендә "ТР халыклары телләре турында "ТР Законының һәм ТР халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча ТР Дәүләт программасы[3] үтәлешен тикшерде. Сессия бу документларның гамәлгә куелышында уңай яклар белән бергә зур кимчелекләрнең булуын да билгеләп үтте[4].

Дәүләт Советында әйтелгән кимчелекләргә өстәп, шуны әйтәсе килә: министрлыклардан, шәһәр һәм район администрацияләреннән телләр Законын канәгатьләнерлек дәрәҗәдә үтәүне таләп итү урынына Дәүләт Советы депутатлары да, аларга ияреп, Министрлар кабинетының махсус бүлеге дә аны ничек итеп, кайсы яклап үзгәртергә икән дигән буш кайгы белән артык мавыгып китмәделәр микән, дигән сорау туа.

Татар теленең барлык өлкәләрендә дә иркен кулланылуын тәэмин итү милләтне сан һәм сыйфат ягыннан үстерүнең төп шартларыннан берсе.

7. *Милли телне, милли мәдәниятне саклау һәм аларны саклаучыларны тәрбияләп, үстереп чыгару ягыннан* ***татар авылларын саклау****, алардагы социаль-икътисади вәзгыятьне камилләштерү аерым әһәмияткә ия.* Кызганычы шул: информация чаралары үсү авылга да шәһәрләрнең, хәтта чит илләрнең тискәре күренешләрен әкренләп кертә бара. Моңа каршы көрәш, авылны савыктыру шул ук информация чаралары аркылы алып барылырга мөмкин. Турысын әйтергә кирәк, авылны яшәтү, андагы милли телне, мәдәниятне саклау һәм камилләштерү юллары бездә бөтенләй ачыкланмаган. Бу мәсьәлә бөтен җитдилеге белән дәүләт структуралары алдында да, Фәннәр академиясе бурычлары системасында да, БТК башкарма комитеты һәм БТИҮ каршында да бөтен кискенлеге белән торырга тиеш.

8. *Милләт яшәешендә* ***дуслык мохитен*** *саклау һәм камилләштерү аерым әһәмияткә ия.* Милли үсешкә уңай тәэсир итә торган дуслык милләтнең зыялылары арасында да, милләтнең аерым төркемнәре арасында да башка милләтләр белән мөнәсәбәттә дә булырга тиеш. Кызганыч, бу безнең шактый аянычлы өлкә.

XVII гасырда татар җирләренә килгән төрек сәяхәтчесе Әүлия Чәләби мондагы зыялылар арасында дуслык булмауга исе китә, һәм моны башка халыкка буйсынып, аңа яраклашырга тырышып яшәүдән килә дип аңлата. Татар зыялылары арасында дуслык булмауга башка чорларда да игътибар иткәннәр. Ләкин хәзерге зыялылар арасында дуслыкны җимерүнең гайре табигый формалары барыбызны да гаҗәпкә калдыра. Бездә нәкъ менә милләтне тергезү, саклау һәм үстерү проблемалары белән шөгыльләнүчеләргә ясалма гаепләр тагу, аларның абруен төшерү өлкәсендә армый-талмый хезмәт итүче белгечләр, аларның моңарчы күрелмәгән әшәке алымнары, боларның ялганнарын басып торучы матбугат органнары барлыкка килде.

Ачык дискуссияләрдә җиңә алмагач, каршы як өстеннән югары оешмаларга әләк язу һәм, коллектив исеменнән булсын дип, аларга алдау юлы белән имзалар җыю, аерым эшлеклеләргә яла яккан хатларына акча түләп (үзенекен түгел, билгеле), башкалардан кул куйдыручылар, чит кеше исеменнән хат язучылар, мөнәсәбәтләрне мәхкәмәләргә җиткереп торучылар, хәтта үз дошманнарын башкалар исеме белән мәхкәмәгә бирүчеләр үсеп чыкты. Мондый күренешләргә каршы җәмәгатьчелек чаралар күрә алмаса, бездә милләтне тергезү, саклау һәм үстерү эшенә бик зур зыян салыначак.

XIX йөзнең II яртысында бердәм татар милләте булып оешкан Казан татарлары, Себер татарлары, Әстерхан татарлары, мишәрләр, керәшеннәр арасында үзара үпкәләшләрнең 2002-2003 елларда кузгатылуы һәм көчәеп китүе безне шулай ук бик нык борчый.

Милләтне тергезү, саклау һәм үстерү мәсьәләләрен файдалы итеп чишү өчен, татарның башка милләтләр белән дуслыгы да төп шартларның берсе булып санала. Соңгы елларда татар һәм рус информация чараларында татарны руслар, башкортлар белән ачуландыручыларны тәнкыйтьләп язган мәкаләләр еш күренә.

XIX йөзнең II яртысында рус империясе үсеп килгән чорда безнең элekke зыялыларыбыз һәм байларыбыз Рус дәүләте эчендә бердәм татар милләтен

оештыра алганнар. Хәзерге татар зыялыларына һәм байларына шулардан үрнәк алу бик отышлы булыр иде.

9. *Татарны милләт буларак тергезү, саклау һәм үстерү мәсьәләләрен уңай хәл итүдә аның **үз тарихының дөрес мохитен** булдыру шулай ук зур әһәмияткә ия.* Ныклап тикшереп тормастан, бер үк *татар* исеме белән йөртелгәнлектән, безнең татарны вакытында бик күп илләрне яулаган чыңгызлылар армиясеннән (ягъни монгол-татардан) калган халык дип уйлап, күп кенә рус, көнбатыш, гарәп, фарсы, фин-угыр тарихчылары һәм зыялылары татар дип аталган халыкка тискәре мөнәсәбәттә торып, үз халыкларында татарны күрә алмаучылык мөнәсәбәтен тәрбияләп тордылар. Татарга карата мондый мөнәсәбәт хәзер дә еш чагыла. Бер генә мисал китерәм. В. В. Похлебкин дигән бер тарихчы үзенең 2000 елда Мәскәүдә басылган "Татары и Русь" дигән китабында хәзерге татарны монгол-татарның турыдан-туры дәвамы рәвешендә тикшерә дә, монгол-татарның дәүләтчелеген юкка чыгардык, хәзер татар дәүләтчелеген (ягъни Татарстанны) ахырына кадәр юк итү бурычы тора (167 б.) дип йомгак ясый.

Дилетант зыялылардан чыккан бу иске карашны Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, С. Шпилевский, Г. Әхмәров, Риза Фәхретдин, Һ. Атласи, Г. Гобәйдуллин, Н. Воробьев, А. Смирнов, Х. Гимади, А. Халиков кебек галимнәр дөрес түгел дип таптылар, күптөрле тарихи чыганакларны анализлап, хәзерге татар халкының Болгар дәүләте чорында *болгар* дип аталган бик борынгы җирле төрки кабиләләрдән формалашуын ачтылар, татар ул килмешәк түгел, ә бик борынгы җирле тамырлы халык дип исбатладылар. Бу караш татар яшьләре арасында үз халкы белән горурлану хисләре уятып торды, шуңа күрә алар үз татарлыкларыннан ваз кичәргә уйламадылар да.

XX гасырның 60 елларында—Төркиядә, 90 елларда Татарстанда кайбер тарихчылар, киресенчә, татарның бөеклеген күрсәтәбез дип, татарны Чыңгыз хан һәм Бату хан яуларыннан калган халык дип күрсәтүне үзләренең "патриотик" бурычлары дип таныдылар. Татар этногенезын җирле болгарлар һәм алар составындагы бик борынгы җирле төркиләр белән бәйләүне алар, татарны кече итеп күрсәтү максатыннан, рус колонизаторлары һәм Сталин уйлап чыгарган дип яздылар. Татарны монгол-татар белән тиңләү татар яшьләрендә татар булып язылучыларны бик нык киметкәнлектән, урда татарчылары дип аталган бу төркем татарның руслар, украиннар, үзбәкләр, казакълар һ. б. арасында ассимиляцияләнүенә каршы көрәшергә кирәк дип тә тапмадылар.

Халкыбызны тергезү, саклау һәм үстерү турында фикер алышканда, татар этногенезының мондый проблемаларын принципиаль югарылыкта хәл итәргә мәҗбүрбез.

10. *Татар милләтен тергезү, саклау һәм үстерү эшен Татарстаннан тыш регионнарда **милли-мәдәни автономияләр** алып бара.* Боларның тәҗрибәләре әле бик бай түгел, шулай да үз бурычын аңлап, халкыбызны саклау эшләрен тәртипле итеп алып барган автономияләрне дә күрсәтә алабыз. Милли-мәдәни автономияләрнең эшләрен оештыру турында фикер алышулар булып тора, ләкин бу эшне өйрәнү һәм камилләштерү буенча бездә галимнәр, белгечләр төркеме тупланмаган әле.

11. *Милләтне тергезү, саклау һәм үстерү эшләрен җайга салу өчен **дәүләти булмаган оешмаларның** тәэселүе һәм аларның эшен нәтиҗәле итү тырышлыклары да зур әһәмияткә ия.* Дәүләти булмасалар да, боларның эшчәнлеген дәүләт органнары координацияләргә тырыша, билгеле дәрәҗәдә матди чыгымнарын да каплый. Мондый оешмаларга Бөтентатар иҗтимагый үзәге, Бөтендөнья татар конгрессы, Татар хатын-кызлар оешмасы "Ак калфак", Гомумроссия күләмендәге татар оешмасы "Ватаным", Бөтентатар мәгариф берлеге, Иттифак партиясе, Милли мәҗлес һ. б. керә. Бу оешмаларның төп бурычлары бер үк—татар милләтен саклау һәм үстерү мәсьәләләренең иң әһәмиятле якларын табып, шуларны хәл итү белән шөгыльләнү. Бу изге эшне алар төрлесе төрле дәрәҗәдә башкара, ләкин зыялылар арасындагы кебек үк, болар арасында да эшләрне үзара килештереп дусларча эшләү җитешми, һәр оешма татар проблемаларына баш булырга тырыша. Мин үзем болайрак фикер йөртәм: татарлар бөтен Россиягә таралып яшиләр, дәүләт казнасына салым бирәләр, шул акчалардан татарны тергезү, саклау һәм үстерү проблемалары белән Россия дәүләте күләмендә, ләкин Татарстан дәүләте белән

килештереп шөгыльләнерлек бер оешма булырга тиеш, башка оешмалар төп йөкне аның белән бергә тартып барырга тиешләр.

12. *Татар милләтен тергезү, саклау һәм үстерүдә хәл иткеч рольне* ***Татарстан дәүләте органнары*** *уйныйлар.* Президент аппаратында да, Дәүләт Советында да, Министрлар кабинетында да бу әһәмиятле мәсьәләләрне чишә торган структуралар эшли. Иҗтимагый оешмаларның бу юнәлештәге эшләрен координацияләүгә дә дәүләт органнары әһәмият биреп килələр. Кайбер министрлыкларның һәм Фәннәр академиясенең бүлекләре дә татар милләтен тергезү,саклау һәм үстерүнең югарыда саналган юнәлешләрен хәл итүдә катнашалар. Ләкин Татарстан дәүләтчелегенең бу юнәлештәге эшләре бик уңышлы бара дип булмый, төп эшнең камилләштерелергә тиешле тармаклары шактый күп әле.

Мин үзем Фәннәр академиясенең бу юнәлештәге эшен сизелерлек йомшартуын ачыктан-ачык әйтергә кирәк саныйм. Югарыда әле генә саналган 12 юнәлеш буенча Россия күләмендәге экологик конгресста, этноэкология секциясен ачып, гуманитарлар да, төгәл фән әһелләре дә мәсьәләләрне комплекслы хәл итү юлларын эзли идек. 2002 елдагы экологик конгресста ТР Фәннәр академиясе беренче мәртәбә этноэкология секциясен оештыруны кирәк тапмады.

Милли хәрәкəттә төп максатны—милләтебезне тергезү, саклау һәм үстерүгә хезмәт итү максатын һич онытырга, аны икенче, өченче дәрәҗәдәге, беренче карашка кызык күренгән, юнәлешләр белән алмаштырырга юл куелмаска тиеш.

## Чыганаклар


1. *Документы ООН.* Декларация о правах лиц, принадлежащих к национальным или этническим, религиозным и языковым меньшинствам. (Принята Генеральной Ассамблеей ООН 18 декабря 1992 г., резолюция № 47/135.//Национальные меньшинства (Документлар җыентыгы).—Казан, 1995, 7-10 битләр.

Венская декларация и программа действий (извлечение). 1993 елның 25 июнендә кабул ителгән. Шунда ук. 11 бит.

*Документы Совета Европы*

Принципы, касающиеся национальных меньшинств. (Разработаны Европейской комиссией по обеспечению демократии посредством права)//Шунда ук. 12-14 бб.

*Документы организации безопасности и сотрудничества в Европе*

Документы копенгагенского совещания конференции по человеческим измерениям (Извлечения)//Шунда ук. 15-17 бб.

Доклад совещания экспертов СБСЕ по вопросам национальных меньшинств в Женеве. (1991 елның 19 июлендә кабул ителгән)//Шунда ук. 18-25 бб.

Хельсинские решения (извлечения), 1992 елның 10 июлендә кабул ителгән.// Шунда ук. 25-29 бб.

*Документы содружества независимых государств*//Шунда ук. 31-38 бб.

*Документы двусторонних соглашений Российской Федерации*//Шунда ук. 39-46 бб.

2. Актуальные экологические проблемы РТ. Тезисы докладов II Республиканской научной конференции.—Казан, 1995. "Этноэкология" бүлеге (20 докл.), 252-266 бб.

Актуальные экологические проблемы РТ. Тезисы докладов III Республиканской научной конференции.—Казан, 1997. "Этноэкология" бүлеге (25 докл.), 343-358 бб.

3. "ТР халыклары телләре турында" ТР Законы, ТР халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча ТР Дәүләт программасы. —Казан, 1996.

Тел язмышы—милләт язмышы. 2002 елның декабрь аенда Дәүләт Советы сессиясендә З. Вәлиева, М. Шәймиев, Р. Миңнуллин, Р. Вәлиев, И. Таһиров чыгышларының төп эчтәлеге. Сәхифәне Роза Рәхмәтуллина әзерләде//Ватаным Татарстан, 15 гыйнвар, 2003 ел.


❊

*Дискуссия: "Безнең заман герое"*

**Радик Фәизов**

## АЛАР БЕЗНЕҢ АРАДА

Журнал редакциясе безгә хәзерге заманда, менә бүгенге көндә әдәби әсәр герое булган яисә булырдай кешеләр хакында сүз башларга тәкъдим итә. Чыннан да, безнең заман геройлары алар кемнәр, алар нинди? Башта ук шунысын кисәтик, галәмәт тә кыен сорау бу. Сүз кешелек дөньясының иң югары, иң кыйммәтле рухи һәм мәдәни казанышы булган әдәбият, әдәби әсәрләр һәм алар битләренә күтәреп куярга лаеклы табылган затлар турында бара бит. Укучыларның миллионлаган армиясе үрнәк алырга, үз тормышларында, яшәү гамәлләрендә өлге итеп куярлык шәхесләр турында. Чыннан да, әдип халкы үзенең иң яратканы яисә күрәлмаганы, күңелен дулкынландырганы, әсәр кадәр әсәр язарга этәргеч биргәне итеп безнең арабыздан кемнәрне сайларга тиеш әле? Авырлыгы тонналап исәпләнә торган сораулар бу. Заманыбызның нинди икәнен барыбыз да бик беләбез, күреп торабыз.

Яше белән өлкән әдипләр хәтерли булыр, совет хакимияте вакытында бу сорауларга җавап бирүе җиңел генә иде. Дөресе, ошбу җаваплар каядыр шунда өстә, югарыда, коммунизм идеологлары тарафыннан тәгаенләп куела һәм түбәнгә, әдипләр өстәленә төшерелә генә иде. Әгәренки әдәби әсәр күтәреп килсән, редакцияләрдәге мөхәррирләр һәм әдәби хезмәткәрләр сиңа бу хакта вәгазь укып алырга бер дә иренми иде. "Җанашым, әсәрең әлегә барып чыкмаган. Без совет укучыларына лаеклы типларны күрсәтергә тиеш. Бар яктан килгән, унган-булган, гомуми эштә соңгы чиккә кадәр фидакарь, актив, эшчән, намуслы, җиң сызганып коммунизм төзегән типларны",—дип.

Ә беләсезме, мин үзем, шәхсән, моны бернинди гаепкә санамыйм. Бу социалистик реализм ысулы иде һәм ул чакта барча әдипләр дә шушы ысул белән иҗат иттеләр дияргә мөмкин. Үзләренең әсәрләрендә нәкъ менә тормышта актив, хезмәт сөючән, җәмгыять мәнфәгатьләрен үзенекеннән өстен куя алган кешеләрне сурәтләделәр, шуларга табындылар. Әмма, уйламагыз, аларның геройлары арасында уңай гына түгел, киреләре дә бар иде. Үз мәнфәгатен өстен куйган, астыртын, шәхси байлыкка омтылган, холкы белән дә әшәке булган типлар. Ләкин алар, кагыйдә буларак, хикәяләү барышында үзгәрергә, үзләренең кимчелекләрен, хаталануларын белеп алырга, алардан ваз кичәргә һәм җиң сызганып гомуми эшкә бирелергә тиешләр иде. Нәрсә, әллә начар идеме бу?! Шушы мәсләкне тоткан көйгә иҗат итеп, безнең татар әдәбиятында да зур әдипләр, чын сүз осталары үсеп чыкты һәм алар халык яратып укыган, ихлас күңелдән кабул иткән әсәрләр дә яздылар. Әдәбиятыбызның алтын фондына кереп калган һәм әле дә яратып укыла торган әсәрләрне.

Алып карасаң, бәлки бу хәзерге заманда бераз сәеррәк тә ишетелер: ләкин ул вакытта аның тормышта, безнең арабызда нәкъ менә шундый таләпләргә җавап

бирердәй кешеләре дә житәрлек иде бит. Гомуми эшкә, гомуми хәрәкәткә ихластан бирелгән, җәмгыятьтә югары урыннар биләүләренә дә карамастан һәм мөмкинлекләре булса да, бернинди шәхси байлыкка, муллыкка омтылмаган, хәрәм үзләштерүләргә бармаган, намусы белән чип-чиста, гадел һәм тыйнак затлар. Чын мәгънәсендәге Кешеләр! Мин үзебезнең Дусым авылында "колхоз эшенә соңга калам бугай!" дип, кулына сәнәген тотып югары очка йөгереп менгән кешеләрне хәтерлим. Социализмны аны коммунистлар гына түгел, бөтен совет халкы төзеде. Хәзерге көндә кайбер әдипләрнең "социализм халыкка көчләп тагылган иде!" дип пыскып торуы дөреслеккә хилаф салу гына ул.

Монда шунысын да искә алыйк әле, гадәттә, безнең тирә-яктагы кешеләргә, таныш-белешләргә караш, аларга биргән бәябез бик субъектив була. Без, дөресен генә әйткәндә, тирә-юньдәгеләрдән күбрәк гаеп эзләргә, аларның тискәре якларын гына алга чыгарып куярга күнеккән. Әгәренки арабыздагы кемнән дә булса: "Сезнең таныш-белешләр, дуслар, туганнар арасында әдәби әсәр герое булырдай, аны үрнәк алырга өлге итеп куярдайлары бармы?" дип сорасаң, ул ни әйтергә белми аптырап калыр иде. Кайберәүләренең: "каян килсен безгә андый кешеләр?" дип куюлары да бар. Әмма уйлырак, гакыл иясе кеше булса: "ник булмасын, бар андыйлар!" дип хәл итәр иде.

Үткән гасырның житмешенче елларында мин Арча район газетасы редакциясендә, мөхәррир урынбасары Равил Сабирович Вәлиев белән бер бүлмәдә утырып эшләдем. Партия мәктәбен бетергән, коммунизм идеяләренә чын күнелдән бирелгән кеше иде ул. Бирегә килгәнче партия һәм совет органнарында эшләп зур тәҗрибә туплаган, тормыштан бик тә мәгълүматлы, нык принциплы, дөньяны танып белүе бик колачлы кеше. Сүз уңаенда әйтим, мин ул сөйләгәннәрдән, аның фаразларыннан чыгып бик күп публицистик әйберләр яздым. Без аның белән еш кына, бик кызу бәхәсләргә кереп китә идек. Башлыча, гел бер темага. Мин безнең илдә, безнең җәмгыятьтә бернинди сүз ирege, демократия булмавын бәян итәм. Равил Сабирович шунда ук гөлт итеп кабына, безнең илдә тулысынча сүз ирege, чиксез демократия хөкем сөрә дип исбатларга керешә. Чит илләрдәге капиталистик демократияне череккә, икейөзлегә чыгара. Безнең бәхәсләр берни белән дә тәгәлләнми, һәркем үз фикерендә кала.

Равил Сабирович әдәбият һәм сәнгать тормышыннан да бик хәбәрдар торды. Бервакыт без аның белән үз алдыбызга сорау куйдык: безнең тирә-юньдә, Арча бистәсендә без белгән, шул замандагы әдәби әсәр герое итеп алырдай кешеләр бармы? Һәрьяктан килгән, укучыга үрнәк итеп куярлык, чын мәгънәсендә әйбәт шәхесләр. Мәсьәләгә бик җитди карадык, кандидатларны бик сайлап кына алдык. Һәм ни диярсез! Андый кешеләрне байтак таптык. Кайчандыр КПСС райкомының беренче секретаре, ә аннары педагогия училищесы директоры булган Мөнәвир Гәрәевич Ибраһимов, шулай ук райком секретарьлары Әсгать ага Йосыпов, Гани Нуриевич Нуриев, үзебезнең инде мәрхүм редактор Шакир ага Гафаров. Күрәмсез, коммунистлар партиясенең район дәрәҗәсендәге җитәкче органнарында журналистлар һәм халык та ихтирам иткән шәхесләр дә булган икән. Аннан килеп, Арча автотранспорт предприятиесе шоферы Сәлихҗан Галимҗанов, укытучы Фатыйма апа Нуретдинова, пенсиядәге Һашим ага Нуриев, безнең ул чактагы редактор Тәлгать Нурзадович Мостафин.

Тәлгать Нурзадович үзенең барлыгы белән шул кадәр эшчән, тыйнак һәм намуслы бер зат ки, шул унайдан бер вакыйганы хәтергә төшерим әле. Бервакыт редакциядә үзара гына бәхәс чыкты: безнең илдә якын арада коммунистик җәмгыять төзеп буламы? Күпләр мона зур шик белдерде. Сәбәп итеп кешеләрнең, бөтен халыкның рухи яктан әзер түгеллеген китерделәр. Бездә кеше рухының әлегә гомумән түбән булуын, коммунистик җәмгыять вәкиле таләпләренә рухы белән бөтенләй дә җавап бирмәвен. Искәртим, бу чакта редакциядә Мостафин үзе юк иде. Шунда мин тордым да әйттем:

—Ни эшләп төзеп булмасын икән коммунизмны? Менә җәмгыятьнең һәр әгъзасы безнең Тәлгать Нурзадович кебек булсын иде. Иртәгә үк илдә коммунизм гөрләп торачак!—дидем. Һәм шунда барысы да минем фикергә кушылдылар.

Аннан килеп, Равил Сабирович үзе дә, мәрхүм, менә дигән әдәби әсәр герое булырдай шәхес иде. Урта мәктәптән ары югары белеме булмаса да, үзлегеннән укып гаять киң һәм тирәнтен гыйлем туплаган. Ни турында сорасаң да, аннан җавап алырга була. Эшкә һич иренми, бу мөхәррир урынбасары өчен вак эш дип тә тормый. Гаять тапкыр, шаян сүз остасы! Хәтта төскә-биткә дә чибәр, ярау, күркәм, кыскасы, дөнья бәһасе кеше иде. Әдәби әсәр битенә әлләни үзгәртмичә дә, күчереп

кенә куярга лаеклы герой.

Әлбәттә, уйлый күрмәгез, менә мондый унай шәхесләр янәшәсендә ул заманда да бөтенләй икенче типлар, яман кире, сәер, аңлап булмаслык геройлар да тулып ята иде. Үзләренең начар холыклары белән күзгә бәрелеп торган бәндәләр. Аларны атап тору кирәкмәстер.

Менә болар үткән заманның әдәби әсәр герое булырлык типлары. Әдәбиятта тулысы белән социалистик реализм хөкем сөргән заманнар. Һәм ул вакытларда әдипләр иҗат иткән очерк, хикәя, повесть, роман һәм хәтта шигъри әсәрләр үзәгендә дә әнә шундый шәхесләр торды. Хәзерге заманда "без ул вакытта тегеләй яздык, болай яздык, тел яшереп советларга каршы булдык" дип сөйләнүләр—юк сүзләр. Барыбыз да бер кысада идек.

Мин үзем, шәхсән, социалистик реализм тарафдары булсам да, танырга мәҗбүрмен: бу ысулның җитди кимчелекләре бар. Әдәби әсәрләр иҗат иткәндә бу ысул, котылгысыз рәвештә, схемага, ясалмалылыкка китерә. Уңай геройны әдип никадәр тормышчан, тулы канлы итеп бирергә уйласа да, аның кайбер кыңгыр якларына күз йомарга, кайчак хәтта рухи фаҗигасен да читләтеп үтәргә мәҗбүр була. Әгәр инде кире геройны сурәтли икән, ана да симпатия белән карарга, әсәр ахырында аны, һичшикчез, акылына китерергә, дөрес юлга чыгарып бастырырга тиеш була. Бу бит инде әдипкә тормыш хакыйкатеннән читкә борылырга туры килә дигән сүз. Һәм ул заманның әдәбият чиновниклары тарафыннан шулай таләп тә ителә иде! Ә. Еники, С. Баттал, А. Гыйләжев, А. Расих кебек һәм тагын бүтән әдипләрнең тормыш хакыйкатенә ахырынача туры калырга ниятләп язылган әсәрләренең ул вакытларда нинди кискен гаепләүләргә дучар булганын барыбыз да хәтерли.

Социалистик реализмны гына өлге итеп кую кайчак көлкеле, буталчык хәлләргә дә китерде. Хәтерлисездер, русларның бөек язучысы А. Чеховның "Крыжовник" дигән кыска гына хикәясе бар. Фабула болай: бер алпавыт адәм үз бакчасында крыжовник үстерә. Бу эшкә ихлас күңеленнән бирелеп, бик һәйбәт итеп. Шуның белән үзенә кунакка килгән туганын сыйлый. Моның белән бик горурлана, мактана. "Үзем үстергән җимеш, үзем үстергән, үз бакчамда!" дип кабатлый, хозурлана. Безгә бу хәлне мәктәптә, социалистик реализм сагында уяу торучы укытучылар болай дип аңлаттылар: әдип монда шәхси милекчелекне күрәлмый, аннан ачы итеп көлә, дип. Ай-һай, алай булды микән? Китереп тагылган ярлык кына түгел микән бу? Әдип кемнең дә булса үз куллары белән куак утыртып, җимеш үстереп алуыннан, шуның өчен куануыннан, горурлануыннан нәрсәгә дип көләр икән? Теләсә нинди җәмгыятьтә дә бер дә гаепкә алырдай гамәл түгел бит инде бу. Юктыр, бөек язучы монда абыйсыннан көлмәгәндер, ә бәлки аны яклагандыр. Укытучыларның хакыйкатьне бозып күрсәтүе булгандыр бу.

Һәм дә... шушындый җитди кимчелекләре булуга да карамастан, мин үзем, шәхсән, һаман да социалистик реализм тарафдары булып калам. Татарның гади генә бер язучысы, әдәбият солдаты буларак. Хәзер, Ходайга шөкер, сүз иреге, хөррият. Теләсә нинди ысул белән иҗат итәргә мөмкинчелек туды. Моңа каршы икән бу агай, дип уйламагыз тагын. Сүз иреге—барча иҗатчылар өчен гаять зур бәхет! Ләкин мин, башка ысуллар белән бергә, хәзер дә социалистик реализм яшәргә хаклы дип саныйм. Әдәбият тормыш ваклыкларына гына кереп батмаска, аның әшәкелекләрен, имансызлыкларын тасвирлау белән генә мавыкмаска, ә укучыны яктылыкка, яхшылыкка өндәргә тиеш, укучыда югары гражданлык хисләре тәрбияләргә тиеш! Хәтта әдәбият һәм сәнгатьнең төп мәсләге шул дип исәплим мин. Кем белә, бәлки ялгышамдыр. Бүтән фикерләр дә әйтелер. Шуның өчен игълан ителгән бәхәс тә бит инде.

Сорауларга җавап эзләгәндә тагын шунысын искәртик: моннан егерме еллар элек, совет чорында, җәмгыятьнең составы шактый ярлы, бертөрле иде. Эшче, колхозчы, интеллигенция, хезмәткәрләр. Тормыш та бер калыпта, бер юнәлештә, максат та бер һәм ачык—бергәләп коммунизм төзибез. Әлбәттә, бу максат әдипләр алдында да тора. Алар иҗат иткән, алар тудырган типлар да бертөрлерәк, алар да бер якка атлый.

Һәм... менә! Дөбердәп күкләр күкрәп, яшеннәр яшьнәп тә тормады, нининдер тын, астыртын зилзилә булды. Җәмгыятьнең билен буып, аякларын тышаулап торган богаулар шартлап өзелде. Без мәңгелек дип иман китергән җәмгыять пирамидасы гөрселдәп ишелеп тә төште. Һәм китте шуннан хәлләр! Таркалулар, буталулар, төрләнүләр. Ни булса ул булды, әмма халыкларга иң кирәклесе—ирек килде. Сүз уңаенда, әдип халкына сүз иреге генә түгел, ә бөтен ил халкына хәрәкәт, шөгыль,

вөждан иреге. Уйлап кына карагыз: адәмнәргә шәхси милек туплау, шәхси баю рөхсәт ителде. Полный ходка, бернинди чикләүләрне белмичә! Әле моннан күп булса унбиш ел элек бу гамәл өчен хөкем итәләр иде. Бу юлны тоткан байтаклар хәтта бик һәйбәтләп өтермәнгә кереп утырдылар. Бервакыт мин үзем, район газетасы редакциясендә эшләгәндә, бер мәкаләдә "сәүдәгәр" сүзен яздым. Хәзер әйтергә көлке, шул сүз өчен үземне райкомга чакыртып алдылар, тиргәделәр, кисәттеләр. Шул бәхетсез сүз, минем исемне иясртеп, Казан каласына барып җитте. Ышанмыйча тормагыз, булган хәл бу!

Хәзер кулланууга кергән "Яңа гасырда—яңа адымнар!" дигән гыйбарә бик дөрес ул һәм җәмгыятьнең халәтенә дә туры килә. Соңгы елларда безнең җәмгыять гаять зур үзгәрешләр кичерде, бөтенләй дә икенчегә әйләнде. Кешеләр үзләре теләгәнчә, сәләт һәм мөмкинлекләреннән чыгып кәсепләнергә керештеләр. Алыпсатарларның бөтен бер армиясе, сыйныфы үсеп чыкты. Араларында, безнең Арча бистәсе чикләрендә генә дә, чын мәгънәсендә баеп киткәннәре, әллә ничә кибет ачып, зур йортлар салдырганнары бар. Хәтта җәмәгатьчелек биналары төзеткәннәре! Элеккеге хезмәткәр, интеллигент вәкилләре арасыннан сәүдә эшенә бирелгәннәре җитәрлек. Файдасын табалар, күрәсең. Үземнән байтак яшь элеккеге бер хезмәттәшем сәүдәгә бирелде, шәхси кибет тота. Бервакыт мин аннан уены-чыны белән "син—капиталистмы хәзер?" дип сорадым. "Әйе, мин—капиталист!" дип җавап бирде ул, бернинди уенсыз, горурлык белән әйтте. Кайбер сәүдәгәрләр, районнан читтә яшәгәннәре дә, авылларда мәчетләр, җәмәгать биналары салуда, чишмәләрне төзекләндерүдә ярдәм итәләр.

Сорау туа: мондый югары гражданлык хисенә ия сәүдәгәрләр арасында әдәби әсәр герое булырлык типлар юк микән? Ә ни эшләп табылмасын ди!

Авыл зур үзгәрешләр кичерә. Хәзер колхозлар, күмәк хуҗалыклар бетүгә йөз тота дисән дә ялгыш булмас. Әмма ләкин куркасы юк. Авыл халкы, асылда, күмәкләп эшләүдән баш тартмый. Күмәк хуҗалыклар күмәк җәмгыятьләргә, авыл хуҗалыгы предприятиеләренә әйләнә. Кайберләре кодрәтле фирмалар, компанияләр ярдәме белән. Әйтик, минем туган авылым Дусымда да күмәк хуҗалык түгел инде. Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять. Җире болай да бик аз бу хуҗалыкның соңгы елларда хәле мөшкелләнгән иде һәм "Татнефтепродукт" холдинг-компаниясе аны үз канаты астына алды. Хәлләр шунда ук яхшы якка үзгәрде, авылдашлар хәзер эш хакын даими, вакытында ала, авылда зур төзелешләр бара.

Хәзер авыл җирендә монарчы без матбугаттан укып, чит илләрдә барлыгын гына белгән яңа төр хезмәт ияләре—фермерлар үсеп чыкты. Тәвәккәллек итеп үз башларына җир кисеп алучылар, анда иген үстерүчеләр, димәк, җир биләүчеләр. Мина таныш журналистларның сөйләүләренә караганда, кайберләренең эшләре уңышлы бара, алар арасында кызыклы, үзенчәлекле фикер иясе, көчле шәхесләр бар. Минемчә, авыл, нәкъ электәге кебек, әдәби геройлар бирергә җирлек булып кала. Авыл халкы арасында да әдәби әсәрләр герое дәрәҗәсенә күтәреп куярлык шәхесләр җитәрлек. Шул ук фермерларга әлеге әдипләрнең генә түгел, журналистлар каләме дә кагылмаган диярлә була. Алар каләм осталары игътибарыннан читтә әле.

Җәмгыятебездә без электә юньләп белмәгән тагын бер, юка гына булса да яңа катлам—дин әһелләре, дингә хезмәт итүчеләр катламы барлыкка килде. Мин үзем динле адәм түгелмен, әмма танырга мәҗбүрмен: аларның гамәлләре, вәгазьләре, гомумән дин, халыкка зур йогынты ясый. Чөнки алар изгелеккә, һәрьяктан тыйнаклыкка, яхшыга өнди. Төбендә бит алар да халыкка хезмәт итәләр. Араларында бик кызыклылары, хәтта әле кайчан гына җиң сызганып коммунизм идеяларына хезмәт иткәннәре дә бар. Һәм аларны да, кайберәүләр эшләгәнчә, кискен гаеп итү, уптым илаһи тиргәү кирәкмәс. Киресенчә, аларны өйрәнү, белү зарур. Кеше рухы, кеше психологиясе нинди үзгәрешләр кичерә, нинди текә борылышлар ясый ала? Чынлап та, әдәбиятта бик кызыклы, яңа тема булыр иде бу.

Әлбәттә, халык арасында хөрриятттән, бирелгән ирекләрдән явыз максатларда файдаланучылар, төрле җинаятьчеләр дә җитәрлек. Язмышы шундый булудан яисә үз гаебе белән дә җәмгыятьтә тоткан урынын югалткан, түбәнгә тәгәрәгән, тормышның иң төбенә төшеп җиткән адәмнәр дә бар. Никадәр әйтәсе килмәсә дә, болар да җәмгыятебез әгъзалары һәм тормыш барышына йогынты ясыйлар. Мин үзем, әдип буларак, җинаятьче катламны әдәби әсәрләр битләренә күтәреп куюны якламас идем. Ләкин бит күп кенә әдипләр үзгә фикердә тора. Җинаятьчел типларны үзәккә куеп алар әсәрләр иҗат итә. Һәм уңышлы гына әсәрләр туа. Димәк ки, алар да хаклыдыр.

Жыеп кына әйткәндә, хәзерге көн каләм иясенең мөмкинлекләре гаять иркен. Совет чоры белән чагыштырмас дәрәҗәдә. Күңеленә хуш килгән теләсә кайсы шәхесләр, вакыйгаларга таянып әдәби әсәр иҗат итәргә була. Тик ул шәхесләр һәм аларның кылган гамәлләре китап укучыларның игътибарын җәлеп итәрлек кенә булсын.

Әмма илдә үзгәртеп корулар башлангач, зур итеп сүз ирекә бирелгәч, безнең әдип халкы шактый ук аптырап, хәтта югалып калды. Әнекәем, хәзер ничек язарга да, халык арасыннан нинди типларны сайлап алырга? Кыен мәсьәлә бу. Әле генә барысы да ап-ачык иде, ничек язасын әйтеп торалар, ә геройларны инде бармак белән төртеп диярлек күрсәтәләр иде. Һәм без, әдипләр, шуңа күнегеп тә беткән идек. Чынлап та, күрсәтеп торганда эшләве җиңел бит ул. Ә монда... барысы да үз башыңа, үзбуйлы хәл итәргә.

Алай да әдип халкы җаен тапты. Күпчелек каләм ияләре, хәтта ки барысы да диярлек, үткән заманны тасвирлый башлады, гүяки, әле генә җимерелеп төшкән җәмгыятьтә яшәвен дәвам итте. Ул дәвернең, чыннан да, югары күтәреп күрсәтергә лаеклы, кызыклы типларыннан, гади хезмәт кешеләреннән геройлар туды, коммунистларның икейөзлеләре хаклы рәвештә тиргәлде. Бу уңайдан Фоат Садриевның соңгы елларда иҗат ителгән һәм укучылар тарафыннан хаклы рәвештә югары бәя алган әсәрләрен күрсәтү генә дә җитә. Шушы юнәлештә бик күп роман, повесть, хикәя, поэмалар иҗат ителде. Жыеп кына әйткәндә, үткәндәге җәмгыять тормышына тулы һәм хәзер инде объектив анализ ясалды. Бер усал тәнкыйтьче хәтта "бездә бүгенге көн татар әдәбияты юк, ул үткәннәрне хәтерләүдән генә тора" дигән фикерне әйтте.

Ә, беләсезме, монда бер дә гаепкә алырдай нәрсә юк. Әдәбият ул, хәтта бөтендөнья күләм әдәбият, гомумән, башлыча үткәннәрне хәтерләүгә, аларны анализлауга, бәя бирүгә нигезләнгән. Искә төшерик Л. Толстойның "Сугыш һәм солых"ын, бүтән дөнья даһиларының мәшһүр әсәрләрен. Адәм баласы бүгенгене аңлап, белеп, аңа бәя биреп тә бетерә алмый бит. Бигрәк тә җәмгыять зур тетрәнүләр, үзгәрешләр кичергән бер дәвердә. Үткәннәргә нигезләнеп иҗат итү барча дәверләр әдәбиятына хас һәм табигый күренеш булды һәм шулай булып калыр да.

Тик бу безнең татар әдипләре заманадан тәмам артта калды, дигән сүз түгел әле. Татар әдәбиятында да нәкъ бүгенге көнне яктырткан, бүгенге геройларны кычкыртып тотып алган әсәрләр пәйда булды. Сез Т. Галиуллин, Ф. Латыйфи, Р. Мөхәммәдиев, К. Кәримов, З. Хәсникяр, Г. Гомәров, Н. Гыйматдинова, Л. Шагыйрьҗан, М. Маликова, Г. Галиева әсәрләрен генә алыгыз. Хөррияттән файдаланып әллә никадәр фантастик һәм хыялый, хәтта ниндидер серле, укыганда куркыта торган әсәрләр дә туды. Г. Гыйльмановның "Албастылар"ы үзе генә дә ни тора! Аллага шөкер, бу яктан да кысыр түгел безнең әдәбият, бүгенге көн геройлары туып кына торалар. Һәм яхшылары, һәм яманнары. Уңай яки кире дигән сүзем.

Әлбәттә, һәм аны ник яшереп торырга: яңа язылган барча әсәрләрне укып бару һәм аларга бәя бирү—мөмкин эш түгел. Алай да һәркем үзе яратып укыганнардан чыгып фикер йөртә ала. Мин үзем, укучы буларак, озак еллар буена Флүс Латыйфи иҗатын дикъкать белән күзәтеп киләм, ул язганнарны яратып укыйм. Иң әүвәле, ерак үткәнне хәтерләү булса да, "Хыянәт" романы үзенең аз һәм төгәл сүзле, вакыйгаларның мавыктыргыч һәм табигый булуы, гомумән, яңалыгы белән җәлеп иткән иде. Геройларының намуслы, әйткән сүзләренә тугрылыклы, ихлас күңелле булулары белән дә. Аннан соң килгән "Ишелеп төшкән бәхет", "Бәйсез этләрне атарга!" романнары. Дөрес, бу әсәрләрнең дә геройлары, башлыча, үткән заманда яшәгәннәр. Ләкин аларның гамәлләре һәм рухлары бүгенге көнгә килеп тоташа, алар бүгенге көн кешеләре, шулай кабул ителәләр. Алар һаман да, башлыча, үз мәсләкләренә тугрылыклы, намуслары чиста,көчле шәхесләр. Язучы үзе килешерме юкмы, белмим, әмма мин Ф. Латыйфи геройларын социалистик реализм геройлары дип саныйм. Һәм тагын Ринат Якушев белән хезмәттәшлектә иҗат ителгән "Тамга", "Соңгы кисәтү", "Игезәкләр" дигән фантастик повестьлар. Безнең татар әдәбиятында әле моңарчы күрелмәгән, гаҗәеп кызыклы әсәрләр! Аларда да ерак үткәннәр бүгенгегә китереп бәйләнә, хәзерге заманда яшәп торган адәмнәрнең үткәндә яшәп алган икенче тормышлары, хәтта кылган гамәлләре, кайчандыр ясалган бик үкенечле хаталары тасвирлана. Шайтан алгыры, туктагыз әле! Бик кызыклы икән бит әле. Үлдем дә беттем түгел икән, безнең бу дөньяда икенче гомеребез дә булуы мөмкин икән. Ошбу дөньяларда әле тагын, бәлки тагын да яшәп алуыбыз. Бу яклары белән дә кызыклы бу повестьлар.

Менә соңгы елларда күләмле проза әсәрләре иҗат итәргә кереп киткән һәм җилле

генә уңышларга да ирешкән Камил Кәримовның "Ак бүрек" повесте. Монда инде нәкъ бүгенге көн адәмнәре, мошенник, карак, алдакчы, тормышның төбенә төшеп киткәннәр, закон сагында була торып намуслы кешеләргә ышанмаучылар, заманга яраклашып үз намусына хилаф кылучылар тулып ята, мыжлап тора. Ни хәл итик: бүгенге көн, бүгенге җәмгыять! Тик, әсәрдәге төрле халык арасында нәкъ тормыштагы кебек, рухы белән нык булган, чын мәгънәсендә кеше булган шәхесләр дә житәрлек. Житмәсә, алар әсәрнең төп геройлары—Ансар белән Венера. Ансар, садә күңелле, изгелеккә омтылган яшь кенә егет, тирә-юньдәгеләрнең әшәкелеге, мәкере, хәзерге тормышның имансыз булуы аркасында зур зыяннар күрә. Життем дигәндә җимерелеп төшә, сөйгән ярыннан колак кага язып кала. Әмма намусына тап төшерми, заманга яраклашмый, мәслэгенә туры кала һәм... Ахырында барыбер җиңеп чыга, дөреслекнең өстә калуына ирешә. Ансар—Венераны гына түгел, китап укучыны да гашыйк итә торган егет. Ансар—әле һаман да социалистик реализм герое!

Нәбирә Гыйматдинованың "Аргы очта, бирге очта..." повестенең төп геройлары да әле яшь кенә булсалар да, укучыны сискәндереп җибәрерлек адәмнәр. Алардагы үзара күрәлмауга, хөсет һәм мәкергә исең китәрлек. Шайтан алгыры, нәкъ менә безнең татар кешесенә хас сыйфатлар! Борынгыдан ук килгән, халыкка күп зыяннарын китереп салган, ә бәлки дәүләтчелегебезне югалтуга да сәбәпче булган сыйфатлар. Юк, "җәнҗәл аларны үзе эзләп тапты. Бу дуртәүнең бәхетеннән күптән көнләшә иде ул..." дип, язучы бик дөрес әйтми. Җәнҗалны алар үзләре, әле ялгышып та түгел, ә аңлы рәвештә, белә торып чыгаралар. Аларның үзара дуслыклары ул бернинди дуслык булмаган, бәлки астыртын дошманлык, көнчелек булган. Бик көчле, хәтәр дошманлык. Ул әсәр башында ук гөрләп калкып чыга, безнең геройларга гомергә житәрлек үкенечләр, тирәнтен рухи яра, бетмәс-төкәнмәс кайгы-хәсрәт бүләк итә.

Нәбирә ханымның бу әсәренә карата укучылар тарафыннан тәнкыйть сүзләре дә булды. Ясалма хәлләр бу, болай язмаска кирәк иде, дигән юнәлештә. Минемчә, ясалмалылык, чыннан да, бераз булса да, язарга кирәк иде. Ник, белеп торыйк үзебезнең кем икәнлегебезне! Сүз уңаенда әйтик: бу геройлар, алып карасаң, әлләни гайре табигый да түгелләр. Арабызда мондый әшәке бәндәләр элек тә бар иде, хәзер дә бик житәрлек. Алланың биргәненә шөкер.

Әдәбиятка, күрәсең, язасы килгән әсәрләреннән тулгак тотып килеп кергән Гөлчәчәк ханым Галиева тагын менә "Өзелгән өмет" повестен язып бирде. Ай-яй! Бу әсәрнең геройлары "Тулгак"ныкыннан да җиллерәк, реалистик һәм тормышчан типлар. Тормышчан дип шуңа басым ясыйм, повестьта тасвирланган күренешләр дөньяда ифрат киң таралган. Җанашларым, сез яшәгән шәһәрләрдә генә түгел, ә бистәләрдә, хәтта инде кечкенә генә авылларда да мондый хәлләр, ир белән хатынның бер-берсенә тугрылыклы булмавы, сөяркәләр белән бәйләнеш тотулар бик тә житәрлек. Алай гына да түгел, бу хәл дөньякүләм киң таралган, дөньякүләм әдәбиятта да моңа киң урын бирелә. Тик менә совет хакимияте елларында безнең өчен тыелган, һәрхәлдә, тиргәлү китерә торган тема иде бу.

Гөлчәчәк ханым җәмгыятебездәге бу гөнаһлы гамәлнең югары даирәләр арасында иң киң таралганын тотып алган. Әсәр геройлары Касыйм ага белән Галия һәм Ахияры да бил бөгеп эшләгән гади кешеләр түгел, корсак киереп йөргән түрәләр. Тик алар барыбер—тормыштагы адәмнәр, бөтен яхшы-яман яклары белән яктыртылган, арабызда бүген йөргән кешеләр. Ни хәл итәсең, дөнья шундый инде ул. Һәркем шәхси бәхеткә, мөмкин кадәр күбрәк ләззәт, канәгатьләнү алуга, кәеф-сафага омтыла. Берни белән дә, беркемнең мәнфәгатьләре белән дә хисаплашып тормастан.

Китерелгән мисаллардан күренгәнчә һәм бәхәс соравына җавап итеп әйткәндә, безнең татар әдәбиятында бүгенге көн геройлары бар, аларның кылган гамәлләре, холыклары һәм көрәшләре дә шактый тулы ачыла. Әдәбият тулы канлы тормыш белән яши, дип әйтергә нигез бар. Бу—минем шәхси фикер. Бәхәс барышында тагын әллә никадәр кызыклы фикерләр әйтелер әле.

"Безнең иҗатчыларга заман героен ачуда нәрсәләр житеп бетми?" Бу сорауга, гомумән, җавап бар микән? Иҗатчыга "алай язма, болай яз!" дип вәгазь укып тору кирәкле әйбер микән? Әмма, алай да уртага бүгенге көн геройларын куеп язылган әсәрләрдә шундый берьяклылык шәйләнә—ул адәмнәрнең җәмгыятьтә тоткан урыннары, иҗтимагый тормышка мөнәсәбәтләре, шул юнәлештә гамәлләре дә күренми. Алар әсәр битләрендә, башлыча, үзләренең кара гамәлләрен ачып салу өчен генә яшиләр кебек. Моны өстә санап үтелгән һәр әсәрдә күрергә була.

Әдәбиятка яна геройлар, яна типлар кирәк! Югары гражданлык хисенә ия булган, укучыны җәлеп итәрлек, ана тормышында үрнәк булырлык геройлар.



Марсель Бакиров

# ИҢ БОРЫНГЫ ШИГЫРЬ НИНДИ БУЛГАН?

Марсель Бакиров—шигырь белгече профессор Хатип Госманның шәкерте, гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм аның иң борынгы формалары, жанрлары, алымнары турында җитди монографияләр тудырган галим. Шуның белән бергә, ул, беренчеләрдән булып, борынгы шигъриятебезнең тарихи поэтикасын, милли образлар системасын һәм сәнгатьчә сурәтләү эволюциясен дә өйрәнде. Өстәвенә, төрки-татар шигыренең ритмик-интонацион төзелеше, сан-иҗек (силлабика) һәм төрки гаруз системаслары, фольклор шигыре һәм аның төрләре хакында да хезмәтләр язды. Шигырь һәм борынгы поэзия белгеченең укучыларыбызга, әдәбиятчылар һәм язучылар игътибарына тәкъдим ителә торган бу яңа тикшеренүе иң элгәрге һәм архаик сүз сәнгатенең моңарчы аз билгеле булган төрләрен, шәкелләрен өйрәнүгә һәм ачыклауга багышланган.

Һәр фән өлкәсендә диярлек мөһим күзәтүләргә нигезләнгән, әмма күренешнен асылын тулысынча ачып бетерә алмаган карашлар була. Әгәр мондый карашлар күренекле галимнәр тарафыннан үткәрелсә һәм күпмедер дәрәҗәдә фактик материал белән дә ныгытылса, алар бердәнбер дөрес һәм күренешне тулысынча иңли торган концепция төсен ала. Мин шигырь теориясендә ныклап урнашкан, әмма яңа, өстәмә фактик материалларга таянып үзем ясаган нәтиҗәләр таләп иткәнчә, төзәтмә кертүне, тулыландыруны сораган шундый ике карашка тукталасым килә.

Сүз иң архаик шигырь төзелешенең табигате, шул исәптән борынгы төрки шигырь корылышының нинди формалардан үсеп китүе турындагы карашлар турында бара. Аларның беренчесе—XX йөзнең егерменче елларында төрки шигырь төзелешенең башлангыч һәм милли ритмик үзенчәлекләре турында кызыклы күзәтүләр белән чыккан поляк тюркологы Г. Ковальскийныкы. Үзенә кадәрге ориенталист Б. Фабоның күзәтүләрен[1] дәвам итеп һәм үстереп, ул "ике юллык—төрки поэзиянең иң борынгы формасы булган" дип белдерде һәм лирик шигърияткә хас дүртьюллыклар һәм эпик шигырьгә ("эпик шигырь" дигәндә вакыйгалеккә, хикәяләүгә нигезләнгән эпос-дастан тексты күздә тотыла) хас күпъюллык тезмәләр шул "ике юллык тәңгәллек"тән үсеш алганнар дигән караш үткәрде [2].

Шигырь белгече В. М. Жирмунский үзенең тикшеренүләрендә Ковальскийның "ике юллы строфа" төрен эпик шигырь төзелешенең дә сыйфаты һәм формасы итеп каравы белән килешмәвен әйтте һәм мондый нәтиҗәгә килде: "Изначальной структурной формой древнетюркского народного эпического стиха является не двучленная строфа, а то, что было мной названо эпической тирадой (или строфемой), т. е. цепочка стихов неопределенной длины, объединенная параллелизмом, (отсюда не обязательно двучленным, часто многочленным". "Такие цепочки стихов соответствуют вообще поступательному движению эпического рассказа у многих народов" [3]. "Тирада" безнең әдәбият белемендә һәм фольклористикада кулланыла торган "сарын" дигән төшенчәгә туры килә һәм шигъри эпос-дастаннардагы бер-беренә сарылып-үрелеп килүче тезмәләрдән төзелгән күпъюллык строфаны белдерә.

Хәзерге вакытта шигырь белгечләре, кайбер искәрмәләр ясау исәбенә, бу карашларның икесен дә таныйлар, ачыклап әйткәндә, ике юллык тезмә лирик җыр-шигырьнең иң элгәрге төзелеш төре булган дип, эпос-дастаннарның строфа корылышы исә ритмик-синтиксик тәңгәллеккә нигезләнүче күпъюллык архаик формадан үсеп чыккан дип исәплиләр.

Без поэзиянең борынгы төрләрен өйрәнү барышында Г. Ковальский белән В.Жирмунский ачыклаган шигырь формаларыннан да архаиграк, хәтта күпмедер

дәрәҗәдә аларның һәр икесе өчен дә өлге, иң беренче жирлек (архетип) хезмәтен үтәгән өченче форма да булган дигән фикергә килдек. Бу иң архаик шигырь төзелешенең нигезендә төрле борынгы язма ядкарьләрдә, шулай ук берничә буын сәяхәтче-этнографларның хезмәтләрендә теркәлгән берьюллык шигырь формасы ята. Ачыклап әйткәндә, җыр-шигырьнең башлангыч төре бер генә тотрыклы гыйбарәдән тора торган, әмма, һичшиксез, кат-кат такмаклар яки көйләп башкаруга исәп ителгән берьюллык поэтик-эмоциональ сөйләм рәвешендә була, һәм нәкъ менә бер үк тәртиптә кабатлануы аркасында мондый микротекст, ритмик куәт алып, үзенә бертөрле шигъри-музыкаль иҗат башлангычының формалашуына китерә.

Без бер үк гыйбарәне кабатлау юлы белән җыр-шигырь иҗат итү алымы һәр борынгы халыкның башлангыч чор поэзиясенә хас уртак пракануи булган дип исәплибез. Моннан тыш, әлеге иң архаик шигъри-музыкаль канун стадиаль яктан ярым кыргыйлык яки ыруглык чорында яшәгән һәм мәдәни үсеш ягыннан артта калган кабиләләрдә дә киң кулланылган. Узган гасырларда Европа сәяхәтчеләре һәм этнографлары тарафыннан Африкада, Төньяк Америкада, Океания утрауларында яшәүче төрле кабиләләр арасында язып алынган аерым иҗат үрнәкләре, безнеңчә, әнә шул турыда сөйли. Бауман исемле европа сәяхәтчесе, мәсәлән, Африканың көньягында яшәүче бубе исемле кабиләне өйрәнгәндә шундый бер хәлгә тап була: диңгез төбеннән энҗе-кабырчыклар эзләү белән шөгыльләнүче әлеге кабиләнең бер әгъзасы, яр буенда ял итеп утырганда, кинәт "Акула бубенын кулын тешли" дип җырлап җибәрә. Һәм, тукталмыйча, әлеге сүзләрне кызганыч тавыш белән ярым көйләп, ярым такмаклап үз телендә кабатлый башлый. Чумып диңгез төбеннән энҗе эзләүче бубе негрлары өчен акула, әлбәттә, хәтәр һәм фаҗигале хәлләр белән бәйле балык була. Шуңа күрә дә экспромт рәвештә туган һәм бер көйгә янгырый башлаган әлеге җырны башкалар да күтәреп алалар, һәм шунда ук ул аларның уртак халәтен чагылдыручы күмәк җырга әверелеп китә:

Акула бубенын кулын тешли.
Акула бубенын кулын тешли.
Акула бубенын кулын тешли[4].

Көйләп һәм кат-кат кабатлап башкарылучы бер юлдан торган җыр-шигырь үрнәкләре көньяк Африкада яшәүче бушмен кабиләләреннән аеруча күп язып алынган. Алар арасында ырым яки ярым дога рәвешендәгеләре дә, теге яки бу йолага бәйләп, яисә сунар вакытында башкарылганнары да, шулай ук гамәли-практик ихтыяҗ белән турыдан-туры бәйләнмәгәннәре дә бар. Мәсәлән, кояш чакырганда бушменнар тарафыннан күмәкләп башкарылган шигъри текст мондый:

The sun up there, up there[5].
*Кояш биектә, биектә.*

Ә монысы—бушмен сугышчыларының үз җәясенә атап һәм, әлбәттә, кабатлый-кабатлый көйләп башкарган җыры:

Әй син, каты агач, каты агач.
Әй син, каты агач, каты агач[6].

Бразилиянең тропик урманнарында яшәүче ботокуд исемле кабилә әгъзаларыннан язып алынган поэтик текст та бер юлдан, ягъни пракануи таләбенә туры китереп чыгарылган бер юллык "строфа"дан тора. Ботокудлылар аны, дошманнарын жиңгәч, үзләренең хәрби башлыкларына атап җырлый торган булганнар һәм шатлыкларын да шул бер гыйбарәне кат-кат тәкърарлау аша белдергәннәр:

Наш начальник не знает страха[7].
*Безнең башлыгыбыз курку белми.*

Иң кызыгы шул: партөрки бабаларыбыз иҗатына бәйләнешле борынгы материаллар арасында да бер гыйбарәдән—кабатланучы бер үк юлдан торган архаик шигъри-поэтик текст үрнәге сакланып калган икән. Борынгы кытай чыганакларында теркәлгән бер язмада мондый мәгълүмат бирелә: "По преданию, у Юсуна было две дочери. Обе сестры были очень красивы. Жили они в девятиярусной яшмовой башне. Однажды небесный правитель послал к ним ласточку. Ласточка пролетела над

ними, кружилась и кричала "и-и-и". Сестры поймали понравившуюся им птичку и посадили в нефритовый ларец. Через некоторые время они открыли ларец, заглянули, а ласточки и след простыл. Она улетела на север и больше не возвращалась. А в ларчике остались два яичка. Сестры занрустили и стали петь:

Ласточка, ласточка, улетела!
Ласточка, ласточка, улетела!

По преданию, это была самая ранняя северная песня"[8]. Шушы ук ярым легендар фактны чагылдыручы икенче бер язмада да соңгы җөмлә "Эта песня положила начало северным мелодиям"[9] дип тәмамлана.

Безнең эрага кадәр II йөздә Кытайның төньягында һәм көнбатышында яшәүче һуннар арасында булган һәм аларның күп җырларын, көйләрен язып алып кайткан атаклы сәяхәтче Чжан Цянь мәгълүматларына караганда, шулай ук кытайларның һун җырларын "төньяк җырлары" дип атап йөртүләрен исәпкә алганда[10], югарыдагы текстлардагы "северная песня", "северные мелодии" дигән гыйбарәләрнең һәм бер юллы җырның пратөрки бабаларыбызга караганлыгы, безнеңчә, шиксез. Янә шуны өстәргә кирәк: буй җиткән чибәр кызларны күккә—Тәңрегә багышлап манарада асрау традициясен без соңрак чор һуннарында, дөресрәге, уйгурларның борынгы бабалары булган гаогюйлар риваятендә дә очратабыз[11].

Аерым сәяхәтчеләрнең һәм этнографларның язмаларында берьюллык җыр-шигырьнең ритмик һәм музыкаль үзенчәлекләрен аңларга омтылу очраклары да юк түгел. XIX йөзнең икенче яртысында ике ел ярым Яңа Гвинея утравында яшәгән рус этнографы Миклуха Маклай, мәсәлән, җирле папуас җырларының гап-гади төзелешенә, кып-кыска текстка корылуларына һәм еш кына барабан тактына кушылып башкарыла торган үтә садә көйләренә игътибар итеп, мондый нәтиҗә ясаган: "Эти песни, которые поются соло или хором, состоят только из немногих слов, иногда даже одного слова, которое все время повторяется, причем мелодия мало варьирует"[12]. Бу кызыклы күзәтү музыка белгечләренең түбәндәге нәтиҗәсе белән туры килә: "Принцип остинантской повторности *(итальянча остинато—үҗәтле рәвештә бертуктаусыз кабатлау)* исторически был наиболее ранним способом организации музыкальной мысли"[13]. Архаик культуралардагы бу үзенчәлек, минем фикеремчә, тормыш күренешләренең һәм вакыйгаларның туктаусыз кабатланып, әйләнеп торучы цикл рәвешендә күзаллануы белән дә бәйләнгән булырга тиеш.

XX йөзнең 70 елларында Миклуха Маклай эзләре буйлап сәяхәттә булып кайткан фольклорчы Б. Путилов та папуаслар фольклорында сакланган кадими җыр-шигырь үрнәкләре белән кызыксына һәм, үзенә кадәрге атаклы тикшеренүченең күзәтүләрен дәвам итеп һәм яңа мәгълүматлар белән тулыландырып, болай яза: "**Одностиховые песни** вовсе не редкость в новогвинейском фольклоре. Тексты папуаских песен предельно элементарны: **одна много раз повторяющаяся фраза**. Однообразный мотив выполняет функцию законченной мелодической формы. Это—так называемые **однострочные** мотивы"[14] *(аерып язу безнеке.—М. Б.)*. Соңгы өзектәге "одностиховые песни", "однострочные мелодии" дигән гыйбарәләр яки төшенчәләр, безнеңчә, иң архаик җыр-шигырьнең табигатенә аеруча туры килеп тора. Чөнки аларның текстлары да, шулай ук башкарыла торган көйләре дә нәкъ менә кат-кат әйләнеп кайтуга, сүзмә-сүз яки аз гына үзгәртеп кабатлауга нигезләнүче бер юллы гыйбарәдән һәм бер юллы музыкаль фразадан төзелгән.

Гвинея папуасларының крахмал ярмасы ясаганда башкарган хезмәт җыры моңа мисал була ала:

| | |
|---|---|
| Bom, bom marare | *Саго, саго ясыйлар,* |
| Marare, tamole, | *Ясыйлар кешеләр,* |
| Mara, marare, | *Ясый, ясыйлар,* |
| Bom, bom marare, | *Саго, саго ясыйлар.* |
| Marare, marare | *Ясыйлар, ясыйлар,* |
| Bom, bom marare[15]. | *Саго, саго ясыйлар.* |

Шигырь теориясеннән чыгып әлеге күзәтүләрне үстерү юнәлешендә тагын шуларны әйтергә мөмкин: сүз бара торган шигъри-музыкаль праформада берьюллыклар һәм строфа, һәм рифма вазыйфаларын да үз өсләренә алганнар. Ник дигәндә, нәкъ менә кабатлану аркасында берьюллык "строфа" үзенең киресенә—антистрофага

әверелгән, шул ук юл белән ишәйгән тезмәләр исә охшаш яңгырашлы, ләкин һәркайсы аерымланып торучы "бер юллы строфа"лар исәбенә барлыкка килгән.

Янә бер әһәмиятле өстәмә: кабатлану исәбенә вертикаль юнәлештә ишәюче поэтик берьюллык эченә горизонталь юнәлештә үсү мөмкинлеге дә салынган булган. Бу очракта без җыр-шигырь юлының эмбриональ цезура ярдәмендә ике-өч өлешкә бүленүен яки иҗекләрнең якынча булса да тәртипкә салынуын күздә тотабыз. Австралия аборигеннарының җенси магиягә, ягъни ирлек куәте байлык, муллык китерә дип ышануга нигезләнгән эротик җыры, мәсәлән, кабатлау һәм антитеза алымы ярдәмендә өч буынга бүленә. Ачыклап әйткәндә, ир-атлар тарафыннан тирәсенә куаклар үскән чокырны әйләнә-әйләнә һәм сөңгеләр *(сөңге—ирлек куәте символы)* белән чәнчә-чәнчә төн буена башкарылган берьюллык җырның тексты түбәндәгечә:

Pulli nira, pulli nira, wataka[16]

*(Бу) чокыр түгел, чокыр түгел, (бу) vulva!*

Ә болары—борынгы төркиләрнең магик рухлы иҗатына һәм кабер ташъязма поэзиясенә караган шигъри текстлар. Аларның беренчесе, VII йөз ядкаре дип исәпләнгәне, Алма-Ата өлкәсенең Илий районы төбәгендәге каберлектән табылган бронза йөзеккә рун хәрефләре белән язылган.

Sök, saš[17].

*Чүк, куркак!*

Төрки сугышчы йөзегенә уелган әлеге берьюллыкның тылсым көченә ия дип каралганлыгы, тәэсир итеп, дошман якны буйсындырырга тиешле ырым рәвешендә кулланылганлыгы, безнеңчә, шиксез. Нибары ике сүздән генә торган гыйбарәнең ритмы да бик үзенчәлекле: һәр сүз бер үк зурлыкта-озынлыкта килә һәм бер үк аваздан башланып китә. Димәк, әлеге шигъри-магик гыйбарә кайтулы тәңгәл бәйләнешкә һәм төрки поэзиядә акрынлап үсеш алган аллитерация *(аллитерация—бер үк авазларның кабатлануы)* алымына корылган. Бер үк юл эчендә бер-берсен кабатлаучы һәм куәтләп килүче ике буын хасил булуын әнә шуның белән аңлатырга кирәк.

Хакасия җирендә борынгы Енисей кыргызлары *(дәүләтләренең яшәгән дәвере—VII-XIII йөзләр)* калдырган шигъри сөйләмле кабер ташъязма үрнәгендә дә аллитерация алымы ярылып ята. Ритмик буыннар үзара тигез булмаганлыктан, әлеге берьюллыкның ирекле леккә тартым ритмы һәр ике буын башында бер үк авазларның һәм һәр буын ахырында бер үк сүзләрнең кабатлануы исәбенә барлыкка килә.

Эрдәм болсар будуныг—эрк будуныг[18].

*Шанлы булган халык—батыр халык.*

Енисей кыргызларының Алтын күл төбәгендә куелган кабер ташы язмасында да (VIII йөз) аллитерация алымына корылган калыплашкан юл бар, ягъни ушбу текстта да төрле зурлыктагы ике ритмик буынны сүз башындагы бер үк авазлар бергә бәйли.

Alun šuņa juš kejiki, I artgyl, tog(g)ul

*Алтын Суна кош-корты, I ишәй, үрче*[19].

Түбәндәге мисал исә—күп төрки халыкларда уртак ышанулар җирлегенә барлыкка килгән борынгы йола иҗатыннан. Аерым алганда, әлеге магик шигъри юлны борынгылар язын җирләр кардан ачыла башлаган чорда, шул исәптән "Нәүрүз" бәйрәмендә ягылган учак аша кат-кат сикергән вакытта кабатлый торган булганнар.

Алас, Алас, I ар балээден I калас[20].

*Алас, Алас, I һәр бәладән I калдыр.*

Варианты:

Алас, Алас, I кули балодан I халяс[21].

*Алас, Алас, I бар бәладән I коткар.*

Монда инде сүзмә-сүз кабатлау һәм аллитерация алымнары гына кулланылып калынмаган, ә рифмалар да барлыкка килгән һәм ритмик-интонацион тәңгәллек, кайтулы бәйләнеш исәбенә шигырь юлы ике, хәтта өч буынга яки мәгънәви кисәкләргә (синтагмаларга) бүленгән. Белүебезчә, борынгыдан килүче һәм шулар өлгесендә ясалып торучы беръюллык мәкальләр дә еш кына шушы ук алымнарга нигезләнгән була. Ахыр килеп, хәтта ике юллы мәкальләр дә күбрәк бер юл эчендә тернәкләнгән мәгънәви-семантик яки ритмик-интонацион тәңгәллләрдән һәм антиподлардан үсеп чыга. Бу, димәк, халык поэзиясенең "күзәнәкләре" һәм афористик иҗат төре булган мәкальләр формалашуда беръюллык проформа шулай ук зур роль уйнаган дигән сүз. Моны XI йөздә яшәгән атаклы тюрколог Мәхмүд Кашгарыйның "Диване лөгатет төрк" сүзлегенә теркәлгән борынгы мәкаль үрнәкләреннән дә сиземләргә була.

Беръюллыклар:

Кош кылыч I кынка сыгмас.
*Куш кылыч I кынга сыймас.*

Коркмыш кишигә I кой башы I кош көрүнир.
Сув бермәскә (бирмәгәнгә) I сөт бер.

Алымчы арыслдан, I биримче сычган.
*Алачагы бар—арслан, I бирәчәге бар—тычкан.*

Ике юллыклар:

Бирин-бирин I миң болур,
Тама-тама I көл болур.

Алыплар бирлә I урушма,
Бегләр (бәкләр) бирлә I турушма (тартышма)[22].

Берьюллыкның һәм горизонталь, һәм вертикаль юнәлештә үсүенә юл ачкан һәм тотрыклы формула-калыплар эшләнүгә этәргеч биргән иң төп ысулларның янә берсе, иң характерлысы өчлек алымы булган. Бу алымның нигезендә бер үк юл эчендә бер үк сүзнең яки кып-кыска гыйбарәнең өч мәртәбә кабатлану күренеше ята. Әмма соңгы кабатлануында әлеге сүз, азмы-күпме үзгәреп яки өстәмә сүз белән бәйләнештә килеп, ритмик оппозиция дә тудыра. Өч тапкыр кабатлау, гомумән, борынгы сүз сәнгатенең аерылгысыз бер сыйфаты булып тора. Бигрәк тә ул магиягә һәм мифологиягә бәйләнешле күп текстларда тәртипләнеп, утырып житкән һәм хәтта иң борынгы рефрен формалары барлыкка китергән. Грузин фольклорында, мәсәлән, борынгы җырларның тотрыклы кушымта-рефрены рәвешендә сакланып калган шундый берьюллыклар бар. Мәгънәләре хәзерге вакытта онытылган ул сүзләрдә Алгы Азия мифологиясендәге аерым аллаларның исемнәре яңгырашы калгандыр дип уйлыйлар.

а) Цав-нана, цав-нана, нана-цав.
б) Вардо-нана, вардо-нана, нана-вардо.
в) Дели-дела, дели-дела, дала-дели.[23]

Мисаллардан күренүенчә, соңгы буында кабатланучы сүзләрнең инверсиясе, урыннарының алмашынып килүе ритмга тәмамлану төсмере бирә. Иң мөһиме, шушылай тәртипләнү аркасында ритмның эмоциональ-эстетик тәэсирлелеге дә бермә-бер арта, һәм менә ни өчен бу алым бүгенге поэзиядә дә яратып кулланыла.

Ә сине, ә сине, ә сине, туган як,
Бар микән сагынмый торган чак[24].

Не надо, не надо, не надо, друзья,
Гренада, Гренада, Гренада моя[25].

Борынгыларның мондый өчле кабатлауда магик көч күрүләренең бер мөһим сәбәбе дә, безнеңчә, менә шунда, эмоциональ тәэсир көченең буыннан-буынга арта баруында. Нәкъ менә гади кабатлау булмаганга күрә дә, ул, буын саен яна эстетик информация алып килеп, соңгысында иң югары ноктасына житә.

Димәк, архаик форманың, берьюллык эчендәге өчлекнең даими рефреннар тудыруда да роле зур булган икән. Ләкин әлеге форманың шигъри-ритмик вазыйфасы моның белән генә дә чикләнмәгән. Ул, безнең күзәтүләребезгә караганда, шигырь үлчәмнәренең һәм ритмик принципларның башлангыч өлгесе дә булган. Чөнки шул бер юлда, горизонталь өчлек эчендә, вертикаль юнәлештә үсеп китәчәк ритм дулкыны да тернәкләнгән һәм гәүдәләнгән. Аерым алганда, ритмик буыннарның һәм цезураларның беренче яралгылары да, иҗекләрнең-сүзләрнең кайсы сыйфаты белән ритм тудыруда катнашуы да башлап шунын эчендә ачылган һәм ритмик сурәтләре эшләнгән. Без моның шулай булганлыгына борынгы җырлар һәм утырып житкән соңрак чор эпослары мисалында да ышана алабыз. Менә карачайларда һәм әзәрбайҗаннарда сакланган магик характердагы борынгы хезмәт җырларыннан һәм казакъ эпосларыннан өзекләр.

Аскар, Аскар, Аскар тау,
Аскар таудың со бүркт.

Тогай, тогай, тогай су,
Тогай кондым өкінбен.

Долай, долай, дол гыбыт,
Сары майдан тол гыбыт[26].

Булгыр, Булгыр, Булгыр тау,
Булдырып турган кургыр тау.

Алаң да алаң, алаң журт,
Ах ала ордам конган журт[27].

Дутум, дутум, нәнәм дутум,
Сәни саган, дутум, дутум[28].

Югарыдагы мисаллардан өчлекнең 7-7 һәм 8-8 иҗекле силлабик үлчәмнәргә юл яруын һәм ритмга ачкыч ролен үтәвен күрү кыен түгел (текстларның калган өлешләрендә дә шул ук үлчәмнәр, нигездә, саклана). Билгеле, борынгы текстлар арасында иң беренче юлдагы өчлекнең озынлыгы (ягъни иҗекләр саны) белән аннан соңгы юлларның озынлыгы туры килмәгәннәре дә байтак. Алары инде башка характердагы ритмнар һәм башка үлчәмнәр өчен өлге булганнар.

Горизонталь яссылыктагы (аерым юлдагы) ритмның вертикаль юнәлешкә дә, ягъни башка юлларга да күчүе һәм дәвам итүе шигъри сөйләм эволюциясендә яңа һәм хәлиткеч баскыч булган, чөнки башлангыч үлчәм өлгеләренең ишәюе һәм строфа калыпларына үсеп әверелүе шушы баскычта башланган.

Шигырь—бердәй бердәмлекләрнең чиратлашуын гына түгел, ә капма-каршы башлангычларның, төрле антиподларның кабатлануын һәм үзара чәкешүен дә ярата торган сүз сәнгате. Архаик берьюллыклар һәм шуларга тәңгәл рәвештә туган күпьюллык шигъри текстлар арасында без шуларның да борынгы үрнәкләрен күрәбез. Мисырлыларның безнең эрага кадәр 800 нче елда папируска теркәлгән мифологик гимнында, мәсәлән, Кояш алласының *(Ра)* дошманнарыннан өстен чыгуы болай тасвирлана:

Силен Ра, слабы враги!
Высок Ра, низки враги!
Жив Ра, мертвы враги!
Велик Ра, малы враги!
Сыт Ра, голоден враги!

Напоен ра, жаждут враги!
Вознесся Ра, пали враги!
Благ Ра, мерзки враги!
Силен Ра, слабы враги!
Есть Ра, нет тебя, Апон[29].

Түбәндәге шигъри текст исә—шумерлар поэзиясеннән. Хикмәтле сүз, афоризм башлангычына охшаган бу текстта шактый кырыс һәм реаль оппозицион образгыйбарәләр аша ярлы кешенең мөшкел хәле сурәтләнә.

Бедняку лучше умереть, чем жить.
Если у него есть хлеб, то нет соли,
Если есть соль, то нет хлеба,
Если есть мясо, то нет ягненка,
Если есть ягненок, то нет мяса[30].

Ерак заманнардан ук килүче оппозиция алымына татарлардан да бер мисал китерик. Дүртөйле районының Шәехзадә Бабич туган Әсән авылында (Башкортстан) үзебез табып алып кайткан шәкерт дәфтәрендә шактый гына ырым текстлары бар. Борынгы магик фикерләү белән үрелгән бер бозым ырымы баштан алып ахырга кадәр ике кешенең арасын бозуга юнәлдерелгән капма-каршы янәшәлекләрдән тора.

Аю берлән бүре сәүешкәндә,
*(Бу фәләннәр)* шунда *(ягъни шул чакта)* сәүешсен.
Эт берлән мачы тату булганда,
*(Бу фәләннәр)* шунда тату булсын.
Адәм берлән шайтан сәүешкәндә,
*(Бу фәләннәр)* шунда сәүешсен.
Елан берлән бака тату булганда,
*(Бу фәләннәр)* шунда тату булсын.
Урман иясе берлән Шүрәле сәүешкәндә,
*(Бу фәләннәр)* шунда сәүешсен.
Мачы белән сычкан тату булганда,
*(Бу фәләннәр)* шунда тату булсын[31].

Мондый үрнәкләрнең чишмә башы, безнеңчә, беренче башлап борынгы фикерләү составында барлыкка килгән парлы оппозиция алымына, ягъни бинар *(латинча binarus—икеле)* системага корылган фикер сөрешенә барып тоташа. Тикшерүчеләр ачыклавынча, борынгылар мифларын һәм йолаларын да, табигатьтәге һәм тормыштагы төрле нәрсәләрне, күренешләрне дә бер-беренә капма-каршы торучы парларга берләштереп күзаллаганнар, ягъни тирә-яктагы бөтен нәрсәне "без"неке яки "алар"ныкына, "читләр"некенә, "ир-ат"ныкы яки "хатын-кызлар"ныкына, гадәтигә яки изгегә, яхшыга яки начарга һәм башка төрле антиподларга бүлеп аңлаганнар[32]. Хәтта бүленмәс бер бөтенне дә икегә аерганнар һәм, киресенчә, үзара берләшми торган нәрсәләрдән дә пар ясаганнар. Мәсәлән, бүре белән төркиләр үзара кардәш дип уйлау, кояш белән айны ир белән хатын итеп күз алдына китерү, елан токымын изгеләштерелгән бер башлы ләү-сазаганга һәм күп башлы дошман аждаһага аеру, бер-берләреннән кыз-кәләш алучы ике кабиләне бер дуаль *(латинча duo—икеле)* парга берләштерү һ. б.

Әмма матди һәм рухи дөньяны парлы оппозицияләрдә кабул итү логикасы акрынлап чынбарлыкка чыннан да хас булган бинар полюсларны, ягъни капма-каршы ике башлангычтан торучы күп санлы парлы объект-күренешләрне ачарга һәм ныграк танып белергә дә нык ярдәм иткән. Һәм нәкъ менә шуның җирлегендә телебездә төрле антонимнар *(капма-каршы мәгънәле сүзләр)* һәм объект-күренешләрне яки сыйфатларны парлы-парлы итеп төркемләү барлыкка килгән: уң—сул, күк—җир, яшәү—үлем, кыш—җәй, изге—явыз һ. б.

Табигый инде, халык иҗатында, эпик һәм лирик шигъряттә дә парлы оппозицияләрнең күп төрле үрнәкләре формалашкан. Шулай ук һәр культуралы халыкның язма классик поэзиясендә дә фольклордан килүче капма-каршы башлангычлар һәм шагыйрьләр үзләре ачкан яки башлап кулланышка керткән төрле оппозицияләр кулланылган. Һәм басым ясап әйтергә кирәк: мондый парлы антиподлар бүгенге поэзиянең дә егәрлеген, форма-стиль төрлелеген билгеләүче бер сыйфат булып кала һәм аерым шагыйрьләр тарафыннан шуңа нигезләнгән берьюллык шигырьләр дә, шулай ук ике, өч, дүрт юллы строфалар да иҗат ителә. Менә рус һәм татар шагыйрьләре Валерий Брюсов, Василий Субботин һәм Равил Фәйзуллиннан берьюллык парчалар.

О, закрой свои бледные ноги.

Окоп копаю, может быть—могилу.

Көнемнең таҗы—Син китергән төн.

Тынычлык ул—иң бөек илаһи музыка.

Шәфәкъләр алсу-алсу, дөньялар ямансу[34].

Әлеге мисаллар уңае белән шуны әйтергә кирәк: төрле халыкларның хәзерге заман поэзиясендә дә берьюллыкларның яшәве һәм үзенә бер строфа төре ("моностих") тәшкил итүе шигырь теориясендә кануни күренеш буларак таныла[35]. Көйләп яки ярым такмаклап кат-кат кабатлауга исәп ителмәгәнлектән, бүгенге берьюллыкларда мәгънәви һәм ритмик гармония, билгеле, аеруча нык сизелеп торырга тиеш. Шулай булмаган тәкъдирдә алар шигырь буларак кабул ителмиләр.

Гаҗәеп көчле яңгырашлы, көтелмәгән башлангычларны үзара чәкештерүе һәм диалектик бер бөтен тәшкил итүе белән күңелне әсәрләндерүче ике һәм дүртьюллыкларга да мисаллар китерик.

Сергей Есениннан:

Если крикнет рать святая:
"Кинь ты Русь, живи в раю!"
Я скажу: "Не надо рая,
Дайте родину мою".

Сердце остыло, и выцвели очи...
Синее счастье! Лунные ночи!

Габдулла Тукайдан:

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы,
Шунда тамсын күз яшенең иң ачы һәм татлысы!

Дәрдмәндтән:

Атам-анам йорты өчен
Булса мең җаным фида,
Туып-үскән җирем өчен
Соң тамчы каным фида.

Сагыйть Рәмиевтән:

Мине утка салган ул—син,
Мине суга салган да—син,
Утта янсам, суга батсам,
Тартып алган Аллам да—син.

Рәдиф Гаташтан:

Бергә мендек... Бу—Күк, Илаһ дөньясы!
...Мин янган таш, син—йолдызшаһ буласы.
Илтер сине яшьлегең чын тәхтенә,
Мин—картаеп, бу күктән куыласы.

Зөлфәттән:

Илне дөрләтерлек ялкын ята
Жил иркендә калган гомердә.
Илдә көчек булсаң да бик ярый,
Тик ил өчен кирәк өрергә!

Мин былбылдан сезне чактырырмын,
Тыңлатырмын елан сайравын.

Без алда кабатланучы берьюллык сөйләм лирик иҗатның гына түгел, ә эпик поэзиянең дә иң борынгы шигъри формасы булган дигән фикер әйттек. Болай дигәндә, без халык иҗатындагы вакыйгалеккә нигезләнгән эпик шигырьнең яки эпос-дастан жанрының тернәкләнү чоры турында сүз алып барабыз. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, халык эпосы ялралганда жанрның урта гасырлардагы классик төренә (мәсәлән, угызларның "Коркыт дәдәм китабы", кыргызларның "Манас", үзбәкләрнең "Алпамыш", каракалпакларның "Кырык кыз", татарларның "Идегәй" кебек дастаннарына) хас күпьюллык строфа төре *(тирада, сарын)* әле формалашмаган була. Шуңа күрә дә безнең көннәргә килеп җиткән борынгы эпик җыр-шигырьләр арасында мондый ирекле һәм күптезмәле строфаларга корылмаган архаик текстлар очравы бер дә гаҗәп түгел.

Менә XX йөз башында Г. Ландман исемле европа галиме яңа Гвинеядә яшәүче киваи кабиләсеннән язып алган һәм соңыннан Б. Путилов игътибар иткән мифологик эчтәлекле эпик җыр яки эпос ялралгысы. Ул нибары 16 юлдан тора һәм, җирле мифологик сюжетта тасвирланганча, папуаслар арасында иң беренче булып әҗәлне татыган культура герое Сидоның җир өстендәге тормышы (тулырак итеп әйткәндә, булачак хатыны Сагару белән ничек танышулары, катлаулы никах мөнәсәбәтләре һәм аның өчен көндәше Меури белән көрәшеп һәлак булуы) турында сүз бара. Ахыр килеп, Сагаруның ире җеназасы өстендә йола сыктавы башкаруы, теге дөнья белән тоташтыручы елга буенда хушлашып, мәңгелеккә аннан аерылуы бәян ителә. Героик эпос жанрына хас булган каһарманнарча никахлашу, кәләш өчен батырларча

алышу һәм көрәшеп корбан булу мотивларына нигезләнгән әлеге текстта вакыйгалар агышы җәенке һәм эзлекле сюжетка салып тасвирланмый, ә эчтәлекнең аерым өлешләрен өзек-өзек итеп гәүдәләндерүче һәм кайчакта кинаяле яки "ачкыч" сүзләр ярдәмендә генә хикәяләүче мөстәкыйль шигъри юллар аша бирелә. (Кат-кат тәрҗемә итү аркасында мәгънә төсмерләре бозылмасын өчен, эпосның текстын чыганактагыча русча тәрҗемәдә калдырабыз.)

1. Я иду на хорошие танцы в Яса.
2. Он тронул юбку девушки в Яса.
3. О куруа, лестница Сидо, она возвращается назад в Уцо.
4. Сагару приходит рассерженная, располагается в Яса.
5. В Яса Сагару, хорошая женщина, влезает на вершину набеа.
6. Сидо подходит к набеа и думает: "С какой стороны мне рубит его".
7. Сидо выкликает западный ветер: "Приди свалить набеа".
8. Ветер сваливает набеа и мою жену.
9. Сидо посылает птичку Сараре к Сагару.
10. Сагару отсылает птичку гимае: "Возвращайся на то место, откуда ты пришла".
11. Сидо бьется с лесным человеком Меури каменной дубинкой, но не убивает его.
12. "Мой дорогой супруг, все время он со мной, он преследовал меня все время, теперь он мертв".
13. Маленький попугай, положи мертвого в каноэ.
14. Сагару кладет Сидо в каноэ Сибири, везет его на другую сторону.
15. Слабый юго-восточный ветер несет Сидо.
16. Сидо кричит у водной ямы возле Боигу[36].

Героик характердагы эпос яралгысының әнә шулай аз санлы юлларга гына нигезләнүенең сәбәбе, барыннан да элек, архаик традиция һәм күнегелгән иң элгәрге эпик канун белән бәйле. Ачыклап әйткәндә, эпос үзәгендәге мифик геройлар һәм аның нигезенә салынган мифологик сюжет кабилә әгъзаларына, аны башкаручыларга, һичшиксез, таныш булган һәм асылда шулар контекстында анлап кабул ителгән. Әмма бу очракта безнең өчен иң кызыклысы—эпосның нәкъ менә нигездә берәр юлдан торучы һәм миф контекстында тулы мәгънә алучы микротекстларга бүленүе, димәк, иң архаик җыр-шигырь төзелешенә, дөресрәге—иң элгәрге строфа төренә нигезләнүе. Ландман язып алган әлеге эпик әсәрнең һәр юлы, башлап җырлаучы *(соло)* һәм бии-бии түгәрәк әйләнүче кабилә әгъзалары *(хор)* тарафыннан күп мәртәбәләр кабатлана-кабатлана, бер үк көйгә җырлап башкарылган. Шул рәвешле бер юл башкарылып туктагач, икенчесенә күчелгән, аннары—өченчесенә һәм калганнарына.

Димәк, мифологик эчтәлекле сюжетны өзек-өзек микротекстлар—кат-кат такрарлауга исәп ителгән мөстәкыйль берьюллыклар аша чагылдыру эпик поэзиянең иң борынгы героик төренә—архаик-мифологик эпос башлангычына да хас булган. Һәм бу табигый дә. Эпос белгече С. Ю. Неклюдов бик хаклы язганча, "Наиболее древние формы эпического повествования, как правило, отличались сравнительно небольшим обьемом и соответственно с небольшим событийно-временным охватом"[37].

Классик эпоста кулланылучы күп юллы тирада-сарын формасына килгәндә исә, бу шәкел, безнең карашыбызча, шигырь төзелеше һәм строфика эволюциясенең, шулай ук эпос үсешенең икенче, хронологик яктан соңрак баскычында барлыкка килгән булырга тиеш. Алда искәртеп үткәнчә, шигырь төзелешенең вертикаль юнәлештәге эволюциясе бер үк юлны сүзмә-сүз кабатлаудан акрынлап шул ук тезмә өлгесендә башка тәңгәл юллар тудыруга күчү рәвешендә, ягъни бер үк типтагы, ләкин һәркайсы яна, өстәмә мәгънә алып килүче тезмәләрне ишәйтү юнәлешендә барган.

Хотя ты уходил, да придешь ты!
Хотя ты спал, да проснешься ты!
Хотя ты умер, да оживешь ты!

Встань! Посмотри, что сделал тебе твой сын!
Проснись! Услышь, что сделал тебе Гор!

Он поразил для тебя поразившего тебя,
Он убил для тебя убившего тебя,
Он связал для тебя связавшего тебя.

Исиди тебя омывает,
Нефтида тебя очищает[38].

Образлы-синтаксик тәңгәллекнең бик борынгы классик үрнәге булган бу шигъри текст—"үлүче-терелүче" жир асты алласы Осириска *(Осирис—Йосыфның ерак прототибы)* багышланган мифологик эпостан бер өзек. Мисыр пирамидасының эчке стенасына язылган әлеге текст баштан алып ахырга кадәр төрле төзелешле һәм төрле эчтәлекле җөмләләрнең яки гыйбарәләрнең кат-кат кабатлануына нигезләнә. Ләкин һәр төр гыйбарәнең (юлның) тәңгәл ишләрендә җөмлә төзелеше һәм сүз тәртибе үзгәрмичә саклангалыктан һәм текстта гыйбарәләр төзелеше төрләнеп, алышынып торганлыктан, төрле ритмик вариантлар чиратлашуына корылган гаҗәеп үзенчәлекле образлы-синтаксик тәңгәллек барлыкка килә. Аерым алганда, эпос өзеге тәңгәл җөмләләрнең яки юлларның төренә, составына бәйле рәвештә дүрт ритмик төркемгә бүленеп тора.

Шушындый ук характердагы мисаллар шумерларның, һинд-ираннарның, алтай телләре семьялыгына керүче халыкларның борынгы эпик поэзиясендә дә шактый күп очрый. Бу инде, димәк, беренче булып В. М. Жирмунский тарафыннан ачыкланган эпоска хас күп буынлы, яки күп юллы параллелизм күренеше[39], безнең карашыбызча, алда без тикшергән архетип берьюллыктан үсеп чыккан дигән сүз. Ягъни башка юлларны беренче яки үзеннән алдагы юлга тәңгәл итеп китерү һәм бер-беренә сара-сара ишәйтү жирлегендә барлыкка килгән дигән сүз.

Табигый ки, төрки телләргә хас сүз тәртибе буенча, ерак бабаларыбызның синтаксик тәңгәллеккә корылган борынгы эпик һәм лиро-эпик текстларында фигыль-хәбәрләр күпчелек очракта җөмлә яки шигырь юллары ахырына туры килә. Бу алым хәтта, өлешчә булса да, кече күләмле аерым жанрларга да үтеп кергән. Менә Алтай төбәгендәге бер тауның кыя ташына рун хәрефләре *(төркиләрнең борынгы алфавиты)* белән язылган келәү-алгыш үрнәге. Анда беренче юл төзелешен кабатлаучы күпьюллыкларда кабилә тавының иясеннән тормышны житеш һәм мул итеп коруда ярдәм итүе сорала.

| | |
|---|---|
| Agin toli, tuq qil, | Барын житеш, тук кыл, |
| An (=aŋ) jagimi inč qil, | Җәнлекле ягымлы имин кыл, |
| Šiq(=šok) inaqi bar qil, | Зур дуслыкны бар кыл, |
| Ölö (=ала) küsagič šat qil, | Өмет-теләкләрне көткәнчә кыл, |
| Baj alip kej, al kej. | Куәтле kej, бөек kej[40]. |
| | ("Kej"—муллык мәгънәсендә). |

Сүз уңаенда синтаксик тәңгәллек жирлегендә формалашкан тагын бер кызыклы үзенчәлеккә тукталып китү сорала. Бу очракта без синтаксик яктан үзара тәңгәл юллар эчендә бер-берләренә саннары буенча да тәңгәл килүче сүз-буыннар барлыкка килүен күздә тотабыз. Мәкальләрдә бу күренеш ике яки күп дигәндә өч-дүрт юл эчендә генә гәүдәләнсә, алтай, хакас, тува һәм өлешчә казакъ, кыргыз кебек төрки халыкларның борынгы эпосларында—күп юлларны үзенә буйсындыручы киң таралган система. Ижекләр санын түгел, ә сүзләр санын саклауга нигезләнгән бу борынгы ритмик форма думбра чиртеп, яки сазда, лутняда уйнап шигырь әйтүче чичән-жыраулар өчен бик кулай алым булган һәм йөзләрчә юлларны импровизация юлы белән ижат итәргә, туктаусыз башкарырга мөмкинлек биргән. Шуның белән бергә әлеге алым, текстның эчтәлегенә, образ-күренешнең хәрәкәтенә карап, юллардагы сүз-буыннар санының вакыт-вакыт икенче саннар белән алмашынуына, үзенчәлекле аралаш форма тууына да юл куйган. Менә казакъ жыраулары ижатыннан бер мисал (жәя эчендә юллардагы сүзләр саны күрсәтелә):

Агасы бардын, жаксы болса жагасы бар, (6)
Жаман болса, інісіне жабар жаласы бар, (6)
Інісі бардын, жаксы болса тынысы бар. (6)

Жаман болса, агасына берер жумысы бар, (6)
Баласы бардын, жаксы болса панасы бар, (6)
Жаман болса, Кудайдын перген пелеси бар[41]. (6)

Күренүенчә, текстта сүзләр саны бар юлда да бертигез. Кыргызларның "Манас" эпос-дастаныннан алынган түбәндәге өзекләрдә исә сүзләр саны төрле вариацияләрдә килгән, һәм бу катнаш "үлчәм" тудырырга, шул юл белән бер ритмнан икенчесенә күчәргә мөмкинлек биргән.

Алтайга Манас жеткенде, (3)
Айдыны көпке кеткенде, (3)
Кыйры менеп чынданып, (3)
Кыргыз бүткен жыйналып, (3)
Улын жыйын топ булду, (4)
Укса камбас кеп булду, (4)
Кеп Манаска токтолду (3)

Яки:

Бәри кәлкил. (2)
Башым бакты! (2)
Евим тахты! (2)
Хан бабамын кәјкүси! (3)
Гадын анамын севкиси! (3)
Атам, анам вердији, (3)
Көз ачыбан көрдүјүм, (3)
Көнүл вериб көрдүјүм, (3)
Көнүл вериб севдіјүм, (3)
Дирсә хан![42] (2)

Кытайларның безнең эрага кадәр тотем хайваннарына багышлап иҗат ителгән "Сынар мөгез" дигән түбәндәге келәү алгышы да бер типтагы җөмләләрне кабатлауга корылган. Әмма бу юлы билгеле бер аралыкта кабатланучы риторик эндәшләр һәм бераз гына үзгәреп, билгеле бер тәртиптә килүче рефрен тезмәләр өч юллы строфалар тууына китергәннәр.

Единорог! Своим копытом
Ты наших сыновей сохрани!
О ты, Единорог!

Единорог! Своим челом
Семью ты нашу сохрани!
О ты, Единорог!

Единорог! Своим рогом
Ты наш род сохрани!
О ты, Единорог![43]

Америка индеецлары науаларның җирле аллалар анасына—Тетео-иннанга багышланган түбәндәге гимнында да билгеле бер тәртиптәге кабатлаулар өчәр юллы строфалар барлыкка китергән. Текстларның эчке төзелешендә һәм эчтәлегендә күпмедер аермалар булуга карамастан, "Сыңар мөгез" келәвендәге һәм әлеге гимндагы һәр ике төр строфа да асылда архаик характерда, ягъни бер һәм ике юллыктан үсеп чыккан тәңгәлләр, бер типтагы кабатлаулар җимеше булып торалар.

Ах, желтый цветок раскрыл лепестки,
То наша мать, лицо спрятав под маской,
Из Тамоанчана в край наш пришла.

Ах, белый цветок раскрыл лепестки.
То наша мать, лицо спрятав под маской,
Из Тамоанчана в край наш пришла[44].

Аерым халыклар иҗатында катлаулы бәйләнешкә корылган өчьюллык строфа калыплары акрынлап активлашып, нормалашып киткәннәр һәм классик поэзиягә дә үтеп кергәннәр. Моның төрле характердагы күпсанлы үрнәкләрен без кытайларның иң борынгы лирика энциклопедиясе-тупланмасы саналган "Шицзин"да да, шулай ук японнарның язма шигъриятендә дә очратабыз. Катаута *(5-7-7 иҗекле үлчәм)* һәм хокку *(5-7-5 иҗекле үлчәм)* дип атала торган япон шигъри шәкелформалары, мәсәлән, әнә шундыйлардан. Янә килеп, борынгы традициягә нигезләнүче өчьюллык строфа төрләре теге яки бу дәрәҗәдә төрки халыкларда,

шул исәптән татар сүз сәнгатендә дә урын алган. Түбәндәге мәкальләр һәм һәр юлы ике мисрагтан, ягъни ике ярты юллыктан торучы мөнәҗәтләр моңа ышандыргыч дәлил була ала.

Эт өреп картая,
Егет йөреп картая,
Кыз көлеп картая.

Кызыл төлке—җир күрке,
Матур егет—ил күрке,
Матур кызлар—өй күрке.

Алла сине бар итте, үзенә һәм яр итте,
Рәсүлләргә таҗ итте, йә Мөхәммәд Мостафа!
Саллалаһе галәйкә, йә Мөхәммәд Мостафа!
("Йә Мөхәммәд Мостафа").

Исрафил сурын өргән, йә Хәбибем, тор, дигәй.
Лә Иляһи, тормаймын өммәтләрем тормыйча,
Гөнаһлы өммәтләрем "ярлыкагыл" димичә.
("Исрафил сурын өргәй").

Өчьюллыкка корылган шигырь текстларын язма поэзиябездән дә күпләп китереп булыр иде. Шагыйрьләрдән Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Шамиль Анак халык иҗаты традицияләрен дәвам итеп һәм үстереп, әлеге тип строфаның төрле вариантларын тудырдылар, шул исәптән ак шигырь шәкелендәге рифмасыз үрнәкләрен дә иҗат иттеләр. Шул ук вакытта әлеге шагыйрьләр иҗатында беренче башлап эпос-дастан шигырендә, йола фольклорында һәм магик поэзиядә *(ырымнарда)* формалашкан катнаш үлчәмле шигырь үрнәкләре дә барлыкка килде.

Берьюллыкны кат-кат сүзмә-сүз кабатлау алымыннан кабатланмый торган текстлар иҗат итүгә кучүнең иң архаик бер ысулы ике юллык строфа төрен үзләштерү белән бәйләнгән. Монысы инде, алда әйтелгәнчә, строфаларга бүленешне яратучы лирик поэзиядә, шулай ук иң кечкенә һәм афористик жанр үрнәге булган мәкальләрдә тернәкләнгән. Берьюллыктан ике юлга күчү төрлечә гамәлгә ашырылган. Мәсәлән, шуның бер ысулы ике ритмик буынлы яки ике ярым *(ярты)* юллы *(гарәп-фарсы термины белән әйткәндә, ике мисраглы)* тезмәне цезура үтә торган жирдән ике юлга бүлүгә корылса, икенчесе—кабатлана торган юлга катализатор вазыйфасын, ягъни төрләндерү-үзгәртү ролен үтәүче өстәмә сүзләр кертеп жибәрү рәвешендә булган. Бу исә сүзмә-сүз кабатлаудан качарга, яңа төр кабатлаулар һәм яңа мәгънәви-ритмик вариацияләр тудырырга мөмкинлек биргән. Шул юл белән әлеге алым бер үк төрле кабатлау инерциясен җиңәргә һәм ритмик тәңгәллеккә, мәгънә үзгәрешенә корылган ике юллыклар иҗат итәргә юл ачкан. Мисал өчен дүрт мең ел чамасы элек шумерлар иҗат иткән иң борынгы мәхәббәт лирикасы үрнәгенә мөрәҗәгать итик. Жирле ышану һәм йола буенча шумер патшасы ел уңдырышлы килсен өчен ел да бер кызга өйләнергә тиеш булган. Әлеге жыр-гимн менә шул "изге никах" вакытында башкарылган.

**Супруг**, дорогой моему сердцу,
Велика твоя красота, сладостная, точно мед.
**Лев**, дорогой, моему сердцу,
Велика твоя красота, сладостная, точно мед[47].

Ә монысы—Тын океандагы Мариан утрауларында ыруглык тормышы белән яшәүче кабиләдән язып алынган жыр. Аны хатын-кызлар күмәк рәвештә яр буенда башкарганнар. Кабат-кабат жырлаганда тексттагы сан курсәткече генә *("алты", "жиде" һ. б.)* үзгәреп, алышынып торган.

**Эзылог** о но лого диллдину.
**Оалог** о но лого диллдину[48].

*Дингездә алты мәртәбә чумыла,*
*Дингездә алты мәртәбә өскә чыгыла.*

Борынгы уйгурлар иҗатыннан да бер-ике мисал китерик. Таң алласына багышланган гимн, мәсәлән, мондый юл белән башлана һәм икенче юлда баштагы гыйбарәгә бер сүз өстәлә:

Taң tenri kelti,
Taң tenri özi kelti.

Taң tenri kelti,
Taң tenri **özi** kelti[49].

Шигъри сөйләмгә корылган юрау китабының (VIII йөз) түбәндәге юлларында төрләндерүче, өстәмә информация алып килүче сүзләр саны инде күбрәк. Шул ук вакытта, беренче юлдагы кебек үк, әлеге алмаш, катализатор сүзләр эчке, горизонталь аллитерация таләбен дә саклаганнар (чагыштырыгыз: б-б, к-к).

| | |
|---|---|
| Buz bulut jorudu **budun** üzə jagdu, | *Соры болыт гизде, халык өстенә яуды,* |
| Qara bulut jorudu **qamug** üzə jagdu[50]. | *Кара болыт гизде, бөтен җир өстенә яуды.* |

Тагын бер җитди искәрмә: тикшереп үтелгән мисалларда алда сүз барган парлы оппозиция, контрастлык алымы да якыннан торып катнашкан. Ачыклап әйткәндә, әлеге алым аерым объект-күренешләрне яки гамәлләрне капма-каршы куюю рәвешендә дә, шулай ук тәңгәл образларны яңа сыйфатлар өстәп баету, градацияләп үстерү төсендә дә гәүдәләнгән. Мондый шәкелләрне үзләштерүгә, һичшиксез, мәкальләрнең хөкем-фикерләү төзелеше дә ярдәм иткән, һәм хикмәтле сүз сәнгате белән шигърият асылда үзара "кан алмашып", бер-берсенең казанышларыннан файдаланып үскәннәр. Нәтиҗәдә, кабатлаулардан башланган һәм яңа үзенчәлекләр белән баеган ике юллыкларның бик күп төрләре барлыкка килгән.

Хәзерге поэзиядә актив кулланыла торган дүртьюллыкларның "кендеге" дә, миңа калса, ике юллыкларга гына түгел, ә шуларга җирлек булган берьюллыкларга да барып тоташа. Дүртьюллыклар туунын бер борынгы чыганагы яки ысулы—берьюллык өлгесендә тәңгәл юллар санын ишәйтү. Моның бик күптәнге яки архаизм рәвешендә дәвам иткән үрнәкләрен төрле халыкларда очратырга була. Менә Шу-Син исемле шумер патшасының әнисе Абисимтига багышланган гимннан бер строфа.

**Она** дала жизнь тому, кто чист.
**Это мать** дала жизнь тому, что чист.
**Абисимти** дала жизнь тому, кто чист.
**Царица** дала жизнь тому, кто чист[51].

Ә монысы—безнең эрага кадәр ике меңенче еллар уртасында һинд-иран (ария) кабиләләре арасында иҗат ителә башлаган "Ригведа" җыентыгындагы гимннан. Аны патшаны беренче башлап тәхеткә утыртканда башкара торган булганнар.

| | |
|---|---|
| dhruvá dyaúr dhruva prthivi | Твердо небо, тверда **земля**, |
| dhruvásah párvata imé | Тверды **горы эти**, |
| dhruvám visvam idám jadad | Тверд **весь этот мир**, |
| druvó rája visám ajam | Тверд **этот царь племен**[52]. |

Әлеге дүртъюллыкларның икесендә дә кабатланучы тезмәләр үсә баручы градация барлыкка китергәннәр, ягъни һәр юл үзеннән алдагы юлдан, борынгылар карашынча, куәтлерәк информация алып килүгә исәп ителгән һәм иң югары нокта йомгаклап куючы соңгы юлга туры килгән. Шушы ук архаик алымга корылган дүртьюллыкларны без төрки халыклар иҗатында да очратабыз. Түбәндәге караим җыры шуның бер дәлиле була ала.

Лапа-лап кар йава,
Эрби баба кой сойа,
Хазар оглу ат чаба,
Байларымыз той чала *(үткәрә)*[53].

Ләкин дүрт юлда да бер типтагы җөмләләр яки гыйбарәләр кабатлануы бер тонлы ритмик инерция дә тудырган. Шушы инерцияне текстның соңгы юлында туктату, дүрт юллык строфага тәмамланган төсмер бирү өчен, акрынлап яңа ритмик алым *(катализатор)* үзләштерелгән. Бу очракта без соңгы юлның капыл гына башка ритмга күчүен һәм башка типтагы гыйбарә белән дүртьюллыкны очлап, тәмамлап куюын күздә тотабыз. Менә борынгы төрки поэзиядән Мәхмүд Кашгари җыентыгында (XI йөз) теркәлгән характерлы мисаллар.

| | |
|---|---|
| Этил суы ака торур, | Әрән алпы окуштылар, |
| Кайа төпи кака торур, | Кыныр көзин бакыштылар, |
| Балык тәлим бака торур, | Камуг толмун токуштылар, |
| Көлүң такы күшәрүр. | Кылыч кынка күчүн сыгды[54]. |

Безнең күзәтүләребезгә караганда, нәкъ шушы шигъри ритм-үлчәм (4+4=9) күп төрки халыкларда, атап әйткәндә, уйгыр, алтай, әзербайҗан, гагауз, төрек поэзияләрендә борынгыдан ук килүче бер традиция буларак сакланган, дәвам иткән. Бер үк вакытта бу ритм-строфа калыбы татар мөнәҗәтләренең дә яраткан бер үлчәменә әверелгән. (Тик әлеге үлчәмдәге текстларны озын үлчәмгә әверелдереп, бәет рәвешендә ике юл итеп язу гадәткә кергән. Без исә, борынгы ритм-метр калыбы башкаларга да аңлашылсын, күренеп торсын өчен, мисалларыбызны дүрт юл итеп бирәбез.)

Ата дисәм, авырый башым,
Ана дисәм, түглә яшем,
Чит илләрдә ялгыш башым,
Аерылдым туганнардан.

Йортың вәйран кала дими,
Хәләл әнкән кала дими,
Авыр кайгы салам дими,
Бу ни гаҗәп үлемдер *(бу)*[55].

Әгәр югарыда анализланган мисалларда һәр дүрт тезмә яки баштагы өч юл бер үк типтагы, ягъни үзара тиңдәш җөмләләрдән торсалар, ике юллыклардан үсеп чыккан дүртъюллыкларда инде бик еш бер-берсенә тәңгәл яки капма-каршы торучы мәгънәви-семантик парлар барлыкка килә. Асылда тәүге ике юлы табигатьне тасвирлауга, соңгы ике юлы исә авторның яки лирик геройның хис-тойгыларын сурәтләүгә нигезләнгән образлы-психологик параллелизм алымы да парлы тәңгәллек яки парлы оппозиция мирасы булып тора. Мондый дүртъюллыклар арасында шулай ук табигать образлары белән психологик кичерешләр гаҗәеп дәрәҗәдә керешкән, бербөтен булып үрелгән төрләре дә юк түгел. Ике юллыклар җирлегендә туган һәм ике башлангыч тәңгәллегенә корылган мондый дүртъюллыкларның иң борынгы классик үрнәкләре кытай поэзиясендә аеруча еш очрый. Безнең эрага кадәр XII-V йөзләрдә үк иҗат ителгән поэтик әсәрләр тупланмасы "Шицзин"ны тәрҗемә итүче А. Штукин "каждому синологу известен параллелизм как изощреный и любимейший художественный прием в Китае" дип юкка гына язмаган[56]. Менә шул җыентыктан аерым мисаллар:

Ветер с дождем холодны, словно лед...
Где-то петух непрерывно поет.
Только, я вижу, супруг мой со мной—
Разве тревога в душе не замрет?

Вышла на небе луна и ярка, и светла...
Эта красавица так хороша и мила!
Горечь тоски моей ты бы утешить могла;
Сердце устало от думы, и скорбь тяжела.

Нет, я не орел и не коршун... Крыльями
Взмахнул бы я, к небу направив полет!
Нет, я не осетр и не малая стерлядь,
Сокрылся бы я в бездну глубокую вод![57]

Тарихи-чагыштырма мәктәбе вәкиле, күп халыкларның фольклор һәм әдәбияты белгече профессор А. Н. Веселовский образлы-психологик параллелизм күренешенең иң борынгы җирлеген табигать белән кешене тиңләштерүгә һәм шул мифологик фикерләү нигезендә ике буынлы тәңгәллек барлыкка килүгә бәйләп аңлата. Мифологик ышану юкка чыкканнан соң исә кешегә һәм аның рухи халәтенә, эш-гамәленә тиңләштерелгән табигать образлары чагыштыруларга һәм символларга әверелгәннәр, төрле троплар *(троп—кинаяле, күчерелмә мәгънәле гыйбарә яки сурәтләү чарасы)* тудыруда катнашканнар. Һәм табигый ки, образлы-психологик тәңгәллек бер һәм ике юллыклар эчендә дә, шулай ук өч һәм дүрт юллыкларда да гәүдәләнә алган, һәм хәзер дә бу шулай.

Инде хәзер, беръюллыктан башланган сыйфат һәм сан үзгәрешләренең төрле типтагы ике юллыклар һәм дүртъюллыклар тууына китерүен күзәтеп чыкканнан соң, шәкел-строфика өлкәсендәге кайбер соңрак казанышларга да игътибар итү урынлы булыр дип уйлыйм. Әмма, сүзне озынга сузмас өчен, бу юлы гомумтөрки һәм татар шигъриятендәге аерым бер юнәлештәге мисаллар белән чикләнү дә җитәчәк. Шундый мисалларның иң характерлысы—беренче башлап казакъ шагыйре Абай Кунанбаев (1845—1904) иҗатында кулланылган "алты аяк" дип йөртелүче строфа. Мәгълүм булуынча, Абай—казакъ язма поэзиясенә нигез салган һәм традицион төрки строфалар төзелешенә үзенчәлекле реформа ясаган сүз остасы. Сүз

бара торган "алты аяк", ягъни алты тезмәле, янәшә һәм юл аша рифмалы строфа калыбында иҗат ителгән "Бойы булгаң" шигыре моңа мисал була ала.

Бойы булгаң,
Сөзі жылман,
Кімді көрсем, мен сонан;
Betti бастым,
Katti састым,
Тура каштым жалма-жан[58].

Абайның шактый шигырьләренә өлге булган әлеге строфа төре бик кызыктыргыч һәм йогынты ясаучан, таралучан булып чыга. Аның үрнәкләренең соңыннан казакъ шагыйрьләре Бейимбет Майлин, Сәкен Сейфуллин, Беркияз Кулеев, кыргыз шагыйре Аалы Токомбаев, каракалпак шагыйре Хожамет Ахметов, кумык шагыйрәсе Шейит-ханым Алишева, караим шагыйре Ш. Фирковичның иҗатында да урын алуы шуны раслап тора. Менә Фирковичның "Čуty erda" дигән шигыреннән бер строфа.

Bunda jašlar,
Anda irlar,
Kyzny erda beradlar,
Ana ajtty,
Ata kušty,
Kyvdan suradlar[59].

Күренүенчә, әлеге текстта рифмалар юл башларына да күчкән. Борынгы хазар, бөҗәнәк һәм кыпчак кабиләләре катнашмасыннан торган караимнарның (XIV—XV йөзләрдә аларның күпчелек өлеше Кырымнан Литва, Польша һәм Көнбатыш Украина җирләренә күчереп утыртылалар) төрки төбәкләрдән шактый читтә яшәгәнлеген исәпкә алганда, 1935 елда латин шрифты белән Вильнюста басылган бу шигырьнең кайсы әдәбият йогынтысында Абай традициясендә иҗат ителгәнлеген билгеләү кыен.

Әлеге традиция тәэсиреннән Көнчыгыш мәдәнияте белән тыгыз бәйләнештә торган татар классик язма поэзиясе дә читтә калмаган. Дәрдмәнднең халкыбызның киләчәк язмышы турында борчылып иҗат иткән атаклы "Кораб" шигыре—шуның бер саллы үрнәге.

Чыкты җилләр,
Купты дулкын—
Ил корабын җил сөрә!
Кайсы юлар,
Нинди упкын
Тарта безне җан сорап?!

Никадәр генә гаҗәп тоелмасын, алты юллы строфаның, "алты аяк"ның килеп чыгышы да, минем инануымча, берьюллыклардан башлангыч алучы ике юллыкларга барып тоташа. Моңа ышану өчен Мәхмүд Кашгари сүзлегендәге аерым мисалларга игътибар итү дә җитә.

| | |
|---|---|
| Kənli kũjũb I qany quryb I agzu acyb qatgurar,<br>Syzgurgalyr I ũziklərі I əssiz jũzi burqurar. | Его сгоревшим сердцем, высохшей кровью, открыв рот, он скорбит.<br>Страсти иссушают, лицо глупца сморщивается. |
| Өndũn nələk I jalvarmadyn I qac qata bərdin tavar,<br>Tolumlug bolub qatyndyn I qarun əmdi jər suvar. | Почему ты прежде не просил пощады? Сколько раз ты отдавал добро!<br>Вооружившись, ты укрепился. Теперь твоя кровь оросит землю [61]. |

Шигъри ритм тойгысы булган кеше килешер: югарыдагы текстларның төзелешенә "алты аяк" калыбына үсеп әверелү мөмкинлеге салынган. Әмма моның өчен шагыйрь ритмик буыннарны (аларның бүленеш чикләре текстта цезура сызыклары белән күрсәтелде) мөстәкыйль юлларга әверелдерә һәм үзара рифмалаштыру югарылыгына күтәрелергә тиеш. Абай һәм аның яңалыгын беренче булып эләктереп алган яки

дәвам иткән башка шагыйрьләр нәкъ шулай эшләгәннәр дә инде.

Татар классикларыннан Һади Такташ та—шушындый күренеш белән аваздаш казанышка ирешеп, татар шигыренә үзенчәлекле реформа ясаган шагыйрь. Аның интонацион-сөйләм шигыренә юл ярган әсәрләренең нигезендә халык җырларыннан килә торган 10-9 иҗекле үлчәм ята. Ритмик буыннарны горизонталь сызыклар һәм күпме иҗектән торуларын саннар белдән күрсәткәндә, ә цезураларны "+" белән билгеләгәндә, әлеге үлчәмнең һәм шуңа нигезләнгән строфа калыбының схемасы түбәндәгечә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 4 | 2 | 4 | (10) | 4+2+4=10 | ике тапкыр |
| ___ | ___ | 3 | (9) | 4+2+3=9 | |
| ___ | ___ | 4 | (10) | | |
| ___ | ___ | 3 | (9) | | |

Такташ бу ритмик төзелешнең традицион табигатен үзгәртте: буыннарны "башка чыгарып", мөстәкыйль юлларга, цезураларны (буын араларындагы ярым тынышларны) исә тулы паузаларга әверелдерде. Нәтиҗәдә, теләсә кайсы ритмик буынны аерып чыгарырга, шигырь юллары санын төрлечә үзгәртергә мөмкинлек бирә торган хәрәкәтчән ритмлы шигырь төзелеше туды. Бер үк вакытта шагыйрь, төп үлчәм кысасын саклаган хәлдә, аерым ритмик буыннарны төшереп калдыру, йә булмаса яңа буын өстәү һәм яңа ритмик юл кертеп җибәрү алымнарын да кулланды.

Салкын карга басып Алсу килә,
Үзе көлә,
Үзе сөйкемле; } (9)
Үзе усал,
Үзе болай бер дә } (10)
Усал түгел кебек шикелле.

Ай да ялгыз, (9)
Безнең Зөбәйдә дә...
**Ул тын гына** } (10)
Айга карап килеп утырды, (9)
Һаман көлеп йөргән зур күзләрен (10)
Канлы яшьләр белән тутырды[62]. (9)

Белүебезчә, дөнья халыклары сүз сәнгатендә һәм татар поэзиясендә иркле шигырь дә бар. Йола поэзиясеннән һәм шаман дога-чакыруларыннан ук башлангыч ала торган һәм шактый төрләргә-төсмерләргә тармакланган бу шигырь төзелеше хәзерге вакытта шактый актив. Ләкин темабыздан читкә чыкканлыктан, бу очракта иркле шигырьгә бәйләнешле нибары бер үзенчәлекне генә сиздереп үтәсе килә. Силлабик, силлабо-тоник, гаруз шигырь төзелешләрендә иң кечкенә ритмик берәмлек иҗек булса һәм ритмның нинди булуы иҗекнең табигате (басымлы һәм басымсыз, озын һәм кыска, ачык һәм ябык булып килүе) яки саны белән билгеләнсә, монда, әлеге шигырьдә, андый берәмлек—шигырь юлы (гыйбарә-синтагма яки җөмлә). Бу үзенчәлек үзе үк берьюллыкка иҗекләре төрле сыйфатлы тезмәләр ялгануга юл куя. Ләкин иркле шигырьдә сүзләр тәртибе һәм җөмлә төзелеше дә төрле булганлыктан, әлеге төр шигырь тууын, һичшиксез, синтаксик тәңгәллеккә һәм сүз-стопаларның билгеле бер санда килүләренә корылган шигырь төрләреннән сонрак дәвергә бәйләп карарга кирәктер.

Инде кабат шигырь һәм строфа төзелешенең башлангычы булган берьюллыкка әйләнеп кайтыйк. Берьюллык һәм, гомумән, берлек борынгыларның дөньяга карашына һәм мифологик күзаллауларына да гаҗәеп дәрәҗәдә туры килеп торучы үлчәмбизмән булган. Ыруглык дәверендә яшәгән кешеләр бер санын һәр нәрсәнең башы, нигезе итеп санаганнар. Безнең эрага кадәр өч меңенче елларда Мисырда кояш алласы Ра, мәсәлән, бөтен нәрсәне яратучы, барлыкка китерүче итеп каралган һәм хәтта кайбер мифларда үзен-үзе яраткан итеп күз алдына китерелгән. Бу хакта аңа багышланган бер гимнда болай диелә:

Хвала тебе, Великий, родивший богов,
Создавший один себя самого.
Сотворивший обе земли,
Создавший себя силой плоти своей,
Сделал он тело свое сам:
Нет отца, зачавшего образ его,
Нет матери, родивший его,
Нет места, из которого он вышел[63].

Борынгы культураларда һәм мифологик системаларда шулай ук, хаостан космос тудыручы җенессез алла образларыннан тыш, бар дөньяны һәм тереклекне яратучы итеп фараз ителгән "дөнья анасы" образы да бар. Ассириялеләрнең Аруру, эламлыларның Кирририша, кытайларның Нюй-ва, бурятларның Төөдәй *(яки икенче версия буенча—Эхе-бурхан)*, чувашларның Ама исемле алиһә-аналары, мәсәлән, шундыйлардан. Моннан тыш, аерым диннәрдә һәм архаик мифологиядә дөньядагы иң беренче әдәми зат яки аерым халыкларның нәсел башлыгы, беренче бабасы да ялгыз кеше итеп күз алдына китерелгән. Христиан һәм Ислам диннәре буенча, дөньядагы иң беренче кеше—Адәм, Хаува *(Ева)* исә икенче итеп аның сул кабыргасыннан яратылган. Якут мифологик эпосында беренче кеше итеп тасвирланган Эр Согатах Эллэй—ялгыз ир, әтисе дә, әнисе дә юк; бурят эпос-улигерындагы Аламжи Мэрген "үзе үзеннән яралган" һәм беренче булып торак төзегән, терлекчелеккә өйрәнгән культура каһарманы.

Кыскасы, борынгы культуралар мисалыннан аңлашылганча, бер саны тәүге чорда, тәртип саны булудан бигрәк, бербөтенне, бердәмлекне белдерүче күрсәткеч булган һәм, "алла", "космос" төшенчәләре кебек үк, бар нәрсәләрнең башлангычы итеп кабул ителгән[64]. Димәк, бер бөтенне тәшкил иткән бер санының поэзия ялганда җыр-шигырьнең дә "нигез ташы", беренче кирпече булганлыгы һәм архаик күренеш буларак сакланып калуы, хәтта яңа шартларда ярашып дәвам итүе бик табигый. (Хәзерге вакытта бер юллык кушымта өлеше күп мәртәбәләр кабатланып башкарыла торган җырлар иҗат ителүен исегезгә төшерегез: "Подари мне любовь, подари мне любовь...", яки: "Голубая луна, голубая луна..." һ. б.) Атаклы инглиз шагыйре, Нобель премиясе лауреаты Томас Стериз Элиот болай дигән: "Рискну утверждать, что поэзия начинается с дикаря, бьющего в барабан в джунглях и в дальнейшем она сохраняет эту основу—ударность и ритм; метафорически можно сказать, что поэт старше, чем другие люди"[65]. Ә джунглида яңгыраган барабан тавышы нигезендә кат-кат кабатланучы ритм ятканлыгы һәм сүз сәнгатенең башлангыч дәверендә, шулай ук архаик поэзиядә шул ритмның кабатланучы берьюллык шигырь белән бергә үрелеп гәүдәләнгәнлеге безгә инде билгеле.

**Марсель БАКИРОВ,**
*филология фәннәре*
*докторы, профессор.*

## Кулланылган әдәбият

1. B. Fabo. Rhytmos und Melodie der türkischen Volksieder//Keleti Szemle.—Budapest, 1906.—VII.—S. 121-124.
2. T. Kowalski. Ze studiow nad forma poezji lodow tureckich.—Krakow, 1921.—P. 129-181. Әлеге хезмәтнең русчага тәрҗемәсе: Ан. Линин. К вопросам формального изучения поэзии турецких народов//Изв. Восточного фак-та Азербайджанского гос. ун-та.—Баку, 1926.—I.—С. 139-158; 1928.—II.—С. 137-162.
3. В. М. Жирмунский. О некоторых проблемах теории тюркского народного стиха//Вопросы языкознания.—1968.—№1.—32.
4. Шурц Генрих. История первобытной культуры—М., 1923—Вып. II—С. 585.
5. C. M. Bowra. Primitive song.—London, 1962.—P.63.
6. Шунда ук, 68 б.
7. Эрнст Гроссе. Происхождение искусства.—М., 1899.—С. 218.
8. Юань Кэ. Мифы древнего Китая.—М.: Главн. Ред. Вост. лит-ры, 1987.—С. 123-124.
9. Шунда ук, 301 б.
10. Б. Л. Рифтин. Из истории культурных связей Средней Азии и Китая (II в. до. н. н. э.)// Проблемы Востоковедения—М., 1960.—С. 96-127.
11. Н. Я. Бичурин (Иакинф). Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена.—М.—Л.: Наука: 1950.—Т. 1.—С. 214-215.

12. Миклуха Маклай. Собрание сочинений.—М.—Л., 1950.—Т. 1.—С. 116-117.
13. Н. Б. Зубарева. Об эволюции пространственно-временных представлений в художественной картине мира//Художественное творчество—Л.: Наука, 1983.—С. 27.
14. Б. Н. Путилов. Миф—обряд—песня Новой Гвинеи.—М.: Наука, 1980.—С. 1980. Янә аныкы: Песенно-музыкальный фольклор бонгуанцев//На берегу Маклая.—М.: 1971.—С. 227-253.
15. Миклуха Маклай. Алда күрсәтелгән хезмәт, 110 б.
16. Е. В. Аничков. Весенняя обрядовая песня на западе и у славян.—Спб., 1903.—Ч. I.—С. 87
17. А. С. Аманжолов. Руническая надпись на бронзовом кольце//Вестник Академии наук Казахской ССР.—Алма-Ата: Гильм, 1971.—№1 (309).—С. 65-66.
18. Древние письмена Хакасии.—Абакан, 1970.—С. 23.
19. С. Г. Кляшторный. Стелы Золотого озера // TURCOLOGICA.—Л., Наука, 1976.—С. 261.
20. Т.Д. Баялиева. Доисламские верования и их пережитки у киргизов.—Фрунзе: Илим, 1972.—С. 48.
21. Г. П. Снесарев. Реликты домусульманских верований и обрядов у узбеков Хорезма.—М.: Наука, 1969.—С. 41.
22. Махмуд Кошгари. Туркий сузлар девони ("Девону луготит турк").—Тошкент, 1960-1963.—I, II, III томнар.
23. Грузинские народные песни, I. Мифологические песни.—Тбилиси, 1972.—С. 38-40.
24. Мөнир Мазунов. Туган як//Жырлыйк әле.—Казан: тат. кит. нәшр., 1980.—21 б.
25. М. Светлов. Стихи и песни.—М.: Художественная лит-ра, 1962.—С. 39.
26. Мухтар Магауин. Кобыз сарыны.—Алматы: "Жазушы" баспасы, 1968; Акындар жыры—Алматы, 1963.
27. Къарачай халкъ ждырла.—М., 1962.—28 б.
28. Азербајчан фолклору антолокијасы.—Бакы, 1968.—42 б.
29. М. Э. Матье. Древнеегипетские мифы.—М.—Л., 1956.—С. 41-42.
30. Сэмюэль Н. Крамер. История начинается в Шумере.—М., Наука, 1963.—С. 145.
31. Марсель Бакиров. Ырымнар // Мирас.—Казан: 2003.—№1.—24 б.
32. В. В. Иванов. Двоичная символическая классификация в африканских и азиатских традициях //Народы Азии и Африки.—М., 1969.—№5.—С. 206-236; Клод Леви-Стросс. Структура мифов// Вопросы философии.—М., 1970. №7.—С. 152-164; Б. Ф. Поршнев. Социальная психология и история.—М.: Наука, 1979.—С. 232.
33. Василий Субботин. Строки.—М.: Советский писатель, 1972.—С. 45
34. Равил Фәйзуллин. Кыска шигырьләр.—Казан: Тат. кит. нәшр., 1978.—5-10 б.
35. С. Шунаева. Строфика современного русского стиза//Научные труды филологического факультета Киргизского ГУ.—Фрунзе, 1972.—Вып. XVIII.—С. 57-58.
36. Gunner Landman. The foik-tales of the kiwal papuas.—Helsingfors, 1917.—Acta societatis scientiaris fenrikae.—T. XLVII.—P. 116-117; Б. Н. Путилов. Алда күрсәтелгән хезмәт, 64-67 б.
37. С. Ю. Неклюдов. Закономерности стадиальной эволюции эпоса Центральной Азии и Южной Сибири//MONGOLICA. Памяти акад. Б. Я. Владимирцова.—М.: Наука, 1986.—С. 76.
38. М. Э. Матье. Алда күрсәтелгән хезмәт, 113 б.
39. В. М. Жирмунский. Ритмико-синтаксический параллелизм как основа древнетюркского народного эпического стиха//Вопросы языкознания.—М., 1964.—№4.—С. 21-39.
40. Е. И. Убрятова. Древнетюркская руническая надпись из Бичикту-Бома // Бронзовый и железный век Сибири.—Новосибирск: Наука, 1974.—С. 161-163.
41. Шешендек сөздер.—Алма-Ата, 1967.—138 б.
42. Манас. Беренче бүлек. I китап.—Фрунзе, 1958.—198, 124—241 б.
43. Л. Д. Позднева. Литература древнего Китая//Литература древнего Востока.—М.: Изд. МГУ., 1971.—С. 258.
44. Кецаль и голубь. Поэзия науа, майя, кечуа.—М.: Художественная дитература, 1983.—С. 42.
45. Татар халык мәкальләре. Төзүчесе Н. Исәнбәт.—Казан: Тат. кит. нәшр., 1963.—Т. 1.—38, 45, 217 б.
46. Мөнәҗәтләр һәм бәетләр. Төзүчесе К. Хөснуллин.—Казан: Раннур, 2001.—14, 43 б.
47. Сэмюэль Н. Крамер. Алда күрсәтелгән хезмәт, 243 б.
48. Путешествие в Южный океан и Беренгов пролив для отыскания северо-восточного морского прихода.—Спб., 1823.—Ч. III.—С. 79-80.
49. Л. Ю. Тугушева. Поэтические памятники древних уйгуров//Тюркологический сборник, 1972.—М.: Наука, 1973.—С. 239.
50. С. Е. Малов. Памятники древнетюркской письменности.—М.—Л.: Изд. АН СССР, 1951.—С. 84.
51. Сэмюэль Н. Крамер. Алда күрсәтелгән хезмәт, 245 б.
52. Т. Я. Елизаренкова. Древнейший памятник индийской культуры//Ригведа.—М.: Наука, 1972.—С. 76.
53. К. М. Мусаев. Грамматика караимского языка.—М.: Наука, 1964.—С. 78.
54. Махмуд Кошгари. Алда күрсәтелгән хезмәт.—I том. 103, 192 б.
55. Татар халык иҗаты. Бәетләр.—Казан: Тат. кит. нәшр., 1983.—262, 286 б.
56. Шицзин. Книга песен и гимнов.—М.: Художественная литература, 1987.—С. 311.
57. Шунда ук, 79, 111, 184 б.
58. Абай Кунанбаев. Шыгармаларының толык жыйнагы.—Алма Ата, 1954.—Т.1.—110 б.
59. T. Kowalski. Karaimsche texte im dialekt von troki.—Krakowie, 1929.—S. 37.
60. Дәрдмәнд. Сайланма әсәрләр.—Казан: Тат. кит. нәшр., 1959.—33 б.
61. И. В. Стеблева. Развитие тюрских поэтических форм в XI веке.—М.: Наука, 1971.—С.163, 257, 151, 254.
62. Һади Такташ. Сайланма әсәрләр.—Казан: Тат. кит. нәшр., 1963.—162, 195 б.
63. М. Э. Матье. Алда күрсәтелгән хезмәт, 85 б.
64. Мифология народов мира. Энциклопедия.—М.: Советская энциклопедия, 1988.—Т. 2.—С. 630.
65. Томас Стернз Элиот. Назначение поэзии. Перевод с английского.—Киев: Airland; М.: ЗАО "Совершенство", 1997.—С. 147—148.

## Адлер Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

*АБЫСТАЙ*— Мәдрәсәләрдә дәрес бирүче хатын, күбесенчә мулла, мәзин хатыны, остабикә. *Абыз* (укымышлы) *тутыкай/тутай* сүзеннән кыскарып ясалган дигән фикер бар. Ишан хатынын *ишан абызтай* дигәннәр.

*"АГАЧКА ЖИРЛӘҮ"*— "Татар әдәбияты тарихы"ның беренче томында кулланылган термин. Борынгы Болгарда (һәм кайбер башка халыкларда) үлгән кешеләрне җиргә дәфен кылмыйча, агачка асып кую йоласы. Бу йола кеше җанының туганчы һәм үлгәннән соң урнашу урыны саналган изге "тормыш агачы" белән бәйле. Мондый ышану татар әкиятләрендә дә телгә алына ("Без, ди, җиргә күммибез, ә зур мичкәгә тыгып, тимер кыршау кидертәбез һәм агачка асып куябыз, ди"). Шул ук вакытта болгарларда тәңрегә хезмәт итәргә иң лаек кешене агачка асу гадәте дә яшәп килгән (тәңрегә корбан китерү). Мондый йола борынгырак кабиләләргә, мәсәлән, һуннарга, аннары Әзи культурасына (яңа эраның III—V гасырлары) да хас булган. В.Ф.Генинг Әзи культурасына караган каберләрдә бала сөякләре очрамавын "агачка күмү" йоласы белән аңлата.

*АЖДАҺА*— "Йөзгә җитеп, канатланып оча торган елан" *(Н.Исәнбәт)*. Бу атама борынгы фарсы "*аҗи даһак*" (елан-ялмавыз яки Зәххак еланы) сүзеннән килә (мишәрдә: *аждак*). Сөйләкләргә караганда, *Зәххак (Даһһаһ)* дигән бер патша Иблис белән дуслашып, аны үзенең хөкемдарлыгын саклаучы итеп яллый. Иблис хезмәт хакы итеп аңардан ике иңбашын үптерүен сорый. Патша моңа риза була, ләкин Иблис үпкән җирләреннән ике елан үсеп чыгып, бу еланнар көн саен ашарга бер яшь егет яки кыз таләп итә башлыйлар. Шул рәвешле, Зәххак патша һәр көн ике кешесен корбан итәргә мәҗбүр була.

Халыкта елан йөз ел яшәгәч аждаһага әйләнә дигән ышану бар. Ә аждаһа дөньяда мең ел яши, ләкин ул татарлар торган җирдә булмый икән. Бу инде аждаһага ышануның татарларга читтән кергән хорафат икәнлегенә ишарәли.

Мең елдан соң аждаһа юха еланга әверелә. Юха исә кеше яки берәр хайван кыяфәтенә керә ала. Күп очракта ул гүзәл кыз кыяфәтенә кереп, егетләрне үзенә өйләнергә мәҗбүр итә. Тагын шунысы бар: кеше кыяфәте алып кырык тугыз көн яшәгәч, Юха кабат Аждаһага әверелә икән.

Халык әкиятләрендә аждаһа берничә башлы итеп сурәтләнә (әкиятләрдә ике, өч, дүрт, алты, җиде, тугыз, унике башлылары очрый). Димәк, татар шәһәре Казанның гербы итеп аждаһа сурәте алу дөреслеккә хилафлык итү була. Татар әкиятләрендә аждаһа-елан белән сугышу сюжеты болгарларга иран халыкларыннан сасанилар дәверендә кергән дип уйлыйлар (*А.Халиков*). Шушы ук ирани сюжет Мәскәү гербында кабатлана.

Дж.Джосселининың 1672 елда Лондонда басылган "Яңа Англиянең сирәк ядкярләре" дигән китабында Төньяк Америкадагы дакота кабиләсенең тотем тамгасы сурәтләнгән. Бу сурәт турында Әбрар Кәримуллин: ул "практик яктан Казан шәһәре гербына тәңгәл, Идел буе болгарларының акчаларында очрый, символ буларак борынгы заманнарда башка төрки халыклар арасында да, шул исәптән Урта Азиядәге төрки халыкларда да билгеле" дип яза. Шулай да аның фикере белән килешү кыен. Дакота кабиләсе тамгасында сурәтләнгән хайванның ике генә түгел, бәлки дүрт тәпие бар, канатлары тарихка кадәрге птеродактильләрнекенә тартым, койрыгы исә чаяннныкы шикелле. Ул чынлыкта Мәскәү гербындагы җирдә яткан аждаһага охшаган (ул да яры канатлы, дүрт тәпиле, койрык очында угы бар).

Иске татарча әдәбиятта *әҗдәрһа* язылышы да очрый: "Йитсә татлы суга сусамыш ир, Курыкмас алында булса әҗдәрһа" *(Сараи)*.

*Аҗаган* сүзе дә тарихи яктан аждаһа сүзенә килеп ялгана. Р. Әхмәтьянов *нәҗагай* сүзен шулай ук аждаһа сүзенә бәйләп аңлата.

---

*Дәвамы. Башы 1 санда.*

*АРАБЕСКАЛАР*— Гарәп бизәкләре. Нык стильләштерелгән үсемлек мотивларына яки геометрик төзек күппочмаклыкларга (өчпочмакларга, квадратларга һәм алтыпочмаклыкларга) нигезләнгән бизәкләр. Бу абстракт фигуралар бихисап тапкырлар кабатланып, бердәм декоратив кыр хасил итәләр. Савыт-сабаны бизәгән, агач минбәргә кисеп-уеп эшләнгән яки идәнгә мозаика итеп тезгән арабескалар һәм геометрик орнаментлар үзләренең бердәмлеге һәм гармониясе белән Аллаһының чиксезлеге һәм бүленмәслеге турындагы идеяне сурәтлиләр.

Арабескаларда кеше Аллаһыны ача. Менә шуңа күрә мөселман рәссамнары үзләре иҗат иткән әйберләргә (ташка, агачка уеп эшләнгән бизәкләргә, мозаикага, металлга чүкеп ясалган әйбергә, келәмгә яки миниатюр рәсемгә) беркайчан да исемнәрен язмаганнар.

*АРГАМАК*— Зифа кыяфәтле ат нәселе; озын муенлы, озын торыклы гарәп аты токымы. Э.В.Севортян фикеренчә, тува һәм кыргыз телләрендәге *арг* һәм *аргы* сүзләреннән килеп чыккан ("эре карьер белән, ягъни нык сикертеп чабу" мәгънәсендә). Ихтимал, "Сад" сүрәсенең (38) 31 нче аятендә сүз барган затлы токымлы чабышкы атларны "юртак" дип түгел, башкорт тәрҗемәсендәгечә "аргамак" дип алу дөресрәк булыр.

"Борынгы Болгар чорында *аргамак* дип корбанга билгеләнгән атны һәм "ат рухын" атаганнар" *(Р.Әхмәтьянов.)*

*АСЫЛТАШ*— Табигатьтә табыла торган затлы, кыйммәтле таш, җәүһәр. Электә бизәнгеч буларак болгарлар һәм татарлар арасында *фирүзә, сердолик, тапас (тәршиш), яшым, зөбәрҗәт, ләгыль, ләҗүрд (лазурит), анар, аквамарин, якут, хризолит, гакык,* шулай ук *гәрәбә* һәм *энҗе-мәрҗән* кулланылган. Исемнәреннән үк күренеп торганча, аларның күбесе безнең якларга Шәрыктан кайтартылган. Асылташ булып исәпләнмәсә дә, борынгылар *каш* дигән яшькелт яки ак төстәге мәгъданны (нефрит) пычак һәм кыргыч ясау өчен, шулай ук сугыш һәм сунарчы коралы сыйфатында күп кулланганнар. Ул төркиләрдә сихер ташы буларак та танылган.

*АГА*— Төрки телләрдә өлкәнлекне белдергән сүз (татардагы "агай" да шул ук мәгънәдә). Әзәрбайҗаннарда *ага* сүзе исем булып та йөргән, аны ир-ат исеменә ялгап та әйткәннәр. Ул титул булып та йөргән, хәтта хатын-кыз исеменә дә ялганган. Бу очракларда исемендә "ага" компоненты катнашкан кеше хан гаиләсеннән булган (мәсәлән, Аксак Тимернең иң хөрмәтле хатыннарыннан берсе Туман-ага исемле була). Электә Госманлы империясендә һәм Иранда ага титулын яубашлары, югары дәрәҗәле руханилар һәм евнухлар *(хасилар, хәрәм агалары)* йөрткән. Җиһангирлар һәм дин әһелләре исеменә ул сүз ахырына ялганса, евнухлар исеменең алдыннан әйтелгән. Тарихта бер кызыклы факт та билгеле. Иранда беренче Каджарлар династиясеннән булган шаһ Ага-Мөхәммәд исемен йөрткән. Ләкин төрек аристократларыннан чыккан бу хөкемдарның исеме Мөхәммәд-ага булырга тиеш иде түгелме? Хикмәт шунда ки, Ага-Мөхәммәд әле бала чагында ук дошманга әсир төшкән һәм аны шунда печкән булганнар.

"Ага" сүзе татар исемнәрендә дә компонент булып катнаша, ләкин ул исем алдына ялгана: мәсәлән, *Агабай, Агабәк, Агахан* исемнәре.

*АДМИРАЛ*— Гарәпчә *Әмир әл (бәхер)*— диңгез хуҗасы, диңгез әмире сүзеннән үзгәреп, башта рус теленә, аннары татар теленә кергән. Шул рәвешле, Һинд океанында Африкадан көнчыгыштарак урнашкан һәм адмирал Васко да Гама хөрмәтенә аталган *Амирант утрауларын* "Әмир утраулары" дип язу дөресрәк икән.

*АЗАМАТ*— 20—30 яшьләр арасындагы ир-егет. Гомумән, гаскәри хезмәткә иң беренче барырга тиешле таза, мәһабәт гәүдәле, солтанәт кеше. Гарәпчә *газаәт* сүзеннән (олылык, бөеклек, горурлык мәгънәсендә).

*АИТ г.*— Татарда исем булып та йөргән сүз (мәсәлән, *Аитов* фамилиясендә сакланган), *гает* сүзенең башкача әйтелеше. Татарда тагын Гает, Гаетбай, Гаетгол, Гаетмөхәммәт, Гаетхан, Гаетхуҗа, Гаетҗан исемнәре дә булган. Мондый исемнәрне гает бәйрәме көнне туган балага кушканнар. "Гаетмөхәммәт" исеменең фонетик һәм диалекталь вариантлары арасында очраган *Аетмөхәммәт, Аетмәт, Аймәт, Әйтмәт* исемнәренә игътибар итик. Мондый фонетик үзгәрешләр башка төрки телләргә дә хас. Мәсәлән, күренекле кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматовның фамилиясе *Айт* һәм *Мөхәммәд* исемнәреннән тора, Мөхәммәд биредә *Мамат*-ка тикле кыскарган гына. (Алим Гафуров катлаулы исемнәрдә *Мамат*-ның *Мат*-ка тикле кыскаруын искәртеп китә).

*АКМАН-ТОКМАН тар.* — Март ахырларында була торган кайталый салкыннар. Гарәп телендә "бәрде гаҗүз" — "*карт-карчыклар суыгы*". Календарь вакыт ягыннан "*әбиләр чуагы*"на капма-каршы. Р.Әхмәтьянов бу сүз кыпчак теленнән үк килә дип исәпли. Тагы шуны да әйтергә кирәк, "Татар теленең диалектологик сүзлеге"ндә (1969) нугайбәк-керәшен сөйләшендә *акман-тукман* — "март урталарында була торган көчле бураннар" дип күрсәтелә. Аннары борынгы болгар календаренда февраль-мартны да *акман-токман* дип атаганнар.

*АКСӨЯК тар.* — Ак токым. Затлы нәселдән, югары катлаудан яки дини саны булган кеше — аристократ, морза/дворян, ишан, сәет, түрә һ.б. Мондый сүз монголларда да булган. Татар телендә тагын шушы ук мәгънәгә якын *ак кул* дигән сүз бар. Гомумән, *сөяк* сүзенең нәсел мәгънәсенә дә ия булуы *үз сөягем* — үз нәселем дигән сүздән ачык күренә.
Чаг.: *Карасөяк.*

*АК ЕЛАН* — Татарларда әкияти-мифологик зат, еланнар патшасы, кайбер төрки халыкларда, шул җөмләдән татарларда, тотем хайван. Гадәттә каһарманга ярдәм итә, бүләкләр бирә.

*АК КИЕК* — Кыйммәт тиреле җәнлек, рустагы *пушной зверь*. Электә болгарларда ак киек сәүдәсе зур урын тоткан.

*АКЧА* — Шәрыктә вак акчаны шулай атаганнар, бу сүз, мәсәлән, Обейд Заканиның "Күңелле китаб"ында ("Ләтаиф") очрый. Нәкый Исәнбәттә "акча" сүзенә карата кызыклы гына фикергә тап буласың: "Борынгы Идел-Болгарда *(шулай ук русларда, удмуртларда һәм марилларда да — А.Т.)* металл акчага кадәр тиен тиресе акча берәмлеге саналган. Шул чакларда озак кына заман ике тиен тиресе бер көмеш акча хакына тиңләп йөртелүдән "ике тиен — бер акча" сүзе әйтем булып киткән булу ихтимал". Нәкый Исәнбәттә үк "акча" сүзенең килеп чыгышына карата икенче бер халык этимологиясенә тап булабыз. "Акчаның башы "аһ", соңы "чаһ" дигән мәкальгә түбәндәге искәрмә бирелгән: "Чаһ — чокыр дигән сүз *(фарсы)*. Ягъни, акча аһ-ваһ белән табылып, ул ук адәмне кабергә — чокырга кертәдер. Имештер, "акча" сүзе шушы "аһ" белән "чаһ" дигән ике сүздән ясалган да, шуны "аһчаһ" дип әйтүдән соңыннан "акча" сүзе килеп чыккан...
"Фәнни әдәбиятта "акча" сүзенең этимологиясен "ак" төскә бәйләп аңлату чыннан да бар. Р.Әхмәтьянов рус телендәге "белка" сүзе башта вак акчаны белдергән һәм татарча "акча" сүзенең калькасы булып тора, дип яза, ягъни аның этимологизациясендә тиен җәнлеге бөтенләй катнашмый. Ибн-Рустә язмаларында да "ак дирһәм" телгә алына, ягъни атамада акчаның төсенә басым ясала.
Бу гипотезаны кабул иткән очракта "ярмак" сүзен "ярымак" рәвешендә этимологизацияләп булыр иде (тарихчы Ә.Мөхәммәдиев фикеренчә — ике яртыга бүленгән акча).
Кәгазь акча Кытайда Цин династиясе чорында кулланылышта йөргән. Кытайның беренче монгол императоры Хубилай һәм аның варислары император казнасын баету өчен бу системаны киң кулланганнар.
Кара: *Тиен; Тиген; Тәңкә.*

*АКЧУРА* — "Ак" һәм "чура" — *яугир, хәрби, угыл, егет, батыр, игенче, дус* сүзләреннән тора. М.Глухов бу исем "борынгы заманнарда ак чырайлы угылга бирелгән" дип яза, ягъни аны "табигый исем" дип саный. Аның фикеренчә, Алтын Урдада мондый исем төрки сугышчыларның (башлыча кыпчак каүменнән булганнарының) атамасы булып киткән. Хәер, М.Глухов бу фикерен нигезләп-нитеп тормый. Шул ук вакытта "карачура" сүзе дә булган, ул да кеше исеме булып йөргән. Ә "Акчура исеме марилларда хәзер дә кулланылышта йөри" *(Гомәр Саттаров).*

*АЛАҢГАСАР тар.* — Идел буе халыкларында (татарларда, башкортларда, марилларда, удмуртларда), шулай ук казакларда һәм караимнарда кайчандыр Идел буен яулап алган әкияти әзмәверләр. Нәкый *Исәнбәттә "Алаңгасар Алман би, алымсаклы яман би"* дигән мәкальне очратабыз.. Н.Исәнбәт "алаңгасар" сүзен "илтифатсыз" мәгънәсендә дип аңлатса да, моны нигезләмәгән. Күп кенә тикшеренүчеләр исә әлеге сүзне электә аланнар белән хәзәрләр төзегән хәрби берләшмә атамасының халыклар хәтерендә сакланган эзе дип саныйлар.

*АЛАША* — Печкән айгыр, ләкин бу сүз гомумән ат мәгънәсендә дә йөргән. Тау ягы-Тархан сөйләшендә алашаны *"къазакъ ат"* диләр. Чыганакларга караганда,

төркиләр күбесенчә алаша җиккәннәр (гарәпләрдә менге атлар гадәттә бия булган). Рус телендәге *лошадь* һәм *лошак* сүзләре дә төрки *алаша* һәм *алашак* сүзләренә барып тоташалар (төрки телдәге басымсыз беренче "а" рус телендә төшеп калган; "алабута" һәм "алачык" – русча "лебеда" һәм "лачуга" – сүзләренең дә шундый ук үзгәреш кичергәнлеген күрәбез). Димәк, бүген без айгыр белән ишәктән алынган хайванны *алашак* дип атасак, асылда татарча сүз кулланган булабыз. Хәлбуки, еш кына *"качыр"*ны (ишәк белән биядән алынган хайван, мул – кушылгак) *"алашак"*тан (лошак) аерырга туры килгәли. Гарәпчә тагын *бәгыл* дигән сүз бар, ул да ишәк белән аттан алынган хайванны белдерә.

Нурихан Фәттах "алаша" сүзе кайчандыр ике "л" белән язылган булырга мөмкин, ул чагында алаша – "алла улы" булып чыга дип гоманлый. Мондый этимологик фантазияләр ышанычсыз.

*АЛПАК тар.* – Татар-болгар сугышчылары кигән тимер баш киеме – очламның (шлем) бер төре, шишәк. Рәвеше – гадәттә шар яки конуссыман. Аның алгы ягында борынчасы булган. Яугирнең битен һәм муенын саклау өчен, алпак читенә тимер боҗралардан үрелгән челтәр беркетелгән.

*АЛТЫН АЙДАР бор.* – Ирләрнең баш түбәсендә яки маңгаенда кырмый калдырылган чәч толымы, *какул*. Дастаннарда аны алтын чәч, алтын толым дип атау да очрый.

*АЛЬМАНАХ г.* – Җыентык басма. Хәзерге мәгънәсе – төрле авторларның гадәттә тематик яктан бериш беллетристик әсәрләре тупланган мәҗмуга. Бу сүз Европа телләренә һәм рус теленә дә кергән. Атаманың этимологиясенә килгәндә, аерым галимнәр бу очракта гарәп сүзе (Испания аркылы) белән грек сүзе очрашып, үзара керешеп киткәннәр дип уйлыйлар. Ләкин гарәби вариант игътибарга лаек. *Әл-манаһ* сүзендәге "наһ" тамыры "тукталыш", "ял итү" (кәрвандагы дөяләрнең чүгүе) мәгънәсендә. Шушындый тукталышлар вакытында сәфәрчеләр бер-берсенә кызыклы хикәяләр, кыйссалар сөйләгәннәр.

*Альмәнах* язылышы да очрый.

*АЛХИМИЯ гл.* – Гарәпчә *әл-кимийә* сүзе башта латин теленә, аннары башка Европа телләренә дә алхимия рәвешендә кергән. Гарәпләрдә һәм иске татарча китапларда бу сүзнең *кимья, симия* вариантлары очрый (бер үк вакытта химия һәм алхимия мәгънәләрен берләштерә). XIX гасыр ахырларында француз химигы Бертелоның тикшеренүләренә караганда, тарихта алхимия буенча беренче язмалар Борынгы Мисыр чорына ук карыйлар (моннан 2000 еллар элек язылганнар). Ләкин бөтендөнья фәненә алхимия гарәпләр аркылы мәгълүм була. Гарәпләрдә исә алхимиянең атасы булып Җәбир Ибн әл-Хәйан исәпләнә. Гарәп һәм латин китаплары аны "әс-Суфи" (ягъни суфи) дип атыйлар, ә урта гасырларда алхимиянең үзен дә софистика дип атаганнар. Инде VIII гасырда ук гарәпләр һәм европалылар Җәбир Ибн әл-Хәйанны бу гыйлемнең остазы дип санаганнар. Ул исә *Җәгъфар Садыйк* исемле бөек суфи галимне (700 – 765) үзенең остазы дип атый. Җәбир Ибн әл-Хәйан үзенең хезмәтләрендә өч төп элемент – тоз, күкерт һәм терекөмеш турында язып калдырган. Ул гади металларны затлы металларга әверелдерә торган "фәлсәфи таш"ны менә шушы өч элементны билгеле бер нисбәттә кушып ясарга мөмкин дип ышанган. Гомумән, XVI гасырларга кадәр алхимиклар гади металларны "фәлсәфи таш" ярдәмендә алтын-көмешкә әверелдерүне максат итеп куйганнар һәм хәзергә кадәр бу хыялый таш алхимия дигән фәннең синонимы кебек булып аңлашыла. Европалылар гарәп алхимиясе белән 1144 елда инглиз Роберт Честерскийның алхимия турындагы гарәпчә китап тәрҗемәсе аркылы танышканнар. Шул рәвешле көнбатыш Европа телләренә бик күп химик (алхимик) атамалар да килеп кергән. Мәсәлән, шәркыять галимнәре "азот" дигән сүзнең йә гарәпчә "аз-зат" (нәрсәнең дә булса асылы, "эчке реальлеге", эчтәлеге) сүзеннән, йә "терекөмеш" мәгънәсендәге "зибак" сүзеннән ясалган дигән фикергә килделәр. Хәтта бөек Парацельсның да алхимик терминологиясе гарәп атамаларының туры тәрҗемәсеннән гыйбарәт диярга мөмкин.

Алхимиклар тырышлыгы белән күп кенә химик кушылмалар ачылган, ягъни алхимиянең фәнгә керткән өлеше бәхәссез.

Алхимия белән кызыксыну татар дөньясына да үтеп кергән. Мәсәлән, татарча иске чыганаклар XVIII гасыр азагы – XIX гасыр башында Казан артында Кышкар мәдрәсәсендә мөдәррис булган Сәгыйд хәзрәтнең (Ибраһим улы Сәгыйд) "гади мәгъдәннәрдән алтын, көмеш ясау тәҗрибәләре ясап күп еллар азаплануы" турында хәбәр итәләр *(Исмәгыйль Рәмиевтән).*

*Дәвамы бар*

*Шәриф Камалның тууына 120 ел*

# КОШЛАРДА ДА КЕШЕ ЯЗМЫШЛАРЫ...

Адәм баласын кошларга тиңләү, язмышларын кошлар язмышы белән чагыштыру әдәбиятта күптәннән килә. Яралу тарихы ерак гасырларга күмелгән "Сак-Сок"ларга барып тоташа ул... Кайсы гына әдип күктә, иркендә үзләре телгән тарафка үз ихтыярларында уйнаклап очкан шул табигать иркәләренә сокланмаган да, иҗатында әлеге образларга мөрәҗәгать итмәгән! Әмма ул каләм җимешләренен азлары гына вакыт сынаулары аша үтә алган. Ә уза алганнары арасында, һичшиксез, Шәриф Камалның "Акчарлаклар" повесте иң күренеклеләреннән саналырга хаклы. Язучыны классик әдип итеп танытkан әсәр ул. Әдәби тарихыбызның чын мәгънәсендә, Тукайга ияреп әйткәндә, "һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер". Повестьның дөньяга килүенә быел 90 ел тулды. Инде тугыз дистә ел буе ул татар канлы, милли җанлы укучыны дулкынландырып, уйландырып, сокландырып килә. Әсәре үзеннән соң да яши алган язучы—бәхетле язучы ул. Тормышта бәхет эзләүчеләрне диңгездән мәрхәмәт өмет итүче акчарлакларга тиңләгән Шәриф Камалның тууына бу елның февраль аенда 120 ел тулды. Димәк ки, милли әдәбият дөньясы өчен икеләтә юбилей, ягъни борынгылар әйтмешли, тәгаен генә "нурын галә нур" ("нур өстенә нур") инде бу.

* * *

Шәриф Камал 1884 елның 27 февралендә Пенза губернасы Инсар өязе (хәзерге Мордва республикасы) Пешлә авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Ул башлангыч белемне үз авылларында ала. Аннары исеме тирә-юньгә шактый мәгълүм булган Ләбәҗә мәдрәсәсенә килә. Ш. Камал шәкерт чагыннан ук үз көнен үзе күрә башлый: тимер юл төзелешендә кара эшче булып шактый чиләнә, бер сәүдәгәргә ялланып озак кына ил гизә. Кайда гына йөрсә дә аны укуын дәвам итү теләге ташламый һәм шул нияте аны әүвәл Төркиягә, аннары Мисырга китереп чыгара. Әмма матди кыенлык, ычкынмаслык булып чабуга ябышкан мохтаҗлык егеткә изге ниятләрен тәмаман тормышка ашырырга ирек бирмиләр. Дөрес, Каһирә шәһәрендә Казан ягыннан килгән бер профессор аны "Җамигыләзер" исемле пансионга укырга урнаштырырга ярдәм итә һәм ул анда бер ел белем дә эсти. Әмма, әлеге дә баягы фәкыйрьлек гыйлем туплауны дәвам итәргә мөмкинчелек бирми. Тәкъдире аны кире Россиягә куа.

1905 елгы революция алдыннан—ул инде Украинадагы күмер шахталарында, Каспий диңгезе буендагы балык промыселларында. Ныклап фикерләсәң, Ш.Камалның бу чор гомерен "газап чигеп йөрү" дип атарга мөмкин булыр иде. Әмма ул юл сәфәрендә йөзләрчә төрле характерлар белән очраша, тормышның эченә үк кереп, иҗтимагый тормышның иң түбәнге баскычында торган кешеләр белән аралаша, аларның уй-фикерләрен, гадәтләрен, яшәү максатларын хәтеренә сендерә бара. Киләчәктә болар барысы да булачак әдипнең "язар ризыгына" әвереләчәкләр, тормыш төбендәгеләр исә, әдәби образ буларак, кабат яшәү сыйфатына ия булачаклар. Бер уйласаң, Ш. Камалның вакыйга-күренешләргә бай гомер юлы, ул кичергән хәлләр, гомумән тормыш тәҗрибәсе тагын әллә ничә язучыга җитәр иде.

1905 елгы революцияне Ш. Камал Петербургта татар мәдрәсәсендә мөгаллим булып каршылый. Бер үк вакытта "Нур" исемле беренче татар газетасында эшли, шигырьләр, мәкаләләр яза, тәрҗемә белән шөгыльләнә. 1906 елда аның "Сада" ("Аваз") исемле беренче шигырьләр җыентыгы дөньяга чыга. Ул шигырьләрдә туган халкының караңгылыкта яшәвенә уфтану, аны изүчеләргә нәфрәт, хатын-кызның авыр хәле турында уйланулар, революция палачларына көчле ләгънәт, мәгърифәтчелек идеяләренә каршы чыккан иске типларны фаш итү һ. б. мотив-идеяләр үзәккә алынганнар. Дөрес, бу шигырьләр, әдипнең беренче тәҗрибә үрнәкләре буларак, сәнгатьлелек ягыннан да, әдәби эшләнешләре буенча да шактый кайтышлар. Ш. Камал моны үзе дә аңлый һәм шигърияте төп иҗат кыйбласы итеп танудан туктый.

Революция чигенеп, кара реакция чоры башлану Ш. Камалның Петербургта

яшәү шартларын гаять кыенлаштыра. 1907-1910 елларда ул үз авылларында яши һәм балалар укыта. Шунда беренче хикәясе "Уяну"ны язып, "Шура" журналына җибәрә һәм хикәя басылып та чыга. Бу классик әдип булып танылунын юл башы. 1910 елда ул Урта Азия якларына сәфәр чыга, Оренбургта туктала һәм "Шура", "Вакыт" редакцияләренең берләшкән конторасына хисапчы булып урнаша. Бу дәвер—Ш. Камалның зур иҗади активлыгы белән характерлы. Кара, авыр вәзгыять, өстәвенә, тормыш шартларының кыенлыгы әдипне максатыннан—язу, иҗат итү теләгеннән биздерә алмыйлар. Язмыш кыскан саен ул каләменә үҗәтләнебрәк ябыша төшә. Аның хикәяләрендә гомер буе изелеп, кыһәрләнеп яшәүдән гаҗизләнгән, барыр кыйбласын тапмый гасабиланган, еш кына кешелеген югалту дәрәҗәсенә җиткән типлар үзәккә алына, шыксыз тормыш тудырган ямьсез инстинктлар алгы планга чыга. Язучының "Муса ачуланган иде. Ачуыннан күзләре акайган, йөзе ут шикелле яна, дулкынлануыннан сүзен әйтә алмый иде..." сүзләре белән башланган "Уяну" (1909) дигән беренче хикәясе кешедәге шул ерткычлык сыйфатларын калку итеп тасвирлый, явызлыкның авыр фаҗигасен өшеткеч картиналарда сурәтли.

"Буранда" (1909) хикәясенең дә үзәгендә психологик конфликт ята. Солдат Мостафа, кышкы буранның котыруына карамастан, өенә кайтып җитәргә һәм әнкәсе белән күрешергә ашкына. Аның әнисеннән аерылуына егерме ел икән. Атасы ике дистә ел элек әнисен куып җибәреп улын аңа каршы тәрбияләгән булган һәм хәзер ул "анасыннан бөтенләй бизгәнлеген уйлап газап чигә", аягына егылып гафу үтенергә тели. Мостафа кайчандыр әнисенә карата кылган начарлыклары, салкын мөгамәләсе өчен вөҗдан газабы кичерә, шул хис аны салкын буранда юлга чыгарга мәҗбүр итә. Ләкин аның изге ниятләре тормышка ашмый: ул кайтып кергәндә инде, анасының гомере өзелгән була.

Язучының "Козгыннар оясында" (1910) хикәясенә күз салсак та бәхетсезлекне, фаҗигане күрәбез. Шахтерлар тормышыннан алып язылган бу әсәр шәхес драматизмына китергән сәбәпләрне бөтен тулылыгында аңларга ярдәм итә.

Ш. Камал үз иҗатында хокуксызларны яклау идеясен алгы планга куя, берәүләр аһ органда, зар түккәндә, канлы яшь койганда, кемнәрнеңдер үзләрен әллә кемгә куеп, тук-канәгать тормыш белән гомер сөрүләрен фаш итә. Ил ыңгырашканда мәгънәсез ыгы-зыгы, буш шапырыну белән мавыгуларны каһкаһәле көлү утына ала. Шул рәвешле, Ш. Камал хикәя-новеллаларның бер төрен сарказм белән сугарылган әдәби-идеологик коралга әверелдерә. Дөрес, бу өлкәдә аның хикәяләре сан ягыннан күп түгел, әмма татар әдәбиятының гомуми үсешендә сүз сәнгатен ирония, сатира сыйфатлары белән баетуда ул әсәрләр мәгълүм роль уйнадылар. Шунысы игътибарга лаек: әдипнең бу юнәлештәге иҗаты 1910 нчы елларда, ягъни реакция котырган бер дәвердә башлана. "Сәмруг кош" (1910) хикәясендә үтә европалашкан, "дөнья цивилизациясен" мыскылга калдырган милләт каһарманнарыннан көлә. "Мәрфугать" мәйданында очу ярышы булачак, имеш, шарты: егерме минут эчендә кояшка җитәргә, әле ул гына түгел, җиткәнлегенне белдерер өчен "кояшның тап уртасына кадак кагып бүреген элеп куярга" тиешле икән. Бу абсурд эшне милли герой Гайнетдин әфәнде Гайнелисламов иң соң иҗат иткән "Сәмруг кош" исемле машинасы белән гаять уңышлы башкарып чыга. Җыелган агай-эне кояшта чите кама белән әйләндергән очлы гына мескен бүрекнең асылынган көе торуын күреп чиксез кәефләнә. Бу көлүдә усал ирония бар, язучы вак-төяк адәмнәрнең үзләрен прогресс тоткалары итеп исәпләп, буш ыгы-зыгы белән мавыгуларын, мәгънәсез мин-минлекләрен, шапырынуларын фаш итә.

"Депутат" (1910) хикәясендә "Государственный дума" депутатының Петербургка бару күренеше тасвирлана. Үзенчә бик "выразительный" нотыгын вокзалда сөйләп халыкны шаккаттырырга җыенса да, сыңар тыңлаучы да таба алмый мыскылга калуы, вагонга кереп утыруга ук бөтен депутатлык вазифаларын онытып шәхси мәшәкать-уйларына чумуы үтемле сатирик алымда сурәтләнә.

"Көзге яңгыр астында" (1915) хикәясендәге Гайфулла исә үзен туташлар алдында эре һәм җитди күрсәтү өчен ясалма купшылык белән мавыгучы бер тип буларак характерлана. Үз дәрәҗәсенә хилафлык китермәс өчен ул тышкы сыйфатларына үтә игътибар итеп һәрдаим контрольдә булырга тырыша. Менә, "извозчик!"—дип кычкыра да: "Шактый эре чыкты бу. Якын-тирә кешеләр: "Бу егет бер дә генә җәяү йөрергә яратмый, күрәсең", дип уйласыннар өчен, ачуланган сымак мыгырданып килмәгән извозчикларны бер суккан дә булдым..." Менә кызлар белән сүз алышканда, "бусы бигрәк мужикча чыкты..." дип кәефсезләнә; бераздан үзен тагын акыллы, төпле кеше итеп хис итә дә бик канәгать кала: "Тавышымның тигезлегенме әйтерсең, сүзләрнең урынлыгынмы, һәммәсе аптека үлчәвендә, бигрәк тә мәгънә ягы муаффәкыятьле чыкты".

Кыскасы, хикәядә мәгънәсез мәшәкатьләр белән кайнашкан вак бәндәнең рухи

хәерчелеге фаш ителә.

Гомумән алганда, Ш. Камалның сатирик хикәяләрендәге геройлар "Хажи әфәнде өйләнә" (1915) комедиясендәге типларны тудыруда бер әзерлек булдылар, алардагы сыйфатлар тагын да калку һәм гротесклы тасвир алдылар.

Ш. Камал хикәяләрендә бәхет-бәхетсезлек, өмет-өметсезлек һәрвакыт янәшә йөриләр һәм бу каршылыклы бергәлек психологик киеренкелекне үстерә, әсәрнең тәэсир итү көчен арттыра. Әйтергә кирәк, эшчеләр темасына язылган хикәяләр язучыга күләмле әсәр иҗат итәр өчен әзерлек этабы булдылар. Аларда күтәрелгән тасвир-фикерләр, сурәтләнгән образлар "Акчарлаклар" (1914) повестенда яңа сыйфатлар, яңа чалымнар белән баетылган хәлдә тәкъдим ителәләр. Тормышның үзгәрергә тиешлегенә, кешенең бәхеткә омтылу идеалына ышаныч, чарасызларны, мохтажларны яклау идеясе бу әсәрдә киң планда һәм оптимистик пафоста раслана. Геройлар дөньясы кинәя, чынбарлыктагы иҗтимагый контрастлык тирәнәя.

Повестьта гади генә бер эпизод бар. Шәрәфи карт кәефе әйбәт чагында кызына бәйрәмгә таба читек алып бирергә вәгъдә итә. "Газизә:

—Әнкәй, кайсы бәйрәмгә таба ул?— диде.

Карчык аз гына уйлап торды да, күңелсез генә иттереп:

—Белмим, кызым...— диде.

Бәйрәмнәр ерак иде әле..."

Димәк, хыяллар тормышка ашачак бәйрәмнәр ерак икән, аңа барыр юл әлегә анык кына түгел, ул тарафны әлегә томан сарган. Язучы әллә ни әһәмиятле күренмәгән шундый эпизодлар белән укучыны уйланырга этәрә, зур социаль проблемалар чолганышына алып керә. Ни өчен Шәрәфи карт, башкалардан дәрәҗәсе, тәҗрибәсе белән аерылып торса да, ничәмә еллар буе зур хезмәт куеп хуҗаларны баетып яшәсә дә, мохтажлыктан арына алмаган, сасы балык базында гомере узган? Ни өчен Гариф, "сигезәр потлы капчыкларны уйнатып ала торган егет", сөйгәне Газизәне авылга алып кайтырлык та акча эшли алмаган? "Монда юллык та булмады ич", ди ул гарьләнеп. Ул бит—тырыш, унган, юкка гына иптәшләре аны артельщик итеп сайламаганнар; балык тотканда куркыныч тугач котырынган диңгезгә беренче булып ташланучы да ул бит. Ш. Камал әнә шулай укучысы белән бергә уйлана, сиздерми генә сабак бирә, мондый яшәү үзгәрергә тиеш дигән нәтиҗәгә алып килә. Шуңа аның геройлары да "Козгыннар оясында"гы кебек кара өметсезлеккә чумган адәмнәр түгел. Алар инде үз хакларын хаклап дауга әзерләнеп килүче кешеләр. Әсәрдә бер вакыйга бар: хуҗалар давыл вакытында ятьмә салырга мәҗбүр иткәч, көймәчеләр бик хәтәр хәлгә кала. Шунда ярдагыларның берсе иптәшләренә карап болай ди: "Әгәр көймә кайтмаса, әнә теге ике господинны буып суга ташламакчы булалар". Бу әлегә стихияле бунтка якын, әмма инде аларда киләчәктә бәхетләрен урлаганнарга каршы аңлы көрәшкә күтәреләчәк кешеләрнең чалымнарын да тоярга мөмкин.

* * *

Октябрьдән соңгы чорда әдип актив эшли. Оренбургта нәшер ителүче "Юл" һәм "Сабан" газеталарының редколлегия члены, аннары җаваплы редактор хезмәтләрен үти. Күпсанлы мәкалә, фельетон, хикәя бастыра. Язучы төрле темаларга мөрәҗәгать итә: "Эшче-крестьян матбугаты һәм укытучылар", "Советское строительство турында киңәш", "Авыл көнкүреш кооперацияләре", "Кулак кем?" һ. б. Егерменче еллар башында иҗат иткән хикәяләрендә дә Ш. Камал заманның яңа сулышын җиткерергә тели. Менә аның "Түләтергә исәпли" (1924) исемле хикәясе. Анда гомере буе дини йолаларны калдырмый үтәп килгән карт эшче беркөнне кинәт зур үзгәреш кичерә һәм мәчеткә бармыйча, клубка юнәлә. Шунда үзен күп еллар буе дин сөреме белән агулап килгән дин әһелләреннән әрәм узган елларын "түләтергә исәпли". "Хәйри—комсомол" (1924) хикәясендә яшүсмер егетнең, үсә төшкән саен, ни рәвешле сугышка һәм байларга карашының формалаша баруы бәян ителә. "Авыл матур уйлый" (1925) хикәясендә совет яклы крестьян (мәчетне клуб итү мәсьәләсендә башлап йөрүче) һәм аның делегатка хатыны образларында язучы матур тормыш төзүче яңа кешеләрне сурәтләргә омтыла. Бу әсәрнең дәвамы булган "Җыр тавышлары ишетелгәндә" (1926), "Адәм үсә" (1927) хикәяләрендә дә үз азатлыгы өчен генә түгел, башка крестьяннарның да тулы бәхете өчен көрәшүче заман геройлары тасвирлана.

Әмма болар барысы да берьяклы, схематик, декларатив характердагы шактый көпшәк язмалар һәм әсәрләр иде. Аларның кычкырып торган агитацион эчтәлеген күрми мөмкин түгел. Моныңише иҗат үрнәкләренең революциягә кадәр үк "Ўяну", "Козгыннар оясында" ише хикәяләре, "Акчарлаклар" кебек повесте белән татар дөньясында танылган Шәриф Камал каләменнән чыгуын кабул итүе дә читен.

Совет дәвере тәнкыйте, әдәбият белеме фәне тарафыннан уңай бәяләнүгә кара-

мастан, Ш. Камал үзе бу чор иҗатыннан бик үк канәгать калмаган булса кирәк. Язучының иҗади кыйбла эзләп Октябрьгә кадәр уныш казанган тема һәм образларга мөрәҗәгать итүе шундый фикер уята. Ш. Камал 1930 елда "Козгыннар оясында" хикәясенә нигезләнгән һәм шул исемдәге драмасын иҗат итә. 1927 елда "Акчарлаклар" повестеның дәвамы буларак "Таң атканда" романы дөнья күрә.

Әмма ул "Акчарлаклар" повестена караганда шактый кайтыш иҗат җимеше сыйфатында кабул ителә. Мондый хәл Ш. Камал кебек күренекле әдипләр иҗаты өчен генә түгел, ә бөтен бер татар әдәбиятына хас вәзгыять иде. Чор ситуациясен хәл кадәри тарихи-объектив күз алдына китерү өчен заман әдәби хәрәкәте шаһитына сүз бирү кулай. Фәтхи Бурнаш "Революция һәм татар әдәбияты" (1929) мәкаләсендә болай яза.

"Фатих Әмирхан, Дәрдмәнд, Сәгыйть Рәмиевләр революциядән соң бик аз һәм җөзә (өлеш—Ф. Б.) нәрсәләр калдырып, өчәве дә үлеп киттеләр.

Галимҗан Ибраһимов соңгы вакытларда бик җитди рәвештә авырып алды. Борынгы хезмәт урынына кайтару өчен берникадәр еллар дәваларга туры киләдер.

Г. Рәхим, Г. Газизләр, матур әдәбиятны ташлап, күптән тикшерү, гыйльми эшләргә киттеләр.

К. Әмири, С. Җәлал, М. Гали, Г. Камал, С. Сүнчәләй кебекләр соңгы елларда һичбер нәрсә бирмәделәр дияргә мөмкин.

Фатих Сәйфи әдәби хезмәтләрен ташлап идарә һәм җәмәгать эшләренә бирелде.

Кәрим Тинчурин "Җилкәнсезләр"еннән соң бернәрсә биргәне юк.

Мәҗит Гафури, Зариф Бәшири агалар соңгы елларда әдәбиятка өстәмә булырлык иҗатлар күрсәтмәделәр.

М. Фәйзи үлде.

Исәнбәт әле дә эшләп килә, ләкин соңгы елларда аның җитди хезмәтләре күренми.

Шәриф Камал хикәя һәм романнар бирүендә дәвам итә. Ләкин без югарыда аның иҗатындагы борынгы җанлылык, зәвык, матурлыкларның шактый кимеп барганын әйткән идек".

"Таң атканда" романы дөнья күргәндә Ш. Камалның Казан тормышы башлана. Ул биредә дә газаплы иҗади эзләнүләр алып бара, күп яза, үзен әдәбиятның төрле өлкәләрендә сынап карый. 1928-1934 еллар аралыгында әдип драматургия өлкәсендә актив эшли. Ш. Камалның Октябрьдән соңгы беренче пьесасы—"Ут" (1928) драмасы булды. Анда сыйнфый сизгерлеген югалткан, мәхәббәтендә алданган җитәкче кешенең трагик язмышы сурәтләнә: гражданнар сугышында каһарманлыклар эшләгән, тыныч тормышта трест белән идарә итү йөзендә сыйнфый дошман капкынына юлыгып, фаҗига кочагында кала.

Әдипнең "Таулар" (1931), "Томан арты" ("Габбас Галин", 1934) пьесалары да шундый эчтәлекле. Бу пьесалар үз заманы өчен актуаль проблемалар күтәргән драма әсәрләре итеп танылсалар да, һич тә "Хаҗи әфәнде өйләнә" комедиясе кебек озын гомерле була алмадылар һәм шул дәвернең иҗат үрнәкләре, язучының әдәби мирасыннан бер ядкарь сыйфатында тарих томанына күмелеп калдылар.

Утызынчы еллар уртасыннан Ш. Камал киң колачлы проза әсәре язуга керешә. Бу эшкә ныклап, зур әзерлек белән тотына. Әйтергә кирәк, ул чор— әдәби иҗат өчен гаять катлаулы, шомлы һәм хәвефле чор. Татар әдипләренең зур бер төркеме кулга алынган, күпләрнең язмышы кыл өстендә. Бу шартларда Ш. Камалга каләмдәшләре язмышын кабатламавын акларга да туры килде. Шуңа да ул үткәндәге иҗатына ревизия үткәрергә, социологизм таләпләреннән чыгып, элек язылган әсәрләренең кимчелеген күрсәтергә һәм "тәүбә итәргә" дә тиеш булды. 1938 елда дөнья күргән "Сайланма әсәрләре"нә язган "Сүз башы"нда әдип, башлыча, түбәндәгеләрне тезәргә мәҗбүр: "минем революциягә хәтле язылган әсәрләремдә сыйнфый каршылыклар йомшак чагылдырылган, сыйнфый көрәш моментлары бөтенләй томаланып калган". Аңлашыла ки, мондый шартларда кулына каләм алырга җөрьәт иткән һәр язучыдан икеләтә, өчләтә ихтыяр көче, рухи батырлык таләп ителә. Рәсми идеология әдәбиятта яңа эчтәлек, яңа геройлар таләп итә.

Традицион-классик стиль белән язылган әсәрләрдә тормышны эпик киңлектә, бөтен этнографик-көндәлек детальләр белән тасвирлап бирүдә, шул нигездә экспрессив-динамик хасиятләр булдыруда да чиксез мөмкинлекләр туа. Гәрчә, бу дәвер прозасының төп эчтәлеген сыйнфыйлык һәм фиркалелек принциплары буенча иҗат ителгән әсәрләр билгели башласа да, югарыдагы иҗат алымнарын инкяр итмәү язучыга унышлы иҗат үрнәкләрен тудырырга булыша. Бу үзенчәлекле күренешнен классик мисалы итеп Ш. Камалның совет чоры иҗатындагы иң күренекле әсәрләреннән берсе булган "Матур туганда" романын атарга мөмкин. Берничә томнан торачак зур эпопеяның беренче кисәге итеп планлаштырылган әлеге роман

1937 елда басылып чыга. "Матур туганда" үзе генә дә тәгалләнгән мөстәкыйль әсәр сыйфатында бәяләнергә хаклы. Романның үзәген тәшкил итүче коммуна оештыруга багышланган вакыйгалар ахырына кадәр тәгалләнеп бетә, куелган проблемалар әсәр дәвамында хәл ителә бара.

Романның төп проблемасы пролетариат әдәбияты дәгъвә иткән сыйнфыйлык кысасына уңай гына яраша ала. Исеменнән үк аңлашылганча, әсәрдә төп игътибар "матурның тууын", ягъни яңа тормышның искелек калдыклары белән бәрелештә җиңү тантанасын тасвирлауга юнәлтелә. Ш. Камал үзе дә әсәрнең темасын билгеләп, авылда һәм шәһәрдә барган сыйнфый көрәшне чагылдырырга теләвен әйтеп уза. Шул рәвешле, әсәрнең фабуласы капма-каршы идеологияне һәм позицияләрне бәрелештерүдән гыйбарәт булып кала. Бер тарафта яңа тормыш өчен көрәшүче ярлылар катлавы һәм аларны туплаучы җитәкчеләр—губком вәкиле Фәтхи, ячейка секретаре Мостафа, коммуна председателе Һидият. Каршы якта Садыйк хаҗи, аның улы Әмирҗан, ак офицер Чуркин, кулак Хөснуллин. Һәм, ниһаять, ике тараф арасында буталып, кыйбласын тапмый адашып калган "гидай" Нәгыйм. Вакыйгалар барышына баглы рәвештә ситуацияләр куера, атмосфера кыза. Роман котылгысыз булган коралы бәрелештә коммунарларның банданы тар-мар итүе белән тәгалләнә.

1939-1940 елларда "Совет әдәбияты" журналында "Матур туганда" әсәренең дәвамы булган "Ныклы адымнар" романы басыла башлый. Биредә вакыйгалар шәһәргә күчә, язучының үткен каләме белән катлаулы НЭП чоры картиналары җанлана. Әмма башланып киткән сугыш, язучының авыруы һәм үлеме әсәрне тәгалләргә мөмкинлек бирми. Шунысы игътибарга лаек: Ш. Камал, гәрчә хакимият таләп иткән штампларга ярашлы композиция кулланса да, характерлар һәм типлар тудыруда схемачылыктан күпмедер дәрәҗәдә котыла алды. Әсәрдәге тискәре геройлар, заман әдәбиятында киң таралган алым буенча, көлке, яки җирәнгеч карикатур типлар түгел, ә җанлы һәм тормышчан булулары белән аерылып торалар. Аларның кайбер гамәлләре хуплауга да лаек. Шуның белән бергә уңай геройлар да аерым кимчелек һәм хаталардан азат түгелләр. "Акчарлаклар" повестендә сынау узган язучы каләме "Матур туганда" романында да тормышны бар катлаулыгы белән күрсәтү җәһәтеннән җитди уңышларга ирешә алды. Шулай да тану кирәк: идеологик аспектны алгы планга чыгарып, сыйнфыйлык һәм партиялелек принципларына өстенлек бирү әсәрнең сәнгатьлелек дәрәҗәсенә зур зыян ясады. Ф. Бурнашның алда карап үткән мәкаләсендәге Ш. Камал иҗатындагы "борынгы җанлылык, зәвык, матурлыкларның кимеп" баруы хакындагы фикере белән килешми мөмкин түгел.

Эчтәлекне агитацион максатка буйсындыру талантлы каләм белән язылган әсәрнең дә сәнгатьлелек дәрәҗәсен арзанайтуга, сюжет кысасына коры дидактизмның үтеп керүенә сәбәп булды. Әйтергә кирәк, бу хәл заман әдипләренең хатасыннан битәр, бәласе иде.

Ш. Камал зур иҗади планнар белән яши. Ул киң колачлы трилогия язу өчен актив рәвештә материал туплавын дәвам итә. Каләмдәш дусларына да еш кына әйтә торган булган: "Миңа озак яшәргә кирәк, язачак әсәрләрем күп минем". Әмма рәхимсез үлем һич көтмәгәндә аның олы максатларына балта чаба. Үлемсез "Акчарлаклар"ның авторы 1942 елның 22 декабрендә кинәт вафат була.

Хәер, чын каләм әһелләренең гомере еллар кысасына гына сыя алмый. Чын әдипләрнең гомере халык хәтере белән исәпләнә. Тукай, Әмирхан, Исхакыйлар кебек... Дәрдмәнд, Ибраһимов, Г. Камаллар сыман... Шәриф Камалның мәңге тере геройларында да без язучының үзенең яшәвен тоябыз. Хәсән Туфан бер шигырендә болай дип әйткән иде: "Ш. Камал булса да үзе, Тукайга тугандыр ул..."

Шулайдыр ул!

**Фәрит БӘШИР**,
*филология фәннәре докторы*

# 68—КАЛӘМ ( КАЛӘМ) СҮРӘСЕ

*(Каләм сүрәсе 52 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Нун сүрәсе, дип тә йөртәләр.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Нун. Изге каләм белән язылган изге сүзләрне әйтеп, ант итәмен ки: **(2)** *(Ий, Мөхәммәд)* Раббыңның рәхмәте илә син һич тә тиле түгелсең. **(3)** Шик юктыр ки, синең өчен бетмәс-төкәнмәс әҗерләр бар. **(4)** Һәм син, әлбәттә, югары-саф әхлакка ия кеше. **(5, 6)** Кайсыларыгызның тилергән икәнлеге озакламый күренер, алар да күрер. **(7)** Хактыр ки, Раббың тугры юлдан язган кешене бик яхшы белеп тора, тугры юлга барганнарны да белә. **(8)** Шулай булгач, *(Хакыйкатьне)* ялганга чыгарганнарга буйсынма. **(9)** Алар синең күндәм булуыңны теләр, үзләре дә сиңа күндәм мөгамәләдә кебек булыр *(Алар синең җайлаганыңны-майлаганыңны тели, үзләре дә сине җайлап-майлап, үз диннәренә кертергә маташыр.)* **(10)** Һәр ант итүчегә дә ышанма. **(11)** Ялачыга, гайбәтчегә, тырнак астыннан кер эзләүчегә ышанма. **(12)** Игелеккә комачаулаганга, муеныннан гөнаһка батканга ышанма. **(13)** Рәхимсез, нәселсез әтрәк-әләмгә ышанма. **(14)** Хәтта аның байлыгы һәм нәселе үрчемле булса да, аңа буйсынма. **(15)** Андый кешегә аятьләребезне укыганда, ул:

–Әби-баба әкиятләре бу,–дип торыр.

**16.** Озакламый Без аның борынын кисәчәкбез *(кикриген шиңдерербез).*

*(«Чыннан да, Бәдер сугышында Вәлид исемле кяфернең борынын кылыч белән кисеп төшерәләр».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**17.** Бервакыт Без бакча тотучыларны *(Мәккә кяферләренә)* бәла китереп сынаганыбыз кебек, боларны да бәла китереп сынадык. Ничек итеп алар *(бакча ияләре)*: иртәнге якта *(һичкем күрмәгәндә)* җимешләрне җыеп алырбыз, дип сүзләштеләр. **(18)** Ләкин алар: Аллаһ боерса, иншалла, мохтаҗларга да бирербез, димәделәр. **(19)** Тик алар йокыда чагында Раббы тарафыннан җибәрелгән дәһшәтле ут өермәсе бакчаны камап алды. **(20)** Бакча кап-кара көл булып калды. **(21)** Икенче көнне иртән кардәшләр бер-берсенә: **(22)**

–Мул уңыш җыеп аласыгыз килсә, бакчага иртүк торып барыйк,–диделәр һәм **(23)** үзара сөйләшә-сөйләшә бакчага киттеләр. **(24)**–Бакчабызга бүген бер генә хәерче дә керергә өлгермәсен. **(25)**

*(Юксылларга ярдәм итәрлек)* көчләре булса да, аларны ярдәмнәреннән мәхрүм итәргә ниятләделәр. **(26)** Бакчага килеп баксалар, шаккаттылар *(бакчаларын танымадылар)*:

–Ихтимал, без ялгыш юлдан киткәнбездер,–диделәр. *(Ялгыш түгеллеген аңлагач, алар)*: **(27)**

–Юк, юк! Без дә мәхрүм калдык,–диделәр. **(28)** Араларыннан акыллырагы әйтте:

–Мин сезгә, Аллаһ теләсә, иншалла, дип әйтергә кушмадыммы?–диде.–Аллаһка тәсбих әйтик, димәдемме? **(29)**–Әлхәмдүлилләһ, без үз башыбызга үзебез язык алдык,–диделәр.

**30.** Аннан соң алар гаепне бер-берсенә аударырга тотындылар. **(31)** Ниһаять, әйттеләр:

–Кайгы төште башыбызга, чыннан да, без хәттин ашкан азгыннар икәнбез,–диделәр. **(32)**–Бәлки, Аллаһ монысы урынына тагын да яхшырак уңыш бирер! Чөнки без тәүбә иттек. Раббыга юнәлдек.

**33.** Менә бусы дөнья газабы булды сезгә. Ахирәт газабы исә, һичшиксез, моннан да хәтәррәк булыр. Их, әгәр дә алар бу турыда белсә иде! **(34)** Хактыр ки, саф мөселманнар өчен Раббы катында нигъмәтләре чиксез мул булган җәннәтләр бар. **(35)** Аллаһка итагатьтә булганнар белән гөнаһкярларны тигез күрербезме? **(36)** Сезгә ни булды? Ни дәрәҗәдә фикер йөртәсез? **(37)** Әллә сезгә кагылышлы берәр китап бармы кулыгызда, *(гөнаһ кылырга)* сез шул китаптан өйрәнәсезме? **(38)** Сез теләгән һәрнәрсә, һичшиксез, булачак, дип язылганмы анда? **(39)** Кыямәт көненә чаклы ни теләсәк, шуны кылырга хакыбыз бар, дигән килешүегез бармы Аллаһ белән? **(40)** Син *(Мөхәммәд)* алардан сора:

–Шундый килешү бар, дип кайсысы раслый ала икән? **(41)** Әллә аларның кодрәтле башка дуслары бармы? Алар хаклы булса, *(Аллаһтан да)* кодрәтле шул дусларын монда китерсеннәр. **(42)** Ул Көн килеп җиткәч, балтырлар ачылыр *(яшерен эшләрнең, гөнаһларның өстеннән пәрдә алыныр)* һәм сәҗдә итәргә чакыру булыр, ләкин алар *(кяферләр)* сәҗдәгә бөгелә алмас.

**43.** Хурлыктан карашлары аска төбәлгән хәлдә калырлар. Гәрчә, алар сау-сәламәт булган хәлдә дә сәҗдәгә чакырылган иде, ләкин алар сәҗдәгә иелергә теләмәгән иде. *(Хәзер, теләсәләр дә, иелә алмыйлар.)*

**44.** *(Ий, Мөхәммәд)* син бу сүзне *(Коръәнне)* ялганга чыгарган кяферләрне Минем өлешкә калдыр. Без искәрмәгән яктан, әкрен-әкрен генә аларны газапка тарта барырбыз. **(45)** Без аларга *(бирәсе җәзабызны)* озакка кичердек. Хакыйкать шулдыр ки, Мин корган тәдбирләр какшамас. *(Җәза барыбер бирелер.)* **(46)** Син алардан түләү хакы сорыйсыңмы, юкса? Шуның аркасында алар бурычка батканмы? **(47)** Яшерен серләрне белү гыйлеме алар кулындамы, юкса? Ул гыйлем китабын алар язамы? **(48)** Син Раббыңның хөкемен түземлек белән көт. Балык карынындагы *(Юныс)* кебек булма. Исеңдәме, ничек итеп ул *(тынчулыктан, тарлыктан зарланып)* Аллаһка ялварган иде. **(49)** Әгәр дә аңа Раббысыннан ярдәм килеп ирешмәгән булса, ул, һичшиксез, бичара хәлдә, хур ителеп, ярга чыгарып ташланган булыр иде. **(50)** Ләкин соңыннан Раббы аны сайлап алды вә изгеләр сафына куйды.

**51.** Ул инкарьчылар, Коръән укыган вакытында карашлары белән булса да, сине ялгыштырырга тырышыр. *(Эшләре барып чыкмагач)*:

–Көн кебек ачыктыр ки, ул тилергән,–дип әйтерләр.

**52.** Коръән бары тик галәмнәргә хәбәр бирүче вәгазьләрдән тора.

## 69—ХАККА (КОТЫЛГЫСЫЗЛЫК) СҮРӘСЕ

*(Хакка сүрәсе 52 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Кыямәт көненә Хакка дип тә әйтәләр. Ягъни, Кыямәт хакыйкать буларак, хак–чынбарлык буларак, котылгысыз киләчәк. Хаклыкның, дәреслекнең тантана итә торган котылгысыз көне–Кыямәт булачак.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Котылгысыз рәвештә тормышка ашачак Хакыйкать көне! **(2)** Нинди була ул Хаклык тантана итә торган котылгысыз көн? **(3)** Бу турыда сиңа кем, ни-нәрсә хәбәр итте? *(Аллаһтан башка һичкем хәбәр итә алмас.)*

**4.** Сәмуд белән Гад халыклары Кыямәтне *(Хакыйкать көнен)* инкарь итте. **(5)** Сәмуд халкы гадәттән тыш каты гөрелте *(зилзилә)* белән һәлак ителде. **(6)** Гад халкы

исә котчыккыч үкерә торган, хәтәр давылда һәлак булды. **(7)** Аллаһ аны *(каты давылны)* җиде төн, сигез көн буена туктатмады. *(Әгәр син анда булса идең)* ул халыкның бер мизгел эчендә эче куыш агачлар кебек, кырылып ауганын күрер идең. **(8)** Ичмасам, исән калган бер кеше күрерсеңме?

**9.** Фиргавен дә, аннан алдагылар да, асты өскә килгән калаларның халыклары да шушы хатаны кабатладылар *(ягъни, Аллаһны, Коръәнне, пәйгамбәрләрне санга сукмадылар, шуның аркасында гөнаһка баттылар).* **(10)** Шулай итеп, алар Раббының пәйгамбәрләренә каршы баш күтәрде. Шуңа күрә, Аллаһ та аларны дәһшәтле җәзага тартты.

**11.** Хактыр ки, дөньяны су баскач, Без сезне *(борынгы бабаларыгызны)* көймәгә утыртып, коткардык. **(12)** Бу эшне Без киләчәк буыннарга кисәтү һәм сабак булсын, колаклары ишетеп, хатирә итеп сакласын, дип башкардык.

**13.** Сур быргысына беренче тапкыр өрелгәч *(бөтен кешеләр дә үлеп бетәр, галәм харап булыр),* **(14)** Җир үзе дә, таулары да урыннарыннан күчеп, бер-берләренә бәрелеп, тузан хәленә килер. **(15)** Менә шул көн Кыямәт булыр. **(16)** Күк урталай ярылыр. Ул көнне Күкнең терәге булмас *(гравитацион көчләр юкка чыгар).* **(17)** Фәрештәләр аның *(Күкнең)* әйләнә-тирәсендә булыр. Ул көнне Аллаһның Гарешен *(тәхетен)* сигез фәрештә күтәрер. **(18)** Ул көнне сез *(хисап, җавап өчен)* Аллаһның хозурына китерелерсез. Ул көнне һичбер сер яшеренеп калмас. **(19)** Китабы уң кулына бирелгән *(мөэмин)* кеше әйтер:

–Алыгыз минем китапны, алыгыз да укып багыгыз. **(20)** Мин, чыннан да, *(Кыямәт көнендә)* хисап тотачагымны белеп яшәдем дөньяда,–дияр. **(21)** Бу кеше Сәгадәткә ирешер. **(22)** Югары җәннәткә керер. **(23)** Җимешләре үрелеп алырлык якында гына булыр. **(24)** Аларга:

–*(Дөньяда)* яшәгәндә кылган игелекләрегезгә күрә, рәхәтләнеп ашагыз-эчегез!–дип әйтелер.

**25.** Китабы сул кулына бирелгән *(кяфер)* кеше дә әйтер:

–Аһ, китабым миңа бирелмәгән булса, яхшырак булыр иде. *(26)* Аһ, бу хисапларны тотмаса идем. **(27)** *(Дөньядагы үлемем)* соңгысы булып *(яңадан терелмәгән булсам).* **(28)** Байлыгым миңа бер файда да бирмәде. **(29)** *(Бөтен)* патшалыгым *(хакимиятем)* кулдан китте,–дип үкенеп үкерер. **(30)** *(Аллаһ боерыгы яңгырар):*

–Тотыгыз да аны богаулагыз! **(31)** Аннан соң аны дөрләп янган ялкынлы утка атыгыз! **(32)** Аннан соң аны җитмеш аршын озынлыгындагы чылбыр белән урагыз. **(33)** Чөнки ул бөек Аллаһка ышанмады. **(34)** Мохтаҗларга ризык бирмәде *(һәм бирдермәде).* **(35)** Шуңа күрә, бүген монда *(Кыямәттә)* аны кызганучы бер генә дусты да юк. **(36)** Гослин дигән эчемлектән башка эчәренә су да булмас. **(37)** Гөнаһкярлардан башкасы ул гослинне эчмәс.

*(«Гослин» исемле бу эчемлек турында Х. Чантай китабында болай язылган: «Җәһәннәмдә кайналучыларның канлы эреннәре. Бәгъзеләре аны «юынтык, шакшы су», дип тә шәрехли. Әлбәттә, монда күчермә мәгънәдәге бер символика бардыр».)*

**38.** Күзегез белән күргәннәрегез *(Күкләр, Җир, дәрьялар)* белән, **(39)** күзегез белән күрмәгән *(фәрештәләр, рухлар, матдә кисәкчекләре)* белән ант итеп әйтәмен ки: **(40)** һич шик-шөбһә булмасын, Ул *(Коръән)* иң мәртәбәле илчем *(Җәбраил)*нең җиткергән сүзедер. **(41)** Ул *(җенле)* шагыйрь язган китап сүзе түгел. Сез әле һаман да ышанмыйсыз! **(42)** Ул бер күрәзәче сүзе дә түгел. Сез әле һаман да ышанмыйсыз! **(43)** Ул *(Коръән)* галәмнәрнең Раббысы тарафыннан иңдерелде! **(44)** Әгәр дә *(Пәйгамбәр Без әйтмәгән сүзне)* Безгә каршы үзлегеннән уйлап чыгарган булса иде, **(45)** әлбәттә, Без аны уң кулсыз калдырган булыр идек. **(46)** Аннан соң Без аның йөрәк тамырын буар идек. **(47)** Сезнең берегез дә Мине бу эштән тыя алмаган булыр иде. **(48)** Шик юк ки, Ул *(Коръән)* гөнаһлардан курыкканнар өчен катгый вәгазьдер. **(49)** Белеп торыгыз ки, сезнең арада *(Коръәнне)* ялганга санаучылар да бар. **(50)** Хактыр ки, *(Коръән)* кяферләргә хәсрәт ташучы Китап. **(51)** Шик юк ки, *(Коръән)* Хакыйкатьнең үзедер. **(52)** Шулай булгач, бөек Раббыбызның исемен тагын да югары күтәрер өчен гыйбадәт кылыгыз. Аңа тәсбих әйтегез!

*Безнең календарь*

## Фәрит Яруллинның тууына 90 ел

Татарның мәшһүр композиторы Фәрит Яруллин 1914 елның гыйнвар аенда Казанның Суконный бистәсендә дөньяга килә. Аның әтисе Заһидулла Яруллин—халык музыканты, беренче татар кыллы оркестрын оештыручы, композитор буларак, үзе дә байтак кына җыр һәм инструменталь пьесалар, мәшһүр "Тукай маршы" авторы.

Тәүге музыкаль белемне Фәрит Яруллин әтисеннән ала. Аннары, 1930 елда ул Казан сәнгать техникумына укырга керә. Башта виолончель буенча, тора-бара, шуңа өстәп махсус фортепьяно классында да белем ала башлый. Техникумда уку елларында ук ул Татарстанның музыкаль мәдәниятына нигез салучыларның берсенә әверелә. Үзешчән хор түгәрәкләрен оештырып, аларга җитәкчелек итә, яңа ачылган яшьләр театрында, сүзсез кинофильмнарда музыка башкара.

1933 елда Фәрит Яруллин Мәскәү консерваториясенең татар опера студиясенә укырга керә. Биредә ул композиция буенча мәшһүр профессор Г.И. Литинскийда белем ала, бу остазы аның дустына әверелә. Мәскәүдә уку елларында (1934—1939) егет чын мәгънәсендә һөнәрмәнд композиторлык осталыгына өйрәнә, үзе дә җырлар, романслар, инструменталь миниатюралар яза башлый. Ә зур күләмле әсәрләрдән: виолончель һәм фортепьяно өчен соната, кыллы квартет һәм симфония иҗат итә, "Зөлхәбирә" операсын язарга керешә. Әнә шулай үзен музыкаль әсәрләрнең төрле жанрларында сынап карау яшь композиторның иҗади үсешенә шифалы йогынты ясый. Иң мөһиме: аның көйләренә генә хас үзенчәлекле моң һәм чалымнар пәйда була. 1937—1938 елларда исә аның күңелендә Габдулла Тукайның "Шүрәле" әкият-поэмасын көйгә салу теләге туа. Шагыйрь Әхмәт Фәйзи белән очрашу, аралашу аның бу теләген тагын да ныгыта. Ниһаять, 1941 елның җәендә автор "Шүрәле" балетының каралама нөсхәсен балетмейстер Л. В. Якобсонга тапшыра һәм балетны сәхнәләштерү эшләре башланып китә. Әмма балет сәхнәгә күтәрелә алмыйча кала—сугыш башлана. "Шүрәле" авторы Фәрит Яруллинны да, армиягә алып, башта Ульяновск пехота училищесына өч айлык хәрби өйрәнүләргә, аннары исә сугыш кырына җибәрәләр. 1942 елда ул очраклы рәвештә дусты-остазы Генрих Литинский белән очраша. Танылган профессор Фәрит Яруллинны Мәскәү консерваториясенең хәрби-дирижерлык факультетына күчерү хакында югары командованиегә үтенеч хаты яза. Әмма ләкин, бюрократик киртәләрне кичеп рөхсәт хаты килеп җиткәндә, татар композиторын янәдән фронтка озаткан булалар... Озак та үтми, аяусыз бәрелешләрнең берсендә ул һәлак була. Хәбәрсез югалучылар исемлегендә йөргән сугышчы-композиторның кабере исә фәкать кырык елдан соң гына ачыклана.

Фәрит Яруллин—татарның беренче милли балетын тудырган шәхес. Аның "Шүрәле" балеты 1945 елдан алып Казанда, Мәскәүдә генә түгел, ә Советлар Союзын тәшкил иткән республика башкалалары театрларында да, Болгария, Румыния, Германия кебек илләрнең мартәбәле сәхнәләрендә дә уйналды һәм уйнала килә.

Татарның мәшһүр композиторы Фәрит Яруллинның иҗаты һәм тормышы хакында язучы Рашат Низамиев "Ут һәм җыр" дип исемләнгән роман-хроника иҗат итте.

## *«Казан утлары» архивыннан*



*Бауман урамындагы Матбугат йорты балконында бер төркем язучылар. Сулдан уңга—Нәби Дәүли, Сәрвәр Әдһәмова, Баян Гыйззәт, Хәсән Хәйри, Хәсән Туфан, Ибраһим Гази, Гомәр Бәширов (Ибраһим Гази белән сөйләшеп тора), Әнвәр Давыдов. 1965 ел.*



*Язучы Нурихан Фәттах. 1985 ел.*



*Язучы Габдрахман Әпсәләмовны соңгы юлга озату. Табут янында басып торалар—Фикрәт Табиев (КПСС өлкә комитетының беренче секретаре), Салих Батиев (Татарстан Югары Советы рәисе). 1979 ел.*



*Баш мөхәррир бүлмәсендә әңгәмә. Сулдан уңга—Нури Арсланов, Кояш Тимбикова, Сибгат Хәким, Зәки Нури. 1980 ел.*



*Шагыйрь һәм публицист Рахмай Хисмәтуллин. 1995 ел.*



*Шигырь бәйрәме көне истәлеге. Алгы планда—язучылар Мөсәгыйть Хәбибуллин һәм Вакыйф Нуруллин. 1989 ел.*

*Берлекнең яңа әгъзалары*



## Хуҗи Мәхмүтов

Мәхмүтов Хуҗиәхмәт Шаһиәхмәт улы 1933 елда Татарстанның Мамадыш районы Түбән Ушмы авылында крестьян гаиләсендә туа. Өлгергәнлек аттестаты алгач, ике ел авыл мәктәбендә укыта. Казан университетында татар филологиясе бүлегендә укыганда республика матбугатында аның беренче шигырьләре, рецензияләре басыла башлый. "Җыр һаман яңгырый" ("Совет әдәбияты", 1956), "Моабит шигырьләренең вариантлары", "Фәтхи Бурнаш" ("Татарстан яшьләре", 1957) кебек мәкаләләре яшь авторның каләме өметле булуын күрсәтә. Соңрак ул проф. Хатип Госман җитәкчелегендә "Фәтхи Бурнаш поэзиясе" дигән темага диплом эше яклый.

Студент чагында ук Хуҗиәхмәт өч ел рәттән Тел, әдәбият һәм тарих институты оештырган фольклор экспедицияләрендә катнаша, ике елдан артык университетның тел һәм әдәбият кафедрасында өлкән лаборант булып эшли. Бу абруйлы уку йортын кызыл диплом белән тәмамлагач, Буа шәһәренә китеп, анда чыга торган "Яңа юл" (хәзер: "Байрак") газетасында әдәби хезмәткәр, җаваплы сәркатип, бүлек мөдире вазифаларын башкара.

1966 елдан бирле Х. Мәхмүтов Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих (хәзер: сәнгать) институтының халык иҗаты бүлегендә эшли. Биредә ул аспиранттан алып баш гыйльми хезмәткәргә кадәр үсү юлы үтте, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклады. Аның даими шөгыльләнә торган өлкәсе—фольклорның афористик жанрлары, ягъни ул чын мәгънәсендә халык иҗатының энҗе-мәрҗәннәре белән эш итә. "Кечкенә дә төш кенә", "Афористические жанры татарского фольклора", "Язылмаган кануннар" кебек монографияләреннән ачык күренгәнчә, галим бу төр әсәрләрнең тирән хикмәтен, нәзберек шигъриятен нечкә тоемлап яза. Х. Мәхмүтов егермедән артык китап, 600 ләп мәкаләләр авторы. Ул хөкүмәтебез тарафыннан Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән билгеләп үтелгән 12 томлык "Татар халык иҗаты" җыелмасын матбугатка әзерләүгә зур өлеш кертте: бу фундаменталь басманың редколлегия әгъзасы, биш томның фәнни мөхәррире булды, ә "Табышмаклар", "Мәзәкләр", "Мәкальләр һәм әйтемнәр" томнарын турыдан-туры үзе төзеде, аларга тирән эчтәлекле кереш мәкаләләр һәм фәнни искәрмәләр язды.

Үзенең "Мәңгелек ядкяр", "Борынгылар әйткән сүзләр" дигән китапларында Х. Мәхмүтов VIII—XVII йөзләрнең төрки язма һәйкәлләрендә сакланып калган афористик гыйбарәләрне барлап, бүгенге татар мәкальләре белән чагыштырып чыкты, алар арасындагы традицион бәйләнешләрне ачыклады. Үзенең мондый тикшеренүләре белән ул алты томлык "Татар әдәбияты тарихы"ның беренче томында һәм вузлар өчен чыгарылган "Борынгы төрки һәм татар әдәбиятының чыганаклары" исемле дәреслек-хрестоматиядә дә катнашты.

Х. Мәхмүтовның каләменә гыйльми дә, үтемле һәм кызыклы да итеп язу сыйфаты хас. Аның "Ел тәүлеге—12 ай", "Канатлы сүз—хикмәтле сүз" кебек китапларындагы бүлекләр мавыктыргыч әдәби парчалар кебек укыла, шуның белән белгечләрнең генә түгел, киң катлау укучыларның да игътибарын җәлеп итә.

Галим һәм әдип буларак, Х. Мәхмүтов төрле фәнни, гамәли конференцияләр эшендә актив катнаша, инде 30 елга якын радиодагы "Тел күрке—сүз" тапшыруының даими авторларыннан берсе булып тора. Ул—Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Халыкара Төрки академиянең хакыйкый әгъзасы.

Узган елның 26 декабрендә Кабул итү Коллегиясе карары нигезендә (рекомендация бирүчеләр: А. Әхмәдуллин, З. Мансуров, Ф. Урманче) Язучылар берлеге Идарәсе Мәхмүтов Хуҗиәхмәт Шаһиәхмәт улын Татарстан Язучылар оешмасына әгъза итеп кабул итте.



## Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### МӘДӘНИЯТКА МӘДХИЯ

18 декабрьдә Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концерт залында Татарстан Мәдәният министрлыгының төзелүенә 50 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды.

Татарстан соңгы елларда Россия мәдәни тормышы үзәкләренең берсенә әверелә бара. Республикада мәдәни эшчәнлекне тәэмин итүче дәүләт институтлары системасын саклап калу, шулай ук аларны үстерү базасын булдыру мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтенең бик әһәмиятле максаты булып тора, дип күрсәтеп узды Татарстан мәдәният министры Илдус Тарханов. Бүген республиканың мәдәни тормышын традицион фестиваль һәм конкурслардан башка күз алдына китереп булмый. Егерме елдан артык инде Ф. И. Шаляпин исемендәге Халыкара опера фестивале уздырыла. Россиядә бердәнбер шундый фестиваль бу. Р. Нуриев исемендәге балет фестивален, "Европа-Азия" Халыкара хәзерге заман камера музыкасы фестивален, "Нәүрүз" Халыкара төрки халыклар фестивален, "Хор ансамбльләре"н уздыру, "Пианофорум"ны, И. Шакиров исемендәге Халыкара татар җырын башкаручылар конкурсын, С. Сәйдәшев исемендәге яшь башкаручылар төбәк конкурсын һәм башка чараларны уздыру традициягә әверелде.

Кичәдә катнашкан Татарстан Премьер-министры Рөстәм Миңнеханов атказанган мәдәният эшлеклеләренә, артистларга, тармакның күп кенә хезмәткәрләренә ТР Президентының Рәхмәт хатларын, мактаулы исем бирелү турындагы документларны тапшырды.

Тантаналы кичәдә Татарстан Премьер-министры урынбасары Зилә Вәлиева, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Роберт Миңнуллин һәм башкалар катнашты.

### ЯҢА ЛАУРЕАТЛАР

Яңа ел алдыннан гына Татарстан Президенты М. Шәймиев "Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Репсубликасының 2003 елгы Дәүләт премияләрен бирү турында" Указга кул куйды.

Бу премияләр ел саен гуманитар, табигать һәм техник фәннәрне үстерү, принципиаль яңа технологияләрне эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга зур өлеш керткән, фән һәм техника казанышларын файдаланып, югары нәтиҗәләргә ирешкән галимнәргә бирелә.

2003 елда Татарстан Республикасы Дәүләт премиясенә 8 хезмәт лаек дип табылды. Гуманитар фәннәр өлкәсендә исә әлеге премиягә "Татарлар" монографиясе өчен Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты галимнәре Рәүфә Уразманова, Дамир Исхаков, Розалина Мусина, Светлана Суслова, Наил Халиков, Татар фольклорын җыю, саклау, өйрәнү һәм пропагандалау дәүләт үзәгенен фәнни хезмәткәре Рәмзия Мөхәммәдова; "Татарстан: тел симметриясе һәм асимметриясе" дигән монографиясе өчен В. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты галимәсе Луиза Бәйрәмова лаек булды.

### ЯНӘ ЛАТИН ИМЛЯСЫ ТУРЫНДА

24 декабрьдә ТР Дәүләт Советының Фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссиясенең Татарстан Республикасы Конституциясенең 4 һәм 8 маддәләренә аңлатма бирү турындагы запросы уңаеннан ТР Конституция суды карары игълан ителде.

Мөрәҗәгать итүнең сәбәбе—ТР Конституциясе маддәләрендә латин графикасы нигезендә татар әлифбасын билгеләү өчен хокукый нигезнең, һәм әлеге мәсьәләнең республика карамагында гына булу-булмавында билгесезлек. РФ Конституциясе нигезендә, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарында, массакүләм мәгълүмат чараларында һәм вакытлы басмаларда, мәдәният өлкәсендә, РФ дәүләт теле белән беррәттән, алфавитларын республикаларның үз дәүләт телләрендә билгеләргә хокукы бар. Мөрәҗәгать итүчеләр фикеренчә, әлеге законнар нигезендә республикалар үз дәүләт теленең график нигезен мөстәкыйль рәвештә билгеләүгә хокуклы.

ТР Конституция суды бу җәһәттән карар кабул итте. Анда, аерым алганда, дәүләт теле буларак, татар теле әлифбасының график нигезен билгеләү, шул исәптән, татар теле әлифбасын латин графикасы нигезендә торгызу Татарстан Республикасы карамагына керә, диелә. Бу хокук, Россия Федерациясе республикаларының үз дәүләт телләрен билгеләүгә конституцион хокукының состав өлеше буларак, Татарстан Республикасының дәүләти-хокукый статусының мөһим элементы булып тора, һәм ул федераль конституцион хокук нигезендә ТР һәм РФнең үзара килешенүе белән генә юкка чыгарылырга мөмкин.

### ТЕАТРДА ӨЙ ТУЕ

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин җитәкчелегендәге парламент делегациясе Уфада булды. Башкортстан башкаласында Башкортстан Дәүләт Җыены һәм

Татарстан Дәүләт Советы арасында алга таба хезмәттәшлек итү турындагы беркетмәгә кул куелды.

Татарстан парламенты Русия субъектларының законнар чыгару органнары белән хезмәттәшлек турында 25 килешүгә кул куйды. Очрашуда Ф. Мөхәммәтшин искәртеп узганча, ТР Дәүләт Советы белән Башкортстан Дәүләт Җыены арасында 1997 елда төзелгән килешү—ин нәтиҗәлесе.

Шул ук көнне Башкортстан башкаласы үзәгендә "Нур" татар дәүләт театрының зур залын ачу булды. Коллективны котлап, Башкортстан Президенты М. Рәхимов, Уфа хакимияте башлыгы П. Качкаев, Башкортстан татарлары конгрессы башкарма комитеты рәисе Э. Хәмитов һ. б. чыгыш ясады.

Дәүләт Советы Рәисе Татарстан Президенты М. Шәймиевнең котлау хатын укып үтте.

—Бу—театр коллективы өчен генә түгел, ә Башкортстанда яшәүче барлык татарлар өчен дә көтеп алынган вакыйга,— дип дәвам итте сүзен Ф. Мөхәммәтшин. —Ике тугандаш халыкның бөек дуслыгын бернинди сәяси давыллар һәм сынаулар да какшата алмады, һәм Уфа үзәгендә татар театрының яңа бинасын ачу бу дуслыкның нәтиҗәсе турында сөйли.

Татарстан парламенты татар театры коллективына "Газель" микроавтобусы бүләк итте. Әлеге тантанада, Татарстан парламентчыларыннан тыш, ТР мәдәният министры И. Тарханов, Камал театры директоры Ш. Закиров һәм баш режиссер Ф. Бикчәнтәев җитәкчелегендә Академия театры артистлары да катнашты.

## РЕДКОЛЛЕГИЯ УТЫРЫШЫ

30 декабрьдә "Казан утлары" журналының киңәйтелгән редколлегия утырышы үткәрелде. Анда редколлегия әгъзалары һәм журнал хезмәткәрләре катнашты. Журналның 2003 елдагы эшчәнлеге турында баш мөхәррир Равил Фәйзуллин кыскача хисап тотты. Утырышта узган елда журналда басылган төп әсәрләр, әдәби хәрәкәттә аларның урыны, үзенчәлекләре, гомумән, әдәбиятының үсеш тенденцияләре турында сүз барды. Чыгыш ясаучылар—драматург Туфан Миннуллин, шагыйрь Гәрәй Рәхим, язучы Зиннур Хөснияр, галимнәр—Миркасыйм Госманов, Фоат Галимуллин, Хатыйп Миңнегулов, сәнгать белгече Розалина Шаһиева һ. б. журнал эшчәнлеген яхшырту турында фикерләре белән уртаклаштылар, эшлекле тәкъдимнәр әйттеләр. Чыгыш ясаучылар журналның узган елдагы эшен, нигездә, уңай бәяләделәр, тиражның чагыштырмача канәгатьләнерлек булуын билгеләп үттеләр. Редколлегия әгъзалары "Казан утлары"ның 2004 елга билгеләнгән перспектив планы белән дә таныштылар һәм аны хупладылар.

## ДУСЛАРЫБЫЗ БӘЙРӘМЕНДӘ

Чуашстан Республикасы башкаласы Чабаксарда чуаш язучылар оешмасы төзелүгә 80 ел тулуга багышланган тантаналар булды. Биредә Мәскәүдән, Казан, Түбән Новгород, Ульяновскидан һәм башка төбәкләрдән кунаклар килде. Татарстан делегациясендә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, шагыйрь Ренат Харис бар иде.

Чуаш язучылары форумы эшендә республиканың Президенты Н. В. Федоров катнашты һәм чыгыш ясады. Иҗади оешманың җитәкчесе Валерий Тургай оешманың 80 еллык эшчәнлеге турында сөйләде. Ул чуаш әдәбияты үсешенә татар коллегаларының уңай йогынтысын билгеләп үтте.

Татарстан делегациясе Президент М. Ш. Шәймиевнең чуаш язучыларына котлавын һәм Казан Кремле сурәте төшерелгән келәм тапшырды, чуаш коллегаларын 2004 елның язында Татарстанда булачак чуаш әдәбияты көннәрендә катнашырга чакырды.

Кунаклар әдәбият музеенда, Яңа Чабаксар шәһәренең истәлекле урыннарында, Шоршеле авылында, космонавт А. Николаев музеенда булдылар.

## СӘЛИМҖАНОВ ИСЕМЕНДӘГЕ АЙ

Татарстан Президенты М. Шәймиевнең быел чыгарган Указында болай диелә: Россиянең халык артисты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Россия Федерациясенең К. Станиславский, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты, күренекле театр эшлеклесе, режиссер һәм педагог, профессор Марсель Хәким улы Сәлимҗановның истәлеген мәңгеләштерү максатында, аның җәмгыять һәм дәүләт алдындагы хезмәтләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Театр эшлеклеләре берлеге тәкъдимнәрен, иҗат зыялылары һәм җәмәгатьчелек вәкилләре мөрәҗәгатьләрен хуплап, карар бирәм: Актерлар йортына Марсель Хәким улы Сәлимҗанов исемен бирергә һәм киләчәктә аны "Марсель Сәлимҗанов исемендәге Актерлар йорты" дип атарга.

## ГАДЕЛ КУТУЙ ОНЫТЫЛМЫЙ

К. Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театрында язучы Гадел Кутуйның 100 еллыгына багышланган кичә үтте. Аны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин ачып җибәрде, язучының тормыш юлы белән таныштырды. "Япь-яшь килеш безнең арадан китсә дә, аның иҗат яктылыгы озак елларга бара",— диде ул. Аннары Г. Кутуйның улы шагыйрь Рөстәм Кутуй сүз алды. Кичәгә әдипнең туган ягы—Пенза өлкәсе, Новокузнецк районы Татар Кынадысы авылыннан да кунаклар килде.

Казан Яшь тамашачы театры артистлары язучының әсәрләреннән өзекләр, шигырьләр укыдылар. Татарстанның атказанган артистлары Рафаэль Сәхабиев, Рөстәм Маликов, Татарстанның атказанган артисткасы Флюра Сөләйманова, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Мәсгут Имашев, Россиянең

һәм Татарстанның халык артисты Айрат Арсланов, Рамил Миндияр кебек талантлы сәхнә осталары, Харис Нигъмәтҗанов җитәкчелегендәге уен кораллары оркестры катнашуы кичәне тагын да күркәмләндереп җибәрде. Байбулат Батуллинның "Рөстәм мажаралары" повестеннан өзек укуын тамашачы көчле алкышлар белән каршы алды. Залда язучының кызы Гөлшат һәм фронтта Г. Кутуйны күреп белгән, бүгенге көндә исән-сау Шакир Абилов та бар иде.

Кичәне Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлеге оештырды.

* * *

Гадел Кутуй юбилее аның туган ягы— Пенза өлкәсенең Татар Кынадысы һәм Бистә авылында да билгеләп үтелде. Юбилей мөнәсәбәте белән бу якларга Казаннан бер төркем әдәбият-сәнгать вәкилләре килде. Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин җитәкләгән делегация составында язучылардан—Җәүдәт Дәрзаман, Флера Тарханова, Рәдиф Сәгъди, галимә Розалина Нуруллина, артистлар— Рамил Миндияр, Гөлшат Имамиева һ. б. бар иде. Алар авыл халкы һәм мәктәп укучылары белән очраштылар. Бу очрашуларны оештыруда Кузнецк районы хакимияте башлыгы урынбасары Фәридә Курмаеваның хезмәте зур булды.

## ЯШЬ ПИАНИСТЛАР БӘЙГЕСЕ

Казанда яшь пианистларның Н. Җиһанов исемендәге II республика конкурсы үтте. Аны Татарстан Мәдәният министрлыгы, мәдәни һәм сәнгати уку йортлары буенча республика методик кабинеты, Н. Җиһановның мемориаль музей-фатиры, Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе оештырды. Казан, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама, Бөгелмә, Алабуга һәм Татарстанның башка шәһәрләреннән һәм районнарыннан килгән яшь башкаручылар Н. Җиһанов музеенда булып, композиторның тормышы һәм иҗаты турында бәян итүче кызыклы материаллар белән таныштылар. Кайберләренә хәтта композиторның роялендә аның әсәрен башкару бәхете дә елмайды. Конкурсның лауреатлары һәм дипломатлары катнашындагы йомгаклау концерты С. Сайдәшев исемендәге Зур концерт залының камера залында булды.

## ШАГЫЙРӘ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Әлмәттә район һәм шәһәр хакимияте, "Татнефть" ачык акционерлар җәмгыяте, Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге, Әлмәт дәүләт нефть институты химаясендә Сажидә Сөләйманова иҗатына багышлап "Исәнме, тормыш!" дип исемләнгән ачык студентлар фестивале узды.

Фестиваль С. Сөләйманова һәйкәленә чәчәкләр куюдан башланып китте. Аннары ай дәвамында жюри конкурска килгән эшләрне (гыйльми хезмәтләр, әдәби, музыкаль, сынлы сәнгать әсәрләре, фотосурәтләр) карады.

Ниһаять, ел ахырында нефть институтының актлар залында йомгаклау кичәсе булды, 6 номинация буенча призлы урыннар билгеләнеп, 50 ләп студентка Мактау грамотасы һәм бүләкләр тапшырылды.

Әлеге кичәдә Казаннан Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин җитәкчелегендәге бер төркем язучылар, сәнгать әһелләре дә катнашты. Алар арасында Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары Шаһинур Мостафин, шагыйрьләр Әхмәт Рәшит, Шәмсия Җиһангирова, шагыйрь һәм прозаик Марсель Галиев, прозаик Камил Кәримов, Татарстанның халык артистлары Рафаэль Сәхабиев һәм Рамил Курамшин бар иде. Әлеге фестивальне үткәрүгә Әлмәт дәүләт нефть институты ректоры, профессор Александр Емекеев, проректор, социология фәннәре докторы, профессор Рәсимә Рәхимова, институтның мәдәният һәм ял итү үзәге директоры Людмила Волдавина зур өлеш кертте.

## ЗУР ХЕЗМӘТЕН БӘЯЛӘП

"Пирамида" мәдәни-күңел ачу үзәгендә "Бөтендөнья татар конгрессы", Халыкара иҗтимагый берләшмәләре берлеге башкарма комитеты уздырган ел йомгакларына багышланган кичәдә Россиядә һәм чит илдә яшәүче татар оешмалары вәкилләре катнашты. Шул тантанада милләттәшебез, Казакъстан Табигый Фәннәр академиясе академигы, атказанган сәнгать эшлеклесе, "Почет билгесе" ордены кавалеры, Франция сәнгать академиясенең көмеш медале иясе, СССРның Рәссамнар берлеге әгъзасы Камил Вәлиәхмәт улы Муллашевка милли сәнгатебезне үстерүдәге хезмәтләре өчен Татарстанның халык рәссамы исеме бирелде. Бүләкне ТР Президенты Минтимер Шәймиев тапшырды.

Ел ахырында Казан милли мәдәният үзәгендә күренекле рәссамның зур күргәзмәсе булып узды.

## КҮРГӘЗМӘ ЗАЛЛАРЫНДА

Үткән айда Рәссамнар берлегенең күргәзмәләр залында Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, ТР Милли музее баш рәссамы Фаил Зыязовның һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Канәфи Нәфыйковның хезмәтләре куелган күргәзмәләр булып үтте.

Фаил Зыязов күркәм пейзажлар һәм натюрмортлар иҗат итү белән утыз елдан артык мәшгуль. Музей экспонатлары белән эшләү дә аның иҗатында урын алган: көнкүреш, милли кием, бизәнү әйберләре аша ул борынгы тормышны, бабаларыбызның гореф-гадәтләрен тасвирлый.

Канәфи Нәфыйков иҗатында исә тарихи темаларны чагылдырган сюжетлар өстенлек итә.

Сынлы сәнгать әсәрләрен иҗат итүдән тыш, авторлар музей һәм театр өлкәсендә рәссам сыйфатында да зур хезмәт куялар. Фаил Зыязов республика музейларын сәнгатьчә бизәү буенча эшли, экспозицияләр һәм күргәзмәләр оешты-

руда катнаша. Канәфи Нәфыйков республиканың байтак театрлары спектакльләренә декорацияләр ясавы белән дә мәгълүм рәссам.

### ГАЛИМ ЮБИЛЕЕ

Йөз еллыгы уңаеннан, 17 декабрьдә күренекле әдәбият галиме Мөхәммәт Хәйрулла улы Гайнуллинга (1903-1985) туган җирендә—Апас районының Кызыл Тау авылында сынчы Фәһим Фәсхетдинов тарафыннан эшләнгән бюст куелды. Исеме исә урта мәктәпкә бирелде. Мондагы бер бүлмәдә музей да булдырылды.

Казандагы "Апас" якташлык җәмгыяте җитәкчесе журналист Хәлим Гайнуллин тырышлыгы белән оештырылган әлеге тантана Апас районы халкы өчен зур бәйрәмгә әйләнде.

### КЫРЫМ ТАТАРЛАРЫ НИЧӘҮ?

Соңгы халык санын алу нәтиҗәсенә караганда, Россиядә 4 мең 149 кырым татары яши. Әйтергә кирәк, элекке җанисәп нәтиҗәләре белән чагыштырганда, бу сан күпкә кимегән, чөнки кырым татарлары соңгы елларда үз тарихи ватаннары—Кырымга күченеп кайтты.

Кырымда хәзер 270 мең кырым татары яши, ягъни ул Кырымдагы барлык халыкның 12 проценты дигән сүз. Төрле сәбәпләр аркасында 150 мең кырым татары хәзергәчә Урта Азиядә яшәп кала бирә. Ләкин аларның күпчелегенең Кырымга кайту теләге зур, әлбәттә. Бу теләкнең тормышка ашырылуы әлеге дә баягы икътисадка бәйле. Төркиядә бүгенге көндә 5 миллионга якын кырым татары яши. Румыниядә—70, Болгариядә—20, ә АКШта 7 мең кырым татары бар.

### ФИЛАРМОНИЯДӘ ЯҢА ҖИТӘКЧЕ

Мәдәният министры Илдус Тарханов карары белән Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе директоры Әсгат Зөфәр улы Сафин үз вазифаларыннан азат ителде.

Аның урынына Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры урынбасары булып эшләгән Кадим Назир улы Нуруллин билгеләнде. Ә. Сафин филармониянең концерт залын җитәкләячәк.



## КОЯШ ТИМБИКОВА

2004 елның беренче көннәрендә танылган язучы, Татарстанның һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Журналистлар берлегенең Хөсәен Ямашев исемендәге премия лауреаты **Кояш Закир кызы Тимбикова** 66 яшендә вафат булды. Кояш Тимбикова Татарстанның Чистай районы Наратлы Елга авылында туып үсә һәм шунда урта белем ала. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаганнан соң бөтен гомерен журналистикага, әдәбиятка багышлый. Ул озак еллар—егерме ел дәвамында "Азат хатын" (хәзерге "Сөембикә") журналында эшләде.

Кояш Тимбикованың беренче язмалары матбугатта 1959 елда ук күренә башлый. Аннары бер-бер артлы хикәя, повесть җыентыклары дөнья күрә. Археологлар тормышына багышланган "Тәңкәле тау", КамАЗ төзүчеләр тормышыннан "Агым уртасында" җыентыклары укучылар күңелен яулап алды. Кояш Тимбикованың журналист тормышы да бик актив иде. Ул—илебезнең күп төбәкләренә барып җитә алган журналист. Кояш Тимбикова—"КамАЗ төзелеше ударнигы". Аны БАМны төзүчеләр дә яхшы белә иде. Әсәрләре рус, башкорт телләрендә дә дөнья күрде.

1979-93 елларда Кояш ханым безнең журналда эшләде, бүлек редакторы һәм җаваплы секретарь вазифаларын башкарды, татар әдәбиятында очерк һәм публицистика жанрларын үстерүдә зур өлеш кертте. Төп әдәби әсәрләре дә иң әүвәл безнең журналда дөнья күрде. Ул туры сүзле, егет характерлы, әйткән сүзен төгәл үти торган, шул ук вакытта нечкә күңелле, шәфкатьле кеше иде. Аның якты исеме безнең күңелләрдә озак сакланыр.

*«Казан утлары» хезмәткәрләре*

## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Мәҗлес». Шәрыкъ миниатюралары остасы **Сергей Широков** рәсеме. Язучы Рауль Мирхәйдәров коллекциясеннән.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрь **Нияз Акмал**.

# КАЗАН ШӘҺӘРЕНӘ—1000 ЕЛ

*Панаев театры*



*«Динамо» стадионы*




Үткәнебез һәм бүгенгебез. Бер үк ноктадан бер гасыр аерма белән төшерелгән фоторәсемнәр.

*Хаҗи Абдулла Дубин коллекциясеннән.*

Индекс 73210



Нияз Акмал

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)